ISSN 0206—4189



# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1985

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгына*



# Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

**Татарстан Язучылар союзын**
**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының**
**Мактау грамотасы белән бүләкләү турында**

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм оештырылуына 50 ел тулу уңаеннан Татарстан Язучылар союзын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләргә.

**Татарстан АССР Верховный Советы**
**Президиумы Председателе Ә. БАҺАВЕТДИНОВ.**
**Татарстан АССР Верховный Советы**
**Президиумы Секретаре Д. ДӘҮЛӘТШИНА.**

Казан, Кремль, 1984 ел, 7 декабрь.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

2

1985

## Бу санда

С. ХӘКИМ. **Тукайга.** Шигырьләр . . . . . . . . 3
Ә. ЕНИКИ. **Соңгы китап.** . . . . . . . . . . 10

ДУСЛАР ЖЫРЫ

О. СУЛЕЙМЕНОВ. **Куып тот!** Шигырьләр. . . . . 71

Р. НИЗАМИЕВ. **Урман эчләрендә урман.** Повесть . . 73
Ф. САФИН. **Таң.** Шигырьләр . . . . . . . . . 97
Х. ӘЮПОВ. **Гамәл дәфтәре.** Шигырьләр . . . . . 102

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

Р. ФӘИЗОВ. **Ике тапкыр ветеран.** Хикәя . . . . . 106

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. АКМАЛОВ. **Җыр елгасы.** Шигырьләр . . . . . 113
Г. СӘЛИМОВ. **Кафедагы песи.** Шигырьләр . . . . 117

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ, **Уральскида Тукай урыннары.** . 119

Р. ХИСМӘТУЛЛИН. **Тамырлар тибеше** . . . . . . 120

З. НУРИ. **Яшел диңгездәге кояшлы утрау** . . . . 129

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

М. ХӘСӘНОВ. **Шигъриятнең саф, раушан көзгесе** . 132
Г. ЛОМИДЗЕ. **Сүнмәс нур** . . . . . . . . . . 139
С. ХӘКИМ. **Буыннар авазы** . . . . . . . . . 141
И. ГЫЙЛӘҖЕВ, А. ЛИТВИН. **Россиядәге 1905—1907 еллар революциясе Казанда** . . . . . . . . 143

Д. ВӘЛИЕВ. **Мәңгелеккә сәяхәт** . . . . . . . 148
А. ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА, Х. ГАТИНА. **Җәлил турында истәлекләр** . . . . . . . . . . . . . . 154

КПССНЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

БИБЛИОГРАФИЯ

С. АЛИШЕВ. **Болгар-татар тарихына яңа китап** . . . 158
М. ГАЙНЕТДИНОВ. **Татар хрестоматияләре** . . . 159
Х. МӘХМҮТОВ. **Исемнәр — тарих хәбәрчеләре** . 161
М. ФӘЙЗУЛЛИН. **Сәнгатькә юл ярганда** . . . 163
**Бер сорауга — бер җавап** . . . . . . . . . 172

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Г. ГЫЙЛМАНОВ. **Кояшлы шигърият** . . . . . . . 173

ИЛЬҺАМ ШАКИРОВКА 50 ЯШЬ

ҖЫРЛАП ЯШӘРГӘ! . . . . . . . . . . . . . 178

КЫЗЫКЛЫ ХӘЛЛӘР . . . . . . . . . . . . . 186

КУЛЬТУРА ТОРМЫШЫ КӨНДӘЛЕГЕ . . . . . . 188

КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ (Н. Лаисов, Р. Рәкыйпов, Н. Хисамов) . . . . . . . . . . 191
ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ** *(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФӘҮЕС МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Повесть **А. ЕНИКИ** «Последняя книга».
Стихи **С. Хакима**. Повесть **Р. Низамиева**, стихи **Ф. Сафина**, **Х. Аюпова** и других.
На конкурс «Подвиг продолжается» рассказ **Р. Фаизова** «Дважды ветеран».
К 100-летию Тукая: рисунок **Т. Хазиахметова** из серии «Тукаевские места в Уральске».
Очерк **Р. Хисматуллина**, посвященный проблемам охраны природы.
Статья **З. Нури** о Марийской АССР.
В рубрике «К истории литературы» статьи **М. Хасанова, Г. Ломидзе** и **С. Хакима**, посвященные творчеству основоположника булгаро-татарской литературы Кул Гали.
Статья **И. Гилязева** и **А. Литвина** «Революция 1905—1907 годов в Казани». Статья **Д. Валеева** «Три путешествия в вечность». Воспоминания о М. Джалиле.
В рубрике «Библиография» рецензия на книги: «Булгаро-татарская монетная система XII—XV вв», «Татарские хрестоматии XIX века» и «Словарь татарских имен».
Отрывки из документального произведения о композиторе Дж. Файзи.
В номере отмечаются юбилеи Ш. Бабич (90 лет), И. Шакирова (50 лет).
«Занимательные истории», «Дневник культуры», «Вновь принятые члены Союза писателей СССР».
На наших обложках: творчество художника **И. Рафикова**.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производстога бирелде 14. 12. 1984 ел. Басарга кул куелды 12. 2. 1985 ел. ПФ 04150. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64100. Заказ К-451. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1985 ел.

# Сибгат Хәким

## Тукайга

Күрдем гомеремдә бу җирнең
Күп төрле шагыйрьләрен.
Сиңа табынган шикелле
Беркемгә табынмадым.
Синнән башланды татарда
Шигырьдә шаулы гомер.
Башка беркемнән дә түгел,
Тик синнән шагыйрьлегем.
Телем дә синең «Туган тел»,
Иманым — синең иман.
Сине тудырган халыкның
Алдында башым иям.

1984. Трускавец.

●

Тукайдан соң да бу тормыш
Бер минут тукталмады,
Узды бу җирнең өстеннән
Шаукымлы Туфаннары.

Ике сүз — ике бөеклек,
Әйтерсең, юри Туфан
Сайлаган язмыштан бары
Үзенә тиң сүзне: «Җиһан».

1984. Трускавец.

●

Казынмыйм чүптә, уемда
Бүгенге тормыш, ил-көн,
Язу өстәлем — сугышкан
Кырларым кебек иркен.

Кирәксә җир сөрә беләм,
Атны тугара беләм.
Язам, каләм белән түгел,
Язам Дугалар белән.

1984. Трускавец.

❁

«Шүрәле» балеты авторы
Ф. Яруллин истәлегенә.

Ике рота командиры,
Икебез дә Дугада;
Таң белән кыңгыравына
Кемдер китереп суга да
Кайнарга керешә җәһәннәм,
Ике ара мең адым,
Бәрелеп минем блиндажга
Тора иде моңнарың.

Ике рота командиры,
Ике моңлы лирикның
Хисләре ике канаты
Кебек иде ирекнең.

Авыр сугышлары барган
Көннәрендә Дуганың,
Ишеттем урманда шыңшып
«Шүрәле»нең елавын.

Бар минем халкымда моңнар.
Һәр моң бер гасыр кебек,
Йөртәсең җаныңда асрап
Әнкәң догасы кебек.

Нинди зур бәхет: Дугада
Калган булсаң үлмичә,
«Шүрәле» үлемсезлеге
Җиткән иде югыйсә.

10 июль, 1983.

❁

Һәр йорт каршында бер тополь,
Сөйләшәләр таңда лепердәп,
Ялгыз калган авыл карчыклары
Утыралар төсле җеп эрләп.

Һәр йорт каршында бер тополь,
Әйтерсең лә безнең әниләр
Узган сугыштагы улларына
Тезелешеп оек бәйлиләр.

Һәр йорт каршында бер тополь,
Яшел яулык — яшел ябалдаш.
Күп булса да яшел яфраклары,
Яраларны алар ябалмас.

Һәр йорт каршында бер тополь,
Шыксыз җилләр ишек кагалар,
Кулдан төшкән җылы бияләйләр,
Оекбашлар, җепле кабалар...

1984

*

Трускавец. Курортта үзем,
Үткәннәр белән яшим.
Ачлык ел шушы якларга
Юл тотып, әти, Рәхим
(Рәхим ул абый, күп булса
Ундүрт яшь, чандыр малай,
Гомеремнең ахрына тикле
Сызланып сагыныр малай).
Чыкканнар килеп, эш эзләп,
Ил буйлап язмыш сипкән,
Балталарына эш тапмый
Үлгәннәр ачтан, тифтән.
Шулар йөрәгемнән китми,
Тамактан үтми сыньк,
Карыйлар шикелле күзгә
Ашаганда ымсынып.
Ялым ял түгел, кайгыдан
Әйләндем мин сырхауга,
Күзем әз генә йомсам да
Баса узган чор алга.
Минем күз алдында көн-төн
Ике тын шәүлә йөри,
Минем бу җиргә килгәнне
Әйтерсең, шәйләп йөри.
Мин хаста, кайда күңелнең
Бәхетле, якты чагы?
Көнгә өч тапкыр эчсәм дә
Мактаулы «Нафтуся»ны,
Файдасыз, ятам бүлмәмдә
Берәзлексез җан елый,
Ә тышта гүя ярышып,
Шат авазлар яңгырый,
Хисләрдә ярыша яшьлек,
Аның саен Рәхимне,
Сагынам әтине, кабул ит,
Дала, кайнар яшемне.

1984. Трускавец

## Тәбикмәк

Әллә бар ул, әллә юк хәзерге
Яшь, тук буын өчен тәбикмәк.
Ачлык елны менә шул тәбикмәк
Язмышымны минем хәл итмәк.
Яраттым мин балта осталарын,
Чәер исле алъяпкычларын,
Сизми калдым шулар тирәсендә
Сабый гомерем алга очканын.
Әтиләр йорт салды берничә пот
Бәрәңгегә мари-бәлешкә.
Йомычкалар арасында ялгыз
Утырам уйнап, кермим мин эчкә,
Көндезге чәй, мин бит артык тамак,
Бүтәннәргә бары мин имгәк,
Онытмаган әти, кырган башка
Чәпәгән дә кайнар тәбикмәк,
Бүреген киеп, минем янга чапкан
(Бер сүз дә юк урлау хакында).
Елады ул олыларча үксеп,
Үзе өйгән бура артында.

Үлгәндә дә хәтеремнән чыкмас
Шул вакытта минем курыккан,
Елады ул баш пешкәннән түгел,
Оятыннан, гарьлек, хурлыктан.
Әллә бар ул, әллә юк хәзерге
Яшь, тук буын өчен тәбикмәк.
Ачлык елны менә шул тәбикмәк
Язмышымны минем хәл итмәк.

Октябрь, 1983.

Бар Казанда бер мәгариф йорты,
Бик файдалы нәрсә мәгариф.
Сез уйлыйсыз инде бу ай саен
Укыр өчен шунда бара дип.

Юл өстендә завод, көн дә безне
Тукландырган ипи заводы.
Мин бит — авыл... Арыш арасыннан...
Сез беләсез минем зәвыкны.
Бала чакларыма китә алып
Шул заводта пешкән кабартма.
Кабартмамы, мәгарифме—кайсы
Хисләремне минем агарта?

Завод каршындагы урындыкта
Утырам озак, иртән сабакка
Бармый калган сабый бала кебек,
Авыл миче, әнкәй, кабартма
Хыялымнан чыкмый, онытылам
Мин бит — авыл, Авыл кешесе,
Укудан ни — белмим, күңелемдә
Кабартманың калды хуш исе.

1984.

## Көз

Көз көз инде. Уйлар-хисләр башка,
Язар шигырь башка, көй башка.
Ятам кырда салам кибәнендә
Йөзне куеп көзге кояшка.
Үрдә юллар... Җитмеш яшьлек гомер...
Ачлык, сугыш... Кайда ул рәхәт...
Сугышып узган урыннарга сәфәр
Һәм Европа буйлап сәяхәт.
Үрдә юллар... Иҗат, әдәбият.
Язганнар күп, ачыш — сынаулы.
Бүген мин бар җәнҗаллардан азат,
Ятам, аста арыш саламы.
Үрдә юллар... Җитмеш яшьлек гомер...

Укучылар нидер көтә күк.
Камыл исе, төчкелт арыш исе,
Ятам кырда суккан көлтә күк.

Ятам кырда җаным-тәнем белән
Шушы җиргә рухи берегеп.
Күзге сүрән кояш яктысында
Тонык кына кабына бер өмет.

Сентябрь, 1983.

## Нигез

— Бу нинди зират?
— «Өчиле» зираты...
— Ә «Өчиле»?
— Булган. Хәзер юк. Җир белән
Тигезләнгән исеме.
— Бу нинди көтү?
— Күрше авыл көтүе...
Өркер төсле,
Көтүче кабер ташында
Утыра бөркет төсле.
Көтүен куып китергән
Монда ни пычагыма?
Сыерлар үкерә нигезнең
Басып дүрт почмагына.
Яшәгән, гомер кичергән
Әллә ун буын монда.
Әйтче, ни мәгънә кешесез
Чишмәләр ургуында?

Казан елгасы буенда
Сырмаларын көз сырган
Балан — авыл таралганда
Качып калган кыз сыман.

Нинди эчпошыргыч бушлык
Югалтса җир кешене...
Бу нинди авыл?
— Бу, туган,
Арча ягы «Өчиле».

Октябрь, 1983.

## Гөберчәк

Чакрып торган зәңгәр хыял идең,
Бар икән бер сине күрер чак.
Торналарның көзге моңын тыңлап,
Кырларыңнан уздым, Гөберчәк.
Кызыктырып, салам кибәнендә
Мәтәлчекләр атына бер сабый,
Синдә үскән малайларның исеме
Я Мөхәммәт, яки Курсави.
«Кеше китә — җыры кала», дидең.
Моңы кала, дидең, Гөберчәк.
Шул «Торналар төшкән җир»дә яшәп,
Хезмәт итеп узган гомер шәп.
Тартты мине көзге моңсу зират,
Тартты һәр таш, кабер, чардуган.
Кырыкбердә туганнарның моңы
Каеннарга килеп сарылган.
«Кеше китә — җыры кала», дидең,
Эше кала, дидең, Гөберчәк.
Ә бездән соң? Бер уй борчый мине;
Калырмы җыр бер көн без үлсәк?

«Кеше китә — җыры кала», диден,
Сәрә, чәчә җирне Кәшфиләр.
Зираттагы өрәңгеләр генә
Тора тып-тын, берни дәшмиләр.
Курсавилар һәм Тукайлар даны
Кырларыңа яткан, Гөберчәк.
Синең туфрак — нигез бәхетле дип,
Горурланып безнең йөрер чак.

Сентябрь, 1983.

❁

*Миркасыйм Госмановка.*

Икенче бер илдән бабаларың
Нигезенә кайттың, Миркасыйм.
Иң беренче тапкыр очрашканда
Ят тоелдың никтер миңа син.
Төсең-битең искә төшерсә дә
Кыяфәтен усал Чыңгызның,
Җимермәдең ләкин, фәндә бөек
Кол Галиләр данын торгыздың.
Шиһаб хәзрәт варисларын күреп,
Горурланып, сөенеп мин яшим,
Котлыйм изге туфрагыңда кабат
Туган көнең белән, Миркасыйм.

27 май, 1984.

❁

*Р. Моранга.*

Сине рәнҗетүем түгел,
Рувим, миңа рәнҗемә,
Минем тәрҗемәи хәлне
Итеп булмый тәрҗемә.
Сиңа тигез рифма кирәк,
Күлмәк булсын җитеннән,
Минем тәрҗемәи хәлем
Тора үлем-җитемнән.
Тора бөлгенлек-ачлыктан,
Тора ятимлегемнән,
Тора сугыштан, блокада,
Абыем әсирлегеннән.
Тора таныш Җәлилләрдән
Куллары богауланган,
Тора Ватан сугышына
Тиң бөек елаулардан.
Фаҗига болай да бик күп,
Күбесен эчкә йотам,
Тапшырам теге дөньяга
Тапшырган кебек Туфан.

1984. Трускавец.

❁

Март ае. Кояш. Кар зәңгәр.
Күк йөзе чиста — зәңгәр.
Калын кар астына кереп
Кышлаган чишмә зәңгәр.
Рәхмәтем әйттем тормышка
Мин шундый кышны күреп,
Чишмәкәй — зәңгәр песекәй
Тырышып мышный кебек.

1984. Трускавец.

●

Шәһәрдә күзгә бернәрсә
Күренми, ел узганы
Сизелми, авылда калка
Бала чак йолдызлары.

Йолдызлар кайда күбрәк,
Кайсы өй турысында?

Яналар кай төштә, охшап
Чиләге тулы суга?

Мөлдерәп, түгелер-түгелмәс,
Әллә авыл бетә дип,
Йолдызлар тора ташландык
Нигезләргә текәлеп...

1984. Трускавец.

●

Уникенче йөз. Болгар көзгесе.
Чая карашлы дүрт якта дүрт кош.
Кадерле мирас, канатлы мирас,
Сөенәм: ничек тимәгән ут-күз.
Идел өстендә талпынып алар,
Нәкъ сигез гасыр килгәннәр очып,
Давыл һәм җилне ярып чыныккан
Канатларында «Кыйссаи Йосыф».
Җир шары кебек Болгар көзгесе,
Омтылган күккә дүрт якта дүрт кош.
Әй, бөек, сәнгать, канатлы сәнгать,
Нинди илаһи бәхетле очыш.

Октябрь, 1983.

●

Иске кабер ташларында сүзләр
Чорналганнар — урман-чытырман.
Ятларга ят, миңа газиз, якын
Тарихым бар, туган йортым бар.

Сүзләр-юллар, сүзләр бер-берсенә
Үрелеп менгән зәңгәр үрләр күк.
Ничек булса, шулай кабул иттем,
Тарихымны кормыйм үзгәртеп.

Узганымны минем хәтәр, диләр,
Үткәннәрдән бүген хәвеф күп.
Калыйм җирдә үрелеп, иске кабер
Ташларына язган хәреф күк.

Октябрь, 1983.

Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

ӨЧЕНЧЕ ӨЛЕШ

## СӘХИФӘЛӘР[1]



Егерме беренче елның рәхимсез корылыгыннан соң килгән егерме икенче ел җәе гаҗәпләнеп бетмәслек һәм сокланып туймаслык булды. Менә алтмыш елдан артык инде мин аның кебек җәйнең килгәнен белмим, хәтерләмим... Күпмедер охшаганы булгандыр, бәлки, әмма теге җәй шикелле күңелдә сакланып калганы истә юк. Ихтимал, бик зарыгып көтеп алганга күрә ул безгә шулай гадәттән тыш ямьле, ягымлы, бәрәкәтле булып күренгәндер дә?.. Юк, аның өчен генә түгел!

...Ничегрәк килде соң ул егерме икенче елның җәе?.. Язлар җитеп, кошлар килгәч һәм җир яшәргәч, майның урталарыннан ук көннәр ничектер озакка утырды. Көндезләрен җилсез-аяз, ә төннәрен җылы яңгыр явып үтә. Бу һәркөнне диярлек шулай кабатлана — кичтән күк читендә болытлар кабара, төнлә ашыкмыйча гына килеп, шифалы яңгырын сеңдереп кенә коеп китә, ә иртән күк йөзе офыктан-офыккача чалт аяз, дөнья тагын ялт иткән! Кояш тигез генә кыздыра, кура селкенерлек тә җил юк, ә җир рәхәткә талгандай тирләп, парланып ята. Агачлар, үләннәр, чәчкән-утырткан нәрсәләр барсы да парниктагы шикелле күзгә күренеп үсә-күтәрелә... Әнә шундый җәй килде ул елны тәмам арыккан, интеккән табигатькә һәм бөтен җан ияләренә!

Безнең ишегалды электән үк тап-такыр иде, менә шул такырны да бәбкә үләне басып китте. Моңарчы шәрә яткан яки сирәк кенә кылган үскәләгән тау түбәләрен дә тездән куе үлән каплады. Былтыр чәчелеп тә чыкмый калган урыннарда арыш һәм бодай күкрәп үсте. Безнең якта үзеннән-үзе әнә шулай үсеп киткән арышны —«ту арыш», бодайны — «ту бодай» диләр. (Яңадан туган мәгънәсендә булса кирәк.)

Ачлыктан кипкән, бетеренгән халыкның авызы, ниһаять, табигать биргән беренче ризыкларга тиде. Башта, тугайлар ачылгач та, төче юа, кузгалак бик күп булды, шунда ук койма-читән буйларын яшь кычыткан каплап алды, аннары озак та тормый якын урманнарда какы, балтырган өлгерде. Болар барысы да ризык иде. Инде табигатьнең шушы һәм тагын күп кенә нигъмәтләренә ялганып, кеше үзе чәчкән-утырткан азыклар да бер-бер артлы әкренләп өлгерә башлады. Кыскасы, халык ачлыктан чыкты, ачтан үлү куркынычы бетте.

Әмма бу гаять матур килгән бәрәкәтле җәйдә дә өс-башлары тетелеп беткән ач хәерчеләр, керләнеп беткән арык ятим балалар («беспризорниклар») бик күп иде әле. Хәерчеләргә оя кирәк, эш кирәк, шуларны тапканнан соң гына алар Дәүләкән урамнарында күренми башладылар. Тик хәер сорашуны кәсеп итеп алганнары гына һаман йөриләр иде әле, ләкин тора-бара андыйлары да бик аз калды. Ә ятим балаларга килгәндә, аларның вакларын власть органнары җыеп алдылар, зурраклары исә Дәүләкәнне ташлап, Уфа яки Самара якларына китеп бардылар бугай. Дәүләкәннең Габдулла исемле бер малае да шуларга ияреп киткән дип ишеттек. Бу Габдулланың гыйбрәтле тарихы бар, җае чыкса, бәлки, сөйләрмен дә әле.

Гаҗәп, миңа да Дәүләкәннән китәргә өч кенә ел калган икән инде. Ә нәрсә ул өч ел?— күз ачып йомганчы үтә дә китә. Без хәзер ун-унбиш елның үтеп киткәнен дә сизмичә калабыз, шушы еллар дәвамында күргәннәребез дә бик сыек, сөйлим дисәң, рәтләп сөйләр нәрсә дә юк. Ә менә Дәүләкәндә торасы калган өч елым шактый ук озын да һәм күргән-кичергәннәргә бик бай да булган икән. Бу бит, дусларым, житмештән житмеш өчкә житү түгел, ә унөчтән уналтыга житү — бу бит бөтенләй башка!.. Малайлыктан чыгу, балигъ булу — менә нәрсә ул минем өч елым... Һәм моның нинди үткен-тирән кичерешләр белән бәйләнгәнен, шәт, үзегез дә бик яхшы беләторгансыздыр...

. Хуш, ничегрәк дәвам итим икән күргән-кичергәннәрне?.. Кыска вакыт, озын яшьлек... дигәндәй, шул санаулы гына елларда күргәннәр бик күп — кайсыннан башларга?.. Ярый, вакытның үзенә ияреп барыйк әле, шулай итсәк, бәлки, дөресрәк тә булыр.

...Менә ачлыктан соң килгән гаҗәеп җәйне сөйләдем мин... Шушы җәйдән илдә туклык башланды. Ләкин зарыгып көткән туклыкны табигать кенә түгел, тормыштагы көтелмәгән зур үзгәреш тә китерде: бу үзгәреш нэп дигән яңа бер нәрсә иде — без менә шуның гаять хикмәтле чорына кердек. Нэпның нәрсә икәнен, кем аны зарури табып, гамәлгә керткәнен барыбыз да тарихтан беләбез, шуңа күрә мин аны илебез тормышында нинди зур роль уйнаганын монда язып тормыйм. Минем бары Дәүләкәндәге нэп турында гына сөйлисем килә — үз күзем белән күргәнне, үзем белгәнне генә.

Мәгълүм булганча, нэп хосуси сәүдәгә киң юл ачты. Патент ал да сату итә башла — полный рөхсәт!.. Бер ел үттеме икән, Дәүләкәндәге моңарчы ябык торган кибет-магазиннар ачылып бетте диярлек (кай арада һәм кайдан товары табылган?). Бу коммерция шаукымы бик күпләрне һәм бик тиз үзенә тартып алды. Элекке «купичлар»ны әйткән дә юк, сәүдә алар өчен хәләл кәсеп, бу көнне алар, билгеле инде, көтеп кенә торганнар. Шулай ук элекке приказчикларның да күбесе җиң сызганып сату итәргә кереште. Мәсәлән, биш приказчик, бер сәүдәгәр «Алга» ширкәте төзеп, Басыйр купецның ике катлы магазинында эш башлап җибәрделәр. Тиз арада «Алга» чынлап та бик алга китте, Дәүләкәндәге иң эре сәүдә фирмасына әйләнде. Элекке сәүдәгәр һәм приказчиклар гына түгел, моңарчы сәүдәнең нәрсә икәнен дә белмәгән кайбер кешеләр дә, хәтта үсмер малайлар да «җиңел табыш»ка кызыгып, вак-төяк белән аяк өсте генә булса да сату итәргә тотындылар.

Гомумән, алу-сату, алыш-биреш эшләре бик җәелде, бик көчәйде, базарлар бик җанланды, авылдан һәртөрле азык-төлек күпләп керә башлады, чәйханәләр һәм сыраханәләр ачылды, пекарнялар күпереп торган ап-ак калач, булочниклар (мәсәлән, Эрлих дигән немец булочные) төрле тәмле нәрсәләр пешереп чыгарырга кереште, шул ук немецлар сыр, май, колбасалар эшләп чыгара башладылар. Шәймөрат башкорт бал коеп сатарга тотынды, ә кымызны инде әйткән дә юк — һәркөнне Көрмәнкәйдән, Акколайдан, Шәриптән китереп кенә торалар.

...Каяндыр кытайлар килеп чыкты. Беришеләре, бигрәк тә кеп-кечкенә сабый аяклы хатыннары, төрле төстәге махсус кәгазьләрдән чәчәкләр һәм башка бик матур әкәмәт нәрсәләр ясап саттылар, беришеләре исә ачык прилавкаларда тимер аршиннарын уйната-уйната ситса һәм ефәк белән сату иттеләр, ә тагын берничәсе базар чатындагы йортта ниндидер бер исерткеч ясап (исемен оныткамын), сатарга тотындылар. Баштарак аларның бу әллә нинди сихер белән ясалган эчемлекләренә халык ябырылган иде дә, соңга табан күпмедер кеше шул зәхмәттән үлә язып калгач, бик тиз аңардан биздeләр. Ахырда Дәүләкән властьлары ул кабакны бөтенләй ябып та куйдылар... Шунысы тагын кызык: әлеге кызыл мал белән сату иткән баерак кытайлар Дәүләкәннең чибәр-чибәр генә марҗа кызларын үзләре белән дә алып киттеләр.

Әйе, дөнья бик тиз үзгәрде, гүя иске тормыш көтмәгәндә борылып кайтты. Магазиннар, кибетләр, такта лареклар көн буе ачык, кичләрен лампалар яндырып та сату итәләр. Җаның ни тели — шул бар, тик акчаң гына булсын!.. Бигрәк тә азык-төлек күбәйде, чынлап торып муллык килде. Мин Дәүләкәннең 1924—25 еллардагы көзге базарларын бик яхшы хәтерлим. Бу чакларда базар үзенең иске мәйданына гына сыймый иде инде — ул ак чиркәүдән арырак башланып, Дәүләкән чокырына хәтле барып җитә иде. Чиркәүдән ары ерак урында мал базары — анда, атлар-сыерлар арасында, авыл агайлары, маклерлар, чегәннәр; анда коелган юеш печән исе, буы чыгып торган яңа тизәк исе, чыпчыклар чыр-чуы... Мал базарыннан соң чиркәү урамы буйлап үзәккә таба Бурангол, Кыдрач башкортлары, Бәләбәй ягы чувашлары китергән утын йөкләре тезелеп киткән. Боларга ялганып, ләкин аркылы мәчет урамына да борылып, Дим тугаеның печән йөкләре тезелеп тора. Шуннан соң без төп базар мәйданына керәбез. Монда инде азык-төлек... Чиркәү урамының дәвамы буларак сузылган Кәримовлар бакчасы буенда ит рәтләре. Дәүләкәннең үз итчеләре дә, авыл агайлары да итмайларын шушында саталар. Әле дә исемә төшкәндә гаҗәпләнәм: сугым вакытында базарга ит заты шул хәтле күп керә иде, сарык түшкәләрен, мәсәлән, утын әрдәнәсе шикелле, өеп куялар иде. Чана саен я сыер түшкәсе, я тана түшкәсе ята торган иде. Муллык бер килсә — килә икән ул!

Мәйданның каршы ягында он-ярма рәте. Монда онның төрлесен — арышныкын, бодайныкын, карасын-агын — өч аякка аскан соскылы бизмәннәрдә саталар. Монда шулай ук зур тәпәннәрдән бал сатучылар, җирдән генә чабата-чыпта, тимер-томыр, табак-савыт сатып утыручылар, кыскасы, бу — базарның иң тыгыз җире. Кулдан иске кием, вак-төяк чүп-чар, куян тиресе сатучылар да һәм кесә караклары да шушында кайнаша.

Бу тыгыз җирне узгач, таш кибетләр башлана. Алар берничә рәт, күбесе татарларныкы, шулай ук русларныкы да бар. Кибетләрнең ишекләре киңенчә ачык — монда инде зур сәүдә, җитди сәүдә бара. Ләкин шуны әйтергә кирәк, аерым кибетләрнең (мәсәлән, «Алга»ларның) сәүдәсе ничаклы гына зур булмасын, әмма элекке замандагы шикелле приказчиклар тоту юк иде. Һәрбер хуҗа бары тик үзе генә яки компаньоны белән генә сату итә, ә базар көннәрендә исә хатынын һәм малаен эшкә җигә. Ч нки ул бик тиз белеп алды: совет шартларында кеше көченнән файдалану бик хәтәр эш икән. Шуңа күрә нэп сәүдәгәре кырыкка ярылса да кибетенә кеше яламады. Хәер, ул үзе дә искиткеч өлгер — алучы алдында теле-телгә йокмый, кулларына күз иярми торган иде.

...Кибетләр рәтен үтеп, вокзал урамы аша чыккач, янә бер зур базар башлана. Бу — «Марҗа базары» (марҗалар саталар икән дип уйлый күрмәгез тагын!). Исеме бик күптәнге, чөнки шушы шактый зур мәйданда элек-электән үк рус, украин, немец хатыннары бричкалардан

һәм төрле яшелчә һәм дуңгыз балаларын сата торганнар иде[1]. Монданиләр генә юк, хәтта Дәүләкәннең эссе туфрагында үскән вак кавын белән юка кабыклы карбыз да була иде. Татар һәм башкорт үзе үстерергә иренгән яшелчәне шушыннан ташый торган иде.

«Маржа базары»н ерып узганнан соң, Дәүләкән чокырына барып чыгасың. Чиркәү арьягыннан ук башланган шау-шулы, әкәмәт кызыклы, чуп-чуар озын базар менә шунда инде тәгалләнә дә. Безгә дә кайтыр якка борылырга вакыт.

Чокыр буендагы кыска урамны узып, Эткол (русча — Итколовская) урамына чыгабыз. Бу инде Дәүләкәннең төп урамы — иң озын урам. Мондагы күп кенә йортлар базар көнне «базарчылар» кертәләр. Үзенә күрә бер кәсепкә әйләнде бу... Безнең күршедә генә бернечә йорт «базарчылар» белән тула торган иде. Агайлар шунда атларын тугарып калдыралар, базарда йөреп эшләрен бетергәч, кайтып, кибет күчтәнәче белән тирләп-пешеп чәй эчәләр. Ул көнне ике самовар алмаш-тилмәш кайнап кына тора иде. Моның өчен хуҗа һәр «базарчы»дан ничә тиендер акча алып кала. Төшеме әйбәт булгандыр, ахрысы... Әнә, безнең каршыдагы Бибикамал апа да үзенең бик кечкенә ишегалдын «базарчылар» белән тутыра иде. Өе дә зур түгел иде, ләкин килере булгач, тыгызлыктан, мәшәкатеннән куркып тормаган. Асылда «базарчылар» кертү Бибикамал апа кебек ятим хатыннар эше иде дә.

Гомумән, нэп елларында базар шаукымына тартылмаган, йотылмаган кеше калды микән? Әйтерсең, бөтен Дәүләкән ул көнне аякка баса, һәркем бер генә тапкыр булса да базарны әйләнеп керә. Һәр кеше нидер ала, нидер сата яки болай гына карап йөри... Якын-тирә авыллардан да безнең базарга килмичә калучы булмагандыр. Өлкәннәр кодасы яки баҗасы белән очрашып «сәй» (яки «мәй») эчеп чыгар өчен, ә яшь-җилкенчәкләр исә көнбагыш ярып йөрер өчен генә булса да килә. (Мин инде элекке әсәрләремдә башкорт муллаларының базар көнне безнең күрше Миңлегәрәй агай өендә кымыз эчеп, курай тартып, кәефләнеп утыруларын язган да идем.) Еракларадан килүчеләр дә күп була иде. Безнең үзебезгә дә кырык чакрымдагы Каргалыдан кем дә булса килмичә калмый иде. Болар инде чын «базарчылар»— дүшәмбе көн кичтән үк базар мәйданы шундый базарчыларның ат-арбалары белән тула башлый иде. Ә иртәгесен монда нинди генә халык юк: татары, башкорты, урысы, чувашы, немецы, яһүде — кыямәт көнне кубарылгандай барсы да шушында кайнаша-болгана... Озын сүзнең кыскасы, һәр сишәмбедә булып уза торган Дәүләкән базары әнә шулай бик зур да, бик җанлы да һәм карап йөрер өчен бик кызыклы да була торган иде.

...Ярый, болары мәсьәләнең бер ягы, ваграк ягы... Без әле нэпның тагы да зуррак һәм мөһимрәк нәтиҗәсен күрдек: Дәүләкәнгә бөтен этрафтан әүвәлгечә иген агылып керә башлады. Игенне дәүләт тә җыя, хосуси кешеләр дә җыя, болар арасында хәтта яһүтләр дә бар иде. Билгеле инде, иген болай күп кергәч, Дәүләкәннең моңарчы тик торган мәшһүр тегермәннәре дә хутка китте. Аларның «Якир», «Труд», «Гардер» тегермәннәре кебек бик зурлары дәүләт кулында иде. Вагракларын хосуси кулларга да бирделәр шикелле. Мәсәлән, Үтәмишләрнең биш катлы тегермәннәре ачлык елның кышында утырып янганнан соң, шуңардан ничектер зарарланмыйча калган бер өлешендә алар яңадан ашлык тарттыра башладылар... Көзен-кышын өзлексез иген кереп торуның тагын бер кызыклы галәмәте — ул да булса, ачлык елында кырылып бета язган күгәрченнәрнең кинәт бихисап үрчеп китүендә иде. Ашлык бушаткан җирләргә алар кара болыттай төшеп утыралар; һавага күтәрелә башласалар, канат тавышларыннан колак тонып китә иде.

[1]1978 елны Уфадан Оренбург аша Сакмар буена барып чыккач, мин Куандык базарында бер кызыклы тамаша күрдем: дуңгыз балаларын авыллан «Жигули» машинасының багажнигына төяп китерганнәр — шуннан гына сатып торалар.

Дәүләт тегермәннәренең башына «хуҗа» итеп Гыйният дигән кеше куелды. Ул Дәүләкәннең бер извозчик улы булган, ләкин без аны элегрәк күреп белми идек, революциягә чаклы ул гел читтә йөргән. Извозчик абзыйның Сафый исемле бер улы һәм Галимә исемле җиткән кызы да бар иде. Боларын әзрәк хәтерлим: Сафый (Сафиулла) абый гармунда чибәр генә уйный иде, ә сеңелләре Галимә спектакльләр куюда катнашып йөрде.

Гыйният хакында, үзе кайтып күренү белән бер үк вакытта диярлек, төрле сүзләр дә чыкты: ул, имеш, ниндидер яшерен партиядә торган, партия өчен акча кирәк булгач, банкларны басуда катнашкан, үзе, имеш, патша жандармнарыннан гел качып йөргән. Булыр да! Бәлки, шуның өчен аны Дәүләкән тегермәннәренә җитәкче итеп куйганнардыр да. Әмма ләкин бу «җитәкче» иң элек үзе өчен гаять өлгер чын хуҗа булып чыкты. Бер-ике ел да үтмәгәндер, Гыйният абзаң Дәүләкәннең иң шәп урынында, ягъни әлеге без барып йөри торган водокачка янындагы ачык мәйданда, калай белән япкан, такта белән тышлаган, биш-алты тәрәзәсе Дим буйларына карап торган бик шәп йорт салдырып җибәрде, зур-иркен ишегалдына шулай ук калай белән яптырып ак мунча, койма белән әйләндереп, таза-чибәр капка бастырып куйды. Шуларның барсын да, ягъни йортыннан алып, капка-коймасына кадәр, лимон төсендәге сарыга буятты. Үзе ул кара айгыр җиккән, йомшак күн утыргычлы, рессорлы тарантаска утырып кына йөри башлады. Һәм озак та үтмәде, халык аңа «кинәт бай» дигән исемне дә такты. Бу кушамат бик тиз таралды, абзыйның исем-фамилиясен дә оныттылар, телдә бары «кинәт бай» гына калды.

Хәзер, ярты гасырдан соң, мин тегермәннәр «хуҗасын» гаепләргә дә, хөкем итәргә дә җыенмыйм. Асылда мин аны белмим, күргәләвем дә бик аз, тик шуны гына әйтә алам — ул заманда Гыйният абзый кебек кинәт баеп китүчеләр аз булмады. Бу хәлләр барсы да әлеге шул нэп дигән хикмәтле нәрсәнең җимешләре иде.

Шулай да минем, малай башым белән, Гыйният абзыйга бер этлегем тиде. Эш шунда, Мәрвәр утарыннан килеп, Дәүләкән мәктәбендә бер кыш укыган Гобәйдулла дустым «кинәт бай» турында бәет чыгарды. (Хәтерләсәгез, Гобәйдулланың «һәҗү»[1] белән мавыкканын «Дәүләкән» өлешендә сөйләгән идем инде). Менә монда да шәкертнең кулы тик тормаган, «кинәт бай»ны үзенчә фаш итеп тоткан да язып чыккан. Миңа килеп, сер итеп кенә укып күрсәтте. Бәет, ахрысы, икебезгә дә кызык тоелгандыр, һәм без аны үрчетергә булдык. Ике кулдан куш дәфтәр битенә берничә нөсхә итеп күчердек. Шуннан соң апрель аеның җылы, караңгы бер кичендә (бу 1924 елның язы иде) шул күчермәләрне бер-ике урам чатына, мәчет коймасына, Гыйният абзыйның үз капкасына да ябыштырып куйдык. Бу эшнең үзебез өчен бик хәтәр икәнен, ахрысы, сизгәнбездер, чөнки бүтән беркемгә дә әйтмәдек, сөйләмәдек, эчебездән тындык.

...Икенче көнне бәетне күргәннәр, укыганнар, хәбәре дә таралып өлгергән — безнең үзебезгә дә: «Кинәт бай»ларга бәет чыгарганнар!»— дигән «яңалык» бик тиз килеп җитте. Ул гына түгел, «кинәт бай»ның булышчысы, сабан туйларында көрәшүче озын-таза Нури абзый әйткән янәсе: «Кем язганын белсәм, ботыннан тотып җиргә бәрәм!»— дигән имеш. Без моны да ишеттек. Ләкин серебез ачылмады, белүче булмады, куркыныч узды, бәет үзе дә тиздән онытылды. (Бала-чага эше дип карадылар булса кирәк.) Ә Гыйният абзаңа нәрсә? Утырган урыны биек, йөрткән аты шәп — сыңар төге дә селкенмәгәндер... Тик минем күңелдә генә ниндидер ямьсез бер юшкын утырып калды. Күрәсең, яшерен эшне яшьтән үк яратмаганмындыр инде.

[1] һәҗү — сатира.

«Кинәт бай»ның соңгы язмышы турында бер хәбәрем дә юк. Дәүләкәндә озак төпләнеп кала алмаган булса кирәк — мин Казаннан кайтып йөргән чакларда, ягъни егерменче елларның азакларында Гыйният абзый үзе юк, ә шәп таза йорты тора иде әле. Анда кайбер туганнары һәм әлеге Нури агай яшиләр иде. Нури йортны караучы да, саклаучы да иде бугай.

Шушы әйберне язарга җыенгач, Гыйният абзый турында сорашып карадым — белүче булмады. Тик кемнәндер: «Гыйният ачтан үлгән»,— дигән гаҗәп сүзне ишеткәнмен һәм шуны блокнотыма язып та куйганмын. Кайда, кайчан, нишләп?— бу сорауларга җавап юк, күрәсең, сөйләүче үзе дә белмәгәндер. Билгеле, минем моңа һич тә ышанасым килмәде — кайчандыр Дәүләкән тегермәннәрен кулында тотканга күрә генә түгел, ә бигрәк тә аның революциягә чаклы ук инде утны-суны кичкән кеше булуын белгәнгә күрә дә ышанасым килмәде.

Тагын нәрсә әйтәсе калды Дәүләкәндәге нәп турында? Әйе, бу вакытта тагын дин көчәйде дип тә әйтергә була. Тиз арада мәчетләр җанланды, җомга намазына йөрүчеләр күбәйде, елына ике килә торган гает бәйрәме кутәренке үтә башлады. (Гражданнар сугышы вакытында һәм ачлык елында бу эшләр тәмам сүрелгән иде.) Сәүдәгәр халкы, авылның хәлле кешеләре, гомумән, дин тотарга ярата лар — бу электән үк билгеле. Ләкин фәкыйрь-фокаралардан һәм хезмәтчеләр белән һөнәрчеләрдән дә мәчет юлын таптаучылар аз түгел иде. (Һәрхәлдә, җомга намазын калдырмыйлар иде.) Бу туклыкка һәм иминлеккә ирешүнең бер галәмәте булмады микән?.. Ачлык вакытында бит югыйсә мәчетләр бөтенләй бушап калган иде. (Мәсәлән, хәзерге вакытта да халыкның күпмедер өлеше дин тота, яки дин кушканны эшләргә тырыша — бу бит инде хәерчелектән, бөлгенлектән, нужадан түгел, һәрхәлдә.) Нәп елларында исә халыкның иң зур күпчелеге иске заман тәрбиясен алып калган кешеләр иде әле. Шулай булгач, ул чакта диннең вакытлыча көчәеп китүе гаҗәпмени?!

Ә бер ике-өч елдан инде совет бәйрәмнәре өстенлек ала башлады. Аларның иң зурлары, билгеле булганча, Октябрь белән Май бәйрәмнәре иде. Аларны аеруча дәртләнеп һәм шатланып бәйрәм итүчеләрнең күпчелеге дә, билгеле, яшьләр иде. Шулай ук Дәүләкәндә революция вакыйгаларына катнашучыларның да читкә китмәгәннәре исән-саулар — алар оештыручылар, алар беренче сафта!.. Бигрәк тә Беренче Май бәйрәме язның аяз, матур көненә туры килсә, бик күңелле, тантаналы уза торган иде. Үзенә күрә демонстрация дә, митинг та булып ала, төрле уеннар да оештырыла, кыска гына вокзал урамы да әкрен генә гулять итеп йөрүче, киенешкән яшьләр белән тула иде.

Шундый бәйрәмнәрнең берсе белән бәйләнгән кызык кына вакыйга әле дә булса исемдә: нәкъ беренче Май көнне безнең Дәүләкән белән Яңа Шәрип арасындагы тигез кырга әнә бурына охшаганрак куш канатлы кечкенә генә яшел аэроплан төшеп утырды. Ишеткәнебез бар, әмма җиргә төшкәнен моңарчы һич тә күргәнебез юк иде. Шунда ук бала-чага, яшь-җилкенчәк барыбыз да кырга чаптык. Тыныбыз бетә язып барып җиттек, чорнап алдык, карап торабыз бу әкәмәт аэропланга! Әнә ул нинди икән!.. Янында зур күзлекле, озын колаклы күн бүрек кигән очучысы да басып тора. Һәм көлемсерәп кенә җыелган халыкка аңлата: «Мин осавиахимнан килдем, ди, сезгә шушы очкычны махсус күрсәтер өчен, ди, инде утырып карарга теләүче булса, мин аны һавадан йөртеп тә килә алам»,— ди.

Димәк, утырып очарга да була?!— бусы инде гаҗәп-хәйран! Моңарчы бит әле Дәүләкәндә һичкемнең аэропланга утырып караганы юк иде. Кем генә башлап утырыр икән?.. Ләкин ни өчендер утырырга ашкынып торучы юк. Күрәсең, бераүнең дә җирдән аерылырга йөрәге җитми. Ә очучы кыстый: «Курыкмагыз, килегез, машинам бик әйбәт, исән-сау шушында китереп төшерәм»,— ди. Башкалар бер-берсенә карашып, икеләнеп торган арада, бер кәҗә сакаллы агай алгарак ерып чыкты да:

«Кая, булмаһа үзем осып караем әле»,— диде. Ул аты белән килеп туктаган бер йөк ташучы икән. Бүреген батырыбрак киде дә, чыбыркысын тоткан килеш, очучы ярдәме белән аэропланга менеп тә утырды. Шунда ук очучы үзе дә менеп урнашты. Бераздан аэропланның алдындагы агач калаклары зырлап әйләнергә тотынды, аннары үзе кузгалып, кыр өстеннән сикергәләп китте-китте дә, отыры кызурак чабып, ахырда җирдән дә аерылды. Халык аэроплан артыннан йөгереп, шаулап, бүрекләр чөеп, агайны озатып калды.

Аэроплан башта Дим тугайлары өстеннән Әлшәй ягына таба китте, Акколайларны узгач, Түлән буена борылды, шул чакта бераз күздән дә югалып торды, аннары тимер юлы буйлап Дәүләкәнгә таба кайтты һәм яңадан нәкъ шушы урынга исән-имин төшеп тә утырды. Бөтен очуына бер унбиш-егерме минут вакыт киткәндер... Аэроплан туктауга агайны күтәреп алып, җиргә бастырдылар. Ул шунда ук геройга әйләнде. Бала-чага, артыннан калмыйча, көтүләре белән иярep йөри башлады. «Я, агай, ничек булды, ниләр күрдең?»— дип сораучыларга ул исе китмәгәндәй гади генә: «Әйбәт булды, дөньяны күрдем, тик менә колак кына тонды»,— дип җавап бирә иде. Ә малайларның кабаланып: «Адәм ничек күренә, атлар, сыерлар?..»— дип кызыксынуларына каршы ул, көлемсерәп: «Атның дүрт аягы ла күренә, ә мона сусканың аяктары бөтенләй күренмәй»,— дип җавап биргән иде.

Шулай итеп, Дәүләкән тарихында аэропланга беренче мәртәбә утырган кеше йөк ташучы бер башкорт агае булып чыкты. Тик кызганыч, исеме генә елъязмаларга кереп калмады.

Хуш, үз хәлебез турында да сөйләргә, ахрысы, вакыттыр... Әлбәттә, истә калган кадәресен арттырмыйча һәм киметмичә. Билгеле инде, безнең атабыз да нэп башлану белән сәүдә эшенә кереште. Әйткәнемчә, сәүдә аның өчен хәләл кәсеп иде. Әмма әлектән үк килгән бер гадәте (яки комарлыгы) бар — ул һәрвакыт йөрү белән бәйләнгән сәүдәне ярата иде. Шуңа күрә кибет ачмады, бернинди ширкәткә кушылмады, ә искечә ялгыз башы йөреп сату итәргә тотынды. Башта ул Самар юлын таптады. Авыл халкында кием-салымга кытлык бик зур иде, өс-баш күптән искереп, тузып беткән, яңаны тектерергә һәркемнең дә хәленнән килми, бик күпләр үзенә кирәкне талчуктан эзли торган иде. Талчуктан киенү бик гадәти бер эшкә әйләнгән иде ул чакта. Безнең атакай да, менә шуны исендә тотып булса кирәк, Самара талчугыннан берничә капчык кием-салым тутырып кайта иде дә, шуларны Дәүләкән базарында һәм якынтирә базарларда кулдан сатып йөри. Әйбәт сәүдә димәс идем, вак эш, дәрәҗәсе дә түбән, әмма нишләсен башка чарасы булмагач?!. Картның мондый «сәүдәгә» тотынырга мәҗбүр булуының төп сәбәбен мин бары соңрак кына аңладым.

Самара талчугына атакай мине дә берничә тапкыр ияртеп алып барды. Минем эшем аның үзен дә, алган әйберләрен дә сагалап йөрү — мин бу «мөһим» эшкә ярыйм, миңа инде ундүрт яшь.

Самара зур шәһәр, мин белгән Уфадан да, һичшиксез, зуррак... Зур-зур таш йортлар да монда күбрәк. Станциясе дә ифрат зур — үтеп чыга алмаслык юлларда тезелеп торган кызыл эшелоннарның да исәбе-хисабы юк.

Беренче мәртәбә барып төшкәч тә мине бик гаҗәпләндергән нәрсә — вокзал мәйданындагы извозчикларның төрле яктан атакайга «князь» дип дәшүләре булды. Валлаһи менә, әле берсе, әле икенчесе: «Князь, әйдә кил, утыр да утыр!»— дип чакырып кына торалар. Башта мин моңа мыскыл итү дип аңладым, бик гарьләндем һәм сакаллы русларга чынлап торып ачуым килде. Тик соңыннан гына белдем: татарга «князь» дип

дәшү көлү дә, мыскыл итү дә түгел икән, бу бик күптән руска кереп калган бер гадәт икән ләбаса!

Ә Самара талчугы — галәмәт!.. Вокзалдан ерак та түгел зур мәйдан, еллар буенча таудай өелгән кырмыска оясыдай өзлексез мыжгып, «кайнап» тора. Шулай ук ул өзлексез бөтерелеп, чайкалып, гүләп тә тора. Монда, әйтерсең, бөтен Рәсәйнең сатучысы һәм алучысы, сукбае һәм зимагуры, карагы һәм жулигы җыелган — ерып йөрерлек тә, читенә барып чыгарлык та түгел!.. Искиткеч уяулык кирәк монда, югыйсә күз ачып йомганчы акчаңнан да, әйбереңнән дә колак кагасың!

Самара ул Себергә һәм Урта Азиягә китә торган иң озын юллар өстендә тора. Шуңа күрә монда кырык яктан килеп тыгылган кырык милләт халкы бутала. Монда сатылмаган нәрсә юк — аларны белеп тә бетерерлек, санап та чыгарлык түгел. Без кием-салым карыйбыз, безгә кием-салым кирәк. Һәм бу «товар» да мең төрле. Өр-яңасы да, тузып беткәне дә — кайсын телисең, рәхим итә күр!.. Берәрсенең кулындагы ошаганрак әйберне карый башлау белән ниндидер шикле кешеләр безне чорнап та алалар. Һәркайсы үзенең сәләмәсен күзебезгә төртә башлый:

— Яле, агай-эне, алып җиффәр булмаса, гомерең буе рәхмәт укырсың! Балаларыңа да әйтеп калдырырсың...

— Абзый, мөселман кеше икәнсең, баскан урынымда җир йотсын, минекеннән дә юнерәген тапмассың!

— Әй, мажик, ач капчыгыңны, бушлай ташлыйм. Каян килеп кая китмәгән безнеке!..

Ә безнең кайгы ничек кенә булса да кесә белән капчыкны саклау — шуңа күрә тизрәк бу тыгыз чолганыштан ычкыну ягын карыйбыз. Чынлап та кырмыскалар шикелле мыжгып торган бу халык арасында иң читене — кирәк әйберне карап алу иде. Шуңа күрә без, талчук уртасында бераз буталганнан соң, этешә-төртешә читенә чыга идек тә, капчыкларыбызга утырып, үткән-сүткәнне күзәтә идек. Берәр ышанычлырак кешенең кулында юньлерәк әйбер күренсә, атакай шуны чакырып ала да иплӛп кенә әйберсен карый һәм сатулаша башлый. Әйбер бик төрле булган шикелле, сатучысы да бик төрле — кайбере белән бик тиз килешәләр, ә кайбер үҗәте белән килешә алмыйча җаны чыга. «Насыйбы безнеке булыр!» — ди минем карт гүя үзен юатып.

Без җыйган кием-салымнарның берсе дә яңа түгел, барсы да киелгән, ләкин бөтен-таза, «рәхәтләнеп» иләрлек әле... Мин үзем дә ул елларны кеше иңеннән төшкәнне киеп йөрдем. Хәтеремдә, Самара талчугыннан алган бәрхет якалы, зәңгәр тужуркам — зуррак иде ул миңа, шулай да яратып кидем үзен.

Талчукта эшебез беткәч, күрше мәйдандагы тимер ишекле таш кибетләр рәтендә дә йөрдек. Кибетләрнең эчендә генә түгел, тышында да товарлар өелеп ята. Бик кызу сәүдә бара — монда да алучыны буш җибәрмәскә тырышалар, хәтта арттан кычкырып калалар. Җиләк-җимеш бик күп — үзбәкләр, төрекмәннәр китереп тутырганнар. Шулардан күчтәнәчкә өрек, күрәгә, киш-миш алып киттек.

Ул елларда зур калага читтән килгән кешенең «Фатир кирә» торган берәр яхшы танышы була иде. Безнең дә Садовой урамда шундый таныш мишәрләребез бар иде. Каланың таш урамнарын таптый-таптый тәмам алҗыгач, шуларга куна кирә торган идек. Иркенләп туйганчы бер ашаугычуебез дә шунда үтә иде. Аннары инде башны тизрәк мендәргә куясы килә. Зурлар чыдам, зурларның һаман сүзе бетми, ә мин әкрен генә торып, чоланга чыгам да әзер урынга авып, шунда ук «мәртка» дә китәм. Их, бу Самара, Самара, кем генә сиңа чыдар?!. Вакыт-вакыт каяндыр гармун тавышы ишетелеп киткәндәй була. Ләкин мин аны төшемдә ишетәм дип кенә беләм. (Җәя эчендә генә әйтим, танылган оста гармунчы Гали Җәмлиханов без кереп йөри торган хуҗаның улы икән ләбаса!.. Мин моны күп еллардан соң гына белдем. Ә малай чактагы кыска гына очрашулар күптән онытылган булган.)

Икенче көнне бик иртә генә капчык-төеннәребезне күтәреп, вокзалга төшеп китәбез. Монда үзенә бер дөнья!.. Мәхшәр дияргә дә була. Вокзал алды мәйданында кем генә йөрми-буталмый — килүче, китүче, актык киемен сатучы, сәләмә малай-шалай (беспризорниклар), бетле хәерчеләр, шикле хатын-кызлар, нидер сагалап йөрүче ирләр, чегәннәр — мин инде Самараның бирегә килеп тыгылган извозчикларын, ломовойларын, рәт-рәт тезелеп утырган азык-төлек сатучы маржаларын әйтеп тә тормыйм. Унҗиденче — унсигезенче елларда ук урынынннан купкан халык, адашкан сарык көтүедәй, һаман әле бутала да тулгана. Кая бара, ни өчен бара, нәрсә эзли — хода белсен! Бик биек һәм бик озын вокзал бинасына керсәң, анда да энә төшәр урын юк. Бөтен идәне сандык, кәрзин, әрҗә, капчык, төеннәр белән тушәлгән. Ашау-эчү, йоклап яту, хәтта үлеп яту да шул ук таш идәндә. (Бер карт урысның шунда үлгәнен үз күзем белән күрдем.) Монда нинди генә исләр аңкымый. Әмма иң көчлесе — карболка исе. Хәзер инде тиф та, холера да юк кебек, ләкин карболканы һаман да җәлләмиләр, күрәсең...

Менә шунда ике аяк сыярлык урын табып, капчык-төеннәр өстендә утырырга кирәк. Берең утыра, берең поезд сагалый. Белешмә бюролары ул чакта булганмыдыр, һич әйтә алмыйм, ләкин бөтен «белешмә»не үзең кебек аптырап йөрүчедән беләсең яки перронга чыгып, килеп туктаган поездларның кая китүләрен сорашасың... Белмичә утырсаң, Уфа урынына Оренбургка киттең-бардың — монда поездларның беришесе Уфа-Чиләбегә, икенчеләре Ташкент ягына китәләр. Кассаларга якын барырлык түгел, анда сытылып үләргә мөмкин. Күбрәк проводниклар белән сөйләшеп утыру ягын карыйсың — сөйләшә белсәң, утырып була торган иде.

Элегрәкме, шул еллардамы, вокзалларга җыелган халыкны, чүпне көрәгән шикелле, төяп алып китүче «Максимка» дигән поезд йөри башлаган иде. (Аны Максим Горький геройларын истә тотып, шулай атаганнар, имеш!) Дүртенче класслы соры вагоннар, аларда ике кат тоташ сәндерәләр... Менә шул сәндерәләргә халык бәрелә-сугыла, ызгышатартыша кереп тула. Урын алганнар — ирләр һәм хатыннар — рәттән тезелешеп яталар. Монда оялу да юк, гаеп итү дә юк. Тик иң түбәнге сәндерәләр генә тоташ түгел, утырып барырлык, тәрәзә янында кечкенә өстәле дә бар — юньлерәк, чистарак кешеләр шунда эләгергә, утырып кына булса да шунда кайтырга тырышалар.

Безгә дә күбрәк менә шул «Максимка»га эләгеп китәргә туры килә иде. Самара белән Дәүләкән арасы әллә ни ерак та түгел, хәзерге скорый җиде-сигез сәгатьтә үтә торгандыр, ләкин безнең «скорыебыз» тәүлектән артык та өстерәлә торган иде. Рәхәт поезд иде ул, бер җан иясе булмаган разъездларда да сәгатьләп тора, кешеләр вагоннардан төшеп, яшел чирәмгә йөзтүбән капланып, йоклап та меңәләр иде. Әмма барыбер кузгала ул! Башта кычкырта, халыкны җыя, аннары ахылдый-ухылдый китеп бара.

Бу «Максимка»да да, Самараның үзендәге шикелле үк, иң беренче кайгы әйберләрне саклау иде. Ничә барып, ничә кайттык, әмма арысак та, ачыксак та, йокламасак та бәла-казага юлыкмыйча бөтен «товарыбыз» белән исән-имин Дәүләкәнебезгә, ниһаять, кайтып төшә идек. (Бу язганнар 1922—23 елларга карый, бер-ике елдан соң поездлар күбәйде, йөрүләре шактый ансатлашты: вагоннарның да төрле төскә буялганнары чыкты — мягкий дигән зәңгәр-сарысына бай нэпманнар гына утырып йөриләр иде. Ләкин безгә андый «йомшагына» бервакытта да утырырга туры килмәде.)

Сәүдәләр кыза. Кибетләр гөрләтеп сату итә. Каяндыр товары да чыга, товары да килеп тора. Яңа сәүдәгәрләрнең эшләре шәп бара — моны аларның кыяфәтләреннән, өс-башларыннан да күреп була иде. Кайберләре яхшы атлар да җигә башладылар.

Әмма мин атакайның «сәүдә»сен, әйткәнемчә, яратмый идем. Хурлана да идем. Малайлар алдында Самара кебек зур каланы күрүем белән мактанасым да килми иде — беләләр ич, безнең нәрсә өчен анда барып йөргәнне. Дөрес, аларның берсе дә ул чакта сату эшенә начар карамый иде, мин дә шулай ук начар карамый идем. Аннары кемнәр генә сатуга тотынмады законный нэп заманында?! Житезрәк малайлар үзләре дә базар көннәрендә кое суы сатып булса да акча төшерергә тырышалар иде.

Мина исә атайның бары «товары» гына ошамый иде. Ярый әле шул товарын базарда сатып йөрергә мәжбүр итмәде. Әгәр мәжбүр итә калса, мин җирдә стаканлап тәмәке сатып утырырга риза булыр идем, әмма кеше искесен селкеп йөрергә, юк, алла сакласын, бервакытта да!

Ни өчен соң минем атай, Дәүләкәндә шактый абруйлы бер кеше булуына карамастан, сатуның шундый вак-түбәнен сайлады икән? Бер сәбәп итеп мин аның йөрергә яратуын әйткән идем. Ләкин чын сәбәп, төп сәбәп аңарда гына булмаска тиеш. Дөресен генә әйткәндә, кием-салым күтәреп йөрүдән әллә ни зур файда да күрми иде. Баштарак бу «товар» шәп кенә үтсә дә, соңга таба инде отыры авыр китә башлады — кайбер нәрсәләрен айлар буена сата алмыйча йөдәп бетә иде. Чөнки халык бөтенәйде, искегә исе китми, яңаны алырга яки тектерергә дә хәленнән килә башлады.

Сизәм, атакайның кәефе дә әйбәт түгел, әледән-әле уфтана да көрсенә, еш кына үзалдына моңланып та ала. Аның өчен мин дә борчылам — минем дә борчылыр вакытларым җитте дияргә ярый... Ә көннәрдән беркөнне мин һич көтелмәгән бер гаҗәеп хәлгә тап булдым. Базар көн иде бу, мәктәптән кайтып керсәм, өебезнең кухня ягында, сәкедә атакай иңбашларын селкетеп, тавышсыз гына елап утыра!.. Инәй аның янына баскан, сабыр гына юатып тора иде, ахрысы... Мин бу хәлне күрү белән аптырап, өнсез калып, бусагада шып туктадым. Шулай да инәй сизеп алды, борылып миңа кулы белән генә чыгып китәргә ишарә ясады. Мин күләгә шикелле артка чигенеп кенә чыгып киттем... Әйтергә кирәк, мин бала елавын да авыр күтәрә идем, әмма олы кешенең, җитмәсә, атай кешенең елавы мине тәмам кисте, хәлсез итте, гүя бөтен эчемне актарып чыгара язды. Үземә урын таба алмыйча, әллә кызганудан, әллә гарьләнүдән үкси-үкси тизрәк абзарга кереп яшерендем. Тик шунда гына беренче тетрәнүдән көч-хәлгә айныгач, мин ниндидер бер гаҗизлеккә төшеп: «Ни булган аңа, ни өчен ул сакаллы башы белән сәкедә елап утыра, нинди бәхетсезлеккә тарган?!» — дип ачынып уйландым. Озак тынычлана алмадым, абзарда озак яшеренеп тордым... Аннары курка-курка гына өйгә керсәм, атакай юк, чыгып киткән, инәй үзе генә иде. Ул да бик боек, нидер ямап утыра... Бераз икеләнеп торганнан соң, мин шулай да әкрен генә сорадым:

— Ни булды соң, инәй?

— Атаң бер пәлтәсен урлаткан,— диде инәй.

— Шул гынамы?— дидем мин бик гаҗәпләнеп.

— И бала, белмисең шул син атаңның хәлләрен!— диде инәй авыртирән сулап.— Бер пәлтә югалту да зур каза аның өчен.

Менә шуннан соң гына мин аның «талчукчы» булып йөрүенең төп сәбәбен аңлагандай булдым. Ул, баксаң, купецлар теле белән әйткәндә, сумасыз сәүдәгәр икән ләбаса! Чистарак, абруйлырак сәүдәгә тотынырга инде аның хәленнән дә килми икән... Һәм бу дөрес иде, чынлап та ул шулай иде — тагы да соңрак миңа мәгълүм булды: атакай революция алдыннан сәүдә итеп тапкан бөтен сумасын шушы-асты таш, өсте агач әйбәт йортка тыгып бетергән, имеш! Ә сумасыз сәүдәгәр — канатсыз кош кебек, йөгереп караса да очып китә алмый икән ул. Аннары минем атакай бу нэп дигән яңа шартларга тиз генә җайлаша да алмады шикелле — ниндидер серен, хикмәтен аңлап җиткермәде бугай ул аның...

Бәлки, аңа өлгерлек, үткенлек, әрсезлек, хәйләкәрлек җитеп бетмәгәндер?! «Нэпман» дип йөртелгән совет шартларындагы яңа купецлар нәкъ менә шул сыйфатлары белән аерылып та торалар иде... Кыскасы, мактанырлык түгел иде атайның эшләре һәм мин моны малай башым белән дә сизә идем, үземчә уйлана да, борчыла да идем.

* * *

...Әмма чынлап торып уйланыр һәм борчылыр вакытлар мине соңрак көткән икән әле... Тормышның тиз үзгәрүенә исең китәр! Яңарак кына коточкыч ачлык кичергән идек, инде шуның артыннан ук дип әйтерлек туклыкка да ирештек. Моны нэп нәтиҗәсе диделәр. Һәм бу чынлап та шулай иде. Ләкин — гаҗәп хәл — нэп үзе файдалы бер нәрсә булып чыкса да, аңа караш һәм мөнәсәбәт бер дә әйбәт түгел икән шул!... Моны миңа шактый иртә чамаларга туры килде. Чөнки нәкъ менә нэп тудырган яңа сәүдәгәрләргә («нэпманнарга») караш гаять начарланды.

Ачлык елыннан соң, егерме өченче еллардан башлап, Дәүләкәндә комсомол хәрәкәте яңадан көчәеп китте. Татар һәм башкортлардан да комсомол сафына керүчеләр була башлады. Ә бер-ике елдан инде комсомолга кергән егетләрне һәм кызларны дистәләп санарга мөмкин иде. Алар барысы да сатучы белән кулакны, әлбәттә, сыйнфый дошман итеп саныйлар иде. Ләкин мөнәсәбәтләре төрлечә — берәүләре йомшаграк, икенчеләре рәхимсез катылар. Моны инде мин үземә карата булган мөнәсәбәттән дә ачык сизә идем, тик бу хакта соңрак, җае чыккач сөйләргә туры килер, ахрысы... Хикмәт шунда ки, нэп тулаем һәм нэп тудырган «элементларга» начар караш ул бер Дәүләкәндә генә түгел, бөтен илдә хөкем сөрә иде. Мин ул чакта газета-журналларны укый идем инде, кайберләрен үзем дә яздыра идем. Менә шул газета яки журналның кайсын гына ачып карама, син анда нэпман, спекулянт, кулакны яманлаган, каһәрләгән, фаш иткән яки алардан бик әче көлгән юлларга очрап кына торасың — укып кына өлгер!.. Хәтта үзе дә нэп аркасында дөньяга килгән хосусый «Бабич» журналы да (аны өч кешелек «ширкәт» чыгарырга тотынган иде) беренче саныннан ук нэпманнарны хурлаудан, мыскыллап көлүдән башлады. Ләкин бу кызыклы гына хосусый журналның гомере, нэпманныкы шикелле үк бик кыска булды — бары өч саны гына чыгып калды шикелле... Әмма ташка баскан сүзнең тәэсире көчле бит ул!.. Минем әле күп нәрсәне белмәгән, аңламаган тынгысыз башыма сәүдә ул бер дә хәләл кәсеп түгел икән, сәүдә урлау-талау шикелләрәк бер гаепле эш икән, сәүдәгәр үзе дә начар, зарарлы бер кеше икән ул, дигән уй шактый тиз керә дә башлады. Ә мин бит шундыйрак кешенең баласы. Ничегрәк кабул итәргә тиеш мин боларның барсын да?.. Китап сүзенә, газета-журнал сүзенә бик нык ышана торган чагым. Аларда язылганнар белән бер дә икеләнмичә килешергә әзермен, аларга ияреп, бөтен сатучыларны начар, кирәксез кешеләр дип санарга әзермен, әмма дә ләкин үз атамны түгел, атам миңа кадерле дә, кызганыч та, аннары мин аны һич тә начар кеше дип саный да алмыйм. Киресенчә, бик әйбәт кеше ул минем атам. Бүтәннәрдән сорасагыз да шулай диячәкләр. Күптән бер нәрсәне сизеп киләм: барлык туганнар, күршеләр, якын таныш-белешләр бер дә риясыз аны яраталар иде. Аннары ул үзенчә гадел дә иде, алдашудан, хәрәмләшүдән, кеше хакына керүдән саклана, чөнки гөнаһлы булудан бик курка иде. Ә сату итүенә килгәндә, аның бит бүтән һөнәре юк, сәүдә күптәнге кәсебе (хәзер аңа илле яшь), революция буласын алдан белмәгән, хәлбуки яшәргә кирәк, безне асрарга кирәк, я нишләсен ул?!. Яңадан крестьян эшенә кайтырга монда аның җире дә, аты да юк, яше дә узып бара инде, шулай булгач, ирексездән мәҗбүр ул тузанлы базар мәйданнарын таптарга... Әмма күпмегә су-

зылыр икән соң бу каһәргә юлыккан сәүдә эше?!. Нәрсә көтә безне? Ничек яшәргә? Мин нишләргә тиеш?.. Ышанасызмы, унөч-ундүрт яшьлек малай башы өчен кинәт кенә туган мондый шикләнү, икеләнү, аптырау белән тулы уйларга җавап табуы бер дә җиңел түгел иде, абзыйлар!

1924 елның январенда Ленин вафат булды. Шул чакта мин Уфада, җизниләрдә идем. (Каникул көннәрендә килгәнмендер, ахрысы.) Бу вакытта җизниләр диния назаратының зур ихатасындагы бер агач йортта торалар иде. Яхшы хәтерлим, бик салкын кышкы көннең кичендә җизни белән Срур тутакай киногa киттеләр. Җылы өйдә Рокыя тутакай белән без бер көтү бала-чагалар гына калдык. Күпмедер вакыттан соң, һич көтмәгәндә, әллә нинди гайре табигый сәер бер кыяфәттә (әллә бик курыккан, әллә берәр нәрсәсен югалткан — тәгаен генә әйтә дә алмыйм) Срур тутакай ялгыз үзе генә кайтып керде. Без аның хәвефле-сәер кыяфәтенә дә, ялгыз гына кайтуына да шунда ук игътибар иттек, җизнигә берәр нәрсә булмады микән дип шомлана калдык, ләкин үзебез башлап сорашырга җөрьәт итә алмыйча тордык. Срур тутакай бу чакларда бик чибәр яшь хатын булу өстенә, бөтен йортка байбикә шикелле баш хуҗа да иде. Бары өстен чишенеп, залдагы зур өстәл янына бик арыган кешедәй утырып, күпмедер вакыт хәл алганнан соң гына үзе башлап безгә әйтте:

— Балалар, Ленин үлгән!

Моның тәэсирен мин хәзер ачык кына әйтә алмыйм, алдашырмын дип куркам. Әмма шуны әйтергә кирәк, Ленин исеме безнеңише зурракларга гына түгел, кечерәкләргә дә бик таныш иде, әлбәттә. Бу исем күптән инде халык теленнән бер дә төшми иде. Иллә мәгәр, аның үлеме халык язмышы, ил язмышы, бөтен дөнья язмышы өчен нәрсә икәнен, нинди нәтиҗәләргә китерәсен без әле аңлаудан бик ерак идек. Бу гаять зур югалту — без менә шуны гына аңлый-тоя алганбыздыр ул минутларда!

Тукта, ә җизни кайда соң?

Срур тутакай безгә кинотеатрда булган хәлне кыскача гына сөйләп бирде: кино башланып, халык мавыгып кына карап утырганда, кинәт картина өзелә һәм залда ут кабына... Гадәттәге өзелү дип кенә аңлый тамашачы моны, артык исе дә китми, тик кайбер түземсез яшьләр генә аяк дөбердәтеп сызгырырга тотына. Ләкин шул чакта экран алдында хәрби киемдәге бер ир уртасы кеше чыга да, халыкка тынычланырга ишарә ясап, кулын күтәрә. Халык тынычлана.

— Картинаны без туктатырга куштык!— ди бу, үзе дә ак җаймадәй агарынган кеше, һәм гаҗәпләнә калган тамашачыларны тагы да сынык тавыш белән... ныйсы килгәндәй бераз көттереп, ахырда әкрен-салмак кына, әмма һәр сүзен бик ачык иттереп әйтә:— Иптәшләр, өлкә партия комитетына Мәскәүдән ашыгыч телеграмма килде. Бүген, 21 январьда, Горкида... Владимир Ильич Ленин вафат!..

Залда гаҗәеп бер тирән тынлык урнаша — әйтерсең, кешеләр бермәлгә сулау, селкенү, сүз әйтә алу сәләтен югалтып җибәрәләр. Тик күпмедер секундлардан соң гына төрле урыннан сабырсызланып кузгалган, авыр сулаган, тәкатьсез үксегән тавышлар ишетелә башлый. Экран алдындагы кеше тагын кулын күтәрә:

— Гражданнар, тәртип саклагыз, тынычлык саклагыз! Кино бүген туктатыла... Өйләрегезгә таралысыз... Безнең белдерүләрне иртәгә газеталардан укырсыз. Ә монда булган коммунистларның барсына да шәһәр комитетына җыелырга!

Халык кузгала, картинаны карап бетерү турында беркем тарафыннан бер генә сүз дә булмый, барысы да аяк астына карап кына, этешмитөртешми ишекләрдән салкын, караңгы төнгә чыга башлый. Ә җизни Срур тутакайны капка төбенә хәтле китерә дә үзе ашыга-ашыга шәһәр комитетына китеп бара.

...Тагын ниләр ишеткәнне һәм ниләр уйлаганны искә төшерәсе килә дә бит, әмма бик күп еллар узган шул инде... Һәрхәлдә, бер уй күңелгә килмичә калмагандыр: Ленин урынына кем булыр икән?.. Бу бик табигый, чөнки борын-борыннан ук баш кеше, житәкче кеше үлеп киткәч, халык зурысыннан алып, кечесенә хәтле иң элек әнә шуны уйлаган: кем генә булыр икән? Һәм күп өмитләрен ул шуның белән бәйләгән. Дөньяда озак яши торгач, без дә моның дөреслегенә кат-кат ышандык.

Янә бер нәрсә хәтердә эләгеп калган. Җизни икенче көнне соң гына бик арып, йончып кайтты. Ашарга утыргач, безнең алда Срур тутакайга кайда булуларын, ни эшләгәннәрен сөйләде. Алар, бер төркем татар коммунистлары, төнне газета редакциясендә уздырганнар. Ленин вафатына багышлап чыгарылачак газетаны шунда эшләүчеләр белән бергәләп, ашыгыч рәвештә хәзерләгәннәр. Кайсы утырып мәкалә язган, кайберләре үзенең теләгән язарга керешкән, башкалары алар язганны укыган-төзәткән — кыскасы, һәммәсенә дә эш җиткән. Тик шигырь юк икән, ә шигырьсез газетаны чыгарып булмый, ярамый, мөмкин түгел... Шунда ук тиз генә шигырь язуны Гариф Гомәр дигән шагыйрьгә йөкләгәннәр. Аны аулак җиргә утырткannar, янына бармаска, дәшмәскә кушканнар... Әмма ләкин Гариф абый яза алмыйча бик азапланып беткән, имеш. Үзен кулга алалмый икән шагыйрь — берничә юл гына яза да сыгылып төшеп елый башлый икән... «Шагыйрьне юата алмыйча йөдәп беттек», ди җизни...

Нишләп соң бу кечкенә эпизод минем хәтердә сакланып калган әле? Бәлки, шул чакларда үзем дә язу турында хыяллана һәм аз-маз гына сызгалый башлаганга күрәдер?! Бүтәнчә ничек аңлатыйм? Шагыйрьнең җаны тетрәнүдән шигырь яза алмыйча газаплануы миңа да тәэсир итмичә калмагандыр, ахрысы...

Тарихтан беләбез, Ленинны Горкидан китергәннән соң, Мәскәүнең Кызыл мәйданында җирләү — (вакытлы мавзолейга кую) — 27 январьда булды. Мин инде Дәүләкәнгә кайткан идем. Көннәр гаять суык, очкан кош та катып җиргә төшәрлек. Дәүләкән тын, урамнары буш, капка төпләрендә малайлар да күренми. Кешеләр үзләре дә, авыр уйлары да, кара-кайгылары да әйтерсең, моңсу-боек өйләренә кереп бикләнгән. Тоташ туңган тәрәзәләре генә, агарып калган сукыр күзләрдәй, дөньяга күрмичә карыйлар. Эңгер-меңгер вакыты якынлашып килгәндә тын, куе һаваны калтыратып, тегермәннәрнең гудоклары кычкырта башлады. Аларга станциядәге паровоз гудоклары кушылды. Үкси-үкси үкергән бу гудок тавышлары кинәт сискәндереп җибәрде, бәгырьләрне телгәләп узды һәм гүя үлемгә көчле — килешмәс нәфрәт булып яңгырады.

Матәм көннәре үтеп китте, мәктәпкә дә йөри башладык. Әмма Ленин үлеме аңда һәм күңелләрдә яши иде әле... Моны нәрсәдән сизеп була?.. Әйткәнемчә, Ленин исемен ишетмәгән-белмәгән кеше элек тә юк иде. Инде үзе үлгәч, аның исеме тагы да киңрәк таралып, кадерлерәк булып китте. Бу җәһәттән аның язмышы бүтәннәрнекеннән бик нык аерылды: мәсәлән, башкаларның исемнәре, үзләре исән чакта никадәр популяр булуга карамастан, үлгәннән соң шактый тиз онытыла башласа, Ленинныкы, киресенчә, бөек шагыйрьләрнеке шикелле, һаман күтәрелә-зурая барды. Бу исем бигрәк тә яшьләр һәм балалар күңеленә бик нык керә башлады. Күпме бала-чага аның турында шигырь язмады — әгәр шул чактагы балалар матбугатын актарып карасагыз, моны үзегез дә күрерсез. Билгеле, матбугатта чыкканы меңнән бер генә ул, ә чыкмаганы бихисап булырга тиеш. Һәрбер мәктәптә «Ленин почмагы» оештырылды, балалар үзләре аны үз куллары белән тырышып бизәделәр. Шул матур «почмаклар»да беренче мәртәбә стена газетасы да күренә башлады. Ә газета инде, билгеле, рәсемсез булмый, шигырьсез булмый. Ничектер үзеннән-үзе рәсем ясаучылар да, шигырь язучылар да табыл-

ды. (Малайлар-кызлар арасында бу эшкә азмы-күпме сәләте булганнар һәрвакытта табыла икән ул.) Минә безнең мәктәптә дә Мөхәммәтгали шигырь язган, Фәтхелислам язган, алардан күрмәле мин дә яздым. Бу бит минем язу теләге белән исерә башлаган чагым — ничек инде мин Ленинга багышлап шигырь язмыйча кала алыйм, ди?! Булмый ул!.. Һичшиксез, күңелемдә ниләр тугандыр инде, нидер әйтәсем килгәндер, тик бәлки кыюлыгым җитмичә торгандыр, ә менә иптәшләремнең язганын белгәч, дәртләнеп тоттым да тәвәккәлләдем. Әмма тырышыптырышып язуымнан нәрсә килеп чыкканын хәзер инде әйтә алмыйм, шигырь сакланмаган, сүзләре дә истә калмаган, хәтта исеме дә онытылган. (Тик һәр юлы ундүрт-унбиш иҗектән торганын хәтерлим, чөнки иҗекләрне бармак белән саный-саный язган идем.) Бу шигырь минем беренче тәҗрибәм диярлек. Ләкин язу эшен шигырьдән башлавымны мин моңарчы бер дә әйткәнем юк иде шикелле, чөнки бердән, шигырьләрне бик аз яздым, икенчедән, үземдә шигырьгә сәләт юклыгын бик тиз сиздем. Шулай да минем Ленинга багышлап шигырь язуыма, шәт, ышанырсыз — бу очракта алдашып маташу бик зур түбәнлек булыр иде. Аннары шул чакларда мин берничә шигыремне (ихтимал, Ленинга багышланганын да) Мәскәүгә «Кечкенә иптәшләр»гә җибәреп караган идем. Әгәр журналның 1924—25 елларда чыккан саннарын актарып карасагыз, иң соңгы битенең астында Әмирхан иптәш Яникәефкә: «Әйтер фикерегез булса да, шигырьләрегез чи-зәгыйфь», дигәнрәк мәгънәдәрәк җавап басылганын күрерсез. Моның өчен редакторы Муса Җәлилгә бәлки үпкәләгәнмендер дә, әмма зәгыйфь шигырьләр язудан тизрәк туктарга ул, һичшиксез, ярдәм дә иткәндер дип беләм. Соңыннан Муса белән очрашкан чакларда бу хакта бервакытта да сүз булмады — ул инде журналында басылмаган «шагыйрьләр» арасында минем дә булуымны күптән оныткан, ә мин моны шаяртып кына булса да аның исенә төшерүдән, билгеле, тыела торган идем. Шагыйрь алдында шагыйрь була алмыйча калуың белән мактану... юк килешми, егетләр!

... Ә нэп гөрли. Сәүдәләр шәп бара. Базарларга азык-төлек ишелеп керә. Тормыш беркадәр тигезләнде кебек — элеккедәй череп баючылар да, кара-җәяү калучы ярлылар да күренми диярлек. Халык тулаем канәгать сыман. Ләкин озаккамы бу?.. Ленин вафатыннан соң киләчәк турында уйлану һәрбер кешенең күңелендә туган булырга тиеш. Әлбәттә, һәркем үз хәленнән, үз теләкләреннән чыгып уйлана... Хәер, артык борчылырга урын да юк шикелле... Үзгәрешләр күтелми, дөнья үз эзеннән искечә һаман тәгәрәр кебек... Газета битләрендә дә, җыелышларда да гел «Ленин юлы, Ленин байрагы, Ленин тәгълиматы» дип кабатлап кына торалар. «Ленин үлде, әмма эше яши!»— дигән сүзләр бөтен җирдә язып куелган иде. Ләкин Ленин юлын кем, ничегрәк дәвам иттерәчәк — бу хакта фикерләр бер үк түгел кебек — шулайрак сизелә иде. Дәү абзыйлар:«Ленин көймәнең коерыгын болаерак тоткан иде, ә икенче берәү, бәлки тегеләерәк тотар»,— диләр үзара сак кына сөйләшкән чакларында...

Мин безнең Дәүләкәндә комсомолларның артуын, көчәюен әйткән идем инде. Шулай ук нэп тудырган яңа байларга, сатучыларга, баерга тырышкан авыл агайларына, гомумән, искене хәтерләткән, искегә тарткан бөтен нәрсәгә нәфрәт-ачуның да көчәюен әйтеп узган идем. Һәм бу нәфрәт, бу ачу отыры көчәя бара иде. Һәм ул нәфрәт-ачу сүздә генә түгел, гамәлдә дә үзен сиздерә башлады. Иң элек әле «финотделлар» хосуси сәүдәгәрләргә елдан-ел зуррак налоглар салып, аларны ничек тә кысарга, чикләргә керештеләр. Шулай ук авылларда таза тормышлы агайларны һәм кулакларны кысрыклау да башланды булса кирәк. Җыеп кына әйткәндә, сүз хәзер күбрәк сыйныфларны бетерү, илдә социализм төзү турында бара. Димәк, бу нэп дигән нәрсәнең гомере озака бармаячак — моны нэпның иң кызган чагында да ничектер сизәргә мөмкин иде.

Миңа инде унбиш яшь! Минем инде үз уйларым, үз кайгыларым бар. Мин дә бит шушы заман эчендә үсеп килүче бер адәм баласы! Заманның җилләре, эсселәре, салкыннары миңа да кагыла, авырттырып кагыла... Бер елдан мин Дәүләкәнемнән чыгып китәргә тиешмен... Ә күргән-кичергәннәрем һаман да күп әле шуларны сөйләр өчен миңа унбиш яшьлек халәтемә кайтырга кирәк. Бу һич тә ансат түгел. Нәрсәдән генә башларга соң?!

Ахрысы, мәхәббәт белән әдәбияттан башлау дөресрәк булыр. Ник дигәндә, адәм баласының уянуы һәм күзе ачылуы мәхәббәт белән китаптан башлана. Һәрхәлдә, алар икесе дә кешене балалыктан чыгара һәм хыял, өмит дөньясына алып керә. Беренче татлы газап белән беренче куанычлар да шулардан башланса кирәк.

Мәхәббәттән котылу юк. Табигать адәм баласын барлык җан ияләре шикелле үк ике җенес итеп яраткан икән, димәк, мәхәббәт орлыгы аңа инде ана карынында чакта ук салынган да булган. (Хәзергечә әйтсәк, башта ук программалаштырылган.) Тик берәүдә бу тылсымлы орлык иртәрәк шыта, икенчедә — соңырак, берәүдә — көчлерәк шытып чыга, икенчедә — зәгыйфьрәк, аерма бары шунда гына.

Миндә исә, ни хикмәттер, шактый иртә кыймылдый башлады ул хәерсез орлык!.. Югарыда мин күрше кызына койма ярыгыннан «гашыйк» булуымны язган идем инде. Бу хәлгә без — мәҗнүн, унсигезенче елның җәй башында дучар булдык...

...Көн дә диярлек кешегә сиздерүдән курыккандай мыштым гына койма буенда йөрим. Сакланып кына әле бер ярыктан, әле икенче ярыктан «аны» эзлим. Хәер, болай качып-посып күзәтмәгән чакта да инде ул минем күз алдымнан китмәс булды — гел менә гади генә ситса күлмәге, нечкә-нәфис сыны белән, башын әз генә ия төшеп каршымда басып тора кебек. Нинди дер сәер бер хәл сизә башладым мин үземдә — гүя каяндыр күкрәгемә кереп оялаган ап-ак кына йомшак кош шикелле, ул да минем эчемдә яши, бер генә адым да миннән калмый — ятсам да, торсам да без гел бергә, имеш! Әнә шундый серле бер малайга әйләндем әле мин, бик кадерле табышым бар минем, шуны ят күзләрдән ничек тә сакларга тырышам, тик менә ул ап-ак «кошчыгымның» исемен генә белмим әле мин...

Хуш, абзыкаем, нәрсә бу! «Гашыйк» булу түгелме соң?.. Шулайрак шикелле... Иллә мәгәр мин моны «мәхәббәт» дип әйтә алмас идем, чөнки мин әле мәхәббәтнең нәрсә икәнен белмим, мәхәббәт турында әле уйлый да белмим — мәхәббәт ул зурлар эше, ә мин нечкә сыйраклы арык кына бер малай... Миңа бит күрше кызыннан берни дә кирәкми, минем аны бары ешрак күрәсем генә килә. Ләкин койма ярыгыннан түгел, янына барып, якыннан күрәсем килә. Ул да мине күрсен иде... Ничек карар иде икән?.. Бу куркыныч, бу мине хәтта калтыранып куярга мәҗбүр итә, әмма барыбер аңа бик күренәсем килә. Тик менә Борһан купецның капкасы безгә дә кайчан гына ачылыр икән?!.

Әйткәнечмә, минем бу хәлгә юлыгуым унсигезенче елның хәтәр җәенә туры килде. Ул җәйдәниләр булганын мин башта ук язып узган идем инде. Кыскасы, Гражданнар сугышы бара, Дәүләкәнгә сугыш әле бер яктан, әле икенче яктан килеп җитә, кешеләрдә баш кайгысы да мал кайгысы... Шул чакта сугыштан куркып без дә китеп бардык, Борһан абзый да балаларын төяп, Уфага китеп барды, мин дә «кошчыгымны» күпмедер вакытка күздән югалттым. Әмма күкрәгемнән очырмадым! Моның шулай икәнлегенә мин яңадан Дәүләкәнгә кайткач ышандым: уянды минем ап-ак кошым күкрәгемдә!.. Беренче көннән үк мин аның уянганын сиздем. Тизрәк аны күрергә ашыктым... (Бу вакытта алар да Дәүләкәнгә кайтканнар иде инде.) Елдан артык югалтып тордым мин

аны — ничегрәк, нindirәк икән ул хәзер?.. Без бит бер яшькә үстек, үзгәреш бардыр, буйга гына түгел, башка яктан да әзрәк үскәнбездер... Минем, мәсәлән, хәзер койма ярыгыннан карап торасым килми, минем өйләренә кереп күрәсем, дәшәсем һәм сөйләшәсем килә.

Аларга беренче керүемне ачык кына хәтерләмим. Һәрхәлдә, Уфага киткәнче үк булгандыр дип беләм, чөнки кызыллар беренче тапкыр Дәүләкәнне алгач, бөтен йортларга рәттән атлар, солдатлар куйдылар. Борһан абзыйның капкасы да, ниһаять, төбенә хәтле шыңгырдап ачылды. Билгеле инде, атлар, солдатлар бар җирдә һәрвакыт малайлар кайнаша. Без менә шул чакта Борһан абзый ихатасына да курыкмыйча кереп йөрдек. Әлбәттә, мин «аны» да күргәнмендер инде, ләкин ничек итеп — якыннанмы, ерактанмы — ул кадәресе исемдә калмаган. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки без, малайлар, өеребез белән йөрибез, без иптәшләр алдында кыз күзләүдән бик куркабыз. Тик бер нәрсәне яхшы хәтерлим — аның Һаҗәр исемле икәнен шул чакта ук ничектер белгән идем.

... Егерменче елларга да кердек. Сугышлар бетәргә өлгермәде, коточкыч ачлыгы килеп җитте. Ләкин, шуңа да карамастан, мин күрше кызын онытмыйм, мин аның барлыгын тоеп яшим... Бәлки, ул бу авыр чакта миннән ерагаеп, томан эченә китебрәк торгандыр — ачлык бит ул бөтен нәрсәне кешедән ераклаштыра. Хәтта бергә уйнап йөргән малайлар белән дә очрашулар бу вакытта бөтенләй бетә язган иде. Әмма адәм баласы, әгәр исән калса, үзенең өмет-хыялларын әллә нинди һәлакәтләр аша да түкми-чәчми алып чыга икән... Барсы да терелә, барсы да яктыга үрелә. Ә мәхәббәт хисе барсыннан да элегрәк уяна, элегрәк әйләнеп кайта.

Мин дә, билгеле, шул ук хәлне кичердем, ләкин башкачарак итеп кичердем. Чөнки мин тагын берничә яшькә үстем. Хәзер инде минем Һаҗәргә гыйшкым тагы да көчәя, тирәнәя төшү белән бергә, ничектер аңлырак, мәгънәлерәк тә була башлады. Баштагы шикелле аның мине үзенә ни өчен тартуын аңламыйча мңгерәүләнеп йөрү урынына, мин хәзер үземдәге аңа булган хисләрнең нәрсә икәнен, кайдан килгәнен шактый ук дөрес чамалый идем. Бик яшерен рәвештә генә, курка-курка гына үземә: «Бу мәхәббәт!»— дип әйтә дә ала идем. Унөч-ундүрт яшьләрдә моның шулай икәнен аңлау, шуңа тәмам ышану, минемчә, бер дә гаҗәп түгел.

Аннары мин бу яшьтә әдәбиятны күп укый идем. Җитмәсә, үзем дә әдип булу турында хыяллана башлаган идем. (Ә матур әдәбият ул мәхәббәткә сусауны бик көчәйтә, ашыктырып бирәр кызга гашыйк та иттереп куя. Сынаганыгыз бардыр, шәт?!) Соңыннан, еллар узгач, мин үземнең Һаҗәргә булган мәхәббәтемне күбрәк шул роман, хикәяләр аркасында тумадымы икән дип тә уйлаштыргалый идем. Һәрхәлдә, күңелдә яралганны көчәйтеп җибәрүдә, һичшиксез, йогынтысы булгандыр аның... Икенче яктан, күрше кызы белән мавыгуым минем «әдип» булырга хыяллануымны да һичшиксез, көчәйткәндер. Кемнең генә яраткан кызына гадәттән тыш шәп кеше булып күренәсе килми?! Хәер, мин моны тәгаен шулай булды дип әйтә алмыйм, ул хакта бәлки уйлый да белмәгәнмендер әле, ләкин шулай да миндәге ярату хисләре күңелдә әкренләп шигърият тойгыларын да уяткандыр дип әйтәсем килә. Хәзерге заман шагыйрьләре шигърият белән мәхәббәтне бер итеп күрәләр, ягъни шигърият ул мәхәббәт диләр турыдан-туры... Тик мәхәббәтне хатын-кыз белән генә чикләнмичә аны җиргә, илгә, кешегә дә күчерәләр. Шагыйрьләр өчен ул ихтимал шулайдыр да, ләкин мин үзем, пәри башка, җен башка дигәндәй, алар икесе ике нәрсә, ягъни хатын-кызга мәхәббәт кешенең үзе белән бергә туа, ә дөньяга мәхәббәтне (яки нәфрәтне) яши торгач кына татый башлыйсың дип уйлый идем. Берсе — табигатьтән, икенчесе — аңнан.

Ярый, фәлсәфә күпкә китте, җитеп торыр. Онытмыйк, мин гашыйк, мин мәхәббәт утында янам! Хуш, ә каршы як, Һаҗәр туташ үзе ничек соң, ничегрәк карый ул миңа, өмит, ышаныч бармы аның тарафыннан?..

Иң беренче вакытларда без әле балалар гына идек, нидер уйлау, нидер белергә теләү дә юк, минем бары аны күрәсем һәм аңа күренәсем генә килә, әмма ләкин аның бер төрле дә карашын сизмим — гүя ул мине белми дә, күрми дә иде. Һәм моңа гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки мин урам таптаучы яланаяк малайларның берсе, үзем арык-котсыз, өстемдә дә ситсы күлмәк, ычкырлы ыштан, ә ул башка — өеннән беркая да чыкмаган, малай-шалайлар белән беркайчан да аралашмаган үзе чибәр, үзе пөхтә, шактый һавалы купец кызы — билгеле инде, карамый, күрми ул!..

...Үтә берничә ел. Без инде бала түгел, үсмерләр... Күңел дә сизгеррәк, зиһен дә үткенрәк... Һаҗәр тагы да матурлана төште, күкрәкләре дә тула башлады. Миңа да бераз ит кунды, битем дә алсулана төште, өс-башым да рәтләнде — Самара талчугыннан кайткан бәрхет якалы тужуркадан, чалбардан, ботинкадан йөрим. Ләкин шуңа да карамастан, Һаҗәр миңа карамый, мине күрми. Мәхмүткә карый, Таһирга карый, ә миңа күз дә салмый. Әйтерсең, мин юк, мин яшәмим аның өчен!.. Ниһаять, әрнеп-сыкрап аңладым: Һаҗәр юри, аңлы рәвештә миңа күз салырга, мине белергә теләми икән... Әмма ни өчен соң, ни өчен, кемнән ул хәтле ким мин?!. Аңгыра-ахмак түгелмен ләбаса, азып-тузып та йөрмим, кешедән ояла да беләм, җан иясен кызгана да беләм. Энеләре, сеңелләре белән дә арам әйбәт кенә, көн саен очрашабыз, сөйләшәбез, бергә уйныйбыз — нигә соң бары аның тарафыннан гына мондый... тәкәббер салкынлык?!. Һәм минем кечкенә башыма бу зур газап иде.

...Тик бер ара гына мин аның игътибарын үземә җәлеп итә алдым. Ул китап укырга ярата иде. (Күп кызларга караганда да.) Еш кына мин аның ачык тәрәзә төбендә, алга күчергән чәч толымын бер сүтә, бер үрә-үрә итәгендәге китабын укып утырганын күрә торган идем. Моңа мин һәм сөенәм, һәм өмитләнәм, чөнки бу хәл мине ничек тә аңа якынайтырга тиеш иде. Үзем мин китапханәгә дә йөрим, кешеләрдән дә алып укыйм. Сүз нәрсәдән, ничек башланып киткәндер инде, ләкин озак та үтми мин Һаҗәргә китап ташый башладым. Әлбәттә, бик теләп һәм рәхәтләнеп... Мин аның янында булам, мин аңа дәшәм, кулына китап бирәм яки алып китәм... Минем бер дә тиз генә китәсем килми, минем озаграк сөйләшәсем килә (укылган китап турында күпме сөйләшеп булыр иде!), ләкин кызганычка каршы, миндәге теләк Һаҗәрдә юк. Нишләтәсең, юк кына бит!.. Юри сорашсам да аның өзеп кенә «ошады» яки «ошамады» дигеннән башканы ишетмим. Сизәм инде, сизәм, тизрәк китүемне көтә. Гаҗәп, эремәсә эреми икән эчендәге зәңгәр боз!

Бу хәтле салкынлыкның сәбәбен мин ул чагында, әйткәнемчә, аңлаудан гаҗиз идем. Шулай да соңрак бер хакыйкатьне ачкандай булдым: аңа минем яратуым бер дә ошамый икән ләбаса, шуңа ачуы килә, шуның өчен гел сырты белән тора икән ул... Гәрчә мин яратуымны телдән бер вакытта әйтмәсәм дә, ул аны һичшиксез белә иде. Үземә карап та һәм бүтәннәрдән ишетеп тә, чөнки минем Һаҗәргә «гыйшык тотып» йөрүем, кызганычка каршы, фаш ителгән иде инде. Беләсезме, мәхәббәт газабын үз эчеңдә генә асрап булмый, аны иртәме-соңмы кемгә дә булса ачасың, шуның белән янәсе үзеңә җиңеллек табасың. Менә мин дә Мәхмүт дустыма, җәйге айлы кичләрнең берендә, икәүдән икәү генә йөргән чакта, бик дулкынланып-кичереп, үземнең серемне ачкан идем. Мәхмүт моңлы бала, хәсрәтле җырлар ярата, үзе дә күршеләрендәге Гыйззетдин абзыйның кызы Мәрьямгә гашыйк. (Гаҗәп, малайларның «мәхәббәтләре» гел күрше кызларыннан башлана.) Ул да миңа үз хәлен сөйләгән иде, шулай итеп, уртак хәсрәтләребез булу аркасында без бик

дуслашып та киткән идек. Әмма ләкин минем сөйләгәннәрем, гәрчә Мәхмүт беркемгә дә әйткәнем юк дип антлар итсә дә, Дәүләкән малайлары һәм кызлары арасына таралып та өлгерде. (Ахрысы, тагын берәрсенә «чишкәнмендер» инде.) Мине артымда да, алдымда да үртәү китте, хәтта коймабызга «Әмир + Һаҗәр» дип язып та куйдылар. Ә бит безнең коймалар терәлеп үк тора. Һаҗәр анда нәрсә язылганын белмичә калмый, әлбәттә. Менә шуннан соң минем хәлне күз алдыгызга китереп карагыз инде. Аклану мөмкин түгел, иң яхшысы — күзенә күренмәскә!.. Ходаем, мин бит моңарчы да кагылган гашыйк, ә нигә кирәк булды тагын аның нәфрәтен кузгатырга? Ярата алмаган кеше кызгана да алмый ул... Моның шулай икәнен миңа бер татырга туры килгән иде бит инде. Әмма гашыйклар бер көйдергән утка күбәләк кебек яңадан да барып керәләр.

...Моннан бер ел чамасы элек булган иде ул вакыйга... Көз ахыры иде, көннәр шактый суытты, тугай өстенә ак бәс кунды, ниһаять, менә Дим култыгы, Комач өсте дә куксел боз белән тигез генә капланды. Ә кар юк, кар әле төшмәгән иде. Бер-ике-өч көн узуга Комач бозы безнеңише малайларны күтәрерлек ныгып та өлгерде. Әнә шундый көннәрнең берсендә өч кыз Арыслангәрәй тыкырыгыннан су буена төштеләр. Болар безнең каршыдагы Таифә апа һәм Гайшә апа белән Һаҗәр иде. Мин аларны яр башында очраттым һәм нишләптер үзем дә аларга ияреп төштем. Бәлки Таифә апа дәшкәндер, ул хәйләкәр кыз иде, минем хәлне дә белә иде, хәер, дәшмәсә дә, Һаҗәрне күргәч, иярмичә булдыра алмадым инде. Төштек шулай, мин шунда ук боз өстенә кереп киттем — ул тәмам ныгыган, зурларны да күтәрерлек иде. Кызлар да әзрәк таптанып тордылар да сакланып кына бозга бастылар. Шуа-шуа гына киттек. Мин кыюлык күрсәтергә теләп, алдан йөгереп барып шуып та китәм, ә алар кулларын җәеп, аумаска тырышып, вак-вак кына шуышып киләләр. Шулай бара торгач, шактый киң Комачның аръягына да чыгып җиттек. Кызарышкан идек, куанышкан идек, миңа да бик күңелле иде. Ни сәбәптер бу вакытта боз өстендә беркем дә юк, тик бераз ерактарак мин белмәгән бер малай үзе ясаган «тимераякта» шуып маташа иде. Малай буйга да миннән зур, яшькә дә олы булырга тиеш. Без, бераз тын алгач, кире үзебезнең якка чыга башладык. Шул чагында теге малай кулындагы таягын күтәреп, туп-туры минем өскә җилләнеп килмәсенме?! Күрәм, усал ният белән килә бу, ә минем кулымда берни дә юк. Шуннан мин тоттым да ярга таба чаба башладым. Барып җитсәм, каты җиргә басам, кулыма ташмы, таякмы да ала алам. Малай чакта мин бик шәп йөгерә идем, берәүне дә уздырмый идем, бәлки хәзер дә аны җиткермәгән булыр идем (ул бит агачтан ясаган «Тимераякта»), ләкин бәхетсезлеккә каршы, ярга җиткәндә генә нәрсәгәдер сөртенеп, йөзтүбән барып та төштем. Малай килеп тә җитте, кулындагы таягы белән минем тубыкка китереп тә сукты. Минем сыным катты, хәтта тавышым да чыкмас булды — тубыкның никадәр авырта торган җир икәнен белсәгез иде!.. Ә кызлар алдында хурлыгы ни тора?!. «Гашыйк» пычрак ярда аунап ятсын әле! Мин кызулык белән сикереп тормакчы да булган идем, ләкин аякның яман авыртуына түзә алмыйча яңадан бөгелеп төштем. Шул арада кызларым килеп җиттеләр. Таифә апа юри генә кызгангандай: «Егет, сиңа ни булды?» — дип сорады, ә Гайшә апа белән Һаҗәр тукталып тормыйча көлә-көлә үтеп тә киттеләр. Я, шәфкатьсезлек, түгелме бу? Күсәктәй малайның куып җитеп, таяк белән тубыкка сугуын күрделәр ич, күрделәр!.. Бәлки, минем куян шикелле качуымнан көлә торганнардыр... Чын малай эшемени ул качу... бигрәк тә кызлар алдында! Әлбәттә, канга батканчы сугышырга кирәк булган, тагы да катырак кыйналырга, ичмасам, бу кадәр хурлыгы булмас иде.

Әнә шундый тән һәм җан ярасы алган идем мин ул чакта. Әмма адәм баласы әрсез, тиз онытa барсын да, яра да әкренләп төзәлә, тик

җөе генә торып кала. Боз өстендәге вакыйгадан соң бер-ике ел үтеп тә китте. Без тагын шактый гына үстек. Миңа инде 16 нчы яшь, егет булып барам. Ә Һаҗәр чын туташ булып җитте. Аның миннән ике яшькә олырак булуын да белдем. Өлгергән туташка мәхәббәт тә аеруча көчәя икән... Дөрес, безнең ара әүвәлгечә ерак, әүвәлгечә салкын, ләкин хәзер без бер-беребезгә карата әдәп саклыйбыз, очрашканда исәнләшәбез, сирәк кенә сөйләшүдән дә качмыйбыз. Һаҗәр мине яратмавын электәге шикелле ачык күрсәтми һәм ачыктан-ачык кырын да тормый. Боларны ул ничектер әчкәрәк яшерде. Шулай да мин чын хәлне күреп торам, Һаҗәрдә өмитем юк диярлек, әмма аның турында хыялланырга яратам. Гашыйкның бер үҗәтлеге бар — ул чигенә белми. Гашыйк ул — шыр тиле!

Хуш, кай тирәдәрәк йөри минем хыялларым? Хәер, башта менә нәрсәне әйтергә кирәктер, ахрысы: мин инде язу-сызу белән чынлабрак мавыга башладым. Почмакка куйган кечкенә өстәлем бар, өстәлдә бәләкәй генә өем китапларым тора, каршыдагы стенага уку китабыннан копировка аша күчереп алган Тукай белән Лермонтов рәсемен дә ябыштырып куйдым. Көн дә шул өстәлемдә күпмедер утырган булам, аны-моны сызгалыйм, шигырь нишләптер чыкмый, ә хикәя-мазар язарга «мәүзугь» (тема) таба алмыйм. Әллә пьеса язып карарга мы?.. Театр куярга җыенсак, пьеса таба алмыйча йөдибез. Шәп булыр иде барып чыкса!.. Көннәрдән бер көнне Дәүләкән коймаларында шәмәхә кара белән язылган афишалар: Бәлдәй клубында фәлән-фәләневнең 5 пәрдәлек әсәре куелачак!.. Ха, моңа хәтта Һаҗәрнең дә исе китәр иде. Тик менә нәрсә хакында язарга?.. Үзебезнең тирәдән бер нәрсә дә табылмый бит әле... Әллә булмаса, Англиядәге эшчеләр хәрәкәте турында язып карарга мы?.. Тәк, тәк, гәзитәләрдә дә күп язалар андагы эшчеләрнең революцион көрәше турында... Валлаһи дип әйтәм, мин шундый пьеса язарга тотынган да идем. Гәзитәләрдән инглиз исемнәрен чүпләп алдым, шуларны «катнашучылар» итеп тезеп чыктым һәм яңа биттән аларны «уйната» да башладым... Ярый әле тиз айнылым мин бу эштән... Юк, егетләр, язучы буласы килгән кешенең бала чакта да ахмак булырга хакы юк!..

...Тагын өстәп шуны да әйтәсем килә: мин әүвәлгечә һаман китап укырга ярата идем. Күбрәк иске әдәбиятны, чөнки яңасы бик аз табыла иде әле... Ул чактагы минем хыялларыма иске әдәбиятның турыдан-туры йогынтысы булгандыр, ахрысы... Мәсәлән, мин өмитсез мәхәббәттән чахуткага сабышканмын, имеш. Мин үлем түшәгендә, көннәрем дә санаулы гына калган... Ә күршебездә Һаҗәрнең туен гөрләтеп үткәрәләр икән. Аны кызыл симез чырайлы бер таза егеткә бирәләр имеш. Мин менә шул туйны — ишегалларыннан ишетелеп торган җыр-музыка тавышларын, егетләр-кызларның шаулап-шатланып көлүләрен ишетеп ятам... Бик авыр, имеш, минем хәлем... Ул да булмый, бер заман кыңгыраулы пар атларда Һаҗәрне егет йортына алып китәләр. Шул чагында мин актык көчемне җыеп урынымнан торам да, ачык тәрәзәгә сөялеп, соңгы мәртәбә скрипкада бик моңлы бер көй уйныйм имеш!..

Очтылар «моңнар» фазага, җырлашып кызлар белән.
Мин торып калдым, торып калдым күңел сызлау белән![1]

Әнә шундый төче, сентименталь, мәгънәсез хыял. Әлбәттә, каяндыр кергән инде ул миңа...

Егерме бишенче елны Казанга киткәч тә мин Һаҗәр турында уйланудан туктамадым. Казан минем дәрәҗәмне аның алдында күтәрергә тиеш иде. Дөрес, килгән елны ук миңа уку насыйп булмады, китап магазинында курьер булып кына эшләргә туры килде. Аның каравы «Безнең юл»да минем «Озын көй тыңлаганда» дигән беренче зәгыйфь кенә әйбе-

---

[1] Ш. Бабич шигыреннән.

рем басылып чыкты... Әйбер зәгыйфь булса да, журнал үзе бик авторитетлы иде — шул заманның бөтен мәшһүр язучылары аның битләрендә басыла иде. Менә мин дә шулар арасына кысылдым.

Егерме алтынчы елның җәендә мин яңа чалбар, яңа ботинкалар киеп, «Безнең юл»ны да үзем белән алып, Дәүләкәнгә ялга кайттым. Бу вакытта шактый гына чибәрләнеп тә киткән идем, коңгырт чәчләрем дә ак маңгаема алкаланып төшеп тора иде. Дәүләкәндә калган иптәш малайларым да, таныш кызларым да миңа, билгеле, шунда ук игътибар иттеләр, кызыксынып, сокланыбрак карадылар. Кар же, Казаннан кайткан егет!.. Ә Казан ул елларда Дәүләкәннән бик еракта иде.

Кайткан көнне үк мин Борһан абзыйларга да кердем, һәммәсе белән дә күрештем, һәммәсе дә мине шаулап каршы алдылар. Һаҗәр дә миңа игътибар итмичә калмады — күреште, төбәлебрәк карады, хәтта сөйкемле генә елмайды да...

...Шул чакларны искә төшерсәм, бәгырьне үкенү хисе телеп уза: ходаем, нигә дим мин шул хәтле җебегән булдым икән?! Үземне иркен, бәйсез тотасы урында, тагын элеккечә кызара, тотлыга башлыйм. Гүя мин, чәч җибәреп кайтсам да, һаман әле малайлыктан чыгып җитмәгәнмен. Ачу китергеч хәл! Тагын иң гаҗәбе, Һаҗәр алдында каушау ничектер гадәткә керә язды, соңыннан башка кызлар алдында да мин еш кына югалып кала торган булдым. Ә туташым яңадан салкын калыбына керде, горур-өстен ул, хәтта Казан журналында минем исемем белән басылган «Озын көй»... дә аңа тәэсир итмәде бугай... Һәрхәлдә, укыды да, бер сүз әйтмичә кире кайтарып бирде. Әмма шунысына шөкер итәм, аның тирәсендә күп чуалмаска минем шулай да көчем җитте. Бик тиз бергә үскән, сагындырган дусларым арасына кереп киттем. Безнең бергә иңләгән Димкәебез бар, аның киң тугайлары бар, тугайларында камышлы күлләре бар — җаның теләгән кадәр чап, чум, уйна, ауна!..

Миңа, Казанның салкын кышын ике-өч көнгә бер генә ягылган һәм юньләп яктыртылмаган да ташландык йортында үткәргән, тәмам суырылып, агарып кайткан яшь-яшь егеткә тагын ни кирәк?!. Ул йорт турында, җае чыкса, сүз булыр әле, ә хәзергә әйтәсе килгәнем шул — минем үпкәләрем элек тә бик үк сәламәт түгел иде, язын үземне начар тоя башлап, Әбүбәкер абзыйга[1] күренгәч, ул миңа туп-туры әйтте: «Энекәш, йөрмә монда, Дәүләкәнеңә кайт, саф һавада йөр, кояшта кызын, күбрәк сөт-май аша, хәлеңнән килсә кымыз эч!»— диде. Димәк, мин әле сәламәтлегем турында да уйларга тиешмен икән. Әбүбәкер абзый киңәшләрен тоту Дәүләкән шартларында бик җиңел иде ул елларда. Барысы бар, барысы җитәрлек, һава да, ризык та саф, пакь, шифалы. Сөт-май үзебезнеке, яшь сарык ите көн дә базарга чыгып тора, ике көннең берендә Акколайдагы дус башкортыбыз бер чирек кымыз да калдырып китә. Юкка гына ул елларда Дим буена кымызчылар агылып килми торганнар иде.

Аннары минем белән бер вакытта Казаннан Фәхтелислам белән Хәбибрахман да кайтканнар иде. Уфадан кайтучылар да бар иде. Дәүләкәннең үз яшьләре дә күп, бик активлашып барган чаклары. Клубка җыелу, спектакльләр кую, кичке уеннарга чыгу, Дим өстен яңгыратып көймәләрдә йөрү — болар гадәткә кергән күңел ачулар, ләкин мин алар хакында хәзергә сөйләп тормыйм, чөнки бу күңел ачуларның берсенә дә Һаҗәр йөрми — катнашмый иде. (Бәлки атасы тыйгандыр, ә бәлки үзе теләмәгәндер.) Шул сәбәпле минем өчен иң якты хатирәләр белән бәйләнгән күмәк уеннарда аның урыны буш, бары тик күңелне әкрен генә сызландырып, каядыр эчтә генә ул саклана иде.

Көз яңадан Казанга баргач, мин, ниһаять, укырга керә алдым. Уку ул минем киләчәгем — башка бүтән юл юк миңа. Язучы булыр өчен дә

[1]Доктор Әбүбәкер Терегулов — соңыннан профессор. Безнең Каргалыдан чыккан кеше. (Ә. Е.)

уку зарури. Аңлырак яшьләрнең барысы да хәзер укырга омтыла — Себердән, Уралдан, Донбасстан һәм тагын бик күп яклардан татар яшьләре агылып килә башладылар. Казан урамнары йөзләренә азрак аптырау да, кызыксыну да, куану да чыккан бик чуар киемле шул яшьләр белән тулды. Бездән күрмәле дигәндәй, бу көзне бер унлап Дәүләкән яшьләре дә Казанга килделәр. Кайсылары татрабфакка, кайсылары педагогия техникумына урнаштылар. Урнаша алмаганнары кире кайтып киттеләр. Торып калганнары барысы да диярлек электән үк бергә укыган, бергә йөргән таныш егетләр һәм кызлар иде. Бары казак Усман дигәне генә ят егет, яшькә дә олы, үзен бик өстен тотарга да яратучы иде. Кәкрерәк нечкә борнының ике ягында батып торган соры-салкын күзләре дә аның кешегә гел сынап, шикләнеп карыйлар төсле иде. Ул Совпартшколага укырга керде. Калганнарыбыз исә якын авылдашлар сыйфатында еш кына очрашып, хәбәрләр уртаклашып, өйдән килгән күчтәнәчләребез белән дә сыйлашып тора идек.

...Инде студентлар буларак без барыбыз да кышкы каникуллар вакытында тагын Дәүләкәнебезгә кайттык. Ике атна чамасы вакытны концертлар куеп, кунакларга йөрешеп бик күңелле генә уздырып җибәрдек. Менә шушы вакытта минем өчен фәукылгадә бер вакыйга булды — гомеремдә беренче мәртәбә Һаҗәр белән кинога бардым. Бу «бәхеткә» мин күршебез Таифә апа аркасында ирештем. Билгеле, минем үтенүем буенча, ул башта Һаҗәрне үзләренә кич утырырга чакырган, аннары ничектер җайлап-көйләп кенә кинога барырга күндергән. Шулай итеп, без өчәүләшеп иске заманнан ук эшләп килгән «Томанныйга» киттек. Билетлар алып, залга кергәч, Һаҗәр уртага утырудан да баш тартмады. Картина, әлбәттә, хәтердә калмаган. Янымда гына «ул!» Маңгай күзе экранда булса да, күңел күзе бары тик аңарда гына!.. Билгеле, мин аның җиңенә кагылырга да җөрьәт итә алмадым. Шулай ук берниндн сөйләшү дә булмады. Бәлки, Таифә апаның янәшә генә утыруы да телне бәйләгәндер, хәер, бик игътибар белән кино караган кызга нәрсә генә әйтә алаҫың?!.

Карап бетердек, салкын төнгә чыктык, шыгыр-шыгыр атлап, өйләргә ашыктык... Өйләребез бер төштә, кайтып җиткәч урам уртасында туктадык, хуш, шуннан соң... шуннан соң кызларга хәерле йокы теләргә генә калды. Ләкин хәерле йокы теләр алдыннан мин шулай да Һаҗәрдән сорадым:

— Һаҗәр, сезгә хат язарга ярыймы?

Ул әз генә көттереп һәм юри генә көлемсерәгән булып:

— Языгыз!— диде.

Шуннаң соң инде кызларым үзләренә кереп киттеләр, ә мин капкабызга таба атладым. Өйгә керәсе килми иде, бераз рәшәткәгә сөялеп тордым. Дәүләкән йоклый, тынлык һәм бушлык... Минем күңелдә дә шулайрак... Нәрсә генә бирде миңа бу көтеп, теләп алган кинога бару?.. Бер генә өмит чаткысы да кабызмады шикелле ул миндә... Юк, әллә кабыздымы?.. Дөресен мин соңрак белдем: аз гына кабызган икән шул!..

...Әйе, нәкъ шушы кечкенә өмит чаткысы кабынганга күрә дә мин Казанга китәр алдыннан, инәйне ризалатып, үзебездә яшьләр кичәсе уздырдым. Ул чакта залыбыз буш иде әле... Төп максат, билгеле, Һаҗәрне чакыру, керерме-юкмы — бу минем өчен гаять мөһим иде. (Моны, әлбәттә, Таифә апа аша гына эшләргә мөмкин иде.)

Әйтелгән көнне, дәшелгән сәгатьтә чакырылган кунакларым — унбишләп егетләр, кызлар — дәррәү генә килеп беттеләр. Таифә апа белән Һаҗәр юк әле. Мин борчылам, хәтта борчылуымны яшерә дә алмыйм. Иң куркытканы тагын шул: менә сигез ел инде терәлеп торган күршеләр булып яшәсәк тә Һаҗәрнең безнең өйгә бер кайчан да, бер генә тапкыр да аяк атлап кергәне булмады. Сәер халык шулай да бу

Борһан абзый семьясы. Ә аңа хәзер әзер сылтау: кергән җирем түгел, кермим — вәссәлам!

Тышкы ишек төбендә аяк каккан тавышлар ишетелде. Атылып чыксам — Таифә апа, ә артында Һаҗәр басып тора!.. Рәхим генә итә күрегез, туташлар!.. Әйдәгез әйдә, узыгыз-уз! Бик көтә идек сезне... «Кадерле кунак көттереп килә»,— ди Таифә апа, миңа күз кысып. Зарар юк, зарар юк, дим инде мин өтәләнеп, чынлап та шулай бит — өмитне бер вакытта да ашыгып сүндерергә ярамый, егетләр!

...Башта кунакларны инәйнең тәмле сыйлары белән чәй эчердек, аннары стена буена тезелешеп утырып, төрле уеннарга күчтек. Танца дигән нәрсәне белми идек әле ул чакта, әмма үзебезнең гади көйләрне кумәкләшеп җырларга бик ярата идек. Безнең күп уеннарыбыз борынгы аулак өйләрдә туганнар, шуңа күрә аларны артык шауламыйча утырып кына уйныйлар да... Дөрес, без үскәндә инде яңа уеннар да туган иде — мәсәлән, кулга-кул тотынышып, җырлый-җырлый әйләнә торган «римский папа» (исеме каян килгәндер, хода белсен!) яки менә укыганрак яшьләр арасында бик модный булып киткән «мәхәббәт почтасы»... Чын булса, бу соңгысын шагыйрь Ченәкәй бастырып чыгарган, имеш. Моңа ышанырга да була, чөнки төрле чәчәкләр исеменнән мәхәббәт сүзләрен аңардан башка кем генә язып таратыр икән?!.

...Без дә уеннарның берсен дә калдырмадык, көлдек, шауладык, ләкин киртәдән чыкмадык — әдәп-инсаф дигән нәрсә бездә бар иде әле. Кыскасы, кичәбез күңелле-матур гына узып бара, кунакларым шат, мин үзем дә бик шат, бигрәк тә Һаҗәргә карап сөенәм — ул да бернинди канәгатьсезлек сиздерми иде.

Әмма шатлык тиз үтүчән. Бигрәк тә бөтен уең гел «бераү» тирәсендә генә әйләнсә, бер мизгел эчендә барысы да үзгәрергә мөмкин. Чөнки синең кәефеңә беткәнче ул хуҗа.

...Соңгы уеннарның берсе иде шикелле. Уенның исемен дә оныткан-мын, ничек башланганын да хәтерләмим, бары тик үземә кагылган кадәресе генә ташка чукып язгандай хәтердә калган... Ул болай булды: миңа кече якка чыгып торырга куштылар, аннары бераздан чакырып керттеләр. Шул вакыт эчендә уенга катнашучылардан минем турыда сүз (фикер) җыйганнар. Уенны алып баручы үткен кыз Маһирә миңа шуларны укый: фикерләрнең яхшылары бар, бик үк яхшы булмаганнары да бар, ләкин күбесе көлке сүзләр — мәсәлән, «Әмир төшендә кемне ешрак күрә икән?» яки «Әмирнең колаклары зур, күзләре кечкенә, нидән ул алай?»— кебекләр. Минем бурыч үзем сайлап, шуларның берсен «ачу», ягъни кем язганын әйтеп бирү. Әгәр дөрес әйтсәм — мине аның янына утырталар, әйтмәсәм — җәза бирәләр. Күп очракта, билгеле, ялгышасың.

...Кайсын сайларга икән дип уйланып торганда тагын бер бик хикмәтлесе килеп чыкты: кечкенә кәгазь кисәгенә «Мин Әмирханны яратам» дип язылган иде. Монысы шунда ук минем уемны да, күңелемне дә били алды.

— Йә, кайсын сайладың?— дип сорый Маһирә миннән.

— Соңгысын.

— Үзең дә сайлый беләсең икән, егет!.. Йә, кем язган соң аны?..

Мин ике дә уйлап тормыйча, ниндидер балаларча беркатлылык белән, тик аз гына каушый төшеп, тоттым да:

— Һаҗәр!— дидем.

Әйтүем дә булды, бөтенесе егылып көләргә дә тотындылар. Тыела алмыйча озак итеп. Үртәп тә, мыскыллап та, кызганып та көлү иде бу... Мин шул мизгелдә үк нинди зур ахмаклык эшләвемне сизеп алдым, әмма эш узган, исем — йөрәктә генә сакланасы исем авыздан ычкынган иде инде. Тиледән сорама үзе әйтер диләр. Хәер, монда утыручыларның

кайсысы гына минем Һаҗәр белән саташуымны белми икән?! Ләкин аларның берсе дә мин үземне-үзем генә болай ахмакларча фаш итәрмен дип көтмәгән иде, әлбәттә. Һәм мин алар алдында гүя шыр-ялангач калган бер хәлдә идем. Һәм бу хәлдән чыгар өчен миңа да кычкырып көләргә — юри көлкегә әйләндерергә кирәк иде дә бит, тик минем — сантыйның шуңа да тапкырлыгым җитмәде. Түгәрәк уртасында кая яшеренергә белмичә бераз таптанып тордым да, аннары уттай янып, кызарып тизрәк бер читкә китеп утырдым.

Ә «яратам»ны язучы... чукынмыш Таһир булып чыкты. Маһирә шуны әйткәч, егетләр, кызлар тагын бер «тәгәрәшеп» көлделәр. Бусы тагы да әшәкерәк булды. Ичмасам, кызлардан берәрсе уйнап кына язган булса да мин бу хәтле үк оятка калмас идем.

...Башта Һаҗәр утырган якка карый да алмадым — сикереп торыр да дулап чыгып китәр дип курыктым. Тик бераздан сакланып кына күз төшерсәм, туташым кузгалырга уйламый да кебек, йөзе алсуланган, күзләре кысылган — башкалар белән бергә рәхәтләнеп көлгән булса кирәк. Минем көлкегә калуым аңа ошагандыр ахрысы, ә бәлки әле эченнән генә «шәп иттеләр!» дип кинәнеп тә куйгандыр. «Шул кирәк сиңа!»— дидем мин үз-үземә ачулы нәфрәт белән...

Әнә шулай төгәлләнде минем ниндидер өмитләр багълап уздырган «кызыклы» кичәм. Хәер, кунакларым өчен ул чынлап та кызыклы узды. Киткәндә бик канәгать булып, миңа да, Хәдичә абыстайга да (инәйгә) рәхмәтләрен әйтә-әйтә таралыштылар. Барсы белән бер үк вакытта Һаҗәр дә чыгып китте. Бу юлы мин, каршы алгандагы шикелле, аның тирәсендә бөтерелергә теләмәдем. Бер читтәрәк тик кенә торып калуны артыграк күрдем.

Зал бушап калгач, минем җанымны бер шик кимерә башлады: кызлар, егетләрнең кемнән, ни өчен бу хәтле көлүләрен инәй белмәде микән?.. Эчке якта утырса да монда кычкырып әйткән сүзләрне ул мотлакан ишеткәндер инде. Әмма ишеткәнен миңа сиздермәскә тырыша кебек — уйчан, сүзсез генә залны җыештырып йөргән була. Ә минем шигем аның саен көчәя генә бара — ишеткәндер, һичшиксез, ишеткәндер!.. Бик газаплы үтте минем ул төнем...

Әйе, кечкенә шатлык та кайчак зур булып тоела, зур газап та торабара кечкенә булып кала. Үзгәрә, язгы-көзге һава шикелле үзгәрә гашыйклар кәефе... Тик соңыннан искә төшергәндә шатлыгы да, газабы да күңелдә бары үкенү хисе генә уята... Инде тынычланырга да вакыт түгелме икән?.. Җиткәндер, ахрысы... Аңгыра, селәгәй малай чактан ук башланган бу «гыйшык утында» яну сигез елга сузылды, әмма аның утыннан ник бер өмит чактысы кабынсын иде дә, ник бер җылылык җанга иңсен иде! Һаҗәрнең бер-ике тапкыр гына игътибар иткән булуы да бер үртәү, бер ымсындыру булып кына калды түгелме соң?! Юк, җиткәндер, ахрысы, җиткәндер... Вакытны заяга уздырырга ярамый. Миңа бит тиздән унсигез тула. Миңа инде кызлар карыйлар, мин үзем дә кызларга карыйм. Буем-сыным, йөзем-битем кешенекеннән бер дә ким түгел. Казанда укыйм, таныш-белешләрем арта бара, язучылар арасына да әкренләп кенә кереп барам — япь-яшь көе боларга ирешү, нигә азмыни ул?.. Дөрес, кыюлык белән әрсезлек җитми-җитүен, ләкин бит үсә-өлгерә төшкәч, аларына да өйрәнербез. Хәзер менә нәкъ өйрәнә-өйрәнә тәҗрибә туплый торган чорга кердек бугай...

Кыскасы, мин үземдә Һаҗәрдән суыну сизә башлагандай булдым. Һәрхәлдә, аңа өмит баглауның бикәрлеген инде аңладым шикелле. «Рөхсәт итүенә» карамастан хат та язмадым, чөнки ни генә, ничек кенә язсам да барыбер җавап булмаячак. Әйе, онытырга вакыт, онытырга!.. Башканы эзләргә, башканы табарга — тик күңелдә бушлык кына туа күрмәсен! Әмма бөтен бәла шунда ки, мин бит ел саен Һаҗәрләр күршесенә кайтам, алдан ук аның белән очрашасымны, күрешәсемне белеп кайтам... Һәм, билгеле инде, бөтенесе дә яңадан йөрәктә яңара.

Егерме жиденче елның җәендә, укуларны бетергәч, без яшьләр тагын үзебезнең Дәүләкәнебезгә кайттык. Бу инде июнь ахырлары булгандыр. Гадәттәгечә, якын күршеләребез Бибикамал апаларга һәм Борһан абзыйларга кереп, күрешеп чыктым. Һаҗәрне күрмәдем — Хәйретдин жизниләргә киткән иде, диделәр... Бер атна чамасы вакыт узды, ә минем аны һаман күреп сөйләшә алганым юк әле. Сылтаусыз керергә кыенсынам, ул бит инде егерме яшьлек туташ, миңа хәзер әдәп кагыйдәсен сакларга туры килә... Әлбәттә, без очрашмыйча калмабыз, күрешербез, сөйләшербез дә, тик минә ничегрәк каршы алыр икән ул мине, ничегрәк үзен тотар икән — бик мөһим бу минем өчен. Мин дә бит хәзер башка!.. Һәр җәһәттән...

...Ә матур иртәләрнең берсендә, булачак очрашу турында әнә шулай хыялланып яткан чакта каршыбыздагы Габдрахман кереп, сөенче әйткәндәй, авызын ерып, миңа хәбәрне салды:

— Беләсеңме, синең Һаҗәреңне бер егет алып киткән бит...

Мин ирексездән сискәндем, ләкин:

— Юкны, лыгырдама!— дидем, ничектер уйламастан гына.

— Ышанмасаң, әнә, энеләреннән сора!

— Койма аша гына торабыз, алып китсәләр, кыңгырау тавышларын мин дә ишетер идем,— дигән булам, акылга сыймас бу хәбәрне уенга борырга теләп. Ә Габдрахман күзләрен хәйләкәр генә кысып, отыры мине үртәгәндәй:

— Атлар жиктереп торырга вакытлары булмаган шул,— ди.— Кичкенә төенчеген алган да шыпырт кына чыгып сызган... Һаҗәрең!

Юк, әллә нәрсә бу, шайтан алгыры!.. Габдрахманны беләм мин, кеше үртәргә, ялган сөйләргә аңа гына куш! Әмма... Әмма бу юлы ялганламый кебек, явыз!

— Ни сөйлисең син... черки!..— дим мин кашларымны җимереп.

— Белгәнемне сөйлим... Ялганласам, баскан урынымда җир йотсын!

Мин сикереп тора яздым, ләкин тыелып калдым. Ниһаять, ышандым мин... тындым. Дөньяда булмый торган эшмени ул?!

Габдрахманның әйткәннәре дөрес булып чыкты: Һаҗәр кичә көпәкөндез әтисенә дә, үги әнисенә дә әйтмичә генә бер егеткә ияреп киткән дә барган. Станциядә ахирәтләреннән кемдер аларны озатып та калган, имеш.

Бу эшнең ничек булганын төпченеп сорашу минем өчен бик уңайсыз иде. (Ничек тә сер сынатмаска кирәк иде миңа.) Шулай да әкренләп кайбер нәрсәләрне белдем: иярттеп китүчесе Ыслактан килеп чыккан Низам исемле бер егет, имеш. Борһан абзый күршесе Арыслангәрәй агайларда күпмедер вакыт кымыз да эчеп торган... Һаҗәр белән танышып китүе шул чакта булгандыр, ахрысы.

Хуш, ярый, исемнәре Низам да булсын ди, ә нинди рәк кеше икән соң ул егет?.. Белгәнрәк кешеләрнең әйтүләренә караганда, ул имеш гади авыл гыйбаты гына түгел, утырган, чарланган һәм күпмедер укыган да егет янәсе, өстәвенә, Ыслакның беренче комсомолларыннан ди, ниндидер әйбәт кенә урында эшли дә икән... (Ыслак — волость үзәге иде.) Боларның күпмесе дөрестер, әмма шомарган егет булса кирәк, Һаҗәр кебек һавалы кызны үзенә карата белгән... Ләкин һавалы кызмы соң Һаҗәр? Беренче очраган егеткә тагыл да кит, имеш,— кайда монда кызлар горурлыгы?! Хәер, белмим, антырап кына әйтүем, гайбәтенә керәсем килми... Җаны теләгән жылан ите ашаган диләр, хәерле булсын!.. Хуш, инде нишләргә миңа, утырып бер жыларга, што ли? Юк, булмый, ярамый... Яшерә алмыйм, өмитләрнең болай кинәт кенә өзелүе күңелләрне бик әчеттерде әчеттерүен (сигез ел буена саклап килгән өмитләр иде бит), әмма ант итеп әйтә алам — артык гамь-хәсрәт чикмәдем мин... Күрәсең, көтеп алган хәсрәт булгандыр...

Гажәп, Дәүләкәннең үзендә Һаҗәр кебек чибәр кызга кеше табылмаган. Югыйсә, йорт саен диярлек мыек чыгарган егетләр бар... Бәлки Һаҗәрнең «купец» кызы булуы аларны куркыбрак торырга мәҗбүр иткәндер. Мәсьәләнең бу ягына хәзер бик игътибар итә башладылар. Ә Ыслак егете әнә бер дә куркып тормаган... Беләм мин ул Ыслакны! Әлшәйдән ары, Корсак буенда утырган (Корсак — кечкенә елга исеме) бишме-алтымы мәчетле бик зур мишәр авылы. Базарында да, җыенында да булганым бар. Мәгълүм ки, зур авылның халкы гадәттә бик чуар була. Андый авылларда исемле байлар, мулла-мутагайлар, фанатик картлар белән беррәттән, ата дәһриләр дә, җете коммунистлар да, чая комсомоллар да күп табыла. Низам иптәш тә әнә шундыйларның берсе булса кирәк. Югыйсә, Дәүләкәнгә килеп, «купич» кызын сорамыйча гына алып китәргә батырчылыгы җитмәс иде.

Шулай итеп, Дәүләкәнебездә бер кыз кимеде. Ләкин моңа әллә ни зур әһәмият бирмәделәр шикелле, азрак тел кайрадылар да тындылар... Бездә яшьләр болай да җитәрлек, җәйнең матур чаклары, йөрүләр, күңел ачулар көн саен диярлек булып тора... Мин дә шулар арасында, шул ваемсыз хәят эчендә, бер уеннан, бер тамашадан калмыйм, әмма шулай да кара-калын толымлы «күрше кызы» минем күңелемдә тынып бетмәгән, ләкин әкрен генә ераклаша барган җыр шикелле һаман саклана иде әле.

...Тиз узды шау-шулы көннәр, җәй дә үтте, китәр вакытлар да җитте. Тавыш-тынсыз гына аккан Дим белән хушлаштым, тып-тын айлы төн белән хушлаштым, инде яңадан терелмәс хыялым белән дә хушлаштым...

Казанга кайткач, минем башка бүтән гамьнәр төште. Хәлләр тиз үзгәреп тора бу заманда... Миңа укуны калдырып, Донбасс якларына китеп барырга туры килде (сәбәбен — соңыннан). Шуннан соң шактый еллар узды, күп нәрсәләр баштан кичте, ә Һаҗәр әкренләп һаман ераклашты... ераклашты, әмма бөтенләй үк онытылып бетмәде — кечкенә бер төер сыман күңелнең нииндидер яшерен бер җирендә сакланып ята бирде. Хәбәрем юк, кайда икәнен дә белмим, тик әллә нидә бер искә төшергәлим. Ләкин шулай да каяндыр, кемнәндер колакка кайбер хәбәрләр килеп керде: Һаҗәрләр күптән Кырымда торалар, ире аның — Низам иптәш — шундагы органнарда эшли икән. Димәк тормышлары көйләнгән булырга тиеш.

1972 елны, ягъни кырык биш елдан соң мин Һаҗәрне күрдем. Бу вакытта алар Ессентукида торалар иде — мин моны белә идем. Өч тапкыр Кисловодскида булдым. Икенче баруымда Һаҗәрнең Казанда торучы җизнәсе Хәйретдин абзыйдан Низам Вәлиуллинның адресын алып киттем. Ләкин Кисловодскига соңгы баруымда гына, кайтып китәр алдыннан, мин аларны шул адрес белән эзләп таптым. Акка буялган бер катлы, өч тәрәзәле таш йортның капкасыннан барып кердем. Керүгә үк җыйнак кына җимеш бакчасы, шул бакчага чыккан өй баскычы һәм шул баскычта... Һаҗәр үзе... Мин аны күрүгә таныдым. Ихтимал, белеп килгәнгә күрәдер бу, ләкин шулай да 65 яшьлек карчыкның Һаҗәр икәнлеген танып булырлык иде. Буе-сыны да, йөзе белән кечерәк күзләре дә аның кыз чагын яхшы ук хәтерләтә иде... Мин аңа «Һаҗәр!» дип дәштем һәм таныйсызмы дип сорадым. Ул миңа аптырабрак, сүзсез генә беравык карап торды, бәлки кем икәнлегемне әзрәк чамалагандыр да, ләкин катгый рәвештә, юк, танымыйм, диде... Мин исемемне әйттем. Шуннан соң ул чынлап гаҗәпләнде, ирексездән әкрен генә «ходаем!» дип тә куйды, ничектер каушый да төште, йөзенә бераз гына куанычлы елмаю да чыкты: «Сез, диде, ничек болай, диде, кайдан... әйдә, узыгыз!..— диде. Һәм шунда ук артына борылып, өй эченә: — Низам, чык әле, безгә... менә кем килде!»— дип кычкырды, әмма ни өчендер исемемне әйтмәде.

Өйдән искерәк күлмәк, таушалган чалбардан гына, буйга миннән кайтышрак һәм юанрак кеше чыкты. Бу инде миңа бик күптән таныш Ыслак «егете» Низам үзе иде, әмма менә болай якыннан каршымда күрүем гомеремдә беренче тапкыр гына! Ул да мине гомерендә беренче тапкыр гына күрә, ләкин минем кем булуым турында бөтенләй хәбәрсез иде бугай... Һаҗәр дә безне нигәдер таныштырмады. Шуңа күрә минем үземә кем булуымны, кайдан килүемне, Һаҗәр ханымны бала чактан ук белүемне әйтеп бирергә туры килде. Ул моны бик хуплап каршы алды һәм бик әйбәтләп минем белән күреште. Эчемнән генә тагын уйлап куйдым: ахрысы, бер нәрсә дә белми торгандыр бу абзый кеше!..

...Өйгә кердек, утырыштык. Өйдә тагын бер яшь хатын бар иде — бу Һаҗәрнең Ленинградтан кайткан кызы икән. Аның кулында япон балаларына охшаган ике яшьлек чамасы бик сөйкемле кара гына кызы да бар иде... Утырышкач, алар миннән кайчан килүемне, кайда ял итүемне, тагын күпме торасымны сораштылар. Шуннан соң Һаҗәр торып ук китте (күп булса, бер биш минут утыргандыр) — без Низам белән икәү генә калдык.

Мин бөтен «тарихны» белгәнгә күрә, аңа, билгеле, бик кызыксынып карыйм, ләкин аның егет чагын бер дә күз алдыма китерә алмыйм. Ул бик үзгәргән булырга тиеш. Хәзерге кыяфәте исә шәптән түгел — бик тузган, таушалган кешенекенә охшаган. (Ахрысы, эчкәндер дә... Бу хакта ишеткәнем дә бар иде.) Битен-муенын җыерчык басып бетергән, чәчләре күптән сирәгәеп, агарып беткән, куе кашлары чуалып, асылынып төшкән. Әмма тузган кыяфәтле булуына карамастан, ул шактый тере, җегәрле күренә иде. Аннары сүзгә бик юмарт икән. Беренче генә күрешүебез бит, ләкин шулай да мине якташы итепме, әллә моннан кырык биш ел элек Һаҗәрнең «күршесе» булганга күрәме, үзләренең бөтен тарихларын миңа сөйләде дә чыкты.

Әйе, алар сугышка чаклы Кырымда торганнар. Ул, Низам Вәлиуллин, комсомолдан алып пенсиягә чыкканчы гел органнарда эшләгән. (Ләкин кайсында эшләгәндер — үзе әйтмәде, ә мин сорамадым.) Сугыш башлангач, Һаҗәрне ике баласы белән тиз генә туган авылы Ыслакка илтеп куйган. Шунда ук кире Кырымга кайткан һәм мондагы партизаннар отрядының командиры булып, немецларга каршы сугышкан. Немецларның теңкәсенә бик нык тигән булса кирәк, алар аның башы өчен ун мең марка акча да вәгъдә иткәннәр. Шулай да фашистлар кулына эләкмәгән. Кырымны азат иткәч, яңадан үз эшенә кайткан, ләкин соңыннан үзе дә бу җирләрдә торып кала алмаган... Шуннан соң Башкортстанга кайткан, ләкин анда озак төпләнеп тора алмаган, яңадан бу тарафларга күчерүне сораган. Шулай итеп, начальство боерыгы белән Ессентукига килеп урнашкан. Аңа шушы аерым йортны биргәннәр... Тагын органнарда күпмедер эшләп, ахырда пенсиягә чыккан. Хәзерге вакытта бакча карап, чәчәкләр үстереп, карчыгы белән тыныч кына яшәп ята. Хезмәте, әлбәттә, җиңел булмаган, ләкин тормышы әйбәт тәэмин ителгән булса кирәк. Һәрхәлдә, «күршем» Һаҗәргә, таш койма эчендә утыргандай, газап һәм нужа кичерергә туры килмәгән — шулай аңладым мин... Һәм эчемнән генә уйлап куйдым: әгәр язмыш аны минем белән бәйләгән булса, «лаеш шулпасын» аңа шактый ук эчәргә туры килгән булыр иде.

Хуҗа сөйләгән арада, Һаҗәр чәй өлгертте, табын әзерләде. Ул һаман үз эшләре белән йөренеп торды. Гүя әдәп өчен генә килеп утыра да бер-ике минуттан тагын торып китә... Хозяйка кешенең эше бетәмени дидем мин баштарак, аннары ирексездән бу аның элеккечә читләшергә, һавалыгын күрсәтергә тырышуы түгелме икән дип тә уйлап куйдым. Бәлки, ялгыша да торганмындыр, ләкин сүзгә бер дә катнашмавы миндәге каядыр сакланып яткан шикне уятырга җитә калды... Инде чынлап та читләшүе булса, бу... бу бик гаҗәп, әлбәттә. Ул борын-

гы Һажәр түгел, мин борынгы «Әмир» түгел — без шулкадәр ераклашканбыз ки, яшьлектә булган хәлләргә инде ышануы да читен. Ләкин бит без бер туфракта күршеләр булып үстек — моны онытырга, моның белән исәпләшмәскә мөмкин микәнни?! Хәер, кеше күңелен кара урман диләр, аның караңгы почмакларында ниләр генә ятмый торгандыр!

Чәйгә утырышкач, Һажәрнең теле шулай да бераз ачылды. Ул сирәк кенә булса да Уфага кайткалый икән. (Дәүләкәнгә кайтканым юк диде.) Минем турыда да бртларыннан әзрәк ишеткәләгән. Мәсәлән, минем язучы булып китүемне белә икән. «Сез бит яшьтән үк язгалый идегез шикелле»,— диде ул миңа. Әнә шулай уйламастан гына минем яшьлеккә кагылып алды. Ләкин тизрәк башка сүзгә күчте. Гаиләм, балаларым турында бераз сорашты. Сүз ахырында мин яңадан әдәбиятка күчеп, сез кыз чагыгызда укырга ярата идегез, мин сезгә китап ташый идем, дидем. Ул көлемсерәп кенә: «Онытмагансыз икән әле»,— дип куйды. «Ә хәзер ничек?..» «Вакыт булганда хәзер дә укырга тырышам»,— диде. Билгеле, русча гына укый икән, татар китапларыннан күптән аерылган... Кайткач, берәр китабымны сезгә җибәрермен, дидем мин аңа... Ул моңа каршы ризалыгын белдергәндәй башын кагып «рәхмәт» дип куйды.

...Чәйдән соң мин кузгалдым, алар мине озата чыктылар. Әзрәк бакчаларын да күреп китәсем килде. Роза чәчәкләре монда күп иде. Һәм бик эреләр, бик матурлар иде алар... Минем сокланганны күреп, Низам иптәш: «Әллә бер-ике төбен биреп җибәримме?» — диде. «Белмим шул, дидем мин, кайтып җиткәнче кормаслар микән?» «...Тамырларын юеш чүпрәккә төреп тотсагыз, берни булмый»,— диде Низам, һәм тиз генә ике төп розаны казып та алды, юеш чүпрәккә әйбәтләп төреп тә бирде... «Рәхмәт, сезнең истәлек булыр»,— дидем мин аларга... Чыгып киткәндә баш иеп Һажәрнең кулын кыстым, ә Низам мине вокзалга кадәр озата барырга булды. Юл өстендә винолар сата торган бер подвал очрады, мин юлдашымны шунда кереп чыгарга чакырдым, ул берсүзсез риза булды, һәм без подвалга төшеп, берәр стакан кызыл вино да эчеп чыктык. Кыскасы, Низам иптәш белән безнең «борчак пеште». Ике көннән инде мин Казанга да кайтып китәргә тиеш идем.

...Әнә шулай узды минем кырык биш елдан соң Һажәрнең үзен дә, ире Низамны да беренче һәм соңгы мәртәбә күрүем... Аннан соң менә тагын унбер ел узып китте. Ләкин хәзер монда язганнарым барысы да дөрес, нәкъ булганча, чөнки мин шул чакта ук аларга баруымны блокнотыма кыскача гына язып куйган идем. Иң ахырында мондый сүзләр дә бар: «Шунысы гаҗәп, минем күңелдә бер нәрсә дә уянмады, барысы да күптән сүнеп беткән икән»... Әнә шулай язып куйганмын мин Һажәрне күреп кайткан көнне үк... Димәк, бу дөрес, димәк, Һажәргә карата бала чакта ук туган мәхәббәт хисе миндә инде әллә кайчан сүнгән, беткән, онытылган... Барып күрүләрем тик шуны белү өчен генә булган икән!..

Казанга кайткач, озакка сузмыйча, мин Һажәр исеменә татар һәм рус телендә ике китабымны җибәрдем, әмма Һажәрнең үзеннән «алдым, рәхмәт» дигән хәбәр килмәде... Саклап алып кайткан розаларым да, үземчә яхшылап утыртуыма карамастан, тамырлана алмадылар. Язга чыккач та кордылар.

...Еллар узып, дөньяны да таный башлагач, мин ирексездән уйлап куя идем: Һажәр теге чакта Ыслак егетенә ияреп китеп, дөрес эшләгән бит!.. Аңа бит инде башка юл юк, калмаган. Егермегә җитеп килгән кыз үзенең киләчәге турында ничек уйламасын да борчылмасынди?! Атасы Борһан абзыйның сәүдә эшләре, бүген булмаса иртәгә сүтелергә, бетәргә тора. Алда нинди язмыш көтә — билгесез. Мондый хәлләрдә

купец кызларының аңлырак, житезрәкләре ышанычлы кешеләргә сыеналар икән, моңа бер дә гаҗәпләнергә туры килми. Булды андый эшләр... Гражданнар сугышы вакытында мулла яки бай кызларын командир һәм комиссарлар да иярте киткәләделәр (хәтерлисездер, Борһан абзыйның зур кызы Зәһирә апаны да 1918 елны бер кызыл гаскәри алып киткән иде), соңыннан нэп елларында шундый ук «чит» кызларны күренеклерәк урын тоткан совет работникларының хатынлыкка алуы мәгълүм. Бу нәрсә, билгеле булганча, безнең әдәбиятта да чагылмыйча калмады.

Әгәр дә Һаҗәр үзенең Низамын яраткан да булса (әлбәттә, бөтенләй яратмыйча кушылмагандыр инде), димәк, ул аңа тагылып китеп бик дөрес эшләгән — ир канаты астына кергән, гаилә корган, тормышын тәэмин иткән. Билгеле, аңа шул гына кирәк тә булгандыр...

Инде бер генә минутка фараз кылыйк: Һаҗәр минем яратуыма ышанып, шул чакта миңа чыгарга риза булды, ди. Ә мин аны тизрәк үземә алдым, ди... Моның ахыры ни булыр иде икән?.. Менә шуны уйлыйм... уйлыйм да ихтыярсыздан калтыранып куям. Бик зур бәхетсезлеккә дучар булыр идек шикелле... Иң элек мин аңардан яшьрәк, укып маташкан чагым, хатын асрарлык урыным да, рәтем дә юк. Аннары иң хәвефлесе — мин үзем дә чыгыш ягыннан Һаҗәрнең ише диярлек, ә ул чактагы шартларда бу инде җанны бик борчый торган мәсьәлә иде. Хәтта укуымны бетерә алуым да икеле иде. Кыскасы, юлым да әле ачык түгел, киләчәгем дә хәзергә билгесез. Менә шундый хәлләрдә мәхәббәт хакына өйләнеп кара инде?!

Ярый, илдә чыпчык үлми дигәннәр, без дә нужа ләмкәсен иңебезгә киеп, дөньябызны ничек тә сөйрәгән булыр идек әле... Әмма эш бары тырыша-тырмаша яшәп маташуда гынамыни?.. Берга тора алу өчен ипи-су белән бер үк дәрәҗәдә мәхәббәт тә кирәк түгелме соң?.. Чын бәхет бары шунда гына ич!.. Билгеле, мин үземнең мәхәббәтемә ышана алам. Малай чактан ук бөреләнгән бу серле хис егет булып житкән чагымда инде чын мәхәббәткә әйләнгән иде. Ул әлбәттә сүрелмәскә һәм сүнмәскә тиеш!.. Ә Һаҗәрдә ничегрәк соң?.. Ул да бит яшь кенә кыз чагыннан ук мине яратмыйча, миңа карамыйча үсте. Инде уйлап карагыз, нинди дер сәбәпләр аркасында минем белән кушылырга мәҗбүр кыздан элек булмаган мәхәббәтне хәзер көтеп булачакмы?.. Әлбәттә юк яки... бик тә шикле... Асылда ул болай булачак: мин аны яратачакмын, ә ул мине ярата алмыйча интегәчәк. Я, моңардан да зур бәхетсезлек булырга мөмкинме?! Бу бит гомерлек газап, гомерең буена сызланып-сызып яшәү дигән сүз!.. Мин үзем моның нәрсә икәнен бик яхшы беләм һәм Һаҗәрнең дә мондый хәлгә дучар булмавына ихлас күңелдән сөенәм.

Хәер... мәхәббәттән башка да торып була бу дөньяда. Балалар хакына, туганнар хакына, сүз-гайбәттән куркып һәм тагын бик күп сәбәпләр аркасында тора кешеләр. Бигрәк тә хатын-кыз чыдам, хатын-кыз түзә: гомеркәемне утларга салдым, дип яшерен генә яшьләрен түксә дә тора ул үзенең хатынлык вазифасын үтәп. Әмма күпме сабырлыклар кирәк моның өчен!..

Ә миңа исә күк томаннар артында торып калган еракта, бик еракта әнә шул бәхетсез мәхәббәтем нигъдер бик кадерле. Балки ул таш астыннан чыккан яшь үлән шикелле саф мәхәббәтем мине гел генә хыял дөньясына китеп яшәргә, шуннан үземә ләззәт-юаныч табарга өйрәткәндер, балки ул мине Дим буйлары өстендәге айлы кичләрнең тирән тынлыгын ишетергә өйрәткәндер, балки ул мине җирдәге һәм судагы барча җан ияләренә миһербанлы булырга өйрәткәндер... Мәхәббәтнең кодрәте чиксез — аның хәтта караңгы чырае алдында да сәҗдәгә егылырга ярый!

...Уза гомерләр, уза... Инде Низам да, Һаҗәр дә бу дөньяда юклар. Сугыштан соң Хәбибрахман мәрхүм (әйе, ул да мәрхүм) Дәүләканга

бер кайтуында Һаҗәрнең кечкенә фотосын каяндыр табып миңа китергән иде. Кемнеңдер кулына төштеме ул фото, күпме эзләп тә таба алганым юк. Ярый әле хәтер бар, хәтер саклый барысын да — нечкә кашлы ак йөзен дә, кара-калын толымнарын да!

Миңа тагын чигенергә туры килә. Казанга китәр алдыннан Дәүләкәндә үткәргән соңгы елым турында язмыйча үтү мөмкин түгел — шактый күп вакыйгаларны эченә ала ул соңгы елым... Минем «сәхифәләрем» бер-берсенә ялганып барырга тиеш.

Иң элек үз хәлебез турында. Атайның эшләрен шәптән димәс идем. Йөри, чаба, ансын ала, монысын сата, ләкин бер дә күтәрелеп китә алмый. Самарага йөрүен дә ташлады, чөнки иске кием-салым үтми башлады. Бетте, кеше хәзер яңасын кияргә тырыша. Ә атай еш кына сума юк дип зарлана. Димәк, зуррак сәүдәгә аның үз көче генә җитми. Берәр кеше белән кушылып, уртак эш башларга да уйлана иде шикелле...

1924 елның җәендә Стәрлетамактан Муса Хәбиров дигән кеше яшь хатыны белән бергә Дәүләкәнгә килде. Алар безгә фатир керделәр һәм өебезнең зал ягында тора башладылар. Без инде йортны сатып алган көннән диярлек зал якка кеше кертә башлаган идек. (Билгеле, акчасы килсен өчен.) Семьябыз бәләкәй булгач, өйнең әчке башы да безгә җитә иде. Фатирчылар китеп, зал як күпмедер вакыт бушап торганда, без үзебез дә иркенләп бер торып кала идек.

Әйткәнемчә, Муса абзый Хәбиров кара айгыр җиккән яхшы тарантаска яшь хатынын утыртып, безгә килеп керде. Аның шул кара айгыры белән яхшы тарантасыннан башка бүтән нәрсәсе юк та иде. Киемсалымнары, ястык-мендәрләре исәпкә керми, ә калганы — мәсәлән, өй җиһазы — барсы да бездән иде.

Муса абзый Эстәрле мулласының улы икән. Яхшы ук укымышлы булырга тиеш. Әрмәнгәрәк охшаган зур күзле, озын борынлы кара кеше, тик буй-сын гына әрмәннеке түгел — юанрак та, аяклары да кәкрерәк... Ә менә яшь хатыны Зәйнәп апа иреннән калкурак,бик зифа да һәм бик чибәр дә иде; чем кара чәч, сызылып киткән кара каш, тулы гына шома битенең ике ягы да чокыраеп тора һәм шушы нәни чокырчыклар аны аеруча ягымлы-мөлаем итеп күрсәтә дә иде. Шуның өстенә ул гаҗәп шат табигатьле, көләргә дә, сөйләргә дә яратучан алчак бер хатын да иде. (Иренең нәкъ киресе.) Мандолинада чибәр генә уйный иде.

Ул Троицк кызы икән. Алдынгы сәүдәгәр гаиләсендә үскән булса кирәк. Кыз чагын исенә төшереп сөйләгәне хәтеремдә. — Без кышкы салкын кичләрдә,— дип сөйләгән иде ул,— бөтен гаиләбез белән зур залдагы түгәрәк өстәл тирәсенә җыелып, яшел абажурлы, асылмалы лампа яктысында һәр кайсыбыз нәрсә дә булса укып утыра идек. Әтием гадәттә «Вакыт» яки «Шура»ны укый торган иде, энеләрем «Ак юл»ны карый, ә мин «Аң» белән «Сөембикә»не укырга ярата идем. Безгә шуларның барысы да килә иде. Әтием бик һәвәс иде укырга. Әнә шулай үткәрә идек без кышкы озын кичләрне...

Һәм шушы татар әдәбиятын укып үскән, татарча бик матур сөйли белгән, музыкага да сәләте булган туташны Муса абзый Троицкига барып, никахлап алган, Эстәрлегә этисе йортына килен итеп алып кайткан, аннары, озак та тормыйча, ни өчендер Эстәрледән Дәүләкәнгә китергән. Безгә фатирга килеп керүләре кем аркасында булгандыр инде, мин үсмер малай башым белән моны үзем өчен яхшыга юрадым. Зәйнәп апа кебек чибәр, ачык, мөлаем, мәдәниятле яшь кенә хатынның ниндидер бер якты, матур эзе күңелләрдә калырга тиеш иде. Ул еш кына безнең якка чыгып, инәй белән сөйләшеп утырырга ярата иде. Шул чакта мин аңа, барлыгымны да сиздермәскә тырышкандай, читтән генә карап утыра идем. Ә ул Троицк каласы, аның кызлары, егетләре, андагы

тормышлары турында мавыгып сөйли иде, аннары сагынуларын аңлатасы килгәндәй, башын кырын сала бирен, мандолинада уйнап җибәрә иде. (Ихтимал, шушы ишетүләр нәтиҗәсендәдер инде, минем күңелдә Троицк каласына гомерлек бер мәхәббәт тә уянып калды. Әмма кайчандыр татар халкының шактый гына күренекле мәдәни бер учагы булган даладагы бу каланың үзендә, кызганычка каршы, миңа булырга туры килмәде. Бары Куандыкка барышлый вагон тәрәзәсеннән генә карап узарга насыйп булды.)

...Кышка кергәч, озын төннәрнең берсендә, Зәйнәп апа бездә беренче бәбиен тапты. Берничә көн без аны күрми тордык, тик бала тавышын гына ишеткәли идек. Өчме-дүртме көн узгач, бәбиен күтәреп, безнең якка да чыкты. Апабыз бер дә үзгәрмәгән диярлек, шундый ук шат, мөлаем, сүзчән, тик беркадәр агара гына төшкән иде. Инәй аларга бәбине котлап ит бәлеше пешереп кертте һәм чиккән башлы озын бер сөлге дә бирде.

Хуш, Муса абзыйга да эш кирәк бит әле, гаиләсен асрарга кирәк. Ләкин Дәүләкән кебек кечкенә җирдә эш табулары бик читен иде. Озак та тормый ул үзенең кара айгырын тарантасы-ние белән сатып җибәрде. Шуннан соң минем атакай белән әйбәтләп сөйләшә, мәслихәтләшә торгач, алар үзара килешеп, «аллага тапшырып», «яңа «эш» башлап җибәрергә булдылар: көзгә табан базар мәйданында такта кибет (ларек) ачып, бакалея әйберләре белән сату итәргә тотындылар. Товарлары — чәй-шикәр, өрек-йөзем, кәнфит-ландарин, прәннек-клиндер, тагын шуның кебек азык нәрсәләре иде. (Аларны оптом сатучылардан алалар иде бугай) Алмаш сату итәләр — ярты көн Муса абзый кибеттә торса, калган ярты көнне атакай торып уздыра. Ике арада, әлбәттә, тулы ышаныч, һәр көннең сатуын махсус кенәгәгә теркәп баралар. Ай тулгач, йомгак ясыйлар да, файдага чыккан акчаның күпмесендер тигез итеп бүлешәләр... Ләкин сатулары шәп бара дип әйтмәс идем. Базарда аларныкы шикелле лареклар аз түгел иде, аннары бакалея белән сату итүче зур-зур кибетләр дә бар — халык та күбрәк шуларга кереп, ашыкмыйча сатулашып алырга ярата (ә ларектан ашыккан кеше генә ярты кадак, чирек кадак нәрсә эләктереп китә). Кыскасы, безнекеләр бәләкәй генә такта куыш эчендә таптанып, салкын кышны ничек житте алай үткәзеп җибәрделәр дә, язга чыккач, сәүдәне бетерергә, кибетне ябарга булдылар. Бу сәүдә аларга көткән нәтиҗәне бирмәде, шуның өстенә шактый зур налог та китереп салдылар. Аеруча Муса абзый «эшне» тизрәк очлап бетерүне ашыктырды — аның инде сәүдәне генә түгел, Дәүләкәнне дә ташлап китәсе килә иде. Калдык-постык товарларын сатып бетерделәр, налогларын кертеп түләделәр, шулай итеп кечкенә генә бер «ширкәт» нэпның башыннан ук диярлек яшәүдән туктады. Бу «ширкәт»тән минем атакай тагы да зәгыйфьләнебрәк чыкты шикелле, чөнки шуннан соң инде ул патент алып сату итүдән туктады. Ә Муса абзый җәйгә чыккач та хатыны белән баласын алып, Ташкент тарафларына китте дә барды. Әнә шулай бөлгән яки үзенә эш эзләгән татарларның Урта Азиягә китүләре 1925 елдан ук башланды дияргә ярый.

...Инде миңа да киләчәгем турында уйланырга вакыт иде. Унбишем тулды бит... Бәлки иртәрәктер дә? Юк, бер дә иртә түгел, нәкъ менә уйланыр чак. Дөрес, күп нәрсәне белү дә, аңлау да юк әле, әмма сизенү бик көчле. Нәрсә көтә безнең ишеләрне алда? — заман үзе мәҗбүр итә яшь-яшь кенә башларны шул хакта уйланырга... Бу нэп дигән нәрсә бик гөрләп башланса да һәм озакка сузылыр кебек тоелса да, ике-өч елдан ук инде аның кыска гомерле булачагын чамаларга мөмкин иде.

Баштарак, нэпның иң кызган чакларында кибет ачып сату итүчеләрнең малайлары да аталары эшенә нык тартылдылар. Чөнки яңа

сәүдәгәрләрнең берсе дә приказчик-мазар тотмады, моны ул күтәрә алмый иде (һәм курка да иде), шул сәбәпле кирәк чакта хатынын яки малаен-кызын эшкә җикте. Миңа исә, ачлык елы артыннан ук атакайга ияреп Самарага барып йөрүне исәпләмәгәндә, сату эшенә бөтән тартылырга туры килмәде. Муса абзый белән кушылып кибет ачкач та мине ул эшкә тартмадылар. Бәләкәй генә кибет өчен алар икесе бик җиткән иде, ә мин, билгеле, артык идем анда, бигрәк тә Муса абзый исәбенчә. Телдән үк әйтмәсә дә, аның уен-шиген аңларга була иде.

Хәер, төп сәбәп аларда гына түгел иде, әлбәттә. Атамның сәүдәсе зур булса да, бик шәп барса да, мин инде бу сату эшенә үзем теләп, кереп китә алмас идем. Дөньяны әкренләп таный башлавым мине ул эштән тыйган булыр иде. Сез беләсез, мин бик иртә татар китапларын укый башладым. Ә китапларның берсе дә сәүдәне мактамый, сәүдәгәрне яхшы итеп күрсәтми. Киресенчә, китапта язганнарга ышансаң, руханилар белән сәүдәгәр-байлардан да начаррак кеше юк. Ә мин китапка, әлбәттә, ышанам. Дөрес, мин атамны начар кешегә санамыйм, шулай ук үзем белгән башкаларны да (мәсәлән, күршебез Борһан абзыйны яки Гатаулла бабайны) начарлар дип әйтә алмас идем, ләкин барыбер сату итү әйбәт эш түгел икән дигән уй миңа кереп оялаган иде инде. Аннары бит әле мин үзем дә язучы булырга курка-курка гына хыялланып маташам. Кая инде ул монда сәүдәгәрлек турында уйлау!.. Әгәр дә мәгәр хыялым вөҗүдкә ашса, мин бит бөтенләй башка дөнья кешесе булачакмын!.. Киләчәктә, боерган булса! (Ләкин бу киләчәк минем өчен шактый ук ерак булып чыкты — бер 20—25 елдан соң гына мин, ниһаять, әдәбиятка үтеп керә алдым.) Ә хәзерге вакытта исә мин мәктәпнең эчендә дә, тышында да бик активлашып киттем. Җәмәгать эшләренә зур дәрт кузгалды миндә — замана рухы керә башлады. Укыйм, язган булам, Мәскәү һәм Казанда чыккан гәзит-журналларны да алдырам. (Атакай моның өчен акчасын кызганмады.) Әле җитмәсә, Гомәр Вафиннан мандолинада уйнарга да өйрәнеп маташам. Үзе ул бик шәп уйный иде, ләкин миннән булмады — музыка сәләтеннән бөтенләй мәхрүм икәнмен...

Әмма аның каравы, миңа «дивар гәзитәсе» чыгару бик ошап китте. Бу әле бик яңа нәрсә иде, өйрәнелмәгән, күнегелмәгән, шулай да мин аңа җиң сызганып тотындым. Бер-икесен хәтта берүзем диярлек язып чыгардым. Дөресрәге, материал барысы да минеке, ә зур каты кәгазьгә күчереп язу башканың эше. Минем кулым (почеркым) шактый ямьсез. Ә менә күршебездәге Гарифның кулы ташка баскандай бик ачык, бик пөхтә яза иде. Сез Гарифны онытмадыгыз микән?.. Аның турында башта ук сүз булган иде инде. Ул тегүче Зариф абзый малае, әнисе аны киез җәйгән идәнгә утыртып, йөзем һәм чикләвек төше белән сыйлый торган иде — хәтерлисезме? Зариф абзый чахоткадан үлеп киткәч, алар фәкыйрьлеккә төшеп, бик бетеренделәр. Тол хатын үзенең улы Гариф белән безнең якын күршебез Сылубикә җиңгигә (аның ире Сәлимҗан агай да холера вакытында үлеп киткән иде) өйдәшкә кереп, шундагы озын сәкенең чаршау белән генә бүлгән бер башында торып яталар.

Хәлләре бик авыр, әнисе төрле кешеләргә көнлекле эшкә йөреп ашарлык ризык китерә, ә Гариф, әтисенең авыруын алып калган үсмер малай, күбрәк өйдә ятып кына тора. Үтә ябык, нечкә муены эчкә киткән, иңбашлары төртеп чыккан, күзләрендә нур сүнгән... Әмма дәрт бар, кызыксыну бар, еш кына мине тәрәзәдән чакырып, бүген мәктәптәниләр булды, нәрсәләр укыдыгыз, дип сораша. (Ул үзе инде укуга йөрүдән туктаган иде.) Мин аны гәзитә язышырга чакыра кергәч, аңа да бик куанып риза булды. Тиз генә өстенә иске сырмасын киде, бүреген киде, ә менә аягына төпләгән, бер кунычы көйгән пимадан башка нәрсәсе юк икән. Ә тышта апрель ае, бөтен җир су, лычкылдаган баткак... Шуңа күрә Гарифны әйбәт кенә аркама атландырып, үзебезгә күтәреп алып кайтырга туры килде. Ләкин болай аркада китереп, аңардан гәзитәне яздыру ике генә

мәртәбә булды — бердән авыру иптәшне артык борчыйсым килмәде, икенчедән, минем өчен инәй дә бик борчыла иде (чехотканың йогышлы икәнен кем генә белми?).

Үзебезнең мәктәптә дә, Гариф шикелле үк булмаса да, матур гына язучылар бар иде. Бүтән мин өйгә алып кайтып, яздырып йөрмәдем.

Инде гәзитә шаукымыннан бераз айныгач, бер заман мин театр уйнау, кичәләрдә катнашу белән бик мавыгып киттем. Дөресен генә әйткәндә, театрны мин үземне белә башлаганнан бирле яратам. Театр һәрвакытта миңа гаять кызыклы, күңелле, шау-шулы үзенә бер мәзәк дөнья булып күренә иде. Һәм бик тарта иде бу дөнья минё үзенә!.. Анда катнашып йөргән, сәхнәсенә чыгып уйный алган абыйларга, апаларга бик кызыга идем, хәтта көнләшеп тә карый идем. Тизрәк үсәсе дә шулар арасына кереп китәсе килә иде. Бәлки шуңадыр, мин унҗиде-унбиш яшемнән үк үземнән зур егетләр һәм кызлар арасына кереп йөри дә башладым.

Дәүләкәннең театр белән бәйләнгән тарихы да шактый кызыклы, шуңа күрә минем аңа махсус тукталып китәсем килә.

Чын булса, беренче спектакль Дәүләкәндә приказчиклар тарафыннан 1911 нче елда ук куелган, имеш!.. Моңа ышанырга була. Без беләбез, бу татар дөньясының бик нык тәрәккый иткән еллары... 1905 елның җил-давылыннан уянган татар халкы үзенең тәрәккыятендә йөз елда уза алмаганны, күп булса, ун-унбиш ел эчендә узды. Шуның нәтиҗәсендә безнең халык бөек Октябрь революциясенә дә аңлы, алдынгы бер халык булып килеп керде һәм революция көрәшенә, аның җиңүенә үзеннән зур өлеш кертте.

Димәк, бу гомуми үсеш-күтәрелештән безнең кечкенә Дәүләкән дә читтә торып калмаган. Театр уйнау исә ул елларда Казан, Ырынбур, Уфа кебек мәдәни үзәкләрдә генә түгел, татарлар яшәгән Себер, Урта Азия һәм үзебезнең өяз шәһәрләрендә дә була башлаган иде. Гаҗәп тиз таралды бу сәнгать безнең татар дөньясында!.. Вак шәһәрләрдә моны башлап җибәрүчеләрнең күбрәк приказчиклар булуы да аңлашылса кирәк, чөнки нәкъ шулар арасыннан яңалыкны күреп, күтәреп алучы кыю яшьләр чыкканнар да инде. Андыйлар Дәүләкәндә дә булган. Кайберләрен мин дә әле беләм: болар Хисами, Кәрим, Мәгыйҗан, Габдрахим абзыйлар... Соңрак аларга ярлы гаиләдән чыккан яки байларда асрау булып эшләгән кызлар да кушылган. Шуларның икесе — Галия апа белән Фатиха апа хәзер дә исәннәр әле.

Мин үзем аларның уеннарын 1920 елдан күрә башладым. Миңа әле ун-унбер яшь кенә, театр карарга да, кемгә дә булса, мөгаен Зәкия тутакайга, ияреп кенә барганмындыр. (Ул шундый тамашаларны карарга бик ярата иде.) Нәкъ шул елның кышында «Галиябану» безгә дә килеп җитте. Мин менә шуны Бәлдәй клубының сәхнәсендә беренче мәртәбә күрдем. Соңыннан Казан сәхнәсендә, иң шәп артистлар башкаруында бу спектакльне кат-кат карасам да, әлеге кечкенә сәхнәдә, унлы лампа яктысында күргән беренче «Галиябану»ым бер вакытта да алдымнан китмәде. Мин аны ниндидер бер тамаша итеп кенә карамадым, Галиябану булып Суфия апа, Хәлил булып Мәгыйҗан абый уйнаганын да белмәдем. Мин аны чын бер вакыйга дип кабул иттем, шуңа беткәнче ышанып, чын күз яшьләрем белән җылап утырдым. Менә ул чәчәкле яулык ябынган, чиккән алъяпкыч бәйләгән, тула оек өстеннән кара галушлар кигән, үзе җиңел, үзе сөйкемле, үзе бик оялчан, вакыт-вакыт хәтәр сизгән коштай дereлдәп куйган, тавышын да калтыратыбрак сөйләгән минем беренче Галиябануым, менә кара кәләпүшен кырынрак салып кигән, кара камзулы өстеннән яшел билбау буган, кул-

тык астына кечкенә иске гармун кыстырган, тыйнак, әдәпле, саф күңелле, гади авыл егете минем беренче Хәлилем! Авыл тынгач кына аның тәрәзәгә килүе, иске гармунын әкрен генә тартып, тыелып кына җырлавы, ә Галиябануның тәрәзә янагына ышыклана төшеп, оялып-куркып җырлап җавап бирүләре — болар һәм бөтен уен искиткеч яңа, таң калдырырлык, бәгырьләрне өзәрлек иде. Аларның берсе Искәндәр хәзрәт ишегалдында торучы тол хатынның кызы Суфия апа, ә икенчесенең кайдадыр конторщик булып эшләүче Мәгыйҗан абый икәнен белгәч, минем күңелемдә бу кешеләргә гомерлек бер мәхәббәт уянып калды. Шунысы тагын кызыклы, Галиябану белән Хәлилнең саф көчле мәхәббәте аларның үзләренә дә күчкән икән — шушы спектакльдән соң алар озак та тормыйча матур гына туйлап өйләнештеләр дә. Тик алар сәхнәдән никтер тиз киттеләр, бәлки моңа өйләнешүләре сәбәп булгандыр, ләкин барыбер Суфия апа белән Мәгыйҗан абыйлар күпләр хәтерендә Дәүләкәннең сагынып искә алырлык беренче артистлары булып калдылар. Хәзер инде аларны белүчеләр юк диярлек — мин дә тагын берничә кеше генә...

...Хикмәтле ерак елларның тагын бер кечкенә кызыклы эпизоды истә саклана, шул ук артистлар сәхнәдә «Мөгаллим» дигән әсәрне уйнап күрсәтергә тиешләр. Тамашага килгән бала-чага арасыннан алар үзләренә бәләкәйрәк малай эзлиләр: бу малай спектакльдә бик кечкенә бер роль «уйнарга» тиеш икән. Менә шушы уен өчен минем энем Илдарханны сайлыйлар да, сәхнәгә алып менеп, аңа нәрсә эшләргә кирәклеген өйрәтәләр: «Син, ускәнем, менә шушында юри генә йоклап яткан булырсың, ә менә бу абыең кычкырып фәлән сүзне әйткәч, уянып, үкереп җыларга тотынырсың... Аңладыңмы?». «Аңладым!», «Үкереп җылый беләсеңме?», «Беләм!», «Менә бик әйбәт!» (Әйтергә кирәк, минем энекәш өйдә җылый башласа да яшь үгез шикелле үкерә иде.) Шулай итеп, энемне сәкегә яткызалар, өстенә юрган да каплыйлар. Пәрдә ачыла, уен башлана... Уен бара, малайның уянып җылар вакыты да җитә, ләкин ул никтер уянмый, артистлар аның тирәсендә тыз-быз киләләр, бер үк сүзне отыры кычкырыбрак әйтеп тә карыйлар, ә малайның гамендә дә юк — ул, баскан, юри генә түгел, ә чынлап торып йоклап киткән икән! Изерәп, төшләр күрә-күрә йоклый малай!.. Шулай да аңа карап уен тукталып калмый, дәвам итә, ахырына да барып җитә. Пәрдә төшкәч, энекәшне көчкә төрткәләп уяталар. Менә шул чакта инде ул үкерә-үкерә җылап та җибәрә! Ниһаять, «роле» исенә төшә, малайның...

Ярый, һәвәскәрләр уйнаганда ни булмас, аңа берәүнең дә исе китми, тик рәхәтләнеп бер көләләр генә.

Билгеле, театр уены ул яшьләр эше. Алар яраталар, алар дәртләнеп йөриләр. Әмма озакка түгел, монда буыннар тиз алышына. Өч-дүрт, күп булса биш ел уйнаганнан соң «искеләр» сәхнәдән китә башлыйлар — я өйләнәләр, я кияүгә чыгалар һәм тормыш арбасына җигеләләр. Алар урынына яңалар җитешә, яңалар килә. Әйтик, егерменче елларда без әле клуб ишеге төбен таптаучы, зур артистларга шаккатып йөрүче малайлар гына булсак, 1924—1925 елларда инде үзебез дә сәхнәгә менеп, каушый-каушый гына уйный башладык. Бу вакытта Мәгыйҗан, Габдрахим, Габдулла абый һәм Галия, Фатиха, Суфия апа кебек «корифейлар» берәм-берәм китеп беткәннәр иде. Ләкин безнең буын турында сүз башлаганчы минем Дәүләкәнгә ара-тирә килеп чыккан чын (профессиональ) артистлар турында да әзрәк сөйләп узасым килә. Бу кызыклы һәм гыйбрәтле. Мәсәлән, минем чын артистларга гаҗәпләнүем дә, соклануым да, хәтта аларны кызгануым да шушы чакларда туып, күңелемдә сакланып калды булса кирәк.

...Хәтеремдә көзге Дәүләкән ярминкәсе. Нәп кергәч беренче ярминкә әле бу, шулай да бөтен тирә-яктан татары, башкорты, русы, чувашы килеп тулган, базар мәйданы ярларыннан чыккан дәрьядай әкрен генә гүләп, чайкалып тора. Читтән килгән сәүдәгәрләр дә күп, җиңел кулдан

гына корып ташлаган такта кибетләр дә күп, ә ярминкәгә кергән малның, азыкның, товарның хисабы юк! Хәтта сәнгате дә читтә торып калмаган — базар мәйданының бер кырыена сәләмә брезенттан түгәрәк балаган да корылган. Монда цирк артистлары үзләренең уеннарын күрсәтәчәкләр икән. Ләкин балаган тирәсендә хәзергә шаулашкан бала-чагадан башка халык та юк диярлек. Халыкның башы-күзе тонган, алар базар айкыйлар, базарда бөтен эшләре... Балаганның тышында биек кенә сәндерәсе бар, менә шунда өч артист чыгып басканнар. Берсе — кып-кызыл чукмар борынлы, самавыр җиздәй җирән чәчле клоун, икенчесе — күлмәге-ыштаны тоташ, тыгыз, җиңсез нәрсә кигән таза гына ир — герләр чөеп уйнаучы, өченчесе — битен-күзен бик нык акшарлаган, өстенә кендектән түбәнрәк кып-кыска кызыл күлмәк кигән, озын шәрә аяклы бер маржа. Алар халыкны чакыралар, клоун нидер кычкыра, кулындагы кыңгыравын һаман селкетә, җирән чәчен дә еш кына «аягүрә» бастыра. Гер күтәрүче кулларын баш өстенә куеп, йомры мускулларын уйнатып күрсәтә. Ә кыска итәкле маржа кулындагы шөлдерен селкә-селкә ниндидер такмак әйтеп маташа. Әмма халык авызын ачып, бераз гына карап тора да тагын үз юлы белән китеп бара. Нигәдер ашыкмый халык балаган эченә керергә... Шуннан соң әлеге маржа сәндерәдән төшеп, бер 100 метр чамасы базар эченә кереп китә дә, озын-шәрә аякларын югары күтәргән килеш куллары өстендә генә кире балаганы янына кайта. Аның артыннан ябырылып, чыйнап бала-чага, егетләр-кызлар, ак чикмәнле яшьрәк башкортлар ияреп килаләр. Вәт тамаша!.. Ә хатынның бите тузан эченнән бара, бөтен буяуларын юып кара тир ага — ул инде яшь тә түгел, муенын-күкрәкләрен вак кына җыерчык басып бетергән. Әнә шулай әллә ничаклы халык ияртеп, көчкә-хәлгә балаган янына килеп җитә ул, әмма ләкин аның шәрә ботларын күрер өчен генә ияргән халык билет алырга да, балаган эченә керергә дә ашыкмый, ә күбесе тамаша беткәндәй шунда ук китеп тә бара. Әлбәттә, балаган бик кызыклы урын, барыбер ул бала-чага, яшь-җилкенчәкләр белән тула, андагы кызык-мәзәк уеннарны исе китеп карап утыра, тик шулай да халыкны үзләренең тамашаларына шундый азап белән тартырга тырышкан бу тузган-таушалган, инде олаеп та барган ярлы балаган артистлары миңа нигәдер бик кызганыч булып тоелган иде шул чакта.

1924 елның җәендә Ырынбурдан Дәүләкәнгә бер төркем артистлар килде. Алар биш кеше иде — Ильяс Кудашев-Ашказарский, Сабир Гаспринский, Хәлил Наильский, Безруков (исеме онытылган) һәм хатын-кыздан Мәрфуга Кудашева-Ашказарская. Дәүләкән туфрагында моның кебек тә данлы һәм яңгыравыклы фамилияләрнең булганы юк иде әле. Җитәкчеләре Кудашев-Ашказарскийны элек тә ишеткәнебез бар иде (театр тарихында бик мәгълүм кеше), әмма бу Гаспринский, Наильскийлар... нинди йолдызлардыр — беренче генә ишетүебез... Аларның килүе Дәүләкән өчен, әлбәттә, зур вакыйга иде, тик аңлашылып кына бетми — безнең кечкенә Дәүләкәнебезне алар белеп килделәрме икән, әллә белмичә очраклы гына килеп чыктыლармы икән?.. Хәер, ишетеп-белептер, чөнки Кудашев-Ашказарскийның үзен дә шушы Бәләбәй өязеннән чыккан кеше диләр бит... Аннары безнең Дәүләкән караңгы бер почмак та түгел, шуның өстенә кымызга килеп йөргән татар зыялылары аша аны күп җирдә беләләр дә... Ләкин шулай да зур корабка зур диңгез кирәк диләрме?.. Күтәрә алырмы икән кечкенә Дәүләкән моның кебек шөһрәт ияләрен?!

Гадәттә, гастрольгә килгән артистларга бездә спектакль куеп китү ул елларда бик ансат иде. Рөхсәт-мазар алу да юк шикелле. Бәләбәй клубы күп вакытта буш тора, сторож хатын үзебезнекеләрдән берәрсе кушты исә ача да кертә — рәхим генә итегез! Бары тик җирле һәвәскәрләр белән сөйләшеп, килешергә генә кирәк, чөнки алардан башка читтән килүчеләрнең бер генә спектакльләре дә уңмый торган иде.

...Белмим инде, нәрсә сәбәп булгандыр — Дәүләкән үзе ошамаганмы, клубын яратмаганмы, әллә һәвәскәрләр белән килешә алмаганмы (хәер, нинди килешү — алар бит катнашкан өчен бер вакытта да акча сорамыйлар), әмма ни генә булмасын, Ильяс абзыебыз ике-өч көннән, Мәрфуга апайны алып, бездән китте дә барды. Мәшһүр фамилияләре генә калды хәтерләрдә язылып!.. Әйттем ләбаса, бәләкәй безнең Дәүләкән алар өчен, бәләкәй — базарсыз көннәрдә йокымсырап тын гына торган бер авыл кебек кенә бит ул! (Зур каладан килгән кешеләр өчен бигрәк тә!)

Ләкин калган өчесе китәргә ашыкмадылар. Гаспринский җитәкчелегендә һәвәскәрләр катнашы белән бер-ике спектакль дә куйдылар. Гаспринский үзе уйнамады да бугай — ни хикмәттер, бу спектакльләрнең берсе дә хәтердә сакланып калмаган. Тамашачы да күп түгел иде шикелле, һәрхәлдә аншлаг булмады. Монда, бәлки, җәйге озын көннәр сәбәп булгандыр, эш өсте, халык арып кайта, иртә ята, иртә тора, кыскасы, сезоны ул түгел.

Ул чакларда сбор җыяр өчен бер-ике көн алдан кибетләргә кереп, билетларны сәүдәгәр абзыйларга да тәкъдим итеп йөриләр иде. Яшьрәк нэпманнар баш тартмый, ала, әмма картраклары бушка бирсәң дә алмыйлар. Кирәкми аларга театр, алар мәчеткә йөрүчеләр, башка дөнья кешеләре! Ә сбор дигәнең бик кирәк артистка, бөтен өмите аның бары шул сборда! Ярый ла һәвәскәрнең ашарына бар, торыр җире бар, ә читтән килгәннәргә сбор булмаса ничек яшәргә?

Сабир агай Гаспринский да бер-ике атна чамасы торганнан соң, чыкмады монда рәт дигәндәй, ялгызы гына китте дә барды. Инде биштән бары икәү — Наильский белән Безруков кына торып калдылар. Шулай итеп, башта исемнәре белән безне шаккатырырлык булып килеп төшкән труппа Дәүләкәндә, кыска гына вакыт эчендә, таралды да бетте.

Бу сөзелеп калган икесе турында сүз башлаганчы Гаспринскийның үзе турында әйтеп бетерик. Сабир Гаспринский — Ашказарскийның бертуган энесе — театр дөньясында шулай ук азмы-күпме билгеле кеше. (Утызынчы елларның башларында ул татар академия театрында баш администратор да булып эшләде.) Безгә килеп чыккан чагында Сабир абый ачык соры төстәге җәйге костюм һәм ак панама кигән, йөреше белән дә чын шәһәр интеллигентын хәтерләткән, утыз-утыз бишләр тирәсендәге бер ыспай чибәр генә ир иде. Сырлы таягын селкә биреп, Дәүләкәннең кибетләре арасыннан узганда һәркемнең дикъкатен үзенә җәлеп итә торган иде. Бәлкем, әнә шулай берәүгә дә охшамаган килеш-килбәте белән ул Басыйр абзыйның гимназистка кызы Газизә апаны үзенә карата да алгандыр. Карату гына түгел, алар арасында кыска, әмма кайнар гына роман да булып алды бугай... Һәрхәлдә, безнең яшьләр аларның айлы кичләрдә икәүдән-икәү генә аулак урамнарда йөрүләрен дә, ә кайчагында көпә-көндез җитәкләшеп Дәүләкән тавына менеп китүләрен дә күрмичә калмадылар. Инде гайбәтләре дә чыга башлаган иде, ләкин, әйткәнемчә, Сабир абый озакламый роман җепләрен ансат кына өзеп, ак панамасын болгый-болгый бездән китеп тә барды... Кичерегез, бу хакта мин ничектер уйнап кына язам, бәлки болай ярамый да торгандыр, бәлки алар арасында чын тойгы да булгандыр, хода белсен!.. Әмма иртә өзелгән роман — ташлап калдырган чәчәк төсле кызганыч та, кадерсез дә!

Инде Наильский белән Безруковка килсәк, боларның эшләре харап иде. Китә дә алмыйлар, торырга рәтләре дә юк — әнә шундый авыр хәлдә калдылар ул бичаралар! Монда тагын шуны да әйтергә кирәк, Хәлил Наильский малайлыктан чыгып бетмәгән япь-яшь, ваемсыз бер егет, үзе белән бергә яшь кенә хатын да ияртеп килгән иде. Сәрби исемле, Ырынбурның зур гына бай кызы икән — Хәлил менә шуны әти-әнисеннән качырып алган да киткән... Кызганыч иде бу кыз бала — үзе бик яшь, бик юаш, бик йомшак, аның бала йөзендә «ни булды миңа?» дигән тирән

бер гаҗизлек һәрвакыт чагылып тора иде. Җитмәсә әле үзе йөкле дә икән.

Кызганып булса кирәк, аларны теге чалгыга киселеп үлгән Кәрим абзыйның хатыны Миңкамал апа үзенең кухнясына керткән иде. Стена буенда тар гына тимер кровать, икесенә бер мендәр, өсләренә Наильскийның бөрмәле каеры тунын ябынып яталар — бу тунны да аңа кемдер биргән булырга тиеш. Тышта инде шиксыз салкын көз иде.

Әмма ничек яшәргә?.. Артистның башка бер төрле кәсебе дә, эше дә, килере дә юк. Һәм иң гаҗәбе — үз хәлен аңлау да, кайгыру да юк иде шикелле бу зур гына авызлы озын-чандыр егеттә. Базар арасында йөри, сүзгә җор, мәзәк сөйләргә ярата, шуның өчен генә аны кайбер танышбелешләре чәйханәгә дә алып кергәлиләр. Ә кухняда аның акчамы, ризыкмы табып кайтканын көтеп корсаклы хатыны утыра. Ул, бичара, шул кадәр юаш иде, балыктай өнсез иде, миңа, мәсәлән, аның Халилга бер генә тапкыр да үпкәләп, ачуланып әйткәнен ишетергә туры килмәде. Артистлар тирәсендә гел генә чуалырга яратканга күрә, мин Наильскийга да шактый ук ияләшеп киткән идем һәм аңа ияреп еш кына аларның торып яткан кухняларына да бара торган идем. Ләкин барган саен диярлек мине Сәрби апаның әнә шундый мескенлеге ирексездән сыкрата иде, нәрсә бу — көчле яратуданмы, әллә киресенчә, көчсезлектәнме дип уйланырга да мәҗбүр итә иде. Әйе, чынлап кызгана идем мин аны, буш кул белән бармаска тырыша идем, я кибеттән алып, я инәйдән сорап аңа ни дә булса китерә идем. «Рәхмәт!»— ди иде ул миңа әкрен генә, ләкин күтәрелеп карарга ояла иде.

Шулай да Хәлил Наильский үз хәлләрен җиңел генә җиңеләйтү өчен бер талпынып карады. Театр сенсация ярата бит... Менә бу егет тә Дәүләкәнне шаккатырыр өчен әлеге Гаспринский белән Газизә апа арасында булып алган кечкенә роман турында 3 пәрдәлек пьеса язып ташлады. Пьесаның әдәби ягы, әлбәттә, ташка үлчим генә булгандыр инде, әмма эчтәлеге белән ул бик йөгәнсез, шапшак бер әйбер иде. Газизә апаның үзен дә, әтисе Басыйр абзыйны да, шулай ук төп «герой» Сабир Гаспринскийны да теләгәнчә хур итеп, мыскыл итеп, төрлечә буяп бетергән иде. Басыйр абзый олы яшьтәге сәүдәгәр кеше булгач, «автор»зны, дегеткә буясаң да ярый, дигәндәй, кызганып та, тыелып та тормаган.

Ул чакларда берәр әйберне сәхнәгә куяр өчен бернинди рөхсәт-мазар кирәкмәгәндер, ахрысы... Шуңа күрә, җирле һәвәскәрләр язып ташлаган әйберләр дә ансат кына уйнала торган иде. «Артистлар» җыелышып укыйлар да «ярый, булган бу» дип шунда ук рольләрен дә бүлешәләр.

Наильский да үз әйберсен кую хәстәренә җиң сызганып кереште. Бу вакытта элегрәк елларны уйнаган өлкән һәвәскәрләр театрдан читләшкәннәр иде инде. Алар урынына безнең кебек «яшь буын» (күбрәк үсмер малайлар) килгән иде. Хәлил абзый менә шуларны бик кызыксындырды, уйнаучыларны сайлап алды һәм ашык-пошык репетицияләр үткәрергә дә тотынды. Үзе ул Сабир Гаспринскийны уйнаячак иде. «Һа!— ди иде ул репетиция вакытында кулларын күтәреп.— Дәүләкәннең төшенә дә кермәгән шаккатыргыч бер тамаша булачак бу!..»

Хәлил абзый миңа да роль тәкъдим итте — Газизә туташның энесе булып уйнарга. Спектакльдә катнашу безнең өчен зур дәрәҗә, без аны көтеп кенә торабыз, шуңа күрә мин башта ике дә уйламыйча риза булдым. Ләкин икенче көнне үк инде мине нидер борчый башлады, нигәдер менә бер дә күңелем ятмый бу «шаккатыргыч тамашага», һәм үз алдыма бераз шулай уйланып, борчылып йөрдем дә, ахырда кыюланып рольдән баш тарттым. Наильский моның өчен мине каты гына сүгеп ташлады, ләкин эш тукталып калмады — рольне шунда ук эләктереп алучы да табылды. Әмма соңыннан, бигрәк тә спектакльне карагач, мин уеннан баш тартуым өчен бик сөендем.

Уйналачак спектакль турында инде сүз халык арасына таралып өлгергән иде. «Автор» моның өчен бик тырышты, дүрт-биш көн алдан ук «Дәүләкән купецы тормышыннан алып язылган көчле сатира» дип афишалар да чыгарды. Кем хакында, нәрсә хакында икәнлеге билгеле булгач, спектакль көнне Бәлдәй клубына халык, бигрәк тә яшьләр белән бала-чага килеп тулды. Ниһаять, пәрдә ачылды, спектакль уйналды. Бала-чага билгеле, шау-гөр килеп утырды. Зурлар исә, никадәр генә талымсыз булмасыннар, ниндидер бер ярамаган, килешмәгән ямьсез тамашаны күзәткәндәй уңайсызланып, кызарып утырырга мәҗбүр булдылар. Ярый, «купич»ның үзеннән көлсен дә ди, бу инде гадәткә кергән нәрсә, әмма аның яшь гимназистка кызын болай ачыктан-ачык мәсхәрә итү нигә кирәк булды икән?— менә нәрсә һәркемнең күңелен тырный иде шикелле. Без ул чакта пасквиль дигән нәрсәне белми идек әле, ләкин шуның иң алама үрнәген үзебезнең сәхнәдә күрдек. Хәтта спектаклыга катнашучы безнең һәвәскәрләр дә моны соңыннан сизмичә калмадылар.

Бер уйлаганда, Наильский үзе дә кызганыч иде. Аның шушындый түбәнлеккә төшүе, әйткәнемчә, каты нужадан иде. (Нужа печән ашата, дигәннәр.) Ләкин зур өмитләр белән шаулатып куйган халтурасы бер төрле дә җиңеллек китермәде. Шул ук бөлгенлек, эшсезлек, аптыраганлык — барысы да искечә калды. Нишләргә? Дәүләкән шартларында артист булып кына яшәү һич тә мөмкин түгел. Шуны соңрак булса да аңлап, ул ахырда безнең кинотеатрга эшкә урнашты. Эше — ишек төбендә билет тикшерү һәм билетсыз үткән малайларны сөреп чыгару — моны вышибал диләр бугай... Бик мәзәк кенә иде Хәлил Наильский, төскә дә чибәр иде, артистлык сәләте дә аңарда, һичшиксез, бар иде, әмма артык ваемсыз, пошымсыз, җиңел генә уйлаучан — шуның аркасында ул бездә адашып калып, үзен дә, яшь-яшь хатынын да күпме җәфаланырга, күпме түбәнлекләр кичерергә мәҗбүр итте.

1926 елның җәендә, мин беренче мәртәбә Казаннан Дәүләкәнгә кайткан чагымда, алар үзләренең Ырынбурларына кайтып киткәннәр иде инде. Бик дөрес эшләгәннәр. Бәлки әле Сәрби апаның эти-әниләре дә аларны гафу итеп, үзләренә кабул иткәннәрдер. Кечкенә сабыен күтәреп кайткан газиз бала бит... кагып буламы соң?!. Юньсез кияүгә дә сәүдәгәр бабасы янында берәр төрле эш табылгандыр, шәт! Соңыннан миңа Наильский фамилиясе белән тарихка кереп калган артистларны ишетергә туры килмәде.

Дәүләкәнгә Ашказарскийлар белән бергә килеп, адашып калган артистларның бишенчесе Безруков дигән бер мишәр иде. Самара егете булса кирәк. «Труппа»га ничек эләккәндер — ул кадәресе, безгә намәгълүм (китапча әйтсәк). Әмма араларында иң мескене һәм иң җәфа чиккәне шул бичара иде. Өстендә керләнеп беткән, төсен югалткан кыек якалы күлмәк, таушалган иске пинжәк белән иске чалбар — шулардан башка бер әйберсе, хәтта башына кияр нәрсәсе дә юк. Ләкин ул абруен сакларга тырышучы инсафлы егет иде, шуңа күрә әрсезләнеп, соранып, берәүгә дә тагылып йөрмәде. Аның кайда торганын, ничек яшәгәнен дә белүче булмады. Әнә шулай күпмедер вакыт Дәүләкәндә бер тиенгә тилмереп, ачлы-туклы каңгырып йөрде дә үзеннән-үзе ничектер гаип тә булды. Ул чакларда товар поездларына эләгеп, төрле якка китеп була иде — без инде аны үзенең Самарасына киткәндер дип юрадык.

Болар — нэп вакытының сәнгать «корбаннары». Җиңел генә шөһрәт казанырга уйлап, бәхетсезлеккә дучар булучылар ул елларда очраштыргалыйлар иде әле.

Дәүләкәнгә ялгыз гына килеп чыккан артистлар да булгалады. Бер җәйне Мохтар Мутин килеп, безнең һәвәскәрләрне аякка бастырып, утлы табада биетеп, шаккатырып, бер генә спектакль уйнап китте. Бу инде чын артист иде, күренеп кенә узды, әмма тавышы озакка сузылды... Аннары Уфадан Мансуровский дигән өлкән генә бер абзый килеп чык-

калый иде. Шулай ук ярлы артист. Чабулары салынып төшкән зәңгәр пинжәгенең җиң очларын ак җеп белән типчегән булса кирәк, шәмәхә кара белән җыйнак кына буяп куйган. Шулай да үзе ак якасына кара бантик тагып йөри. Ул җырчы иде, озын башкорт көйләрен матур гына җырлый иде. Шуңа күрә аны базар көннәрендә баерак башкортлар үзләре белән чәйгә алып кереп, әйбәт кенә сыйлап, сәке түрендә җырлатып утыралар иде. Уфаның борынгы кешеләре бу Мансуровский дигән җырчы артистны хәзер дә әле бәлки хәтерли торганнардыр.

Дәүләкәнгә килеп чыккан тагын бер кеше турында әйтмичә уза алмыйм. Ерак Ленинградтан килгән иде, күрше Арыслангәрәй агайларда күпмедер вакыт кымыз эчеп ятты. Гаҗәп сәер бер кеше иде ул... үзе татар, ләкин исем-фамилиясен әллә белмәдек, әллә белеп онытгык — хәзер инде әйтүе дә читен. Һичшиксез, сәнгать дөньясыннан, тик театрданмы яки эстрададанмы — ул кадәресен дә ачык кына белә алмадык. Кечерәк кенә буйлы, бөтенләй сакал-мыексыз, йөреше һәм кыланышлары белән шактый ук хатынкызга охшаган иде.

Кичкә табан капка төбенә чыгып утырса, без аның янына бара торган идек. Ул бер дә тартынып тормыйча безгә төрле мәзәкләр сөйли торган иде. Мәсәлән, Петроградта, имеш, бер вакытны иң кечкенә аякларга ярыш үткәрелгән. Шул ярышта аның аяклары, имеш, иң кечкенә булып табылган һәм беренче зур призны алган... Хет ышан, хет ышанма!.. Ә аяклары чынлап та үсмер кызларныкыдай кеп-кечкенә — безгә мактана биреп, сузып күрсәткән дә иде.

Бер җылы кичне без, берничә егет, аның белән көймәдә йөрергә төштек. Үзе ул бик матур җырлый да икән. Дим өстендә рәхәтләнеп җырлап барды. Шул чакта мин аңардан беренче тапкыр «Алма-Ата» көен ишеттем. Күңелнең нигәдер үзеннән-үзе нечкәрергә торган чагы иде. Шуңадыр, ахры, аның бу яңа җыры миңа бик нык тәэсир иткән иде. Дим өсте көзгедәй тип-тигез, кучкыл-зәңгәр, талларның күләгәләре яткан, мин суны чапылдатмаска тырышып, әкрен генә ишәм, җыр мине еракка-еракка алып китә. Әмма кая илтә ул мине — мин белмим, белмим... Миңа бик ямансу, хәсрәтем эче-татлы, ирексездән күзәмә яшьләрем килә... Мондый хәл җыр тынлаганда минем белән хәзер дә булгалый әле. Шул сәбәпле җырларның сүзләрен мин бер вакытта да отып кала

...Кечкенә аяклы, матур җырлаучы бу сәер кеше Дәүләкәннән китәр алдыннан, Наильский белән сөйләшеп, безгә бер спектакль дә куеп күрсәтергә булды. Куйган нәрсәсе Чеховның «Аю» дигән ике генә кешелек комедиясе иде, үзе ул шундагы Елена Ивановна исемле, күптән түгел ире үлгән тол хатынны уйнады. Аюдай тупас помещик ролендә Наильский иде. Яше һәм кыяфәте белән бик үк туры килмәсә дә, аны грим һәм кием ярдәмендә помещикка охшаттылар. Әмма инде Ленинград артисты, әлеге ире өчен хәсрәт чигүче, ләкин ахырда «аю» кочагына эләккән Елена Ивановнаны искиткеч оста башкарды. Буе-сыны, чәче-бите, хәрәкәте, кыланышы, тавышы — бөтенесе коеп куйган чын табигый хатын-кызныкы иде. «Бесподобно!» дияр идем мин әгәр дә рус булсам. Белмәгәннәр аны ир дип тә уйламадылар, ә белгәннәр шаккатып утырдылар.

Заманында безнең кечкенә Дәүләкәндә әнә шундый күз күрмәгән тутый кош сыман гаҗәеп кешеләр дә булып, үзләре турында тиз генә онытылмас истәлекләр калдырып киткәлиләр иде. Әмма Дәүләкән аша укучылар белән якыннан очрашуның минем өчен иң истәлеклесе 1925 елның җәендә булган иде. Моны сөйләмичә үтү ярамас... Ничектер бер көнне ялгызым гына вокзалга таба киттем. Барып җитсәм, вокзал тирәсе буш, кеше юк, тик перрон рәшәткәсе буенда гына шәһәрчә киенгән ике ир белән ике ханым басып торалар. Җирдә чемоданнары — күрәсең, яңарак кына поездан төшеп калганнар. Яннарыннан ашыкмый-

ча гына колак салып уздым: үзара кызу гына татарча сөйләшәләр... Бу мине бик кызыксындырды — күренеп тора, ни житте генә кешеләргә охшамаганнар. Май чүлмәге тышыннан билгеле ди — һичшиксез, алар, кыяфәтләреннән күренгәнчә, чын шәһәр зыялылары. Ирләрнең берсе озын буйлы, эре, мәһабәт кеше, кулында калын, сырлы таяк, зур башында салам эшләпә. Икенчесе урта буйлы, жыйнак-ыспай, өс-башы да бик пөхтә. Хатыннарның исә берсе ак чырайлы, нәфис, юка гына гәүдәле, икенчесе яшьрәк тә, тулырак та һәм бик алчак та күренә. Кулларында нечкә саплы зонтиклар... Шунда ук уйлап алдым — болар, һичшиксез, кымызга килүчеләр, ләкин ни өчен монда кая барырга белмәгәндәй үзләре генә басып торалар? Туктар урыннары юкмы әллә?.. Кире борылып, яннарыннан тагын узган чакта мин уңайсызланыбрак булса да сорамыйча түзмәдем:

— Абыйлар, сезгә әллә фатир кирәкме?

Ханымнарның әлеге яшьрәге һәм житезрәге бик ачык тавыш белән:

— Кирәк иде шул, энекәш!— диде.— Син мондагы фатир төшерүчеләрне беләсеңме әллә?

Мин аптырап калдым — кемне әйтергә? «Базар» төшерүчеләр күп бездә, ләкин боларны анда илтеп булмый, билгеле... Теге мәһабәт дәү абый да калын тавышы белән сорап куйды:

— Может, сезнең бу салагызда алама гына булса да мосафирханә бардыр?..

— Юк шул, мосафирханә юк!— дидем мин, уйланып, һәм абыйларның йөзендә «булмады бу малайдан!» дигән төслерәк бер чырай күргәч, тиз генә әйттем үзләренә:— Ә мин сезне үзебезгә алып кайтам!

— Үзебезгә?.. Сез фатир кертәсезмени?

— Кертәбез.

— Без бит берничә көнгә генә...

— Барыбер.

Алар ышанып бетмәгән шикеллерәк бераз миңа карап тордылар. Мин бит инде малай гына түгел, уналты яшьлек... егет дияргә дә ярый — ышанырга тиешләр иде. Шулай да ак чырайлы юка ханым йомшак кына миннән сорады:

— Әти-әнием риза булырлармы соң, туганым?

— Булырлар, безнең залыбыз хәзер буш тора, урын житәрлек.

«Зал» дигәнне ишеткәч тә аларның йөзләре ачылган кебек булды: барырга ярый, димәк!

— Йортыгыз еракмы соң?— диде яшь ханым, жәһәт кенә.

— Юк, әллә ни ерак түгел.

— Бик хуп!— диде калын тавышлы абзый.— Киттек алайса... Әйдә, шәкерт, алдан атла!

Чемоданнарын жирдән алдылар, һәм мин ияртеп алып киттем бу шактый мәзәк, чибәр, сөйкемле кешеләрне!.. Безгә тимер юл буйлап бераз барасы да, аннары «Холодный переулок» дигән кыска бер урамга керәсе. Урамның аргы очында безнең йорт инде күренеп үк тора... Үзем атлыйм, үзем әзрәк кенә борчылам да: берьюлы дүрт кеше ияртеп кайтып, мин инәйне уңайсыз хәлдә калдырмам микән, алай-болай ризасызлыгын белдермәс микән? Ничек тә аңа алданрак әйтәсе иде бит... Сылтавын табып, артымнан килүчеләргә «әнә безнең йортыбыз, мин парадный ишекне барып ачыйм әле» дидем дә тиз генә алдан йөгердем. Өйгә килеп керү белән инәйгә кабаланып әйттем:

— Инәй, мин вокзалдан дүрт кунак алып кайттым, бик әйбәт кешеләр, син инде ачык кына каршы ал!

Инәй тәмам каушап калды:

— Ай аллам! Ни сөйлисең? Нинди кунаклар, әйтми-сөйләми...

— Шулай туры килде инде... Уфадан, берничә көнгә генә... Тик син, зинһар, ризасызлык белдермә!

— Нишләп белдерим, үзләре риза булсалар...

— Риза, риза!— дидем дә мин тизрәк төшеп, парадный ишеген ачтым.

Кунакларым килеп җиткәннәр иде инде. Керделәр, каушабрак торган инәй белән бик ачык исәнләштеләр: «Кабул итсәгез, абыстай, менә без улыгызга ияреп килдек»,— диделәр. Инәй дә: «Рәхим итегез, яратсагыз — торырсыз, урын житәрлек»,— диде аларга. Мин зал ишеген ачып, кунакларны эчкәре уздырдым. Керделәр, әйберләрен куйдылар, карандылар, ошаттылар булса кирәк — ничектер җиңел сулап, иркенәеп киткән шикелле булдылар.

Ак чырайлы апа миннән: «Исемең ничек, туганым?»— дип сорады. Әйткәч, «әдипләр исеме икән»,— дип тә куйды.

— Атаң кем?— диде дәү абзый.

— Нигъмәтҗан.

— Фамилиясе?

— Еникеев.

— Еникеев?.. Каргалы морзасы?

— Шулай шикелле,— дидем мин кызарып, һәм кайдан белә икән дип бик гаҗәпләндем.

Апалар инәйнең исемен сорадылар, мин әйткәч, икесе дә аның янына чыгып, «Хәдичә апа!» дия-дия бик ягымлы-ачык итеп сөйләшергә дә тотындылар. Инәйнең самавары куелган иде инде. Залга табын әзерләнде. Инәй сөтен, маен, ак күмәчен тәлинкә тутырып кертте. Кунаклар бик мәмнүн булып, чәйгә утырдылар.

Хуш, кемнәр булып чыкты соң бу мин иртәгә кайткан Өфе кунаклары?.. Моны үзләреннән туп-туры сорап булмый иде, килешмәячәк иде, шуңа күрә аларның үзара сөйләшүләреннән генә белергә мөмкин иде. Ирләрнең берсенә Нури, икенчесенә Шакир дип дәшәләр. Апаларның өлкәнрәгенә Нәгыймә, яшьрәген Маһирә диләр икән. Кыскасы, бер-ике көннән генә, ниһаять, мәгълүм булды: кунакларымның бер пары Нури Сакаев белән Нәгыймә Таждарова, икенче пары Шакир Шамильский белән Маһирә Мирвалиева иде. Татарның дан тоткан артистлары — мин инде аларны ишетеп белә дә идем.

...Килүләре исә чынлап та кымызга икән. Бездән Көрмәнкәйгә китәргә тиешләр. Ләкин кечкенә шәһәрне хәтерләткән Дәүләкән кебек җанлы гына бер урында тукталырга туры килгәч, алар үзара сөйләшеп, монда бер спектакль уйнап китәргә булдылар. Ул елларда сезон бетереп, эштән бушаган артистларның җай чыкканда сбор өчен спектакль уйнап китүләре гадәти бер эш иде. Менә Нури абый белән Шакир абый да каядыр барып, кемнәр беләндер сөйләшеп, тимер юл буендагы элекке зур рус мәктәбенең сәхнәсен бер кичкә алып торырга килешеп кайттылар. Хәзерләнүгә бер 4—5 көн вакыт киткәндер. Мин дә аларга әзрәк булыштым — ак кәгазьгә шәмәхә кара белән язган афишаларын урам чатларына ябыштырып чыктым. Шуның өстенә әле алар мине, спектакль көнне, сәхнә будкасына суфлер итеп тә утырттылар... Уйнаган әйберләре «Ташландык бала» исемле 3 пәрдәле драма белән «Чалбарлы туташ» дигән бер пәрдәлек комедия иде. Бу соңгысы халыкның игътибарын бик җәлеп итте бугай, чөнки чалбар кигән туташны берәүнең дә күрү түгел, ишеткәне дә юк иде. Шуңа күрә тамашачы шактый күп килгән иде, хәтта бик сирәк күренә торган кайбер мөхтәрәм кешеләр дә бар иде. Мәсәлән, нәп вакытында гына Дәүләкәнгә күчеп килгән һәм сату итәргә керешкән Стәрлетамак мулласы Мөбәракша Ханәфи дә остабикәсе белән әнә иң беренче рәткә килеп утырган! (Бу кайчандыр шактый мәгълүм, искечә әйтсәк, тәрәккый пәрвәр мулла иде. Аның эчүчелек һәм тәмәке тарту кебек зарарлы гадәтләргә каршы язган рисаләләре дә заманында басылып чыккан иде. Бу мулла халкында Шәйхзадә Бабич болай дип язган иде:

Мөбәракшаһдер Ханәфи, төп-түгәрәк, оп-озын
Аклы-коңгырт, күкле-саргылт, чуп-чуар һәм кып-кызыл!

Күрәсең, бик чуар кеше булган ул.

Спектакльне яхшы артистлар уйнагач, билгеле, бик уңышлы узгандыр инде — мин суфлер чокырында утырып, барысын да ачык күрә дә алмадым. Әйтергә кирәк, минем суфлерлыгым артистларны вакыт-вакыт читен хәлгә дә куйгалады шикелле, чөнки сәхнәдә барган уенга авызымны ачып мин, аларга сүз бирергә дә онытып җибәрә идем. Шул чакта артистларның берәрсе будка алдыннан: «Сүз, сүз!» дип пышылдап узгач кына айнып китә идем. Хәер, сүз бирсәм дә, бирмәсәм дә алар барыбер үз эшләрен эшли иделәр. Соңыннан мине шелтәләп тә тормадылар — күрәсең, моның ише генә нәрсәгә игътибар итмәскә күптән өйрәнгәннәр инде. Ә бәлки «егетнең» күңелен төшермик дигәннәрдер.

Әнә шулай итеп китте ул бердәнбер чын спектакль. Икенче көнне үк алар пар ат яллап, бездән Көрмәкәйгә китеп тә бардылар. Бездә бары алты гына көн тордылар, әмма бу алты көн минем өчен онытылмас бер бәйрәм булып калды. Алар янына залга керергә никадәр уңайсызлансам да барыбер кермичә түзә алмый идем. Гаҗәеп бер хөрлек, табигыйлек, гадилек һәм өзлексез уен-көлке иде алар арасында... Шуның өстенә Маһирә апа бик матур җырлый да иде. «Менә шулар кебек булсаң иде дә, шулар кебек торсаң иде!» — дип хыяллана идем мин ниндидер бер сагышлы-татлы уфтану белән. Үзләре дә сизмәстән алар әнә шулай әсир иттеләр дә киттеләр минем өмит-теләкләрем әле яңа гына уяна башлаган япь-яшь җанымны!

Шулай да язмышка рәхмәт әйтергә тиешмендер, ахрысы... 1925 елның августында Казанга килгәч, күпмедер вакыттан соң, мин аларның да Казанда булуларын белдем. Дүртесе дә Уфа театрыннан Казан театрына күчкәннәр икән. Ул чакта татар театры хәзерге ТЮЗ бинасында (Островский урамында) иде. Минем әле аларның берсен дә күргәнем юк, эзләп барырга кыенсынам да, ләкин күрәсем бик килә — ачык кына аңлап җитмәсәм дә моның минем өчен ниндидер бер әһәмияте булырга тиеш кебек иде. (Һич югы, таныйрлар микән дип кызыксынуым булгандыр бәлки.)

Ниһаять, сезон ачылып, спектакльләрнең берсенә баргач, мин театр бинасында Нәгыймә Таҗдарованы очраттым. Дәштем, билгеле — ул мине шунда ук таныды, ачык йөз белән исәнләште һәм бераз гаҗәпләнеп, минем шулкадәр ерактан Казанга ничек, ни өчен килүемне сорашты. Антракт вакытында сөйләшү кыска гына булса да, бу очрашу мине бик куандырды һәм ничектер тынычландырды. Нәгыймә апа әле, Нури абзый белән, шушы ук театр йортының бер бүлмәсендә торуларын да әйтергә өлгерде. Шакир абый белән Маһирә апа икенче җирдә торалар икән.

...Әкренләп мин калганнарын да күрдем. Күбрәк сәхнәдә уйнаганнарын күрә идем, ләкин ара-тирә театр эчендә дә очрата идем. Мин — укырга дип килгән яшь кенә егет, ә алар дәү кешеләр, исемле һәм эшлекле кешеләр — үземә ниндидер аерым игътибарны көтмим, әлбәттә, әмма очраганда Дәүләкән малаен танып, бездә биш-алты көн генә булса да торып китүләрен исләренә төшереп, ачык йөз күрсәтсәләр, миңа шул бик җиткән иде. Һәм әйтәсем килә, шушы тану, шушы үз итүләре алар тарафыннан гомерләренең ахырына кадәр диярлек бетмәде.

Еллар узып, үзем дә инде яшь ягыннан шактый олыгайгач, мин бу дүрт артистның икесе, ягъни Нәгыймә апа Таҗдарова һәм Шакир Шамильский белән ярыйсы гына якынаеп та киткән идем. Ни өчен икесе белән генә дигәндә, моның ачык сәбәбе шул: алар Казанга килеп күпмедер торгач та Шамильскийларның яшь балалары фаҗигале рәвештә үлеп китә. Менә ана өчен шушы аеруча зур хәсрәттән соң, Маһирә апа Мирвалиева сәхнәне ташлап, Казан университетының медицина факультетына укырга керә һәм биш елдан инде врач булып та чыга. Сәхнәне никадәр генә яратмасын, күпме генә иләшмәсен, әмма авыруларга, вакытсыз үлемнәргә каршы көрәшү аның җан таләбенә әйләнә. Ватан

сугышын да ул, башыннан ахырына чаклы врач буларак, фронтларда йөреп уздырды.

Нури Сакаев исә 1927 елның февраль ахырында кинәт кенә үлеп китте. Мин аның җеназасын (күмү мәрасимен) яхшы хәтерлим. Ул елларда шагыйрь, әдип яки артистның үлеме аеруча зур бер кайгылы вакыйга булып санала иде. Гәзитәләр дә аңа күп урын бирәләр иде. Озатырга халык та күп җыела торган иде. Моның шулай икәненә ышанып өчен Фатих Әмирхан белән Һади Такташның үлемен искә төшерү дә җитә.

Нури Сакаевны да бик зурлап озаттылар. Иң элек аның вафатына багышлап, Салих Сәйдәш үзенең мәшһүр «Сакай маршы»н язды. Бәгырьләргә үтәрлек бу гаҗәеп көчле-моңлы матәм маршы Сакаевны озаткан чакта беренче мәртәбә уйналды да... Нури абзыйның гәүдәсен театр бинасыннан алып чыгып, ачык машина өстенә урнаштырдылар (машина ул чакта бик сирәк нәрсә иде.) Табутының баш очына мәрхүмнең юан таягы белән кара эшләпәсен, ә аяк очына киеп йөргән ботинкаларын куйдылар. Артистны соңгы юлына аның исән чагында кигән, тоткан әйберләре дә озата бардылар. Бу моңарчы күренмәгән бер яңалык иде.

Тагын бер онытылмаслык эпизод: күмү мәрасиме Татарстан урамына җиткәч, «Шәрыкъ клубы» алдында тукталды. Халык тынып калды. Кәрим ага Тинчурин машина өстенә басып, татар театрының беренче үз йорты булган, сәхнәсендә Нури Сакаев та күп мәртәбәләр уйнаган шушы тар гына гади кирпеч бинага мәрхүмнең соңгы сәламен тапшырды... Әнә шулай тантаналы — җылы, күркәм, матур итеп озаттылар татар сәхнәсенең олы артистын!

Нәгыймә Таҗдарова белән Шакир Шамильский Нури Сакаевтан соң бер егерме ел чамасы озаграк яшәделәр. Дөрес, алар да дөньядан бик вакытсыз иртә киттеләр, әмма шулай да татар сәхнәсен үзләренең онытылмас гүзәл эшләре белән бизәп, театр сәнгатебездә тирән эз калдырып китәргә өлгерделәр.

Миңа аларның икесе турында да язарга туры килде. Сугыштан соң башта Бөтенроссия театр җәмгыяте тапшыруы буенча Таҗдарова турында язарга керештем... Нәгыймә апа авыру иде инде. Мин аның театр ишегалдында Сәйдәш торган кызыл йортның икенче катындагы кечкенә бүлмәсенә барып, кровате янына утырып, үзе һәм эше турында сөйләгәннәрен тыңладым. Шулай ук язып килгәннәремне дә янына утырып, үзенә укыдым. Әмма басылып чыкканын күрү аңа насыйп булмады. (Нәгыймә апа озак авырудан соң 1947 елның мартында вафат булды.) «Н. Таҗдарова» дигән кечкенә китап бары 1957 елда гына дөньяга чыкты. Шулай да бу китап безнең әдәбиятта артист иҗатын тикшерүгә багышланган беренче тәҗрибә, беренче әсәр дә иде.

Шакир Шамильский Нәгыймәападан ике ел чамасы алданрак — 1945 елның маенда вафат булды. Хатыны Маһирә апа да фронттан кайтып җитмәгән иде әле. Шакир абый бөтен сугышны ялгызы гына бик авыр шартларда яшәп үткәргән. Рәхимсез сугышның корбаны дияргә дә була аны... Мәрхүмне җирләгән көн бик нык истә калган, чөнки бу 8 нче май көне иде. Ни хикмәттер, шул ук кичне йокларга яткач, таң алдыннан Шакир абый бик ачык булып минем төшемә дә керде. (Соңыннан мин бу төшне язып та куйган идем.) Һәм шул чакта безнең урам тәрәзәсен кемдер бик каты каккан тавышка уянып киттем. Төшем өзелде... Янабызмы әллә дип сикереп торсам, тәрәзәгә күрше хатыны капланган, ике куллап кага-кага безгә кычкыра: «Нишләп ятасыз, торыгыз, сугыш беткән, ишетәсезме, сугыш беткән, җаныкайларым!»

Әйе, бөек җиңү хәбәрен китергән 9 нчы май таңы иде бу. Халыкның шатлыгы чиктән ашкан, урамнарга һәм мәйданнарга ташып чыккан көн иде бу... Бу көнне шатлыктан да, хәсрәттән дә җылаучылар аз булмады. Тик шуны мәрхүм Шамильский гына күрергә өлгермичә бер көн алдан китеп барды.

Шакир Шамильский минем иң яраткан, иң хөрмәт иткән кешем һәм артистым иде, һич тә икеләнмичә мин аны бөек артист дип әйтә алам. Билгеле инде, аның турында да мин язмыйча кала алмадым. Вафаты уңае белән «Совет әдәбияты» журналында язып чыктым, соңрак тагын тулырак һәм киңрәк тә итеп яздым. 1965 елны аның турында бер кечкенә истәлекләр китабы да җыеп чыгардым.

Шулай итеп, малай чакта уйламастан гына үзебезгә ияртеп кайткан артистларым белән миңа соңыннан да әнә шундый якын һәм дәвамлы бәйләнештә булырга туры килде. Кызык икән ул язмыш дигән нәрсә! Еш кына һич көтелмәгән нәтиҗәләргә дә китереп чыгара икән. Һәм уйлыйм ки, бу олы затларның минем киләчәгемә дә уңай йогынтылары булмыйча калмагандыр, әлбәттә.

1925 ел, гомумән, бик истәлекле ел булды минем өчен... Нәкъ шушы елда миңа туган-үскән оядан да аерылырга туры килде. Безнең тормышыбызга да шактый үзгәрешләр кертте ул нәүбәттәге бер ел.

...Атай хәленә килгәндә, аны нэпның беренче банкроты диярга була.

Югарыда язып узганымча, безнең атакай үзебездә фатирда торучы Муса Хәбиров белән базар мәйданында кечкенә такта кибет ачып, шунда бер кыш сату итеп азапланганнан соң, сәүдәләренең рәте-юне булмагач, кибетләрен яптылар да калган сумаларын бүлешеп, тату гына аерылыштылар. Муса абзый, хатыны белән баласын алып, Ташкент тарафларына китеп барды, ә без үзебезнең мактаулы Дәүләкәнебездә яшәргә тиеш идек. Атакай Дәүләкәнне никтер бик ярата һәм кая да булса күчеп китү турында уйлап та карамый иде. Әмма ләкин әнә шул уңышсыз сәүдәдән соң, нэпның әле иң кызган чагында безнең картның яңадан патент алып, үзе генә сату итәргә рәте беткән булып чыкты. Ул елларны кечкенә генә кибет ачып сату итүчеләргә дә зур налог салына иде. Һәм моны запас акчалы бик оста сатучылар гына күтәрә ала иде. Югыйсә, кибетеңнән дә, хәтта йортыңнан да колак кагуың мөмкин... Ләкин бит торырга кирәк, семьяңны асрарга кирәк, безне дә аякка бастырырга кирәк. Атакай күптән инде крәстиян эшеннән аерылган, игәр җире дә, җигәр аты да юк, бар мөлкәте — йортыбыз да бер сыерыбыз гына... Бүтән һөнәре юк, яше дә илледән узган. Билгеле ул базар тирәсендә алыш-биреш итеп кенә яши ала. Хуш, шуннан соң нишләргә, нинди юлын-чарасын табарга? Нэп заманындагы базарларда үз кулы белән нидер ясап, аяк өсте генә яки җиргә утырып кына сату итүчеләр дә күп була торган иде. Кибет тотмагач, аларны чын нэпманнардан санамыйлар, ә вак-төяк белән табыш итүчеләр генә дип карыйлар. Берәү чабата үреп сата, икенчесе чаганнан кашыклар ясап сата, кемдер тагын үзе иләгән куян тиреләрен күтәреп йөри. Азмыни шуның ише ипи-тозлык акча табучы һөнәрмәндләр?! Менә безнең атакай да үзенә шундый бер эш тапты — ул тимер чыбыктан кием элгечләр, таба һәм утюг аслары үреп сатарга керешге. Шуларны ясар өчен кирәк булган кискеч, бөккеч, «карга борны» кебек коралларны да каяндыр тапты, ә материалның үзен, ягъни тимер чыбыкның төрлесен Златоуст, Миасс якларына барып, шуннан табып алып кайта иде. Авыр йөк бу аның өчен, әмма бүтән чарасы юк — «башыңа төшкәч, башмакчы буласың» дигәннәр тормышны татыган агайлар... Белмим, бу «кәсепнең» табышы күпме генә булгандыр инде, ләкин һәрхәлдә акмаса да тамгандыр — акчаның бик бәрәкәтле чагы иде. Шуның өстенә, без йортыбызның урам башына һәрвакытта фатирчы кертә идек — бу да үзенә күрә бер терәк... Менә шулайрак яши торган булдык без нэпның нәкъ «чәчәк аткан» чагында.

Шул ук егерме бишенче елның язында уналты яшь тулды. Шул ук елны мин җиденче сыйныфны да тәмамладым. (Сугышлар аркасында өзелеп тормасам, бәлки иртәрәк тә бетергән булыр идем.) Уналты яшь,

үзегез беләсез, адәм баласының балигъ булу вакыты, шушы яшендә кеше малайлыктан аерыла, егет булып житешү чорына керә. Акыл, зиһен, хыял, рух — барысы да бик тиз үсә, көчәя, тирәнәя башлый. Эзләнү кила, тынгысызлык кила, хәтта борчылу да... Мин иң элек менә шушы тынгысызлык белән борчылуны үземдә сизә башладым. Билгеле, моның миңа гына кагылган аерым сәбәпләре бар иде. Һажәргә булган өметсез мәхәббәтне әйтеп тормыйм, чөнки мин (гәрчә мәхәббәт газабы кешенең жанын бик жәрәхәтләсә дә) аңа күпмедер дәрәжәдә иялләшкән идем инде. Иң борчыган, иң уйландырган нәрсә — ул киләчәк мәсьәләсе иде. Жиде сыйныфны гына бетерсәм дә, яшьтән әдәбият укыганга һәм соңгы вакытта газета-журналларны да күзәтеп барганга күрә, минем аң дәрәжәм белемемнән шактый ук өстен иде. Кем баласы икәнемне дә беләм, сәүдәгәрләргә карашның начар икәнен дә күреп торам, нәпның гомере кыска буласын, ил язмышы башка юлдан китәсен дә беркадәр чамалыйм. Менә шуңа күрә дә үземә юл сайлау, кем булу мәсьәләсе томанлырак, билгесезрәк рәвештә булса да минем жанымны ирексездән борчый да тора.

Гүя мин нидер эшләргә, каядыр китәргә тиеш, әмма кая китәргә, нәрсә эшләргә — бу кадәресе әле суга сәнәк белән язылган. Кечкенә Дәүләкән шартларында моңа жавап табуы да читен иде, аннары миңа әзрәк кенә үсә төшәргә дә кирәк булгандыр, ахрысы.

...Һәм шушы нәрсәне ничектер сизепме, әллә аң дәрәжәм өстенрәк булганга күрәме, мин үземнән яшькә олыраклар арасына керергә омтыла башладым. Үз тиңнәрем белән Димнең төрле жиренә барып су керүләрне яки чабата киеп футбол тибүләрне исәпләмәгәндә, минем инде якыннан аралашкан дусларым үземнән өч-дүрт яшькә олы, житкән егетләр иде. Алар арасыннан иң беренче итеп, мин, әлбәттә, Зөфәрне күрсәтер идем. Чөнки кече яшьтән үк дәвам итеп килгән якынлыкның тора-бара егетләр арасында гына була торган дуслыкка әйләнүе бик табигый иде. Әмма мине аңа тарткан тагын бер тирәндәрәк яткан сәбәп тә бар иде. Зөфәр бит ул егерме өченче елдан ук безнең беренче комсомол, яшьләрне үз артыннан ияртүче, күп эшләрне башлап йөрүче, өстәвенә әйбәт кенә гармунчы да, шәп кенә дикламатор да иде — билгеле инде аның кебек үткен булган егеткә һәркем тартыла, һәркем ярарга, ышанычын казанырга тырыша. Минем өчен исә кешегә ышану икеләтә зарур иде. (Бергә уйнап-көлеп йөргән иптәшләр арасында да иртәме-соңмы мөнәсәбәтләр үзгәрәчәген, бер вакытны моның миңа да кагылачагын мин ничектер сизә дә башлаган идем.) Әмма Зөфәрнең мине читкә какмаячагына ышандым.

Икейөзле түгел иде ул, атасы кебек туры сүзле — андый кеше хатаң булса туп-туры үзеңә әйтер, иллә мәгәр хаиннарча артыңнан китереп сукмас... Еллар үзды, нинди генә вакытларны кичермәдек, ләкин ике арадагы дуслык, бер-беребезгә ышану какшамады, бозылмады, искечә кала бирде. Тик безгә иртә аерылырга һәм озак еллар очрашмыйча торырга туры килде. Бары олыгаеп беткәч кенә без, ниһаять янадан очраша алдык. Ул инде күптәннән Бәләбәйдә яши иде — менә мин аны күрер өчен генә ике тапкыр шушы шәһәрдә булып киттем, һәм 1969 елны үземнен туган көнемә — Дәүләкәнгә дә чакырып алдым.

...Зөфәр миннән дә битәр Хәбибрахман белән ныграк дус иде, чөнки яшь ягыннан тиңрәк булып, иртәрәк бер-берсен белгәннәр, бергә йөри башлаганнар. Хәзер инде алар икесе дә бу фани дөньядан киттеләр, әмма хәтердән һәм күңелдән киткәннәре юк. Ак күлмәк, кара чалбар киеп йөргән егет чакларыбызның тере образлары булып, икесе дә бөтен кыяфәтләре белән минем күз алдымда сакланалар. Соңгы елларда безнең жырчыларыбыз каяндыр «Жомга» көен табып чыгардылар. Бу бит Зөфәрнең Димдә йөргәндә, кечкенә гармунында өздереп уйнаган көе, безнең аңа кушылып, дәртләнеп-шашып жырлаган көебез ләбаса! Моннан нәкъ алтмыш еллар чамасы элек!

Эчемнән генә әллә җырлыйм, әллә җылыйм:

> Гармуныңны тартып уйна урларга менгәндә дә,
> Онытасым юк үлгәндә дә, гүрләргә кергәндә дә...

Юк, булмый, житәр!

Казанга китәсе елны мин тагын үземнән дүрт яшькә олы бер егет белән шактый ук якынайдым. Бу — Фәтхелислам Хәкимов иде. Әнисе Латыйфа җиңги, энесе — Миңнеислам. Болар турында мин «Дәүләкән» өлешендә беркадәр язып узган идем. Аталары грузчик Мансур агай 1918 елны ук тифтан үлеп киткән. Тол хатын, ике малай бик авыр хәлдә калганнар, кеше өендә генә үтә фәкыйрьлектә яшәгәннәр. Егерме беренче елның ачлыгында алар бәлки исән дә калмаслар иде, ләкин бәхетләреннән аларны Гатаулла карт ач үлемнән коткарып кала. Карт аларга хәленнән килгән кадәре ризык та һәм ишегалды түрендәге өеннән җылы почмак та бирә. Тук елларга ирешкәнче алар күпме-азмы картка хезмәт күрсәтеп, шунда тыныч кына яшәделәр. (Ләкин батрак булып түгел, чөнки Гатаулла бабайның үзенең өч житкән улы бар иде.) Ике малай икесе дә мәктәпкә укырга йөрделәр. Мин үзәмә тиң Миңнеислам белән нигәдер артык дуслашып китә алмадым, ә менә агасы Фәтхелислам белән без киресенчә ару гына дуслашып киттек. Моның ике сәбәбе булды: мин Фәтхелисламнан белмәгән дәресләремне өйрәнә идем, икенчедән, Фәтхелислам да минем кебек әдәбият уку белән бик мавыга торган иде. Ул миннән бер сыйныфка югарырак укый һәм әйтергә кирәк, бик сәләтле шәкерт иде ул. Бигрәк тә математикадан, ә бу минем иң авыр дәресем,— менә мин аның янына шушы авыр дәресне өйрәнергә бара идем.

Әйткәнемчә, алар ишегалды түрендә озын гына йортның бер янтык мөешендә димме, торалар иде. Ишеге дә аның туп-туры ачык һавага чыга иде. Кем өчен, нәрсә өчен эшләнгән булгандыр инде бу мөеш (яки бүлмә), әмма ул шулкадәр бәләкәй иде ки, ишегеннән кергәч тә бусагада ук тукталып калырга туры килә. Чөнки эчкәрәк үтәргә урын юк — каршыда гына мич авызы, уңда, ике стена арасында, кыска гына сәке, шушы ике нәрсә белән «торак мәйданы» тулган да беткән. Ашау-эчү, ягу-тору иске киез җәйгән сәкедә, ә үзләренә житәрлек кенә савыт-сабалары мич кашагасы белән бердәнбер тәрәзә төбендә. Бүтән әйбер заты юк, хәер, мич белән сәке арасында бер бүкән тора икән әле — бу Фәтхелисламның пима (киез итек) төпләгәндә астына иске бишмәт салып утыра торган урыны. Күрше-тирә керткән пималарны әйбәт кенә төпләргә ул азмы-күпме килере өчен үзлегеннән өйрәнгән иде. Туры безе, кәкре безе, зур калын энәсе, әйбәтләп сумалалаган сүс җепләре бар — дәрестән кайткач, бүкәненә утырып, берәр пиманы ике тезе белән кысып телен дә авыз читеннән чыгара төшеп, эшкә тотына иде.

Фәтхелислам өс тә юка, эш тә кала дип булса кирәк, кыш көне бер дә чыгып йөрми иде, шуңа күрә мин үзем дәфтәрләремне күтәреп аңа килә идем. Үткән дәресне кабатлыйсы бар, укытучы биреп җибәргән мәсьәләләрне чыгарасы бар — менә миңа шуларны эшләүдә Фәтхелислам дусның ярдәме кирәк. Мин каршысына, сәке кырына утырып, әнә шул «чыкмыйча» мине азаплаган мәсьәлә белән аны таныштырам. Ул әйтергә ашыкмый, эшеннән дә аерылмый, тик «үзең уйладыңмы, тагын уйлап карале»,— ди миңа... Мин тагын каш җыерып уйлаган булам, ләкин барыбер «очын» таба алмыйм, тик шуннан соң гына ул ничек эшләргә кирәген әйтеп бирә. Кайчагында аның бер сүз әйтүе житә — мин шунда ук эләктереп алып, мәсьәләне ахырына чаклы эшләп тә чыгам... «Син, Әмир, ялкау,— ди торган иде ул миңа.— Әнә тырышкач булдырасың, бит!»— ди иде. Мин аның яныннан, билгеле, куана-куана кайтып китә идем.

Биредә аеруча шуны әйтергә кирәк, Фәтхелислам бик сабыр, тыйнак һәм гаҗәп әдәпле егет иде. Гаҗәбе шунда ки,— яшьтән үк атасыз калу, авыр нужа, фәкыйрьлек, ачлык бүтән берәүне бәлки бозып та бетергән булыр иде, әмма әнә шуларның барысын да бик нык татыган Фәтхелисламда бозылуның бер генә төрле дә билгесе юк, киресенчә, әдәп-инсаф ягыннан ул иң әйбәт шартларда яшәп, иң яхшы тәрбия алганнарга да үрнәк булырлык иде. Кайдан, нәрсәдән бу?.. Бәлки, нәсел-нәсәбеннәндер, бәлки Гатаулла бабай, Габдрахман абзыйларның да аңа уңай йогынтысы булгандыр, ә бәлки авыр нужа аркасында урам малайлары белән күп аралашып йөрмәү дә аны бозылудан саклагандыр?!. Ләкин шулай да әхлак дигән нәрсә, минемчә, күбрәк нәселдән килә. Энесе Миңнеислам да бит бу җәһәттән агасына охшаган.

Укулар бетеп, җәйгә чыккач, без буш вакытларыбызда, күбрәк безнең өйдә китап укырга ярата идек. Кояшлы көнне — өй артындагы бакчада, явымлы көн булса, зур залда икәү генә китапны алмашлап кычкырып укый торган идек. Гадәттә, мин ялгыз үзем генә укырга ярата идем, ләкин хәзер, дәресләрне бергә хәзерләп өйрәнгәнгә күрәме, кулыма яхшырак китап керсә, Фәтхелисламны да бергәләп укырга чакырмыйча калмыйм. Ул китап укуның тәмен белә, миңа кадәр үк күп кенә дини китапларны һәм дини акыятләрне укып та өлгергән. Элек бит андый китаплар кулдан-кулга йөреп, бик укыла торган булган. Ләкин хәзер инде безнең иң яратып укыганыбыз матур әдәбият, аның да иң яңалары... Шундый китап кулга эләксә, без инде аңардан аерыла алмыйбыз, хәтта инәйнең каймак тугып биргән катыгын ашаган чакта да!

...Һич онытасым юк, Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен икәү алмашлап укып чыгуыбызны! Сары кәгазь тышлы, соры кәгазьгә басылган, әдипнең креслога утырып төшкән рәсеме дә урнаштырылган корьәннән дә калынрак бу роман безне тәмам йотты, әсир итте, без аңардан аерыла алмас булдык, тиз генә бетмәвен, уку рәхәтенең бер дә өзелмичә дәвам итүен теләдек. Моңарчы да мин үзем генә яки икәү бергә укыган матур китаплар аз булмады, әмма «Безнең көннәр» кебек бу хәтле дә безгә ошаганы, безне беткәнче биләп алганы булды микән? Моның сәбәбен без ул чакта бәлки аңлап та бетермәгәнбездер, ләкин шулай да әсәрнең бер ягын сизмичә һәм тоймыйча калмадык: роман үзенең эчтәлеге, ягъни чоры, вакыйгасы, кешеләре белән безнең өчен гаять яңа һәм кызыклы иде. Менә ни өчен аның күп кенә каһарманнары да — Даут Урманов, Хәбиб Мансуров («Сруже») Сәхип шәкерт, Гөлбикә, Баязит карый, морза кызы Рауза, Даутның сөйгәне Нәфисәләр — хәзергә чаклы онытылмыйча хәтердә сакланып килделәр. Мондый хәл сирәк була. Ихтимал, шуңа күрәдер, мин бу романның әдип тарафыннан утызынчы елларның башларында төзәтелгән вариантын шушы көнгә кадәр укырга җөрьәт итә алганым юк, ничектер менә беренче басмасыннан алган тирән тәэсуратны югалтырмын дип куркам. Бәлки, мин ялгыша да торганмындыр, төзәтелгән варианты бәлки яхшырак тадыр да, ләкин нигәдер шуңа ышанып бетә алмыйм. Чөнки ул елларда «төзәтелгән» кайбер әсәрләрнең беренче вариантларына караганда шактый йомшак булып чыгуларын күрергә туры килде. Гомумән, конъюнктурага иярел әсәр төзәтү ул, минемчә, сәнгать эше түгел.

Безнең эшебез китап укып утыру белән генә чикләнми, әлбәттә. Күп вакытыбыз уенга, йөрүгә, җәмәгать эшләренә дә китә иде. Фәтхелислам егерме яшендә муйнына хәтта кызыл галстук та бәйләде, мәктәптә яңа оешкан пионерлар отрядына аны вожатый итеп куйдылар. Ә мин күбрәк клуб тирәсендә йөрим, анда үткәрелгән кичәләргә, спектакльләргә катнашырга атлыгып торам. Бу җәйдә безнең яшьләр бик активлашкан иде, ләкин мин аларның һәркайсы турында язып тора алмыйм — бик озынга китәчәк. Шулай ук бик кызыклы, бик күңелле көннәребез турында да сөйләп бетерү мөмкин түгел... Әмма ике кешенең яз-

мышы белән бәйләнгән бер вакыйганы шулай да сөйләү кирәктер дип уйлыйм.

...Җәйнең бик ямьле вакытында, печәнгә төшәр алдыннан без дүрт егет, ике кыз спектакль күрсәтеп йөрер өчен авылларга чыгып киттек. Җитәкчебез Әфтәх исемле, Волкомолда эшләүче егет иде. Зөфәрнең бик якын дусты ул, бер елгылар, бер үк вакытта комсомолга да кергәннәр, җитмәсә, икесе дә оста гына гармунчылар. Ләкин Әфтәх характеры белән Зөфәрдән нык кына аерыла да иде. Зөфәр кайнар, тынгысыз, ә бу, киресенчә, сабыр-тыныч, кешеләргә мөгамәләсе дә тигез һәм шуның белән ул безне үзенә тарта да иде... Менә шулай аның җитәкчелегендә авылдан-авылга йөрибез. Ул чакта клуб дигән нәрсә юк, ябылган мәчетләр дә юк әле, тамашабызны гел диярлек мәктәпләрдә күрсәтәбез. Йөри торгач, ахырда без Өршәк буендагы Мерәс дигән башкорт авылына килеп җиттек. Бу безнең юлыбыздагы соңгы авыл иде. Мерәслләр бербересенә якын гына торган ике авыл — без шуларның зуррагында туктадык.

Авылда җыен көне иде — күчебез белән җыенда йөрдек. Монда күргән ярышларны, уеннарны язып тормыйм — болар билгеле нәрсәләр. (Көрәшне, ат чабышын кем күрмәгән?!.) Минем икенче бер нәрсәне язасым килә: халык арасында җыен кызыкларын карап йөргәндә безгә киез эшләпә, ак күлмәк, кызыл ыштан, оек-чабата кигән бер таза-чибәр егет иярде. Кулларын артка куйган, як-ягына каранган була, ә үзе бездән бер адым да калмый — эчебездән генә, шикләнә бирәп, бу куе-кара кашлы егеткә ни кирәк икән дип уйлыйбыз. Ахырда йөри торгач, бер туктап торган арада үзе үк башлап Әфтәхтән сорады:

— Агай, сез Дәүләкәннәнме?

— Ийе, Дәүләкәннән,— диде Әфтәх.

— Әртистләрме?

Әфтәх егеткә сынаулы караш ташлады да көлемсерәп кенә:

— Ийе, монда без артистлар, менә бүген сезгә уйнап та күрсәтәбез әле,— диде.

— Бик әйбәт, көнен белеп килгәнсез,— диде егет тә елмаеп, аннары аз гына дәшми торып, тагын сорады:— Ә сез, агай, үзегез кайда эшлисез?

— Минме?.. Мин элек тегермәндә эшләдем, ә хәзер волкомолда эшлим.

— Вот!— диде егет эзләгәнен тапкандай кинәт яктырып.— Сез кирәк тә инде миңа!

Хуш, ни өчен әле бу егеткә һич көтмәгәндә Әфтәх шулкадәр кирәк булып чыкты?.. Баксаң, аның бик зур бер теләге бар икән: укырга һәм укырга! Юк, ул грамотный егет, үз авылында башлангыч мәктәпне күптән бетергән инде, ләкин хәзер аның кая да булса читкә китеп, зур җирдә укыйсы килә икән... Менә шуңа ничек ирешергә?.. Волкомол ярдәм итмәс микән?..

— Итәр, ник итмәскә!.. Теләгең бик әйбәт, егет кеше, ну читкә киткәнче тагын монда бер-ике кыш укырга кирәк булыр,— диде Әфтәх аңа.

Ләкин егет моның белән килешеп бетмәде, яшем узып бара, быелдан яки киләсе елдан да калмаска кирәк диде. Кыскасы, алар арасында әнә шундый бик мөһим сөйләшү булып алды.

Әйе, авыл яшьләрендә уку дәрте бик нык кузгалган чак, хәтта менә иң читтәге башкорт авылында да уянган икән инде ул дәрт!

Җыен бетәр-бетмәс, егет безне үзенең өенә дә кыстый башлады. Без, бераз кыенсынсак та, барырга риза булдык — җыеннан кунак алып кайту ул күптәнге йола, аны кире кагу килешмәячәк иде. Егетнең атасы юк, анасы белән икәү генә торалар икән — шулай диде ул безгә.

...Җил капкалы, читән абзарыннан башка бүтән бер каралтысы да булмаган, салам түбәле бәләкәй генә ярлы өй, әмма шушы ярлы өйдә егетнең инәсе — озын чандыр гына җиңгә — безне бик тәмле бәйрәм кой-

магы белән сыйлады. Сары майда гына «йөзгән» нечкә генә әче коймак ашап туймаслык иде. Җиеннан ачыгып та кергәч, без аны, иркен сәкегә аякларны бөкләп утырып, сөтле чәйне эчә-эчә, әйбәтләп бөктек кенә!.. Шәп төште бер таба коймак!

Ләкин соңрак безнең башыбызга бер кайгы да төште, бу авылда спектакль куярлык урын юк икән. Иске генә мәктәпләрен яртылаш сүтеп, яңадан сипли башлаганнармы шунда — кыскасы, әнә кереп, тамаша күрсәтеп булырлык түгел диделәр безгә. Бик аптырауда калган идек, шуннан соң хуҗа егетебез безне түбән Мерәскә алып китте. Ике авыл арасы бик якын иде, җәяүләп кенә барып та життек. Кечкенә генә, бөтен генә, күңелле генә бер авыл икән бу Яңа Мерәс... Һәм шушы авылда заманның кая таба барганын чамалый белгән бер бай башкорт үзенең келәт белән абзар арасындагы арбалар, чаналар тора торган ачык лапасын безгә биреп торырга риза булды. Кердек, карадык, лапасның түшәме юк, кыегы гына бар, аркылы киртәгә кибәр өчен яшь каен себеркеләре эленгән. Хуҗа сбруйларын келәткә күчерде, арбалар үз урынында калды. Без лапасның бер башын дәррәү генә әрҗә, мичкә кебек нәрсәләрдән бушатып, җир иләнен себереп, чаршау корып җибәрдек. Тамашачылар өчен бер-ике эскәмия дә табылды, калганнарына әнә арба-чана, я аяк өсте генә карарлар... Елына бер килгән тамаша бит бу, тик менә бик караңгыга калмасак иде. Чөнки ут юк, ут булмаячак, хуҗа лапаска лампа асуны катгый рәвештә тыйды. Дөрес тыйды, әлбәттә... Көннең дә иң озын чагы, сәгать уннарда гына сыек караңгылык инде, бары шул чакта гына ике авылның утызлап яшь-җилкенчәкләре лапаска, ниһаять, кереп тулдылар. Без инде күптән әзер идек, көтә-көтә арып та беткән идек. Әфтәх яшьләргә комсомол исеменнән кыска гына нотык сөйләде, шуннан без чаршауны шылдырып, уйный башладык. Кызганычка каршы, нәрсә уйнавыбыз ачык кына хәтердә калмаган — ялгышмасам «Яшьләр алдатмыйлар» дигән ике пәрдәлек кенә комедия иде бугай. Хәер, ни генә уйнамыйк, лапас астына йолдызлардан гына иңгән төнге яктылыкта тамашачылар йөзләребезне ачык күрмәсәләр дә, сүзләребезне бик ихлас тыңладылар. Ул заманда читтәге авылларда «тиятер» дигән нәрсә бик тансык иде, яшьләр бик мавыгып карыйлар һәм тәртипне дә һич тә бозмыйлар иде. Тамаша беткәч тә әле алар таралырга ашыкмыйча урамда безне көтеп тордылар.

Без эшне бетереп, җыенып, хуҗага рәхмәт әйтеп чыкканда таң сызылып килә, җир өстенә тын-соры яктылык әкрен генә җәелә башлаган иде инде. Яңадан иске авылыбызга кайтырга булдык, әлеге юлдаш егетебез үзенә чакырып тора — кызлар өйдә, ә без печәнлектә йокларбыз, ди. Киттек. Безгә ияргән егетләрнең берсе: «Давай, чабыннан кайтаек әле»,— диде. Чынлап та нигә тузанлы юлдан атларга? Авылны чыккач та болынга төшә торган арба эзе белән Өршәккә таба борылдык. Болында яшь үлән тездән югары, иртәнге бал чыгы төшкән, чәчәкләргә инде бал кортлары да килеп житкән... Күе үләндә күп эзләр калдырып атлыйбыз. Тынлык, алсу-тирән тынлык, тик әнә әрәмәлектәге кошлар гына уянып, балалары белән нидер чекердәшәләр... Әфтәх гармунын күкрәгенә күтәрә биреп, тартып җибәрде. Тирән таң тынлыгында яңгыраган гармун тавышы гаҗәеп икән ул! Бәгырьнең кай җиренә генә үтеп керми дә, нинди генә хисләр уятмый икән ул!.. Хәтта егетләрдән гармунга кушылып җырларга җөрьәт итүче дә булмады — һәммәсе дә әсәрләнгән, йотылган, онытылган, гүя аларга шушы гармун тавышыннан башка берни дә кирәкми!.. Һәм Әфтәх тә шуны сизгәндәй аеруча бер дәртләнү, кабыну белән, әйтерсең соңгы мәртәбә, бөтен күңелен — җанын салып уйнады... Күпме уйнады, нинди көйләр уйнады — мин әйтә алмыйм, әмма аның шул уйнавы минем хәтеремдә, минем колагымда гомерлеккә торып калды.

Сүз ике язмыш турында дидем. Инде менә шуның берсе: шул ук җәйнең сентябрь башында Әфтәх Уфа рабфагына укырга китәргә тиеш. Китәсе көнне ул кечкенә чемоданына кирәк-яракларын, китап-дәфтәрләрен салып, эшен бетереп куя да, урам аша гына торган Гомәр исемле егеткә әллә йомыш төшеп, әллә күрешеп чыгар өчен генә керә... Гомәрне мин дә бик яхшы белә идем. Ул ире үлгән Хәят исемле укытучының улы иде, зур кара күзле, кара чәчле, тыгыз-җыйнак бәдәнле егет, мандолинада бик оста уйнаучы — мине дә уйнарга өйрәтеп маташкан иде дә, тик бер хикмәт тә чыкмады. Гомәрнең Әминә исемле миннән берничә яшькә генә кечерәк, күп малайларны үзенә караткан бик чибәр сеңлесе дә бар иде. Алар Дәүләкәнгә ачлык елыннан соң кайсыдыр шәһәрдән күчеп килделәр. Ахрысы шунлыктан Гомәр дә, Әминә дә бик пөхтә киенеп йөрүләре һәм үзләрен ничектер һавалырак тота белүләре белән безнең Дәүләкән яшьләреннән аерылыбрак, өстенрәк торалар да иде. Шулай ук шәһәр йогынтысыдыр инде, Гомәрнең һич берәүдә булмаган ау мылтыгы да бар иде.

...Әфтәх менә шуларга керә, өйдә Гомәр ялгыз үзе генә була, һәм... бераздан Гомәр кулында әлеге ау мылтыгы атылып китә. Тугыз ядрә Әфтәхнең йөрәге аша үтә — кайберләрен соңрак аның аркасыннан ярып та алалар. Әфтәх берничә минуттан җан да бирә... Әнә шундый фаҗигале, мәгънәсез үлем!..

Игътибар иткәнсездер, мин мылтык Гомәр кулында атыла дидем, ягъни ул Әфтәхне үтерү максаты белән юри төзәп атмаган. Соңыннан суд та аңа мондый гаепне тага алмаган. Һәм Гомәрнең юри үтерү максаты белән атуына ышануы да бик читен, чөнки моның өчен аңарда Әфтәхкә карата ниндидер зур дошманлык, үч алу теләге булырга тиеш. Ләкин мондый дошманлыкны берәү дә белми, берәү дә сизмәгән — хәтта Әфтәхнең иң якын дуслары да. Кыскасы, мылтык Гомәр кулында ялгыш атылган (әлбәттә, саксызлык аркасында дип уйларга кирәк) — тикшерү вакытында Гомәр бары тик әнә шулай аңлаткан... Әйткәнемчә, алар өйдә икәү генә булганнар, әмма ничек булганын сөйләүчесе бер генә!

Дәүләкәннең беренче комсомолын бик зурлап җирләгәннәр, бөтен яшьләр, бөтен мәктәп укучылары озата барган, митинг булган, бәхилләшү сүзләре әйткәннәр. Зөфәр әйтә, Әфтәхне күмгән чактагы шикелле минем гомеремдә алай җылаганым булмады, ди.

Мин бу вакытта Казанда идем инде. Бу фаҗигале вакыйганы үз күзем белән күрмәдем. Тик күп еллардан соң моның барысын да миңа Зөфәр сөйләде. Ул иң элек кан эчендә яткан Әфтәх янына барып җиткән, ул күргән, ул белгән мылтык атылудан башка һәммәсен — менә мин дә Әфтәх һәлакәтен нәкъ аңардан ишеткәнчә язып чыктым.

Хәзер икенче бер язмышны да искә төшерик. Әлеге Мерәс җиенында очрап, безгә ияреп йөргән, Әфтәхкә укыйсы килүе турында борчылып сөйләгән киез эшләпәле, оек-чабаталы башкорт егете шул ук елны Казанга килеп чыкты — без аны, һич көтмәгәндә кала урамында очраткач, гаҗәпләнеп тә калган идек. Егеттә уку дәрте чынлап та бик көчле булган икән. Башта ул рабфакка керә, аны бетергәч, Казан университетында укый, аны да бетергәч, аспирантурада кала (шикелле) — һәрхәлдә сәләте һәм тырышлыгы аркасында бу мәһабәт, таза адәм үсә-үсә фән докторы дигән дәрәҗәгә дә ирешә. Махсус белеме буенча геолог ул, Татарстанда нефть ятмаларын табуда күп эшләгән галим. Озак еллар Казанда торган иде, хәзер Уфага күчкән дип ишеттем... Мин һаман аның исемен әйтмичә килдем. Инде ярый да торгандыр: ул — Билал Юсупов. Нефть чыгаручылар аны яхшы белергә тиеш.

...Ике язмыш! Алар нәкъ бер төсле булырга тиеш иде кебек. Ләкин әнә берәүгә язды, берәүгә язмады! Язмыш үзенә күрә бер табышмак ул!..

— Укырга, укырга, укырга! — дигән Ленин бабай. Һәм бу ялкынлы өндәү татар, башкорт яшьләренең дә колагына кергән иде. Егерме бишенче еллардан башлап, бигрәк тә татар яшьләре арасыннан, читкә укыр-

га китүчеләр күбәйде. Озакламый бу үзенә күрә бер хәрәкәт рәвешен алды. Авыл егетләре һәм кызлары Бәләбәй, Уфа, хәтта Казан белән Мәскәүгә таба да юл сала башладылар.

Миндә дә шул ук теләк, шул ук кайгы... Әмма бу кайгы бары укыйсы килү белән генә чикләнмәгән иде. Әйткәнемчә, яшьтән үк әдәбият уку, соңгы вакытта гәзит-журналларны карап бару һәм үземнән олырак яшьләр белән аралашу нәтиҗәсендә минем күңел күзем шактый ук ачылган иде. Миңа үз юлымны табарга кирәк, һәм соңга калмыйча!.. Әгәр Дәүләкәндә торып калсам, мин югалырмын, мин бер кем дә була алмам — менә шундый бер эчке сизенү минем җанымны гел борчый да тора. Тыштан гамьсез йөрсәм дә, уйнасам-көлсәм дә мин тыныч түгел, мин һаман уйланам... Билгеле, гел китү турында, каядыр китәргә кирәк, тик Дәүләкәндә генә калмаска!... Әлбәттә, минем өчен иң якыны, иң уңае Уфа иде. Анда җизниләр тора, җизни зур урында эшли (Шәриф Сүнчәләй Башкортстан гыйльми мәркәзенең рәисе иде) — аларга барып сыенырга, алар ярдәме белән берәр җиргә укырга да кереп булыр иде... Һәм шушы өмит белән җәй уртасында, ниндидер сылтау табып, Уфага барып та кайттым. Ләкин баргач күрдем (хәер, электән дә белә идем), алар Рокыя тутакайның өч ятим баласын укыталар. Каргалыдан Зөләйха да килергә тиеш икән, шулар өстенә мин дә килсәм, бу бик күпкә китәчәк, килешмәячәк — мин менә шуны аңладым. Әлбәттә, теләгемне әйткән булсам, алар тарафыннан бәлки бер төрле ярдәм дә булыр иде, ләкин әйтеп белдереп тормадым инде... Мин әле аларга әйтмичә генә үземә эш тә эзләп карадым, бер-ике учреждениенең коридорына да кереп чыктым, әмма юкка гына вакыт әрәм итеп, каңгырып йөрү иде бу... Әйләндем-тулгандым да тизрәк Дәүләкәнемә кайтып киттем.

...Һәм кайтсам, минем алдымда һич көтелмәгән икенче бер юл ачылырга тора, имеш!.. Эш шунда ки, мин Казаннан Татарстан гәзитәсен алдыра идем. Билгеле инде, Казанның үзеннән килгән гәзитәне мин башыннан ахырына чаклы бик җентекләп карап чыга идем. Бу юлы да Уфадан кайтуыма килеп торган гәзитәләрне дикъкать белән күзәтеп чыктым. Шул чакта берсенең соңгы битендә басылган игъланга күзем төште. Укыйм, яхшырак төшенер өчен икенче тапкыр да укыйм — хуш, нәрсә бу?.. Казанда рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыйммарәтчелек мастерскойлары бар икән. Игъланда менә шушы мастерскойларга укырга керү шартлары басылган. Ягъни мәсәлән, бу мастерскойлар имтихан биреп кергән яшьләрне я рәссам, я һәйкәлтараш, я гыймарәтче итеп чыгарачак икән. Татар яшьләрен махсус менә шунда укырга чакыралар! (Ул мастерскойлар русча Архумас дип атала иде.)

Бу игълан мине бердән канатландырып җибәрде, бөтен уем бары шунда тупланды: рәссамның кем икәнен мин беләм, һәйкәлтарашын бик үк белеп бетермәсәм дә, чамаладым — һәйкәлне ясаучы булырга тиеш, ә гыймарәтчелекне лөгатьтән карарга туры килде, аңсы — архитектура, имеш, ягъни матур биналар салдыручы. Нинди шәп, нинди гүзәл һәм мактаулы һөнәр иясе булырга мөмкин икән ләбаса! Шартларына караганда, шунда керер өчен минем белем җитәргә дә тиеш кебек.

Кыскасы, бу игълан мине тәмам хыялыйга сабыштырды, мин инде башка бер нәрсә турында да уйлый алмый башладым. Ятсам да торсам да минем уемда бары Казан, бары шундагы мастерскойлар, бары шуларда укып һәйкәлтарашмы, гыймарәтчеме булу хыялы! (Рәссам булырга күзем җитми, чөнки рәсемне бик начар ясый идем.) Ә күңелгә бер кереп утырган уйдан котылу мөмкин түгел — димәк, китәргә, һич нигә карамыйча китәргә, китәргә!

Әмма минем юлымда гаять зур киртә бар: атам-анамның ризалыгын алырга тиешмен. Бу ансат булмаячак, ялгызым гына Казанга чыгып китү өчен ризалык алу, юк, бу бик авыр булачак. Ләкин мин тәвәккалләргә

тиеш, вакыт аз, сузарга ярамый, ашыгырга, ашыгырга кирәк! Берничә көн бәрелеп-сугылып йөрдем дә, ахырда туп-туры әйттем үзләренә: Казанда менә шундый уку йорты бар, ул менә шундый кешеләр укытып чыгара, мин менә шунда китәргә булдым, дидем. Билгеле, алар минем «һәйкәл тарашларымны тамчы да аңламадылар. Инәй шунда ук ике кулын селтәп: «Ни сөйлисең, балам, куй, җүләрләнә күрмә, бер кая да җибәрмим!»— диде һәм яшьләрен тыя алмыйча җылый ук башлады. Атакай исә ашыгып каршы төшмәде, ул шактый ук уйга калды. Әлбәттә, ул укуның кирәклеген белә, укуга каршы да түгел, әмма Казан хәтле җиргә барып кергән мәктәбем нәрсә ул, нәрсәгә укыталар анда, рәтле кеше чыгачакмы аннан — менә нинди уйлар аны борчый иде булса кирәк. Бу хакта сүз күп булды, көн дә диярлек миңа үзем дә юньләп белмәгәнне аларга тотлыга-тотлыга аңлатырга, төшендерергә, еш кына кызып китәргә, җылап та алырга туры килде. (Духтырлыкка яки агрономлыкка укыйм дисәм, билгеле, бик тиз аңларлар иде.) Ләкин иң төп авырлык бу түгел иде, иң төп авырлык минем «ике бөртек»нең берсе булуымда иде. Ничек итеп шундый газиз баланы җаныннан аерып, әллә кайдагы зур калага җибәрмәк кирәк, китәр дә югалыр, эзен дә таба алмассың, ходай үзе саклый күрсен!.. Бигрәк тә инәйнең бөтен курыкканы, гел әйтеп торганы әнә шул иде, чөнки ул үзе күп йөргән, күп җирләрне күргән кеше. Тик яшеңбәләкәйрәк, улым, ди ул миңа, берәр ел сабыр иткәндә яхшырак булмасмы, ди. Ләкин инде мин сүз-киңәш тыңлаудан узган идем. Һич нигә карамыйча өзлексез китүне таләп итүем, өзгәләнүем, бәргәләнүем ахырда аларның каршылыгын сындырды. Ниһаять, атакай соңгы сүзен әйтте: «Ярый, улым, бар, бәхетеңне сынап кара!»— диде. Тик шулай да бер шарт белән: мин үземә ышанычлы бер юлдаш табарга тиешмен. Аңлыйм инде, аңлыйм шартларын — куркалар бичаралар, ялгызымны гына чыгарып җибәрергә!

Минем шатлыгым, әлбәттә, эчемә сыймый иде, мин инде Казанны күрмәс борын ук бәхетле идем. Ә юлдаш (иптәш) мәсьәләсенә килгәндә атайлар бик дөрес әйтәләр — юлдашсыз ярыймы соң?!. Юл ерак, Казан күрмәгән шәһәр булганга күрә генә түгел, ә яшь чакта без, гомумән, иптәшсез бер көн тора да, бер кая бара да алмый идек. (Хәзер генә ул ялгызлыкка өйрәндек.) Кыскасы, иптәш кирәк. Тик менә кемгә әйтергә, кемне күндереп булыр икән?.. Барлык дусларымны берәм-берәм күздән кичерәм — бу зур эштә бит дус малайның үз теләге генә җитми, бигрәк тә ата-анасы риза булырмы — менә хикмәт нәрсәдә!.. Мәсьәләнең иң элек шушы ягын уйлап, мин башта Сафиулла абзый малае Габделбарыйга әйтеп карарга булдым. Сафый абзый балаларына белем бирүне бик хуп күргән кеше, кызы Рәкыя апаны да революциягә хәтле үк рус гимназиясенә биргән иде, малайларын да иске мәдрәсәгә йөртмичә бары совет мәктәбендә генә укытты. Бари үзе дә безнең арада иң тырышып укучы иде, киләчәктә дә ул барыбер кая да булса укырга китәчәк.

...Мин аңа үземчә бик мавыктыргыч итеп, гәзитәдәге игълан турында сөйләдем. Беләсеңме, Казан бит ул дидем, теләсәң рәссам, теләсәң һәйкәлтараш яки гыймарәтче (архитектор) булырга мөмкин дидем. Түп-түгәрәк битле, кап-кара Барыем мине елмаеп кына тыңлады. Елмаюдан кысылып бетә язган күзләренә карап, аның әллә чынлап, әллә юри генә тыңлавын белеп тә булмый иде. Мин сөйләп беткәч, ышанмагандай сорап куйды:

— Ә сине җибәрәләрме соң?

— Шту син!— дидем мин, гаҗәпләнгән булып — берсүзсез җибәрәләр. Шуңа күрә сине чакырам да.

— Ярый, мин дә әткәйләргә әйтеп карармын,— диде Барием, ничектер сүлпән генә.

Әнә шулай балаларча гына сөйләшеп алу булды безнең арада. Барый ни өчендер Казан турында да, мин мактаган уку турында да сорашып тормады, шуңадыр инде миндә аңа ышаныч та туа алмады. Һәм икенче көнне үк инде ул миңа:«Юк, малай, булмый, әткәйләр якын да килмиләр»,— диде.

— Сөйли белмәгәнсеңдер, ышандыра белмәгәнсеңдер,— дидем мин аңа, кинәт ачуым килеп.

— Ә нәрсәгә ышандырып торырга,— диде Барый, бер дә исе китмичә генә.— Тугызны бетергәч, мин, беләсеңме, духтырлыкка укырга китәм... Бәлки әле шул ук Казанга!..

«Алай икән!— дидем мин эчемнән генә, һәм бер хакыйкатьне ничектер аңлагандай булдым: рәссам яки һәйкәлтараш булыр өчен генә уку берәүне дә артык кызыксындырмый да, тартмый да, күрәсең!.. Дәүләкән малайларына болар чынлап та бик ерак, бик ят нәрсәләр... Духтырлыкка яки агрономлыкка уку — бу икенче мәсьәлә, бу инде бик дәрәҗәле дә һәм бик кирәкле дә.

Әмма... кемне дә булса табасы иде бит, шайтан алгыры! Бик мөһим ич бу минем өчен — табылмаса, минекеләр дә я сүрелә башлар... Тик кемгә барып төртелергә, кемне генә котыртып карарга?!. Габдрахманнымы? Юк, ярамый, кирәкми, үзе теләсә дә — чөнки ышанычлы иптәш түгел... Таһирны да котыртып булмаячак, үзенең шушындагы туфрагына бик нык тамыр җибәргән малай, кышларын атасына ияреп бүре сугарга йөри, җәйләрен тирә-як җыеннарны калдырмыйча кола айгырларын чабышка йөртә, аннары кунак ярата, туй ярата, аулак өйләрне ярата. Менә шунда ул бәлки үзеннән берәр «һәйкәл» ясап та калдырыр... Дөрес, минем Мәхмүт дустым бар, ул минем белән Казанга түгел, җир читенә дә китәр иде, әмма ләкин атасының каты кулларыннан ычкына алмаячак. Итче Галинең нинди кеше икәнен мин сезгә сөйләгән идем инде.

Әнә шулай кемгә тукталырга белмичә, күңелдән эзләп, сайланып йөри торгач, мин кайгымны Фәтхелисламга әйтеп карарга булдым. (Сез беләсез, соңгы вакытларда без аның белән шактый якынаеп киткән идек.) Әлбәттә, аны кузгатып булыр дигән өмет белән түгел — чөнки Фәтхелисламның шушы яшенә җитеп, Дәүләкәннән беркая да аяк атлап чыкканы юк. (Аргы яктагы Көрмәнкәйдә дә булганы бар микән әле?) Икенчедән, фәкыйрьлекләре бик көчле, Казанга хәтле чыгып китәргә кайда аның акчасы да кайда кием-салымы?!. Аннары бит ул монда инәсен карарга, энесенә дә ярдәм итәргә тиеш. Дөрес, укырга бик сәләтле егет, күрше-тирәгә пима тәпли-тәпли булса да Дәүләкәннең тугыз еллыгын бетерер инде, иллә мәгәр читкә китеп укулар аңа, ай-һай, насыйп булыр микән?!

Шулай да мин аңа бер керүемдә аптыраганнан гына Казанга китү мәсьәләсен әйттем, иптәш юклыктан зарландым, менә синең белән киткәндә нинди шәп булыр иде, дип тә өстәдем. Ул моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, бары: «Кая, миңа да китереп күрсәт әле шул игъланыңны!»— диде.

Шул ук көнне мин аңа газитәне китереп тә күрсәттем. Бик җентекләп укыды да тагын бер сүз әйтмичә кире үземә бирде. «Я, ничек соң?»— дидем мин, сабырсызланып. «Әйбәт, ләкин синең өчен түгел»,—диде ул. «Нишләп?». «Рәссам булыр өчен зур кабилият кирәк!»

Аңардан моны ишеткәч, мин кинәт аптырап калдым.

— Туктале, Фәтхелислам!— дидем, ашыгып.— Анда бит әнә гыймарәтче булырга да укыталар... Кем ул гыймарәтче?

— Ну... зур йортлар, матур биналар салдыручы... Русча әйтсәк, архитектор.

— Әһә, үзең дә беләсең икән!.. Нигә әнә шуңа укымаска? Мин, мәсәлән, шул бүлегенә керергә дип барам да.

— Иң әйбәте шунсы инде аның,— диде Фәтхелислам, ниһаять,

уйланып кына.— Мине дә бик кызыксындыра анысы... архитекторлыкка уку!..

Миңа җитә калды аның бу сүзләре... Бернинди өметем булмаса да, мин аны бик нык кыстый башладым. Төрлечә — мавыктырып та, мактап та, хәтта ялварып та... Ләкин ул сүзен әйтергә ашыкмады — отказ да юк, ризалык та юк, бары «уйлармын» дип кенә куйды. (Гүя миннән котылыр өчен генә!)

Әлбәттә, аңа тәвәккәлләве бик читен — мин моны күреп торам. Ләкин бит миңа да көтүе ансат түгел, август аена кердек, китәргә булганда ашыгырга кирәк, хәзерләнергә!.. Мин инде бүтән егетләргә әйтеп тә тормадым, көн дә ут капкандай тотам да Фәтхелислам янына йөгерәм... Булса, аның белән бергә, булмаса — үзем генә! Һәм менә ахырда Фәтхелислам тыныч кына минем белән Казанга... барырга риза булуын белдерде. «Я, алла!» дидем мин, бер җиңел сулап. Җилкәмнән, әйтерсең, «Ярыш» тавы төште!..

Хәер, Фәтхелисламның бу кыю адымын мин бары үземә генә кайтарып калдырсам, өстемә артык зур җаваплылык алу булмасмы икән?.. Аның бит үз акылы бар, ул үзе барсын да уйлаган, исәпләгән булырга тиеш. Әмма шулай да кыю адымның сәбәпчесе мин булдым, мин аны урыныннан кузгаттым... Аның киләчәк язмышында моның хәлиткеч әһәмияте булачак әле — сез дә бер күрерсез!

Ярый, бусы булды, инде тизрәк юлга әзерләнергә кирәк. Үзем ашыгам, Фәтхелисламны да сакланып кына ашыктырам. Бездә, моңаебрак булса да әзерлек бара. Атакай бер җинел генә ак кәрзингә бик һәм йозак куеп бирде. Инәй шул кәрзингә юып киптергән, сырлы бәләк белән тәгәрәткән күлмәк-ыштаннарымны, бер-ике өске күлмәгемне, тастымал, оекбаш, кулъяулык кебек әйберләремне әйбәтләп салып куйды. (Кышкы киемнәрне, әгәр Казанда калырга туры килсә, соңыннан посылка итеп җибәрергә булдылар.) Китәр көн җиткәч, инәй юлга күп кенә итеп ит кыздырды, бер тавык та пешерде, бер бөтен икмәк, май, күкәй кебек азыкларны да кичтән әзерләп, шуларның барысын да аерым бер кечерәк бөрмәле капчыкка тутырды. Атакай кулыма 10 сум акча бирде. Бу, әлбәттә, аз, бик аз, ләкин мине, артыңнан тагын җибәрербез, дип юаттылар. Акча белән бергә атакай Казан докторы Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов исеменә язган хатын да миңа тоттырды... Казан халкына бик билгеле, соңыннан профессор булып танылган Әбүбәкер абзый Терегулов безнең Каргалыдан чыккан кеше, атакай аны яхшы белә икән — белү генә түгел, кайчандыр аңа ниндидер ярдәме дә тигән... Без менә шушы хат белән Әбүбәкер абзыйларга барып керергә тиешбез. Бүтән безнең барып төртелер урыныбыз да, кешебез дә Казанда юк.

...Тәгаен китәсе көнебезне минем дус-ишләргә артык белдерәсем килмәде. Шаулап озатырлар, ә кире әйләнеп кайтырга туры килсә? Юк, кирәкми, белми калулары яхшырак. Әмма күрше Борһан абзыйларга кереп чыгудан тыела алмадым. Бигрәк тә Һаҗәр өчен... Соңгы тапкыр күрәсем, күрешәсем һәм нәрсә әйтеп калыр икән дип беләсем килде. Кичкырын гына кердем. Зәкәрия, Яхъя, Хава, Хәким — алар бик ишле бит... Барысы да шаулашып, мине сырып алдылар. Барысы белән дә саубуллаштым, ләкин алар арасында Һаҗәр юк иде. Ул өй эченнән — ачык тәрәзәдән безнең тамашага карап тора иде. Беләм, чыкмаячак һәм яныма килмәячәк. Мин үзем ачык тәрәзәгә бардым, «иртәгә мин китәм инде»,— дидем, кулымны суздым. Ул да кулын бирде, ул да: «Хушыгыз!»— диде һәм шуның белән саубуллашу бетте. Мин чыгып киттем... Йөрәктән суырып кына ташлыйсы иде дә бит, булмый гына ләбаса, ходаем!.. Ярый, зур сәфәргә чыгар алдыннан күңелне болай төшермик әле — миңа язган бәхетләр дә бәлки табылыр әле, табылыр...

...Менә китәсе көнебезнең кояшлы иртәсе — бу августның әллә җидесе, әллә сигезе иде. Иртә генә тордык, иртә генә чәйне дә эчтек. Барыбыз да уйчан, инәй, бичара, боек, әйтер сүзләр дә беткән кебек.

Тик энем Илдархан гына гамьсез, бернинди күңелсезләнү юк, хәтта китүемә үзенчә куана да иде бугай. Әйтерсең, агасының Казан хәтле Казанга китүе малайлар алдында аның да дәрәҗәсен күтәрәчәк! Минем өйдә утырасым килми, тиз генә Фәтхелисламга барып килдем — хәзерләнеп ята, станциягә бер вакытта чыгарга булдык... Соңгы тапкыр ишегалдын әйләнеп чыктым, соңгы тапкыр коебызның салкын суын эчеп карадым...

Без өйдән күтәренеп чыкканда каршы яктан Фәтхелислам да үзе ясаган откалы әрҗәсен күтәреп һәм инәсе белән энесен ияртеп, безгә таба киләләр иде. Бергә кушылып, ишле бер төркем булып, Холодный тыкырыгы буйлап тимер юлына таба атладык. Безнең бит юлыбыз башта поезд белән Уфага, аннан инде пароход белән Казанның үзенә, боерган булса!

Вокзалга кайбер иптәшләр дә озата чыкканнар иде. Алар үзләренең көлү-шаяртулары белән безнең хәлне бераз җиңеләйттеләр. Югыйсә, аерылышу минутлары күңелсез — авыр, ничектер киеренке — ясалма була башлый... Инәйләрнең йөзләрендә хәсрәт, күзләрендә яшь, әйтер сүзләре әллә беткән, әллә төер булып утырган, ә без, китүчеләр, аларның хәлен җиңеләйтер өчен берни дә эшли алмыйбыз. Таптанып торабыз, як-якка каранабыз, бер әрсенең юк кына сүзеннән дә, тай кешнәгәндәй, кинәт кенә көлгән булабыз. Ярый әле болай интегеп тору озакка бармады. Әнә, элеватор ягыннан килеп чыккан поездның кара паровозы күренде. Атакай безгә билетларны алып, китереп биргән иде инде. Пассажир поезды монда ике-өч минут кына тора. Килеп туктавына без барысы белән дә ашык-пошык саубуллаштык, инәйләр тавышсыз гына жылаша башладылар... Әйберләрне тиз генә әләктереп, вагоныбызга йөгердек. Юри ашыкмый торган проводник билетларны караганчы һәм без кереп урнашканчы поездыбыз инде кузгалды да... Бәй, киттек тә мени?! Тизрәк ачык тәрәзәдән сузылсак, әнә вокзал бинасы да, кызыл фуражкалы станция начальнигы да, бер жирдә өелешеп, селкенмичә безгә карап торучы якыннарыбыз да әкрен генә артка йөзгәндәй ераклаша баралар. Без аларга кул болгыйбыз, ә инәйләр күзләренә җәелгән яшь пәрдәсе аша безне бәлки күрми дә торганнардыр... Поезд кызулый... станциянең озын, сары пакгаузларын узабыз, менә биш катлы «Труд» тегермәнен дә үттек, тимер юлына якын йортларның түбәләрен соңгы тапкыр күреп калдык. Озакламый поездыбыз казылма чокырга керде һәм Дәүләкәнебез күздән дә югалды... Без киттек, без минут саен ераклашабыз. Ләкин бу минутларданиләр уйлап, ниләр кичерүебезне мин аңлата алмыйм. Гомумән, житди уйлар килде микән безнең таркау башларга?.. Үзара сөйләшмибез, ачык тәрәзәдән яшел кырларга тик кенә карап барабыз. Әмма ләкин уйлый белмәсәк тә нинди дер бер эчке сизенү кичерә идек шикелле... Күңелнең бу сизенүе ике капма-каршы тойгыдан, ягъни бүгенге аерылышу кайгысыннан һәм, ниһаять, китә алу куанычыннан туган иде булса кирәк. Шуңадыр инде безгә бер үк вакытта ямансу да һәм ничектер жиңел дә кебек иде.

Поездыбыз такылдап, селкенеп бара да бара. Дәүләкән каршындагы ялгыз, мәһабәт «Ярыш» тавы да бездән әкренләп ераклаша, тик кин тугайлар уртасыннан боргаланып аккан Дим генә бездән калышмый — аның юлы да биек Уфа тауларына чаклы... Разъезд саен туктый-туктый барган поезд безне Уфага бер өч сәгатьтән генә илтеп житкерәчәк... һәм менә кузгалып китүебезгә күпме генә вакыт үткәндер инде, безгә беренче юл газабын да татырга туры килде. Әйтсәм, кеше ышанмас, һич уйламаган-көтмәгәндә нәрсәдәндер кинәт Фәтхелисламның бизгәге кузгалды. Аның бизгәге барын белә идем, ләкин авырып ятканын күргәнем юк иде, шактый ук әшәке бер нәрсә икән ул!.. Фәтхелислам, бичара, дер-дер калтырый, теше-тешкә тими, үзе көлдәй күм-күк булды. Өстәге сәндерәгә менеп, капчыгын баш астына салып, бөгәрләнеп ятты... Я, кирәк бит, үч иткәндәй, юлга чыккач кына!.. Мин, билгеле, бик борчылдым.

нишләргә дә белмим, Уфадан кире борылмаса ярар иде дип курка да башладым. Чишмәгә җиткәч, вокзалдан аңа бер кружка кайнар су китереп бирдем. Ул шуны ике учына алып, тешләренә тидерә-тидерә, йотымлап кына эчте. Рәхмәт әйтеп, кружканы кире бирде. Бераздан калтырануы басылгандай булды һәм йокыга киткәндәй тынып калды.

Сәгать өчләр тирәсендә Уфага килеп җиттек. Вагоннан төштек, зур бина аша вокзал мәйданына чыктык. Каршыбызда Уфаның галәмәт биек тавы басып тора — менә шул тауга менәргә кирәк. Ул елларда шәһәргә менәр өчен извозчиклардан башка бер төрле дә транспорт юк иде. Акчаң булса, извозчикка утырасың, булмаса — җәяүләп кенә менеп китәсең. Ләкин хәзер извозчикка утыру безнең өчен һич тә көтелмәгән расход. Нишләргә икән дип башны кашыйм мин, ә Фәтхелислам әйтә, давай җәяү генә меник ди. Менә алырсыңмы соң?.. Менәм, ди. Ярый, мин әйтәм, киттек алайса! Безнең бит вечүтеки яшь чак, көчле чак, безнең кебекләр гомумән извозчикка утырмыйлар. Әнә, барысы да кырмыскалар шикелле әкрен генә тауга үрмәлиләр... Дәүләкәндә чакта еш кына:

Уфа таулары биек, йөри арыслан киек.
Су сипмәгән гөлләр кебек, йөрибез янып-көеп,

— дип җырлый торган идек. Менә безгә дә августның бүгенге яман эссе көнендә шушы тауның җәфасын шактый ук татырга туры килде. Шулай да, туктый-туктый булса да, менеп җиттек, иркенләп бер сулыш алдык һәм туктап, артыбызга да борылып карадык. Чынлап та биек икән шул каһәр! Әнә, аста гына торган зур вокзал бинасы да, башка таш корылмалар да бихисап юлдагы озын-озын эшелоннар да моннан ничектер ерагая да һәм кечерәя дә төшкән кебек күренәләр. Ә бит алар гүя аяк астында гына...

...Тагын кузгалып киттек. Бер борылыштан соң центральный (хәзерге Ленин) урамның очына барып кердек. Уфаны бөтен аркылысына кисеп узган шушы иң озын, иң туры, иң шәп урам буйлап без аның икенче очына чаклы барырга тиешбез. Аннан инде җизниләр торган Садовой урамы да ерак калмый. Шундагы 3 нче номерлы бер катлы зур гына таш йортка безнең юлыбыз... Бу йортны тарихи бер йорт дияргә дә була. Җизниләр торган елларда, ләкин төрле вакыттарак анда Сәгыйть Сүнчәләй дә, гәзитә редакторы Муса Юсупов та, тел галиме Вәли агай Хангильдин дә торып киткәннәр. Мәҗит агай Гафури да еш кына килә торган булган. Зур гына бакчалы, верандалы, сигезме-тугызмы бүлмәле иркен-тоташ бер йорт иде заманында. (Хәзер дә әле саклана ул йорт, ләкин аны вак кына квартираларга бүлеп бетергәннәр.) Соңыннан минем үземә дә күп булырга туры килде бу йортта.

Бүген исә әлсерәп барып җиткәч, башта үзем генә керергә булдым. Ничектер капчыклар, кәрзиннәр күтәреп, капыл гына икәү барып керүне яхшысынмадым. Йорт иркен булса да торучылары да аз түгел, аннары монда бөтенесенә Срур тутакай хуҗа, ә ул хөрлеккә, бәйсезлеккә өйрәнгән горур хатын — ничек кабул итәр бит әле безне? Мине күргәч тә ул:

— Бәй, кайдан килеп чыктың әле син болай?— дип, гаҗәпләнүен яшермичә каршы алды. (Күптән түгел миңа бер килеп китәргә туры килгән иде бит инде.) Мин аңа Дәүләкәннән Казанга барырга дип бер иптәшем белән юлга чыгуыбызны, ләкин иптәшемнең поездга утыргач кына кинәт авырып китүен аңлатырга тырыштым.

— Нинди авыру ул тагын?— дип сорады Срур тутакай, җәһәт кенә.

— Бизгәге кузгалды.

— Бизгәк кенәме? Эч авыруы була́ күрмәсен! Шундый эсседә. Ә кайда соң ул иптәшең?

— Капка төбендә калды әле,— дидем мин, уңайсызланып кына.

«Йорисез шунда, җәфалар!» дигәндәй тамак кырып куйды Срур тутакай, аннары миңа коры гына:— Алып килгәч инде, урамда калдырмыйлар, туганым!— диде.— Бар, чакыр, урын табарбыз!..

Әлбәттә, башта ук мин бу йортта безне кабул итәчәкләрен белеп килгән идем, ләкин бит безнең эше «саладан килүчеләрдә», гадәттә, тыйнаклык дигән нәрсә кирәгеннән артыграк була... Ярый, бигайбә, тизрәк чыктым да әйберләрне күтәреп, Фәтхелисламны ияртеп кердем. Безне зур кухня янәшәсендәге кечкенә, караңгырак бер бүлмәгә урнаштырдылар... Монда салкынчарак та иде. Тыштагы кызудан соң безгә бер мәлгә рәхәт тә булып китте. Ләкин бераздан Фәтхелисламны тагын калтырата башлады. Бүлмәдә җыештырып куйган тимер карават тора иде — мин Фәтхелисламга чишенеп шунда ятарга куштым. Ул ботинкаларын гына салып, юка одеал астына кереп ятты. Мин өстенә кыска сырмасын да капладым.

Бу йортта ике изге җан бар — берсе аның Рокыя тутакай (атакайның бертуган сеңлесе, ә Срур тутакайның апасы була), икенчесе — җизнинең әнисе Һаҗәр әби. Рокыя тутакай шушы йортның бөтен йөген тартучы, бик кече күңелле, миһербанлы хатын — ул шунда ук Фәтхелисламга сөт тә кайнатып кертте, өстенә тагын бер чиста одеал да бирде. Һаҗәр әби исәниндидер дарулар, үләннәр китерде, үзенең бәрхеттәй йомшак тавышы белән ашыкмыйча гына егетнең хәлен сорашты, аннары тәҗрибәле карчык буларак үзенчә дәвалый да башлады. Фәтхелисламның хәле күпмедер вакыттан соң чынлап та җиңеләйде, дер-дер калтырануы бетте — басылды, температурасы да төште булса кирәк. Дөрес, иптәшем шактый ук йомшап, хәлсезләнеп калды, ләкин яңадан бу зәхмәте кузгалмаса, безгә иртәгәдән ничек тә чыгып китәргә кирәк.

Кичкырын, җизни дә эштән кайткач, мин алар янына чыктым. Верандага караган иркен бүлмәдә чәй табыны әзерләнгән иде. Ике якка киң итеп ачылган зур ишектән, куе бакчаның төрле үлән, чәчәк, алма исләре белән бергә, кызуы инде сүрелгән кичке талгын һава да кереп тора. Әйбәт вакыт, күңелле вакыт. Әмма кайчан булган иде соң бу?.. Күптән, бик күптән шул инде... Чәй янында җизни белән Срур тутакай миннән ни өчен болай кинәт кенә Казанга барырга теләвемне сораштылар. Мин аларга теләгемне булдыра алган кадәр аңлаттым һәм яхшырак аңласыннар өчен теге газитә игъланын да эчке кесәмнән чыгарып күрсәттем. Алар игъланны укыдылар, бераз уйланып тордылар, ләкин «юкка кузгалгансың, туганым» дип әйтмәделәр. Мин әзрәк сизәм инде — аларны миннән рәссам яки һәйкәлтараш чыгармы икән соң дигән шик борчый иде бугай. Әмма җизни дә, Срур тутакай да минем укырга омтылуымны, һичшиксез, хуплыйлар иде. Әгәр мин шушы теләп барган җиремә керә алсам, бу да бик әйбәт, бу да бик күркәм эш булачак, инде моның кебек махсус мәктәпкә керүе читен икән, Казанда уку йортлары бетмәгән, шуларның берәрсенә керергә тырыш, диделәр алар миңа сак кына. Иптәшем турында да сораштылар. Һәм ахырдан икебезгә дә максатларыбызга ирешүне теләделәр. Яхшы сүз — җан азыгы! Минем рух-дәрт бердән күтәрелеп киткән иде бу тын, җылы кичне туганнар белән бер табында утырганда.

...Икенче көнне без бик иртә генә торып, кухняда гына Рокыя тутакай әзерләгән чәйне эчеп, чыгып китәргә җыена башладык. Һаҗәр әбинең Фәтхелисламны кичтән дәвалап яткыруы бик шифалы булып чыкты — егетем иртән торганда яшь тәкә шикелле сау-сәламәт иде инде. Бәлки әшәке бизгәк аның буыннарын бераз йомшарткандыр да, әмма аңа карап кына монда безгә озаклап тоткарланырга ярамый иде. Китәргә тек китәргә!

Без зур йорттагы халыкны тәмле йокыларыннан уятмыйча гына кузгалырга булган идек тә, ләкин барыбер белеп, Һаҗәр әби дә, җефәк халатын киеп кенә Срур тутакай да безне озатырга чыктылар. Рокыя тутакай кулыбызга зур гына төргәк ниндидер ашамлыклар тоттырды, Срур тутакай миңа «туганым» дия-дия, гадәтенчә үзенең акыллы киңәшләрен бирде, аннары барысы да бергә хәерле юл теләп, ишек төбеннән озатып

калдылар. Шулай итеп, без, ике шәкерт, кәрзин-капчыкларыбызны күтәреп, бөтен шәһәр аша җәяүләп кенә пристаньга төшеп киттек.

Ниһаять, менә алдыбызда, түбәндә, безнең ак юлыбыз — Агыйдел! Гүя көтеп ята ул безне... Ирексездән тукталып, бер генә минут сихерләнгәндәй карап тордык та яңадан капыл гына кузгалып, түбән төшеп киттек. Аякларыбыз йөгертә генә безне ак юлыбызга таба!..

Ул заманда Уфа пристане бик кечкенә иде. Су өстендә пароходка охшаган бер корылма (ягъни дебаркадер) тора, ә яр өстендә бер төрле дә бина-мазар юк. Тик агым үрендә, бераз читтәрәк нииндидер озын лабазлар, алар каршында өсте ачык баржалар гына күренә.

Китәргә дип төшкән халыкның күбесе яр буенда аунап яткан бүрәнәләр өстендә утыра... Мин дә Фәтхелисламны әйберләре белән шул бүрәнәләрнең берсенә утыртып калдырдым да, үзем халык арасында йөрештереп, пароходның кайчан китәсен, билетларның кайда сатыласын сораштым. Белгән агайлар, Казан пароходы монда, тик каядыр өстәрәк йөк төятә, диделәр. Билет сатыла торган урынны да тиз таптым — ул су өстендәге пароходка охшаган әлеге корылмада икән.

Менә шундый мөһим эшләр артыннан өтәләнеп йөри торгач һәм көтә торгач, безне алып китәсе ике катлы ап-ак чибәр пароход салмак кына килеп, нәрсәләрнедер шыгырдатып, безне дә әкрен генә селкетеп, ниһаять, пристань корылмасына терәлде. Касса да ачылды. Кысылып-сытылып дигәндәй мин иң арзанлы 4 нче класска ике билет алдым. Фәтхелислам бөтен әйберләрне күтәреп минем янга төшкән иде инде. Тагын күпмедер зарыгып көткәннән соң халыкны пароходка кертә башладылар. Халык дәррәү кузгалды. Ә без ашыкмыйча җайлабрак керергә тырыштык. Кергәч әле кая таба барырга белмичә, юл өстендә тукталып калдык. Беренче тапкыр утырабыз бит! Кемдер безгә ачуланып:«Әнә, сулга, койрыкка!»— дип кычкырды, һәм без караңгы тар аралыктан кемнәргәдер бәрелә-төртелә сулга таба киттек. Иң койрыкта икән без барасы класс!.. Берничә генә рәт аслы-өсле сәндерәләре дә бар икән, ләкин инде аларны алдан керүчеләр алып бетергәннәр иде. Капчыклы агайларның ни өчен ашыгуларын бары шунда гына аңладык. Ярый,хәерле булсын дидек тә хәзергә стена буена, идәнгә урнаштык.

Төш вакытларында пароходыбыз, ниһаять, эшен бетереп, башта ике тапкыр, аннары өч тапкыр өзеп-өзеп, каты гына кычкыртканнан соң, бушап калган пристаньнан аерылып, әкрен генә кузгалып китте. Мин тизрәк «койрык»ның иң арттагы ачык җиренә чыктым. Пароход аз гына үргәрәк менеп, киң генә дуга ясап борылды да елга уртасыннан түбәнгә таба юл алды. Киттек без, киттек! Хәерле сәгатьтә!.. Гаҗәеп рәхәт икән пароходта барулары — селкетми, сикертми, гүя аккоштай йөзеп кенә бара. Тик ике ягындагы зур тәгәрмәчләрнең агач калаклары суны салмак кына шапылдата, койрыгы артыннан бик озак булып киң эзе ярылып кала, ә як-якка тыгыз атластай йомры дулкыннары бер-бер артлы куышып ярларга таба китәләр... Болар барысы да минем өчен бик яңа, барысын да беренче генә күрәм. Әле Агыйделнең ярларына, әле Уфаның тауларына карыйм — кош оясыдай тауның нәкъ түбәсенә урнашкан яки озын чокыр араларына сылашкан йортлар әкрен генә артта кала бара, шәһәр кырыннан ук тауларны каплап куе урман сузыла, урман эченнән манаралап эшләнгән нииндидер матур биналар сирәк кенә күренеп кала — хуш инде, хуш, минем җанга якын гүзәл калам!.. Ул заманда Агыйдел буйлап 100 километрга сузылган, көне-төне төтен дә ялкын бөркеп торган, иске Уфаның үзеннән дә зуррак дәвамы юк иде әле... Бөтен әтрафта шәһәрне чорнап алган, кеше таптамаган-бозмаган куе урманнар да сөрелмәгән-казылмаган чиксез киң болынлыклар иде.

Шушы манзарага карап бара-бара күпмедер хушлангач, мин юлдашым Фәтхелислам янына борылып кердем. (Ул, бизгәгеннән куркып, кояшка чыгудан саклана иде.) Төш вакытлары узган иде инде, бик ачыктырган да — без идәнгә табын корып, ашап-эчеп алырга булдык. Гәзи-

тә җәйдек, стенага сөялеп, аякларны сузып утырдык, капчыктан ризыкларны чыгардык. Иң элек минем зур тавыкны ботарладык. Азык-төлегебез житәрлек иде, кыздырган итебез дә бар, агач тустаган белән атланмай, бик күп йомырка (Фәтхелислам үзе генә дә ике дистә пешертеп алган), чәй, шикәр, ипи-күмәч — барысы да бар. Тавыкның калганын икенче көнне хәтта Агыйдел балыкларына да ташладык. (Кыздырылмаганга күрә исләнә башлаган иде)... Пароходның тагын бер рәхәт ягы — аның җиз борынлы зур бакларында өзлексез кайнаган су (кипәтүк) булып тора икән. Менә без дә кайнар кипәтүкне кружкаларыбызга агызып, бөртекле чәйне салып, әйбәтләп кенә чәй дә эчтек.

Хәзер бездә бер генә кайгы — ул да булса урын табу мәсьәләсе. Пароход Казанга дүрт тәүлектән дә ким бармый, диләр. Ләкин бу кадәр озын юлны гел идәндә аунап бару бер дә кызык түгел бит әле. Нишләргә? Әкренләп карана-сораша торгач, бер нәрсә ачыкланды — монда баручыларның бик күбесе үзебезнең татар агай-энесе булып, алар шушы Агыйдел буендагы пристаньнарда төшеп тә бетәргә тиешләр икән. Болай булгач, сәндерәләр дә әкренләп бушарга тиешләр инде. Тик безгә шуны бик «уяу» сакларга гына кирәк. (Соңрак белдек, Казанга хәтле баручылар әнә югарыда икән алар. Янә бер ише гади халык 3 нче класста.)

Беренче төнне стена буенда, башны-башка терәп дигәндәй утырып кына үткәрдек. Болай йоклар-йокламас баруның файдасы да тиде. Таң вакытларында пароходыбыз кайсыдыр пристаньга житеп туктагач, Фәтхелислам балалы хатыннан бушаган бер сәндерәне эләктереп алырга өлгергән. (Безнең ише идәндә баручылар аз түгел иде.) Тиз генә мине дә уятты. Әйберләребезне дә күчердек — хәлебез бердән җиңеләйде. Ә көн урталарында Бөрегә житеп, шактый халык монда төшкәннән соң, миңа да бер өстәге сәндерә бушады. Хәзер инде түшәмгә карап, җырлый-җырлый барырга да була. Юлыбыз озын, тагын өч тәүлек барасыбыз бар. Ләкин мондый рәхәттә беренче тапкыр йөзүебез булгач, без ялыгуны да, аруны да белмәдек, хәтта шәп-шәрә сәндерәнең кабыргаларыбызны авырттырып бетерүенә дә чыдадык. Пароходның бөтен эче белән диярлек танышып чыктык, бары уртадагы ухылдап барган машиналар чокырына гына төшмәдек. Бер тапкыр югары катка да менгән идек тә, тик безне аннан бик тиз борып төшерделәр. (Безнең ише дүртенче класс «кошларына» монда менү катгыян мәмнуг, имеш!) Аз гына күреп калсак та андагы чисталыкка, матурлыкка, яктылыкка, иркенлеккә исебез китте. Баручылары да бөтенләй башка шул — асылдан киенгән тутый коштай ханымнар, карлыгачтай нәфис туташлар, кыргычлап чистартылган көр алашадай тук ирләр... Менә кайда икән ул бәхетле кешеләр!— дип уйладык без... Хәер, чын бәхетнең нәрсә икәнен аңлаудан без әле бик ерак идек. Бәхетсезлекнең нәрсә икәнен беләбез, бу — ятимлек белән гариплек. Шулай уйлау безгә ничектер балачактан ук кереп калган иде. Ә бәхет дигәнен безнең әле татып караганыбыз юк. Бу очракта исә кеше пароходның югары катында бара алса, матур киенсә, тәмле ашаса, үзе дә чибәр булса — шул инде безгә бәхетнең иң югары ноктасы булып тоелган. Хәлбуки, соңыннан миңа Казан—Уфа арасын бик күп мәртәбәләр ак пароходның беренче класс каюталарында үтәргә туры килде, әмма моны мин бер вакытта да чын бәхеттән саный алмадым. Бәхет ул минем өчен һаман җавапсыз табышмак булып кала бирде.

...Кайчагында югарыдан пианинода бик матур татарча уйнаганнары ишетелә. Мин шул тавышка якынрак барам. Бик өзә бәгырьне бу музыка, ихтимал, шул чакта бәхет дигән бик кадерле, бик тансык нәрсә миңа якынайган шикелле дә булгандыр, әмма музыка тынгач, тагын бушлык кайта, тагын шөбһә кайта, бәхетем гүя миннән ерагая.

Без күбрәк пароходның койрыгында барабыз — анда җылы, яшык. Фәтхелисламның бизгәге тәмам басылды шикелле, яңадан инде ул бөтән калтыранып ятмады. Бетүе шул була күрсен!..



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме*

Көне буе Агыйдел буйлап бардык. Бер дә үзеннән аерыласы килми. Бик яшел, бик якты, бик ягымлы ул... Бик бормаланып ага ул, бик тар урыннары бар, үрелсәң — кара ярына озынрак колга да җитәр кебек. «Сандугач бугазы» дигән шундый бер бик тар урынны үттек. Ике ягында да биек куе тирәкләр... Мондагы сандугачлар сайравыннан пароходта баручылар йокыларыннан уяналар икән... Гаҗәеп елга, күпме җырларга кермәгән дә кемнәр генә аңа мәдхия язмаган!.. Мәктәптән үк күңелгә сеңгән шагыйрь сүзләре ирексездән телгә килә:

Идел буйларында киң болында
Җылкыларым утлый чабында,
Оҗмахларың торсын бер ягында,
Шул болында йөргән чагымда[1].

Ак пароходның зур тәгәрмәчләре тоныкк кына шаулап суны ишә дә ишә, без кара ярлар, яшел болыннар буйлап барабыз да барабыз... Икенче төнебезне шәрә сәндерәләрдә иркенләп сузылып ятып үткәрдек. Йокы монда гаҗәп тәмле икән, чөнки гаҗәеп саф, җиләсрәк су һавасы безне гүя йомшак кына сыйпап йоклата иде... Иртән торсак, манзара шактый үзгәргән — без Камага кергәнбез икән инде. Бу башкарак икән шул!.. Мәһабәт, көчле, киң елга. Ярлары да ерактарак, таулары да текә-биек, аның суы да кызгылт — күргән кешеләр Агыйделнекеннән нык аерыла диделәр. Әмма бу елганың үз тылсымы бар — ул күңелләрдә ниндидер бер зурлык, иркенлек хисе уята. Елга уртасында озын-озын комлы утраулар очрый, без хәтта утрау читләрендә озын-нечкә сыңар аякларына гына басып, йокымсырап торган соры торналарны да күреп уздык. Бозылмаган табигать, өркетелмәгән кошлар күпме гасырлардан бирле шулай сакланып килә, ахрысы... Гомумән, бу елгалар безнең җаныбызга һәм аңыбызга җырлар белән, әкиятләр белән, ниһаять, әдәбият белән кергән, шуңадыр, бәлки, беренче күрүдән үк шушы елгалар буенда бит инде безнең ерак бабаларыбыз яшәгән, шушы бит инде безнең төп ватаныбыз дигән уймы, тойгымы күңелләрдә ничектер уянмыйча калмады.

Кама өсте җанлырак та иде. Әледән-әле безнекеннән дә зуррак ак пароходлар очрый, галәмәт зур баржаларны сөйрәгән җәенке-карсак пароходлар да очрый, буе берничә йөз метрга сузылган, өстенә кечкенә ак бура утыртып куелган салларны да узып китәбез. Пристаньнар да бу елгада күбрәк, икеме-өчме зур гына каланы да уздык. Пароход озаграк туктап торганда без дә ярга чыгабыз. Монда чын базар, азык-төлектән җаның ни тели — барысы да бар. Күз кыза, әмма акча кызганыч. Шулай да бер урында ике стакан карлыган алдык, икенче тукталганда свежий кумәч белән кайнаган сөт алып кереп ашадык.

...Ниһаять, дүртенче тәүлекнең иртәсендә зур Иделгә кердек. Бу инде олы Идел, баш елга, тарихи елга! Ниләр генә күрмәгәннәр ул үз гомерендә?!. Менә без барып җитәсе Казан да аның ярларында. Шушы үзе генә дә Казанны үстерә, аңа дан өсти кебек... Идел Камадан нык кына аерыла икән. Киңлеге белән бәлки бер чамадыр, әмма бөтен күренеше, әтрафы белән ничектер олы сыман, яктырак та, иркенрәк тә сыман. Аның суы да Каманыкыдай кызгылт-болганчык түгел, ә эретелгән кургашын төслерәк аксыл-коңгырт. Ярлары да төрлерәк, яшел хәтфә белән капланган зур йомры таулар бар, текә генә киселеп төшкән ак балчыклы ярлар бар. Бездән уң кулда исә күлләре, таллыклары белән җәйрәп яткан киң тугайлык, ә тугайлыкның аргы чиге буйлап тоташ куе урман сузылып бара.

[1] Фазыл Туйкин шигыреннән.

...Күпмедер вакыттан соң пароходның югары катында хәрәкәт, шау-шу көчәйде. Казан күренә, диделәр. Эх, шунда мендерсәләр иде. Ләкин булмасны өмит итеп торудан мәгънә юк — без тизрәк пароходның алгы башындагы тар гына палубага уздык. Бөтен күзебез, дикъкатебез алда, елганың түрендә. Шулай җигелеп карый торгач, ерактa, сыек рәшә аша зур каланың биек ак биналары, чиркәү гөмбәзләре күренә башлады. Менә шуңа, шул сихри-мәһабәт манзарага әкрен-әкрен шактый озак якынлашабыз. Кала Иделдән күпмедер читтә булса кирәк — ике арада киң генә тугай барлыгы сизелә... Якынлаша барган саен Казан да ачыклана бара — чиркәүләр бик күп икән, алтын гөмбәзләре елык-елык нурда уйныйлар. Әнә, әнә, калкулык өстендәге шул чиркәү гөмбәзләре уртасыннан киртләчләнеп күтәрелгән нечкә-озын бер манара күренде. Без аны шунда ук таныдык: Сөембикә манарасы!.. Йөрәкләр аша гүя ниндидер бер дулкын йөгерде — ул сабырсызланып, ешрак тибә башлады. Күзләргә дә ниндәндер җылы томан пәрдәсе җәелгәндәй булды. Шунда ук Мәҗит Гафуриның шигъри юллары күңелгә килде (без аны мәктәптә хор белән җырлый торган идек):

Һәр бинадан биек улып күкләргә чыкмыш башың,
Мин беләм белдермәсәң дә агадыр канлы яшең.

Әйе, Сөембикә манарасын беренче мәртәбә менә шулай ачык күрү безнең өчен, һичшиксез, дулкынландыргыч вакыйга иде — без, әйтерсең, ерак тарих түренә, халкыбызның үткән язмышына күз салгандай булдык.

Кала зур, кала мәһабәт иде. Читләрендә озын-озын завод торбалары да күренә — болар инде калага ниндидер бер көч-куәт биреп торалар кебек иде. Без, зур өмитләр белән килүче ике шәкерт, Татарстан социалистик шуралар җөмһүриятенең башкаласына якынлашабыз.

Пароходыбыз килә-килә, ахырда Үсиягә җитеп, яр буендагы дебаркадерларның берсенә әкрен генә терәлеп туктады. Басманы сузгач, озын юлдан арган, талчыккан халык ашыкмыйча гына агылып чыга башлады. Без дә бушап калган капчыкларыбызны иңебезгә элеп, шул агымга ияр-дек. Ярга чыктык, һәм менә, ниһаять, Казан туфрагына аяк бастык.

Май, 1984 ел.

# Олжас Сулейменов

## Куып тот!

Куып җит мине, егет,
Атың кебек ит, егет,
әгәр дә мине сөйсәң,
куып тотарсың кебек.
Сине яратам, егет,
куып җит тә
ал үбеп.
Оялудан тавышым
тамагыма ябышты.
Мине җил куып уза,
ул билемә кул суза.
Аһ, егет артка калды,
әллә атымы талды.
Үчекли мине Ай-кыз.
Мин ялгыз
Айдай ялгыз.
Кулларым инде талды,
атымның сырты канлы.
Эх, сез усал кешеләр,
сез бит миннән көлгәнсез:
шундый батыр егеткә,
шундый матур егеткә,
шундый әйбәт егеткә
туры чаптар урнына
хәлсез ишәк биргәнсез!..

●

Поездлар соңгаралар.
Яшел семафор — харап.
Мәтәлде соры йолдыз —
самолетлар соңгара.
Мәрхәмәтле гасырның
хәкиме каш җыера —
күзеннән аккан нурны
керфек тоткарлап тора.
Барыбер лә ни ялвар,
ни ачу белән эндәш —
чыбыркы озынлыгы
соңгара синең киңәш.
Киләчәкнең шәүләсе
портретның төсен казый,
сөеклем, ничә елга
соңара синең назың!
Клавишлар буйлата,
Листка ярдәм дип уйлап,
дастаннан ирләр кайта,
соңгарып
өч йөз елга...

## Аргамак

Эй, сез кыпчак далалары,
данлы ат көтүләре!
Кипкән үлән яңгырында
айгырлар утлап йөри.

Бир миңа яшь аргамакны —
уйный җан тамырларым,
шәһәрен дә, даласын да
җилим бер, җилен ярыйм.

Аргамакның кайнар канын
җил өреп ялкын итәр,
Тояк
очырган
очкыннан
үләннәр яныл китәр.
Аргамакның аңына да
Һөҗүм тәме
иңәр бер..
Куркак
сукмаклар
йөзенә
тояклар шавын бәрик!..

●

Думбырасын чиртә-чиртә
бер карт акын
бик күптән
җырлый мәхәббәт турында,
инде карлыгып беткән.

Ялпәк йөзләр, мыеклардан
хасил җанлы түгәрәк...
Юртага ишәк ышкына...
Атлар эткә тибәләр...

Моңга кемнәрдер кушыла...
Акын белә җырлавын.
Юртага сөялгән килеш
йоклый сөңге урманы.

Р. ХАРИС тәрҗемәләре

**Рашат Низамиев**

# УРМАН ЭЧЛӘРЕНДӘ УРМАН

ПОВЕСТЬ

## Нигә ашкынам әле...



Кайтып киләм!

Поезд тәгәрмәчләре бертуктаусыз рельсларга суга...

Кояшның мине озата баруы микәнни: юл читендәге имәннәр белән куыша-куыша поезд артыннан йөгерә ул. Кәүсә һәм ябалдашлар ешлыгында югалып тора да, утлы шар сыман яңадан каршыма тәгәрәп чыга. Тирбәлә, оча, чайкала — минем күкрәктә тыпырдап торган сагыну-сагышлар шаукымы, әйтерсең, аңарга да күчкән...

Әйе, минем бөтен гәүдәм электр тогыдай куәтле ашкыну белән тулы! Солдат шинеле кигән, дөм караңгы төннәрдә берьялгызы сакта торган, гимнастеркасына бәсәреп чыккан тозлы тиренең тәмен татып караганнар гына андый ашкынуның ни икәнен яхшы беләдер. Билгә беренче тапкыр каеш буганда миңа унтугыз яшь иде. Әле күптән түгел, заставам белән саубуллашыр алдыннан гына, пограничник дусларым туган көнем белән котладылар: егерме бер яшь... Бу сан миңа, матур һәм серле тоелу өстенә, яшьлегемнең кыл уртасында басып торуымны да искәртте кебек. Яшьлегем уртасынниләр белән, нинди уй-хыяллар белән каршылыйм соң мин?

Ике елым ерак чик буенда, карлы сопкалар иленда узды. Инде менә күкрәктәге хәрби билгеләрне, яшел петлица һәм погоннарны ялтыратып, бөтенләйгә кайтып килешем. Беләгемдә — язулы кул сәгате. Чемоданымда — застава начальнигы үз кулы белән тапшырган истәлекле кәгазь. Анда: «Куркынычлы чик бозучыны тотуда кыюлык күрсәткәне өчен рядовой Фәрит Юлдашевка рәхмәт белдерәм»,— дигән сүзләр язылган. Бу сүзләр миңа «граждански» тормышта да намуслы, гадел һәм тырыш булырга куша.

Тамбурда басып торам.

Поезд тәгәрмәчләренең тигез шавы, борнап чыккан үләннәрнең тере агым булып артка йөгерүе, кояшның тирбәлә-тирбәлә озата баруы: болар һәммәсе тоташ бер җырга — юл җырына әверелә. Тышта яз, май башы. Яшел вагоннарга ышкылып тыгыз-йомшак җил ага. Чәчләргә, куенга кереп тулган шушы рәхәтлекне икенче берераклык белән чагыштырып карыйм: юк, болар башка, болар Камчатканың чәнечкеле җиленә тамчы да охшамаган, мөгаен, туган як кырларының беренче сәламедер бу. Агачлар ешайды, каршымнан күгелҗем-яшькелт ташкын

булып урман шуыша. Тирән итеп сулаган саен аермачык тоям: монысы — чәер катыш ылыс тәме, болары — яшь үлән һәм баллы яфрак исе... Чү, монысы, валлаһидыр, күңел тансыклаган әрем тәме! Чынлап шулай идеме бу, мавыга торгач әллә тоелды гынамы — һәрхәлдә, борыныма кинәт кенә әрем тәме килеп бәрелде.

Поезд инде Азия белән Европа чиген үтеп бара иде...

Ә мин исә бу минутта, гүя, балачак чиген узып барам, тәгәрәп-аунап үскән ишегалдына һәм тыкрыгыма кайтып төшәм. Әрем исе уйларымны чуалтып ташлады. Безнең бәрәңге бакчасы артында үсеп тә карый иде соң әрем! Аксыл томандай җәелеп, киртә буйларында җәй буе патшалык итә. Кулың белән кагылдыңмы, әчкелтем әрем исе көн буе синеке инде, сабынлап та бетерермен димә. Сабаклары катылангач, көзгә таба әни берәм-берәм сындырып алардан идән себеркесе ясый. Әти, матур булсын өчен, сабаклы башын балта белән чабып тигезли...

Кинәт шушы урында йөрәкнең тибеше ешая, күңел төпкелендә яткан иң тирән хис тышка актарылып чыга. Нигә соң әле болай ашкынам? Хатирәләр диңгезен ера-ера, кем янына шул тиклем ашыга күңел?

Әни янынамы?

Әйе, ике ел эчендә мин аның ягымлы тавышын, пешергән ашларын, өстәл тирәли йөргәндәге кайгыртучан хәрәкәтләрен үлеп сагындым.

Әти янынамы?

Әйе, аның ирләрчә нык кулларын, яхшылык нуры бөркелеп торган күзләрен, тәмәке тарта-тарта ишегалды бүрәнәсендә уйланып утыруын бик тә күрәсем килә.

Сеңелем Фәридә белән күрешү шатлыгымы мине алга җилкендерә? Ул инде ике ел эчендә байтак үзгәргәндер. Хәрбиләрчә нык басып, пограничник киеменнән кайтып кергән абыйсын күргәч, нишләр икән ул? Элеккечә ике кулын чәбәкләп сикерер, аннары гына саргылт чәчләрен артка чөеп таулар, диңгез җиле турында сораша башлар, мөгаен.

Әллә соң мин авылдашым Зөлфирәне тизрәк күрү өчен шулай ашкынаммы? Ул хәзер Казанда яши, студентка. Аның хатларын уку мине исертә, яшьлек хыялларымны очындырып тагын да биеккәрәк күтәрә. Безнең бит сөю вәгъдәбез бар, ул мине көтә... Зөлфирә, Зөлфирәм!

Вакыт пружинадай кысылып килә. Берәүдән дә рөхсәт сорап тормастан вакытны ашыктырам икән, моның үзенә күрә сере бар, әлбәттә. Мин ул серне, күңелемдәге хискә, ачышка тәңгәл китереп, бөек сер дип атадым. Ә ачышны, иртәме-соңмы, гомеренең кайсы да булса бер ноктасында һәркем ясарга тиеш, минемчә.

Дөресен әйткәндә, мин унҗиде яшемә кадәр белми йөргән әлеге сер йомгагын әти белән әни үзләре сүтеп, кузгатып җибәрделәр. Унынчы классны тәмамлаган көннәрем иде. Җәйге тымызык кич, түбә калайларын дөбердәтеп яңгыр ява. Күкләрне тутырып яшьнәгән яшеннең яктысы, бер фокуска тупланган нур көлтәсе сыман, секундның меңнән бер өлешендә тәрәзә өлгесенә кереп тула. Әнә шундый дымлы, тылсымлы, тансык бер кич иде ул.

Әни сөйли... Мин яңадан тугандай булам!

Әти сөйли... Мин яшеннәр уртасына килеп керәм!

Юк, яшен уклары мине куркытмый, бары тик тирә-ягымдагы кайнарлыктан бөтен тәнем кыза, чәч төпләрем сәер кытыклана башлый. Балачакта тыңлап үскән әкиятләрем кинәт кечерәеп, юашланып кала. Әти белән әни миңа әкиятләрдән мең тапкыр гыйбрәтлерәк, дөресрәк булган чын хикәят сөйли, турыдан-туры минем язмышыма кагылышлы хакыйкатьне — ничә еллар түкми-чәчми яшереп саклаган йөрәк серләрен минем хөкемгә тапшыралар.

Унҗиде яшемә кадәр белми йөргәнмен...

Бер уйласаң — кеше ышанмаслык хәлләр, үткәннәрдә йомылып калган хатирә. Икенче уйласаң — берниндн сере булмаган ап-ачык дөреслек.

Бөек серем минем! Усал сүзләрдән, гайбәтчел карашлардан саклау өчен мин дә сине вакытлыча күңел төбенә салып куйдым, карлы-буранлы көннәрдә йөрәгемә кысып җылыттым, җәйге чиләдә эсседән ышыкладым. Һай, авыр икән сер саклаулары! Тунгус метеориты үзендәге серне, әйдә, килер көннәргә саклый бирсен. Мин исә һич тә тел кычытканнан түгел, үземнең зиһенем, тәҗрибәм белән ирешкән күңел хәзинәсен кем беләндер уртаклашасы килгәнгә күрә, әлеге серемне Зөлфирәгә сөйләргә тиеш!

Тамбурда басып торам.

Поезд хыял кебек томырылып алга чаба...

Рельслар хәтер сыман тын гына артка йөгерә...

## Хәтерләү

Мин кояшлы язгы көннәрнең берсендә туганмын. Ничек, ни өчен туганмын — шуны ачыкларга тырышуымның беренче тәҗрибәсе буларак, елап та җибәргәнмен. Гадәттәгечә, көн арты көн туган, язлар саен ярыша-ярыша сыерчыклар сайраган һәм мин, камыт аякларымны эшкә җигеп, тәпи йөреп киткәнмен. Кызганычка каршы, мин боларның берсен дә хәтерләмим...

Балачагым якты булып истә калган. Хәтердә калганнар буенча мине иң нык гаҗәпләндергәне кояш иде. Ул — җылы, көләч, якты, серле! Тәрәзә пыяласы аша ансат кына сикереп керә дә өстәлгә, өстәл өстендәге чәйнеккә, буяулы идәннән стенадагы көзгебезгә күчә. Урамга чыккач, мин аның кул җитмәслек биеклектә эленеп торуын аңлыйм, үҗәтләнеп өскә текәләм. Озаклап, бик-бик тырышып караганның соңында кояш нурларының һәр җебен аермачык күрә башлыйм. Тирә-якка туп-туры сызылып киткән алтынсу-көмеш җепләр. Кызлар чәчен тарткан кебек чеметеп кенә тотып карыйсы иде үзләрен. Ярамый, әнә ничек ягымлы, дусларча елмая бит ул, дәшә, үзенә чакыра! Тик анда кадәр менәрлек баскычны минем әле очратканым юк. Тотам да ишегалды бакчасына керәм, сары чуклы көнбагыш пәрәмәченә сарылам — аңардан кояш исе килә кебек.

Әнә шулай акрынлап табигать, кешеләр, тирә-юнь минем тормышыма килеп керде. Яфраклар лепердәвен әйткән дә юк, якадан кереп күлмәк изүеннән шуып чыккан җилләрнең дә миңа ниндидер әйтер сүзе бар кебек.

Табигатьтәге һәр аваз, һәрбер хәрәкәт мине ымсындыра, магнит сыман үзенә тарта. Бал кортларының безелдәвен, башаклар сөйләшен тын да алмый тыңлыйм. Шулай итеп, үзем генә белгән тылсымлы дөньям барлыкка килде. Мин биредә үзем теләгәнчә яшим, йөрим, гаҗәпләнергә өйрәнәм, моңсулыкның ни икәнен дә белмичә рәхәт көннәр кичерәм.

Минем яраткан тау башым бар. Шунда күтәрелдемме, кояшка һәм болытларга күпмедер якынайган кебек булам. Зәңгәр күк биләмәсендә болытлар сөзешә. Болыт күләгәсе, тау бите буйлап тын гына үрмәләп килә-килә дә, миңа — чирәм өстендә чалкан яткан малайга җиңелчә генә килеп кагыла. Мин аны, ул мине кыерсытмый: безнең арада тулысынча хөрлек, туганлык! Ә менә самолет күләгәсен күрсәгез икән — кайдандыр кыйгачлап кына килеп чыга да «ә» дигәнче югалып та өлгерә. Болары — минем патшалыкта гына була торган маҗаралар.

Биш-ун адым атласаң, аяк төбеңнән генә иген кыры башлана. Гүя ул, сыек яшел ташкын булып офыккача җәелгән дә, түгелеп китүеннән курыккандай, тау башында үзен-үзе тыеп, тукталып калган. Иген кыры артында зәңгәрләнеп калын урман күренә. Ә менә урманнан соң нәрсә башлана? Алга таба тагын ниләр бар анда? Минем әле бу сорауларга төшем үтми иде.

Төш вакытында әни медпунктын бикли дә өйгә кайта. Кояшны яратуым юкка түгел шул: елмайган-көлгән вакытта әнием һәрвакыт кояшка охшап кала. Ә менә этине... этине кемгә, нәрсәгә охшатырга соң? Ике дә уйлап торасы юк, имәнгә охшаган ул! Көчле, таза, каты куллы. Өстәвенә, урманчылар кия торган яшел путалы фуражкасына да көмеш билге — пар-пар имән яфрагы беркетелгән. Җәйләрен, бигрәк тә печән өсте чорында, соңарып кайта. Мич буена элгән кожаныннан абага, ылыс һәм тагын әллә күпме хуш исләрне үзенә җыйган урман исе аңкый. Аның белән бергә өебезгә ниндидер нур, җылылык, шатлык керpermanent тулуын тоя идем мин. Әни дә аның тирәсендә йөгергәләп кенә йөри, беләгендә — этигә диган чуклы сөлге. Этинең бер тезендә — мин, икенчесендә — сеңелем Фәридә. Дүртәр нәни беләк белән кояшта каралган муенына сарылабыз.

Өстәлгә самавыр менеп кунаклый, әнкәй үзенә генә хас салмак, ипле хәрәкәтләр белән аш бүлә. Кайнар аштан соң эти белән әни тирли-тирли, чынаяк тәлинкәсенә өрә-өрә тәмләп чәй эчәләр. Тирләргә әллә вакыт юк, әллә инде зурларча итеп эчүнең рәтен белмибез — безнең авыз тирәсенә бары варенье эзләре генә йогып кала...

Этинең үзенә беркетелгән тимеркүк аты бар. Озын торыклы, шома сыртлы, зур һәм хәрәкәтчән колаклары тимерче кайчысыдай уйнаклап тора. Горур муен тирәсенә елышкан чем-кара ялы — пар канат. Шундый ансат, җиңел, сыгылмалы җилдерә ул, ахры, әнә шул канатлары ярдәм итә аңарга. Мин уянып чыкканчы, гадәттә, эти атын җигеп өлгергән була. Куштанлыгын тамчы да яшермичә, арба тирәсендә Сарбай бөтерелә. Әнә шул куштанлыгын өнәп бетермим мин аның. Этләргә акыллы, җитди булу килешәрәк төшә (чик буе заставасындагы овчаркаларны нәкъ менә шуның өчен яраттым да инде мин).

Ярый, эт этлеген итәр ди, минем бит әле дүрт аяклы икенче бер ахирәтем дә бар. Көмештәй аваз белән кешнәп җибәрдеме, күктәге фәрештәләргә чаклы очып барган җиреннән тукталадыр. «Бусы тагын нинди могҗиза?» — дип аптырашалар бугай. Сүз дә юк, колыныбыз бик чибәр: аяклары талчыбыктай нәфис, көмеш йоннары җем-җем килеп тора. Ялы юк әле югын, әмма муен сыртындагы буйдан-буйга сызылган кара бөдрә дулкыны кызыктыра да соң. Их, бер генә тапкыр сыйпап карыйсы иде үзен! Юк, тоттырырга уйламый да колын. Бәлки, шулай үзенә тиз генә якын җибәрмәве, баш бирергә теләмәве белән мине үзенә караткандыр да ул.

Эти ни өчен урманга китеп югала, көнозын анда ниләр эшли — мин әле ул чакта боларны анык кына белми идем. Урман егу, делянка чистарту, питомникта чыршы кәлшәләре үстерү, печән заданиесен үтәү кебек эшләр минем «катнашымнан» башка да бик әйбәт барган. Этинең теленнән «контора» диган ят сүзне ишеткән саен ике катлы бу агач йортның кайдадыр еракта, урман артында булуын чамалый идем.

Алты-җиде яшьлек вакытымда эти мине атына утыртып урманга алып менде. Арба төбенә калын итеп печән, печән өстенә брезент җәелгән. Машина утыргычыннан бер дә ким түгел: чокыр-чакырлы урыннарда җай гына селкетеп тә ала, изрәп китмәгез, янәсе. Мондый чакта йоклап китсәң, йөрәксез, җансыз, туң бавырлы диярләр. Күккә ашкан карт чыршының толымнары оеп калган. Менә югарыдан арба уртасына озынча күркә сикереп төшә. Тиен ыргытты микән аны, әллә урмандагы агачларның мине шулай күчтәнәч белән каршылавымы? Ул да түгел, куелык арасыннан күке кычкырганы ишетелә, колак төбеннән выжылдап төклетура уза. Ерактан караганда тын гына утырган урман эчкәре кергән саен гүли, кайный, рәхәт бер шом белән күңелгә саркып керә. Әгәр янымда эти

булмаса, мин биредә мәңгелеккә адашып калырмын төсле. Менә ул яратып жырлый торган жырын үзалдына көйли башлады:

Урман эчләрендә урман,
Керсәм чыгалмам инде...

Кинәт якында гына ниндидер кошның җан ачысы белән чыр-чу килгәне ишетелде. Әти каеш дилбегәсен ат сыртына ташлады да, әйдә дигәнне аңлатып, миңа сүзсез генә ым какты. Елгыр адымнар белән артыннан көчкә өлгерәм. Кечерәк алан читендә, чыннан да, йодрык чаклы бер чуар кош бәргәләнә, куаклыкка таба атылып бара да канатларын җәя-җәя ачыргаланып кире чигенә. «Ни хәл бу?» — дип гаҗәпләнүем кая, әти кулындагы кыска чыбыркысы белән куаклык төбен кыйный башлады. Бер, ике... тагын әллә ничә тапкыр сукты, ярсып-ярсып селтәнде. Мин аңламаган бер-бер хәтәр эш бар монда, күрәсең. Бераздан, чыбыркы сабына эләктереп, әти ниндидер кара тасманы җирдән күтәрде. Минем беренче тапкыр чын елан күрүем иде, куркудан тәннәрем чымырдап китте.

— Курыкма,— диде әти,— ул инде терелерлек хәлдә түгел. Чарасына күрә җәзасы.

Менә ничек: еланнар хәтта кош оясына да һөҗүм итәләр икән. Кәүсәгә чорналып менә-менә дә, берәм-берәм балаларын тотып ашый... Мондый явызлыкны мин дә гафу итә алмыйм, еланны үтереп дөрес эшләгәнбез.

Әтием үзебез коткарган кош оясын да күрсәтте әле, тик озак юанырга кушмады, юкса кеше кулы тигәннән соң кайбер кошлар оясыннан бизенә икән. Әнә бит, элеккечә үк чырылдамаса да, хәвефләнеп һаман безнең тирәдә бөтерелә, очына. Балаларын ятим итәр хәл юк, калдырып киттек ояны. Сары томшыклы, йоны чыгарга да өлгермәгән гөнаһсыз сабыйларны коткару вакыйгасыннан соң мин көчсезләрне һәрвакыт якларга кирәклегенә төшендем шикелле.

Тагын бер урында — бу юлы инде чәчәкле, җиләкле, күбәләкле аланда тукталуыбызны яхшы хәтерлим. Бераздан тимеркүк атыбызга кигәвеннәр өере ябырылды. Рәхимсез кыланалар, берничәсе күлмәк-ыштан аркылы мине дә тешләргә маташты. Яфраклы чыбык белән мин кигәвеннәр

куган арада әти арба башыннан яшел бөкеле шешә тартып чыгарды. Май сөрткән урынга, гадәттә, чебен-черки җыелучан. Кигәвен халкы бөтенләй башка икән — әти ат сыртына, дуга, дилбегә-дирбияләргә шешәдәге карасу сыекчаны сөрткән иде, син күр дә мин күр, тегеләр шайтан ялагандай юкка чыктылар.

Чү, кырмыска оясы! Менә монысы минем өчен сагындырган яңалык... Ылыс-бүрәнәләрне аркылы-торкылы өйгәннәр дә менә дигән йорт салып куйганнар. Андагы хәрәкәт, андагы ыгы-зыгы! Һәм иң мәзәге шул:

кырмыскаларның кайсы кем икәнен һич кенә аерырлык түгел. Әгәр кешеләр дә шулай бер-берсенә тамчы судай охшаса, никадәр күңелсез буласы, ә? Мәсәлән, мин әтиемә бөтенләй охшамаганмын: зур күзле, курнос борынлы, керпе чәчле. Әтидә, киресенчә, кысынкырак күзләр, озынча борын, дулкынлы чәч. Безне берничек тә бутап булмый. Шулай да мин — уйнау, йөгерү, әнигә булышу дисеңме — әтигә охшарга бик тырышам. Кибеткә барасы булса бигрәк тә...

Беркөн шулай күн сумка эләктереп кибеткә ипигә киттем. Өч йорт аша гына күршем — Дамир да килгән. Кайтышлый кибет буендагы тыкрыкта малайлар белән мәш килеп «сукыр кәҗәле» уйнадык. Тәртибе бик гади:

түгәрәкләнеп басасың, уртадагы төп уенчының кемнедер куып тотканчыга кадәр күзләре бәйле була... Җитәр, һәркайсыбызга өлеш чыкты, кузгалырга кирәк. Ипи салынган сумкамны күтәреп кайта-кайта тәмам хәлдән тайдым бу юлы, сулышым тамагыма капты. Хәлдән тайганчы уйнагангамы,

ай-һай; авыр бүген сумкабыз... Моның сәбәбен баскыч төбенә кайтып утыргач кына аңладым. Минем күзләр бәйле чакта Дамир этлек эшләгән — сумкама кирпеч яшереп өлгергән икән! Сумкадан чыккан кирпечне ачу белән кычытканнар арасына атып бәрдем. Кем өйрәткәндер, Дамирның шулай еш кына астыртын, мәкерле бер эш эшли торган гадәте бар.

...Шулчак үлән арасына иелә төшкән әти үзенә чакырып алды. Барсам — анда ак тәнле, уттай янып торган кызыл эшләпәсенә ак бөрчекләр төшерелгән бер гөмбә кукыраеп утыра. Алдавыч матурлыкка төренеп яшәүче бу нәрсәкәй чебен гөмбәсе икән. Агулы, ашарга ярамый.

Әти әйтә, пошилар аны чир-мазардан саклану өчен ялмап кына йоталар, ди. Кызыл кепкадан йөргән Дамирны ирексездән чебен гөмбәсенә охшатып куйдым. Пошилар аны урманда күрсә, авыз пычратып тормаслар, мөгаен, тармаклы мөгезләренә эләктереп агач башына гына чөярләр... Урман тикле урманда әкәмәт хәлләр булмас дисеңмени!

Печәннәр һәм куаклык арасында айканып йөри торгач, әти эзләгәнен тапты бугай — шатлыгыннан кулын-кулга сугып алды. Куак саен текәлә-текәлә менә нәрсә эзләгән икән ул! Гап-гади миләш, урман миләше...

Нәкъ минем буе, борчак кузагыдай озынча яфраклары кытай җилпәзәсен хәтерләтә. Миңа да ошый бу миләш, бик ошый, тик менә чикләвек куаклары янында кысанрак бугай аңа.

— Һәркем үз гомерендә бер агач утыртырга тиеш, улым. Агачы әйбәт, урыны җайсыз. Әйдә, иң яхшысы — без аны түр бакчага апкайтып утыртыйк. Ул синең миләшең булыр...

Кич якынлашып килә иде. Төбенә юеш чүпрәк куелган чиләккә салдык та алып кайттык миләшне. Тамырларында укмашкан килеш, бүрек чаклы урман туфрагы да ияреп төште авылга.

Минем үз гомеремдә беренче тапкыр агач утыртуым иде бу. Икенче көнне дә нindидер зур эш эшләгәндәй дәртләнеп, канатланып йөрдем, шиңә күрмәсен дип сулар сиптем. Бәхеткә каршы, миләшем тернәкләнеп, матур гына үсеп китте. Әмма миңа аны киләчәктә дә тәрбияләү, иң беренче тәлгәшләреннән авыз итү ләззәте насыйп булмаган икән...

Болары тора-бара аңлашылыр, ә хәзер сеңелем белән әни янына баруыбыз турында сөйлисем килә. Медпункт — аргы як урамында. Икәү бергә чакта авылда безне «Фәрит-Фәридә» дип йөртәләр. Җитәкләшеп медпункт йортына барып кердек. Әни үзе генә иде, нишләп йөрисез болай, дип орышмакчы итенә. Күреп, сизеп торабыз: ачуланып әйткән сүзләре иркәләү булып яңгырый. Аркабыздан сөеп тә җибәргәч, кыюлана төшәбез, бер-бер артлы сораулар яудырабыз.

Килеп кергәч тә әниемнең ак халаты, түр яктагы ак чаршаулар, биредәге пөхтәлек күземне чагылдырган иде. Иялнә төштем бугай. Пыяла шкаф эчендәге шешәле һәм кабы-кабы белән торган даруларга, укол энәләренә күзем төшә. Укол дигәнең, ай-һай, зәһәр дә соң — шөпшәдән ким түгел! Кайчак өйдә әниемнән дә аңкый торган ят һәм таныш исләр борынны кытыклый. Безне иң нык кызыктырганы — борчак тикле генә сары витаминнар...

Тик эшебез витаминга кадәр барып җитмәде. Сагаеп, юашланып калдык: тышта каты-каты сөйләшкән, аяк дөбердәткән тавышлар ишетелә иде. Ул арада төбенә кадәр ачылган ишектән бүлмәгә өч ир кеше шаулап килеп керде. Без куркудан бер почмакка сеңдек: уртадагы абыйның кулы тоташ кан эчендә! Өлкәнрәк агайның: «Салган баштан ярамый шул...» —

дия-дия уфтануы, кемнедер эрләве безне тагын да шүрләтебрәк җибәрде. Кем салган, нәрсә салган — монысы безгә караңгы иде.

Әни ниндидер дарулар сөртә-сөртә яралы абыйның кулын бәйләде, кичекмәстән район больницасына озатырга кирәклеген әйтте. Сөйләшүләреннән шуны аңладык — бу абый электр пычкысында баш бармагын өздергән икән, кулъяулыкка төргән килеш кесәсендә ята. Эсселе-суыклы булып киттем, беләкләремә «каз тәне» чыкты. Сеңелем Фәридә еламсырый ук башлады:

— Әни-и, ул абыйга яңа бармак үсәчәкме?

Никадәр сабыр күренгән әниемне дә тетрәтеп, каушатып җибәрде бу сорау. Менә ул Фәридәне кулларына күтәрде, мине басып торган җиремнән кочаклап алды, аннары безгә түгел, олы кешеләргә җавап биргәндәй болай диде:

— Бармак кынамы соң... Бер киселгән икмәк тә кире ябышмый, балакайларым.

«...Киселгән икмәк кире ябышмый». Җиде яшемдә ишеткән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлар өчен миңа әле тагын ун ел, димәк, дөньяның агын һәм карасын аңлый башлавым, тормыш агачының төрле-төрле җимешләреннән авыз итүем кирәк булган.

Килер көннәрнең шулай һәрвакыт кояштан, яктылыктан торасына нык ышанганмын, күрәсең: мин һаман уйныйм, шаярам, болытларга утырып күкне гизәм. Ләкин бу озакка бармады. Бер-бер артлы диярлек булган ике вакыйга мине самими хисләрдән айнытып, сискәндереп җибәрде, балачагымның шәрран ачык бакчасына кемдер таш атты, авыр итекләр белән узып керде кебек.

Мин инде мәктәпкә йөри башлаган идем. Әле хәреф танып килгән генә чак, юньләп яза да белмибез. Ә менә рәсем ясарга безгә куш: буйыйсың, сызасың, тоташтырасың — менә дигән күренешләр килеп чыга. Мин үзебезнең өйне ясыйм. Өй янында бакча, челтәрле рәшәткәләр. Әти белән бергәләп утырткан миләшем инде зур үскән, түбә карнизларен узып киткән. Учлам-учлам яфраклар арасында тәлгәш-тәлгәш утлы миләшләр кабына. Әйдә, миләшемнән авыз итеп карасын — ботаклар арасына бер кызылтүш сурәте дә төшереп куям.

Ул көнне рәсем дәресендә беренче «биш»ле алдым!

Дамирга «дүрт»ле генә эләккән икән. Тәнәфестә миңа кырын-кырын карап куя, янымнан авызына су капкандай дәшми генә узып китә. Бер урам малайлары бит югыйсә, ә ул күрәләтә читләшә, бүтәннәр тирәсендә кайнаша. Бик исем китте ди, яңа дусларны мин дә табам аны!

Озын тәнәфес иде. Рәшәткәгә сөяләп кенә кештер-кештер кыяр кимерәм. Түзмәде, туң күз Дамир яныма атылып килде. Күзләрен челт-мелт йомып: «Кыяр ашат әле, малай»,— дигән була. Ачы җире, төбе генә калган кыяр кисәгеи нишләтергә белми бер кулдан икенчесенә күчереп йөртәм. Бирсәң — үземнең калдыкны каптыру шикеллерәк, бирмәсәң — «саран, саран» дип дөньяны сасытачак. Икеләнүемне җиңәргә дә өлгермәдем, Дамирның чырае сытылып килде. Күрәм, усак шырпысыдай кабынырга тора бу. Чыннан да, авызыннан ямьсез сүзләр сибә-сибә китеп бара:

— Саран... тәрмәче... тәрмәче малае!

Күр әле, мине нинди әшәке, нахак сүз белән үчекләргә маташа Дамир... Минем этиме? Безгә, әнигә, кешеләргә яхшылыктан бүтәнне эшләмәгән урманчы әтиемме? Күрсәтермен мин сиңа... Нинди гаделсез үртәшү! Хаксызга рәнҗетелүдән беренче тапкыр күз алларым караңгыланып калды. Дамир киткән, ләкин нәни йөрәгемдә зур җәрәхәт, гарьлек тамгасы калдырып киткән иде.

Дөреслегенә берничек ышанмасам да, бу сүз мине кай ягы беләндер куркыта, шикләндерә, шул ук вакытта кемгәдер барып әйтәсе килү теләгеи богаулап та тота иде. Дамирга — «чебен гөмбәсе»нә карата бераү дә сизмәслек итеп нидер кыласым, аның оятсызлыгыннан яшертен

генә үч аласым килә! Класска кердем. Менә Дамирның матур язу дәфтәре, кәкре-бөкре хәрефләрдән тезгән өй эше. Анда да «төрмәче» дип язылгандыр кебек. Парта өстендәге кара савытына үреләм... Бераздан кыйгачлы дәфтәр битендә кара кояшны хәтерләткән зур тап чекерәеп калды.

Укытучыбыз Тәнзилә апа өй эшләрен тикшергәндә мин энәләр өстендә утырдым кебек. Миңа — «биш»ле, Дамирга — «ике»ле. Я, дөресме инде бу? Күңел кыбырсына башлый, тел очына авыр сүзләр килеп бөялә, елыйсым килә... Юк, еларга да, сөйләргә дә ярамый миңа. Рәнҗүне дә, бүгенге шыксыз сүзләрне дә тирәнгә, бик тирәнгә чыга алмаслык итеп күмәргә кирәк — берәү дә белми, ишетми калсын. Мәгънәсез шаярту, аптыраганнан үчекләшү генә булгандыр ул...

Күмдем... Үзем дә сизмәстән, йөрәгемнең кайсыдыр бер почмагында яшерен кабер барлыкка килде. Инде онытылып бара дигәндә генә тиздән аны кабат ачтылар, ачтылар да җәрәхәтенә учлап-учлап тоз сиптеләр. Тормышны аңлар өчен җиде пот тоз ашарга кирәклеген аңлаткан фәлсәфә ташының беренче тозлары шул иде булса кирәк.

Вакыйганың икенчесе иске клубта кино карау хәлләре белән бәйле. Каяндыр тау башына күчереп салынган бу клуб иске булса да таза, халыкны нинди зур бәйрәмнәрдә дә үзенә рәхәтләнеп сыйдыра иде. Кичләрен сирәк-мирәк анда кино күрсәтелә, тик безнең іше вак балыкны кертмиләр. Ә киноны, яшерен-батырын түгел, карыйсыбыз бик тә килә. Клуб артында дөпе-дөпе эшләп утырган мотор тавышы безне кызыктыра, сихерли, әйтерсең, яшеренеп кенә караңгылыкта зур бер чикерткә сайрый. Бездән зуррак малайлар җәйләрен — өстәл астыннан, кышларын олыларның пәлтә итәгенә тагылып билетсыз гына качып кергәлиләр, имеш. Киномеханик Әүхәт абый бик усал, кырыс, ничә карасаң балавыз төсендәге сары мыегын чәйнәр, өчпочмаклы кашын сикертер. Андый кеше басып торганда, әлләлә, өстәл астыннан узулары сират күпере кичү белән бердер ул!

Көннәрнең берендә партадашым Сәйфүш белән без дә кинога качып керергә уйладык. Караңгы кич, кичке тынлыкны дөпелдәтеп Әүхәт абыйның тимер «чикерткә»се сайрый — димәк, кино башланган. Клубны иске дигән идем бит, без сәхнә якның җимерек тәрәзәсен сайладык. Такта кадаклап, пычкы чүбе тутырганнан соң да әле без сыярлык тишек калган анда. Иң өстәге ялганчы тактаны читкә этәрдем дә мәче җитезлеге белән эчкә, сәхнә култыгына шуып төштем. Черек агач, арба маена охшаш тагын нindидер исләр борынны томалады. Ялт — дустым Сәйфүш тә минем эзгә сикерде. Сәхнә тактасына тын гына сөялеп, чын әгәр, кино карыйбыз! Клуб тулы кеше, ә без монда — болындай иркен мәйданчыкта — нибары ике нәни тамашачы. Каршыбыздагы аксыл экраннан сәхнә уртасына нур коела, күләгәле хәрәкәтләр ява. Тоныгын тоныкк бераз, ләкин андагы сәер сурәтләр шактый ачык күренә. Әнә, экрандагы кешеләр без аңламаган телдә нидер сөйләшәләр, кулларын селти-селти каядыр клуб түшәменә төртеп күрсәтәләр... Әнә, безнең борын төбендә генә бомбалар шартлый, кызыл йолдызлы бер абый тәртә башыдай тырпаеп торган тупның тәгәрмәченә авып төшә. Колак төбендә генә яңгыраган дәһшәтле авазлардан идәнгә ныграк сеңәбез... Нәкъ шул минутта фашист тәресе'төшерелгән бер танк үкертеп сәхнәгә таба килә... Менә-менә экраннан сикереп төшәчәк тә икебезне берьюлы сытып узачак!

Шулвакыт экран караңгылыкка чумды, кемнәрдер сызгыра башлауга, залда ут кабынды. Берәү каты-каты басып сәхнәгә таба килә. Кем булыр бу? Сәйфүшнең тәрәзәгә ташлануын сизү белән мин дә корт чаккандай урынымнан сикереп тордым. Әмма соң иде, тәрәзәгә чумам дигәндә генә кемнеңдер келәшчәдәй куллары якамнан эләктереп алды. Әүхәт абый икән! Менә ул миңе бер сүз дә әйтми генә җилтерәтеп сәхнәнең арткы ишегенә алып килә. Келәне чылтыратып ача да йомшак җиремә җиңелчә тибеп караңгылыкка озата. Мин аның теш арасыннан сыгып чыгарган зәһәрле сүзләрен генә ишетеп калам:

— Бүтән монда әзең булмасын, тәрмәче малае!

Чыклы үләнгә яткан килеш җир тырмап еладым да еладым. Сентябрьнең салкын чыклары кайнар күз яшьләрем белән кушылган чакта кем мине аңлый һәм юата ала иде соң? Биек-биектә чекерәеп йолдызлар яна, әнә, арадан иң зурысы, иң яктысы мине үз янына — төпсез караңгылык чоңгылына чакыра. Эх, күккә ашасы иде дә куәт җыеп үсеп кайтканнан соң Әүхәт абый, Дамир кебекләрнең борынына чиртәсе иде бер!

Икенче мәртәбә инде мине шул котсыз, яман сүз белән гаделсез рәвештә мәсхәрә итәләр. Без, малайлар, үзара үртәшкәндә әллә нинди кушаматлар, үчекләү сүзләре әйтеп ташлыйбыз. Бу исә бөтенләй башка нәрсә, чалтыратып яңакка сугудан да хәтәррәк эш.

Ышанасы килми, шулай да эчкә боз кебек салкын шом, шикләнү үрмәли. Әүхәт абый бала-чага түгел бит, аның ысылдап әйткән сүзләре артында ниндидер табышмак, мин белмәгән яшерен мәгънә бардыр, бәлки? Берни дә аңышмыйм, тыкрык буенда каралып күренгән кычытканнар өскә килә кебек... Юк, артымнан ыргытылган теге пычрак сүзне эти белән әнигә ничек тә әйтмәскә, дәшми калырга кирәк. Ялгыш ычкындырдыңмы — бердәнбер әтиеңне үз телләрең белән гаепләү, аны тамчы да хөрмәт итмәү, димәк, урамда ишеткән телә сә нинди алама сүзгә ышану килеп чыгачак.

Капка келәсен күтәргәндә йөрәктәге яшерен кабер кыймылдап куйды шикелле...

Әти белән әни ни турындадыр сөйләшә иделәр. Әнинең «ярамый» дигән сүзе түшәмдә эленеп калды. Мине күргәч тә ник шулай кинәт туктап, үзгәреп калдылар? Нәрсә ярамый, ни өчен ярамый... Киноға баруым турында әйтүләреме, яисә бөтенләй башка нәрсәме? Әнинең күзләрендә яшь бөртеге җемелди, әллә ул инде минем белән булган хәлләрне белеп өлгерде микән? Әти генә тыныч күренә, сынаулы карашын миңа төбәгән: ниләр майтардың, янәсе...

Минем хәлне күрсәгез икән: үзем калтыранам, үземнең киемнәрем юеш, иң куркытканы — костюмның алды дегеткә буялган. Киноға качып керүче малайларны тану өчен киномеханик Әүхәт абый тәрәзә тактасына сылаган икән аны...

Әни карап-карап торганнан соң тирги башламакчы иде, әти күрәләтә яклап калды:

— Житте, әнисе, беренчесе һәм соңгысы дип ышаныйк. Әгәр тагын шулай буялып кайта икән, мин аның белән икенче төрле сөйләшермен.

Орышмый-нитми генә әти миңа яхшы сабак бирде. Икенче төрле сөйләшергә урын калдырам мы соң! Бетте, моннан соң рөхсәтсез кинога йөрү юк, өс-башны буяп кайтулар да клуб чирәмендә бөтенләйгә ятып калды...

Әнинең күз төпләрен сөрткәләп аш бүлүендә, әтинең килеш-килбәте һәм хәрәкәтләрендә ниндидер үзгәреш, киеренкелек сизәм. Өй эченә сәер бер моңсулык, басынкылык иңгән. Бу моңсулык әнинең күзләреннән таралгандыр шикелле. Әтинең кашлары исә сорау билгеседәй бөгәрләнеп килгән. Ул, калын бармакларын өстәл өстендә биеткәләп, өйдәге сәер тынлыкны күпмедер артка чигерә. Бармакларын биетүе — бүген-иртәгә башкарачак эше, мәшәкатьләре турында уйлану, фикер туплау дигән сүз. Нәрсә уйлый ул?

Сеңелем Фәридә генә әллә кайчан мендәренә чумган. Минем дә йокы килә, йокы... Күзләрем йомыла, беләкләрем бушап, иркенәеп кала, тик йоклап киттем дигәндә генә кинәт баягы шом тәнемә үрмәли башлый. Аяктан күтәрелеп менә-менә дә гәүдәмне мыштым гына кармаларга тотына. Юрганыма ныграк елышам, бәлки, калын юрган аша тиз генә үтеп керә алмас ул.

Нидер пышын-пышын килә. Корулы чаршау артында әти белән әнинең шыпырт кына сөйләшкән авазлары лабаса. Нигә йокламый икән алар, кичәгенәк тә шулайрак сөйләшенеп яттылар...

Йокы аралаш сизәм: чыннан да, чаршау артындагы пышылдаулар, өзек-өзек ишетелгән сүзләр һәм өй эченә кереп тулган төнге караңгылык артында ниндидер билгесезлек, яшертенлек посып ята. Бәлки, миңа боларны белү кирәк тә түгелдер, бәлки, ул олыларга гына аңлаешлы, безнең өчен кызыксыз булган четерекле нәрсәкәйдер? Бәлки...

Башкасын уйларга вакыт калмый, күзләрем салмак кына йомылып төшә. Аннары инде мин «төш» дип аталган башка дөньяга күчәм... Киномеханик Әүхәт абыйның кесәләре тулы солидол — арба мае икән. Менә ул шуны кулы белән көрәп-көрәп ала да чәпелдәтеп клубның тәрәзә төбенә сылый. Тәрәзә тишеге томалангач, шаркылдап көлеп җибәрә... Их син, Әүхәт абый, биш тиенлек акча өчен биш сумлык арба маен әрәм итәсең ич!

... Шикләнүләрем дөрескә чыкты: тиздән без каядыр еракка — безнеке шикелле үк урманы, кечкенә таулары булган икенче авылга күчеп килдек. Кечерәк кенә совхоз үзәге икән бу. Биредә кеш, төлке, тагын әллә ничә төрле кыргый җәнлекләр үстерелә. Нәрсә өчен икәнен әти аңлатып бирде: аларның затлы тиреләре яка, хатын-кыз бүреге тегү өчен тотыла икән. Әйтәм аны биредәге чибәр-чибәр апаларның һәркайсында диярлек көяз бүрек тә, елкылдап торган яка. Яканың җәнлек тиресеннән эшләнүен моңа кадәр уйлап та караган юк иде. Менә бит яңа җирләргә күчеп китүнең файдасы — күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңалыклар белән танышасың!

Яңа урында яңа дуслар таптым, ике катлы таш мәктәпкә йөри башладым. Иң куандырганы шул: мине биредә нахак сүзләр әйтеп үчекләүче, җанга кагылучы юк. Рәхәт, күңелле! Әти белән әнинең дә йөзендә тормыштан канәгатьлек билгесе балкый.

Йөрәктәге нәни җәрәхәтем агач куышыдай йомылып, йозакланып килде. Минем өчен тагын якты көннәр башланды.

## Әнинең сөйләгәннәре

Беләсеңме, улым, минем дә яшь-яшь чакларым бар иде.

Врачлыкка укып йөргән көннәрем — кичәге кебек кенә. Без, медицина училищесы кызлары, шау-гөр килеп һәм очынып, шәһәр урамыннан атлыйбыз. Машиналарның выжлап узуы, чәчәк токтан парлар, коляска тирбәтүче аналар дисеңме — алар һәммәсе дә безне котлый кебек. Ә котларга сәбәп зур: бүген без кулга медсестра таныклыгы алдык. Сөйләшүебез дә шул хакта гына:

— Мин туган авылыма кайтам!

— Мин шәһәрдә калам.

— Кызлар, беләсезме, ә мин чирәм җирләргә китәм...

Ай-яй еракка икән, дип иптәш кызларым гаҗәпләнеп миңа карадылар. Әйткән сүзем нык иде — комсомол чакыруы буенча, чыннан да, чирәм җирләргә киттем. Андагы киңлек, андагы батырлыклар! Күз алдыңа китер: урыны-урыны белән иллешәр чакрымга сузылган басуларда иген дәрьясы чайкала. Бу хәлне беренче кат күргәндә сокланудан күзләремә, валлаһи, яшь килде.

Вагоннар шәһәрчеге урынында инде станицалар калкып килә иде. Эшкә урнаштым. Шулай акрынлап кешеләр һәм аларның хезмәте белән таныша башладым.

Мондагы халык җир җимертеп эшли дә, ут чыгарып бии дә белә иде. Күбебез — яшьләр. Кичләрен чирәм җир клубына җыйналабыз. Анда — җыр, гармун, уен-көлке. Синең булачак әтиең, ягъни Рафаэль исемле егет белән шунда таныштым. Кай ягы беләндер үзенә каратты ул. Оста һәм акыллы сөйләшә, күңелгә ятышлы тәмле сүзләрен тыңлавы үзе бер рәхәт. Дөньяга карата үз фикере, ныклы карашы бар. Хуҗалык базасында эшләгән кешегә шулай тапкыр сүзле, кыю фикерле булу кирәктер дә, бер уйласаң.

Икенче елыма китте дигәндә без өйләнештек. Рафаэль анда да үз сүзләрен алга сөрде, икеләнергә урын калдырмаслык итеп кат-кат әйтте:

— Язылышу үзе үк искелек. Бу — бер-береңә ышанмау, ике кеше арасындагы табигый хисләрне җансыз кәгазьләр, ятлар алдына чыгарып салу. Әйдә, акыллым, бүтәннәрне кабатламый гына яшәп күрсәтик әле бер...

Арба күчәрсез булмый, яшьлек юләрсез булмый, дигән бит борынгылар. Инсафлы яшьлегем, беркатлылыгым белән ышанганмын, күрәсең.

Аннары син дөньяга килдең. Әтиеңнең сөенгәннәре! Дусларын җыйды, берничә көн рәттән «тәпи юдылар». Гомер эчендә бер була торган хәл бит, сүз әйтмәдем, юк вакытымны бар итеп кунакларга табын әзерләдем. Күз тия күрмәсен, имеш — сине кеше-кара күзеннән сакларга тырышам. Караган берсе әтиеңә охшаталар үзеңне. Сайландык-сайландык, аннары тоттык та Фәрит дип исем куштык сиңа.

Әтиең икебезгә дә игътибарлы иде. Тавык чүпләп бетермәслек эшләремнең күбесен ул башкара, булыша, кибеттән ашамлыклар ташый. Сине — юргандагы баланы күтәреп саф һавага чыкканнан соң да шат елмаеп, горурланып кайтып керә. Алда безне өр-яңа шатлыклар, телең ачылгач та әйтәчәк «әттә», «әннә» дигән беренче сүзләрең көтеп тора иде. Син инде биләүдән кулларыңны чыгара башладың, бармак бите белән иягеңә кагылганда чак-чак елмаеп куясың. Имезлек суыруларыңны күргән саен йөрәгем рәхәт кысылып куя. Ана булуның зур бәхет, сәгадәт икәнен беренче кат шунда тойдым — карап торган куанычым, киләчәгем син идең.

Ләкин тора-бара әтиең кинәт кенә үзгәрде дә куйды. Ул бөтенләй башка кешегә — хөрлектә яшәргә яратучы, соңарып кайтуны чүпкә дә санамаучы, гаилә эшләреннән азат булган ирекле «әти»гә әверелде. Эше дә алыш-биреш хәлләренә корылган иде, ешрак эчә башлады. Ялгышын аңлар, төзәлер дидем, синең хакыңа түзеп яшәдем.

Син гөнаһсыз бер сабый идең, бәхеткә каршы, боларның берсен дә күрмәдең, белмәдең. Ах, урынсызга кыен ашаган, чарасыз калган чакларым...

Авырулар кайчак туп-туры өебезгә дә килгәли иде. Өйдәге аптечкамда һәммә нәрсә бар — бәйлисен бәйләп, әйтәсен әйтеп дигәндәй, андыйларга кулымнан килгән ярдәмне кызганмадым. Ир-егетләр килсә, әтиеңнең йөзен болыт баса. Тиктомалдан шикләнә, көнләшә башлады, хәтта бәйләнүдән дә тартынып тормый. Бәхетсезлеккә каршы дияргәме, уенчак сүзле әтиебезнең тәртибе дә «уенчак» булып чыкты. Җиткерделәр: үзләренең эшендәге бер яшь хатын җылысына ияләшкән икән ул. Ир бирмәк — җан бирмәк, дигәнне ишетеп белсәм дә, нигәдер исем китмәде, киресенчә, иркен сулап куйдым. Андый йөгәнсез ата белән беребезгә дә җан тынычлыгы килмәячәк бит.

Сине тапкан хөрмәткә әтиең кыйммәтле ваза бүләк иткән иде. Бәйләнә торгач, сәрхүшләнеп кайткан көннәренең берсендә ялгыш төшереп ватты шуны. Челпәрәмә килгән вазаны җәлләдем шул чакта, ни әйтсәң дә кадерле бүләк, якты истәлек иде бит. Хәзер уйлыйм: үзенең гаиләсен дә әнә шулай ваткан, җимергән ул.

Алга таба болай яшәп булмаслыгы көн кебек ачык. Станицадан икебезнең беребез — я ул, я мин бөтенләйгә чыгып китәргә тиеш идек. Кул кушырып утыру ярамый, ике елым тулганны да көтмәстән, йөрәксенеп чыгып киттем. Хәлемә керделәр булса кирәк, тимер юл станциясенә кадәр безне машина озата килде. Якты дөньяны күрүеңә нибары алты ай. Ак эчлекле юрганыңа сыймый башласаң, нәни иреннәреңә сөтле шешә каптырам. Әллә шул чактагы елауларың ата кешегә нәләт булды микән? Әтиең саубуллашырга да килмәде. Киселгән икмәк кире ябышмый дигәнне яхшы аңлаган, күрәсең. Күңелемә якын, язмышыма кырыс булган чирәм җирне калдырып китүебез. Бераз моңсу, бераз ямансу. Шул ук вакытта кимсетелүдән арыну, билгесез киләчәгемнең рәхим-шәфкатьле көннәренә

ышану хисе — бөтенесе берьюлы кушылып, җанымда рәшә күк уйный. Шофер егет, берничә урында машинасын туктатып, кабинада ялгызымны калдырды. Ялгызымны дию дөрес булыр микән? Минем янда бердәнберем, йөрәк җимешем — син бар бит әле! Әнә, күкрәк сөтемнең көче сиңа күчә, күзләреңә йокы ләззәте булып иңә...

Ниһаять, соры вокзал. Ыгы-зыгы. Тимер чыңы. Гудок тавышлары. Татарстанга, Әгерҗе якларына китәсе поездны белештем — биш сәгатьләп вакыт бар икән әле. Сине аулакта бер кат ашатып, көйләп алганнан соң касса тәрәзәсенә бастым да яшен суккан агачтай миңгерәүләнеп калдым: кул сумкасыннан акчаларымны урлаганнар! Көпә-көндез, бала имезгән арада... Почмакка борылып утыруымның файдасы тигән кесә каракларына. Инде нишләргә, ни хәл кылырга? Станицага кире кайту мөмкин эш түгел, туган якка китүләр дә өметсез. Үзем бер хәл, кулларымда имезлек суырудан бүтәнне белмәгән күкрәк баласы бар бит...

Җаныма урын табалмыйча перронда арлы-бирле йөренәм, чуалган уйларымның очына чыгарга телим. Күзләремне яшь пәрдәсе каплаган, күрәсең, бер урында кисәк абынып киттем. Шул вакыт ни булды дисеңме? Асфальт катысына аудык дигәндә без кинәт кемнеңдер көчле кулларына килеп эләктек. Сабый бала егыласы урынга фәрештәләр канатын җәеп тора, диләр бит, әллә, ходаем, безнең белән дә шундыйрак хәл булдымы? «Фәрештә» дигәнем исә кеше кыяфәтендәге таза гәүдәле яшь ир-егет иде: кысынкырак күзләр, озынча борын, дулкынланып торган чәч... Кырыс та, ягымлы да йөзен абайлагач, кайда икәнлегемне дә онытып, аның кулларында килеш үксеп җибәрдем...

Әнә шулай көтмәгәндә танышып киттек без аның белән. Беләсеңме, сине үз улы кебек итеп яратачак, безне ятимлек җилләреннән аралап калачак, синең өчен гомерлеккә әтиеңне алыштырачак кеше иде ул.

Поезд килеп җиткәнче без инде хәйран нәрсәләр турында сөйләшеп, аңлашып өлгердек. Купелы вагонда өчәү бергә кайттык. Ул сине уенчыкларың белән уйнатты, кулларына күтәрде. Син беренчесендә вагон тутырып елап җибәрдең. Беразданияләндең, беренче кат аңа елмаеп күрсәттең. Синең самими елмаюың безнең йөзләргә күчте. Аның бала җанлы, ярдәмчел, киң күңелле булуына таң калырлык иде. Бу кеше тормышның байтак михнәтләрен кичкәндер дип уйлау башыма да килми.

Шәһәрдә хәйран тоткарлану сәбәпле, туган авылыма бер атнадан гына кайтып төштек. Безнең гаилә инде бар яктан да тиешле документлар белән ныгытылган. Мин исә гайбәткә сүз калдырмаслык ышанычлы крепость уртасында идем: без — ир белән хатын, син — сөекле улыбыз. Кабул итегез безне, авылдашлар! Әтиебез сугыш ярасыннан үлгән иде, әнидән калган иске йортка аяк бастык. Менә бит ул кешесез йорт: ишек-тәрәзәләр ябулы, ишегалдын котырынып үлән баскан. Сине, әйберләрне чирәм өстенә куйдым да, сагындырган ишек тоткасына кагылдым. Шул тимер тоткада әнкәйнең кул җылысы сакланган шикелле. Әнкәй үлгән елны дөнья белән элемтәм, бәйләнешем өзелгән иде... Юк, өзелмәгән икән: ул җепләрне ак юрганда килеш син ялгыйсың һәм тәрәзәгә аркылы сугылган такталарны кубаручы әтиең дәвам итә.

Йортым — крепостем, диләр. Әгәр үзара җан тынычлыгы, гаилә татулыгы юк икән, мәрмәр ташлардан салынган булса да — андый йортның нигезе, тотанагы черек. Шалаш эчендә яшәп тә үзләрен бәхетле тоючылар бар бит ул.

Өйнең идән-түшәмнәрен юдык, чистарттык. Юган пәрдә-кашагаларны да элеп җибәргәч, өй эче нурланып китте. Таш чүлмәкләр юнәтеп, тәрәзә төбе саен гөл утырттым.

— Гөлләр кебек яшибез, әнисе!

Әтиең шулай дия-дия абзар-кура, киртә-коймаларны, йорт тирәсен яңартып чыкты. Үзенең күңел җылысы, кешелекле мөнәсәбәте, гадел

булуы, кыен хәлләрдә югалып калмавы белән гаиләбез нигезен дә ныгытты, какшамаслык итте ул.

Урман аръягына җәяү киткән жиреннән жигүле ат белән кайтты, ничек-ничек итеп эшкә урнашуын сөйләде. Мине дә эшем көтеп кенә торган икән — медсестра халаты һәм ак калфак кидем. Авыл сөте килеште үзеңә — үстең, зурайдың, тәпи йөреп киттең. Аяк очларына бастырып, әтиең иртә-кич саен «үчтеки» сикертер иде үзеңне. Аннары сиңа иптәшкә сеңелкәш алып кайттык. Пар килсен дип, үзебез теләгән тагын башка мәгънәләрне дә күздә тоткан хәлдә, Фәридә дип исем куштык. Шуңа исем киткән иде: кызы туганнан соң әтиең дә берни белмичә кибеттән бәллүр ваза алып кайтты. Бизәкләре ут янып торган нәфис савытта — урман чәчәкләре... Өстәл уртасына, әйтерсең, нәни салават күпере кунаклаган! Ана кешегә күп кирәкмени: өйдәге матурлыктан, шатлыктан башларым әйләнде шул чакта.

Күз тимәсен, икегез дә матур, таза, тату үстегез. Әтиегезнең миңа карый да ныграк сөенгәнен белсәгез икән! Атын ишегалдына кертеп тә тормастан, ул иң элек сезнең янга атылып керә. Урамда уйнаган чагыгыз булса, икегезне ике кулына күтәреп печән түшәлгән арбасына утырта. Кыр сумкасында һәрвакыт урман күчтәнәче — я сабаклы җиләк, я кишәнкәлә чикләвек булыр. Күркә, имән чикләвеге яисә агач ботагыннан төрле әкият геройларына охшатып уенчыклар да ясый ул. Әтиегез кулы кагылса, табигатьтәге әйберләр, әллә ниткән хикмәтләр белән баеп, хыялый бер сурәткә әверелә иде. Тәрәз төпләребез музейдан ким түгел. Гөл күләгәсе астына поскан сәер уенчыклар — сезнең иң яраткан дусларыгыз.

Шулай матур, күңелле яшәдек. Алдан ук хәстәрен күреп, сер пәрдәсен корып куйгач, безнең сикәлтәле язмышыбызны белүче, үткәннәребез хакында тел тибрәтеп сөйләүче юк иде. Әмма никадәр генә сакласаң да, үткәннәрне ашъяулыкка төйнәп куеп булмый икән. Әтиеңнең төрмәдә утырып чыгуын каяндыр белгәннәр. Йөземә бәреп әйтмиләр әйтүен, читләтеп кенә суктыручы, сорашучы барыбер табыла: кайда, ничек, ни өчен, янәсе... Әтиегезне авыл халкы ярата иде, гайбәткә санап күпләр моңа ышанмыйчарак карады, билгеле.

Шул көннәрдә авыл советы рәисе миңа чакыру җибәргән. Бардым. Гомер иткән, төрле хәлләрне башыннан кичкән кеше буларак, иплән кенә сорашырга, төпченергә кереште. Урман хуҗалыгының аларга буйсынмавын яхшы белгәнгә күрә, ачылып китмәдем. Бәлки, чакыртуы белән ул хаклыдыр да. Ләкин гаиләбезнең инде онытыла барган серенә шулай тыкшынулары ачуымны чыгарды. Утырып чыгуы хак, дидем, нинди сәбәпләр аркасында — анысын вәзенләп тормадым.

Әтиегездә бу кадәр дә сабырлыклар булса булыр икән! Кулын селти төшеп: «Адәм баласының бүгенгесе кыйммәт»,— диде дә тыныч кына эшли бирде. Тыштан сиздерми булай. Тик күрмимме соң — аның да эчендә ялкынсыз утлар яна, хәсрәтле уйлар кайный. Ни генә димә, гаиләбез өчен кыен һәм четерекле хәл иде бу.

Фәридә әле аңламаска мөмкин, иң курыкканыбыз — әлеге хәбәрнең сиңа барып ирешүе. Син бит инде дәрескә йөри башладың, беренче класс баласы. Иптәшләрең авызыннан шундый сүз ишетүең бик ихтимал иде. Андый көн озак көттермәде: бервакыт син мәктәбеңнән шактый үзгәреп, күңелсезләнеп кайттың. Кичен ашаганда сораулы кыяфәт белән вакытвакыт әтиең йөзенә төбәләсең, карашларыгыз очрашканда күзләреңне шыпырт кына аска яшерәсең. Без инде, әлбәттә, сиңа берни сиздермәскә, сүзне икенчегә борырга тырыштык.

Әйе, сине кемдер беренче кат рәнҗетүен чамаладык. Берни эшләр чара юк, берәүнең дә авызын йозаклап куя алмыйсың. Сизәм: гомер буе үртәлеп яшәү кыен булачак безгә. Барыннан да бигрәк сине урынсызга яралануудан саклап калырга кирәк — уемда шул гына. Үсеп җиткәч, һәм

мәсен дә белерсең, аңларсың әле, тик хәзергә берничек тә ярамый иде. Йокысыз төннәрдә без колактан колакка гына әнә шул хакта сөйләштек. Ниһаять, икенче бер ерак районга күчеп китәргә карар иттек.

Туган авылымда соңгы тапкыр таң аттыруыбыз иде бу.

Икенче көнне төйнисе әйберләрне төйнәп, җыясыларын җыйнап дигәндәй, машинага чыгардык. Тәрәзә төбендәге теге уенчыкларыгыз гына да үзе бер тартма булды. Кулыңдагы миләш яфракларын учлаган килеш син әлеге тартма янына чүгәләдең. Карыйм: кузгалыр чак җитәрәк кенә Әтиегез юкка чыкты. Лапас артындагы аран буенда таптана икән. Тимеркүк атын кочаклаган да елый-елый сөйләнә, бәгырькәем:

— Алты ел буе юлдашым булдың... Бәйләми китсәм дә ташлап качмадың... Рәхмәт, аякларың житез, колакларың сизгер иде. Сау бул, миннән соң да җәбер күрми рәхәт яшә, малкаем!

Ир кешенең елавын беренче кат күрүем иде, аптырап калдым. Тегесе, дөньяда хушлашу бар дигән нәрсә барлыгын аңлаган шикелле, моңсу кешнәү белән җавап кайтарды.

Киттек. Туган җиремнән бик-бик озакка, ә бәлки бөтенләйгә аерылуны сизепме, йөрәгем бәргәләнә башлады. Кулыңдагы кош баласын күз алдына китер: кысып тотсаң — зәгыйфьләнәчәк, бушата төшсәң — очып китәчәк, бит. Сезнең белән ерак сәфәргә чыкканда әнә шундыйрак халәттә идем мин.

Тагын юлга чыгам. Кулымда тагын бала. Тик бу юлы янәшәмдә Әтиегез бар...

## Әтинең сөйләгәннәре

Тормыш шулай, улым, ул тоташ актан яки карадан гына тормый. Декабрь уртасында да шыбырдатып яңгыр яварга мөмкин. Кайчак июнь атналарында да күбәләк кадәрле кар төшә...

Мин үзем Себер ягында туганмын. Татар авылында. Бабай бик гаярь кеше иде. Заманында ялангач кусәк белән берьюлы ике аюны алган. Ничә карасаң, шыңшып кына «Сибелә чәчәк» көен җырлар иде. Хәзер генә яхшы аңладым: сибелгән шул безнең халык, сибелгән...

Дию пәрие адашырлык тайгалар кочагында үстем. Кедр башларына үрмәләп, урман мәчесе житезлегенә өйрәндем. Ылыс энәсе түшәлгән сукмаклар аяк табанымны тупасландырды. Тайга нинди ул дисеңме? Куркынычлы һәм мавыктыргыч. Мәкерле һәм мәрхәмәтле. Тайга шавын кемнәрдер үтереп мактаган диңгез шавына берничек тә алыштыра алмадым мин.

Малай чакның юләрлеге диген: агачларга охшарга тырышып, кайчак ярты көн буе диярлек бер урында басып торам. Аякларым җиргә берегә, иңнәремә ябалдашлар үсеп чыга, хәтта башым тайгага охшатып шауларга ук тотына... Урман үзе дә миңа дуслык, юмартлык белән җавап кайтарды: кесәм тулы чикләвек, изүем тулы үлән, тырысым тулы гөмбә һәм саз җиләге булыр иде.

Үсеп җиткәч тә язмышымны тайгага бәйләдем. Махсус курслардан соң кулыма егерь, бездәгечә әйтсәк, урманчы таныклыгы тоттырдылар. Эшләп киттем шулай. Әнә, үзең күреп торасың: безнең совхозда кыргый җәнлекләрне затлы тиресе өчен читлектә махсус тәрбияләп үстерәләр. Ә анда, тайгада, берәүнең дә катнашы кирәкми — агач башында үзләре сикереп үсә алар. Эзләренә төшсәң — синеке. Менә шушы бушка килгән мал «озын берлек» яратучыларның күзен кызыктыра да инде. Әле тагын аю, поши, юлбарыс, кабан кебек эре хайваннарны да саный китсәкме... Никадәрле ит һәм кыйммәтле тире! Боларны рөхсәт белән, хөкүмәттән махсус таныклыгың булганда гына атарга ярый. Ягъни промысел аучыларына. Әнә, куплап нефть агыза торгач, хәтта океаннарда балык кимеде. Һәркем үзе теләгәнчә кылана, уңлы-суллы ата башласа, тайганы да шундыйрак язмыш көтәчәк бит.

Шулай берчак ашыгыч хәбәр китерделәр: пошилар еш йөри торган Чакматаш иңкүлегенә тагын сакаллы кешеләр килгән, яшел «Москвич» белән. Ниятем нык иде — кичекмәстән кузгалырга, браконьерларның кара сукмагына аркылы төшәргә!

Ярдәмчем Соболевны алдым да атка атланып сигез чакрым ераклыктагы иңкүлеккә юнәлдек. Соболев белән разведкага барып була, тәвәккәл, шактый тәҗрибәле егет, ат өстендә дә ләтчәдән ким йөрми — исең китәрлек!

— Яшка, алабызмы? — дидем.

— Алабыз! — дип җавап кайтарды юлдашым.

Болай кискен, үҗәтлек белән соравымның үзенә күрә сәбәбе бар. Узган ел җәй мин алар белән бер тапкыр очрашкан идем инде. Үземә беркетелгән биләмәләрне карап йөргән чакта. Каядыр якында гөрселдәп мылтык шартлады. Ау сезоны башланырга иртәрәк, димәк, «чакырылмаган кунаклар» эше бу. Ни өчен икәнен хәтерләмим, атсыз, мылтыксыз идем ул көнне. Куркәккә сугылган куакларны аралый-аралый шартлау авазына таба ашыгам. Чамалап бара торгач, өсләренә килеп чыктым мин боларның. Икесе дә сакалдан, яшь-яшь аю баласының тиресен тунап маташалар. Кулларында пычак булгангамы, миңа — ягъни фуражкасы янтайган, нык мышнаудан сүзләре өзек-өтек чыккан кешенең кычкырганына исләре китмәде боларның. Машина номерын карарга дип борылган идем, кайсыныңдыр көчле кизәнүе мине аяктан екты...

Аңга килсәм — хәл мөшкел! Җилкәмә ару гына киртәлек яткырып, кулларымны шуңарга бәйләп куйганнар! Картлар авызыннан бу вакыйганы ишеткәндә кычкырып көлгән идем бер, янәсе тузга язмаганны сөйләмәгез. Инде менә үземә шуны әзерләп куйганнар... Христианның агач тәрегә кадакланган Гайсәсе шикеллерәк мин, бары кулларымнан кан гына саркымый. Күзләрем дә бәйле булгангамы, тиз генә ышанасы килми. Шуңа күрә тегеләрне үгетләргә тырышып карыйм:

— Шаярмагыз, азагы күңелле бетмәс моның...

Дәшмиләр, танытудан шикләнәләр, ахры. Җавап урынына күзләремә бәйләнгән кара материяне чиштеләр. Әһә, мәйтәм, шаһит әйбер калдырудан шөлли болар, димәк, исәпләре — этлек эшләүдә. Ачу белән каерылып карамакчы булам! Кая ул, кулыма бәйләнгән киртәлек тамчы да ирек бирми. Капкынга эләккән җанвар сыман ни үкереп, ни боргаланып карадым — файдасыз. Сумалага капкан саескан акыятен хәтерлисеңме: борынын алса — койрыгы, койрыгын алса борыны ябыша икән. Минем дә эш шулайрак: киртәнең бер башына юл сапсам, икенче башы кәүсәләргә килеп эләгә. Бер генә дә борылыр әмәл юк, тәртеләм дә калам... тәртеләм дә калам...

Мин нишләргә тиеш идем соң?

Инде сәгатьтән артык вакыт узды булса кирәк. Кулларым, аякларым, бөтен гәүдәм талды. Утырып ял итәр идең, торалмый ятуың бар. Йомшаклыгымны сизеп алдылар: көтүе белән черки ябырылды. Аларны куркыту өчен башны туктаусыз чайкап торырга кирәк. Че Гевараның Боливия тауларында ничек йөргәнен укыганың бар бит. Черки талаудан гаҗиз булсалар да, ирекгәге җан бит алар. Ах, кемнеңдер мәрхәмәте белән кулларым чишелеп китсә икән дә, ирек ләззәтен комсызланып суласам икән!

Каршымда — кәүсәләр диңгезе, баш очымда күк белән тоташкан битараф яшеллек. Житте! Ачыклыкка мач китереп җен көчем белән киртәлекне каерам... Нечкә башы тәки шартлап сынды берзаман! Кул сузымы гына җирдә корыган чыршы ботагы. Таза, нык күренә. Кыска булуы исә бигрәк тә әйбәт, димәк, тиз генә сынып китмәячәк. Шуны комарланып эшкә җигәм, ышкыла-ышкыла бауны чишү исәбем. Аркамнан, маңгайлардан гөрләп тир ага, беләгемне көзән җыера...

Мең бәла белән котылдым, ниһаять! Шатлыктан җиргә ятып ауныйм, үлән тырный-тырный кулларымны язам. Ләкин бәләнең зуррагы алда көтеп торган икән. Күпмедер баргач каршыма әсәрләнгән, чыраеннан иман

нуры качкан аю килеп чыкмасынмы! Аның баласын бәхилләп йөр син, ә ул күзен дә йоммый ажгырып өстеңә килә! Янда корал да юк, таяк белән сугып үтерергә — ул бит сиңа чучка баласы түгел. Яшәү белән үлем арасында басып торам. Нишләргә? Яшен тизлегендә уйлап өлгердем: соңгы чараны кулланырга...

Бөтен игътибарым — аюның иләмсез итеп ачылган кызыл авызында. Сул кул белән ялган хәрәкәт ясадым да йодрыгымны бар көчкә кинәт бугазына батырдым...

Ялангач кул белән беренче тапкыр аюга каршы баруым иде бу. Кочаклашып ауганыбызны хәтерлим, үкерергә дә өлгерми калды теге. Бу инде җиңү иде! Тайга әзмәвере тончыгудан җан бирде. Нишлисең бит, үзе сорап алган үлеме иде ул аның.

Йодрыгымны сусыл үлән белән юдым. Уң беләгем канаган килеш кайтып керүгә, хутордагылар «аһ» иттеләр. Очраклы үтерелгән хайванны промыселга озаттык. Менә, күрәсеңме: беләгемдә — тайга төсе, аю теше эзләре...

Теге чакта менә шулай ычкынган иде ул сакалбайлар. Күрәләтә мыскыл итеп. Хәзер дә шулар килде микән, дип уйлыйм. Беткәнме сакаллы бәндәләр, бәлки, түгелдер. Кем генә булмасын — табигать дошманы алар, закон бозучылар. Бозганнар икән, закон каршында җавап та бирсеннәр.

Атларны юырта төшәбез. Алдыбызда Чакматаш иңкүлеге җәйрәп ята. Берзаман этебез алга бәреп чыкты, бездән артык ераклашмый шым гына бара бу. Атларның да колак шомартуында шул ук мәгънә: каядыр якында кешеләр бар!

Эзләренә төшүебез шушы иде. Күзләремә ышанмый торам: чыннан да, иске «танышларым» бит болар. Шул ук былтыргы сакал, искерә төшкән яшел «Москвич». Куллары кан, рөхсәтсез атылган поши итен багажникка тыгып маташулары. Бер читтәрәк суелган хайванның учарлы мөгезе, туңкаюлы башы, аяк-тояклары аунап ята. Агач ботагына эленгән кызгылт үпкә светофор утыдай янып тора. Әлеге канлы вакыйганы мизгел эчендә сөзеп чыктым. Бәхәссез: каршыбызда браконьерның кәттәләре басып тора. Мине таныдылармы-юкмы, әйтә алмыйм, мәгәр атлы, мылтыклы ике егерьны күргәч, баштарак шүрләп калдылар.

— Документларыгыз...

Сүземне әйтеп тә бетермәдем, болан тиресен ташлап икесе тиң шундук машина эченә чумдылар. Әһә, мәйтәм, тагын ычкынмакчылар! Юк инде, бу юлы сезне кулдан җибәрү — гомерлек үкенеч булачак. Ат белән куа бару — ахмаклык, иң яхшысы — тәгәрмәчләрен булса да сафтан чыгару. Аннары күз күрер...

Кузгалып киткән «Москвич»ның тәгәрмәчләренә төбәдем дә чакмага бастым. Утлы гөрселдәү... дары исе... туктап калган машина... Күрәчәгем булгандыр дим: тәгәрмәчкә дип аткан ядрәләрнең берсе шоферга тигән, шайтан алгыры!

Шулай итеп, җинаятькә каршы төшәм дип, бөтенләй уйламас җирдән үзем җинаятьчегә әверелдем.

Гаебемне берничек тә йола торган түгел. Суд булды. Дүрт ел бирделәр. Ныклы режим, тәртип каты... Мохит үзгәрде, ә күңел, күңел шул ук бит! Ике кулым бәйле килеш тайгада ничек интеккәнне хәтерлә. Биредә кулларым бәйсез, әмма күңелем богаулы иде минем. Күнегергә тырыштым. Төрмәдә дә халык төрле — бар әйбәте, бар яманы. Ялангач кул белән аюга каршы барганым өчен кубесе үз итәләр иде. Рязань мужигы белән дуслашып киттек, Иван дәдәй. Заманында урман кискән, Енисей буйлап сал агызган. Булса да булыр икән, менә шул кешенең кулыннан килмәгән эш юк иде. Төрле калай, пластмасс кисәкләреннән сәгать каешы, медальон, авторучка, тәмәке савыты дисеңме — һәммәсен коеп кына куя. Буш вакытында ясый ул аларны. Безне төзелешкә машина белән йөртәләр. Машина фургонының челтәрле рәшәткәсе аша чәрдәкләнеп кояш күренә. Кояш

кынамы, мондагыларның күбесе үз язмышын гомерлеккә чәрдәкләгән кешеләр иде.

Бәхетемә каршы дип әйтимме, амнистиягә эләктем. Вакытыннан алда чыгардылар. Мин яңадан чын кешеләр арасына, элекке тормышыма кайткан идем. Әнә шулай теләсә кемне кочакларга әзер бер чагымда сине, әниеңне очраттым. Күңеле яралы кешеләр бер-берсен тизрәк аңлый, диләр бит. Бәлки, шул нәрсә дә безне нык якынайткандыр — гаилә корырга булдык. Вагонда берга кайтканда,ук сине — орчык кадәрле малайны — ошатып, яратып өлгердем. Тормышны, ирекне, кешеләрне нык сагынгангамы, кояшка тартылган көнбагыштай сезгә омтылган идем. Һәм ялгышмадым. Әниең минем җаныма, рухыма тулысынча тәңгәл килерлек юлдаш, фикердәш, сеңелкәш һәм ана иде. Сине әтисез үсүдән йолып калырга, әниеңнең үткәнен һәм минем сикәлтәле язмышымны сер итеп сакларга сөйләштек. Әниең туып-үскән авылдан күчеп китүебезнең дә максаты, сәбәбе шул нияттән иде.

Бервакыт бәләкәйрәк чагыңда:

— Әти, нигә синең чәчең йомшак, ә минеке каты? — дип сорадың син.

Әниең оекбаш бәйләгән җиреннән кызыксынып, дерт итеп безгә карады.

— Үскәч синеке дә йомшар әле,— дип сүзне мин шаяртуга бордым.

Ә синең, чыннан да, тизрәк үсәсең килә иде. Көн аралаш ишек тупсасына басып үлчәнәсең. Сиңа карап сеңелең Фәридә: «Мине дә, мине дә...» — дип йөдәтә башлый. Аның да буй тамгасын бергәләп ишек яңагына төшерәбез. Сезнең дус һәм тату үсүегезне, кушкаендай житәкләшеп йөрүегезне күреп эчтән генә әй куана идем соң!

Сездәге туганлык, бер-береңә ярдәм итү, яхшылык хисе мәктәп елларында чын дуслыкка әверелде, матур дәвам итте. Берчакны шулай Фәридәбез авырып китте. Салкын тидергән. Әле туңа, әле тирли. Температурасы утыз тугыз — янь-янь гәүдәсе белән ут эчендә газапланып ята. Башындагы кайнарлыктан хәтта миндәренә кул тидерерлек түгел. Әниең биргән дарулар хәлен бераз җиңеләйтте. Мәктәптән кайту белән син сеңелең яткан бүлмәгә керәсең, юатырлык сүзләр эзлисең. Кулыңнан килсә, ярты җаныңны биреп булса да терелтәсе син аны...

Икенче көнне класс житәкчегезне очраттым. «Авырмыйдыр бит, улыгыз бүген дәресләренә килмәде»,— ди бу ихластан сорашып. Борчыла калдым: син иртән күз алдында мәктәпкә чыгып киткән идең ләбаса!

Кайтып керсәм, тыныч кына өйдә утырасың. Өстәлдә — кибет күмәче, ике шешә лимонад... Тиз аңлаштык: дәрескә дип киткән җиреңнән сеңелеңә лимонад алу өчен район үзәгенә баргансың икән. Газлы су сусынны баса, йөзләре яктырып, иреннәре алсуланып китте Фәридәбезнең. «Лимонад эчәсем килә...»— дигән сүзләренә әнә шулай конкрет эш белән җавап кайтаргансың. Бу сыйфатың бик ошады миңа.

Нигә карасам да синең зәңгәр күзләреңнән «Киләчәктә кеше булырмын» дигән җавабыңны укыдым мин.

Инде үзең уйла, чамала: кайчандыр синнән дөреслекне яшереп, без дөрес эшләдек микән? Бабайларның: «Тапкан ана түгел, баккан ана...» — дигән сүзең хәтереңә сал. Ул әти кешеләргә карата да әйтелгән. Мин сиңа үземә ышанган күк ышанам, улым. Ир-егет икәнсең, тизрәк өлгерүдән курыкма, иртә өлгергән алманың,.гадәттә, төше дә тазарак, суты да баллырак була.

Мин сиңа боларны гомер буе әйтергә җыенып яшәдем...

## Хәтерләү

Бервакыт, икенче классларда укыган чакта микән, әти мине район үзәгенә — станциягә алып барды. Кызыл автобус! Аңарга утырып карау

минем күптәнге хыялым иде. Ул һәркөн иртән асфальт юлдан, авыл турыннан узып китә. Ерактан ук кызыл пароход күк йөзеп килә дә кирпеч будка янына туктый. Ишекләре күкеле сәгатьмени — җиңел хәрәкәтләр белән үзеннән-үзе ачыла да китә. Дулкынланам, этигә ияреп мин дә эчкә узам. Автобусның эче тылсымлыдыр дип уйлап йөрүләрем, чыннан да, дөрескә чыга: өстә ялтыравыклы тимерләр, утыргыч саен аккош муеныдай бөгелеп килгән тоткычлар, тәрәзәдә алсу пәрдәләр. Болар бар да күңелдә күтәренкелек, рәхәтлек хисе тудыра. Барганда исә тәрәзәгә «ябышканымны» сизми дә калам, юл буе өр-яңа тәэсирләр...

Район үзәге шактый зур икән. Икешәр катлы агач өйләр белән бишәр катлы кирпеч йортлар, урамнар чиратлашкан. Биек башня, шуның очына кунып, урын өченме талашучы чәүкәләр авазы истә калган. Чәүкелдиләр, гүя, үзләренә күрә җыелышлары бара.

Кибеттән — сеңелемә чәчәкле күлмәк, ә миңа пешкәкле авторучка, китаплар алдык. Соңыннан «Барон Мюнхаузен маҗаралары» дигәне иң яраткан китабыма әверелде, укыган саен шул кешене кайчан да бер күрәсе иде дип хыялландым. Хәтта әле үзем дә аның кебек сөйләргә өйрәнеп киттем. Мәсәлән, болайрак... Беркөн шулай кояш нарат очларына эләккән дә бата алмый азаплана. Көн белән төн буталырга, вакыт туктап калырга мөмкин ич — тизрәк булышырга кирәк. Кулдагы таяк белән төртеп кенә җибәрдем, шундук оясына таба тәгәрәп китте кояш!..

Станциядә кара чыпчыклар күрдем дисәм, монысына да баштарак ышанмый торырсыз әле. Чынлап әйтәм, кояштыр менә, бөтен күлмәкләре кара, аксыл борыннары гына чекерәеп тора. Кара чыпчыкларны беренче кат күрүем иде, шуңа күрә гаҗәпләнеп калдым. Авылныкыларны күр син — чиста, матурлар, рәшәткәгә кунып тик көязләнә бирәләр. Ә болар... Эти аңлатты, ташкүмер тузанында коенып шундый хәлгә төшкән алар. Әйе шул, рельслар буендагы мәйданчыкта, тау-тау ташкүмер өелеп ята. Чемкара, якыннанрак карасаң, кояшта әллә ничә төскә кереп җемелдиләр. Кайткач малайларга күрсәтермен дип бер кисәген кесәгә дә тыктым әле.

Паровозны да беренче тапкыр шунда, станциядә күрдем. Кара чыпчыктан ким түгел анысы да: үз корымына үзе буялып беткән, бер чакрымнан мазут исе килеп тора. Бертуктаусыз уфылдый, терсәкле тәгәрмәчләре белән рельс буйлап йөгерә, абзар чаклы вагоннарны «эһ» тә итми урыныннан йолкып ала. Вәт куәт ичмасам! Ә электропоезд дигәннәре тагын да хәтәррәк икән. Төскә чибәр, күкрәгендә зәңгәр-кызыллы тамгалар бар, баскан урынында биеп торган тимер айгыр инде. Шул кадәрле тимер тавын кузгатканда ничек биле өзелепләр китми аның?

Аннары кайтырга чыктык.

Кайтканданиләр буласын эти үзе дә чамалап бетермәгәндер, мөгаен. Кузгалабыз дип кенә торганда автобуска бер абый керде. Андый да галәмәт эре, тупас гәүдәле кешене бүгенге көнгә кадәр очратканым юк әле. Җилкәләре шкаф чаклы бардыр, беләкләре бүрәнәдән ким түгел. Берүзенә ике кешелек урын кирәк моның! Хәтерлим, автобусның арткы урындыгы мендәр сыман сытылып кына төште. Ялгышмасам, исерек иде бугай ул. Кирә-керешкә төкрекләрен чәчә-чәчә нидер сөйләнә, мин-минлеген күрсәтәсе килеп ачыктан-ачык кычкырына:

— Мин андыйларны күп күргән. Кирәк икән гәүдәсеннән бау ишәрмен... Мин... тай кадәр тайны берүзем җилкәгә күтәргән кеше... Минем кебекләрне хөрмәт итәргә кирәк, андыйлар аунап ятмый. Ә сез башыгызны чучка күк аска иеп барасыз... Шофер, әгәр миңа карап тагын бер шыңшысаң, машинаңның ишеген чәйнәп төкерәчәкмен... Каян килеп кая китмәгән безнең башлар, идрит-кудрит...

Кем бу, нинди бәндә? Шушы әзмәвердәй абыйда чыпчык борыны хәтле дә намус юк микәнни? «Кан калтырап торсыннар әле!» — дип тантана итмәкче, ахры. Автобустагылар, чыннан да, күтәрелеп карарга шикләнә-

ләр. Мин үзем дә аптыраудан куырылып киләм, ахыры юньле бетмәстер кебек моның. Әнә бит, телендә һаман пычрак сүзләр...

Инде фәлән-фәсмәтән дип сүгенә үк башлагач, әти түзмәде, урыныннан сикереп торды. Әйтерсең, ни кылырга кирәген дәшми генә уйлап барган ул.

— Егет, туктат машинаңны!

Әтинең кискен һәм усал әйтелгән сүзләре барлык кешене киеренкелектән айнытып, сискәндереп җибәрде, әлбәттә. Автобус эчендә бер мәлгә авыр, билгесез тынлык урнашты, хәтта теге сәрхүш кыяфәтле абый да, бу ни хәл дигәндәй, аптырабрак калды шикелле. Ләкин үз-үзенә ышаныч бик тиз кайтты аңа, әнә кибәндәй гәүдәсе белән кубарылып әтигә таба килә!

— Чыгып сөйләшәбез... — диде әти шул ук катгыйлык белән һәм ачык ишектән беренче булып чирәмгә сикерде. — Син нәрсә, бу кабахәтлегең шулай үтеп китәр дип уйлыйсыңмы, шайтаннан туган нәрсә?

Ах, нинди шәфкатьсезлек: җавап урынына иләмсез абый әтинең йөзенә китереп сукты! Әти чайкалып артка чигенде, куллары белән берара битен каплады. Аннары купты мәхшәр, китте кызану! Пассажирлар тын да алмый тигезсез көрәшне күзәтәләр, ләкин чыгып булышырдай кеше юк — хатын-кыз да берничә яшүсмер егет нибары... Тайга аюыннан да хәтәррәк тоелды бу кеше. Нишләремне дә белмәстән, кычкырып елый-елый ишеккә атылдым! Кечкенә генә кулларым белән нидер кыласым, әтигә ярдәм итәсем килә. Рәхимсез бәрелеш уртасына ташланып мин нишләр идем икән соң ул чакта?

Йөгергән җиремнән яшь аралаш шуны күреп алдым: кинәт дәһшәтле абый ике куллап эченә ябышты һәм кап урталай сынып, сыгылып төште. Әле һаман да куркуым чыгып бетмәгән, әтинең итәгенә сарылдым. Борыны, авыз тирәсе, куллары кызыл кан иде аның. Автобустагылар әтине аягүрә басып, сокланудан башларын чайкый-чайкый каршыладылар:

— Шул кирәк аңа!

— Икенче масаеп йөрмәс...

— Ай-яй, көч тә бар икән үзендә, әвен чаклы ирне бөгеп салдың!

Әти боларны ишеттеме-юкмы, битләрен кульяулык белән сөртә-сөртә шоферга эндәште:

— Киттек. Безнең автобуста барырга хакы юк аның... Тын чокырына эләкте, бераздан үзе һушына килер ул, борчылмагыз.

Колонка кырыенда туктап алдык, әти битен-кулларын юды, калай кружканы йотардай булып су эчте. Авыз кырыендагы ярасыннан саркып кына алсу кан чыга. Кыргый көче, дуамал гәүдәсе белән һаваланган әзмәверне җиңү тәэсиреннән без барыбыз да чиксез бәхетле идек. Мин инде, әлбәттә, эчтән генә горурланып бардым: менә, күрәсезме, әтием белән булганда миңа берни куркыныч түгел...

Соңыннан, байтак еллар узгач, минем үземә дә дошманның зуррагы, мәкерлерәге белән алышырга туры килгәне бар. Шуны хәтерлим дә, чик буендагы бер көнем күз алдына килеп баса.

... Сугышчан «Тревога!» безне ә дигәнче дымлы сукмакларга сибеп ташлаган иде. Төнге караңгылык сыекланып, вакытның таңга авышкан чагы. Кош очып чыкканны да сизә торган электрон «сакчылар» ярдәмгә килгәч, ил чиген бозучы дошманнарның эше, ай-һай, кыенлашты соң! Бер генә секундны да югалтырга ярамый, артык тавышланмаска тырышып, «Торпеда» кушаматлы овчаркабыз артыннан йөгерәбез. Йөгергән уңайга җилкәне автомат каезлый, фуражка читләренә тир бәреп чыга.

Беренче группабыз дошманның кире чигенү юлын «ябарга» тиеш. Икенчесе — сул яктан әйләнеш ясый. Безнең группага иң җаваплысы: чик бозучы билгесез бәндәнең эзенә төшәргә һәм ахыр чиктә кулга төшерергә. Тере килеш, барлык «хәзинәсе» белән. Җинаятьчене тоту билгесе — яшел ракета... Атлыйсы юлларын картадан җентекләп өйрәнгән булса кирәк, ташлы, үткелле, ерганаклы урыннарны сайлаган ул.

Яктыра төшә, томан сирәгәя, кирза итек асларында ком-таш шыгырдый. Уен эш түгел: без аны яки эләктерәчәкбез, яки ул еракка ычкынып өлгерәчәк. Бәрелешнең ничек буласын һәм ничек бетәсен берәү дә алдан әйтеп бирә алмый. Коралын кулланырмы-юкмы ул, әллә хәленең мөшкелләгән чамалап бирелү ягын карармы?

Ерганак буйлап сак кына өскә күтәреләбез. Өстә куаклар белән чуарланган тигезлек башлана. Бер генә мәлгә туктап тирә-якка колак салабыз... «Шылт» иткән аваз да юк, ялангач таулар, куаклы сыртлар киңлегендә — шомлы тынлык, сәер билгесезлек.

Ә ул безне шунда көтеп торган, эзен яшерү өчен катлаулы «элмәк» тә ясап өлгергән икән. Шуңа алданып овчаркабыз алдагы куаклар арасына кереп югалды. Иң алдан мин йөгерә идем, шулвакыт куак арасыннан кемдер берәү өстемә ташланды. Исәбе — кулга автомат төшерү булган, күрәсең. Комлы туфракта үлемгә-үлем әүмәкләшәбез... Ни гаҗәп: күңелдә бернинди курку юк, киресенчә, үземдә арыслан көче тоям. Лошманның кулын җиргә сыгып төшердем, хәзер гәүдәсен кузгалмаслык итеп бастырып тотарга кирәк. Иптәшләрем килеп җиткәнче... Алар якында иделәр, тиздән безнең ракета яшел дуга сызып, күктә тирбәлә иде.

Җинаятьчене заставага кайтардык. Шактый эре «кош» булып чыкты ул.

Әйткәнемчә, без бәхетле идек, авыл турында автобустан да горур атлап төштем мин. Җәй азагы бит, көн генә үзгәргән иде — салкынча җил исә, офыкларны иңләп авыл өстенә кара болыт явы*килә. Шундый тәбәнәк үзе, ферма түбәсенә тияр-тимәс булып агыла. Ул да түгел, ашлык амбарына җитәрәк коеп-коеп кисәктән боз яварга кереште. Эре, салкынча, матур язу дәфтәрләрендәге сызыктай кыйгачлап төшәләр. Ярый әле башымда кепка бар, шуның аркылы да хәйран авырттыра башны, ә кулны, битләрне чеметепме-чеметәләр! Кызык һәм сәер күренеш иде бу...

Эти мине җитәкләгән, сеңелемә дигән күлмәкне костюм изүенә яшергән,— бозлы чыбыркы яңгырын ерып йөгерәбез шулай. Көч-хәл белән амбарга барып капландык. Амбарның шифер түбәсе чылтырый, дөберди, әйтерсең, аңарга өстән капчыгы белән вак чуерташ сибәләр. Эре-эре бозлар кукуруз сабакларын сындырып бетерде, берничә урында түбә шиферларын чәрдәкләде.

Бозлы манзара уртасында хәйран басып тордык. Амбарның ачык, такыр урынында ашлык көшеле тора иде. Алтынсу төстә, зур биек, вулкан өемедәй очлаеп килгән. Ачык урында торганга күрә, әлеге көшелгә орыпорып, эчкә уелып керә-керә яуды бозлар. «Эштән чыкты бу»,— дип бик кызгандым көшелдәге ашлыкны. Сынган кукуруз сабаклары силоска китәчәк ичмасам, ә бу соң нәрсәгә ярар икән...

Җиргә яткан боз катламы күзгә күренми акрын гына эреп, тиздән юешкә әверелде. Без эти белән көшел каршында басып торабыз. Ни хикмәт, көшелдәге бодай бөртекләренә тамчы да зыян килмәгән! Нибары өсләре чокырланып, шадраланып калган, ә бөртекләр — һәммәсе дә исән, таза, бөтен... Берни булмагандай үпкәсез-нисез томраеп күккә карап яталар.

Амбар ишегалды. Ачылып килгән зәңгәр күк. Нәни таучыкны хәтерләткән гәрәбәдәй көшел... Эти көшелдәге бодайны кушучлап җирдән күтәрә дә әллә үзалдына, әллә миңа әйтәсе килеп болай ди:

— Сәламәт, тук бөртекләрне беркайчан да боз суга алмый шул. Тормышта да әнә шулай күңелең нык, бәдәнең таза булу кирәк...

# Зөлфирә

Куен кесәсенә керү белән бармакларыма — рәхәтлек, тәнемә кайнарлык тарала. Дүртпочмаклы рәсемнән миңа мәхәббәтем Зөлфирә карап тора. Таралып төшкән чәчләр, түгәрәк йөз, коеп куйган кашлар, оялчан һәм акыллы елмаю... Гадилеге, яхшылыгы, ихластан елмая белгәне өчен яраттым бугай мин аны. Фоторәсемне иреннәремә якын китерәм дә күзне йомам: Зөлфирәнең чәченнән урман исе килә кебек. Шушы чәчләргә кереп адашасы, аларның хуш исле кытыклавыннан онытылып иркәләнәсе килә.

...Зөлфирә алты чакрым ераклыктагы күрше авылдан килеп укый иде. Минем урта мәктәпне тәмамлыйсы елым, ә ул тугызынчы класска йөри. Өстендә — кызыл һәм зәңгәр төсләр чиратлашкан шакмаклы күлмәк. Үзе дә, күлмәге дә минем өчен әле күңел туймаган яңа табышмак иде. Минем текәлеп, яратып карауларыма, ниһаять, тылсымлы караш белән җавап кайтарды. Таң калдым: гади күзләр түгел иде бу, алар артында беркем дә үтеп керә һәм аңлый алмаслык тирәнлек, чиксезлек, өр-яңа дөнья башлана иде. Шундый тирәнлекне беренче булып күргәнмен икән, димәк, аны беренче булып та мин ачарга тиеш!

Көн саен димим, атнага берничә тапкыр аны авылларына кадәр озата барам. Кыр юлы, ике авыл арасындагы каен полоса, баш өстендә көмеш тургайлар...

Менә шул чакларда мин инде гашыйк икәнемне аңладым. Китаплардан укып белгән мәхәббәт хисенә минем йөрәктә дә урын барлыгына, кичке утларда һәм йолдызларда билгесез ераклыкка чакыру авазлары тирбәлүенә төшендем. Аның туңа башлаган бармакларын җылыту — беренче тапкыр чын-чынлап кызлар кулы тотуым булган икән! Ромашкалар төшерелгән косынка, чия төсендәге күн сумка, плащ итәге астыннан күренеп торган резин бутыйлар... Кышын — капка түбәсенә кадәр күтәрелеп үскән кар көрте, тәрәзә уты яктысында көмеш тирмәдәй балкыган шул көрт астында басып торулар... Болар бар да хәтеремә мәңгелеккә, беркайчан да җуелмас өчен кереп калганнар.

Буранга һәм яңгырга бәйле мәхәббәтем син, Зөлфирә!

Табигать күренешләреннән ике нәрсәне — буран һәм яңгырны аеруча югары бер хис белән яратам икән, бу — өзелмәс җепләр белән үзебезнең яшьлек таңына барып тоташу, шунда яши башлау галәмәте.

Кышкы каникул башланасы көннәр иде. Син концертта чыгып җырладың, шул җырның көе һәм сүзләре безнең халәткә бигрәкләр дә туры килә иде.

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын.
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын...

Аннары, бер сәгать элек кенә колак төбендә яңгыраган «кыңгырау» моңнарына күмелеп, сине кичке авыл башында көтеп торам. Икебез дә чаңгыдан. Инде мең кат үтелгән юлдан бару кызык түгел, ниятебез — кар өсләтеп кенә сезнең авылга бәреп чыгу. Урап-урап яуган карларның куерганын, җилнең һаман көчәя барып буран чыгуын сизми дә калганбыз. Биткә, күкрәкләргә тоташ актарылган кар дулкыны, салкынча агым бәреләэ. Икәү янәшә булганга күрә курыкмыйбыз, аксыл-соры ташкынны ерып алга барабыз. Сизәм: күкләр тыгызланып, каралып китте. Күзне ачар хәл юк, буран кемгәдер ачуланган җанвардай үкерә, чаңгы таякларын йолкып-йолкып атмакчы итенә. Сөйләшкән сүзләребезне шундук бөтереп ала да очсыз-кырыйсыз караңгылык кочагына илтеп ташлый.

Барабыз... Ә сезнең авылның күренер исәбе юк. Хәер, шулкадәр тыгызлык, караңгылык пәрдәсе аша тиз генә күренер иде микән ул безгә? Адашуыбызны сизеп алдык. Әмма табигать безне өметтән бөтенләй ук мәхрүм итмәгән икән: ялан кырдагы салам кибәненә барып төртелдек.

Иң яхшысы — шуның ышыгында туктап тору, бәлки, буран да басылып куяр? Куллар авырткачы, бармаклар сызлар дәрәҗәгә җиткәнче икәүләп карлы саламны йолкыдык. Үзенә күрә ярыйсы гына куыш килеп чыкты. Чаңгыларны куыш алдына кадап, эчкәре кереп урнаштык. Кар катыш коры ашлык, тукранбаш, клевер исләре аңкый, гүя кыштан җәйгә атлап кердебез. Син туңгансың, битләрең юеш, чәчләреңә кар укмашкан. Бернинди оялу-тартынусыз сине кочагыма алдым, битләреңә кайнар сулышымны өрдем. Сине җылыта торгач үземнең дә тәнемә кайнарлык, эчке бер дәрт тулды. Хәлнең көтелмәгәнлеге, билгесезлеге безне аеруча якынайтып җибәргән иде бу минутта.

Тышта тонык кына буран шаулый... Дөм-караңгы салам мәгарә кочагында без — икәү, янәшә... Ул чактагы бәләкәй генә куыш миңа әнә шулай чиксез, мәңгелек булып күренгән икән. Һәм мин бу шомлы, аулак, серле хәлгә күңелемнең кай җире беләндер бераз риза да идем. Син, кыз бала, курыктың, әниләр борчылыр дип өзгәләндең.

Син хаклы идең, ярты сәгать чамасы бер-беребезгә сеңеп, җылынып утырганнан соң мин ни эшләремне дә белмәстән максатсыз-нисез генә куыштан чыктым. Өнемме бу, төшемме: бездән йөз метр чамасы җирдән, фарасы белән кар ташкынын урталай телеп, трактор узып бара! Чанасында утын төялгән булса кирәк... Куанычымнан бүрекне селки-селки бар көчемә кычкырдым:

— Әй, кешеләр, туктагыз!..

Кабат-кабат кычкырып карасам да, толып бөркәнеп утырган утынчылар тавышымны әллә ишетмәделәр, әллә инде туктарга теләмәделәр, белмәссең.

Тракторда тере кешеләр утыра лабаса, алар, һичшиксез, якындагы авылларның берсенә кайтырга тиешләр. Иң яхшысы — безгә хәзер ничек тә трактор эзенә төшәргә, ашыгырга кирәк!

Син инде нидер барын сизенеп «мәгарәбез»дән чыккан идең. Кулларыңны бер тын яңагыма кыстым да җәһәт кенә кузгалдык. Безнең куркуборчуларыбыз җылы куыш эчендә бөгәрләнеп ятып калды. Трактор эзе безне коткарды, утлары җемелдәп торган фермагызга кадәр алып кайтты. Буранлы кич, карлы чаңгылар, ферма юлында өздереп караган талгын-моңсу күзләрең... Менә ни өчен кышкы бураннарда беркайчан да салкын кан белән йөри алмыйм мин!

Көннәр язга авышканда ул кибәнне ике трактор сөйрәтеп маташканын күрдем. Икесе тиң кара төтен бөркеп төчкерә, ыңгыраша, чылбырлы тәгәрмәчләре белән җан-фәрман актарына, бичаракайлар. Кибәннең исә кузгалып китү исәбендә дә юк, әйтерсең, буранлы кичтә адашкан көнебезгә һәйкәл булып һаман да басып торасы килә аның... Көчәнә торгач сөйрәп чыгардылар, силос чокырыдай йомылып, кибән урынында карлы бушлык тырпаеп калды. Әмма яшьлекнең кабатланмас бу хатирәсен безнең күңелдән ансат кына йолкып алу мөмкинме соң?

Бер-берсен мәңге онытмасыннар, бергә чакларының кадерен белсеннәр дигән теләк белән, ихтимал, табигать безнең өчен барлык хозурлыкларын алдан ук әзерләп куйган иде. Баш өстебезгә зәңгәр чатыр итеп күкләрен корган, киләчәкнең алтын капкаларын төсмерләү өчен салават күпере кабызган, аяк астыбызга чит-читендә ялгыз күкчәчәге, куе арышлары чайкалып торган йомшак юллар җәйгән. Без ул матурлыкларны беркайчан бүлешмәдек, алар — уртак иде.

Салават күпере... Менә ул ерактагы таулар эргәсенә тын гына барып таяна, ничәмә төсләр белән балкып үзенең дугалы капкасыннан санап-

санап кына болытлар кәрванын уткәрә. Менә шушы әкияти күренешләр уртасыннан мин сине тагын озата барам. Кояш көнозын кыздырган иде, юл тузанының кайнарлыгы ботинка табаны астыннан бәреп тора. Бередә тузан, ә кайдадыр әнә яңгыр урман-карларны суга керендерә. Тик бу алдавыч күренеш икән: кисәк кенә җил исте, буынтыклы яшел арышлар түгеләм дия-дия юл читен тутырып чайкала башлады. Эре-эре тамчылар сикереп төшә — кыр өстендә тоташ пышылдау, кыштырдау, сискәнү авазлары...

Икебезнең өстә дә җәйге юка күлмәк иде. Бер-беребезгә карау белән сүзсез аңлаштык: тотарга да каен полосасына таба йөгерергә! Җитәкләштек тә яңгыр шадралаткан юлдан йөгерәбез, үзебез бер сәбәпсез елмаябыз. Тыгыз-эре тамчылар дулкыны безне җиңелчә генә аркабыздан этеп, йөздереп бара — нәкъ канатлы җилкән инде! Минем чалбарга, синең нәфис балтырларыңа йолдыз тамчылары булып балчык чәчри... Каеннар полосасына әнә шулай килеп кердек. Кыяфәтләребезне күргәч, рәхәтләнеп яңадан көлештек. Икебез тиң чыланганбыз, өсләребез манма су, яңгырда юылган толымнарың тагын да карала, чибәрләнә төшкән. Ялангач беләкләреңдә, муен тирәләреңдә җемелдәп тамчы тәгәри. Юеш күлмәгең, талчыбыктай гәүдәңнең илаһи хәрәкәтләрен күрсәтеп бирергә теләгәндәй, мәрмәр тәнеңә ябышкан. Манма күлмәк аша беленеп торган тыгыз күкрәкләрең, тизрәк дөньяга чыгарга ашкынган төсле, бер күтәрелә, бер төшә... Янәшәмдә генә тере, бөек, ымсындыргыч хәрәкәт: кайнар, дәртле, исерткеч омтылыш! Утә-күренмәле күлмәк эчендә магнитлы ике йомры — түм-түгәрәк ай һәм кояш, тылсымлы галәм яшеренеп ятканын тойдым. Ике йомры арасындагы озынча күләгә Киек каз юлына тиң иде...

Менә шунда кинәт башым әйләнеп китте, аяк астымда ап-ак каеннары белән бергә җир шуышты... Дымлы иреннәреңә капланып тыным беткәнче озаклап басып тордым...

Ул көн — хәтердә: яшереп кенә язган шигырьләремә бәреп керә алар, куен дәфтәремә күчә. Чәчләрне җил иркенә ташлап яңгырлы, баллы, салават күперле көннәремә тагын бер кайтасым килә минем!

Каенлы полоса. Кырларны көйдергеч коры җилләрдән, мәрхәмәтсез давыллардан саклау өчен утыртылганын белә идем мин аның. Ир-егет буларак сине тормыш җәберләреннән, әгәр кирәксә, илемне дә хәвефле көчләрдән ышыкларга, сакларга тиешлегемне аңладым шул чакта.

Кайтыр алдыннан гына сеңелем Фәридәдән хат алган идем. Синең студентлар концертында җырлавыңны әйтеп язган. Ә инде үзеңнең«көтәм» дип язган хатларың — чемодандагы иң зур байлыгым, гомерлек хәзинәм!

Безнең әле очрашасы, җырлатып яшисе көннәр алда. Беләсеңме, Зөлфирә, сиңа аулакта, теге чакта икәү генә басып торган каен төбендә озак-озаклап, ачыктан-ачык итеп бөек серемне сөйлисем бар әле минем. Мин аны күңелемнән мең кат уйлый-уйлый, очын-очка ялгый-ялгый ялгызым йөргән чакларда ачтым... Әйе, баланы дөньяга китергән ата да — аның язмышы, киләчәге, бәхете яки бәхетсезлеге өчен гомергә җаваплы икән! Бу җаваплылыкны берниндн очраклык, вакыт ераклыгы, нигезле фәлсәфә, аклану сүзләре дә юкка чыгара яки йомшарта алмый. Әти булу — шулкадәр дә җаваплы, авыр, четерекле, барыннан да элек изге, мәрхәмәтле бурыч икән, мин моны ике әтием мисалында ачык аңладым.

Мин кем улы соң, миндә кем каны ага? Дөнья чаклы уйларым, хыялларым, яшәвем кемгә барып тоташкан? Бу сорауларга җавап бирү, ах, нинди кыен һәм нинди җиңел! Уз әтием миңа кан биргән, җан бүләк иткән һәм ташлап та киткән — мин моны белми үскәнмен. Күргәнең бар микән: урмандагы төбе-тамыры белән кубарылган карт агач куенында үскән зифа, яшь агачны да үзе белән бергә аудара. Мин дә алты айлык чагымда яшь агач хәлендәрәк калганмын лабаса: Ярый әле вакытында икенче бер кеше үз кулларына алып каткан, үстергән, дөньяда барлыгымны расларга, үз-үземне табарга булышкан. Мин аларның кайсын әти дип танырга һәм яратырга тиеш соң? Әлбәттә, соңгысын. Әгәр ул ятимлек-

тән аралап калмаса, «эттә» диеп әйтә алу бәхете бүләк итмәсә, мин нинди кимсенүләр, рәнҗүләр күреп үскән булыр идем! Күңеле китек кешенең дөньяга үпкәсе бар, диләр ич. Миңа тормышның соры, караңгы, күңелсез бер нәрсә булып күренү ихтималы зур булган. Ул чакта табигатькә һәм кешеләргә карата мөнәсәбәтем дә бөтенләй башка төрле, хәтта бәлки ачулы, нәфрәтле юлдан китәр иде, мөгаен...

Этинең яраткан бер сүзе бар: «Дөреслек ул — сары май, беркайчан да аска батмый...» Минем өчен дөреслек — эти үзе, аның шәхесе, якты үрнәге. Балачакта шыбырдап яуган бозлар, амбардагы ашлык көшеле яңадан хәтергә килә. Кукуруз сабаклары чәрдәкләнеп бетте, ә ашлык көшеленә берни түгел — элеккечә мәгърур, сәламәт, киресенчә, юылып чистарып киткән... Безнең эти боз сукканга да бирешми торган мәгърур бодай көшеленә тиң икән! Язмыш кая атып бәрсә дә ныклыгын югалтмый, асылын үзгәртми торган кеше икән ул.

Уйлаганым бар: ни өчен без эти белән әни кешегә беркайчан да исемнәре белән эндәшмибез? Бары эти дибез, әни дибез бары. Күрәсең, тапкан-баккан өчен әле рәхмәт әйтергә өлгермәгән баланың үскәч тә гомер буе хөрмәтләү, баш ию билгеседер бу. Көн саен әйтелә торган әлеге ике сүз һәр буынның телендә искермичә, өр-яңа яңгыраш белән яши икән.

Минем әле әнинең туган авылына — балачакта эти белән бергәләп утырткан миләшем янына кайтасым бар. Җиткән егет, дөресрәге, инде байтак аяк киеме туздырган тәҗрибәле ир-егет булып. Үткәннәргә үпкә сакламый гына кайтып төшәсең дә Әухәт абыйга кул бирәсең, теге чакта синең дегетеңә буялсак та, күңелгә дөнья карасы йоктырган юк, якташ, дип шаяртасың. Дамир гына очрар микән авылда? Кем белә, ә бәлки аның да каеш-погоннарын ялтыратып нәкъ минем кебек ерак җирләрдән кайтып килешедер. Яшьтәшләр бит, ну сөйләшеп тә күрсәтер идек без аның белән! Безнең нигездә кемнәр, нинди кешеләр яши икән? Миләш төбенә утырып татлы уйлар уйлыйсым, киләчәккә берсеннән-берсе матур планнар корасым бар әле минем.

Лубьян урман техникумында укуымны дәвам итәчәкмен. Кайтасымны анда да көтеп торалар. Күрәсеңме, этиемнең яхшылыгы, шәхси үрнәге никадәр көчле булган — икеләнеп тә тормастан, аның һөнәрен үземә гомерлеккә сайладым мин.

Бик биектән, галәм киңлегеннән Гагаринга зәңгәр әкият булып күренгән Җиребездә мин үз урманымны үстерергә тиеш! Урман ул кешеләргә кирәк. Агачлар шавы тантана иткән җирдә гамьсезлеккә, битарафлыкка һәм күңел тарлыгына урын булмастыр кебек. Менә ни өчен урманны яратам мин. Бу дөньяда күп нәрсәләр үзгәрер бәлки, әмма урман җыры кешеләргә гаҗәпләнә белү һәм мәхәббәт хисе бүләк итүдән беркайчан туктамаячак.

Урман шавы безне дә гомер буе озата барыр, Зөлфирә! Ныклыкта, тугрылыкта сынар. Мин бит сине бердәнберем итеп сайладым... Икәү бергә булганда без язмышның теләсә нинди авыр йөген дә җиңел күтәрербез — мин моңа нык ышанам. Ишетәсеңме, поезд тәгәрмәчләренең шавын күмеп, көннең кыл уртасында минем йөрәк тупырдый. Син бит якында, шундый якында!

* * *

Рельслар хәтер сыман артка йөгерә...
Поезд хыял сыман томырылып алга чаба...
Нигә ашкынам соң әле? Алда күрешү таңнары, тормышымның кул тимәгән өр-яңа кырлары көтеп торгангамы? Җавап урынына күңелгә кай төшеннәндер көчле дулкын күтәрелә:
— Хушыгыз, карагай урманнары! Алда мине яшьлек мәхәббәтем Зөлфирә көтә.

1984 ел. Малеевка.

# Фәннур Сафин

## Таң

Җилләр өзгән яфрак сыман
Көннәр оча — еллар кими.
Һәр тәүлек ул үзе кыйсса,—
Көннәр сөйли, төннәр сөйли.

Бер уйласаң, бу заманда
Еллар кыска, чорлар кыска.
Көчкә ялгап өлгерәсең
Гасырларның очын очка.

Шул тизлектә синә, кеше,
Үз-үзеңне тапмак кирәк.
Шуны сөйләп таң атканда,
Ничек йоклап ятмак кирәк?!

## Кемнәр?

Салкын гүрдә аңга, җанга килеп
Кояшка юл ярган батырлар.—
Якыннары чөнки көткән өзелеп:
— Кайтырлар бит,— диеп,— кайтырлар!..

Күтәралыр әле бәлки йөрәк
Кара янгын — салкын шартлауны.
Шунысы да ләкин хак бит аның:
Катлаулы шул дөнья, катлаулы...

Уйга талып иләм Казанкага,
Гүя карыйм серле көзгегә:
Ә бер-бер хәл була калса әгәр,
Кемнәр көтәр икән безне, ә?!

## Күбәләк

Тормыш — дәрья буйлап алдар дулкын
Алып китте сине, әй, ерак!..
«Нәни генә утрау да күренми,
Ничек кайтыйм,— дисең син,— урап?»

Беркатлы җан, ничек кайтырсың соң,
Юк көймәң дә, димәк, җилкән дә.
Утыра тик төнге бер күбәләк
Йокымсырап синең җилкәңдә!

## Ут һәм мин

Яна бер ут бик еракта.
Мин ялгызым куышта.
Җылытмый ут, син аңа хет
Елыш яки елышма.

Аннан җылы кętеп инде
Күпме мөмкин түзәргә?
Ләкин күңел риза түгел
Башка якты эзләргә.

Аның өчен төн эчендә
Мең уянам, мең янам.
Ярый ла, шул утта мин дип,
Үзем тагы юанам...

Нинди язмыш, нинди сагыш
Юллар миңа ут кынам?—
Ялкынланып яшим ләкин
Үзем дә шул ут сыман!

## Мин, син һәм без

Мин гел шулай,
«Син» дип — юлга!
Телим гүя
Бу вакытны узарга.
Китәм яшь кала төзергә
Я яңа юл сузарга.

Син дә инде
Мине сагынып китәсең
Гел икенче тарафка,
Ничек яшьнәп яшәмисең,
Шундый өзелеп ярат та!

Һәм без хәзер —
Илне уттан сакларга дип,
Бер-беренә күз тегеп,
Ике фронтка юнәлгән
Егет белән кыз кебек.

## Якын килсәм

Таң нурында су коендың —
Күреп калдым.
Күзләр белән чәч-чишмәңнән
Үбеп алдым.

Шәфәкъ нурларында тагын
Су коендың.
Су кызының үзе булып
Син тоелдың.

Якын килсәм, сүз әйтергә
Тел әйләнмәс.
Әйләнсә дә, сүзем сүзгә
Һич бәйләнмәс.

Чәчең сыйпар өчен кулым
Күтәрелмәс.
Миңа карап син торырсың
Көләр-көлмәс...

Торатошка әйләнермен
Диеп куркам.
Тик тартыла күңел сиңа,
Күбәләкләр курыкмаган
Кебек уттан...

## Кызлар

Кайчандыр бит шуңа барып җиткәннәр:
Бер-беренә кызлар бүләк иткәннәр
Яки гамьсез генә... түләп киткәннәр;
Кансызлары сабаннарга җиккәннәр.
Үзләренә юкса... варис көткәннәр.

Үткән еллар, алышынган заманнар,
Очкан тәхет, падишаһлар, бароннар,
Гөл-чәчәккә күмелгән, әй, яланнар!..
Сылу кызлар анда бии дә җырлый!
...Ә йөрәктә һаман чал тарих елый...

## Гашыйклар

Безнең өчен ул иң усал,
Иң сөйкемсез кыз иде.
Кем генә соң яраталсын
Шундый кыргый кызыйны?

Ә беркөнне ул җырлады...
Күңеленнән моң алып.
Һәрбер аһәң йөрәкләргә
Калды уктай кадалып.

Ачылды ул шулай кинәт...
Белдек хәзер: без күптән
Бер-беребездән көнли-көнли
Шул кызга гашыйк икән!..

## Уйлану

Таң нурлары төнне эреткәндәй,
Бәхет булып миңа килерсең.
Яннарыма утырып, мин яраткан
Чәчләреңне тарап үрерсең.

Ал шәфәкъгән тамган соңгы нурны
Караңгылык ялмап алганда,
— Ник китте ул, нигә китте?— диеп
Мин дәшәрмен уйчан талларга.

Я син чөеп алтын толымнарың:
— Бөтенләйгә калам!— диярсең.
Яшьлегеңнән, сихри яшьлегеңнән
Ак күлмәгең алып киярсең...

●

Күзләр күрде, күңел гашыйк булды:
Язгы җилдәй һәрбер хәрәкәте.
Акыл әйтте:
— Аның апасы бит
Яшьлегеңнең серле мәхәббәте!..

## Беренче кар

Эри-эри ява карлар,
Кемгәдер бу — иске, узган эш.
Нәкъ умырзая шикелле,
Тәүге сафлык ләкин кызганыч.

Онытылырга теләгәндәй.
Бөтерелеп-биеп ява кар,
Кәлә-кәлә үксеп ява кар,—
Үз-үзеннән качып гүя
Егет иңенә башын сала яр!..

●

Йөрәгеңне яңа, якты көнгә
Исән алып чыгу өчен мәллә,
Уй-диңгезгә чумып, төннәр буе
Син ятасың күзең йомган хәлдә?

Күз йомып та алдап булмый аны,—
Камап ала хәтер дулкыннары!
Язмышыннан шәфкать сорап кайчак
Ишетелә йөрәк сулкылдавы.

Аклангандай тәүге хис каршында,
Җирне бизи кеше, тормыш кора.
... Мең сагышы булып бер ялгызның,
Яшьлек ярларында бер кыз тора...

●

Көзге яфрак туңа, ал учыңа!
Һәрбер матдә нидер сөйли ул,
Узып киткән җылы җәй турында
Үз телендә һаман көйли ул.

Тоясыңмы?
Кызыл яфрак кинәт
Хәтер булып учың пешерде!
Ул бит шулай синең искә төшерә
Онытылган гүзәл кешеңне.

Авырмыни яфрак, ал учыңа,
Уйланып тор бераз тын гына?!
Ул — җаныңа дәва.
Яфрак исә
Рәхәтләнә синең җылыга!..

Көзге яфрак туңа, ал учыңа...

## Иске бакчада

Ләйлә килми бу бакчага
Һәм Мәҗнүнен көттерә.
Кемдер чыга бары этен
Саф һавада йөртергә.

Бу чәчәкләр миңа бары
Чүп савыты дип микән,
Кыз кочкан бер ярым-йорты
Гөлгә тәмәке төрткән.

Япь-яшь ана килә шулчак,
Дөньяга нур бөркелә:
Сиртмәле арбада сабый
Бер елмая, бер көлә!

## Каһкаһә

Матурлыкны артык яратканбыз,
Онытканбыз җирдә нинедер.
Шуңа күрә күңелләргә керә,—
Замананың таңгы җиледер.

Таңга куллар сузсак — шәфәкъ яна —
Чайпала да түгелә ал касә.
Көлә, көлә! Синнән, миннән көлә
Бик ерактан килгән каһкаһә!..

## Бергә

Моңсу гына таңнар атсын әйдә,
Бер юансын әле хисләрең.
Көннәр аяз булыр диеп кенә
Алсуланып килсен кичләрең.

Агылсыннар күңел ташкыннары,
Куанычы җанның — ачык йөз.
Аяз күккә карап, ничек инде
Гамьсез генә галәм буйлап йөз.

Якты галәм буйлап без йөзәбез
Чалкан ятып яшел аланга.
Син гомер сер, имеш, елмаймый да,
Яши торып шундый заманда.

Куллар кулга үрелеп кенә тора,
Һәкъ йөрәктә дуслык ялкыны.
Җирдә көннәр, төннәр уза шулай
Синең, минем йөрәк аркылы.

Хуҗалары ич без шушы җирнең,
Һәм дөрлибез шуңа күрә без.
Ал таңнарны шулай чакырабыз
Һәм кичләргә бергә керәбез.

..................

# Харрас Әюпов

## ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕ

### Таңнарда җил исә...

Дөньяда ни дисәм,—
Таңнарда җил исә,
Җаннарга тынгылык бирмичә.
Таңнарда җил исә...
Чикләрне белмичә,
Җиллән-җилләргә моң күчә.

Җилләрдән — җилләргә,
Еллардан — елларга,
Буыннан — буынга: бер сулыш!

Бабайлар сулышы...
Әтиләр сулышы...
Безнең дә шуларга кушылыш...

Гомерләр кичкәндә,
Елларга күчкәндә
Җаннарны кузгата бел икән...
Таңнарда ни дисәм,
Сызылып җил исә...
Бу яшәү — тоташтан җил икән!

### Яра

Басар өчен сагыну-җирсәүләрне
Булса икән җирдә, һай чара!—
Туган Ил ул көзен китеп барган
Кошларны да тартып кайтара.

Читтә яшәгәннең бар догасы —
Туган җирен сагынып әйткән сүз;
Илен җуйган кеше — ярты кеше,

Камил түгел беркем Ватансыз.
Кояшы да булыр, җилләре дә,—
Ил яктысы җитмәс, Ил исе;

Илләреннән мәхрүм булганнарга
И, Җир шарын кочып елыйсы!

Еллар аша, океаннар аша,
Тик бик азга гына булса да,
Кеше җаны очар кошлар сыман
Туган оясына юл саба.

Кемгә — дәва Ватан, кемгә — яра...
Ниләр белән генә ямасы?—
Илдән киткәннәрнең җаннарында
Иле кадәр була ярасы!..

### Моңлы бер кыл

*Композитор Заһид ага Хәбибуллин истәлегенә.*

Дөньядан ул халык исән чакта
Китә алмый торган заттандыр;
Бүген аның скрипкасында
Тик яңа кыл гына арткандыр...

Моңлы бер кыл иде,— ниләр генә
Кагылмады икән ул кылга!

Бик ямансу чакларында, йөрәк,
Шул моңнарга кушылып сулкылда.

Дөнья белән саубуллашкан чакта
«Тәфтиләү»ләр булып талпынды.—
Китәлмәде ләкин: күңелләргә
Нечкә бер кыл булып тартылды...

*(Бөек Ватан сугышы чорында фронттан килгән үлем хәбәрен кулыма алгач.)*

Никадәрле ныклык кирәккәндер
Бу хәбәрне алган кешегә!—
Кулга тотып караганым булды:
Еллар аша кулны пешерә...

Нишләтсәң дә, төзәләсе юктыр
Аннан калган авыр яраның:
Ак кәгазьдә — кара үлем эзе,—
Мин үлемне... тотып карадым!

«Батырларча һәлак булды»,— дигән,
Язар өчен ничек кул барган?!
Күпме гомер яфраклары шулай
Өзелеп төшеп калган еллардан...

Күпме сабырлыклар кирәккәндер,
Кәгазь булып кайткач ир-атлар!
...Еллар аша килеп төшә җирга
Өзелеп калган өнсез яфраклар...

*Курск шәһәрендәге Туганнар каберлегендә Җиңү көнне кабер саен ак чәчәкләрдән венок салалар.*

Иле исән чакта ирләр үлми,
Ватан-ана барда — кадер бар:
Ил җылысы килеп кагылганда
Чәчәк ата икән каберләр...

Йөрәкләрдән гөлләр шыткан мизгел...
Агачлар да иелеп тын калган,
Үлгәннәрне бер терелтер өчен
Бер минутка тормыш туктаган.

Мәрмәр ташка гөлләр сарылганнар,
Кабер өсләрендә — ак тынлык.
Туфрак агларыннан сирпеләдер
Ак җаннардан төшкән яктылык.

Каберләрнең чәчәк аткан чагы,
Кайткан чагы илгә ирләрнең;
Гасырларның телгә килгән мәле,
Дәшкән чагы чорга илләрнең...

## Үләннәр дә уйланыр чак

И, Яшь үлән, ни гомерләр яттың,
Оеп шулай туфрак эчләрендә!—
Күпме сулар акты, җилләр исте,
Яулар узды синең өсләреңнән...
Берни сизмәдең син, биләүсәдә
Изрәп яткан сабый бала сыман...
Әле генә баш тертәсең менә,
Иске яфрак, камыл арасыннан.
Баш очында Кояш көлеп тора,
Көннәр тыныч, күкләр нинди биек!
Гаҗәпләнеп син сорыйсың сыман:
«Кайда соң мин, нинди чор бу?»— диеп.
Берни белми килеп чыктың шул син
Атом гасырына, и Яшь үлән!
Ни булса да, кире чигенү юк,—
Язмышлар бер безнең синең белән.
Тик алданма: тыныч яшәр өчен
Килми икән җиргә бернәрсә дә;
Үлән булып син яшәргә тиеш,
Эссе көйдерсә дә, җил бәрсә дә...
Борын төрткәнеңә үкенмичә,
Сабыйларның йомшак табаннарын
Иркәлә, сөй әле,— аларны бит
Киләчәктән мөмкин табалмавың...
Күтәрел син: атом гасыры бу,—
Ни чыгармас, әгәр дошмн торсак?
...Җилләр көтте сине... Илләр көтте...
Үләннәр дә җирдә уйланыр чак!

## Әбиләр чуагы

Табигатьнең Вакыт каршысында
Тып-тын калып, башын игән мәле.
...Тезелешеп, җәйне озатырга
Чыгып баскан печән кибәннәре.

Күз килүгә, ак җәймәдәй булып,
Сузылып ята җиргә ап-ак томан;
Кояш нурларында пәрәвезнең
Тирбәлгәне ишетелә сыман.

Тик бер генә күзнекеме соң бу?—
Урманнарны моңсу сагыш сарган:

Кыштыр-кыштыр килеп, алларына
Ялкын өзелеп төшә агачлардан.

Ерак үткәннәргә, киләчәккә
Ишетелер күк, әгәр аваз салсаң;
Күптән киткәннәрне табарсың күк
Болыннарда бүген, эзләп барсаң...

Чал Вакытның дөнья каршысында
Тып-тын калып, башын игән мәле.—
Табигатьнең шушы мизгелендә
И, җаннарны чайкыйсы бар әле!..

## Син

Син калган идең дә,
Югалган идең дә...
Сагынуга кем генә чыдасын?!—
Еллардан калкынып,
Урманнар аркылы
Каршыма син килеп чыгасың.

Суларга төшсәм дә,
Утларга керсәм дә,
Нурларың юлыма сибелгән;
Давыллар кичәсең,
Тауларны тишәсең,—
Кайда да калмыйсың син миннән!

Гомерләр үтәсе,
Без дә бер китәсе,
Барасы юлыбыз билгеле...
Сеңәрсең су булып,
Үсәрсең гөл булып,—
Барыбер табарсың син мине...

# Радик Фәизов

# ИКЕ ТАПКЫР ВЕТЕРАН

хикәя



Күршесе Хәмбәл белән урамнан җиңел атлап кайткан Котдус абзый, үз йортының капкасын ачып керүгә, тукталып калды. Капка баганасына сөялде, авырткан аягын җирдән күтәрә төште. Ни хикмәт, кешеләр арасында йөргәндә авыртуын яшерә, җиңә, авызлыклап тота ала ул. Менә хәзер, ялгызы калгач, шул ләгънәт йөгәннән ычкынды, аякны гына түгел, гәүдәнең дә сул ягын яулап алды, сызлау тирә-юньне, бөтен ишегалдын тутырды сыман. Баш әйләнә, күз аллары күгелҗемләнә, тәрәзәләрдән төшкән ут та кызгылт күренә. Кара син аны: көнозын тракторы белән басу тырмалады Котдус, югары очтан ни хәтле җир җәяү төште, ә менә хәзер капка белән өйалды баскычы арасын үтәр әмәл юк.

Көн дә шулайга китте әле соңгы вакытта.

Ул арада өйдән Хәернисасы чыгып җитте.

— Һай җанашым, җанашым минем! — дип өзгәләнде ул, үзенең борчу тулы күзләре белән иренә карап. Котдус абзый карчыгының йомшак, нык иңенә таянды, шунда күңеленә төер булып укмашкан сукранулары таралып, азрак күз аллары яктырып киткәндәй булды. Күрде инде, күрде инде аның белән Хәерниса да. Ни гомер, ничә еллар буена. Язмышы аңа шушы Хәернисаны бирмәсә, нихәлләр итәр иде ул?

Хәернисасы аны җайлап кына өйгә алып керде, өс-башын чишендереп алды. Аннан урындыкка утыртты да итекләрен салдырып алды, идәнгә алдан ук әзерләп куйган җылы сулы табагын китереп куйды. Котдус бармаклары киселгән аягын җылы суга тыкты, сызлау шунда ук чигенә төшкәндәй булды.

— Котдус дим, әллә җитәрме инде? Әллә, мин әйтәм, бу тикле азап чигеп йөрмисең генәме инде?

Хатынының көн аралаш биредә килгән бу соравына Котдус ни дип тә җавап бирмәде. Сүзне башкага күчерде:

— Малайлардан хат юктыр бит?

— Юк, — диде Хәерниса сулышы белән генә һәм, якынрак килеп, кулын иренең иңенә салды. Алар бер-берсенә сыендылар да, икесе берьюлы уллары стенадагы дәвәйтеп эшләнгән рәсеменә карадылар. Уллары Әхмәт белән Гомәр, офицер киеме киеп, барча авыл халкының күз явын алырлык булып кунакка кайткач, энеләре Ризванны да уртага алып, өчесе бергә фотога төшкәннәр иде. Офицер уллары — Котдусның үзе

төсле тәбәнәк буйлы, киң җилкәле, нык бәдәнле егетләр. Кара мыеклары сызылып киткән, күз карашлары житди, үткер. Ә соңгы еллар иркенлегендә бераз иркәләнеп үскән төпчек малайлары Ризван абыйларыннан байтак калку, зифа, елмаюы балаларчарак. Ата белән ана бу минутта икесе бер уйда иде: таралдылар... Хәзер инде әнә рәсемнәре дә, өй тулы сагыш, борчу гына торып калды. Бу дөнья дигәнең төрлечә шул. Кешенең балалары калада, завод-фабрикаларда, янсә авылда — бар да тыныч эштә. Ә аларныкы имин дип саналган шушы көннәрдә дә бик борчулы урыннарда. Үз хәлләрен үзләре генә беләләр инде... Хәерниса көрсенеп сулкылдарга да җыена барлаган иде дә, ире аны беләгеннән сыйпап, тыеп калды.

— Ризваннан да юк диген?

— Аннан да юк. Ул балакаем ни эшләпләр генә язмый торгандыр инде,— диде Хәерниса һәм яшьләнә башлаган күзләрен иреннән яшереп кенә өстәл әзерләргә кузгалды.

Чәчү өсте. Котдус басудан көн дә бик алҗып, өшәнеп кайта. Хәерниса итле токмач янына өстәлгә үзе генә белгән тәм-томнан койган әчемлек тә китереп куйды.

— Тамагың да кысылды соңгы вакытта. Әйдә, ашаганда гына булса да азрак онытылып тор әле!— дип, кунак сыйлагандай ирен кыстыйкыстый ашатты.

Аштан соң Хәерниса чиста җәймәләрен җәеп урын түшәде, аяк очына электр җылыткычын да көйләп куйды. Котдус абзый гадәтенчә күзлеген киеп, газеталар караштырды. Аннан телевизор каршысына килеп утырдылар. Экран яктырып, беренче кадрлар күренүгә, ата белән ана икесе бердәй авыр сулап, бер-берсенә карашып алдылар. Фәрит Сәйфел-Мөлековның «Егерменче гасыр Тәре йөртүчеләре» дигән фильмы башланып килә иде.

Мондый эш өстендә Котдус абзый, гадәттә, «Вакыт» программасын карау белән урынга ята, аяк җелекләренә җылы үтеп, сызлаулары басыла төшүгә, йоклап та китә иде. Бүген исә алай булмады. Сугышның башыннан ахырынача үткән солдатның тәмам күңелен кузгаткан иде баягы фильм. Үзенең йоклый алмыйча пошынып ятуын Хәерниса-сына белдертмәс өчен, Котдус абзый стенага таба борылып ятты. Әйе, җир йөзендә тагын хәтәр йөри, ай, зур хәтәр! Куәте бар империализмның, коралы чиктән ашкан. Солдатны да күп әзерли икән. Каһәр генә төшсен, әнә бит: экранда тагын шул фашистлар төсле җиңнәрен сызганып куйган кеше үтерүчеләр. Искәреп утырды Котдус, аларның йөз чалымнары, күз карашларына тикле нәкъ шул фашистларныкы: шәфкать дигән нәрсәнең әсәре дә юк аларда. Империализм штамплап чыгарган әзмәверләр. Адәм баласының җанын алып, аның урынына таш җан салып куярга булдыра ул империалистлар.

Күрде Котдус андый роботларны. Сугышта ул разведка взводында хезмәт итте. Бервакыт егетләр, төнлә дошман тылына үтеп, бер немецны эләктереп кайттылар. Иртән, завод командирына сорау алырга алып килгәндә, бернидән курыкмыйча сызгыра-сызгыра атлаган немец, ишегалдындагы җигүле атның ыңгырчагын рәтләп, муеныннан сөеп үтте. Ефрейтор погоннары таккан, озын буйлы, салмак адымлы, дәү куллы бу немецның армиягә кадәр гап-гади бер крестьян булганы әллә кайдан күренеп тора иде. Ул әле атка, әле Котдуска карап, хуҗаларча усал тавыш белән үз телендә ниндидер киңәшләр дә бирде.

Командир янына кереп унбиш минут та үтмәгәндер, баскыч төбендә сакта торган Котдусны сискәндереп, өйалды идәне сайгаклары дөбердәде. Взвод командиры Петро Корнейчук, ачуыннан кып-кызыл булып, немецны якасыннан бөтереп тоткан хәлдә, баскычка алып чыкты.

— Эшен бетер бу хәшәрәтнең. Хәзер үк. Әнә сарай стенасы. Шуңа терә дә ат!— дип кычкырды ул Котдуска.

Мондый әмердән яшь солдат шулкадәр курыкты, хәтта йсрәге кага башлады, тез буыннары йомшап калды. Әле сугышның башы гына, әле Котдусның бер генә дошманга да якыннан атканы юк иде. Аңа, авылда үскән садә күңелле егеткә, кеше үтерү гайре табигый, башына сыймаслык коточкыч бер нәрсә иде. Аннары бит немец хәзер куркынычлы дошман да түгел, ә коралсыз әсир генә. Котдусның үзеннән күп булса икеөч яшькә олы бер крестьян. Өендә яшь хатыны, бәлки баласы да калгандыр. Һәм Котдус ничек тә булса бер җаен табарга тырышып карады:

— Иптәш командир, аны эзләп егетләр төне буе йөрде... Севастьянов авыр яраланды.

Петро ачудан аларган күзләрен акайтып карады.

— Нәрсә җырлап торасың син миңа, ә?!— диде ул.— Әллә шушы этне җәлләп маташасыңмы? Җәлләмә син аны, солдат! Берни белми бу бүкән, белсә дә әйтә торган түгел. Фашистның да фашисты бу.

— Иптәш командир, штабка җибәрик алайса. Үзем илтеп тапшырам!— диде Котдус, башына мондый уй килүгә шатланып. Ул бу фашистны атып егасын һич тә күз алдына китерә алмый иде.

— Ярый, Сәлимов, тыңлап тор алайса,— диде командир, ярсуын көчкә тыеп.— Хәзер мин аннан: «Син-крестьян, син безгә каршы, үзең кебек үк эшче-крестьяннарга каршы ни өчен корал күтәрдең?»— дип сорыйм. Ә син карап тор, яме!— диде һәм әсиргә тегенең үз телендә ниләрдер әйтте.

Шунда фашист, атны күзәтеп торган җиреннән, кисәк уклау йоткандай, сынын турайтты, аларга карады. Башын тәкәббер тотып, шундый җирәнү, зәһәрле ачу, түбәнсетү белән карады ки, Котдус калтыранып куйды.

— Сез... житлекмәгән адәмнәр! Минем фюрерым сезне бу дөньядан себереп түгәргә кушты. О, без, бөек рейх солдатлары, фюрерның бу приказын үтәячәкбез!— дип акырды немец, ятлап куйганны кабатлагандай, һәм Котдуска ымлады.— Ә син, азиат, минем колым булачаксың. Минем итегемне чистартып көн күрәчәксең. Син шуннан бүтәнгә яраклы түгел!

Аннан соң да байтак күрде ул немецларны. Алар Гитлер котырыгына тәмам бирелеп беткәннәр, аны үзләренең алласы итеп күтәргәннәр, безне кол итү, кырып бетерү хокукына иман китергәннәр иде. Юк, иң элек халык күңеленә агу салмый торып, мондый яуга чыгып булмый. Үткән сугышның шулкадәр зыңкарлы, чиктән тыш рәхимсез булуына, озакка сузылуына да нәкъ менә шушы хәл сәбәпче. Әгәр ул вакытта немец халкының башы артка борылмаган булса, бер Гитлер белән аның генераллары гына ни торыр иде?

Газеталарны бик карап бара Котдус. Хәзер менә Америкада шул галәмәт. Хәзер анда халыктан безнең үткәнне, бүгенгене, тарих хакыйкатен яшерәләр. Гади америкалының күңеленә Россия халкы мәхлук дигән оетκы салалар. Янәсе, алар өстенә бер-ике атом бомбасы ташлау, аларның яртысын кырып бетерү әллә ни гөнаһ эш түгел.

...Уйлар, җиргә сызылган буразналар сыман, бер-берсенә ялгандылар. Бу төннең байтак өлешен йокламыйча үткәрәсен белә иде инде Котдус абзый. Күңеле бер купты исә, сугыштан әйләнеп кайта алмаган авылдашлары, сөлектәй егет көе соңгы сулышларын алган сугышчан дуслары күз алдына килеп баса. Алар гүяки бер сафка тезеләләр, карашларын Котдуска текиләр. Алар бер сүз дә әйтмиләр, тик кырыс итеп, таләпчән итеп карап кына торалар. Әле аның кордашлары Әхмәт белән Гомәрне генә алыйк. Игезәк булсалар да, бер-берсенә охшамаганнар. Әхмәт олы гәүдәле, юаш, салмак, гел елмаеп кына тора. Гомәре тәбәнәк, йомры, күзләре ут чәчә. Әле малай чакта ук нинди генә әкәмәтләр күрсәтмәде алар авылда. Тимердән педаль бөгеп, иске сабан тәгәрмәчләреннән автомобиль ясау дисеңме. Төрле тимер кисәкләреннән,

магниттан радиоалгыч ясап, аны сөйләтеп, бөтен авыл халкын шаккатыру дисеңме. Кыш көне кардан ныгытмалар, шырпы күкерте салып ата торган пистолетлар... Авыл яшьләре гел алар янында кайнаша иде. Икесе дә зирәк акыллы, киләчәктә зур кеше буласы егетләр иде алар. Менә сугыш дигән нәрсәнең зәхмәтен кара син: шундый егетләрнең башын адәм актыгы бер немец ашады. Мәскәү астындагы зур авыл өчен атакага барганда, флангта посып калган бер фашист пулеметчысы аларның ротасын бөтенләе белән диярлек кырып салды. Әхмәт белән Гомәрнең җансыз гәүдәләрен үзе күтәреште Котдус. Игезәкләр икесе янәшә диярлек яталар, күзләре ачык, ул күзләрдә авылның зәңгәр күге, сөелмәгән ярлар сагышы, эшләнмәгән эшләр үкенече, фашизмга ләгънәт күрде ул. Фронттан исән кайтып, уллары булгач, аларга Әхмәт һәм Гомәр дип исем кушты.

Аларның якты истәлеген онытырга ярыймы соң?! Котдусның инде алтмыш яшенә җитеп килгәндә, яралы аягын сөйрәп, хатыны, авылдашлары сүзенә колак салмыйча әле һаман тракторда эшләп йөрүе дә шулар истәлегенә. Алар бит эшләп ару бәхетен татымый калды. Әгәр куәтеннән килсә, аларның барысы хакына да җирен сөрер, игенен үстерер иде Котдус. Авылдашлары да, Хәернисa да менә шушыны төшенеп бетерми. Моны аңласа да аның үзе кебек фронт тәмугын үткән кеше генә аңлар.

...Котдус абзый караңгы өйдә үзалдына көрсенеп, гаҗәпләнеп ятты. Сугышта адым саен сагалаган үлем, кан, һичкем аңлатып бирә алмаслык могҗизага да урын бар. Менә ул үзе Мәскәү яныннан кузгалып, Берлинга кадәр диярлек барып җитте. Аңа фашистлар ничәмә тапкыр хәнҗәр кададылар, йодрыклары белән суктылар, дагалы итекләре белән типтеләр, хәтта берсе кулындагы котелогы белән сугып, яңак сөяген урыныннан чыгарды. Ул ничәмә тапкыр госпитальләрдә ятты, тик берсе дә пуля тиеп яраланудан түгел. Җан дуслары Гошаны, Николайны, командиры Петроны үз куллары белән җирләде. Ә менә үзе исән калды. Дүрт ел үлем белән йөзгә-йөз йөреп! Хәтта соңгы яралануы да разведкада түгел, ә блиндажда ял итеп ятканда, ябык ишекне җимереп кергән снаряд шартлавыннан булды. Адашып килгән снаряд кыйпылчыгы сул аягының бармакларын, итек башы белән бергә өзеп алды...

Котдусның ярасы авыр түгел иде. Тик шулай да аны дәвалаган карт хирург, госпитальдән чыкканда, кисәтеп куйды:

— Син, солдат, киләчәгеңә әзер тор. Бу аягың үзен сиздерми калмас әле...

Авылга кайткач Котдус шуны белде: фронтка киткән унҗиде кордашы арасыннан ул авылга берүзе әйләнеп кайта алган икән. Унҗиде егеттән берәү! Ул елларда авылда иң кирәкле кеше механизатор иде. Һәм Котдус, солдат гимнастеркасын салып та тормыйча, тракторчылар курсына барып керде.

— Булмый бу аягыгыз белән. Сезгә бөтенләй бүтән, җинел эш кирәк,— диделәр аңа комиссиядә.

Юк, берәр җирдә каравыл тора яисә кәнсәләрдә счет төймәсе тартып утыра алмый иде Котдус. Бу аның һәлак булган күпме кордашлары, сугышчан дуслары истәлегенә хыянәт итүе булыр иде.

— Мин — разведчик. Булмас дигәнне дә булдырып күнеккәнбез. Аягыгыз мине! Юкса, әнә үзем өйрәнәм дә эшлим,— диде ул. Күкрәге орден-медальләр белән тулы фронтовик сүзенә каршы килә алмадылар.

Байтак еллар буена әллә ни борчымады яралы аяк. Котдус өйләнде, балалар үстерде, үз-үзен аямыйча эшләде.

— Әгәр ходай куšып исән калсаң, син бу дөньяда безнең өчен дә яшә, безнең өчен дә эшлә!— дип васыять иткән иде аңа дусты Петро үзенең соңгы сулышында.

Менә Хәернисасы дөнья бәһасы кеше, фәрештә җанлы хатын булып чыкты әле. Ул аның яралы аягын йомшак бәти тиресеннән оекбаш

тегеп кидерде, оекбаш очына, бармаклар торасы урынга мамык түшәде. Эштән кайтышына иренең итекләрен үзе салдырып алды, аягын карап, төпченеп кенә торды. Аз гына кызару, ялкынсыну күрде исә, май сөртте. Ул майларны эзләп Әтнәсенә, Казанына да йөри, врачлар белән дә сөйләшә, киңәшләр сорап хатлар алыша, китаплар табып укый иде Хәерниса. Котдус үзе дә хатынын мактап туймады.

— Син, карчык, үзең чын доктор бит. Син барында дипломлы врачларың бер якта торсын.

— Һай, әгәр яшь чакларым булса кана. Ике дә уйлап тормас идем, врачлыкка гына укыр идем,— диде хатыны.

Берчак ул яңа нәрсә уйлап чыгарды:

— Син Котди, болай итеп бак әле. Тракторыңа кереп утырдың исә, бу аягыңнан итегеңне салып куй. Аякны аны итек кысанлый, шул ардыра. Педалеңә дә оекбаш белән генә бас, аның өчен мин аслыкка калын күн тектем. Җәлләп йөрмә, монысы тузса, икенчесен тегеп бирәм.

Котдус шулай эшләп карады һәм хатынының зирәклегенә хәйран калды. Кабинага кереп утырып, итекне салып куюга, аның эчендә сыкрана башлаган аяк иркен алып, рәхәт булып китә иде. Аның бер итеген янәшәсенә куеп, оекбаштан гына йөрүенә иптәшләре дә иямәнеп киттеләр. Хабил, бик мәзәкчән кеше, бу хакта шаяртып та ала иде.

Тик менә соңгы елларда карт хирургның әллә кайчан әйткән сүзләре дөрескә чыкты. Иртәнге якта әле ярый, әмма көн азагына таба аяк бик каты итеп, кисеп-чәнчеп сызлый башлый. Кайчак авыртудан тракторчының хәлләре китә, күз аллары караңгылана. Әле былтыр көзлектә, зәп сөргәндә ул өч кешелек звеноның башында барган җиреннән тракторын туктатты. Кабинадан төшеп, җиргә сузылып ятты. Азрак хәл алмыйча булмый, юкса һуштан язуың да бик ихтимал иде. Гаяз белән Хабил, икесе дә яшь, таза ирләр, аның янына килеп җиттеләр. Хабил кабинаны ачып нидер эзләнде, иснәнеп йөргәндәй итте. Аның бөтен нәрсәне мәзәккә аудару гадәте бар иде.

— Әллә Котдус абзый бездән яшереп кенә салгалап йөри инде шунда,— дип сөйләнде ул, аның янына чүгәләп. Ярый әле Гаяз Котдусның хәлен аңлап алды. Өстендәге сырмасын салып, аның сырхау аягы астына түшәде.

— Безнең Котдус абый аяк дип тә тормый инде ул. Әллә геройга тартмакчы була инде шунда,— дип, ярага тоз салуын дәвам итте Хабил.

Бу сүзгә Котдусның җен ачулары чыкты, күңеле актарылды. Тик моны яшьләргә күрсәтү мәгънәсез, ничек тә үзеңне тыярга кирәк иде.

— Сез инде, егетләр, үтә торыгыз. Мин үз җаем белән кузгалырмын,— диде ул.

Икенче көнне аның янына колхоз председателе Фәезхан үзе килде.

— Син инде, Котдус абзый, безнең легендар тракторчы. Мин белгәннән бирле. Рәхмәт сиңа! Әгәр хәзерге көндә сиңа авыр икән, бер дә уйлап торма. Теләсәң әнә механик, теләсәң бригадир итеп куям мин сине,— диде Фәезхан һәм әле былтыр гына алып кайткан куәтле тракторны әйләнеп чыкты. Котдус аның тел төбен бик аңлады: техниканың рәтен белгән һәм исәпчел председатель мондый куәтле машинаның инвалид кулында булуыннан бигүк риза түгел иде.

Дөресен генә әйткәндә, председатель хаклы, бу турыда Котдус үзе дә күптән пошынгалап йөри. Инде мондый сүз дә ишетелгәч, ул хәл итте дә куйды:

— Фәезхан, сиңа сүзем бар. Теге гамәлдән чыгарга куйган ДТны бирегез миңа. Шуны үзем төзәтәм дә, үзем эшлим.

Председатель чын-чынлап аптырашта калды:

— Ни сөйлисең син, Котдус абзый?!

— Менә шундый уем бар иде, Фәезхан. Шундый үтенечем. Син инде каршы килмә.

һәм ул яңа тракторын әле генә укып кайткан яшь егет Фердинандка бирде. Үзе, атналар буе янынннан китмичә, иске тракторны сүтте, хасиятләп җыйды, анысын-монысын яңартты. Буяп та җибәргәч, ярыйсы гына булды тагы иске машина. Аны мастерскойдан чыгарганда шундагы бар халык җыелды. Бәхеткә күрәдерме, ул көнне колхозга, фотоаппаратын күтәреп, район газетасыннан бер егет тә килгән иде. Тракторы янына бастырып, Котдусны рәсемгә төшереп алды. Аннары газетада рәсеме белән янәшә «Ике тапкыр ветеран» дигән мәкалә дә чыкты. Берәүләр Котдусны котлады, икенчеләр бер сүз дә әйтмәде, ә Хабил исә яңача итеп сәлам бирде:

— Салют, ике тапкыр ветеран!

Халыкка үпкәли алмыйсың, бу кушамат Котдуска ябышты да калды. Кем белә, бәлки, аны кайберәүләр киная белән дә әйтәдер. Әмма бу «ике тапкыр ветеран» нәрсәсе беләндер күңеленә якын аның.

...Шулай уйланып яткан җиреннән үзалдына уңайсызлана калды Котдус абзый. Инде төн урталары җитеп киләдер, ә ул, карт тиле, әле һаман да үзен генә кайгыртып ята. Инде ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, дигәндәй...

Әнә стенада аның өч улы. Өчесе дә солдат, аларның һәркайсы өчен үзенә аерым борчыла ата йөрәге. Һәркайсы аның бәгыреннән бер өлеш, һәркайсының беренче тапкыр елмаеп көлүе, сөйләшә башлавы, нәни тәпиләре белән атлап китүе, хәтта чәчләренең исләренә кадәр аның хәтерендә. Бала турында күбрәк әни кеше кайгырта дип, хаталана кайберәүләр. Бала ул анага да, атага да бердәй газиз... Әхмәте белән Гомәре, хәрбилекне үзләре теләп, гомерлеккә сайлап алдылар. Икесе дә бер үк училищены бетерде, икесе дә офицер, икесе дә төньякта, су асты көймәсендә. Ел саен җәйләрен икесе бергә туры китереп, өй тутырып кунакка кайталар. Андый-мондый хәл була калса, аларның ил өчен беренче калкан икәнлекләрен белсә дә, ата күңеле тыныч иде. Акчаны шәп алалар, киемнәре, дәрәҗәләре дигәндәй. Өстәвенә Котдус, гомерен авыр хезмәттә үткәргән кеше, аларны әллә ни авыр көн итәләр дип санамый иде.

Тик шулай да былтыр җәй Әхмәт яхшы ук сиздереп китте. Гомәре балалар белән көнозын Ашыт суында балык каптыра, ә Әхмәт ындыр артындагы хәтфә чирәмлеккә чыгып чалкан ята да, сәгатьләр буена күккә карый. Аяз күкме, болытлымы, аңа барыбер. Бервакыт Котдус көлеп куйды.

— Ни күрдең әле анда ул чаклы?

— Ә беләсеңме, әткәй, шушы болытлардан да матур әйберне бу дөньяда белмим мин. Бер башыңны күтәреп кара әле син шуларга.— Котдус карап алды. Болытлар тек болытлар.— Ни эшлисең, шулай кирәк әле. Безнең шундый хезмәт тә кирәк.

Олы уллары укалы погоннары белән тигез тешләрен күрсәтеп, елмаешып Котдусның күңел күзеннән үтеп тә киттеләр. Алар артыннан шундук сылу буйлы, аксыл йөзле, бала елмаюлы төпчеге-Ризваны калыкты. Урта мәктәптән соң әнисе дә, Котдус үзе дә аны укырга өндәмәделәр. Әгәр институтта укып йөрсә, аның да йортны калдырып авылдан китәсе көн кебек ачык иде.

— Син инде, улым, үз янибызда калырсың. Менә минем кебек иген игәрсең. Нәселдән берәү җирдә торып калырга тиештер бит,— диде Котдус.

Ризван үзе дә абыйларыннан үзгә, йорт җанлы, юаш, кыюсыз егет булып үсте. Авылны, басу-кырларны яратты. Котдус аны малай чагыннан ук үзе белән басуга алып йөрде. Армиягә киткәнче егет бер ел тракторда эшләде.

...Котдус абзый авыр сулап куйды. Армиягә киткәнче шулай булды... Менә исән-сау гына әйләнеп кайтамы әле. Ул илебезнең көньяк чиген-

дә хезмәт итә... Абзый шунда, нәкъ үзенекедәй авыр сулау ишетеп, сискәнеп китте. Караса, Хәернисасы да йокламый ята икән.

— Син ни тагын, карчык?

— Ризван... шул балакаемны уйлап ятуларым.

Котдус абзый Хәернисасын юату өчен күңеленнән сүзләр эзләде. «Солдат ул — һәрчак солдат. Аңа антына тугры булырга дигән. Ни генә булса да, минем улым сынатмас. Нәселебез намусына тап төшермәс безнең улыбыз». Тик хатынына бу сүзләрнең берсен дә әйтмәде. Үзенекен уйласын, тиешлесен кайгыртсын әйдә. Шунсыз күңел дигән нәрсә барыбер тынычлык тапмый ул.

Икенче көнне Котдус абзый басуга бераз соңарып барды. Ул инде звенода эшләүче егетләрне тоткарлаудан уңайсызлана, елга-ерымты буйларын ялгызы гына эшкәртә иде. Ялгызы, ашыкмыйча гына, норманы кумыйча, вәземләп, җирнең тәмам үзгенә утәрлек итеп, күңеленә ошамаган урыннарны кат-кат әйләнеп эшли ул. Шулай җай гына йөреп торганда, төш вакыты җитәрәк, ул басу юлыннан ашыга-йөгерә килгән бер хатынны шәйләп алды. Күңеле дерт итеп куйды, Котдусның маңгаена тир бәреп чыкты. Аның Хәернисасы ашыга, аяк атлауларыннан ук борчулы икәнлеге күренеп тора иде.

Трактор тукталуга Хәерниса, хәле китеп, радиаторга сөялде. Яулыгы астыннан чәчләре чыккан, күзләре бер ноктага текәлеп хәрәкәтсез калган, иреннәре дерелди иде. Котдус абзый кабинадан төште, ни дип сүз башларга белмичә, ни дә булса сорарга кыймыйча куркып калды. Хәернисаны да хәсрәте өнсез иткән, ул да сүз башламый иде.

— Ризван?..— диде Котдус абзый, ниһаять.

— Ризваным... шул балакаем...— дип пышылдады Хәерниса һәм бөгелеп төште. Карт солдатның күкрәгеннән авыр сулышы белән бергә сорау да атылып чыкты:

— Нәрсә?! Ни булган?

— Госпитальдән хаты килде...

Шунда һич көтелмәгән хәл булды. Котдус абзый тиз генә аягына басты, абына-сөртенә Хәернисасы янына килде һәм аның җыерчыклы маңгаеннан үпте.

— Тилердеңме әллә син, карт?— диде тегесе, ни уйларга белмичә.

— Тилердем!— диде Котдус абзый, елмаеп.— Соң, дивана булмасаң, син ни дип бу кадәр коелып төштең әле? Мин тагын монда әллә ниләр уйлап бетердем. Яралы тек яралы. Ярасыз солдат нинди солдат була ди ул... Давай, торма сөмсерең коелып. Барысын да юньләп сөйләп бир!

Һәм алар ызан буена чыктылар. Яшь вакыттагыча, бер-берсенә сыена төшеп, янәшә утырдылар. Бу минутта сөйләшәсе сүзләре, бергәләп уйлыйсы уйлары күп иде шул аларның.

# Нияз Акмалов

## Җыр елгасы

Еллар-чорлар буе кешеләрнең
Сусауларын баскан шушы моң...
Җыр елгасы! Синең ярларыңа
Мин дә бүген килеп кушылдым.
Туган якның изге туфрагыннан
Саркып чыккан чишмә идем мин.
Имәдем мин башны тау-ташларга,
Сиңа килеп башым идем мин.
Челтер-челтер чылтырап аккан чакта
Төпләремдә ятты ак ташлар.
Таң чыклары тамган суларымны
Үрелә-үрелә эчте якташлар.
Үзәннәрнең сере сеңде миңа,
Көче күчте язгы күкрәүнең.
Юлларыма ташлар төшкән чакта,
Шул көч белән җиңде күкрәгем.
Ярсу чакта үзем җырладым мин,
Талгын чакта моңнар тыңладым.
Туңып тордым кайчак, тонып тордым,
Тынып тордым,— әмма тынмадым!
Җыр елгасы! Ерак юллар аша
Дәште мине синең тавышың.
Еллар мине бераз салмак итте,
Тирәнәйде ләкин агышым.
Үзәгеңдә синең аксам да мин,
Каксам да мин ярга моңымны,—
Туган якның көмеш суы белән
Көчәйтергә тиеш агымыңны.
Җыр елгасы! Синең ярларыңда
Диңгез киңлекләре тиң безгә.
Гомер буе мин дә, җырлый-җырлый,
Аксам иде шулай диңгезгә...

## Сил ташы

Хәтер түбәсендә ята ул таш.
Ялгыш кына тисәң дә әгәр —
Гомерләрнең шушы үрләреннән
Иң түбәнгә кадәр тәгәрәр.

Текә таулар шулай ишелер дә,
Текә ярлар шулай ишелер.
Сил кузгалса, ташлар актарыла...
Безнең хәтер шуның ишедер.
Бер таш кирәк кайчак кузгатырга,
Бер сүз кирәк кайчак әйтергә,—
Өстә калган — истә генә йөри,
Күмелгәннәр кайта хәтергә.
Хактырмы ул: тауда сил ташына
Кагылмаска дигән ырым бар.
Сил кузгалса, калка — калыкмаска,
Кагылмаска дигән урыннар!
Сил кузгала — йөрәк телгәләнсә,
Сил кузгала — җанга моң тулса.
Минем хәтер ятлар өчен хәтәр,
Дуслар җанына кагылыр моң булса.
Бер таш кирәк кайчак кузгатырга,
Бер сүз кирәк кайчак әйтергә...
Хәтеремдә минем сил кузгалды.
Кем кагылды минем хәтергә?!.

## Гармунчы Әүхәт

Ул урамга чыкса...
Ә ул шулай
Бер мәртәбә чыга елына.
Ул урамга чыкса — карлар эри,
Ташу китә, дөнья җылына.
Ул үзе дә бераз «җылынып» чыга,
Салып чыга иңенә гармунын.
Ул урамга чыкса, халык белә:
«Әйтер сүзе, брат, бар моның!..»
Айлар буе җигелеп эшләп йөргән
Әүхәткә бу бераз ят сыман:
Ул урамга чыкса, тугарыла,
Тәртәләргә сыймас ат сыман.
Ул урамга чыкса, халык белә
Кай тирәгә барып җыеласын.
Кемдер курка: «Җитәр, җырламасын!»
Халык әйтә: «Тыйма! Җырласын!..»
Гармун тартып такмак әйтә Әүхәт:
«Кемдер ун ел клуб салдырган.
Ун ел буе клуб салдырган да,
Түбәсен бит япмый калдырган!..»
Әйтә Әүхәт: «Туннар, толыпларның
Кирәге дә инде гел беткән:
Янгын каланчасы янган чакта
Котыпларга кадәр эреткән!..»
Әйтә Әүхәт, әйтә: «Атлар беткәч,
Бушап калган икән улаклар.
Оҗмахларда, солы түгел, хөрмә
Ашап яши икән ул атлар!..»
Кемдер көлә, эчен тотып көлә,
Көлгәнгә ул көлке көлкесен...
Берәү әйтә: «Әүхәт!— ди ул.— Брат,
Чамалап әйт, әйтсәң, түлке син!»

Ә Әүхәтнең кемгә исе китсен,
Карап тормый Әүхәт як-ягын.
Әйтерсең лә гармун тавышлары
Хуплап тора аның такмагын.
Ул туктаса, халык кабат сорый:
Әйт әле, әйт, берәр мәртәбә?!.»
Олы картлар ияк сыйпап тора:
«Белеп тибә бу,— дип,— тәртәгә!»
Җырлап китә Әүхәт авыл буйлап,
Такмак сибеп урам юлына.
Ул урамга чыкса...
Ә ул шулай
Бер мәртәбә чыга — елына.

## Авыл туе

«Ачы!..» диеп мең кычкырды халык,
Кабатлады аннан тагын да.
Тәм-томнарның ачысы да иде,
Төчесе дә иде табында.
Туйлар булгач, әйтер сүзе була...
Әллә кызга, әллә кияүгә:
«Бер күтәргәч, кире куйма!» диеп,
Әйтеп салды берәү киная.

Теләкләре шулай изге булгач,
Бу касәләр нигә тулмасын?!
«Калган ашы ачы булса булсын,
Тамган яше ачы булмасын...»
Таң алдыннан таралышты туйлар.
Ябылганда соң кат ачылып,
Күгәнендә биеп йөрде ишек:
«Таралмагыз!.. Һаман «Ачы!..» дип.

## Нәҗибә апа

Юлларыңа чыгып каршылыйммы,
Тезләнимме алларыңа чыгып?
Эре генә үтеп китәрсең күк:
«Йөрмә әле, энем, эч пошырып...»
Нәҗибә апа! Күрше апам минем!
Нәҗибә апа — сере балачакның!
Малай чакка кайта алсам әгәр,
Синең арттан карап калачакмын.
Капка ачып кала идем сиңа,
Кала идем үзем читтә качып.
Көн аралаш безгә керә идең,
Зәңгәр көянтәңне иңгә асып.
«Чишмә суларыгыз беткәндер лә,

Мәчтүрәттәй, бирче чиләкләрең?..»
Әбекәйнең суы көн дә бетсен —
Тик шул иде минем теләкләрем.
Нәҗибә апа! Судан кайтуларың!
Өзелеп-өзелеп кала иде билең.
Койма башларыннан төшмәс идем,
Күзләремне синнән алмас идем!
Күреп алсаң, куып тота идең,
Кочып-кочып мине сөя идең.
«Авылыбызда бер тиң егет миңа —
менә шушы энем...» дия идең.
Унсигездә идең син ул чакта,
Үрти идең һаман үсендереп:
«Су китердем әле, Мәчтүрәттәй,
энекәем тизрәк үссен, диеп!..»
Үсендердең... Беркөн үкседем мин,
Җиргә ятып, иртән чык төшкәндә —
Сез икегез безнең утыргычта
Котдүс абый белән үбешкәндә...
Юандыммы битләремне юып,
Уяндыммы әллә мин дә сабый —
Сезнең туйда, кияү бүләге дип,
Исле сабын биргәч Котдүс абый?!
...Нәҗибә апа! Күрше апам минем!
Нәҗибә апа — балачакның сере!
Һәркемнең дә була унсигезе,
Һәркемнең дә була бердәнбере!
Мин авылга кайтсам, сезгә — кунак,
Балаларың көлә чырык-чырык,
Юлларыма чыгып каршылыйлар,
Каршылыйлар алларыма чыгып...

## Яшьлек җырым

Сулышымны әгәр дөрес алсам,
Җырларымда бер дә ялгышмам.
Гомерләрне кабатланмый диләр,
Кабатлана икән язмышлар.
Яңа яшьләр узса урам буйлап,
Яңа җырлар агыла алардан.
Яшьлек җыры агыла... Ул җырларның
Иң моңлысы синдер, и «Сарман»!
Бер киләдер яшьлек — иң зат чагы,
Иң мәгънәле чагы гомернең!
Бер киләдер гомер...
Бу гомерне
Мәхәббәтле ит син, и җырым.
Мәхәббәтле ит син, яшьлегеннән
Ваз кичмәсен икән берәү дә.
Мәхәббәте эзләп тапсын аны,
Өметләрен җуйган бер мәлдә...
Эзләп тапсын, күзләренә баксын:
«Мәхәббәтең синең — мин!..» диеп.
Зар елатсын, утка-суга атсын,
Тик әйтмәсен генә «Соң!..» диеп.

«Соң инде!..» дип кенә әйтмәсен ул,
Якласын ул һаман яшьлекне.
Йөрәгемнән сыкрау киткәне юк,
Күзләремнән генә яшь кипте...
Кемдер миңа яшьлек елларымнан
Яулык болгый Зәңгәр таулардан.
Яшьлек ярым — изге ярам минем,
Синдәй моңлы ярам, и «Сарман»!
Кемдер миңа йөгереп төшәр сыман
Шул тауларның текә ярыннан.
Һәм кычкырыр: «Мәңге аерылмам!» дип,
Таулар әйтер: «Инде... аерылган!..»
И өзелә былбыл — иреннәрдә
Туктап калса әгәр әйтер сүз —
Йөрәгендә йөрткән моңнарыннан
Һуштан язган бу, дип әйтерсез...
Яңа яшьләр уза, җырга салып
Мәхәббәтнең изге ярасын...
Җырым минем, күңелләргә түгел,
Язмышларга кереп барасың...

## Габделнур Сәлимов

### Кафедагы песи

Өстәл аяклары арасыннан,
итек йөзләренә орына-орына,
кафе гизә «сәяхәтче» песи.
Һәр ят олтан аңа — яңа дөнья!

Сары күзле пескәй, яле, килче,
бер сүз пышылдыймчы колагыңа:
итекләр бит яшь килерлек әйбәт!
Типкәннәре тибәр... болай гына.
Кысар ишек. Куар таш баскычтан
өстәл сөртүченең тастымалы.
Кичке карда, тәрәз яктысында
утыр, берүк ачуланма, җаный.

Кешеләр бит... яшь килерлек әйбәт!
Куаламый алар, уйный гына.
Ә син, пескәй, түз, түз — ачылыр ишек.
Берсе алыр сине куенына.

## Икәүдән икәү

Ачуымнан чатнап беттем, дисең.
Чатнамасын зинһар рух кынаң!
Чатнасаңмы?— һәрбер хаким затка
тотынырсың рәхмәт укырга.
Кем елмая, җөпләп елмаерсың.
Чәчәк атар куштан иренең.
Күзең ышыкка качар!— Ул урынга
пәрәвездәй сырлар өелер.
Үрмәкүчтәй күзең хөр сүз аулар.
Һәм көр кабым яулар!.. Ә менә
чәбәләнер кемнәрнеңдер җаны.
Тик син түгел... Күй, үпкәләмә,
ачулардан чатнау — чатнаумыни? —
Чатнамасын зинһар рух кынаң.
Чәбәләнгән олы затка — сиңа
бер көн килер, рәхмәт укырлар.
...Чатнамавың өчен!


## Ял көне шәһәр кибетендә йөрүче

Яңа кием алмам, ахры.
Ошамады бер төше...
Күзгә саен карап калды
зур күзле моңсу кеше!

Кая китте киемнәрне
сайламый-нитми кию?!
Кешеләр мине болай да
яратыр әле дию?!
Кая китте күзләремнең
чәчри, уйный торганы?
Миндәй зур күзле кешеләр,
ахры, моңсу буладыр...

Чү, нигә шаккаттым әле
җыен тәти киемгә?!
Мине сагына торганнардыр,
кайтыйм инде өемә.

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Уральск шәһәре, Почиталин урамы, 65 нче йорт. Әхмәтша Сираҗетдинов укыткан рус классы. «Мотыйгия» шәкерте Г. Тукай биредә (икенче катта) дәрес алган.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# Рахмай Хисмәтуллин



# ТАМЫРЛАР ТИБЕШЕ

ОЧЕРК

**Очеркист, публицист, шагыйрь Рахмай Хисмәтуллинга 50 яшь тулды. Түбән Кама шәһәрендә яшәп иҗат итүче Р. Хисмәтуллин үз әсәрләрендә заманның мөһим проблемаларын күтәрә һәм аларны тормышка ашыручы кешеләр язмышын матур итеп сурәтли алган иҗатчы буларак танылды. Аның китаплары кайнап торган тормышыбыз елъязмалары буларак укучылар хөрмәтен яулады. Язучыга күптән түгел «Татарстанның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде. Язучыга иҗат уңышлары теләп, укучыларыбызга аның яңа очеркын тәкъдим итәбез.**

Кинәт төн уртасында гигант берләшмәнең дистәләгән заводларында утлар сүнде. Бер, ике, өч минут... Ут тагын беразга гына кабынып алды да тирә-як тагын караңгылыкка чумды. Ун... унбиш... егерме минут үтте. Ут юк. Үле тынлык чорнап алган югары басым астындагы газ тулы йөзләгән реакторлар, ярсу «чабудан» туктап калган компрессорлар, насослар, эшченең күз-колагы булган приборлар арасында, шомлы шәүләләр таратып, анда-санда шырпы; фонарь һәм шәмнәрнең зәгыйфь утлары цехларга җан өрергә азапланды.

Беркайчан да булмаска тиешле хәтәр хәл иде бу. Алдан хәзерлексез тукталу катгый тыелган! Төнге посттагы эшчеләрнең, инженерларның җанын шом-курку өтте. Беркем берниндн инструкцияне, кагыйдә-тәртипләрне бозмаган, әмма югары көчәнешле электр линияләре, хәтта запаслары да янып чыккан иде. Моны берниндн техник нормалар белән дә аңлатып булмый иде. Көтелмәгән, билгесез нинди афәт соң бу?!

Җиде төн уртасында ике-өч сәгать буе утсыз «ут эчендә» кайнаган мәхшәрдән соң, ниһаять, таң атканда линияләрне яңабаштан тоташтыра алдылар. Үз постларында үтә сизгер торып арыган, талчыккан кешеләрнең йөзенә җан керде...

Инде баганалар, чыбыклар, подстанцияләр — барысы да энәсеннән җебенә кадәр тикшерелде. Ахыр чиктә электр чәйнекләренә утырган тузан юшкынына хәтле анализга озатылды. Һәм... аның мәкерле никельхромбарий тузаны икәнлеге ачыкланды. Бу катализатор айлар, еллар буена, установкалардан һавага очып, чәйнекләргә утыра килгән, ниһаять, үткәргечкә әверелеп, линияләрне яндырып аткан иде.

Никельхромбарийның ни икәне яхшы мәгълүм. Заводларда аны бушатканда цехлар өстеннән яшелләнеп зәһәр тузан болыты күтәрелә. Ул тузан атмосферада артып китә күрмәсен дип, күп кенә пунктларда һаваны тикшереп торалар. Зарарын җилкәсендә татыганнар инде кычкырып ук зарланалар:

— Космос заманында шул катализаторның да юньлесен таба алмаслар икән! Нигә шуның зыянсызын уйлап чыгармаска инде?

Бу ай-вайлар яңа катализаторлар эзли торган бер лабораториянең начальнигы Азат Зыятдиновның күңелен бигрәк тә нык җәберли иде.

Нишләмәк кирәк, катализаторлар химиянең тирән серләр дәрьясы шул. Миллион матдәләр арасыннан иң зарарсызын, иң активын, иң арзанын ничек эзләп табарга? Күпме сер.

Азат белә: кайдадыр, чит илдә ниндидер яхшырак башка катализатор бар. Бардыр... Ә нишләп әле без чит ил фирмаларына, гел аяк чалып торган ышанычсыз партнерларга бәйле булып торырга тиешбез?

Шул уйлар аны моннан берничә ел элек гаиләсен калдырып (рәхмәт Саниясенә — өч ел буе, эһ тә итмичә, зур түземлек белән гаилә йөген берүзе тартты!) — химия фәненең иң соңгы казанышлары тупланган Мәскәү химия-технология институтының аспирантурасына китергән иде.

Ачык йөзле, белемгә үтә дә хирес татар егетен, аның итагатьлелеген яраттылар анда. «Асылынсаң асылын агачның асылына» дигән юравы юш килде Азатның, аңа академик Кафаров үзе игътибар итте, идея-белемнәрдән математик модельләр төзеп, матдәләр диңгезендә йөзәргә өйрәтте.

Өч ел укып кайткач, яңа катализаторлар эзләп көне-төне сынаулар, озакка сузылган тәҗрибәләр уздыру, янып-көеп иҗат итүләр башланды. Хезмәткәрләр барысы да хатын-кызлар иде. Алар белән бергә күп борчуларга батып, зур түземлелек белән матдәләрдән нечкәдән нечкә бизәкләр чигәргә туры килде.

Ә бүлмәләрдә, цехларда, җыелышларда, үзара аңгәмәләрдә туган зарарлы юшкыннар нәтиҗәсендә төрле хәвефле очраклар турында кырыс Тормыш белән Вөҗдан сөйләшүе күңел түрендә эленеп торды.

ТОРМЫШ. Быел зарарлы калдыклар инеш-чишмәләрдә, чокыр-чакырларда гына калмыйча, Каманың үзенә чаклы ук төшеп җиткән. Балыклар һәлак булгалый. Кем гаепле икән моңа?

ВӨҖДАН. Барыбыз да! Без, төнге сменада эшләүчеләр, карап торучы, күрүче юк дип, үзебез кран-задвижкаларны ачып, әнә шул зарарлы калдыкларны канализациягә агызып җибәрәбез. Яшерен үлем элмәген үзебез үк ясыйбыз.

ТОРМЫШ. Тыю чарасы да бар инде, югыйсә. Әнә генераль директор планерка саен шуның өчен кызган табага бастыра. Дәүләт комиссияләре штрафлар сала. Шул җитми микәнни соң?!

ВӨҖДАН. Дөнья куабыз шул. Эз генә дә тукталып уйланырга вакытыбыз юк.

Азат белә: вөҗдан йокласа, берниндн ачулану, берниндн штрафлар ярдәм итмәячәк. Ә болай ваемсыз барсак, соңга калуыбыз да ихтимал... Булсын иде бу урман кисү янсә таш вату сыман бер физик эш, урып-кырып кына ташлар идең.

Тукта, таянырга нокталар бар ич. Дөньяда битараф рәвештә көне-төне җир шарының яшәү бәгырен кимерүчеләр генә түгел, ә вөҗданын тормыш ваклыклары йотып бетерә алмаслык, табигать турында туктаусыз инстинктив борчылу кичерүчеләр дә күп ич!

Шуларны эзләргә, табарга, шулар белән кулга-кул тотынышырга, җир бәгърен саклыйк дип нәбат сугарга!

Мәгаен, кешеләргә табигать үзе бүләк иткән туган телендә чолтерәп аккан саф көмеш сулы «Җидегән чишмә»ләрне җырлап дәшәргә кирәктер. Табигать һәм кешелекнең серле бәйләнешләрен ачарга тырышкан әдипләрнең җылы сүзләре белән назлап, күңелләрдәге уй-моңнарның иң тирәндәгесен уятырга иде!

* * *

...Ул сәхнәгә бүген аеруча балкып чыгып басты. Бүген «Җидегән чишмә» әдәбиятсәнгать клубы үзенчәнлеге Казанның тезүчеләр культура сараенда чыгыш ясый. «Гомәр Бәширов иҗаты турында сөйләү өчен техник фәннәр кандидаты Азат Зыятдиновка сүз бирелә»,— диделәр. Залдан кызыксыну дулкыны узды. «Ничек алай? Техник фәннәр һәм әдәбият? Шулай да була аламыни?..»

Моңарчы шәһәрдә «Кама таңнары» дигән әдәби берләшмә күп еллар буена әдәбимузыкаль кичәләр үткәреп, матур гадәткә нигез салынган иде. Әмма һәр тырышлыкның чиге бар дигәндәй, энтузиастларга бу эшне үзлекләреннән генә тартуы ифрат авыр: кунак килә калса, аны аэропорттан алып кайту өчен транспорт таба алмыйча иза чигәләр. Энтузиастларның хәлләре китеп, рухлары сынган чаклар да булды. Шулай итеп, кыенлык белән туган традициянең сүнеп баруын беркем дә күрмәс микәнни?

Күрде, берәү күрде! Һәм ул Азат Зыятдинов иде. Чөнки максатлар уртак: кеше күңеле һәм табигать!

— Туктагыз әле, егетләр! Нишләп соң сез һаман үз казаныгызда гына кайныйсыз?! Илкүләм олы эшләр башкаручы нефтехимикларга бик кирәк бит сез. Алар белән кулга-

кул тотынырга, материаль базага таянырга, әдәбиятны-җырны хезмәт кешеләре белән бәйләргә кирәк сезгә!

Башта «Җидегән чишмә» дигән матур җыр исеме астында бергәләп берничә сынау кичәләре уздырылды. Заллар шыгрым. Бөтен шәһәр шул турыда сөйләде.

Хыялны чынбарлыкка әйләндерүче — Азат иде. «Җидегән чишмә»гә килүе планлаштырылган Казан әдибенең күңел тәрәзәсен иң беренче булып ул шакыды. Хатлар язды, кунакны килергә кирәклеккә ышандырды, иҗат эшләреннән аерып, юлга кузгатты.

Кичәләр бер ел буена шаулап-гөрләп барганнан соң, Азат Шәймуллович, ниһаять, берләшмәнең партком секретаре Илкам Зөфәрович Мортазин янына керде. Секретарьның да тальянда уйнарга, җырларга бик яратуын, әлбәттә, ул белә иде. Сөйләшү дә җылы гына башланды.

Әллә нинди кеше ул Зыятдинов. Үзе синең дә җегәреңне арттыра сыман. Һәм нинди йомыш белән керсә дә, үтенечен әйткәндә, күзеңә туры карап, чигенергә урын калдырмыйча бастырып әйтә. Син аңа ышанасың, аның үтенечен кире кагуы кыенлаша. Чөнки ул, үзе өчен йөрүнең ни икәнен дә белмичә, һәрвакыт җәмәгатьчелекне борчыган үзәк мәсьәләне күтәрә.

— Менә шул «Җидегән чишмә»не,— диде ул секретарьга әйтәсе сүзен дәвам итеп,— нефтехимиклар канаты астына алырга иде бит. Әйтик, теге «Дискоцентр»да түләүле хезмәткәрләр тоткан кебек. Мәсьәлә әлегә хәл ителмәсә дә Мортазин бу сөйләшүдән соң «Җидегән чишмә»гә йөри башлады. Тора-бара ул «Җидегән чишмә»нең иң ялкынлы яклаучысына әйләнде.

— Куанырлык яңа форма бит бу, егетләр. Беренчедән, кешеләребездә нечкә зәвык тәрбияләсә, икенчедән, бәлки, шулай язучылар белән аралаша торгач, кем белә, безнең проблемалар турында да әдәби әсәрләр туар,— диде ул.

Шәһәр җитәкчеләре дә «Җидегән чишмә»дән читтә калмадылар. Фатих Кашапович Котдусов, Хезмәт ияләре депутатларының шәһәр Советы Башкарма Комитеты председателе урынбасары буларак, эшем муеннан дип тормыйча, (үзешчән сәхнәләрдә гөрләп узган яшьлегеннән аерылырга теләмәүчеләр бар бит ул!), бик кирәк чакларда дикторларың көнләшерлек саф матур дикцияле күкрәк тавышы белән ягымлы тәбрикләп, кунакларның җанын эретә белде, кичәләрнең икенче өлешендәге халык уеннары мәйданы уртасына үзе кебек үк чая биюче, җырчы, нәфис сүз остасы хатыны Фирания белән парлашып, мөлаем елмаеп, чәчрәп сикереп төшеп биеделәр.

«Җидегән чишмә» эшенә олпат аксакал, генераль директор урынбасары Мәсгут Сибгатовның да дәртләнеп килеп кушылуы аерым бер җанлылык кертеп җибәрде.

Ниһаять, «Җидегән чишмә»не елына илгә бер миллиард сумлык продукция эшләп чыгара торган предприятиенең канаты астына алдылар, советын сайлап, партком һәм профком каршындагы әдәби-музыкаль клуб итеп рәсми расладылар. Һәм менә «Җидегән чишмә» Казанга ук барып чыкты.

Азатның: «Гомәр Бәширов кебек аксакалы булган халык — бәхетле халык» дип сүзен тәмамлавы булды, зал дәррәү алкышларга күмелде. Г. Бәширов һәм С. Садыйкова иҗатына багышланып, өч сәгать буе барган бу кичә, бөтен зал басып, «Җидегән чишмә» җырын җырлау белән тәмамланды.

... Ул бер көнне шәһәр тирә-юнендәге Камага агып төшүче бөтен инеш-чишмәләрне тикшереп-барлап йөрде. Күпме генә үзебезне юатсак та, барысы да ал да гөл түгел иде шул. Тәссез, җансыз сулар да очрады. Изге Чургат чишмәсенең дә тәме бөтенләй башка...

Әгәр дә уйлап табулар барысы да уңай нәтиҗә бирсә, чишмәләр болай тәмсезләнмәс иде.

— Шулай да менә бу никельхромбарий белән ашыгасы иде. Әмма зур өмет баглаган яңа матдәләрне, басым-температураны «биетеп», төрле режимнарда тикшерүләр куандырмады. Кеймә комга терәлә барды. Реакцияләрне аңлар өчен ниндидер өстәмә информация җитешми. Төбенә кадәр төшенми торып, алга барып булмаячак.

Ул тагын әлеге катализаторны куллана торган пропилен окисе заводын урарга булды. Никельхромбарийның зарарлы булуы бер хәл, өстәвенә, ул әле алынасы стиролга ияреп, өйрә ясап, буталып чыга. Яңадан аны стиролдан аерып алу өчен, сепараторлар, центрифугалар, фильтрлар һәм парга әйләндерүче аппаратлардан — барысы утыз басмадан торган «артык цех» — төзергә туры килгән. «Акыллы», әйбәт катализатор табылса, бу техны шунда ук ябарлар иде. Кайда ул, ни ул? Булырга тиеш ич ул!

Гади, отышлы ысулның булмавы мөмкин түгел. Табигатьтә бит әнә барысы да гади. Бу турыда сүз кузгалса, хезмәттәше Рудәл Сәйфуллин бөтенләй кабынып китә.

— Әйе, әнә күр табигатьне, — ди ул,— тын гына берниндн югары басымсыз, моторсыз, утсыз, югары температурасыз, берниндн зарарлы калдыкларсыз, нибары җиртуфрак, су һәм кояш нуры белән яфрак, тамыр, кәүсә дигән гап-гади «колбаларда» шомырт, сирень, алма, карлыган, бөтнек кебек меңләгән хуш исләр, сагызлар, әллә нинди

меңнәрчә матдәләр ясап ята. Уйласаң, могҗизаның могҗизасы! Исңә, аша, эч, хозурлан! Барысы да камил, төгәл, үз урынында, барысы да ифрат кирәк, берни дә артык түгел. Килер бер көн: Җир шары ямьсен дисә, кешелек газ, төтен пыскытып утыручы торбалар, реакторлардан арынып, иң бөек ысулга, табигать ысулына кайтыр, шуның серен табар...

— Ә хәзер нишләргә? — дип бүлә Азат Рудәлнең романтик уйларын.

— Хәзергә газ иснәргә туры килә.

— Их, Рудәл, табигатькә салган зыяннарыбыз тора-бара безнең гомергә чик куя башламасмы соң?

— Кире авылга кайтырга кирәк! — ди Рудәл күзлеген елтыратып.

— Анда качып кына котылып булса иде. Ул зарарлы калдыклар космоска очып, хулиган хәнҗәре сыман, җирнең атмосфера сүрүен умырып ерткалыйлар, җимерәләр, тереклек өчен һәлакәтле радиактив нурланышларга юл ачалар. Безгә ашыгырга кирәк!..

* * *

Узган җәй Азат миңа туган яклары Балтачка сәяхәт кылырга тәкъдим ясады. Киттек.

Җимеш бакчаларына, өянкеләргә, тупылларга төренгән, инеш үзәнендәге Карадуган авылында Азатның яшьлеге узган. Рәттән тальян гармун чаклы гына туган авылы Таузар да, илгә нидер вәгъдә итеп, инеш-чишмәләргә сыенып утыра... Арырак, кояш чыгышында, җир җәрәхәте сыман, ак ярлы калкулыклар ачылып ята. Бу — башка якларга караганда диңгез астыннан миллион елларга алданрак чыккан карт җирләр икән. Туфрагы көлсу. Тайгага күчеш полосасы. Калкулык өстеннән башланган урманында кырыс чыршылар, күп төрле авыруларга шифа буларак риваятьләргә кергән артыш куаклары.

Икенче көнне иртән үк юлга да кузгалдык. Бер минутны да бушка уткәрү юк. Тукай да сабыйчагының «биш минутлык төш шикелле генә» бер өлешен Балтачның Сасна Пучинкәсендә үткәргән ич! Әнисенең кабере дә шунда. Бардык, карадык, моңсуландык, уйландык... Барыбызның да фикере бер тирәдә йөрде. Римлеләрдә, грекларда әллә ничәмә-ничә Венералар, Афродиталар, Дианалар һәм башка хатын-кыз аллаларының ак мәрмәрдән эшләнгән һәйкәлләре җир өстен балкыткан, кешеләргә шатлык биргән. Хәзерге көндә рус халкында да хатын-кызларга һәйкәлләр шактый. Без дә тирәягыбызга бер әйләнеп карыйк әле: сөеклеләребезгә багышланган җырларыбыз күпме, китапларыбызда аларның гүзәл образлары тулып ята. Ә менә шушы көнгә чаклы берсенең генә дә һәйкәл булып зур мәйданга чыгып басканы юк икән ич. Ә нигә Тукайның Анасына, Җидегән чишмәләребезнең тирән катламнарының символы итеп, шундый бер һәйкәл куймаска икән?!

Бу сәяхәттә без бер заман урман читендәрәк гигант бер иңкүлеккә килеп чыктык. Якынайгач, сокландыргыч манзарадан сулышлар кысылып, йөрәк тибүдән тукталгандай булды. Аста киң рәхәт су җәйрәп ята. Ничек бу болай үзәнлектән өстә, калкулык битендә хасил була алды икән? Татарстанның иң тирән күле икән ул — 23 метр. Төньяк ярыннан чишмәсе шаулап, ургылып чыга да гомер бакый күлгә коеп тора һәм, күлдән беркая да агып чыкмаса да, мәңге дә күлне тутыра алмыйча ага да ага... Кырые унбиш-егерме метр биеклектәге бөҗра тау белән уратылган. Күл янына ук төшеп астан караганда бөҗра таудагы биек агачлар очып күккә ашкан сыман йөрәкләрне җилкендереп җибәрә. Ике-өч дистә ел элек аның бөҗра тау агачлары кырылып бетеп, ярлары шәрәләнеп кала. Мал-туар таптап харап була барган бу күлне — табигать җанын промкомбинат директоры Габделхак Закиров (мәрхүмнең авыр туфрагы җиңел булсын) тимер рәшәткәләр белән әйләндереп алдырта, агачлар утырттыра. Тирә-ягын ял базалары, көймәләр чуарлаган бу күлнең хәзер үз караучысы да бар.

Апуш үскән җирләрнең гүзәллеген ачып бирүче бу табигый һәйкәлне, Тукай төсе итеп карарга һәм Сасна Пучинкәсе, Тукай Кырлай сәяхәте маршрутына кертергә иде! Күл булып күлне үлемнән саклап калган фидакарьләр барда Анага һәйкәл хастәрен күрүчеләр дә табылыр мөгаен!

... Без Азат белән Таузарбасуындагы калкулыкка борынгы каберга менеп барабыз. Менә камыллы кыр уртасында тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган кабер. Ташында инде мүк кимерә барган борынгы гәзиз язулар: «Бу дөньяда һичкем әйтә алмас кемнең кайда ничек үләсен... 1541 ел...» Әңгер-меңгер җиле кабер өстендәге агачларны шомлы лепердәтә.

Нинди кабер бу? Шулкадәр хөрмәт итеп, тимер рәшәткәләр коя-коя нигә аны гасырлар буена саклыйлар? Кем белә, бәлки, аның бер җеп очы юлдашым Азатка ук барып тоташадыр. Аның шәҗәрәсе дә, бик тирән булмаса да, сирәк очрый торган патриотик шәҗәрә ич!

Ерак бабасы, атка атланып, бөтен Францияне тетрәткән рус гаскәрләренең алгы сафында (сәйяр җанлылык әнә кайлардан башлана) Парижга барып кергән һәм нәселгә «французныкылар» дигән кушамат калдырган.

Якын бабалары да яшәү һәм җир өчен гасырлар буе барган күз яшьле даулы елларның, канлы көрәшләрнең иң кыска бер романы сыман бу шәҗәрәне буыннан-буынга биреп юкка гына сакламаганнардыр. 1680 елларда яшәве билгеле булган Мәсәй, Рәхмәтулла, Рахманкол, Гобәйдулла, Мөхәммәтҗан, Шакир, Зыятдин, Шәймулла, Азат, Нариман.

Исемнәр билгеле... Укуын да күп укыйбыз, әмма бабаларыбызның ничек, кайда, нинди хәсрәт-борчулар белән яшәүләрен бик аз беләбез шул. Күп нәрсәне вакыт упкынына ыргытабыз. Без аларның рухын ихтирам итәргә, шәҗәрәләребезне язып түш кесәләрендә йөртергә һич тә өйрәнеп җитә алмадык әле...

Хәтта бу нәселнең моң чишмәләре турындагы беренче хәбәр Зыятдин карт чорыннан гына калган. Аның хатына Хупҗамал әби курай, кубыз уйнаган, болыннарда ялгызы җырлап, уйланып йөрергә яраткан. Азатның әнисе ягыннан тегермәнче, мәчет манаралары куючы балта остасы Муса бабасы да үзе ясаган скрипкаларда өздереп уйнаган. Уйлана китсәң, бөтен нәрсә бабалардан мирас — «Җидегән чишмә» тармаклары да, кыюлык, чаялык та...

Зыятдин бабасы 18 яшеннән әти-әнисез кала. Мулла аңарга, ата-анаңны җирләр өчен гүр садакасы итеп — я сыерың, я атың, ди.

— Яхшы, хөрмәтле мулла абзый, — ди чая егет. — Сыерым да, атым да бар минем. Сыерымны алсаң, ятим балаларны сөт белән үзең туендырып торырсың, ә атымны алсаң, җиремне сөреп, иген игеп, ипи ашатырсың.

Мулла берсен алырга да җөрьәт итми. Зыятдин энеләрен-сеңелләрен аякка бастыра. Төп йортны кече энесенә калдырып, үзе башка чыга. Ул гарәпчә әйбәт укый, латинча таный, газеталар алдырта. Озак яши, әле безнең заманга эләгеп, шәпле атында оныкларын Казаннарга алып барып шәһәр күрсәтеп йөри.

Азатның этисе Шәймулла аганың юлы да татарның иң ныклы егетләре генә үтә алган тимер-томырлы, ташлы-күмерле, утлы-туплы, кургашынлы юллар. Тот та романның төп герое яса. Мәскәүдә — Метрострой, Уралда — таш карьеры, Донбасста — шахталар, Себердә — алтын приискалары. Гражданнар сугышында яралана, ә Ватан сугышыннан бер аяксыз инвалид булып кайта. Утлы сугышлар кичкәндә дә, таш-тимер мәхшәрләрен үткәндә дә ул үзенең тальяныннан беркайчан да аерылмый. Ахры, безнең халыкның бөеклеге, аның улларының көче-куәте, батырлыгы, шагыйрьлеге дә менә шундадыр.

... Азат сабан туе карап йөри иде. Һәр күренешкә аның исе китә: киемнәргә, кеше йөзләренә, сөйләшүләргә, уеннарга. Ул барысын да күреп калырга, күңеленә сеңдерергә ашкына. Көрәшне күзәтү — аның иң мавыкканы! Әмма Азатны бу тамашадан аерыр көч тә бар икән. Ул мәйданны урап килүче тальян тавышын ишетеп алды, сагайды, тынып калды, күзләре дымланды... Туктагыз, дәшмәгез! Аның көмеш тавышын ишеттеме, этисенең картайгач та тальянын күтәреп капка төбенә чыгып уйнавы, авылдашларының җыелып аны тыңлавы күз алдына килеп баса. Мондый чакта Азат — тальянныкы гына! Тальянны ул барыбер эзләп табар, ияртеп китәр...

Азат, тальянга ияреп, мәйданны ике-өч тапкыр урады. Сүзсез түгел, «Шахта»ларны, «Җомга»ларны җырлап. Башка чакта да, бакчаларда ял иткәндә, табын яннарында ул беренче булып җыр күтәреп җибәрер. Әмма сабан туендагы тальян янында аның тавышы аеруча көр, кабатланмас матур, моңлы. Берничек тә өзеп булмаслык бу сихри моңнар аша үткән буыннар, тарихлар белән бәйләнгән ахры ул...

...Метро төзелешендә хәр күңелле, ачык йөзле гармунчы егетебезне, «аттан артык» эшләүче алдынгы Шәймуллабызны ник яратмасын Мәскәү кызлары! Квартира биреп, бөтенләйгә калырга да кыстыйлар. Ләкин Зыятдин бабайның: «Кайт, улым, туган ягың сине юксына»,— дип язуы җитә. Шәймуллаң авылындагы ятимә кыз Ләмигага өйләнеп, ишле, төпле гаиләгә нигез сала. Алты баланың бишесе Бакый, Сәйдәш, Азат, Илгиз, Тәэминәләр югары белем ала. Фәниясе милли аяк киемнәре тегүче булып китә. Дөрес, югары белем белән хәзер шаккатыра алмыйсың. Шул белемең белән син халыкка, илгә ничек хезмәт итәсең? Хикмәт менә нидә!

* * *

... Катализатор сере борынгы шәҗәрәләр тамыры сыман бик тирәндә иде. Инде берничә яңа алым, яңа матдәләр белән ясалган тәҗрибәләр уңышсыз тәгәлләнде. Бу көндәшләргә тантана итәр өчен бик әйбәт форсат иде. «Безне, химиянең җитмеш җиде төрле тозын ашаган агай-апайларыңны алай тиз генә узып китәргә бик ашыкма әле,

егеткәем. КАИ бетердем дә әллә кем булдым дип артык масаясың ахры. Без монда әле чын химиклар була торып та...»

Чыннан да, Азат химиягә Казан авиация институтын бетереп килгән иде. Кем белә: бәлки, киресенчә, очу серләрен белгәнгәдер дә моңарчы аның химиядәге ачышлары, башкаларныкына караганда, алданрак тәгәри иде. Көндәшләре исә, аның инде химия буенча фән кандидаты икәнлеген һәм ике фән кисешкән урынның һәрчак уңдырышлы булуын исләреннән чыгаргалыйлар. Аның бүгенге уңышсызлыгы да уңышка таба бер адым икәнен әле аңламыйлар иде.

Очышлар дөньясы егете үзенә канатларны да дөрес сайлады. Аның берсе — Шәмәрдән егете хромотограф Роберт Гыйззәтуллин, икенчесе Сарман кызы Фәүзия Садриева иде.

Хромотографик тикшерү ысулларының зур остасы, үз эшенә фанатикларча бирелгән Роберт эзләнү чиксез атомнар океанында чайкалганда, сизгер аппарат — маяклары белән, атом эчләренә үтеп кереп: «Юк, монда сез эзләгән җәүһәрләр юк, монда упкын, тегендә рифләр»,— дип, курсны төзәтеп торды.

Ә алны-ялны белмичә эшләүче инженер Фәүзия Азат яккан «утта» янды. Азат кушкан тәҗрибәләрне туктаусыз үзгәртеп яңадан-яңаларын ясап торды.

Ниһаять, эзләнү күпере өстендә бер яктылык күренде. Ышанасы килмәде: КАИ шырпысы химия кабы күкертенә шулай ук оста сыздымыни?! Утыз буынлы аппаратлар чылбырыннан торган «артык цех»тан азат итәчәк «затлы» катализатор иде бу!

Шатлык катнаш борчудан, ышану-ышанмаудан сөйләшүләр үзгәрде, хәтта бераз йөрәк сикерде, тавыш кабаланып, ярсыбрак чыкты. Кычкырып, артык сикереп, бар дөньяга сөрән салырга да ярамый. Серне сакларга дип кул да куелган ич.

Яңа катализатор ачу — максатка беренче адым гына. Алда тагын да текә тау менәсе бар. Радио уйлап тапкан Поповларны, пар машинасын ачкан Кулибиннарны дөньяда әллә бер генә «экземпляр» булгандыр дисеңме?! Күп булган алар. Көрәш ыгы-зыгысына күмелеп, еллар томаны аръягында ятып калганнар. Кайбер ачышлар, аны уйлап тапкан кешеләр үзләре үлгәннән соң гына, дөнья йөзенә чыга алган.

Хыял белән чынбарлык арасында, телисеңме-теләмисеңме, еллар ята. Тау ташкыны кебек ярсып аккан тормыш, әллә нинди яңалыкларыңны әйләндереп ташлап, тузанга-ләмгә күмеп, үзенчә агып ятарга ярата. Шуның өчен дә күпләр ачышын тормышка ашыра алмыйча тәмам арып, көчләре бетеп, эшем бөтенләй югала күрмәсен дип, Бөтенсоюз каталогына тизрәк регистрациягә кертеп, шуның белән тынычланып калырга мәҗбүрләр.

Әлеге катализаторны да лабораториядә ачу бер хәл, ә промышленностьта файдалана башлау көтелмәгән күңелсезлекләр китереп чыгаруы бик мөмкин. Шуңлыктан аны башта промышленность шартларына якынайтып сыныйлар. Анысы да — таулар күчерүгә тиң эш! Аның өчен яңа катализаторларны да кайдадыр күпләп ясарга кирәк. Үз планы турында гына кайгырткан чит заводка өстәмә заказ бирү — үзе чүлдә диңгез булдыру. Каршыңда котып бозы таулары, әллә ничәмә-ничә сират күперләре...

Бу очракта инде син үзеңнең генә түгел, җитәкчеңнең дә кем икәнен сынып аласың. Азмы планны алла итеп, шуңа табынган, шуннан башка күзе берни дә күрми торганнар?! Бәхеткә, берләшмәнең генераль директоры Николай Васильевич Лемаев — фәндә бөек көч яшеренгәнлеген аңлап эш итүче сизгер җитәкче. Беренче елларны ук инде ул фәнни эзләнүләргә хирысланып тотынды. Аның канаты астында дистәгә якын фәннәр кандидаты үсеп чыкты. Үзе дә техник фәннәр докторы дигән биек үрне яулады. Ул бөтен берләшмәне фәнни-тикшеренү институтына әверелдерергә омтыла иде ахры. Генераль директор Азатның ачышын, куанычын яшермичә, зур илһам, зур дәрт белән каршы алды. Икенче көнне үк Азат белән бергә Мәскәүгә очарга хәл кылды.

Министрлыкта да ачышны хупладылар хуплавын. Ләкин эшне оештыруга килгәндә бик үк сикереп төшмәделәр. Катализаторны кайда, ничек эшләтергә икән соң? Моны үз агымына куйсаң, дистә еллар үтеп китәчәк. Мәскәү зур... Кемгә тотынырга? Кем кул сузар?

Ә Азатның фәнни атасы академик Кафаровка мөрәҗәгать итсәң? Менә шунда инде аларның икесенә дә якын, таныш запас «козырь тузлары» уенга керде. Олы мәскәүленең тынычлыгын бозып мөрәҗәгать итәр өчен инде күптән, алдан ук итагать күрелгән иде...

... Бервакыт берләшмәдә, Мәскәүдән академик килә икән, дигән хәбәр таралды. Түбән Кама җирендә космонавтлар, зур-зур язучылар булып китте. Инде мондый хәбәрләр белән генә син Түбән Каманы шаккатыра алмассың. Шулай да, академик сәфәр чыга икән, дигән сүз сәеррәк тоелды. Бездә берниндu академия дә, фәнни-тикшеренү институты да юк ич. Килсә, кемгә килер, кем чакырды икән соң аны?! Бераздан ачыклана төште. Азатның фәнни эше буенча җитәкчесе академик Кафаров турында сүз бара икән.

Язның матур бер көнендә генеральный директор исеменә Мәскәүдән телеграмма алдылар: «Сезгә юлга чыгам. Академик Кафаров». Азатны да шундый ук эчтәлекле кадерле телеграмма куандырды. Әмма моны күпләр белми иде әле.

Азат базардан бер кочак розалар алып, пристаньга академикны каршыларга ашыкты. Транспорт якларын, башкасын җитәкчеләр кайгыртасын ул белә иде инде. Әмма барыбер уңган Саниясе дә: «Кунакны алып кайта күр, табын әзерлим!» — дип, көтеп калды.

Пристаньда рәсми каршылаучылар һәм каяндыр озын колаклардан ишетеп-белешеп, галим халкы да җыелып өлгергән иде инде. Фән маршалы килә ич! Алар арасында: «Нишләп йөри икән инде бу Зыятдинов?» — дип (чөнки букеты артык балку иде!) бераз ятрак итеп караучылар да булды. Азат, исәнләшеп, букетны кунакның кулына тоттыруга, Мәскәү академигы, елмаеп, Азатны кочаклап ук алды, улыдай якын итеп аркасыннан сөя-сөя:

— Нихәлләрдә яшәп ятасың, Азат туганым?! — диде.

— Әйбәт яшим, Виктор Вячеславович, әйбәт!

Кайда сыю-сыймау итагатен яхшы белә иде Азат. Каршылау-күрешү церемониясе тәмамлангач, ул читкәрәк китте. Рәсми каршылаучы агайлар, академикны урап алып, «Волга»ларга якынайдылар. Инде ике-өч машинаның ишекләре шап-шоп ябылып та өлгерде. Ләкин никтер кузгалырга ашыкмадылар. Академик һәм генераль директор «Волга»лардан кемнедер эзлиләр иде. Ә-ә, әнә ул кайда икән, пристань култыксасына таянып карап тора. Генераль директор «Волга»ларга сыеп бетмәгән каршылаучылар арасыннан эзләгән кешесен табуына шатланып:

— Азат, син безнең белән бул! — диде.

Академик фән кандидаты Зыятдинов өчен берләшмәдә яңа лаборатория оештыру, яхшы тәҗрибә установкалары булдыру, фәнни яктан Мәскәүдән булышып тору турындагы килешүгә дә кул куеп, матур эз калдырып киткән иде ул вакытны. Ике-өч ел үтте. Академик киңәш-табышы белән оешкан лаборатория дистәгә якын ачыш ясады. Һәм менә, ниһаять, иң зурысы — шушы яңа катализатор.

... Кафаров Түбән Кама танышларын якты йөз белән каршы алды. Ул ачыш турында телефон аша хәбәрдар иде инде. Үз шәкертеңнең өметеңне аклавы, балаңның әшкә ярый башлавы кебек үк, куанычлы бит ул. Гозерне сөйләп биргәч тә йөзе бер дә алай сүрелмәде:

— Яңа катализаторны Уфада ясатачакбыз! — диде академик. — Үзем даими контрольдә тотачакмын. Борчылмагыз!

Азатның ачышы, тормыш логикасы таләп иткәнчә, күмәк акыл җимешенә әверелде. Үзләренең мең төрле мәшәкатьләре була торып, лаборатория төзүдә, һәртөрле җиһазлар табуда һәр даим җиң сызганып булышкан генераль директор Н. В. Лемаев, баш инженер Г. Җ. Сәхапов, производствода ут капкандай ашыгыч чаклары белән дә санашмыйча, дусларча кул сузган баш технолог А. П. Ворожейкин иң мөхтәрәм соавторлар иделәр. Ә пропилен окисе заводы директоры Р. Г. Галиев, баш инженеры Н. И. Матросов зур дәрт белән сынау установкасын ясарга тотынмасалар, кем әйтмешли, кая барыр идең, кодагый... Матдәләр диңгезендә адашмаска компос биргән академик В. В. Кафаров һәм микрошеф, фәннәр докторы В. Н. Писаренколарның исемнәре бу эш балдагында җәүһәр ташлар иде.

Әнә шулай, һич тә уйламаганда, ачыш үзеннән-үзе берничә милләт вәкиленең дуслык билгесенә дә әверелде.

* * *

Май бәйрәмендә ул тагын балаларын ияртеп, бер генә көнгә булса да өч йөз километр ераклыктагы туган авылына юл тотты.

Таллар бөдрәләнеп сары чәчәк аткан. Юл буйларында беренче нарасый яшеллек борын төрткән. Күңелдә — ашкыну, өмет, җыр, канатлар. Туган җир белән кавышу һәрвакыт әйтеп бетергесез изгелек уята. Әмма аның бу кайтуы үз күңеле өчен генә түгел иде. Олы сере, мәгънәсе бар иде бу сәфәрнең.

Мәдинә ханымның мул табыны янына башта Азат үзе зур гына кап тотып килеп басты. Капны ачты.

— Кадерле нәнәбез — диде ул,— без синең балаларың, оныкларың бүген бирегә, сиңа сиксән яшь тулуны билгеләп үтәргә җыелдык. Менә бу самавырга мондый сүзләр уеп язылган:

Рәхмәт, нәнә!
Синең тәмле чәең
Еракларда йөргән улыңа
Туган җирләр яме, үз йортыбыз,
Ана назы булып тоела.

**Май, 1984 ел. Азатың.**

Ул да булмады, Азатның кызы Гөлнара торып басты.

— Әбекәем, чәең тәмле, хуш исле булсын! — Җитез комсомолка кулыннан самавыр өстенә бизәкле чәйнек менеп кунаклады.

Нариман онык торып басты.

— Әбием, чәйне беркайчан да ялгызың гына эчмә, бергә-бергә эчәргә язсын! — Ул әбисе каршына ике пар чынаяк куйды.

— Рәхмәт, балакайларым, рәхмәт,— диде ана, дулкынланып,— авыруларым ерагайды, картлык сагышларымны юып алдыгыз. — Күзләрендә куаныч яшьләре иде. — Бик каһәрле тормышта үтте минем балачагым. Рәхмәт инде әтеки белән әнекигә, бик әйбәтләр иде: үз балалары кебек якын иттеләр. — Кайната Зыятдин карт белән кайнана Хупҗамал әбине шулай бик олылап, якын итеп әйтә иде ул. — Бу шәфкатьлелек сезгә дә шулардан күчкәндер инде.

Хәзерге тыныч мул тормышта карт әниләрен олылап, һәркем шундый кыска һәм тирән мәгънәле гүзәл спектакль куя алсын иде. Берәү дә, әш узгач кына, тетрәнеп әйнымасын иде...

Азат шәһәрдән буяулар һәм пумалалар да алып кайтты. Табыннан соң алар, зиратка барып, Шәймулла картның кабер өстен чистартып матурладылар, чардуганын буядылар.

Күрегез, белегез, балалар, сез — очсыз җептә өзелмәслек төеннәрсез. Үзеңнән соң кабереңә килерлек игелекле балалар калдырмасаң, нигә ул ВУЗ белемнәре. Бездән соң килә торган буын шуны аңламаса, Түбән Кама тудырган миллиардларча байлык кына түгел, җир шары үзе дә шартлап юкка чыгачак ич.

Шуларны уйлап, исән әнисе, бабалар рухы, авылның керсез вөҗданы каршында бер исәп-хисап биргәч, ана рәхмәтен ишеткәч, күңеле күтәрелеп кайткан иде.

* * *

Азат берләшмә өстеннән күтәрелгән пар, газ-төтен болытларына лаборатория тәрәзәсеннән карап уйга чумган.

1984 елны яңгырлар бик озак яумый торды һәм аның урынына химиклар «бакчасына таш мул яуды».

— Кара, малай, кычкыртып корылык килә бит, ә. Уйбишенче гыйнвардан бирле дүрт ай буена рәтләп берни яумый.

— Бетерделәр, бетерделәр табигатьне. Анда галәм сүрүен тишкалиләр, монда химиклар әллә ниләр очырталар. Барысын да бер табигать-җаныкаем үз йөрәге аша үткәрә.

— Син аның аязлыгын кара, әллә нинди куркыныч аязлык. Шикләндерә бу.

— Әллә нинди галимнәребез бар, яңгырны барыбер яудырта алмыйлар...

Эшкә барышлый-кайтышлый, урамнарда, ял иткәндә, автобус-трамвайларда ишетелгән мондый сөйләнүләр, керми дисәң дә колакка эләгә, күңелне борчый. Эссе май да үтеп китте. Яңгыр юк та юк. Корылык килүдән хафага төшеп, инде тәмам вәсвәсәләнеп беткәндә, июньгә кергәч, табигатьтә кискен үзгәреш башланды.

Әмма ул афәт белән килде. Югары һәм Урта Идел буендагы кызган һава массасына салкын фронт китереп бәрде. Өермә уйнап-шаярып йөзьяшәр имәннәрне шырпы кебек кенә сындырды, машиналарны, агач йортларны һавага чөеп уйнады, корылмаларны җимереп ташлады, корбаннар да алып китте.

Әмма яңгыр килде! Атлантикадан гигант циклон килде! Яңгыр сулышларны иркенәйтеп, тәннәрне җиңеләйтеп, чиләкләп койды, тәпәнләп түкте. Ул кемгәдер ачуланганадай, дулый-дулый давыллап, шашып-ярсып, ашыга-кабалана, бәргәләнә-бәргәләнә яуды. Эһ, дигәнче кыек асларында торган мичкәләр, чаннар тулып ташыды. Асфальтланган шәһәр урамнарыннан чүп-чар, корым-көл-юшкыннарны юа-юа акты.

Беркем сугарып бетерә алмас иген кырларын, бакчаларны, урман-болыннарны, тау битләрен үксү-рәнҗүләрдән арындырды.

Соңгы елларда һава үзгәрешләре амплитудасы артык нык шаяра башлады. Кая икән ул без бала чактагы үз вакытында явып тора торган күкрәүле, кояшлы, җылы яңгырлар?! Я коры җәй, я салкын җәй, я фасыллар күчәнә, я тагын әллә ниләр. Ни генә уйлатмас. Әнә үзәктәге академикларга хәтле төрле машиналарның, химия заводларының арта барган зарарлы юшкыннары күк сүрүенә утыру сәбәпле җир шарының җылына баруын һәм хәтта, котып бозлары эреп, материкларны су басу куркынычын да фараз кылалар. Табигатьнең бу рәхимсез, ярсу уенында күпмедер дәрәҗәдә без, Түбән Кама химиклары да, гаеплебездер, бәлки...

Әмма бүген җанда канәгатьсезлек: глобаль масштабта әнә табигать көйсезләнә, яңалыкларны кертү дә озаккарак сузыла...

Дөрес, соңгы атнада гадәттән тыш зур вакыйга булып узды. Генераль директор һәм аның фәнни референты, танылган галим, профессор А. Г. Лиякумович тырышлыгы белән бер төркем академиклар Кафаровның җиңел аяк эзеннән Түбән Камага килеп, зур башкалаларда гына була торган күчмә фәнни сессия үткәрделәр.

— Сезнең берләшмәне еш кына һәм хаклы рәвештә «сынау өчен полигон» белән чагыштыралар,— диде аларның җитәкчесе академик Н. М. Эмануэль.— Биредә яңа катализаторлар ачу һәм шул нигездә тирә-як мохитне пычратмау чараларын эзләү уңышлы бара. Монда симпозиумнар үткәрү дә ярар иде. Аннары берләшмәнең үзәк-фәнни тикшеренү лабораториясе үзенең потенциалы белән күптән инде фәнни-тикшеренү институты белән ярыша ала икән ич. Берләшмәнең исемен «фәнни-производство» дип үзгәртергә вакыт түгел микән?..

Бу Түбән Кама тормышының яңа бер сыйфат үзгәрешен, фәннең әйдәп баручы көчкә әверелүен рәсми тану, ирешелгәннәргә зур бәя бирү иде. Бәлки, бераз арттырыбрак та әйтелгәндер, әмма чынбарлык моннан да ашкынрак эш таләп итә. Күкләргә юшкын утырып, табигать белән кешелекнең «югары көчәнешле яндыргыч замыканиесе» булганчы, теге төңне бөтен берләшмәдә утлар сүнгән кебек, җир шарының яшәү утлары сүнмәсен өчен, химия дөньясына җир шары масштабында зур үзгәрешләр кирәк, ашыгырга кирәк.

Шул турыда тагын бер ныклап киңәш-табыш итү өчен Мәскәүгә, остаз академик янына барып кайтсаң да ярар иде. Бәлки тәкъдим итеп тә карармын әле...

Һәрвакыттагыча генераль директор эш ташкынында әледән-әле сигнал биреп торган телефон, кнопка-төймәләр, селекторларга чорналып утыра иде. Гадәтенчә, кызу-кызу гына әйтеп салды:

— Азат, юлга җыен, Мәскәүгә. Безне академиклар көтә. Остазыңның да юбилее түгелме соң?

— Әйе шул, Николай Васильевич.

— Шатлана аласың: Уфадан беренче партия катализаторлар юлда. Мәскәүдә дә сүз яңа катализаторларны тизрәк производствога кертү турында барачак. Әзерлән!

Икенче көнне алар Мәскәүгә очтылар.

Түбән Кама.

## Зэки Нури

# ЯШЕЛ ДИҢГЕЗДӘГЕ КОЯШЛЫ УТРАУ

Самолет Йошкар-Олага оча. Менә ул югарыдан карaганда тоташ яшел диңгез булып күренгән урманның ярыннан-ярына бер җилкенүдә сикереп чыгар. Ярты сәгатьтән анда булабыз.

...Мин самолеттагы кебек үк йомшак урындыкта тирбәлеп, Йошкар-Олага барам. Йөгерек шпаллар агымы ниндидер тоташ дөбердекле, үзгәрешсез һәм азаксыз көйгә биешкән күз иярмәс тизлек белән көпчәкләр астына ашыгып тартыла. Тагын да йомшаграгы һәм тынрагы кирәк дисәң, беренче класслы асфальт юлдан чапкан тиз йөрешле автобуска утырырга мөмкин иде. Нибары дүрт-биш сәгатьлек юл...

Әйе, үзенең 400 яше тулган юбиляр — Кокшага елгасы буендагы Йошкар-Ола белән (Кызыл Кала дигән сүз) Казан арасы ерак түгел хәзер. Бу башкаладан Татарстанның һәр шәһәре һәм районына, алардан исә һәр хуҗалыкның басулары һәм фермаларына барып чыгарга сәгатьләр түгел, ә кайбер урыннарда хәтта минутлар да җитә икән ләбаса! Халыкның, бер юл бүтән теләсә нинди юлга чыгара, дигән кайчандыр хыялый гына булган сүзе биредә инде чынга ашкан. Ә Мари әдәбиятының аксакалы Сергей Николаевич Николаев миңа утызынчы еллар азагында үзе шаһит булган менә нинди бер очракның мәзәген сөйләгән иде. Казанга барышлый олаучылар төнге ялга туктый. Барасы юлларын онытмас өчен барысы да арба тәртәләрен Казан ягына каратып калдыралар. Төнлә, мужиклар йоклагач, авылның бер шаяны шул тәртәләрне кире якка борып чыга. Олаучылар иртә таңнан атларын җигеп кузгалалар да кичке якта тагын бер зур авылга килеп кергәч, бик җанланып гәпләшәләр икән:

— Бигрәк яхшы күренә бит, әй. Йортлары нинди төзек. Тоташ нараттан! Чыңлап тора кебек.

— Да, молодец мужиклар эше!

— Сизмисеңме шуны, нәкъ безнең авыл кебегрәк дисәм?..

— Нәкъ шул үзе бит!

Әйе, шактый уңайсыз, көлке хәлдә кала мужиклар...

Миңа Йошкар-Олада һәм мариәлнең[1] Бәрәңге районында беренче тапкыр 1961 елның ноябрендә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырырга барганда булырга туры килде. Х. Туфан, Г. Минский, Г. Шамуков, Г. Әпсаләмов, Ә. Исхак, Ф. Хөсни, И. Юзеев, Ш. Галиев, С. Шакир һәм унлап сәнгать осталарыбыз булган делегациянең башлыгы идем. Тәэсирләрнең кайберсе турында блокнотка да язганмын:

... «Кунакчыл хуҗалар үз башкалаларын җентекле экскурсия белән, аркылысын буен айкап дигәндәй, көне буе күрсәтеп йөрделәр. Аның инде тәмам формалашкан яңа мәйданнары һәм проспектлары, күп кенә урамнары, бигрәк тә парклары һәм бакчалары сокландырды». Кайчандыр бик матур итеп, сырлап-бизәп салынган агач йортлар арасында заманча күп катлы ташпулатлар әле күтәрелә генә башлаган чак иде бу. Ә хәзер инде алар бер бөтен дистәләр яңа кварталлар булып үрчегән. Шәһәр күренешенә ниндидер үзенчәлекле яңалык кертә. Күз явын ала торган нәрсә тагын шул биредә: чәчәкләр бизәге һәм искиткеч мул яшеллек! Чөнки кала үзенең бөтен чикләре һәм читләре белән я элек кораб мачталары ясарга гына диярлек тотылган, чыңлап торган шаулы наратлыкка, я, җилләр искәндә, яшел бөркәнчекләрен тузгытып берсенә-берсе елышкан зифа буйлы каен урманына барып төртелә. Ә кала эчендә аның һәр кешесенә 15 квадрат метр мәйданы туры килерлек куе куаклыклар үсеп тора. Һәр ике ягы буйлап агачлар утыртылган урамнар озынлыгы да 150 чакрым санала.

Үземне урман улы дип санарга балачактан ук күнеккәнмен. Чөнки туган җирем өч яктан урманнар белән камалган авыл. Армиягә Лубян урман техникумын тәмамлыйсы

[1] Мариәл — мари иле.

айда бөтен курс студентлары бергә киттек. Сугышта исә, заслоновчы-партизан буларак, Белорус урманнарындагы землянкаларда күп торылды. Сугыштан соң Йошкар-Оладагы урман эшкәртү институтына укырга керергә хыялланa идем. Ул анда сугышка чаклы ук Казаннан күчерелгән югары уку йорты икәне күңелне тартты булса кирәк...

Шуңа күрә соңгы вакытларда елына бер мәртәбә булса да Йошкар-Олага бармыйча калганым юк. Чөнки урманда ничектер киңрәк сулыйсың кебек һәм колачлырак масштабта уйланыла да. Кыскасы, яшәү ямен чагылдырырга шигъри юллар күбрәк табыла, төсләр һәм тавышлар гаять мул була. Урман турында чын йөрәктән әйтелгән сүзләрне эзләве дә күңеллерәк:

Пайтәхет бар. Фән сараен беләм.
Ә урманны — яшел дивар, дим.
Күргән саен бер үк сорау бирәм:
«Синнән матур тагын ни бар?» — дим.

Мари дусларның Пеледыш Пайрамын — безнең Сабан туебыз шикелле хезмәт, яз һәм чәчәкләр бәйрәмен — инде кат-кат карадым. Ул да гадәттә урман һәм су буйларында үткәрелә. Анда елмаю-көлүләр, иҗат һәм сәнгать белән очрашу истәлекләре күп була. Ә күптән түгел, Мушмари мехлесхозчыларының чиксез зур мәйданында (40 мең гектар чамасы!) табигый урман паркы эшли башлаулары турында укып[1] куандым. Димәк, алда әле безне тыштан караганда бик тә тыйнак күренгән, я сөйләшеп, танышып алгач, эчкерсез, ягымлы, дустанә, җанга якын кешеләр икәнлеге беленгән мари дуслар белән яңа очрашулар көтә.

Ә бит илебездә безне нәкъ әнә шундый хис-фикерләрнең рухи уртаклыгы, күңелләрдә тирән эз калдыра торган дуслык, кардәшлек берләштерә дә инде. Мин халыклар дуслыгының һәрвакыт шундый гади мөнәсәбәтле, даими һәм конкрет формада эшлекле булуын телим һәм яклыйм.

Җыеп әйткәндә, биредә, мариэлдә, бөтен нәрсә танымаслык булып бик тиз үзгәрә, яшәрә дә яңара. Рәссам-табигатьнең ягымлы, нәфис җаны ярдәмендә иҗат ителгән яшел фонга да, шәһәрнең тырыш хезмәт белән күтәрелгән инде шактый биек панорамасында да ачык күренә болар. Әйе, тоташ белемле, экономик яктан көчле Автоном республиканың көче-куәте бөтенесен эшләргә җитә хәзер.

Агач йортлар күпләп юкка чыга —
Язгы бозлар ишә диярсең.
Таш диварлар үрчи гүя белеп
Түбәләре күккә тиясен.

Бу юлларны безнең күптәнге каләмдәш дустыбыз Геннадий Матюковский язган. Ул тумышы белән Идел буендагы болын марие. Шуңа күрә аның шигъри күңел күзләренә Сомботхей бистәсендәге биек ак йортларның инде Кокшагага кергәнe күренү дә гаҗәп түгел. Чөнки Иделдә тагын бер яңа ГЭС турбиналарын эшләтер өчен яңа ясалган Чебоксар диңгезе Мари һәм Чуваш республикаларын тиздән диңгез дәүләтләре итәчәк дип куануы да бик урынлы.

Ә бит боларның бөтенесен, төзүчеләр әйтмешли, нульдән башларга, ягъни юктан бар итәргә кирәк була. Бу уңайдан сүзне моннан дүрт йөз элек һәм Бөек Октябрь революциясенә чаклы билгеле булган кайбер саннарга мөрәҗәгать итик:

... фабрика һәм заводлар юк. Төрле һөнәрчеләрдән 1 столяр, 2 итекче, 2 тегүче, 1 бакырчы, 2 буяучы бар.

... Патша шәһәренә[2] нигез салганнан соң йөз ел үткәч кенә анда 5 таш йорт һәм 129 агач өй була.

... Таш түшәлгән һәм яктыртылган урамнар турында, билгеле, телгә алучы да юк.

... Бездә 22 кабак, 200 трактир, өч харчевня һәм Рейн шәрабе нәүрәбеннән башка бер генә китап кибете дә юк... Каланың 1193 кешесенә — бер врач[3].

— Октябрьга чаклы мари ирләренең — 16 проценты, хатын-кызларының бары 2 проценты гына укый-яза белә.[4]

Ә хәзер шул саннарга җавап әйтер өчен 1980 һәм 1982 еллар саннарының берничәсенә сүз бирик:

...Йошкар-Олада 50 промышленность предприятиесе эшли һәм алар егерменче елдагы продукциядән 20 тапкыр күбрәк продукция эшләп чыгара. Менә арада нindиләре бар: ярымүткәргечле приборлар, ясалма күн, төзелеш индустриясе, электроавтоматика һәм суыткычлар... Тун тегү, мебель, трикотаж фабрикалары, «Сәламәтлек заводы» дигәне үзе генә илебездә эшләп чыгарылган витаминның өчтән бер өлешен бирә! Сәламәтлек дигәннән, мари авыл хуҗалыгы хәзер кымыз, бөдәнә ите һәм йомыркасы кебек савыктыргыч продукцияләр җитештергәнен дә әйтеп үтү урынлы булыр.

[1] Өстәл календаре, 1984 ел, 173 бит.
[2] Йошкар-Оланың борынгы исеме.
[3] Йошкар-Ола турында белешмә китабы (1982).
[4] «Социалистик Татарстан», 10 октябрь, 1982.

Бирeдə илебезгə Йошкар-Ола биргəн «Урман комбайны»н əйтмичə һич мөмкин түгел. Ул, киң-киң полосалар итеп, метрга якын калынлыктагы агачларны кисеп аудара, аның ботакларын əрчи һəм бүрəнəлəрен машинага күтəреп салу өчен зур-зур пакетларга җыеп бəйли. Боларның бөтенесен кабинада утырган бер оператор эшли.

Татар əдəбияты һəм сəнгате атналыгыннан соң, мари дуслар үзлəренең шундый ук атналыкларын Татарстанга килеп үткəрделəр (май, 1962). Бездə дə болыннар һəм бакчалар шау чəчəккə күмелгəн көннəр иде. «Əй эшлисе килə, эшлисе лə, тырыш кояш белəн ярышып» дигəн шигырь юллары нəкъ шул көннəрдə туды бугай. Аны мари дуслар да үз газеталарында бастырып чыгарды. Ə аларның хəзер бөтен илгə танылган композиторлары Эшпай язган «Мин сиңа йөрəк сүзлəремнең барсын да əйтмəдем əле» дигəн җырны бездə Валерий Рыбаков бик оста башкарган иде. Əйе, бик тиз үтеп киткəн декада көннəрендə бөтен сүзлəр дə, əлбəттə, əйтелə алмагандыр. Əмма без барыбыз да дусларыбызның күп кырлы иҗатының халыкчан традициялəрен һəм килəчəк үсешенең перспективаларын бик яхшы белдек. Хəзер исə бу дуслык бер-беребезне үзара тəрҗемə иткəндə, китаплар алышканда, дуслык юлларын киңəйтə барган яңадан-яңа сукмаклар салгандагы конкрет эшлəр белəн өзлексез киңəйтелə һəм тирəнəйтелə.

## Урман үзəге Кызыл Калага

Урманчымын, шуңа ахры, шуңа
Күңел тарта һаман урманга.
Бер аунавы үзе ни тора бит
Сузылып ятып яшел юрганга!

Урман, урман... Гитлер явы килгəч
Күп торылды анда постларда.
Туры килде чөнки дүрт ел рəттəн
Урман кочагында кышларга...

Урманнарда, əйе, күп йөрдем мин
Һəм күп булам анда бүген дə.
Анда салган барлык сукмакларым
Ярылып ята кебек күңелдə.

И Казаным, синнəн һич яшермим —
Мине хəтта көнли аласың: —
Яраттым мин урман Үзəге дип
Мариэлнең Кызыл Каласын.

...Шыгырдасын өчен аяк асты
Җил сырлаган тыгыз кар ята.
Чаңгың эзе карурманга илтə
Кокшагадан чыксак аръякка.

Ылыс исле чыйлап торган һава
Шифасыннан йөзлəр аллана.
Ə җəйлəрен исə, əйтерсең лə,
Татлы тəмен кертə бал аңа.

Чагылганга гүя куе урман
Яшькелт күренə ачык күк йөзе.
Кабатлана «Кугу» сүзе кушып
Дусларымның монда күп сүзе.

Бар да «Кугу», бар да «Рəхмəт»лəлəр
Сəлам — кугу, уртак җыр — кугу...
Күңеллəрдəн күңеллəргə шулай
Дəвам итсен якты юл сузу!

*Киң җәмәгатьчелеккә билгеле булганча, болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының авторы Кол Галинең тууына 800 ел тулу юбилее татар халкының гына түгел, чын мәгънәсендә бердәм совет халкының культура, әдәбият бәйрәменә әверелде һәм киң күләмдә билгеләп үтелде. Казанда бөек шагыйрь иҗатына багышланган фәнни конференция һәм юбилей тантаналары булып узды. Узган елның март аенда башкалабыз Мәскәүдә, язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында Кол Гали иҗатына багышлап, тантаналы кичә үткәрелде. ЮНЕСКОның «Яңалыклар» информацион бюллетенендә, үзәк матбугатта һәм республика газета-журналларында шагыйрьнең иҗатын киң яктырткан мәкаләләр дөнья күрде.*

*Бу санда журнал укучылары игътибарына Татарстан АССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәновның мәшһүр шагыйрь иҗаты һәм аның рухи тормышыбыздагы урыны турындагы шул кичәдәге чыгышын һәм СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзеның «Литературная газета»ның 1984 ел 15 февраль санында басылып чыккан мәкаләләрен, РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь С. Хәким язмасын тәкъдим итәбез.*

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ШИГЪРИЯТНЕҢ САФ, РАУШАН КӨЗГЕСЕ

Кыя ни кадәр биек булса, аның зурлыгын күрү өчен шул кадәр ераккарак китеп карарга кирәк, ди халык. Ә менә XIII гасыр башларында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» шигъри эпосының әһәмиятен һәм мәгънәсен бөтен тулылыгы белән тану һәм бәяләү өчен зур вакыт, ара ераклыгы гына түгел, кешелек тарихының бөек борылышы — Октябрь революциясе кирәк булган. Бары тик Бөек Октябрь, туган илебездә социализмның җиңүе һәм КПССның ленинчыл милли политикасы тормышка ашырылу нәтиҗәсендә генә тормышыбыз кайчандыр хыял гына булып тоелган дәрәҗәдә алга китте, үзгәрде һәм чәчәк атты. Материаль шартларның үсеше исә, табигый рәвештә, гасырлар дәвамына изелеп килгән, хокуклары соң дәрәҗәдә чикләнгән халыкларның рухи тормышына да тамырдан үзгәреш кертте. Социалистик реализм, халыклар дуслыгы һәм туган илгә бирелгәнлек принципларына нигезләнгән милли культура һәм әдәбиятлар үзара бәйләнештә яңа биеклекләргә күтәрелде. Нәтиҗәдә бердәм, тату гаилә булып туган илебездә яшәүче барлык халыкларның да культура офыклары бермә-бер киңәйде, рухи мираска — күп еллар, гасырлар элек иҗат ителгән әдәби җәүһәрләргә игътибар үсте.

Әдәби-культура мирасына мөнәсәбәттә без тулысынча тарихилык, фәнни дөреслек һәм партиялелекне күз алдында тоткан ленинчыл методологиягә, партиябез күрсәтмәләренә нигезләнәбез. Монда бер нәрсә дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел, монда барысы да — телгә мөнәсәбәт тә, әдәби-культура ядкарьләренә бәя дә, тарих вакыйгаларын марксистик-ленинчыл күзлектән аңлату да гаять әһәмиятле. Мәшһүр

болгар-татар шагыйре Кол Галинең классик поэмасы турында уйланганда һәм фикер йөрткәндә әлеге мөһим күрсәтмәләр һәм принциплар даими игътибар үзәгендә булырга тиешле. Илебездә яшәүче барлык төрки халыкларның да рухи культурасы үсешенә җитди йогынтысы булган масштаблы һәм фундаменталь әдәби әсәр турында бара бит сүз.

Урта гасырларда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тарих сәхифәләреннән сокландыргыч зур юл үткән әсәр. Иҗат ителүгә үк бәрәкәтле туфракка төшеп, менә инде җиде гасыр ярым дәвамында ул халык күңелендә, халык хәтерендә яши. Киң катлау укучылар өчен тарихи оптимизм, рухи ныклык һәм бетмәс-төкәнмәс эстетик ләззәт чыганагы буларак, яңадан-яңа буыннарның күңеленә үтеп керә, сокландыруында дәвам итә. һәм, билгеле, әсәрнең үлемсезлеге һәм көче тылсым галәмәте генә түгел. Дистәләгән инеш һәм чишмәләрдән су алып киңәйгән һәм тирәнәйгән дәрья сыман, ул — халыкның гасырлар дәвамына тупланган бай тормыш тәҗрибәсе, рухи матурлыгы һәм иҗади омтылышларына барып тоташкан. Бөек Болгарда яшәгән борынгы бабаларыбызның иҗтимагый һәм рухи чынбарлыгы белән аерылгысыз булып үрелгән, тагы да төгәлрәге, шул тарихи чынбарлык нигезендә туган әсәр «Кыйссаи Йосыф».

Тарихтан билгеле булганча, поэма Идел буендагы Болгар дәүләтенең экономикасы һәм культурасы чәчәк аткан, нык үскән чорда иҗат ителгән. Аның авторы Кол Гали, безгә кадәр килеп ирешкән мәгълүматларга караганда, үз чорының зур шагыйре һәм күренекле фикер иясе була. Ул Бөек Болгарда, якынча 1183 елларда туган дип фараз ителә. Шулай ук аның уку һәм белем күтәрү максаты белән якын Көнчыгышның күп кенә илләре буйлап сәяхәт итүе, заманының байтак галим-гыйлем ияләре, шагыйрьләре, философлары белән очрашкан, аралашкан булуы мәгълүм. Гомумән, Кол Гали үз заманының традицион фәннәреннән киң мәгълүматлы, зур хәзерлекле һәм хөрмәткә лаек фикер иясе булган дип санарга тулы нигез бар. һәм шулар өстенә Кол Гали яшәгән һәм иҗат иткән еллар тарихта шау-шулы үзгәрешләре һәм фаҗигале вакыйгалары белән дә билгеле. XII—XIII гасырлар чатында дала якларыннан ташкын булып килгән илбасар яуларның вәхшилеге нәтиҗәсендә аерым шәһәрләр генә түгел, дәүләт кадәр дәүләтләр җимерелгән, юкка чыккан. Мәгълүм булганча, Бөек Болгар илбасарларга җиңел генә бирешмәгән. Хәтта әлегәчә каршылык күрми бару юлларында беренче җиңелү ачысын да татырга туры килгән аларга монда. Шулай да, Чыңгыз хан урдасының кабат һөҗүме нәтиҗәсендә, илбасарларның көнбатышка бару юлларында калкан булып торган дәүләт көчләренең тигезсезлеге нәтиҗәсендә җиңелергә мәҗбүр була. Кайбер чыганаклар күрсәткәнчә, шагыйрь Кол Галинең тормыш юлы әлеге драматик вакыйгалар чорында, чама белән 1236—1240 еллар тирәсендә өзелгән. Иленә, халкына авыр сынау һәм югалтулар килгән көндә шагыйрь Болгарда булган икән, димәк, аның туган җирен саклап батырларча көрәш кырында һәлак булу ихтималын күз алдына китерү кыен булмас.

Кол Гали яшәгән һәм иҗат иткән еллар чын мәгънәсендә үзенчәлекле, катлаулы һәм каршылыклы була. Элек-электән күп кенә төрки кабилә һәм халыклар яшәп килгән Көнчыгыш Европада исә әлеге каршылыклар аеруча кискенләшә. Бер яктан, мондагы дәүләтләрнең, аерым алганда, Идел буе Болгарларының феодализм җәмгыяте буларак нык үскән, каршылыклары көннән-көн арта барган чор була бу. Икенчедән, Евразия дөньясында яңа этник группалар формалашкан, халыкларның, һәм шул исәптән, төркиләрнең өзлексез хәрәкәте, яңа җирләргә күчеп утырулары белән дә характерлана ул еллар. Билгеле булганча, болар һәркайсы социаль мөнәсәбәтләрнең киеренкелегенә һәм төрле сыйныф вәкилләре арасындагы каршылыкларның бермә-бер үсүенә китергән. Кабилә һәм халыкларның дулкын сыман хәрәкәт итеп, алмашып, аралашып торуы алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең активлашуына, тел һәм культурадагы уртаклыкларның тирәнәюенә дә яңа мөмкинлекләр биргән, киң юл ачкан. Феодаль җәмгыятьнең үсеше, социаль каршылыкларның торган саен тирәнәя баруы исә иҗтимагый-социаль һәм мораль-этик проблемаларга булган кызыксынуны кызу темплар белән көчәйткән. Җәмгыять үсешенең базисын тәшкил иткән әлеге шартларның мәйданга чыгуы һәм кискенләшүе нәтиҗәсендә киң катлам халык массалары арасында иҗтимагый корылыш һәм тәртипләрнең асылына игътибар арта. һәм табигый рәвештә кеше шәхесенең кыйммәте, бөтен кешеләр өчен дә бер дәрәҗәдә матур, мул тормыш, «идеаль» дәүләт җитәкчесе турындагы хыялый-утопик идеяләр

мәйданга чыга. Шәхеснең җәмгыятьтәге урыны һәм әһәмияте, кешенең тыныч, матур тормышка, бәхет-сәгадәткә һәм иминлеккә хокуклы булуын яклау көчәя. Үз чорының фикер иясе һәм шагыйре булган Кол Гали, әлбәттә, киң җәмәгатьчелекне тирәнтен кызыксындырган һәм даими борчый башлаган әлеге проблемалардан читтә кала алмый. Чөнки шул объектив чынбарлыкта аның дөньяга карашы формалашкан, идея-эстетик эзләнүләре тамыр җибәргән. һәм шуңарга нигезләнеп шагыйрьнең мәшһүр поэмасы халык массаларының кешелекле уйланулары, гуманистик омтылышлары нәтиҗәсендә туган әсәр дип расларга урын бар.

«Кыйссаи Йосыф» кебек гүзәл эпос буш җирдә кинәттән генә тумаган, билгеле. Югарыда искә алынган иҗтимагый-социаль шартлар белән янәшәдә әлегедәй классик сәнгать әсәре туу өчен бай рухи җирлек һәм әдәби традицияләр булуы да кирәк бит әле. Шуңардан чыгып кына да Кол Галинең, барыннан да элек, бай традицияле булган болгар язма әдәбияты казанышларына ни дәрәҗәдә таянуын күзалларга мөмкин. Төрки телдәге язма әдәбиятның еракка киткән тамырлары булуы да яхшы мәгълүм. Әйтик, Йосыф Баласагуни дигән авторның 1069 елда иҗат ителгән «Кутадгу билиг» (Бәхет турындагы китап) әсәрендә үк инде бәхет һәм кешелеклелек турында гыйбрәтле уйланулар урын алган. Шәрык илләрен гизеп, тирән белем алган фикер иясенең Әл-Фәраби, Әл-Бируни, Ибн-Сина кебек Көнчыгышның күренекле философлары мирасыннан да яхшы хәбәрдар булуы бәхәс уятмас. Кол Гали иҗаты Көнчыгышның классик поэзиясе үрнәкләре белән дә тыгыз бәйләнештә туган. «Кыйссаи Йосыф»тан күренгәнчә, болгар-татар шагыйре үзенең бөек элгәрләре Фирдәүси, Гомәр Хәйямнар иҗаты белән дә яхшы таныш булган, сюжет сайлауда булсын, шигъри осталык үрләрен яулауда булсын, алардан үрнәк алган. Үз чиратында исә, болар һәммәсе Кол Гали иҗатының идея-эстетик җегәрен һәм зур киләчәген тәэмин итүдә хәлиткеч роль уйныйлар. Замандашлары Низами, Руставели һәм рус халкының мәшһүр «Слово о полку Игореве» әсәре авторы янәшәсендә дөнья әдәбияты тарихында мәртәбәле урын алырга хаклы шагыйрь Кол Гали. һәм бер дә юкка гына түгел. Чөнки күренекле шагыйрь һәм фикер иясе буларак ул үзенең үлемсез поэмасында Көнчыгышның классик поэзиясе һәм философиясендәге гуманистик традицияләрне төрки халыкларның бай эстетик тәҗрибәсе белән синтезлап, Идел буенда яшәгән болгарлыларның иҗтимагый һәм рухи омтылышын чагылдыручы гүзәл шигъри әсәр тудырган автор.

Шагыйрь үз чорының әдәби традицияләрен дәвам итеп, урта гасырларда аеруча киң таралган әдәби сюжетка мөрәҗәгать итә. Ул да булса тугры Йосыф турындагы легенда. Кайбер Көнбатыш версияләрендә аны гүзәл Йосыф турында дип тә йөрткәннәр. Мәгълүм булганча, бу сюжетка иҗат ителгән әсәрләр арасында Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы үзенең сюжет эшләнеше һәм дөньявилыкка йөз тотуы белән аерым урын алып тора.

Әмма Кол Гали, традицион сюжетка мөрәҗәгать итүенә дә карамастан, күз алдына, барыннан да элек, үз чорының кыю новаторы буларак килеп баса. Шагыйрьнең новаторлыгы нидән гыйбарәт соң? Беренчедән, ул традицион сюжетка яңача, заман күзлегеннән мөнәсәбәттә аермачык күзгә ташлана, легенданың социаль һәм мораль-этик мотивларына махсус игътибарда киң чагылыш таба. Икенчедән, поэма шул чорның җанлы сөйләм теленә якынлыгы, халык авыз иҗатына хас тыгызлык һәм образлылык, эпитет һәм төрле сынландыру чараларына байлыгы белән җәлеп итә. Сүз уңаеннан аның бу үзенчәлекләренең алга таба, үз чиратында, халык җырларында һәм яңа заман шагыйрьләре иҗатында дәвам иттерелеп, үстерелүен дә әйтергә кирәк. Гомумән, әсәрнең башыннан ахырынача үзенчәлекле тыныч һәм сабыр агышын тоясың, бу исә халык дастаннарыннан килгән эпик традициянең бер гәүдәләнеше булып тора. Поэманың һәр строфасы шәрык поэзиясендәге робагыйлар һәм халык иҗатында зур урын алган дүртьюллыклар сыман хикмәтлелеге белән дә игътибарга лаек. Җыеп кына әйткәндә, икеләнмичә расларга мөмкин — Кол Гали иҗаты мисалында ерактан килгән бай традицияләре булган төрки шигырь сыйфат ягыннан яңа югарылыкка, профессиональ шигърият биеклегенә күтәрелде. Сүзнең чын мәгънәсендәге классик таләпләргә җавап биргән профессиональлек турында баруы аңлашылса кирәк.

Камиллеккә ирешкән шигъри форма, киң катлам укучыларга аңлаешлы тел, стильдә иҗат ителгән поэма мавыктыргыч эчтәлеге, гуманистик һәм демократик юнәлеше белән дә үз һәм якын була халык күңеленә. Урта гасыр шартларында шагыйрь таланты-

ның шул дәрәҗәдә тирән һәм кыю эчтәлек белән ачылуына безгә бүген сокланырга һәм гаҗәпләнергә генә кала. Хаким идеология тарафыннан схоластика һәм дини фанатизм гына танылган бер чорда чынбарлыкның җанлы картиналарын сурәтләп, чын гуманизм һәм кешелеклелекне яклап дан җырлаган масштаблы әсәрнең дөньяга килүен башкача аңлатып булмый.

Дөрес, шигърият күгендә нинди генә зур фигура булуына да карамастан, үз чорыннан, үз мохитыннан азат була алмый шагыйрь. Андый таләп кую үзе дөрес булмас иде. Кол Гали иҗатында да ислам идеологиясенең йогынтысы үзен һәр даим сиздереп тора. Ләкин, шуңа да карамастан, әсәрнең үзәгенә алынган проблемаларны хәл иткәндә ул дини-мистик схемалар кысасында калмый, дөньявилыкны яклап чыга, гуманистик фикерләрне алга сөрә.

Поэмада үз заманының җитди социаль-әхлакый проблемалары күтәрелә. Шулай да шагыйрь таланты һәм аның фикер офыклары киңлеге ул проблемаларны вакыт һәм пространствода чикләми, ә гомумкешелек яңгырашы биреп хәл итә. «Кыйссаи Йосыф»ның сәнгать әсәре буларак бетмәс-төкәнмәс әһәмияте, беренче чиратта, хәзерге терминологиядән файдаланып әйтсәк, шәхес концепциясен хәл итүдәге новаторлыгында. Аның гуманистик пафосы һәм кешелеклелеге дә әлеге үзенчәлеге белән туры бәйләнештә тора. Ислам өйрәтүенчә, кеше алланың җирдәге бер колы, курчагы гына, ул булганына риза булып, үз язмышына үзе буйсынып яшәргә тиеш. Кеше генә түгел, аның әйләнәсендәге бар нәрсә дә алла кодрәтеннән тора, дип аңлаткан ул чорда хөкем сөргән идеология. Ә Кол Гали исә, әлеге өйрәтүләргә кискен төстә каршы чыга, әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны, кешегә мөнәсәбәттә гуманистик карашны яклый. Тугры Йосыф, зирәк карт Йагкуб һәм гүзәл Зөләйханың физик һәм рухи матурлыгына, гармониясенә дан җырлап, ул бер үк вакытта, кешенең кешелеклелеген даулый, аның акылы, көче һәм табигый хисләре алдында баш ия. Әлеге ышаныч һәм мондый кыюлык урта гасырларда яшәгән болгар-татар шагыйренә каян килә соң? Әлбәттә, иң элек, моны шагыйрьнең тирән гуманизмы, җир йөзендә яхшылыкның явызлыктан һәрчак көчлерәк булуына һәм киләчәктә дә һичшиксез өстен буласына ныклы ышаныч тудырган. Кешенең рухи көченә, физик матурлыгына һәм әхлакый тотнаклыгына җир йөзендә булган һәммә хәзиналәрдән дә кадерлерәк, кыйммәтлерәк нәрсә итеп карау нәтиҗәсендә шәхес концепциясенә мөнәсәбәттә Кол Гали поэзиясе безнең бүгенге карашларыбыз белән авазд аш яңгырый.

Шагыйрьнең гуманистик идеаллары чагылышы җәһәтеннән Зөләйха образы махсус игътибарга лаек. Нигезендә эпик башлангыч яткан бу образга Кол Гали җитди социаль-әхлакый вазифа йөкли, шунлыктан аның иҗат омтылышы һәм ихтыяры да монда аеруча калку чагыла. Билгеле булганча, ислам дине хөкем сөргән илләрдә хатын-кызның хәле бигрәк тә авыр була. Шәригать кануннары, тигезсезлеккә нигезләнгән җәмгыятьнең буыннан-буынга килгән гореф-гадәт һәм әхлак нормалары хатын-кызны иң элементар хокуклардан да гаҗиз булып, буйсынып яшәргә дучар иткән. Шуңа күрә дә хатын-кыз язмышы элек-электән Көнчыгышның күп кенә прогрессив фикер ияләре һәм шагыйрьләрен даими уйланырга мәҗбүр иткән принципиаль социаль-әхлакый проблема булып килгән. Ләкин гаять актуаль һәм бер үк вакытта четерекле дә булган бу мәсьәләне ул шартларда хәл итәргә омтылу башка сыймаслык хилаф эш саналган. Әйтик, Кол Галидән күп гасырлар соңрак яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрьләр дә әле бу мәсьәлә белән күзгә-күз очрашканда иң күп дигәндә үзләренең борчылу һәм ачынуын белгертү белән чикләнгәннәр. XIII гасыр болгар-татар шагыйре исә проблемага сыйфат ягыннан яңа, бөтенләй үзгә булган мөнәсәбәтен белдерә, ул гына да түгел, аны хәл итү мөмкинлекләрен күреп, оптимистик караш белән чыга. XX гасыр башларына кадәр дип әйтерлек әдәбиятыбызда сурәтләнгән хатын-кыз образлары, нигездә, үз язмышларына буйсынып яшәгән хокуксызлар, бәхетсезләр булды. Ә менә Кол Галинең Зөләйхасы андый түгел, эчтәлек һәм сыйфат ягыннан күпкә югарырак тора бу хатын-кыз образы. Зөләйха — гүзәл генә түгел, көчле һәм ихтыярлы шәхес, үз бәхете өчен үзе җавап бирә алган, көрәшергә сәләтле булган хатын-кыз ул. Күпме генә югалту һәм кимсетүләргә дучар булып та үзенең кайнар мәхәббәтен җуймаган, максатына ирешү юлында теләсә нинди чараларга да барырга әзер булган нык рухлы герой. Һәм шул ныклыгы белән Зөләйха үзенең бәхеткә лаек булуын исбат итә. Нәтиҗәдә, образ әйтеп бетергесез зур символик яңгыраш ала. Поэманың

сигезенче гасыр дәвамында халык хәтереннән төшми яшәп килүен һәм киләчәккә үтүен тәэмин иткән идея-эстетик җегәрнең әһәмиятле бер аспекты шунда икәнлеге бәхәссез булса кирәк.

Поэмада аеруча зур әһәмият бирелгән үзәк проблема — хөкемдар һәм халык бәхете проблемасын хәл итүдә дә чын гуманист булып кала Кол Гали. Көнчыгыш поэзиясендә беренчеләрдән булып ул халык мәнфәгате идеясен күтәреп чыга. Шагыйрь дәүләт җитәкчесенең төп вазифасын аның гади халык массаларын ихлас кайгыртып, халык бәхете өчен үз-үзен аямый янып яшәвендә күрә. Бары тик халык бәхете өчен яшәгән хөкемдар гына «идеаль» була аның ышануынча. Йосыф әнә шундый образ. Йосыфта шагыйрьнең дәүләт җитәкчесе турындагы хыяллары конкрет гәүдәләнеш һәм киң колачлы чагылыш тапкан. Халыкны ачлык газапларыннан коткару өчен кылган гамәлләре аның иң зур батырлыгы итеп очраклы рәвештә генә тасвирланмый. Йосыф образында Кол Галинең яңалыгы һәм изге омтылышлары гына түгел, шагыйрь һәм шәхес буларак кыюлыгы, батырлыгы да ачык чагыла. Урта гасыр шартларында халык һәм хөкемдар проблемасын күтәреп, аны Йосыф образында калку гәүдәләндерүне башкача бәяләү мөмкин түгел. Прогрессив фикер ияләрен һәм шагыйрьләрне гасырлар дәвамына даими борчып килгән проблемага яңа гомер, яшәү көче бирә Кол Гали. Мисал өчен, үз вакытында төрки телдә язган шагыйрь Йосыф Баласагуни һәм әзербайҗан шагыйре Низами да бай белән ярлыга тигез караучы шәфкатьле хөкемдар турында хыялланганнар. Алардан аермалы буларак, болгар-татар шагыйре проблемага җитди социаль яңгыраш бирә, әйтик, илдәге идарә гадел булсын өчен, хөкемдар түбәннән, халык арасыннан күтәрелергә тиеш, дип чыга ул. Йосыфның тәхеткә күтәрелгәч, үзенә вәзир итеп фәкыйрь бер кешене алуы да шул турыда сөйли.

Көчле дәүләт җитәкчесе һәм үзәкләштерелгән ныклы идарә турындагы бу идеяләрнең феодаль таркаулык һәм бүлгәләнгәнлек чорында яңгырашы аеруча актуаль һәм прогрессив күренеш. Ә «Кыйссаи Йосыф» иҗат ителгән елларда исә, Болгар иленә тоташ ташкын булып илбасарлар омтылганда бу чакыру тагы да җитдирәк әһәмияткә ия була. Үзара бәхәс һәм бүлешүләр нәтиҗәсендә аерылып, таркалышып өлгергән халыклар, аерым алганда Идел буе һәм Урал итәкләрендә яшәгән тугандаш төрки халыкларга вакытлы һәм кыю мөрәҗәгать булып яңгырый шигъри эпос. Ул берләшергә чакыра, бердәмлеккә өнди, күрше халыклар белән тату яшәүне яклап чыга. Тарихтан мәгълүм ки, болгарлыларның иң якын күршесе ул вакытта ук руслар булган.

Рус дәүләте белән Болгар арасында ул елларда эзлекле политик һәм сәүдә-экономик мөнәсәбәтләр урнаштырылган булуы мәгълүм. Әйтик, 985 елда олуг кнәзь Владимир белән болгар ханы Мөхәммәт арасында «Таш суда йөзгәнче, колмак суга батканчы» гамәлдә калсын дип төзелгән солых шул хакта сөйләүче гыйбрәтле дәлил булып тора. «Повесть временных лет» елъязмасында чагылыш тапкан мең еллык тарихы булган бу документ ике күрше халык арасындагы, тамыры бик еракларга барып тоташкан мөнәсәбәтләрнең ныклыгын раслый.

Һәм шушы урында «Кыйссаи Йосыф»ның тагы бер җитди мотивына махсус игътибар юнәлтү сорала. Башыннан ахырынача гади халык массаларының табигый омтылышларын яклаган поэма сугыш һәм тынычлык проблемасына мөнәсәбәттә дә гыйбрәтле яңгырашка ия. Билгеле булганча, халык өчен сугышның бер вакытта кирәге булганы юк. Шул хакыйкатьне тирәнтен аңлап кичергән шагыйрь тыныч, имин тормышка дан җырлый. Урта гасырларда кабул ителгән традицияләрнең берсенә кискен каршы чыгып, сугыш, яу чабу турында авыз ачып сүз дә әйтми, хәрби каһарманлыклардан башка гына киң полотнолы шигъри әсәр тудыра. Тыныч тормыш һәм кешенең иҗтимагый-рухи омтылышларын иминлек шартларында хәл итүне яклап чыга. Бу үзенчәлеге — чын мәгънәсендәге гуманистик бөтенлеге белән Кол Галинең мәшһүр поэмасы көнчыгыш әдәбиятларында гына түгел, ә гомумән, бөтен дөнья әдәбиятында да җитди урыны булган әсәр. Тыныч, матур тормышны олылаган, кешегә һәм аның гүзәллегенә, акыл көченә чиксез ышаныч белән мөлдерәмә тулы бу поэманың безнең көннәрдә заманча яңгыраш алуы да очраклы түгел. Сугыш һәм тынычлык проблемасы моңарчы булмаган дәрәҗәдә актуальләшеп, бөтен кешелекнең җанын тынгысызлап торган бер чорда үзеннән гуманизм һәм җирдәге имин тормышны олылап якты нур чә-

чеп торган бу әдәби җәүһәр, икеләнми әйтергә мөмкин, безнең көннәрдә үзенең икенче яшьлеген кичерә. Партиябез һәм халкыбыз тынычлыкны яклап көрәшкә күтәрелгән, прогрессив кешелекнең авангардында барган көннәрдә исә, бу аерым игътибарга лаеклы факт.

Әлеге сыйфатлар — тормышның гүзәллегенә сокланып, гуманизм идеяләрен актив яклап чыгуы болгар-татар язма әдәбиятының иң югары казанышы булган «Кыйссаи Йосыф»ка үлемсезлек яулап кына калмады, аны төрки халыклар шигъриятенең яңа сәхифәсен ачкан классик әсәр буларак та танытты. Гомумкешелек проблемаларын югары сәнгатьлелек дәрәҗәсендә чагылдырган поэма үз чиратында Идел һәм Урал буенда яшәгән төрки халыкларның рухи культурасын бөтендөнья әдәби процессына кушуга зур өлеш кертте.

Шагыйрьнең кемлеген белим дисәң, аңарга үз халкының мөнәсәбәте белән кызыксын, диләр. «Кыйссаи Йосыф» иҗат ителгәнгә җиде ярым гасырдан артык вакыт узып бара. Шул вакыт аралыгында халкыбыз язмышында күпме үзгәреш, сынау һәм югалтулар булып узган. Дәүләтләр таркалган, шәһәрләр җимерелгән, йортлар туздырылган, башлар җуелган. Язма әдәби әсәрләрнең бик күп өлеше тарих тузаннары астында мәңгегә югалып, күмелеп калган. Әмма Кол Галинең мәшһүр әсәре югалмаган, халык теленнән төшми яшәвен дәвам иткән, халык хәтерендә җуелмыйча безнең көннәргәчә исән-сау килеш килеп җиткән. Шушы урында Габдулла Тукайның халык җырларына мөнәсәбәттә әйтелгән сүзләрен, үлемсез поэма «Кыйссаи Йосыф»ка нисбәтле искә алудан тыелып калып булмый: «...Әйе, бу — кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады».

Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез... туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан сакланып калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле». Халык җырлары турында әйтелгән бу сүзләр, чынлап та, әлеге гүзәл шигъри әсәргә мөнәсәбәттә дә бик актуаль яңгырыйлар. Чөнки халык авыз иҗатындагы кебек үк, «Кыйссаи Йосыф»та да ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, дөньяга һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәт нормалары, иҗтимагый һәм идея-эстетик аңы, гүзәллекне фәлсәфи категория буларак тану үзенчәлекләре чагылыш тапкан.

Гасырлар дәвамында поэма халыкның яраткан һәм үз иткән сәнгать әсәре булган. Аны аерым-аерым гына укып чикләнмәгән халык, кышкы озын кичләрдә бергәләшеп җылы мич тирәсенә җыелып тыңлап туймаганнар. Поэманы, күләм ягыннан шактый озын булуына да карамастан, күпләр хәтта күңелдән дә белгән, һәр авылда диярлек аны көйләп, җырлап уку осталары да булган. Җыеп кына әйткәндә, ул халык теленнән төшмәгән, телдән-телгә, кулдан-кулга тапшырылып безнең көннәргәчә килеп ирешкән. «Кечкенә чакта шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләребез вә хатыннарыбыз сирәктер. Әлегедәй гүзәл әсәрләр турында сүз чыкканда: бу — татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы»,— дип, очраклы рәвештә генә язмаган халык шагыйре Г. Тукай.

Халык массалары «Кыйссаи Йосыф»ны тикмәгә, эч пошканнан гына укымаган. Ул иреккә һәм азатлыкка сусаган, тигез һәм бәхетле тормыш турындагы матур хыяллар белән рухланып яшәгән, яктылыкка һәм мәгърифәткә омтылган кешеләрнең җанына юлдаш булган. Поэмада укучы әхлак мәктәбе күргән, аның легендар геройларыннан күңел киңлеге һәм юмартлыкка, тугрылыкка һәм намуслылыкка өйрәнгән. Гомумән, күңелләренә хуш килгән әдәби әсәр хезмәт ияләренең социаль һәм рухи идеалларын формалаштыруда әйтеп бетергесез зур роль уйнаган.

Поэманың төрки халыклар арасында, бигрәк тә татар укучылары алдындагы, гадәттән тыш популярлыгы турында сөйләүче берничә фактка гына игътибар итеп узыйк. Бүгенге көнгәчә татарлар яши торган регионнарга ясалган археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә халык арасыннан «Кыйссаи Йосыф»ның 160 тан артык кульъязма нөсхәсе табылган. һәм шундый тарихи кульъязмалар саны елдан-ел ишәя бара. Шуның өстенә, күренекле татар шагыйре һәм галиме Утыз Имәни тарафыннан хәзерләнеп, поэма 1839 елда Казан университеты типографиясендә беренче тапкыр аерым китап булып басыла. Укучылар арасында аңарга сорау шул дәрәҗәдә була ки, аны ел саен дип әйтерлек теге яисә бу нәшрият меңәрләгән тираж белән басып тарата ки-

лә. Нәтиҗәдә, поэманың Утыз Имәни әзерләгән нөсхәсе 80 мәртәбәдән артык басмада дөнья күрә. Ә шагыйрьнең тууына 800 ел, әсәрнең язылуына 750 ел тулган көннәрдә исә Казанда поэманың фәнни яктан шактый камил эшкәртелгән өр-яңа басмасы укучылар кулына ирешә. Төрле характердагы бай фәнни белешмә материалы белән тәэмин ителгән бу басмада әсәрнең тулы төп тексты (транскрипциясе), хәзерге татар әдәби телендәге поэтик күчерелмәсе һәм рус телендәге сүзгә-сүз тәрҗемәсе тәкъдим ителә. Якын елларда поэманың рус һәм татар телләрендәге тагы да камилрәк яңа басмалары да көн күрер, дип ышанасы килә.

Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, гомумән, күп гасырлык тарихы булган татар әдәбиятында зур урын тоткан һәм аның үсешенә даими тәэсир итеп килгән әсәр. Анда күтәрелгән гуманистик идеяләр, поэманың югары сәнгатьлелек дәрәҗәсендәге гүзәл традицияләре татар әдәбиятының буеннан-буена якты эз булып дәвам итә, үстерелә килә. Төрле заманнарда яшәгән шагыйрьләребез, әдипләребез иҗатында аның йогынтысы һәрдаим күзгә ташланып тора. Кол Галидән теге яисә бу дәрәҗәдә шигъри осталыкка өйрәнгән шагыйрьләрнең исемлеген кыскача гына атап үтсәк тә, тулаем татар поэзиясе тарихын бер очтан икенче очка санап чыгарга мәҗбүр булыр идек. Әйтик, Котб һәм Мәхмүт Болгари (XIV гасыр), Мөхәммәдьяр (XVI гасыр), Мәүлә Колый (XVII гасыр), Утыз Имәни (XVIII—XIX гасырлар), Г. Кандалый һәм Акмулла (XIX гасыр)— әдәбиятыбызның үсеш дәверләрен билгеләп торган якты маяклар һәркайсы мәшһүр әлгәрләре булган Кол Гали иҗатыннан берөзлексез бәрәкәтле җылы нур алып торганнар. Яңа дәвер шигъриятебезне нигезләүче Г. Тукай һәм аның замандашлары М. Гафури, С. Рәмиевләр дә «Кыйссаи Йосыф»ка әледән-әле мөрәҗәгать иткәннәр, андагы кешелеклелек һәм иркен-матур тормыш турындагы идея-хыялдан рухи ныклык алып, шуны янә реаль чынбарлыкка нигезләнгән заманча сугышчан, гражданлы иҗатларына кайтарганнар. Гуманизм идеяләре белән өртелгән бу олы иҗат әле дә булса яңадан-яңа буын әдипләргә игелекле йогынты ясап, заман белән бергә актив яшәвендә дәвам итә. Халыкның рухи һәм идея-эстетик идеалын чагылдырган үлемсез әсәр бүген дә аның хәтерендә туган илгә бирелгәнлек, туган җиргә һәм кешегә мәхәббәт, планетабыз иминлеге өчен көрәш символы буларак саклана.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы бер үк вакытта тугандаш башкорт, казах, үзбәк, төркмән һ. б. халыкларның да рухи тормышында әһәмиятле урын алып торган һәм ул әдәбиятларга гасырлар дәвамында бәрәкәтле йогынты ясап килгән. Шуңа да гыйльми хезмәтләрдә аның еш кына уртак хәзинә буларак искә алынуы табигый.

Әлеге бай, гүзәл традицияләрнең бүген лаеклы дәвамы бар — ул күпмилләтле совет әдәбияты. Милли әдәбиятларның гасырлар дәвамында тудырган иң гүзәл классик үрнәкләренең сау, сәламәт башлангычлары белән даими бәйләнештә булган совет әдәбияты бүген дөнья күләмендә тыңдәшсез зур авторитетка әверелде.

Партиябез милли әдәбиятларның үсешен даими кайгырту белән бергә, халыкларның рухи культурасы традицияләренә һәм үткәндәге әдәби мирасына да игътибарлы һәм сак килүне таләп итә. Совет халкының материаль һәм рухи тормышын тагы да бай, югарырак итеп күрергә теләүдән килгән бу олы кайгыртучанлык партиябезнең тарихи XXVI съездында һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы пленумнарында аеруча киң чагылыш тапты.

Әдәбият һәм сәнгатьнең үсүе — ул бер үк вакытта Туган илебез халыкларының какшамас дуслыгы, туганлыгы ныгый баруы, күп милләтле һәм күп бизәкле совет культурасының үзара ярдәмләшеп баюы, көннән-көн чәчәк атуы дигән сүз дә. «Үзенең гуманизмы, иҗади күптөрлелеге һәм сәнгать чараларының байлыгы белән сокландырган Совет культурасы халыкларның үзара аңлашуына зур өлеш кертә,»— дип әйтте иптәш Константин Устинович Черненко КПСС ҮКның Июнь (1983 ел) Пленумында сөйләгән докладында.

Болгар-татар шагыйре Кол Галинең тууына сигез гасыр, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының язылуына 750 ел тулган көннәрдә без бу туганлык һәм бергәлекне тагы бер мәртәбә үз күзләребез белән күрдек. Бу олы юбилей республикабыз башкаласы Казан чикләрендә генә уздырылган бәйрәмгә әверелеп калмады. Тантаналы кичә һәм шагыйрьнең үлемсез мирасына багышлап үткәрелгән фәнни конференцияләрдә Мәс-

кәү, Ленинград, Уфа, Алма-Ата һәм Ташкент шәһәрләреннән килгән галимнәр, шагыйрьләр катнашты. СССР һәм РСФСР Язучылар союзлары катнашы белән илебез башкаласы Мәскәүдәге юбилей көннәре дә тантаналы бәйрәм рухында узды, һәр кичәдә һәм һәр чыгышта өстенлек иткәне халыклар дуслыгы һәм интернационализм идеяләре булды.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — конкрет тарихи җирлек һәм чынбарлыкта туган әсәр. Ләкин дөнья әдәбиятларының бөек шедеврларыннан берсе буларак, ул үзен дөньяга китергән тарихи чорга караганда күпкә озынрак гомер кичерә. Халык хәтерендә җидегасырлык җиде гасырдан тора бирә... 

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — конкрет тарихи җирлек һәм чынбарлыкта туган әсәр. Ләкин дөнья әдәбиятларының бөек шедеврларыннан берсе буларак, ул үзен дөньяга китергән тарихи чорга караганда күпкә озынрак гомер яулады. Халык хәтерендә җуелмыйча безнең көннәргәчә килеп ирешкән әдәби җәүһәр бүген дә яшәвен, кешеләргә бетмәс-төкәнмәс идея-эстетик ләззәт китерүен дәвам итә. Кешелеклелек һәм игелек нуры белән өртелгән, җирдәге тормышны олылаган, бәхетле матур тормышка дан җырлаган чын сәнгать әсәренең язмышы башкача була алмый.

# Георгий Ломидзе,

СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты

## СҮНМӘС НУР

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы язылуга җиде йөз илле ел вакыт үтте.

Урта гасырларның күренекле шагыйре Кол Галинең гуманистик традицияләре төрки телле культураларның формалашуына гаять зур йогынты ясады. Ул болгар-татар язма поэзиясенә нигез салды. Аның поэмасы башкорт, казах, үзбәк, төркмән һәм башка әдәбиятларның алтын фондына керде.

Шагыйрьнең гомере артык озын булмады, фаҗигале тәмамланды. Ул 1183 еллар тирәсендә туган һәм чыганаклардан күренгәнчә, 1236—1240 елларда, Болгар дәүләте Чыңгыз хан урдалары тарафыннан тар-мар ителгән чорда, һәлак булган.

Кол Гали бөек шагыйрь, фикер иясе, һәрьяклап укымышлы кеше булган. Аның гүзәл «Кыйссаи Йосыф» поэмасы дөнья әдәбиятының бөек җәүһәрләреннән санала.

Кол Гали Низаминың, Руставелиның, «Игорь полкы турында сүз» авторының замандашы булган. Бөек замандашлары хакында аның нәрсә дә булса белүен раслаучы беренчел фактлар да юк. Ләкин шунысы кызыклы: аның «Кыйссаи Йосыф» поэмасы үзенең кайбер төп мотивлары белән Руставели һәм Низами иҗатында чагылган идеалларга аваздаш. Гуманизмны, халыклар арасындагы туганлыкны, гомуми әхлакый идеалларны, рух ныклыгын, яшәешнең югары мәгънәсен саклаучы төрле илләрнең һәм халыкларның шагыйрьләре арасында нинди дер рухи аваздашлык хасил булган.

Әлбәттә, эшнең асылы, «Кыйссаи Йосыф» поэмасында тасвирланган гадел яки тугры Йосыф турындагы мифның Тәүраттә дә, Коръәндә дә булуында түгел. Шәрык әдәбиятында Йосыф һәм Зөләйха темасына язылган йөз илледән артык әсәр булуга карамастан, тикшерүчеләр Кол Галинең әзер сюжет тезелешен турыдан-туры үзләштерү яки аңа зур үзгәрешләр кертү юлы белән китмәгәнлеген дөрес күрсәтәләр. «Кыйссаи Йосыф» — төрки халыкларның башлангыч феодаль дәвере әдәбияты тарихында яңа сәхифә ачкан оригиналь һәм үзенчәлекле әсәр. Поэма искиткеч популярлык, шөһрәт казанды һәм казана килә. Статистика белән мавыгучылар тарафыннан ачыкланган: 1839—1917 еллар арасында, аннан соңгы елларны исәпкә алмаганда, әсәр җитмеш тапкырдан артык басылып чыккан.

Кол Гали әсәре битләрендә гаять көчле дәрәҗәдә кайнаган хисләр бәрелеше, изгелек һәм явызлык, намуслылык һәм намуссызлык, дөреслек һәм ялган, гаделлек һәм законсызлык, тыйнаклык һәм мактанчыклык, комсызлык һәм вөҗданлылыкның үзара көрәше безне хәзер дә чиксез дулкынландыра. Беренче карашка, Кол Гали фантастик, реаль булмаган, шартлы, ярыммистик дип әйтерлек дөнья барлыкка китерә. Анда илаһи, сихри көчләр хәрәкәт итә. Алар кешенең гамәленә һәм ниятенә юнәлеш бирәләр, язмышына тыкшыналар.

Әмма поэмада фантастик, шартлы башлангыч җанландырылып бирелгән, конкрет чынбарлык белән бәйләнгән. Хыялый һәм чынбарлык күренешләре үзара нык бәйләнеп, үрелеп, үзенчәлекле, эстетик яктан югары булган бөтен бер дөнья хасил итәләр. һәм поэмада тасвирланган вакыйгаларның чынбарлыкта мөмкин булуына, хәтта дөреслегенә ышану тойгысы барлыкка килә. Шагыйрь гипербола һәм метафораларны күп кулланып, характерларны, вакыйгаларны, капма-каршылыклар көрәшен калку сурәтли, геройларның әхлакый һәм кешелек асылын тулырак ачып бирә.

Поэманың төп герое язмышында түбән катлаудан чыккан кешенең иң югары властька күтәрелү идеясе генә чагылыш тапмаган, гәрчә бу идея үз заманы өчен кыю, гадәттән тыш күренеш булса да. Кол Гали поэмасының мәгънәсе киңрәк, масштаблырак. Йосыф кайгы-хәсрәт, газапларны да аз кичермәгән. Ул көнчел агалары хыянәтенә дучар булган, еланнар һәм төрле хәшәрәтләр белән тулган куркыныч коега ташланган, бик арзан бәягә коллыкка сатылган, зинданга ябылган. Әмма Йосыф өметсезлеккә бирелми, тиеш булмаган бер генә эш тә эшләми, югалып калмый. Ул — дөреслекнең, түземлекнең, тугрылыкның, эчкерсезлекнең, гадилекнең, кешеләрне яратуның җанлы бер гәүдәләнеше. Вакыйгалар кинәт үзгәреп, Мисырда атаклы кеше булып китүенә карамастан, Йосыф үзенең табигатенә, гаделлелегенә, вөҗданына хыянәт итми. Мисыр патшасы Кыйтфирнең хатыны Зөләйха Йосыфка акылдан шашар дәрәҗәдә гашыйк була. Зөләйханың мәхәббәте тасвирланган сәхифәләр шундый көчле, шулкадәр тыелгысыз илһам белән язылганнар ки, алар сезнең йөрәгегезне көйдереп ала сыман. Ләкин Йосыф чибәр Зөләйханың вәсвәсәсенә бирешми. Аның үзен сыендырган Кыйтфир исеменә тап төшерәсе килми, чөнки мәхәббәтне ул ике як өчен дә уртак эчкерсез хис, гашыйкларның йөрәк ашкынуы һәм табигый рәвештә берләшүе дип аңлый. Аның аскетизмы кешелек сафлыгыннан килә.

Ихтимал, Кол Галинең кыю новаторлыгы, аның демократик катлаудан чыккан кешене тәхеткә менгерүендә, аңардан хөкемдар ясавында гына түгелдер. Шагыйрь власть ияләрен башкача бәяләргә, аларның социаль тамырларын, социаль нигезен аныкларга омтылмаган, дип уйларга кирәк. Ул әсәре белән икенче, тагын да әһәмиятлерәк гуманистик фикерне раслаган: язмыш, аның теләсә нинди мәкерле һәм көтелмәгән борылышлары булуга да карамастан, изге күңелле, гадел, намуслы, кешеләрне яратучы, аларның иминлеген кайгыртучы, көтелмәгән хәлләрдә, хәтта фаҗигале хәлләрдә дә үзенең дәрәҗәсен югалтмаган кешеләргә яхшылыкны йөзе белән кире кайтара. Әйтерсең лә, шагыйрь безне изге күңелле, кешелекле булырга чакыра, шул очракта гына син теләгәнеңә ирешерсең ди, чөнки бу дөньяда кешедән дә бөек зат юк, кеше бар нәрсәдән дә: байлыктан да, алтыннан да, энҗеләрдән дә, теләсә нинди әйбердән дә өстен.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасында шундый бер эпизод бар: Мисырның хөкемдары ниндидер Малик тарафыннан кол итеп сатылучы Йосыфны үзенә сатып алырга тели. Үлчәүнең бер ягына Йосыф баса, ә икенче ягына, Малик белән вәгъдәләшкәнчә, хөкемдар чиксез күп хәзинә-байлык сала. Ләкин Йосыф кыйммәтле әйберләрдән авыррак булып чыга. Чөнки Йосыф — Кеше. Әйберләр никадәр кыйммәтле, никадәр авыр булмасыннар, бервакытта да кешенең рухи, әхлакый дәрәҗәсе белән тигезләшә алмыйлар. Бу Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасындагы иң әһәмиятле фикерләрнең берсе.

Шагыйрь тынычлыкка, дуслыкка, гаделлеккә өнди. Ул сугышны кураламый, кешеләр арасындагы үзара дошманлыкны һәм шикләнүчәнлекне гаепли. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә бер тамчы да кеше каны коелмый. Әйе, күз яшьләре мул коела, ә кан — юк. Кешеләр өчен, аларның иминлеге хакына эшләнгән яхшылык эзсез югалмый. Тугры Йосыф үлгәч, ул күмелгән илдә муллык урнаша, халык хәерчелектән һәм ачлыктан котыла. Аның изгелеге, кешелеклелеге якты нур булып кешеләргә хәтта «теге дөньядан» да килеп җитә, аларның күңелен күтәрә, кайгы-хәсрәтләрне җиңәргә ярдәм итә. Дөреслек, яхшылык, кешелеклелек җиңелмәс, алар мәңге яшәячәк һәм яшәргә сәләтле.

Поэманың ахырында шагыйрь гөнаһлы дөнья белән идарә итүче көчләргә ялварып мөрәҗәгать итә. Ул бу көчләрнең киң күңеллелегенә, шәфкатьлелегенә ышана, алардан яхшылык күрсәтүне, шагыйрьнең моңсу күңелен шатландырып, аңа рәхим-шәфкать иңдерүне сорый. Ул юкка газап чикмәгән, юкка гына мәхәббәт ту-

рында, хыянәтнең, көнчелекнең, мәкерлекнең үзгәрешсез асылы турында гүзәл поэма иҗат итмәгән. Кешелек хәтере хәзинәсенә һәм культурасына Кол Гали сизелерлек зур өлеш кертте.

Ерак уникенче гасырда бөек шагыйрь кабызган изгелек нуры сүнмәде. Ул тарих җилләре һәм давыллары һөҗүменә бирешмәде. Кол Гали хыялланган, аны борчыган проблемалар безнең заманда да актуаль. Бөек әсәр һәрвакытта заманча яңгырый һәм яшәргә сәләтле. Ул бервакытта да искерми.

## Сибгат Хәким

# БУЫННАР АВАЗЫ

Башта ишеттем, тыңладым. Соңыннан укыдым. Бала чак. Авыл. Кыш. Мәри урманы. Мыекларына боз каткан кешеләр. Бүрәнә төяп базарга узалар. Төн буе чана табаны тавышы ишетелеп тора. Безнең өй каршында кое. Ишек төбендә чиләкле су. Өстә боз, чүмеч...

Ямь керде өйгә, ә тышта
Җиһанның тоташ кары,
Эштән соң китап тыңларга
Әтинең чордашлары
Җыелды кичен, җан керде,
Шунда бер читтә посып,
Тыңладым, кайда Зөләйха?
Кайда, дип, хәзер Йосыф?
Ишек төбендә бозлы су,
Берәм-берәм чүмечләп
Эчтеләр, янган йөрәккә
Торды алар су өстәп.
Кызсалар, кисәтте әти:
Укыйм, имеш, кем өчен?
Куйды хәзрәти Галинең
Ялтыратып кылычын...

Укыйлар, тыңлыйлар. Төш юрыйлар. Җиде тулы башак — җиде ел туклык. Ачлык куркыта. Тукайның «Көзге җилләр»е кинәт искә төшә. Кайдадыр ачлыктан интеккән ярлылар елый. Әнидән сорыйм: «Әни, бу шигырьләрне әти базардан алып кайттымы?» дим. Әни бер почмакта торган, шушы көнгә чаклы әз генә дә тутыкмаган Болгар чоры көзгесенә күрсәтә. Ул көзгенең дүрт почмагында дүрт кош утыра. «Әнә шул кошлар инде ул шигырьләрне үзләренең канатларында алып килгәннәр»,— ди. Дүрт уяу кош. Берсе арыса, юлны икенчесе дәвам иткән. Икенчесе арыса, өченчесе, аннан — дүртенчесе. Җилдә, яңгырда, давылда. Сигез гасыр буе туктаусыз очканнар алар. Мин бер читтә тыңлыйм, тышта буран улый. «Йосыф китабы» белән менә мин шулай таныштым. Икенче тапкыр очрашуым сугышта, Дугада, сугышчан сакчылыкта булды. Ил язмышы хәл ителгән көннәрдә. Уйламаганда-көтмәгәндә күз алдымда Кол Гали пәйда булды.

Юк, булуы мөмкин түгел, безнең
Бу язмышка кем ул кызыккан?
Эзләп, үтеп мина кырларыннан,
Үтеп хәтта алгы сызыктан,
Шагыйрь Гали килсен... Монда фәкать
Разведчиклар гына булгалый,
Уникенче гасыр башларында

Иҗат иткән шагыйрь Кол Гали
Монда әле нишләп йөри икән?
Тәз, мәһабәт, горур сынлы ул,
Гел сөйләнә үзе: кәтмәгәндә
Очраштыра — гомер шундый ул.
Борчуларын яшермәде миннән:
Безнең тарих — сезнең кулда, — ди.
Улларының батырлыгын таңда
Тикшерергә чыккан Кол Гали.

Йөри карап безнең иманлекне,
Тимә, йөрсен, кума, ул моннан
Үзе китәр, ярдәм итәр өчен
Тарих кайчак куба урыныннан.
Йөри карап таңда иманлекне,
Солдатлары сабыр, гадиләр,
Ярты халык Галиләрдән тора,
Ватанына тугры Галиләр...

Мине, шагыйрьне уйландырган нәрсә — вакыт. Сигез гасырны эченә алган вакыт. Сәнгать әсәре өчен иң усал, иң рәхимсез тәнкыйтьче — фәкать вакыт. Вакыт сынавын сирәк әсәрләр генә уза. «Кыйссаи Йосыф» ник шулай озак яши? Үзе бит бик гади. Минем аны уйлап чыгарган дүртьюллыклар шикелле генә алар. Халыкта аларны робагыйлар дип атап йөртәләр. Формасы гади. Үзе туйдырмый. Ул шигырьләрнең үз моңы бар. Кабатланмый торган аерым бер моңы бар. Биш мең юллык шул китап бер бөтен эпик җыр булып көйләнә, җырлана. Күбрәк хатын-кызлар көйләп укыйлар иде. Хатын-кызлар тавышы күңелдә күбрәк калган минем. Алар арасында үзләренең Зөләйхалары да бар иде. Гасырлар, буыннар авазы бу. Бу шигырьләрне халык үзе көйгә салган. Бу аның мәңге яши торган, мәңге үлми торган авазы.

Ә башкаларга йогынтысы ничаклы! Ул йогынты үзеннән соңгы бөтен татар шагыйрьләрендә сизелә. Тукайда, Тукайдан соңгы хәзерге шагыйрьләрдә ул йогынты. Берничә йөз еллык традициянең нигезе булып тора ул әсәр. Бөтен җырлаганы: сабырлык, тыйнаклык, батырлык, мәхәббәт, тугрылык. Шагыйрь Йосыфны «тугры Йосыф», ди. Татар халкы Тукайны «тугры Тукай», дип йөртә. Халыкка тугрылык.

Әсәрдә халыкны иң борчыган нәрсә — ачлык. Хыялы: икмәк, иген, туклык. Төштә дә, өндә дә шул... Йосыфның Мисырдан күчкән яңа шәһәре — Эмин. Бу тынычлык, ирек, бәйсезлек дигән мәгънәдә. Әсәрнең шулай халыкчанлыгы, сафлыгы мине сокландыра. Бу әсәрне укыгач кешелекнең бала чагы турында уйлана күңел. Марксның борынгы грек әдәбияты турында әйткән фикерләре күңелдә яңара. Кешелек үзенең бала чагын сагынып яши, ди Маркс. «Кыйссаи Йосыф» грек халкының бөек әсәрләре белән аваздаш. «Кыйссаи Йосыф»та татар халкының бөтен милли рухы, характеры чагыла.

Мин туган йортта борынгы Болгар көзгесе саклана. Уникенче йөз көзгесе. Көзгенең дүрт ягында дүрт кош. Шулар «Кыйссаи Йосыф»ны безнең чорга исән-сау китереп җиткергәннәр. Ерак юлдан соң ял итеп утыра алар. Уяулар. Тагын да озаграк, ерраграк юлга әзерләнәләр шикелле. Илаһи сәнгать. Канатлы бөек сәнгать.

Юктыр газаплы, кыен юл
Китапның юлы кадәр;
Үлмиләр, яшиләр озак
Йосыфлар, Зөләйхалар.

# РОССИЯДӘГЕ 1905—1907 ЕЛЛАР РЕВОЛЮЦИЯСЕ — КАЗАНДА

Быел беренче рус революциясенең башлануына 80 ел тула, шул уңайдан илебез халыклары самодержавие белән героик көрәшнең тарихи сәхифәләренә тагын бер мәртәбә дулкынланып һәм горурланып мөрәҗәгать итәләр.

Беренче рус революциясе елларындагы җирле партия комитетлары тарихына күп хезмәтләр багышланган. Шул әдәбиятның кызыклы бер өлешен төрле мемуарлар, истәлек-хатирәләр тәшкил итә.

1905—1907 еллардагы Казандагы революцион вакыйгаларга актив катнашучылар да үз истәлекләрен язып калдырганнар. Аларның авторлары социаль хәлләре, яшь вермалары, белемнәре буенча төрле кешеләр булганнар, исталекләрен дә төрле вакытта, төрле шартларда язганнар (мәсәлән, кайберләре революциядән соң вакыйгаларның кайнар эзеннән үк язылса, икенчеләре исә дистәләрчә еллар узгач, совет чорында дөнья күргән). Шулай булуга да карамастан, ул истәлек-материаллар туган ягыбызның бай тарихын өйрәнүдә искиткеч мөһим роль уйныйлар. Алар безгә заманның революцион рухын тоярга һәм күз алдына китерергә бик нык ярдәм итәләр.

Шунысын да искә алып китәргә кирәк: истәлек-хатирәләр башлыча әдәби-публицистик планда язылганнар, күп вакытта авторлар үзләре шаһит булган вакыйгаларны гына тасвирлыйлар, шуңа күрә аларның фәнни әһәмияте дә безнең өчен төрле булып тора. Бу мәкаләдә без кайбер билгеле шәхесләр тарафыннан язылган истәлекләргә тукталып, аларның үзенчәлекләрен, революция тарихы өчен нинди кыйммәтле чыганак икәнлеген күрсәтүне максат итеп куйдык.

РСДРПның Казан комитеты 1905 елның беренче көннәреннән үк массаларны революцион рухта тәрбияләү, аларда пролетар интернационализм хисен үстерү өчен гаять актив эш башлап җибәрде. Казанда таратылган күпсанлы листовкаларда, прокламацияләрдә большевиклар халыкны бердәм күтәрелергә өндәделәр, политик моментны аңлатырга тырыштылар, принципиаль позицияләрдән пролетариатның сыйнфый дошманнарын фаш иттеләр. «Эшчеләр, руслар да, татарлар да бер үк төсле авыр язмыш кичерәләр, шуңа күрә алар туганнарча бер гаиләгә тупланырга тиешләр. Аларны нәкъ бер төсле итеп хуҗалары изә, бердәй камчы алар җилкәсен туный. Төрле милләт эшчеләре — татарлар, руслар, яһүдләр, әрмәннәр берләшкән очракта гына аларга җиңү киләчәк... туганнарча кулга-кул тотышканда гына, дибез без, эшчеләр бәхетле көнгә чыгачак»[1],— дип әйтелгән комитет тарафыннан таратылган «Татар иптәшләргә» дигән прокламациядә.

1905 елның январь-март айларында Казанда 26 стачка булып уза, аларда 6594 кеше катнаша[2]. Забастовка хәрәкәтенең яңа дулкыны 1 нче Майны бәйрәм итүдән соң башланды. Бу вакыйгаларны В. Н. Залежский[3] менә ничек искә ала:

«Казан оешмасы 1 Май бәйрәмен киң рәвештә билгеләп узуны оештырды. Полиция һәм обывательләр массасы 1 Май көнен шомланып һәм дер калтырап көттеләр. Дары һәм Алафузов заводларында әзерләнгән тәртипсезлекләр турында нефть бакларын яндыру, дары базларын шартлату турында төрле имеш-мимешләрне алдан ук киң тарата башладылар.

Чынлыкта исә комитет 1 Май тантанасын шәһәрдән бөтенләй читтә — кәймәләрдә уздырырга карар бирде. Иртән иртүк эшчеләр, хәтта солдатлар төялгән күп-

[1] «Пути революции», 1923, 3 сан, 115 б.
[2] Очерки истории партийной организации Татарии. Казань, 1973, 79 б.
[3] Залежский В. Н. (1880—1957) — рус революцион хәрәкәтендә актив катнашучы. 1905—1907 еллар революциясе вакыйгаларында Казанда һәм Петербургта катнашкан. 1915 һәм 1917 елларда Үзәк Комитетның Рус бюросы әгъзасы. Октябрь революциясендә һәм гражданнар сугышында актив катнашкан. 1923 елдан педагогик эштә.

санлы көймәләр бер-бер артлы Казанка буйлап түбәнгә юнәлделәр. Иртәнге тугызга пристаньнарда бер генә буш көймә калмады диярлек, булганнарын бәйрәмчеләр яллап өлгергән иде инде.

Маевка беркем дә сизмәслек итеп яшерен оештырылды. Аның кайда булачагын бер-ике кеше генә белә иде. Елга буена сибелеп утырган патрульләрне дә беркем абайларлык түгел: карыйсың, монда кармагына карарга да онытып бер «балыкчы» утыра, су буендагы чирәмлекләрдә самовар гөжләтеп, табыннар әзерләп эшче гаиләсе урнашкан, алар да күрер күзгә гамьсез генә ял итәләр. Үтеп баручы көймәләр шул «балыкчылардан» яки күңелле гаилә башлыкларыннан кая барырга кирәген белеп алалар.

Маевка Игуменов урманында, утрауга әверелгән бер таучыкта узды. Анда 300—400 ләп кеше җыелды. Казан комитетының иң көчле вәкилләре чыгыш ясадылар, шулар арасында «Иптәш Алексей» (Лозовский).

Көймәләр флотилиясе кайтыр юлга чыккач, эшчеләрнең дулкынлануы соң чиккә җитте. Алдагы көймә өстендә Казан комитетының бәрхеттән тегелгән зиннәтле кызыл әләме күтәрелде. Башка көймәләр (алар барлыгы утыз бер иде) аны урап алдылар һәм үз байракларын күтәрделәр. Шунда ук берәү бу күренешне «Казан комитетының эскадрасы» дип атады»[1].

Эшчеләр арасында РСДРПның Казан комитеты йогынтысы үсә барды. Май вакыйгаларыннан соң Алафузов заводы эшчеләренең революцион активлыгы 1905 елның 7 июлендә стачкага әверелде. Ул стачка бер атна дәвам итте һәм аңа 5000 нән артык кеше кушылды. В. Н. Залежский истәлекләрендә бу стачканы оештыру буенча большевикларның эшчәнлеге түбәндәгечә тасвирлана:

«4 июль көнне, эштән соң, завод капкасы каршында партия агитаторы эшчеләрне туктатып, кечкенә генә речь сөйләде, ул аларны болыннарга чыгып җыелышка кушылырга өндәде. Шунда ук комитет прокламацияләре таратыла башлады... Ораторга 500 ләп кеше кушылды. (...)

Икенче көнне комитет митингларны дәвам иттерергә болыннарга Лозовскийны җибәрде. Аларга казаклар һөҗүм иттеләр, Лозовский кулга алынды. Ләкин эшчеләр кулларына ташлар тотып, «заводны тар-мар итәбез»,— дип, аны азат иттеләр»[2]

Күрәбез, эшчеләр казакларга һәм полициягә коралды каршылык күрсәтергә батырчылык итәләр, партия агитаторыннан хакыйкатьне ишетергә теләү курку хисеннән көчлерәк булып чыга. Шунысы да бик мөһим: шактый шүрләгән властьлар эшче массаларына юл куярга мәҗбүр булалар.

РСДРПның Казан комитеты бөтен җирле оешмалар белән элемтә урнаштыруга, яшерен әдәбият алуга үз эшчәнлегендә бик зур әһәмият бирә. Бу эшчәнлек турында В. В. Адоратский[3] болай дип искә ала:

«1905 елда бездә револьверлар белән коралланган хәрби дружина бар иде. Читилләр белән элемтә оештырдык, аннан әдәбият алып тордык. Хатлар конвертларда да килеп ирешә иде. Соңга таба контрабандистлар аша даими транспорт булдырдык. Бер иптәшебез җәй саен пароходка утырып Италиягә чыгып китә дә әдәбият алып кайта. Кайтуга минем яныма килә, парольне белдерә, мин пристаньга үзем төшәм, әдәбиятны үземә алып кайтам. Аны саклауны төрле урыннарда оештырдык, мәсәлән, университетта аны иптәш Державин анатомик театрда саклады. Әдәбиятны саклау катлаулы һәм хәвефле эш иде»[4].

1905 елның көзенә революцион хәрәкәт гаять зур көч белән үсә барды. Октябрь политик стачкасы матбугат эшчеләре чыгышыннан башланып китте. Аңа башка завод-фабрика эшчеләре, студентлар кушылды. Массаларның революцион күтәрелүе үзенең иң югары ноктасына менеп җитте. Солдатларга һәм казакларга каршы коралды сугышлар башланды. РСДРПның Казан комитеты тарафыннан чыгарылган бюллетень халыкны тагын да активрак көрәшкә чакырды: «Барыгыз да урамнарга! Барыгыз да эш ташлагыз! Үтерүчеләргә үлем! Царизмга үлем!» Казандагы 17—21 октябрь көннәре — истәлекләрдә иң тулы чагылыш тапкан көннәр. Ул вакыйгалар турында А. Я. Аросев[5] бик җентекләп язып калдырган:

---

[1] Залежский В. Н. На путях к революции (1896—1906 гг.), кн. I.— М.-Л., 1925. 149—152 бб.

[2] Залежский В. Н. Шунда ук.

[3] Адоратский В. В.— Россиядәге революцион хәрәкәттә актив катнашучы (1878—1945). Казан университетында укыган. 1904 елның язында Казанга эмиграциядән кайта, һәм шул елның июлендә РСДРПның Казан комитеты составына керә. Совет чорында — күренекле тарихчы, академик, 1931—1939 елларда — Марксизм - ленинизм институты директоры.

[4] Стенографический отчет вечера «Истпарта» 3 июня 1921 г.— «Пути революции,» 1923, 3 сан, 64—65 бб.

[5] Аросев А. Я. (1890—1938) — күренекле совет дәүләт һәм партия эшлеклесе, язучы. 1905—1907 еллар революцион вакыйгаларында Казан реаль училищесы студенты булган чакта катнаша. 1907 елдан партия әгъзасы. Октябрь революциясендә актив катнашкан, Мәскәү Хәрби-Революцион Комитеты әгъзасы. 1924—1933 елларда — дипломатик эштә.

«Казанда 1905 елның 16 октябре.

Көндезге уникедә университетта гаять зур демонстрация башланды. Моңа кадәр эленке-салынкы йөргән полиция кинәт аңга килеп, усалланып демонстрантларга ташланды. Бу юлы нагайканың нәрсә икәнен мин үз җилкәмдә татыдым. Күз алдымда атлы полицейский бер гимназистны бәреп үтерде. (...) Демонстрацияне тараттылар, ләкин ул нәкъ иртәгә кабынып китәчәк коралы восстаниегә нигез әзерләде.

17 октябрьда восстание.

Баш күтәрүчеләрнең төп позицияләре: университет, аның каршында — Юшков йортының түбәсе. Әгәр нинди дә булса хәрби часть университетка атарга уйласа, аның тылында калган Юшков йортыннан бомбалар явачак иде. Аннары — шул ук урамда Пассаж. (...) Пассаж почмагы гөмбәзе астында урнашкан Климов сәгать кибетенең чормалары да эшкә ярады, дружинниклар зур дивар сәгатьләрен каерып алып, ачык калган тәрәзәләрдән мылтыкларын төбәделәр. Пассажга каршы духовный семинария (хәзер — Казан университетының геологик факультет бинасы — И. Г., А. Л.). Семинаристлар барысы да бомбалар, яисә гади ташлар, кирпечләр белән кораллнып өлгергәннәр, алар Пассажга һөҗүм итүчеләрнең артына төшәргә әзер иделәр (...)»[1]

18 октябрь көнне Казанда патша манифесты таратылды. Ул көнне шәһәр Думасы бинасы халык белән шыгрым тулы иде. Төрле социаль катлау вәкилләре митингларда, демонстрацияләрдә актив катнаштылар. Большевиклар халыкка манифестның башыннан ахырына кадәр ялган икәнлеген аңлатырга тырыштылар. А. Я. Аросевка иң нык тәэсир иткән речь Думада большевик А. Кулеша рече булган.

Ул көннәрдә митинглардан соң полицияне коралсызландыру башланды. Шунысын әйтеп узарга кирәк: А. Я. Аросевка 1905 елда бары 15 яшь булган, революцияне бик теләп кабул иткән егет коралсызландыруда, әлбәттә, катнашкан. Ләкин ул вакытта әле ул нинди партиягә кушылырга икәнен тегәл аңлап бетермәгән. Кайбер вакыйгаларны, дружинниклар һәм семинаристларның сугышчан активлыгын, бераз күпертеп күрсәтүе дә сизелә. Чөнки коралсыз халыкны җәзалаучылар асылда солдатлар һәм полиция булган. Ул көнне һәлак булганнарның һәм яралануларның саны 40 ка җиткән.

19—20 октябрьда җитәкче революцион орган да төзелә: шәһәр коммунасы. Аның составына большевиклар, эсерлар, меньшевиклар, крестьяннар союзы вәкилләре керә. Билгеле булганча, Октябрь стачкасы җиңелү белән тәмамлана. 21 октябрьда реакцион көчләр «патриотик манифестация» оештыралар. Бу турыда А. Я. Аросев менә ничек яза:

«Көндезге сәгать уникеләргә Дума янындагы митинг шактый сыекланды. «Патриотик манифестация» шәһәрнең татар ягына чыгып шактый ишәйде, анда катнашучылар Воскресенский урамына (хәзерге Ленин урамы — И. Г., А. Л.) чыгып Думага таба юнәлделәр. Процессия башында татар муллалары бара, алар артыннан рус поплары теркелди, аларга сәүдәгәрләр-купецлар, монархист-интеллигентлар, киемнәрен алыштырган полицейскийлар, жандармнар һәм җыен йолкыш ияргән. (Соңыннан билгеле булды, пристав Тутышкин погром оештырыр өчен аларны махсус җыйган булган, һәрберсенә тәүлеккә берәр сум акча да түләгән.) (...) Таяк, рельс кисәкләре, ташлар белән коралсыз халыкны вәхшиләрчә аяусыз тукмау башланды. (...) Карагруһчыларга ярдәмгә солдатлар да килеп җитте. Алар бер-бер артлы Дума бинасына өч залп бирделәр. (...) Кичке сәгать унда Дума бирелде»[2].

Карагруһчылар демонстрациясенең составына игътибар итик: революциягә карата сыйнфый нәфрәт рус һәм татар буржуазиясен, руханиларын берләштергән. Алар приказчикларга, люмпен-пролетариатка кушылып рус һәм татар эшчеләрен кыйнарга бергәләшеп юнәләләр.

1905 елның октябрь вакыйгаларында Казанның төрле катлау вәкилләре катнашты. Воскресенский урамына, Дума тирәсенә, әлбәттә, бар кеше дә барып җитә алмады. Солдатлар һәм полиция урамны һәм бинаны камап өлгергәннәр иде. Әмма революцион күтәрелеш бер кешене дә читтә калдырмады. Мәсәлән, дары заводы эшчесе, 1 Дәүләт Думасы депутаты П. А. Ершов үз заводы турындагы истәлекләрдә менә нинди вакыйгаларны искә ала:

«Вакыйгалар акрынлап булса да октябрьга таба бара иде. Дары заводы эшчеләре исә аерымрак хәлдә калдылар. Беренчедән, эшчеләрнең яртысы диярлек кичәге крестьяннар, калганнары исә кечкенә генә булса да «йорт хуҗалары»! Чынлап

[1] Аросев А. Я. Казанские очерки о революции 1905 г. Казань. 1925. 55—56

[2] Аросев А. Я. Казанские очерки о революции 1905 г., 74—79 66

караганда, саф пролетарийлар юк дәрәҗәсендә. (...) 17 октябрь көнне, манифест чыккан һәм шәһәргә забастовка иң көчәйгән чакта, эшчеләр эшне ташлап 2—3 сәгатькә иртәрәк кайтып киттеләр. Завод хуҗалары казак отрядларын чакырттылар. Погром куркынычы арта барды. Ашыгыч рәвештә халык отрядлары — милиция оештырылды, студентларга корал таратырга карар кабул ителде. Полицияне коралсызландырдык. Ләкин озакка булмады бу. Карагруһчы монархистлар эшнең кая таба борылганын сизеп, көчле агитация башлап җибәрделәр. Яңадан көрәш башланды. Бәрелешләр. Кулга алулар...»[1]

Баш күтәрүчеләр бер мәлгә актив хәрәкәт итә башласалар да аларның чыгышы бастырыла. Бу уңышсызлыкларга бәя биреп, РСДРПның Казан комитеты әгъзалары И. С. Алуф[2] һәм В. В. Адоратский 1921 елда болай дип сөйләгәннәр:

И. С. Алуф: «17 сендә университетта митинг узды. Ул кичке 6 ларга кадәр дәвам итте. Үзәктән әле бернинди телеграммалар алынмаган иде. Телеграмма 18 ендә генә килеп җитте. Шәһәрдә бөтен җир ябык, монда да тынлык хөкем сөрә иде. Хәл буталчык, аңлаешсыз. (...) 19 ында хәлләр кинәт үзгәреп китте, митинглар һәм демонстрацияләр башланды. Полицияне коралсызландырдылар, шәһәр милициясе оешты. 19 ында башланган бу хәлләр 20дә дә дәвам итте. 21 ендә көндезге уникеләрдә революцион хәрәкәтне тар-мар итү башланды, һәм кичкә бөтенесе тәмам ителде». В. В. Адоратский: «Коралсызландыру 19 ында иртән башланды. Думадан тотындык. Алексей (Лозовский) речь сөйләде. Аннан туп-туры 1 нче полиция частена юнәлдек. Алексей кулында Дума кыңгыравы. Коралланырга теләгебез зур булуны әйтеп узарга кирәк, ләкин безгә кыюлык җитмәде, гайрәтләнеп эшкә тотынган булсак, барып та чыгар иде; без барганда, частьта сакчылар юк диярлек иде, тик ике генә солдат каравылда. (...) 1 нче частьтан Проломный урамына (хәзерге Бауман урамы — И. Г., А. Л.) юнәлдек. Демонстрантлар саны һаман арта торды... Татар бистәсенә барып җиттек. Хәтеремдә, анда Ямашев үзенең ораторлык осталыгын күрсәткән иде. Монысы Печән базарында булды. Аның рече бик уңай тәэсир калдырды»[3].

Шулай да коралсызландыру шәһәрдәге барлык полиция частьларында уңышлы узган (бу турыда В. В. Адоратский ни өчендер әйтмәгән), алтынчы частьта гына эш барып чыкмаган, андагы полицейскийлар да 21 енә кадәр борыннарын да күрсәтмәгәннәр, эшчеләрдән куркып, чыкмыйча утырганнар. Дөрес, корал барыбер җитәрлек булмый, алынганы да күп очракта яраксыз булган.

Революциянең давыллы көннәре турында татар телендә дә кайбер материаллар, истәлекләр сакланып калган. Шуларның берсенең авторы — әдәбиятыбызның классигы Мәҗит Гафури. 1905 елның нәкъ октябрь көннәрендә ул Казанда булган һәм соңрак, 1925 елда, «Бишенче ел революциясе хакында истә калганнар» дигән хатирәләрен яза. Ул күбрәк Казанның татар районнарында булган вакыйгаларны тасвирлый, мәдрәсә шәкертләренең революцион хәрәкәте турында, 21 октябрьда оештырылган «патриотик манифестация» турында фактлар китерә.

Мәҗит Гафури истәлекләренә күз салыйк: «Мәдрәсә шәкертләре арасында бу хәбәрләр (башка шәһәрләрдәге революцион хәрәкәт турында — И. Г., А. Л.) таралды, һәм Казан гали мәктәпләрендә укучы студентларның хәрәкәтләре боларга да тәэсирсез калмады. Мәдрәсә шәкертләре белән ике арада катнашулар, алдагы зур эшкә әзерлек күрергә димләп, ике арада йөрүчеләр күренә башлады. Мәдрәсәгә, һәр көн дип әйтерлек, кул белән язылган һәм җилем басмада басылган кочак-кочак прокламацияләр, революциягә өндәүләр таратыла иде. Кайбер татарча прокламацияләр мәдрәсәнең үзендә үк басыла, боларда да шул ук хөкүмәткә каршы өндәү белән бергә, мәдрәсәләрне ислах итү, аларга фән кертү, мантыйк кебек хорафатларны бөтенләй чыгарып ташлау, мәдрәсә идарәләренә шәкертләрдән дә вәкилләр кертү кебек төрле таләпләр куела. (...)

Шәкертләр арасындагы хәрәкәтләрнең иң кызуы мәдрәсәи Мөхәммәдиядә булды. (...)

Октябрьның 15—16 ларында эш тагы да куерды. Кешеләрнең куллары көндәлек эшләреннән бушанды. «Университетта митинг имеш! Студентлар баш күтәрәләр имеш! Казаклар аларны чолгап алганнар, кыралар, аталар имеш!» — дигән хәбәрләр бөтен Казанга яңгырый башлады. Бу хәбәрләр электән үк кузгалырга торган шәкертләргә тагы да ныграк тәэсир итте. Мәдрәсәдә укулар бетте. Һәркем бер нәрсә көтә, һәр кеше бүген таңда зур эшләр булуын көтеп тора башлады. (...)»

---

[1] Ершов П. А. Химики в 1905 году.— Пролетарий Татарстана, 1925, 11 сан, 30 б.
[2] Алуф И. С.— РСДРПның Казан комитеты әгъзасы, РСДРПның Таммерфорс конференциясе (ноябрь-декабрь 1905 ел) делегаты. 20 нче елларда Казан медицина институты профессоры.
[3] Стенографический отчет вечера «Истпарта» 3 июня 1921 г. «Пути революции», 3 сан, 1923, 67—68 бб.

18 октябрь көнне Казан тагын да ныграк шаулый. Мәҗит Гафури ул көн вакыйгаларын тагын да җентекләбрәк тасвирлый:

«Бөтен Казан ирекле рәвештә җырланган «Марсельеза» тавышлары белән яңгырый. Бөтен шәкертләр груһ-груһ[1] урамнарга чыгып китәләр, университет тирәсенә, Воскресенский урамына йөгерәләр. Бу тирәләр халык белән тулган. Һәр җирдә кызыл флаглар җилферди. (...) Урамда да, университетта да, шәһәр Думасында да митинглар, җыелышлар, киңәшләр бара. «17 Октябрь манифесты» гына халыкны канәгатьләндерми. (...)

Бүген Казан ду килә. Урамнан керәсе килми. Җыелган эшчеләр, укучылар корт иле кебек кайнашалар. Озак та үтми полицияне коралсызландыру башлана. (...) Печән базарында бик зур җыелыш булып, анда төрле кешеләр тарафыннан речьләр сөйләнә (Хөсәен Ямашев һәм башкалар). Патшаның «17 октябрь манифесты»ның мәгънәсе югала. Аңа гына ышанып тормаска өндиләр.

19 октябрьда партийныйларга һәм укучыларга корал таратылып, шәһәр алар кулына күчә, «шәһәрнең тынычлыгын саклау комитеты» кулында була. Мәдрәсәдәге шәкертләргә чаклы корал алалар, шулар рәтеннән мәдрәсәи Мөхәммәдиядәге шәкертләр кулына берничә дистә мылтык, шул ук микъдарда кылыч, берничә ат төшә. Таза шәкертләр билләрен буып, коралланып, шәһәрнең тынычлыгын сакларга йөриләр. (...) Бүгеннән башлап мәдрәсә идарәсенә үзләренең таләпләрен кабул итү хакында катгый сорау куялар. Мәдрәсә мөтәвәллиләре, мөдәррисләр, бик зур эшкә очраган кебек, көн-төн җыелыш ясап, нәрсә эшләргә белми аптырыйлар, алай да үзләренчә вәгъдә белән генә алдамакчы булалар.

Шәкертләрнең каннары кайнашкан, вәгъдәләрне көтәрлек түземнәре беткән».

Революцион күтәрелеш, күрүебезчә, хәтта шәкертләрне дә читтә калдырмаган. Алар да үзләренчә, тормышта социаль үзгәрешләр таләп иткәннәр. Ә берничә көннән реакция көчләре яңадан-яна һөҗүмгә күчәләр:

«21 октябрьда университет янында, Воскресенский урамы ягында, күп халыкның кычкырган тавышлары ишетелә. (...) Шунда ук карагруһчыларның тәре күтәреп йөрүләре, студент һәм башкаларны тукмаулары, яһүдләргә погром ясарга керешкәнлекләре хакында хәбәрләр бөтен шәһәргә тарала. «Өч көнлек ирекле тормыш» корырга катнашкан кешеләрнең күбесе яшеренә башлыйлар, кайберләре коралларын илтеп бирәләр. (...)

Бервакыт безнең мәдрәсә урамыннан (хәзер Тукай урамы) болыт кебек халык килеп чыга. Воларның иң алдыннан тәре күтәргән әллә ничаклы поплар, алар артыннан ап-ак чалма, яшелле-сарылы тун яки чапан кигән Казан муллалары, алар артыннан түрәләр, балыкчылар, итчеләр, кибетчеләр баралар. Волар һәммәсе дә тәрегә, патша сурәтенә баш игәннәр. (...) Волар шулай тәреләре белән үтеп киттеләр... Халык кулына таратылган коралларны кире җыеп алу башланды. Шәһәрне тирән тынлык басты. (...) Шулай итеп 1905 елгы Октябрь революциясе күмелде. Күңелләр алдагы зур һәм җиңелмәс Октябрьга юнәлеп, шуны көтеп калдылар»[2].

Үзенең кыска гына истәлекләрендә Мәҗит Гафури Казанның татар якларында булган вакыйгалар турында искиткеч төгәл, башкаларның күзенә чалынмаган фактларны яктыртып яза. Аның истәлекләренең тарихи әһәмияте, безнеңчә, нәкъ шунда.

В. И. Ленин 1905—1907 еллар революциясендә Бөек Октябрьның «генераль репетициясен» күргән, аны шулай бәяләгән. Төрле сәбәпләр аркасында ул революция җиңелүгә дучар ителде, ләкин бу елларда пролетариат һәм большевиклар партиясе туплаган тәҗрибә соңрак дәвер революцион хәрәкәттә мөһим роль уйнады.

Революцион вакыйгаларда төрле өлкәләрдә, төрле сыйныф һәм социаль катлау вәкилләре актив катнаштылар. Татарстан, Казан шәһәре хезмәт ияләре дә бөтен халык хәрәкәтенә үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Россиядәге беренче буржуаз-демократик революциянең башлануына 80 ел тулды, ул героик көрәштә катнашкан кешеләр инде юк дисәк тә, ялгышмабыз, шуңа күрә аларның истәлекләрен өйрәнү, барлау тарихчыларыбызның мөһим бер бурычы булып тора. Революцион традицияләр үрнәгендә яшь буынны тәрбияләү максатыннан чыгып караганда да, Татарстанда революцион вакыйгаларда катнашкан шәхесләрнең мемуарларын җыеп яңадан бастыру бик файдалы һәм кирәкле эш булыр иде.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,
Александр ЛИТВИН,
тарих фәннәре кандидатлары.

[1] Груһ — төркем.
[2] «Белем» журналы, 1925, 11—12 сан. Уфа.

## Диас Вәлиев

# МӘҢГЕЛЕККӘ ӨЧ СӘЯХӘТ

Кат-кат укыганда, һәр әсәр дә сине гел тетрәндерми. Күңел күнегеп өлгерә, аны бик җиңел генә дулкынландыра алмыйсың. Ә менә бу юлы гаҗәп булды. Күптән белгән шигырь юлларын мин кат-кат һәм йотлыгып укыдым:

...Менә шунда берәр пуля очса-килсә,
Килеп ул күкрәгемне бишкә киссә,
Үлем кулы килеп басса — егылсам,
Җаным күккә — гарешкә очса-китсә,
Менә шунда «бәхетле» мин, «бәхет» шул...

Бу юлларны шагыйрь — ни гаҗәп!— унөч яшендә яза. Шагыйрьнең безгә мәгълүм булган шигырьләреннән беренчесе бу.

Уналтыда (һәлак булып, дөньядан китәренә әле егерме ике ел калганда):

Йөреп изге көрәшнең бу юлыннан,
Теләгемә җитәлмәдем — егылдым...
Атылган бер явыз дошман угыннан
Яраландым...
Кадалды ук йөрәгемнең түренә,
Кызылланып, җәрәхәттән ага кан.

Ә уналтыны тутырып, унҗидегә чыккач, сөйгәненә багышланган шигырендә яшь шагыйрь болай ди:

Язгы нәфис бакчаларның киң юлында
Барган чакта, юлларыңа гөлләр үссә,
Уйный-уйный күбәләкләр кулларыңда
Иркәләнсә, сине котлап җилләр иссә,
Шул вакытта ак юлыңны (гөнаһ шомлык!)
Сузылып яткан канлы гәүдә киртәләсә,
Яткан булса ак йөзләре канга тузып,
Синең җанлы шат бәхетеңне үртәләсә,
Син шикләнә күрмә... бәгырем!
Ул — кан белән
Яраланып утлар кисеп тапсыз күңлен,
Әрни-әрни соңгы сүнмәс вөҗдан белән
Җанын биргән үле гәүдә — мин булырмын.

Бу нәрсә бу? Әүлиялык кылумы, үз язмышыңны аермачык сизү, тою, күрүме? Үз язмышыңны гына да түгел хәтта, халык язмышын, тарих язмышын белеп торумы?

Ә менә аның үлем алдыннан язган шигыре:

Май аенда тагын җыйналырбыз,
Кызыл шәраб килер табынга,
Бокалларның көмеш чыңы белән,
Табын җыры яңрар тагын да.

Май аенда,— ди шагыйрь. Истә тотыйк моны. Аннары менә бу күренешне дә күңелгә биклэп куйыйк.

Тик күп түгел,
Каплап бокалларны,
Без табыннан бергә кузгалып,
Юнәлербез дуслар каны тамган
Киң кырларга, җиңне сызганып.
Ватык юллар, янган зур калалар
Без килгәнне көтеп яталар.
Уянсыннар батыр тракторлар,
Уйнасыннар кулда балталар.

Моны Берлин төрмәләренең берсендә ялгыз камерада әҗәл сәгатен көтеп ятучы, якты дөньядан тулысынча аерылган тоткын яза. Хәрби әсирләр лагеренда яшерен эш алып барганы өчен кулга алынгач, 1943 елның октябрендә, хисапсыз күп сорау алулар, җәзалаулар арасында ул үзе инде мәңге күрмәячәк киләчәк турында хыяллана. Аның «Моабит дәфтәре»ндә аерым бер «сугыштан соңгы» шигырьләр циклы бар. Башка шагыйрьләр андый шигырьләрне соңрак язачаклар әле, ә ул сугыш дөрләгәндә, һәлакәтенә бер адым калганда яза.

Кулга эләккән очраклы бер кәгазь кисәгенә яза шагыйрь — еллар үткәч, кулдан кулга күчә-күчә, шул кәгазь кисәкләреннән тегелгән дәфтәр туган җиргә кайтып җитә. Һәм сугышның майда бетәчәген хәбәр иткән әлеге гаҗәеп шигырь безгә килеп ирешә.

Шагыйрь үз тормышы белән генә яшәми. Ул, тормыштан аерылып, үлемгә хөкем ителгән хәлендә дә, алдагы яшәү турында яза. Тәне фани аның, әлбәттә, һәм шагыйрь рухы ул тәнгә генә сыеп тора алмый. Шуңа күрә ул рух төрле киемнәр кияргә мәҗбүр. Без ялкынлы шагыйрьнең солдатка, инвалидка, илне торгызучы төзүчегә әверелүенә шаһит булабыз. Һәм шәхси, хосусан үз яшәешең белән уртак, бөтенкешелек яшәеше арасындагы чик бетә, югала, юкка чыга.

Укучы инде сизенгәндер — бу Муса Җәлил язмышы.

Үләсен белеп торған хәлендә дә шагыйрь әле яшәр кеше кебек яза. Шунда ук — үзен дөньяда инде юк кебек итеп, үлемен табигый бер халгә санап язылган шигырьләр. Гомумән, аның Яшәүгә, Үлемгә, Вакытка мөнәсәбәте (аңарда киләчәк еш кына үткән яки хәзерге заман белән алмашына һәм киресенчә) — үзе бер гаять дәрәҗәдә кызыклы роман. Әйтик, аның, иртәгә башы чабыласын белгәч, төне буе Гетеның «Фауст» трагедиясен немецча укып чыкканлыгы мәгълүм. Яшәү, үлем, Вакыт — җан ияләре, язмышның тере персонажлары диярсең, аның җанының һәр даим сөйләшеп тора торган мәңгелек юлдашлары һәм әңгәмәдәшләре кебек алар. Шуннан соң үлеме алдыннан аның Мефистофель һәм Фауст белән сөйләшүе гаҗәпме соң? Күрәсең, ачыклап бетерәсе нәрсәләр калган булгандыр.

Контрастларга ис китә. Чыннан да, бер яктан, гаять дәрәҗәдә күңел көрлеге, көч сизү, гаҗәеп яшәеш байлыгын тою (боларны аның һәр юлыннан күреп торасың), икенче яктан — күптәннән килә торган, үз язмышының хәвефле азагын тою хисе.

Башына ниләр төшәсен каян белгән ул? Киләчәк дигәне бүгенге көн булып җиткәндә ул «киләчәк» һәрвакыт моннан күп элек үзе тасвирлаган сурәттә аның каршына килеп баса.

Чынга чыккан бу әүлиялыклар шигърият галәмәтеме яки башка берәр нәрсәме?

Менә күңеле күптән сизенеп килгән дәһшәтле очрашу. Шагыйрь шома көйләнгән нацист машинасы каршында берүзе. Ул таш капчыкта, тимер капчыкта. Ул — гомер чигендә. Һәр минутның соңгы минут булуы бар. Йөз ундүрт адым (тикшерүчеләр моны соңыннан төгәлләп санап чыктылар) — ул камерадан дүртенче блокка — җәзалау залына кадәр чиста итеп себертелгән ишегалдыннан барасы ара. Анда шәплэп майланган гильотина һәм аның янында фашист рейхының төп җаллады Эрнест Раендаль басып тора. Магдебургтагы сабын заводы хуҗасы булган бу адәми зат нәселе белән үк башкисәрләр нәселеннән. Гаилә башлыгы үзе, әнә дүрт булышчысы белән корбанын көтә. Бу көнне кискән башы өчен дә аның банк исәбенә утыз марка өстәләчәк. Әнә шунда Яшәү белән, Үлем белән, Язмыш белән, Вакыт белән сөйләшү бетәчәк. Адымнар, аяк тавышлары, ишек йозаклары шалтыравы. Кемгә таба килә бу аяк тавышлары? Мондый минутларда, мондый сәгатьләрдә, мондый көннәрдә нишли кеше җаны? Безгә дүртьеллык шигъри шаһитнамә килеп җиткән.

Үтерсәгез, әйдә, үтерегез,
Котырыгыз аннан, биегез!
Тик шагыйрьгә кара китерегез,
Һәм кулына каләм бирегез.

Шагыйрьгә бу минутта ак кәгазь кирәк тә, каләм кирәк.

Монда инде гадәти хәлләр бетә, логика, фикерләү, аңлау чикләре үзгәрә. Гадәти аңның шагыйрь эченә керергә көче җитми башлый төсле. Гади адәм баласы мондый ситуациядә алай эшли алмас иде кебек. Мондый җан тынычлыгы, андый рухи көч мөмкин түгелдер кебек. Бу мизгелдә кәгазь-кара турында өлешенә үлемсезлек төшкән кеше генә уйлый ала. Шагыйрь мине, укучыны, иң югарыгы абсурд чоңгылына чумарга мәҗбүр итә. Анда мөмкин булырдайның барысы да беткәнлеген аңың белән аңлыйсың, ләкин кайбер шәхесләр өчен мөмкин булмастай нәрсә дә мөмкин икән әле.

Шагыйрьнең «Сайланма әсәрләре»н актарам, ә андагы шигырьләр, бик яшьли үзенең дәһшәтле язмышын сизенеп, аңлы рәвештә, курыкмыйча, елмаеп үлем каршына барган кеше хакындагы әкияттәй хикәят булып тезеләләр. Җәза минутларын үз күзләре белән күргән рухани Юрытконың «Алар елмаеп үлделәр» дигән сүзләре искә төшә. Йөзләгән, меңләгән кешеләрнең үлемгә баруларын күргән руханины шагыйрь һәм аның иптәшләре йөзендәге елмаю тетрәткән.

Үләр алдыннан елмаю мине дә тетрәтә. Бер караганда максатсыз, мәгънәсез кебек ул, адресы да юк аның, көрәшерлек көче дә, ләкин ул, дөньяның иң караңгы базыннан балкып, безгә күренеп тора. Бакыйлык хакына фанилыктан ваз кичүче елмаюы ул. Бу елмаюда фикерләүнең моңарчы билгеле булмаган, нindидер яңа үлчәмнәре ачыла сыман.

Менә шушы факт безгә күп нәрсә хакында сөйли. Гомумән, кеше мөмкинлекләре хакында. Аның җиңелмәс рухы хакында. Һәм аның үлемсезлеге хакында.

Бу мәкаләмдә мин яңа кеше хакында сөйлим. Үтә камил кеше хакында.

Вак хосусый тормыш блокадасын җимереп чыккан ул. Үзендәге эгоистик дәртләрне авызлыклап бастырган. Аның «мин»е иксез-чиксез дөнья өчен ачык. Ул яшәүдән дә, үлемнән дә курыкмый, үз сүзенә үзе җавап бирә. Җирдәге һәр адымын кеше гомере, кеше җаны белән түгел, үз гомере, үз каны белән юа.

XX гасыр дөнья шигърияте бу кешегә якынрак килү өчен ыргым арты ыргым ясый кебек. Һәр ыргымда андый кеше рухының яңа шәкелләре ачыклана бара сыман.

Максатын ул хәзер белә инде:
Туган җире бәхете хакына
Аерылырга язган икән аңа
Балалардан, сөйгән хатыннан.

Еламагыз, ялвармагыз берүк:
Карары нык, тугры ул аңа —
Гөл исләре сеңгән бер җыр булып
Күңеленнән оча ул карар.

Борынгыдан килгән: якты дөнья
Кара дөнья белән көрәшә,
Яшә, шагыйрь: ак хакыйкать өчен,
Бар кешегә бу җир матурлыгы
Барын җитсен өчен син яшә!

Әйе, монысы — гасырыбызның икенче бер шагыйре Нирала.

Урта гасырлар шагыйре турындагы аның поэмасы (әлеге өзекләр шул поэмадан) авторның үзе хакында сыман. Әлеге шагыйрь кебек үк, ул үзе дә җирдә золымны бетерергә омтыла, кешеләрне гомумкардәшлек җепләре белән берләштерергә тели.

Милләтләрнең дөнья ярминкәсендә «һинд рухы»ның иң күренекле вәкиле булып яшәүче шагыйрь шул ук вакытта аның кысаларына гына сыя да алмый.

Индуизмның төп үзенчәлеге: күп нәрсәдә бердәнбер нәрсәне күрергә, һаман үзгәреп, агып торган фани дөньядан ниндидер үзгәрми торган мәңгелек нәрсә табарга омтылудан гыйбарәт. Бердәнбер дигәне — ул табигатьтән өстен көч, бар булганның чиксез куәткә ия мәңгелек хакиме Параматма — индуизм тарафыннан җирдән читтә торучы буларак кабул ителә. Хәтта фикерләү чикләреннән дә тышта ул. Әмма, үзенең герое Тулсидас кебек үк шагыйрь дә бу «бердәнбер»нең җирдәге зат булуын тели, ә моңа иң лаеклысы кеше дип саный. Шулай итеп, аның иҗатында борынгы һинд рухи традицияләре яңа заман цивилизациясе рухи климаты белән бәйләнешкә керә һәм бу хәл ниндидер яңа, өченче төрле «эремә» бирә.

Елга-инешләр турында күпме шигырь язылган... Ә менә Нираланың «Ташкын»ы:

Әй гөрләсен әле,
Гөрләп чапсын
Бу дөньяның гомер чишмәсе!
Бу куәтле ташкын яшьлек башын
Ничек инде әйләндермәсен![1]

[1] «Шигырьләр, җырлар, поэмалар» китабыннан Ә. Гадел тәрҗемәләре.

Шагыйрьнең лирик герое — галәми җан иясе. Аның биешеге булган табигать тә — галәмдәй иркен һәм киң.

Шушы мәңгелек гүзәллек кочагында туу белән сулу бар, үлем белән үлемсезлек бар. Һәм бары тик титаник тынычлык белән бөҗраны өзеп, аның тынычындагы иксез-чиксез яшәү океанына чыккан кеше генә, үлемне җиңеп, үлемсезлек яулагандай була.

Милли һәм социаль җирлек — башка, шагыйрьнең үз «мин»е бүтән цивилизация агачы ышыгында үскән, әмма чын-чыннан бөек булган кеше рухы үзенең табигате белән һәркайда бер төрле — ул барыбер үлемсезлеккә тартыла. Үз ихтыярын чиксез бөтенлекнең ихтыяры белән кушарга омтыла. Бүтән үлчәм офыкларына чыгу әнә шулай якынча бертөрле була.

Сәнгать ул — ике олы дөнья очраша торган бер нокта. Тормыш, объектив чынбарлык белән рәссамның субъектив дөньясы очрашу ноктасы. Бу моментны бик әһәмиятле дип исәпләгәнгә сөйлим мин аның турында. Бу дөньяларның очрашу чынлыгы, аның асыл мәгънәсе, кыйммәте әлеге дөньялар бер-беренә торырлык булганда гына күзгә күренә. Зурлыклары, куәтләре белән бер чамада булганда гына.

Әсәрләр тукымасыннан автор шәхесе саркып торганда гына аерым шигырьләр мозаикасы бер бөтен сурәт хасил итә. Авторның дөнья белән элемтәләре күбрәк булган саен кәгазь битенә аның җан рәсеме дә ачыграк төшеп ята. Ә инде мәгълүм стилистиканы, мотивларны, фикерләрне, тойгыларны күбрәк тиражлы итәргә омтылу ул чын шигъриятнең имитациясе генә: алдавын алдый ул, ләкин күңел көткәнне һич бирә алмый.

Кулыма тагын бер җыентык алам һәм минем алга бөек кеше рухының тагын бер рәвеше килеп баса.

Кешенең «мин»е монда тагын да зурайтылганрак. Бу аерым «мин» үзенең аерымлыгын танырга теләми, хосусый статус хокукыннан үзен бөтенләй мәхрүм итә!



Аерылышу кисте йөрәгемне,
Шул мизгелдә тойдым, ишеттем
Үләннәрнең кичен җырлашуын,
Дәрья һәм таш мине үз итте[1].

Кешенең «мин»е бу таштан үзен әзли кебек һәм таба да: «аннан бер табакбит күренә иде». «Мин» һаман эзләвен белә һәм һәркайда «аңның тотып карап булмый торган шома дөньясын» таба тора.

Шагыйрьчә, аң ул органик материянең иң югары үсеш баскычында гына яралмый. Аң ул материянең, гомумән, хасияте, аның аерылгысыз үзлеге.

Бу яктан Николай Заболоцкий «монист» булган. Һәм гомере буе ул үлемгә аерым бер романик мөнәсәбәттә тора. Аның көчен ул бик зурга куймый, чөнки бөтен рухи һәм матди хасиятләр үлемсез, дип исәпли. Табигатьтә бер нәрсә дә юкка чыкмый, бары тик рәвешен генә үзгәртә. Гомуми саклану законына дөнья энергиясенең материаль, матди ягы гына түгел, ә бәлки психологик ягы да буйсына.

Шуңа күрә, шагыйрь яшәгән дөнья — ул мәңгелек тормыш дөньясы, мәңгелек яшәү һәм яңару дөньясы. Анда кеше үзе дә:

...табигать баласы түгел,
Фикере ул, бәллүр аңы аның!

Җирдәге бар нәрсәне берләштерү уе белән янган, табигатьтән һәр даим Бербөтенне эзләүче шагыйрь (Нираланы искә төшерик) кешенең «мин»е белән дөнья арасындагы чикне каерып сындыра, вата.

Тамырларда каным типсен дип,
Мин күп үлдем. Тере тәнемнән
Аерылып күпме мәет калды,
Мин хәтерлим ансын әле дә,
Их, әгәр бер һушны җыя алсам,
Күрер идем кара туфракта
Мин үземнең җансыз мәетемне
Әчкәредә, ерак-еракта.
Күрер идем диңгез дулкынында,
Күрер идем җилдәй искәнем.
Күрер идем үлгән үземне мин,—
Ә мин исән, һаман исәнмен.

Менә ул, яшәүнең мәңгелеге!

[1] Монда һәм алда — Н. А. Заболоцкий. «Шигырьләр һәм поэмалар». Ә. Гадел тәрҗемәсе.

Тормышның бу бихисап рәвеш үзгәрешләрен логик яктан аңлап буламы? Аларда вакыт инде мәгълүм юнәлеше һәм акыл тулаем иңләрлек характерда түгел, вакыт бирелә грандиоз һәм кабатланып торучы циклларда тора. Бу космик тормыш бара торган киңлекләр исә безгә гадәти булган эвклид дөньясын гына түгел, неэвклид характеристикалы дөньяларны да үз эченә ала.

Аңым сүнәр, ә квантлар дөньясында
Канат җилпер нәни бер чикерткә.

Яшәү һәм үлем — монда, җирдә. Ә анда, кайдадыр башка галактикада, бер чикерткәнең яралуы. Дөньяларның якынаюы, бәйләнеше. Үзеңне, үз «мин»еңне теләсә нинди җанлы нәрсәгә тиңләү — «җансыз кристалл җан тибүен сизгән, шунда миңа тәүге фикер килгән». Әлеге «мин»нең туу һәм үлү көннәре чикләнмәгән, аның гомере җанлы, үзгәрүчән материя үсешенең бөтен вакыт киңлекләрен үз эченә ала.

Шагыйрь фикерләвендә яңа кешенең кызыклы тойгылары ачыла. XX гасырда дөньяны болай тою бик сирәк күренеш түгел инде. Күргәнебезчә, ул бер Заболоцкийда гына очрап калмый. Тик шулай да ул әле уртак тойгыга әверелмәгән.

Минемчә XXI яки XXII гасырда, кеше галәм затына әверелеп, эвклид дөньясында гына түгел, башка үлчәм дөньяларында да хәрәкәт итәргә сәләтле булгач, Галәмнең тулы хокуклы кешесенең яңа тормыш фәлсәфәсе барлыкка килгәч, андый тойгылар төп тойгылар булып әвереләчәкләр.

Ләкин хәзергә әле бу юллар — дөнья сәхнәсендә, үткән дәвер белән чагыштырганда принципиаль яңа кеше аңы күренүнең тәүге билгеләре генә.

Универсаль кеше, өченче кеше җаны үзенең беренче эре шытымнарын бирә. XIX һәм XX гасыр кешеләренең фикерләүләрен бергә куеп карыйк. Пушкинда: «Юк, беркайчан да үлмәмен мин тулысынча... Даным яшәр, яши алса соңгы пиит»... — дигән фикер бар. Ә Заболоцкий болай ди:

Юк, үлмәм, дим, дускай. Гөл иседәй
Кабат тумый калмам кебек мин.
Бер муртайган имән бу җанымны
Яшәтер дип уйлыйм төреп мин.

Баш өстеннән ерак оныкларның
Салмак бер кош булып очармын,
Сезне бер таң булып, я булмаса,
Җәйге яңгыр булып кочармын.

Пушкинның лирик героеның үлемсезлеге — кешелек хәтерендә, кешелек тормышында. Җирдә һәм күктә булганнардан ул үзен бары кешелек белән генә тиңли.

Заболоцкий героеның үлемсезлеге исә кешелек яшәеше чикләрендә генә калмый. Кеше аңының XX гасырда башланган «галәмләшү» процессы, «җанлы» һәм «җансыз» арасындагы чикнең ачылуы, аның иҗатында тулысы белән чагылды. Аның үлемсезлеге — гомумән дөньяның үлемсезлеге ул.

Кеше кулы барысын да булдыра ала. Ул агач та утырта, шуның өстенә напалм да коя.

Ул бишек тә тирбәтә, тирә-юньдәге бар нәрсәне яндыра да ала.

Безнең заманда кешенең бу сәләтләре бик еш күренә. Ләкин XX гасыр шулай ук моңарчы күрелмәгән гигант социаль эксперимент шаһиты да, бүгенге көндә кеше кулы игелек, гүзәллек тудыручы көчкә торган саен ныграк әверелә бара. XX гасыр шулай ук күмәк төстә дөньяга яңа кеше килүенә дә шаһит. Ул кешенең фикерләве күпкырлы, аның аңы галәмнәрне били һәм аның «мин»е инде моңарчы кешелек җәмгыятьләре эшләгән кысаларга гына сыеп тора алмый. Аның рухына артык тар алар.

Кайберәүләргә бу нәрсәләр бүген буш хыял гына булып тоелырга мөмкин. Чөнки үткән чор кешесе дә үз позицияләреннән чигенергә теләми. Хосусый милекчелек зынҗырлары җанын уратып алган кичәге көн кешесе иртәгәге кеше белән көрәшә. Шушы көрәш утларында бүген бөтен дөнья дөрли. Яңа кешенең ныклап аякка басу юлында чын сәнгать, әлбәттә, аның белән. Сәнгать — яңа кеше ягында.

Сәнгать кеше йөрәгенә өмет өсти. Ул мәгълүм рухи кыйммәтләрне яклый. Кеше иртәгесе көнгә ышанусыз яши алмый, ә сәнгать аңа менә шул хисен югалтмаска булыша. Ниһаять, сәнгать кешегә үзенең кеше икәнлеген исенә төшерә.

Яңа дөнья, өмет һәм алдагы гүзәллек пәйгамбәрләре булмыйча, кем булсын бу өч шагыйрь!

Милли культураларның аерым-аерым үсешен һәм яшәвен хәзер күз алдына китерүе дә кыен. Тормышның интернациональләшүе гаять кызу бара, культураларның үзара якын килүе, тоташуы — күз алдында. Бу процесс барышында, әлбәттә, нивелирлау хәвефен дә күрергә мөмкин (куәтләре чамалырак булган художниклар һәм культуралар өчен), икенче яктан караганда, бу процесс кеше кадеренең бөтенләй башка масштабларын тудыра. Ул масштаб, иске, кайчак бик тар чикләрдән чыгып, дөньяга принципиаль яңа булган эстетика һәм этиканы бирә. Һәм без әгәр дә миллилек һәм интернациональлек диалектикасы турында сөйлибез икән, монда эш, мөгаен художникның шәхесенә кайтып калабыр. Эш аның үз иҗатында вакытлы нәрсәләрне мәңгелек белән һәм миллилекне гомумкешелек белән никадәр дәрәҗәдә органик берләштерә алуындадыр.

Хәзерге шартларда һәр милли культура үзенең үсеш тенденцияләре гомумдөнья культура процессы белән чагыштырып карарлык дәрәҗәдә торганда гына «милли культура» дигән исемгә йөз тота ала. Аерым культураларның да, шулай ук аерым художникларның да абруе, дөньяда тоткан урыны һәм йогынтысы аларның дөнья культурасына керткән өлеше белән генә исәпләнә. Чын сәнгать әсәре — ул һәр очракта кеше рухының батырлыгы, ә ул рухка, әйткәнемчә, әүвәлге кысалар тар инде.

Газета битләрендәге дөнья хәлләре хроникасы, телевизор экраннарын тутырган планета сулышы бер нәрсәне раслый: без бөтенебез дә — бөек бөтендөнья конкурсында. Бу — кешенең иң яхшы өметләре, ышанычлары конкурсы.

Ул ышаныч нигездә чынга ашарлыкмы соң?

Милли, раса, сыйнфый чикләүләргә буйсындырылган вак хосусый милекчелек камалышын җимереп чыккан кеше — ә ул кешенең чалымнарын мин Җәлил, Нирала, Заболоцкий әсәрләрендә күрәм — шуны раслый: әйе, өметләр чынга ашарлык. Әйе, җиңү — мөмкин.

Өч шагыйрь — шәхси «мин» чикләреннән чыгуның өч мисалы. Үлем канунын өч кире кагу, мәңгелеккә өч сәяхәт.

Җәлил, Нирала, Заболоцкий иҗатындагы мәңгелеккә өч сәяхәт бездә бер ышанычны — кешелек рухының бөек яңарышына булган ышанычны ныгыта.

# ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында, халык иҗаты әсәрләре белән бергә, татар язучылары турындагы истәлекләр дә саклана. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай турындагы кайбер истәлекләр укучылар игътибарына инде тәкъдим ителде. Ә бу санда исә Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең биографиясенә кагылышлы кайбер язмалар бирелә.

Беренче ике истәлекне шагыйрьнең туган ягы — Оренбург өлкәсе, Шарлык районы, Мостафа авылында Мусаның балачак дусты Гали абый Маннаповтан 1960 елда Хәләф Гарданов язып алган. Гали абыйның истәлекләре Гази Кашшаф эшкәртелүендә 1964 елда «Муса Җәлил турындагы истәлекләр»дә чыккан булуын искә алырга кирәк. Әмма ул безнең фондта саклланучы язманың әчтәлеген кабатламый.

Тагын ике истәлеккә тукталыйк. Аларның беренчесе Әстерхан өлкәсе, Нариман районы (хәзерге Приволжский), Киләнче авылында егерме еллап колхоз председателе булып эшләгән Ибраһим абый Мәхмүтовтан Халидә Гатина тарафыннан язып алынган. Ибраһим абзый Г. Тукайны да күргән. 1924 елдан партия члены, партия-совет эшләрендә актив катнашкан. Ул 1893 елны туган, моннан берничә ел элек вафат булды.

Истәлекнең соңгысы Оренбург өлкәсенең Шарлык районы, Мостафа авылында башлангыч классларда Мусаны укыткан Фәйзи Сафаровның Хәмит Ярмигә язып җибәргән материаллардан алынды (11 март, 1961 ел).

**Асия ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА,**
**Халидә ГАТИНА.**

## Берданка мылтык

Бервакыт авылга казаклар кереп-чыгып йөри башладылар. Казаклар килдеме авылга — кешеләр шым булалар, урамнарга чыгып йөрү бетә. Алар чак кына күренми торган арада без, малайлар, тизрәк тышка йөгерешеп чыгабыз. Ул чакта безгә ун-унике яшьләр иде. Шул көннәрдә Муса безне солдатлар итеп тезә иде дә, «айт-два»га бастыра иде. «Налево, к каблуки, направо, к носки», дип, солдатлардан ишетеп калган командалар бирә бу. Безнең командада кызлар да була торган иде. Алар килгәч, команда «рота»га тула иде. Ун-уңдүрт кеше җыелабыз. Шуннан без аклар белән кызылларга бүленеп алабыз да, әйдәме-әйдә атакага ташланырга. Солдат уеныннан соң беребезнең абзарына җыелабыз. Анда кәгазьдән шлемнар ясыйбыз. Ә Муса сурәт ясый. Сурәт ясарга ул оста иде.

Казаклар авылда халыктан түләү җыеп йөриләр иде. Ә без, алар артыннан ияреп, күзәтеп торабыз. Муса шушы хәлне сурәткә дә төшереп куйды. Сурәте әле дә исемдә: бер казак, биек фуражка киеп, револьверын тотып, бер бабайның алдына баскан. Ә бабай киез өстендә башын иеп утыра. Офицер артында исполнительный[1] басып тора. Алар бабайдан тавык таптыралар.

Мусаның бу рәсемен карап, без эч катканчы көләбез. Ул шулай бернәрсәгә ачуы килдеме, аны шунда ук кәгазьгә төшереп куя. Бервакыт Кәс буада балык тотып утырабыз, тегермәнченең малае белән кызы килде дә безгә балык каптырырга комачаулый башладылар. Муса кепкасы эченнән кәгазь-каләм чыгарды да, шунда ук тегеләрне ишәккә атландырып сурәтләрен ясап куйды. Бу сурәтне тегеләрнең үзләренә дә күрсәттек шикелле.

[1] Исполнительный — биредә офицер кушкан эшне башкаручы.

* * *

Казаклар Мостафадан киттеләр. Өлкән агайлар әйтүенчә, шушы арада Мостафа авылын читләтеп (олы юлдан бармыйча), Күлгән сыртыннан Шарлык ягына бер отряд узачак икән. Бу отряд казаклардан һәм Корбан исемле башкисәр җитәкчелегендәге бай малайларыннан төзелгән бандадан тора, күрәсең.

Коммун Гали, Чырый абзый, шулай ук Миңлегали белән Хәйбул абзыйлар ашыгып көч туплый башладылар. Уилап кеше җыелды. Аларның Бакый һәм Гомәр авыллары белән бәйләнешләре булган, әлеге авыллардан да кешеләр чыгып, бандасың тешен сындырырга тиешләр. Шулвакыт мәгълүм булды: акларның бер отряды да шушы арада үтәчәк икән. Караңгы төшкәч, Чырый абзыйлар берничә кеше җыелдылар да, Бакый һәм Гомәр авыллары белән кушылыр өчен, Күлгән сыртына табан юл тоттылар. Без, малайлар да, сездерми генә, зурлар артыннан иярергә булдык. Безнең алдан хәзерләп куйган «кинжал» — сынык чалгы-пычак һәм бер берданка мылтык бар иде. Мылтыкны Муса табып алган иде. Ул, җирдә озак ятканлыктан, тутыгып, патроннары эчендә торган кое череп беткән иде. Менә шул чалгы-пычак һәм тутыккан берданканы күтәрдек тә акларга каршы баручы зурлар артыннан ияредек. Без башта Нит буенча бардык, аннары әрәмә үзәненнән чыктык. Ә үзәннән Колама тауга күтәрелергә тиешбез.

Колама таудан зур гына юл үтә. Ул юлга чыгарга ярамый, акларга эләгүең бар. Без зурлардан бик тиз күз яздырдык. Берданка авыр булып чыкты. Аны ике кеше күтәреп барабыз. Стволыннан Муса тоткан, прикладыннан — мин. Муса зурларның кая киткәнен күреп калыр өчен алдан китәргә тиеш булды. Шуннан безнең арада ризасызлык башланды, күбебезгә курку төште, барыргамы, юкмы, дип шикләнә башладык. Муса аны-моны уйлап тормый, сез теләсәгез нишләгез, мин киттем, менә сезгә винтовка, ул булгач, курыкмагыз, дип, тутыккан берданканы безгә бүләк итеп, туп-туры Очлы уба сыртына юл тотты. Без борылып кайтыр, куркыр дип уйлаган идек. Тәки кайтмады. Шуннан йөрәкләнеп без дә Колама тауга күтәрелдек. Карасак, юл буйлап пар үгезләр җигелгән дүрт арбалы килә. Алар артында ат менгән берничә казак та күренде. Аларны күрү белән үк без әрәмәгә таба йөгердек. Шунда, каенлык арасында иртәнгә кадәр утырдык та авылга кайттык.

Ә Муса икенче көнне кичкә генә зурлар белән авылга кайтты. Ул аларны Очлы уба тирәсендә куып җиткән булган. Алар юлда теге җигүле үгезләрне очратып, казакларын коралсызландырганнар. Әшнең куркынычлыгын сизеп алгач, ямщиклар (арбада баручылар) тиз генә йөккә ут төрткәннәр. Анда корал һәм киемнәр төялгән икән. Алар янып өлгермәгәннәр, әлбәттә. һәм зурларның байтагы шуннан эләккән өр-яңа хром итекләр киеп кайттылар. Муса боларның барын да күреп торган һәм ул безнең исне китәреп сөйләде. Шуннан без, зурларга ияреп, юлга азык әзерли башладык. Кәс буага тагын балыкка киттек. Балыкны тотабыз да, тазартып кояшка элябез, киптереп каклыйбыз. Муса ак өек белән чабата кигән була, кара сатин чалбарын өек эченә кыстырып җибәрә. Килешеп тора иде үзенең баләкәй гәүдәсенә.

Шушы көннәрне бер күңелсез хәл булып алды. Без, зурларга ияреп, Бакый ягына китәр алдыннан үзебезнең китап-мазарларны, Мусаның рәсемнәрен, шигырьләрен абзар сулыгына (кыегына) кыстырып киткән идек. Кайтуга, безнең әти, аклар кулына эләкмәсен, балисе булыр, дип, аларны утка яккан.

## Ике итек сугышы

Без, Муса, Җиһанша, мин һәм тагы берничә малай, келәткә җыелып, алдашлы уйный идек. Кем чын ялганны белә? Шуннан Җиһанша дигәнебез алдый башлый. Бер җәнлек тоттым, ди ул, карасам, моның башы гәүдәсеннән ун тапкыр зур.

— Мондый хәл була,— ди Муса. — Бу чын ялган түгел.

— Мин бер үгезгә очрадым,— дим мин. — Моның башында сигез мөгезе бар. Бу килде дә мине сигез мөгезе белән берьюлы сөзә башлады. Иң зур ике мөгезеннән тоткан идем, купты да чыкты моның ике мөгезе.

— Бу да чын ялган түгел,— ди Муса. — Чын ялган менә шулай була. Киттем мин башны иеп, аякка итек киеп. Аякны кыса итек, чөнки алар беткән кибеп, кәкрәеп. Юлда карасам, ята бер керпе, үзе үле, үзе тере. Кысып тоттым да моны, ташладым ботарлап, алдым маен, сөрттем итеккә. Моның мае ике итеккә җитми, бер итеккә бетми. Май җитмәгәч, итекләр китте сугышып. Майлы итек китте шуып, майсызы китте аны куып. Майлы итек таеп, Кәс буага төште барып. Нишләргә, юк бит бер итек. Үренәм — кул

җитми, кычкырам — ишетми. Бар, мин әйтәм аякка, алып мен итегеңне, кирәк булса. Аяк төште дә итекне киеп менде. Майсыз итекне дә суга батырып алдым. Шуннан сүрелде. Менә чын ялган шулай була.

## «Ике казан»

Мин ул вакытта райколхозсоюзда председатель булып эшли идем. Бу вакытта Киләнче авылы колхозчыларының тормышлары бик авыр иде. Менә шул чакта мине Киләнче авылына колхоз председателе итеп сайладылар.

1933 елның яз башлары иде. Беркөнне районнан «Ялкын» газетасы редакторы Мөслим Фәтхуллин килде. Аның белән Муса Җәлил дә бар иде. Мөслим мине Муса белән таныштырды: «Бу «Ялкын» газетасыннан Муса Җәлил була. Ул сезнең колхоз белән танышырга килде, аннан бераз ял да итәр». Таныштырды да үзе кайтып китте. Мусаны мин үзебезгә алып кайттым. Өйгә кайткач бераз ял иттек. Якыннанрак таныштык, аннан соң әйттем: «Менә сиңа караватъ, өстәл, урындык. Үзең теләсәң нишлә, без сиңа комачаулык итмәбез». Үзенә бер чыбылдык та бирдек, йокларга тыныч булсын дип.

Икенче көнне иртә белән торып ашагач-эчкәч, күк юргага рессур[1] арба җигеп, киттек бригадаларга, эшләгән җиргә. Муса аларның эшләре белән танышты, ашларын да татып карады. Ул вакытта без балык белән генә туена идек. Безнең бригадаларда ике казан иде: берсе — «ударниклар», икенчесе — «ялкаулар» казаны. Ударникларга ике тәлинкә аш, кыздырылган балык бирә идек, ә ялкауларга бер казан балык шулпасына бер стакан ярма салып пешерә идек. Казан янына язып куйган идек: «ударниклар казаны», «ялкаулар казаны». «Сиңа ялкаулар казаныннан», дип әйтсәң, ул кеше әлеге казан янына якын да бармый иде. Оят бит. Муса, бригадаларга килгәч, бу хәлне күрде. Соңыннан ул җыелыш җыйды. «Ялкын» газетасында аның бу турыда язган «Ике казан» исемле мәкаләсе басылып та чыкты.



**Рәсемдә:** Әстерхан өлкәсендәге Киләнче авылында Ибраһим Мәхмүтов йорты. Бирегә 1933 елда Муса Җәлил тукталган. **Хәмит ЯРМИ фотосы.**

Муса күк юрганың дилбегәсен үзе тотып йөрергә ярата торган иде, шулай үзе генә чыгып бригадаларның эшләре белән танышып йөри иде.

Без аның белән балык тотарга да йөри идек. Беренче көнне атка утырып Кафтаник елгасына бардык. Үзебез белән казан, таба, кармак, чыбылдык кебек кирәк-ярак әйбер-

[1] Рессур — рессорлы, сиртмәле.

лар да алып бардык. Аулга йөрү вакыты иде. Шуңа күрә бер мылтык та алдык. Муса башына яулык бәйләп, күкрәгенә хәтле суга кереп, балык тота торган иде. Шунда ул кармак белән сазан балыгын тотты. Шуннан миңа әйтә: «Ибраһим абзый, ухаmaking үзем пешерәм, балык тотуның бөтен кызыгы да шунда аның»,— ди. Шунда без ухада пешереп ашадык, кыздырып та ашадык. Кичкә хәтле торып, өйгә дә балык алып кайттык.

Аннан соң аның яратып ял итә торган бер елгасы бар иде — Садовой ерек (Бакча елгасы). Бригадаларга барып кайта да шул елга буенда бераз ял итеп, халык белән үзе дә ашап-эчеп, икенче бригадаларга чыгып китә торган иде. Ул бригадаларда стена газетасын чыгаруга зур әһәмият бирә, бу эштә аларга ярдәм дә итә торган иде. Бездә торганда ул «Ялкын» газетасына еш язып торды.

Бригадалардан йөреп кайткач, кич белән ашап-эчкәннән соң, елга буена су коенырга чыгып китә иде. Су коенып кайткач, өстәл янына утырып, бер-ике сәгать эшләп ала иде дә чыбылдыкка кереп ята иде.

Иртә белән бик иртә тора иде. Сауган сөт эчә иде дә тагын бригадаларга чыгып китә иде.

Ул бездә ун-унике көнләп торды. Шулвакыт эчендә бер-ике мәртәбә калага барып килде. Ни өчен барганын белмим.

Кичләрен клубка да бара торган иде. Яшьләрнең уеннарын читтән генә карап тора, үзе катнашмый торган иде.

Китәр вакыт җиткәч, мин аны үзе яраткан шул күк юргага утыртып шәһәргә озаттым.

## Тырыш бала

Мин Мостафа авылында алты ел балалар укыттым. Муса ул вакытта бик кечкенә булса да, беренче класста гына түгел, икенче, өченче класста укыган балаларга караганда да зирәгрәк һәм әхлаклы бала иде. Хәтеремдә калганча, бик кечкенә булганлыктан, аны «кечкенә Җәлил» дип йөртәләр иде. Ишетеп алган җыр, шигырьләрне ятлап, аларны кешеләр каршында сөйләп көлдерә иде.

Оренбурга әтиләре белән күчеп киткәннән соң, җәйлектә авылга кайтып, балалар арасында театр оештыру, күңелле шигырьләр уку кебек эшләргә балаларны туплый иде. Мәсәлән, ул, «Варенье» исемле кечкенә театр китабы язып, балалар белән театр уены оештырды. Мәдәният сөюче аңлы кешеләр: «Кечкенә Җәлил кебек балаң булса иде», дип сокланалар иде.

библиография

# БОЛГАР-ТАТАР ТАРИХЫНА ЯҢА КИТАП

Күптән түгел Мәскәүдәге «Наука» нәшриятында болгар-татар акча системасы турында китап «Булгаро-татарская монетная система XII—XV вв.» (1983) басылып чыкты. Аның авторы тарих фәннәре кандидаты, Казан университеты доценты Әзһәр Мөхәммәдиев. Ул күп еллар буена Мәскәү университеты профессоры Г. А. Федоров-Давыдов белән берлектә Идел буе болгар-татар шәһәрләрен казуда катнашты. XII—XV гасырларда сугылган, шул чорларда әйләнештә йөргән һәм җир астында сакланып, соңгы вакытларда гына табылган бакыр-көмеш тәңкә хәзинәләрен өйрәнде. Әлбәттә, алар галимне чүлпы тәңкәләре буларак кына кызыксындырмый. Идел буе тарихы фаҗигаләргә бай. Төрки-татар телендәге язма истәлекләр күп сакланмаган. Шуңа күрә ул тәңкәләр борынгы чорлардан безнең көннәргәчә килеп җиткән тарихи язма чыганак итеп карала.

Китап үзенә җәлеп итәрлек: «Мөгаен, урта гасырлардагы бик аз дәүләтләр генә Идел буе акча сарайлары суккан кадәр тәңкә суга алганнардыр» дигән сүзләр белән башланып китә. Китапның ахырында китерелгән тасвирламадан дистәләгән мең тәңкәне эченә алган 28 хәзинә һәм коллекция өйрәнелгәнлеге күренә. Шул нигездә автор җитди һәм кызыклы гына нәтиҗәләр ясаган.

Борынгы заманда акчага аның хакы язылмаган. Тәңкә нигездә алтын яки көмештән сугылганга моның кирәге дә аз булган. Әйтик, бер тәңкә икенчесеннән ике мәртәбә авыр икән, димәк, аңа ике мәртәбә күбрәк товар сатып алып булган. Шуңа күрә китапта болгар-татар акча системасының тарихи үсешендәге тәңкә үлчәү нормаларының закончалыклары, акча реформалары, аларның кайчан, кайда, кайсы хан чорында тормышка ашырылу шартлары һәм юллары ачып бирелә.

Борынгы татар әдәбиятында кулланылган акча терминнарын тикшереп, аларны нумизматика фәне белән бәйләү һәм ныгыту авторның тагын бер уңышы дип санарга кирәк. Мәсәлән, ул «мал» яки «динар» кебек терминнарның үзенчәлекле булып, барып тик монголларга кадәр чорда сугылган Болгар тәңкәләрендә генә очравына басым ясап үтә. Шул ук вакытта болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы атаклы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабында да мондый терминнарның шул ук мәгънәдә файдаланганлыгы күрсәтелә.

Тел мәсьәләләрен нумизматик материал белән бәйләү, Болгар кабер ташларындагы I һәм II стилы сөйләшен сыйнфый-политик вакыйгалар белән аңлату авторның «Казан утлары» журналы 1981 ел 6 санда урнаштырылган мәкаләсендә дә чагылыш тапкан иде инде. Тикшерелә торган китапта да бу мәсьәлә ачык итеп куелган. Болгарда XIII—XIV гасырларда сугылган меңләгән бакыр тәңкәләрдә «Котлы булсын», «Котлы булсын яңа пул» (пул — бакыр тәңкә), «Болгар пулы» һәм «уналты пул — тәңкә» дип язылган. Мондый бакыр акчалар алтын яки көмеш тәңкәләр белән чагыштырганда бик арзан булганга, шәһре Болгардан ары китә алмыйча аның урамнары туфрагында гына күмелеп сакланганнар. Менә шул бакыр тәңкәләрдәге язулар, ягъни акча легендалары, борынгы Болгар чоры һәм гомумән Идел буендагы җанлы тел ситуациясен тикшерү өчен кыйммәтле чыганак булып тора. Болгар телен өйрәнү өстендә эшләгән галимнәр нинди генә караштә торуларына карамастан бу тарихи чыганаклар белән хисаплашырга тиешләр.

Китаптан күренгәнчә Идел буенда акча сугу үзәкләре Болгар, Биләр, Сарай әл-Мәхруса, Сарай әл-Җәдид, Сарайчык, Гөлстан, Мукшы, Укәк, Хаҗи-Тархан (Астрахань) һәм Казан шәһәрләре булган. Бу үзәкләр арасында XII—XIII гасырларда Болгар шәһәре өстенлек итсә, XV гасыр башында Казан акча сугу сарае зур әһәмият казанган. Казан, экономик яктан яхшы ук алга киткән булганга, Идел буендагы башка өлкәләргә акча әйләнешендә тон биреп торган. Шулай итеп, Казан ул вакытлардан

бирле мөстәкыйль дәүләт үзеге булган дип әйтергә мөмкинлекләр арта бара. Моңа кадәр тарихи әдәбиятта Казан ханнары династиясенә Олы-Мөхәммәт хан нигез салган, Казан ханлыгын 1437—1445 елларда ул оештырган дигән фикер яшәп килә иде. Дворян тарихчыларыннан калган бу фикердән ваз кичәргә вакыт бик җитте инде. Китапта моңарчы тарихчыларга билгеле булмаган, Олы-Мөхәммәткә кадәр Казанда акча суктырган Гыясетдин турында сөйләнә. Автор анык моңа кадәр фәндә мәгълүм булмаган сигез йөздән артык тәңкәсен тапкан.

Тагын бер әһәмиятле мәсьәләгә тукталып узарга кирәк. Ул да булса, Казанны шәһре Болгарның варисы һәм дәвамчысы итеп карау турында. Моңа кадәр дә без, тарихчылар, бу мәсьәләне социаль-экономик, этник яктан, культура, политика, дәүләт төзелү күзлегеннән карап хәл итә идек. Ләкин тарих фәнендә төрле фикерләр булуын да онытмаска кирәк. Кайбер тарихчылар болгар дәүләте белән казан татарлары дәүләте (Казан ханлыгы) арасындагы турыдан-туры дәвамчылыкны күрмәскә тырышалар. Ә минә бу мәсьәләдә болгар-татар халкы икеләнеп тормаган.

Ундүртенче йөз азагында Аксак Тимер (Тамерлан) гаскәрләре Идел буе шәһәрләрен җимергәннән соң аларда тормыш туктап кала диярлек. Халык кырыла, куыла, йортлар, шәһәрләр җимертелә. Автор сүзләренә караганда урта һәм түбән Идел буе шәһәрләренең күбесендә хәзерге вакытта нинди генә таш яки балчык өемен казып карасаң да, Аксак Тимер һөҗүме вакытында җимертелгән йорт, бөтен гаиләсе белән үтерелеп ташланган кеше сөякләре чыга. Ләкин Аксак Тимер гаскәрләре Казанга килеп җитмәгәннәр һәм ул исән калган. Ә халыкның күп өлеше Кама аръягындагы болгар җирләреннән Казан ягына, электән үк болгарлар тарафыннан үзләштерелгән җирләргә күчкәннәр.

Үзенең акча сарайларында дисталәгән мең акча суккан XV гасыр Болгары — ул инде Казан шәһәре. Халык үзенең традицияләрен онытмаган. Тәңкәләрдән күренгәнчә, шәһәрнең исеме беренче вакытта рәсми рәвештә Болгар яки Болгар әл-Җәдид (Яңа Болгар) булып, соңрак Казан атамасы өстенлек алган.

Автор китапның кереш өлешендә Идел буенда акча сугу VIII гасырда үк башлана дип әйтеп уза. Ләкин бу чор бик аз өйрәнелгән әле. Киләчәктә Әзһәр Мөхәммәдиев кебек тәңкәләр саный-саный укучыларны үзенең яңа хезмәтләре белән ул чорларга да алып керер, безнең белемнәрне шулай итеп тагын баетыр дигән өмет белән аңа иҗади уңышлар теләп калабыз.

**Сәлам АЛИШЕВ.**

# ТАТАР ХРЕСТОМАТИЯЛӘРЕ

Хрестоматия — төрле авторларның төрле характердагы әсәрләреннән төзелгән «уку китабы» ул. Безнең татар әдәбияты тарихында гадәттән тыш язмышлы ике хрестоматия бар: Мартемьян Ивановның (1812 елда туган) «Татар хрестоматиясе» (1842, 1856 елларда басылган); Салихҗан Күкләшевның (1814—1864) «Диване хикәяте татар» китабы (1859). Революциягә кадәр үк инде укымышлылар бу китапларның татар әдәбияты тарихындагы зур әһәмиятенә игътибар итәләр (Җамал Вәлиди, «Шура» журналы). Революциядән соңгы елларда алар белән кызыксыну торган саен арта бара. Әдәбият тарихыбызның бу чоры турында сүз чыкканда алар һич тә игътибардан читтә калдырылмыйлар. Менә, ниһаять, Казан университеты басмаханәсендә, студентларга кулланма рәвешендә, бу хрестоматияләр буенча күләмле махсус фәнни хезмәт тә басылып чыкты: «XIX йөз татар хрестоматияләре». (Казан, 1981). М. Иванов хрестоматиясе турындагы бүлекне Ш. Садретдинов, С. Күкләшев китабы турындагы бүлекне Х. Миңнегулов хәзерләгән. Хезмәттә хрестоматияләр материалыннан күп үрнәкләр китерелә.

Баштан ук әйтергә кирәк: бу хезмәт әлеге хрестоматияләрне фәнни тикшерүләрне яңа баскычка күтәрде. Гадәткә кереп калган күп кенә ялгыш фикерләр дәлилле рәвештә тәнкыйтьләнә, хрестоматияләр турында фикер йөртү ныклы нигезгә куела. Хезмәттә ни өчен татар әдәбияты тарихын өйрәнгәндә бу «уку китапларына» мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булуыбызны аңлатучы фикер дә бар. Билгеле тарихи сәбәпләр тәэсирендә, татар әдәбияты, әлегә, үз исеменнән эшли алмаган, әмма культура тарихыбыз өчен зарури булган «татар әдәби теле халыкның җанлы сөйләм теленә якы-

найту (фольклор) әсәрләрен җыеп эзлекле бер системага салып бастыру (20 б.), рус әдәбияты әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү тәҗрибәсен башлап җибәрү» (22 б.) кебек җитлеккән бурычларны башлап мәйданга куюны хрестоматияләр үз өсләренә алалар, шул эшләре белән XIX йөз татар әдәбияты тарихында үзләренә мактаулы урын яулыйлар. Күп төрле чыганаклар нигезендә зур тырышлык белән язылган хезмәтнең шул мәсьәләләр хакында яңадан-яңа фикерләр кузгатырлык итеп эшләнүен дә аның уңышы дип бәяләргә кирәк. Дөрес, «капкага ук» килеп калган кайбер фикерләрне китапка кертү аның фәнни кыйммәтен тагын да арттырыр иде. Мәсәлән, М. Иванов хрестоматиясеннән китерелгән материаллар — русчадан тәрҗемә мәсәлләрнең һәм көнчыгыш хикәятләренең башка кеше тәрҗемәсе икәнен шактый ачык искәртә. С. Күкләшев бу көнчыгыш хикәятләренең кайберсен соңыннан, яңадан редакцияләп, үз хрестоматиясенә дә кертә. Бу тәрҗемәләрнең авторы шул С. Күкләшев булган дигән гипотезаны куярга тулы нигез бар. С. Күкләшев фарсычадан тәрҗемә эшчәнлеген 1834 елда ук башлап җибәрә: фарсыдан русчага тәрҗемә әсәрен «Заволжский муравей» (№ 11) журналында бастыра. М. Иванов хрестоматия төзегәндә, инде аның белән бергә эшли башлаган С. Күкләшев, бу китапка махсус тәрҗемәләр һәм мәкальләр дә хәзерләп бирүе бик мөмкин. Русчадан мәсәлләр (17 мәсәл) тәрҗемәсен дә ул башкарган булырга тиеш. «Иван Костин» тәрҗемәсендәге кайбер синтаксик, лексик берәмлекләр, (калька, керәшен татарларында гына очрый торган сүзләр, «х» авазын «к»лаштырулар) М. Ивановның керәшен татары булуын искәртмиләр микән?..

«...урнаштырылган әсәрләр... Оренбург төбәгендә киң таралганнар, укылганнар. С. Күкләшев нәкъ менә шуңа күрә дә бу әсәрләргә мөрәҗәгать итә һәм үз китабында алардан үрнәкләр урнаштыра (115 б.) дигән фикер дә бәхәсле. «Ширзад һәм Гөлшаджан», «Җәмшид, Заххак һәм Фәридун» кебек, татар әдәбиятында башка җирдә күзгә-башка чалынмаган «тәрҗемәләрне» бүген, С. Күкләшев исеме белән бәйләп йөртү чынлыкка якын булыр иде. Ул чор татар әдәбиятында нәкъ шул типтагы әсәрләргә борылыш башланган көннәр. (Ф. Халиди, Г. Фәезханов, Ш. Рәхмәтуллиннар чорында (80—90 елларда) ул тенденция чәчәк ату чорын кичерә.) Фарсыдан тәрҗемәче С. Күкләшевнең шул хәрәкәтне сиземләп аңа кушылуы бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Аның русчадан тәрҗемә мәсәлләрен ни өчен үз китабына кертмәве дә аңлашыла. Китапның бер темага багышланган җыентык — «Татар хикәятләре хрестоматиясе» икәнен исеме үк искәртеп тора.

Бу әйтелгән фикерләрне «Хрестоматияләр» турындагы хезмәттә С. Күкләшев темасы кайтышырак эшләнгән дип аңларга ярамый. Хезмәттә С. Күкләшевнең иҗат биографиясен булдыру юнәлешендә мөһим адым ясалган. Бу укымышлының, Рәхмәтулла Әмирханов, Каюм Насыйрилар белән бергә, яңа әдәбиятыбызда демократик юнәлешне башлап җибәрү юлында эшләгәнлеге, шул хәрәкәтнең елга башында торучыларның берсе булуы шактый ачык тәсмерләнә. Әдәбиятыбыз тарихында ул, университет белеме алып, татар әдәбияты, культурасын үстерү өстендә ихлас күңелдән бирелеп эшләүчеләрнең беренчеләреннән.

Билгеле, мондый күләмле хезмәттә кимчелекләр дә юк түгел. Фәнни төгәллек вак детальләрдән, хәтта, өтер, ноктalардан җыелып формалаша. Өтер куелмау, яки урынсыз кую аркасында фикер чатаклыклары барлыкка килүен төрле мисаллар белән күрсәтергә мөмкин. Болар бездәге текстология эшенең соңгы вакытларда гына фәнни нигезгә утыра башлавы аркасында килеп чыккан кимчелекләр, тәҗрибә арту белән аларга урын калмас дип ышанасы килә. Ә менә иске әдәби ядкарьләрне укуда, архаизм-алынма сүзләрне аңлатудагы кимчелекләр — шул юнәлештә ныклап, тырышып тир түгүебезне сорый торган эш. Уңышсыз тәрҗемә-аңлатулар, кызганычка каршы, биредә дә күзгә ташлана. Алар китапның ике бүлегендә дә бар. «Китмәй» сүзен «кәтмәй» (35 б.), «сөенеб» сүзен «сөянеб», «игенче» сүзен «икенче» (44 б.) һ. б. дип укулар моңа мисал була алалар. Мондый чатаклыклар икенче бүлек азагында «Искәндәрнамә» әсәрендә аеруча күзгә ташлана («безем» сүзен, тоташ «бәзем» — (сый мәҗлесе), дип уку һәм тәрҗемә итү, «әйләдек»не — «илдек» дип укулар һ. б.).

Әмма мондый кимчелекләр хезмәтнең әһәмиятенә аз гына да күләгә төшерә алмый. Аның мәйданга чыгуы, андагы олы казанышлар халкыбызның культура тормышында нәтиҗәле һәм күренекле факт булып калачак.

Мәсгут **ГАЙНЕТДИНОВ.**

# ИСЕМНӘР — ТАРИХ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ

Казан дәүләт университеты профессоры Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»[1] басылып чыгуны безнең халкыбыз ономастикасының үсү-җитлегү чорына керүен дәлилләүче объектив бер күрсәткеч дип бәяләргә мөмкин. Әйе, ономастика фәне бездә соңгы 15—20 ел эчендә интенсив үсә башлады һәм нәкъ менә Г. Саттаров хезмәтләрендә фән дәрәҗәсенә күтәрелде. Авторның элегрәк дөнья күргән «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» (1970), «Ни өчен шулай аталган» (1971), «Татарстан АССРның антропотопонимнары» (1973) кебек китаплары нәкъ әнә шуны раслый. Соңгысында кеше исемнәре җирлегендә ясалган авыл исемнәрен өйрәнүгә зур урын бирелә һәм ул авторга кеше исемнәре сүзлеген төзү өчен үзенә бер хәзерлек этабы да булды.

«Татар исемнәре сүзлеге» төзүченең мәкаләсе белән ачыла. Татар исемнәренең системасын, структурасын һәм хронологик классификациясен ачыклауны Г. Саттаров, бик хаклы рәвештә, бу исемнәрнең, татар халкы һәм теле тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә торган хәлдә, дәвамлы тарихи формалашу һәм үсеш юлы кичерүләрен искә алып хәл итә. Исемнәребезнең күп гасырлар буена туплана килгән бай хәзинәсеннән ул беренче чиратта гомумалтай катламын аерып күрсәтә. Фәндә мәгълүм булганча, бик борынгы заманнарда төрки, монгол һәм тунгус-маньчжур телләре гомумалтай теле бердәмлеген тәшкил иткәннәр. Кайбер галимнәр бу бердәмлек безнең эрага кадәр алты мең еллар элек булган дип исәпли. Безнең «алтын», «буга» (үгез) кебек компонентлар катнашкан Алтынбай, Алтынбәк, Алтынчәч, Акбуга, Исәнбуга кебек исемнәребездә әнә шул бердәмлекнең эзләре сакланып кила икән. Автор моны дәлилләү өчен әлеге компонентларның монгол һәм тунгус-маньчжур халыкларь исемнәрендә дә очраганлыгын әйтә, шуның конкрет мисалларын китерә.

Исемнәребезнең чираттагы катламын Г. Саттаров «борынгы төрки катлам» дип исемли һәм аңа хәзерге төрки телләрнең барысы өчен дә уртак булган борынгы төрки кеше исемнәрен кертә (Айбикә, Байтимер, Илбарс, Уразбикә, Үтәмеш һ. б.).

Иске татар теле катламына караган исемнәр хакында сөйләгәндә автор аларның килеп чыгышлары төрле-төрле булуына игътибарны юнәлдерә, бу исемнәр арасында борынгы төрки телгә, болгар-татар теленә, кыпчак теленә мөнәсәбәтле кеше исемнәре очравын күрсәтеп үтә.

Санап үтелгән өч этнолингвистик катламга караган исемнәрнең шактый зур өлеше бүгенге көндә инде кулланылыштан чыккан, алар я авыл исемнәрендә, я аерым фамилияләрдә, я язма ядкарьләрдә генә сакланып калганнар. Табигый ки, искергән исемнәр урынына халык даими рәвештә яңа исемнәр иҗат итә торган. Бу процесс бигрәк тә совет чоры өчен хас. Шуңа күрә дә Г. Саттаровның Бөек Октябрьдан соң барлыкка килгән яңа татар исемнәре катламын махсус аерып күрсәтүе бик урынлы.

Теләсә кайсы телнең үсеш тарихында башка телләрдән сүзләр алу күренешен күзәтергә мөмкин. Мондый алынмалар антропонимнарга да кагыла. Г. Саттаров үзенең классификациясендә татар исемнәренең гарәп-фарсы телләреннән, рус теленнән (һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән) кергән өч катламын күрсәтә, бу катламнарның барлыкка килүе нинди тарихи-иҗтимагый сәбәпләр нәтиҗәсендә булуын ачыклый.

Ниһаять, кереш мәкаләдә татар антропонимиясенең хәзерге торышына анализ ясап, андагы үсеш-яңару процессларын күзәтелә. Болар нинди процесслар соң? Бер яктан, борынгы төрки-татар (Айдар, Айсылу, Алмаз, Арыслан һ. б.), икенче яктан, гарәпфарсы исемнәре (Галим, Галия, Дилбәр, Зөлфия, Камил, Рөстәм һ. б.), әлбәттә, өлешчә, хәзер дә кулланылышта кала килаләр. Моның өчен төп шарт — аларның җыйнакҗиңел әйтелешкә, матур яңгырашка һәм дөньяви мәгънәгә ия булулары. Ә менә дини йолалар һәм ышанулар, элекке социаль катламнар, кәсеп-һөнәр атамалары белән мөнәсәбәтле күп кенә исемнәр, совет кешесенең аң һәм культура дәрәҗәсенә, эстетик зәвыгына туры килмәгәнлектән, кулланылыштан төшеп калдылар.

Элекке исемнәр мирасын шул рәвешчә сайлап үзләштерү белән бергә, совет чорында күп кенә яңа исемнәр барлыкка килде. Бу исемнәрнең актив компонентлары булып ай, ал, гөл, ил, нур, таң, фән кебек тирән мәгънәле, идея-эстетик яктан һәркемне канәгатьләндерерлек сүзләр файдаланылуы күзгә ташлана (Айгөл, Айназ, Айзирәк, Алсу, Гөлгенә, Илгиз, Илнур, Таңсылу, Фәнзилә, Фәннур һ. б.). Бу компонентларның элекке исемнәребездә дә очравын искә алсак, татар антропонимиясенең үсешендә традицияләрнең саклануын һәм яңартыла баруын күрү кыен булмас.

Һәрвакыттагыча, безнең көннәрдә дә исемнәр хәзинәсен баетуда алынма исем-

---

[1] Саттаров Г. Ф. Татар исемнәре сүзлеге. Татарстан китап нәшрияты, 1981.

нәр әһәмиятле роль уйный. Мондый алынмаларның чыганаклары рус теле һәм рус теле арадашлыгында Көнбатыш Европа телләре булуы алдарак искә алынган иде.

Шул рәвешчә, кереш мәкалә тарихи-лингвистик анализны һәм теоретик гомумиләштерүләрне эченә ала. Бер үк вакытта ул сүзлектәге фактик материалны, андагы исемнәр байлыгын җиңелрәк һәм тирәнрәк үзләштерү өчен укучыларга ачкыч булып та хезмәт итә. Ә бу байлык, әйтергә кирәк, күләм ягыннан да, эчтәлеге белән дә гаять зур. Автор соңгы егерме ел дәвамында күп санлы экспедицияләр вакытында җыйналган, борынгы төрки кулъязмалардан, архив документларыннан, сан алу кенәгәләреннән, ЗАГС бюроларыннан, газета-журналлардан, матур әдәбият әсәрләреннән һәм башка чыганаклардан язып алынган, шулай ук аерым һәвәскәрләр туплап җибәргән кеше исемнәренең төгәл документлаштырылган картотекасын төзегән. Илле меңнән артык карточканы эченә алган шушы картотекадан сайлап, хезмәтнең сүзлек өлешендә ун меңнән артык (ә тәрдәшләрен дә кертеп исәпләсәң унбиш мең чамасы) кеше исеме теркәлгән. Бу саннар үзләре генә дә зур тәэсир калдырырлык. Чагыштыру өчен кайбер фактлар да китереп үтү кызыклы булыр. Соңгы елларда башка төрки халыкларның да кеше исемнәре сүзлекләре басыла башлады (Т. Жанузаков. Тайны имен. Алма-Ата, 1974; Ш. Жапаров. Словарь киргизских личных имен. Фрунзе, 1979 һ. б.). Бу басмалардагы исемнәр санының ике мең чамасыннан артмавы «Татар исемнәре сүзлеге»нең никадәр бай булып чыгуын аеруча ачык дәлилли.

Билгеле, хикмәт коры саннарда гына да түгел. Автор исемнәрне җыеп, алфавит тәртибендә теркәп чыгу белән генә чикләнми, ә шул ун меңнән артык исемгә караган бай мәгълүматлы аңлатма бирә. Конкрет әйткәндә, сүзлектә теге яки бу исемнең структурасы, ягъни аның нинди сүзгә (яки сүзләргә) нигезләнеп ясалуы, ул сүзнең кайсы телгә, кайсы чорга (катламга) караган булуы, нинди мәгънә (яки мәгънәләр) белдерүе күрсәтелә. Тамыр сүзләрнең этимологиясен ачу белән бергә, кеше исемнәре ясауда катнаша торган кушымчаларның да мәгънә төсмерләре ачыклап үтелә. Күп кенә очракларда балага ни өчен нәкъ менә шушы исемне бирүнең максаты һәм мотивлары ачыклана, халкыбызның исем кушу белән бәйле йола-ышанулары тасвирлана. Шуңа күрә дә хезмәтне чын мәгънәсендә татар исемнәренең этимологиясе тулы итеп бәян ителгән аңлатмалы сүзлек дип бәяләргә кирәк. Аерым исемнәргә бирелгән аңлатмалар, сүзлек максатлары чигеннән чыгып, фәнни тикшерену дәрәҗәсенә күтәреләләр һәм органик рәвештә кереш мәкалә белән бербөтен булып кушылалар.

Әлбәттә, исемнәргә бирелгән аңлатмаларның барысына да тукталу һәм хәтта аларны телгә алып узу да һич мөмкин түгел. Шуңа күрә туган телебезнең һәм халкыбызның тарихын, этнографиясен, йола-ышануларын, иҗтимагый-эстетик карашларын ачыклауга ярдәм итүче кайбер мисалларга гына игътибарны юнәлтеп үтик. Әйтик, сүзлектә ай (күк җисеме), ак, гөл кебек сүзләр катнашында ясалган исемнәрнең аеруча еш кулланылуы күзгә ташлана (мәсәлән, гөл компоненты кергән 214 исем теркәлгән). Әлеге сүзләр татар антропонимиясендә элек-электән үк сафлык, пакьлек, яктылык, нурлылык, күркәмлек, гүзәллек, намуслылык кебек сыйфатларның символы булып саналганнар. Табигый ки, һәр ата-ана үз баласының әнә шундый күркәм сыйфатларга ия булып үсүен теләгән һәм бу теләгән балага исем сайлауда да чагылдырган. Баланың бәхетле, аң-белемле булуын теләү мотивлары бәхет (архаик синонимнары кот, ураз), галим, гыйлем, фән кебек сүзләр кергән исемнәр аша белдерелгән. Әгәр бу соңгы сүзләр туры мәгънәләрендә алынса, бик күп очракларда аларның символик синонимнары файдаланылган. Менә бер генә мисал. Сүзлектә миңле компоненты кергән 150 ләп исем очрый. Ни өчен болай күп дигәндә, автор язганча, электә миңле бала бәхетле була дип ышанганнар. Әгәр яңа туган баланың тәнендә миңе булса, аңа миңле компоненты кергән исем кушканнар. Хәтта бала туып шактый вакытлар үткәннән соң аның тәнендә миң күрсәләр, аңа миңле сүзе кергән яңа исем куша торган булганнар.

Борынгы йола исемнәренә кагылышлы шундый кызыклы факт та игътибарны җәлеп итә: элек төрки халыкларда баланың кайчан тууына карап исем кушу гадәте дә булган. Халык бәйрәм яки базар кебек шатлыклы, әһәмиятле көннәрне генә түгел, бәлки көннең аяз яки буранлы, яңгырлы булуы кебек детальләрне дә искә алган. Буран, Буранбай, Буранша, Бәйрәмбай, Бәйрәмсылу, Бәйрәмгол, Базар, Базарбай кебек исемнәр әнә шул йола белән бәйләнгән. Алар хәзер Буранов, Бурангулов, Буранчин, Базаров фамилияләрендә сакланып киләләр.

Г. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге» җәмәгатьчелек тарафыннан зур кызыксыну белән каршыланды. Тел белгечләре көндәлек матбугат битләрендә аңа югары бәя бирделәр. Мәсәлән, «Советская тюркология» журналы аның зур фәнни-практик әһәмиятен, татар тел белеменең генә түгел, бәлки тулаем төрки антропонимиканың җитди казанышы булуын күрсәтеп үтте (1982, 4 сан, 104 бит). Бу бәя белән килешмичә мөмкин түгел.

**Хуҗи МӘХМҮТОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

Мидхәт Фәйзуллин

# СӘНГАТЬКӘ ЮЛ ЯРГАНДА

*Татарстанның халык артисты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Җәүдәт Фәйзи үзенең музыкаль сәнгате белән халык күңелендә яши, шулай ук аның якты образы фәнни һәм әдәби хезмәтләрдә дә яшәвен дәвам иттерә. Мәсәлән, композиторның бертуган абыйсы — РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, профессор Мидхәт Фәйзуллин аңа багышлап документаль әсәр язды. Бүгенге санда шушы истәлекләрдән кайбер өзекләр тәкъдим ителә.*

1920 елның җәе. Кечкенә арбага җигүле пони Урал елгасы аръягындагы урман юлыннан юырта. Арбага дүрт малай утырган. Арада өлкәне — мин, ягъни унике яшьлек Мидхәт дилбегә тоткан. Энеләрем — тугызын тутырган Җәүдәт һәм сигездәге Шәүкәт белән аларның кордашы күрше малае Мөхәммәт — пассажирлар.

Минем йөз житди, чөнки кечкенәләрне имин кайтарып житкерү миңа йөкләнгән. Урман сирәгәя барып, борылышта күпер күренде. Оренбургка кайтып житү өчен елга аша салынган шул күпердән чыгарга кирәк. Җәүдәт дилбегә тотмакчы, миңа үпкә белдерә: «Тотып барыйм инде?! Күпергә житкәч, бирмисең инде син!— ди.— Әтигә әйтәм, дилбегәне гел син генә тотып бардың...»

Бәләкәй кара пони — ат белән ишәк нәселеннән, тик озын колаклары гына ишәкнеке. Бик күндәм жан иясе. Әмма кайчагында ишәк холкын да күрсәтеп куючан. Дилбегәне кем тотканын бик чамалый. Йомшак кулны сиздеме, шып туктый, аннары инде кузгатырмын димә. Шуңа күрә дилбегәне энеләремә бирмәскә тырышам. Бу юлы пони, өйгә кайтуны тоеп, күңелле генә юырта иде.

Мышкылдый башлаган энемне юатырга теләп, мин, күпергә житкәнче дип, дилбегәне Җәүдәткә тоттырам. Пони колакларын уйнаткалады, арбадагыларга кырын гына күз салды, ләкин туктамады.

Шул арада сирәк куаклыкка життек. Анда-монда үсеп утыручы маһабәт имәннәр төбендә чегәннәр таборы урнашкан. Пони юлдан чыкты да табор ягына юнәлде. Аны атлар күплеге җәлеп итте булса кирәк. Ишәк холкын күрсәтә башлаган понины Җәүдәт тыя алмас булды. Шул вакыт таза гәүдәле чегән нык һәм көчле куллары белән йөгәннән тотып алды. Пони аңардан ычкына алмыйча туктады. Чегән миңа: «Атыңны сат, яхшы хак бирәм»,— дип сүз кушты һәм понины тешләрен үк карый башлады. Мин куркып, югалып калдым, кечкенәләр елый башладылар. Безнең чарасызлыгыбызны күреп, чегән авызын җәеп көлде генә. «Яхшы хак түлим. Ул акчага чын ат алырсың. Ә бу — ат дисәң, ат түгел, ишәк дисәң, ишәк түгел»,— дип сөйләнә бирде. «Җибәр, ни дип балаларны куркытасың?»— дим. Ул понины үз атына алмаштырырга тәкъдим итте. Безгә таба килеп баручы җигүле арбада ике ирне күргәч, мин бар тавышыма аларга кычкырдым: «Абыйлар! Безне коткарыгыз!» Шуннан чегән бик яман сүгенде дә үзалдына төкеренде, аннары, «Нәрсә акырасың?» дип, понига чыбыркы белән сыдырды.

Бу хайванкайны без ярата идек, әмма ул безнеке түгел иде. Атаклы бай Хөсәеновләрнеке иде ул. Революциягә чаклы ук аларның хезмәткәрләреннән кемдер, пони җигеп, хутордан шәһәргә килгән һәм аны икенче бер хезмәткәргә вакытлыча калдырган булган. Шуннан бирле пони кулдан-кулга күчеп йөрде. Гадәттә аны җәй айларында бик теләп җигәләр, ә кышлыкка кемгә дә булса озатырга тырышалар иде. Чөнки кышын ашатасы була бит. Миллионер Хөсәеновләрнең мал-мөлкәтен, терлек-туарын конфискацияләгәндә, пони, инвентаризация кенәгәсенә теркәлмәгәнлектән, тапшырылмый калган. Шул чактан иясез малга әйләнгән. Узган көздә, бөтен кеше аңардан баш тарткач, безнең әти, хайванны кызганып, үзенә алды да миңа аны карарга — ашатырга, эчерергә, чистартырга кушты. Мин баштарак, бигрәк тә кышын, бу вазифаны теләмичә генә үтәдем, аннары аңа ияләштем һәм әйбәт кенә карый баш-

ладым. Хезмәтемнең әҗеренә җәй буена мин понининың хуҗасы булдым. Көзен без аны бүтән кешегә тапшырырга тиеш идек, әти бу хакта кем беләндер килешеп йөри иде.

Без понига утырып, урам малайларын көнләштерә-көнләштерә, күңел ачып кына йөрмәдек, эшләдек тә. Базарга бара идек, кырга бәрәңге утыртырга, урманга утынга китә идек. Кыскасы, төрле эшкә җиктек без аны. Иң күңеллесе, аны җигеп, ерак күлгә балыкка бару була иде. Шул рәвешле, пони безгә мәзәк өчен генә түгел, эшкә өйрәнүдә дә булышты. Югыйсә без, шәһәр малайлары, ат тугарып җигәргә кайда өйрәнер идек. Ә тормышта болар һәммәсе ярап куя бит. Әти кымыз шифаханәсендә хуҗалыкчы булып эшли башлагач, мине конюх итеп алдылар. Мин ике ат карарга тиеш идем. Мин бу эшне бик теләп, яратып эшләдем, ни дисәң дә, тәҗрибәм бар иде инде. Атларым да юаш, тыңлаучан иделәр. Мин шәһәр малае, ат менеп йөрергә өйрәндем һәм бу һөнәрем белән бик горурлана идем. Әмма бу эшем нибары бер җәй генә булды.

* * *

1923 елның җәй уртасында, кояш уттай кыздырган көннәрнең берсендә Җәүдәт малайлар белән су коенырга киткән. Гадәттә, без икәүләп йөри идек. Ә бу юлы ничектер барасы итмәдем. Азактан әни ялгызын гына җибәрергә ризалашты, тик бер сәгатьтән өйдә буласың дип шарт куйды. Ул вакытында кайтмады, әлбәттә. Без аллә ни хафаланмадык. Җәйге челләдә малайлар халкын судан тиз генә чыгара аласызмыни?! Ике сәгать тә үтеп китте, өч сәгатьтән дә артты. Әни борчыла башлады һәм мине теге малайларга җибәрде. Бар, белеш, алар кайттылар микән, диде. Берсенә кердем — кайтмаган, ләкин өйдәгеләрнең исе дә китми. Икенчеләренә керим дип чыксам, кайтып килүче Җәүдәтне күреп сөендем.

Башта мин аны орышырга керештем. Күземне ачыбрак карасам, ни күрим: күлмәге, чалбары шау пычрак, бөтәрләнеп беткән. «Ни булды?» дигән соравым да җавапсыз калды. Бәлки күңелсезлек килеп чыккандыр?! Берәрсе батмаганмы тагын? Ул башын гына селекте.

Әни башта аның исән-сау кайтуына бик сөенде, аннары баласын шундый кыяфәттә күреп хафага төште һәм сораштыра башлады. Җәүдәт елап җибәрде. Көч-хәл белән тынычландырдык та өстәл янына утырттык. Бөтенләй диярлек ашамады. Йокларга яткырдык. Ул йоклаган арада теге малайлардан сораштырыйм дип талпынган идем, әзләре дә юк,— качканнар.

Берничә сәгать йоклап алгач, ул тормышта үз өлешенә тигән беренче көмеш, сабый тормышындагы имтихан турында сөйләде.

Болар өчәүләшеп икенче утрауга тикле кергәннәр. Су анда сай була торган иде, шунлыктан, балалар анда коенырга яраталар иде. Кайту юлында иптәшләреннән берсе, карбыз бакчаларына кадәр барыйк, дигән. Икеләнеп калганнар. Җәүдәт үзеннән өлкәнрәк малайның сүзен тыңлап күнгән. Ә малайларның берсе нык торган һәм өенә кайтып киткән.

Тимер юл аръягында, Урал суының ике ярында да бакчалар тезелеп киткән. Ә шәһәр ягындагы, уң ярдагы бакчаларга җәяүләп егерме минутта барып җитеп була иде. Ике дус шунда юл тоткан. Акчалары, билгеле инде, юк, ә карбыз ашыйсылары килә. Җәүдәтнең иптәш малае Әхмәтнең тәҗрибәсе бар икән. Карбызлы булыр өчен акча булу гына димәгән икән, юл кырыенда ук үсәләр ләбаса! Юлдан егерме-утыз адым гына керәсең дә карбыз өзеп ычкынасың. Шулай итәргә карар кылалар.

Бакчаларның берсенә кереп, үзләре күтәрердәй буй-буй ике карбыз өзеп йөгерәбез дигәндә, аллә каян гына килеп чыккан бер ир боларга йодрык күрсәтеп янаган. Малайлар бер читтәнрәк табан ялтыратмакчылар икән дә, юк шул: теге сыбызгы сызгырткан! Шалашларыннан йөгерешеп чыккан каравылчылар малайларның кайту юлын «бикләгәннәр». Карбыз каракларына бакчалар эчкәресенә йөгерүдән гайре чара калмаган. Мәгәр андагылар да искәреп алып, эт өстергәннәр. Елгага таба егыла-тора чапканда, Әхмәтне эт эләктергән. Малай акырып җиргә ауган. Җәүдәт шуннан артыгын күрмәгән. Елганың текә ярыннан тәгәрәп төшеп, су кырыенда артына әйләнеп караса: куа килүчеләр яр читенә килеп җиткәннәр, ә этләре аска ыргылырга тора. Җәүдәт суга ташланган. Сай җирдә бераз барган, тирәнгә җиткәч, чоңгылга эләгеп бата башлаган. Ярдагылар чамалап алганнар: малай үләчәк! Шунда егетләрнең берсе йөгереп барып суга кергән һәм, менә-менә су төбенә китәм дигәндә, энемне тартып чыгарган. Ярда һушына килгән...

Өйдә Җәүдәткә нык эләкте: орыштылар, әти озаклап вәгазь укыды. Әти әйткәннәрне энекәш гомерлегенә истә калдырды. Ансыз да үзе кылган яраксыз гамәлне һичкайчан онытмас иде инде ул...

* * *

Казан. 1926 ел. 5 июнь. Җәүдәт (аңа унбиш яшь), мәктәптә имтихан көннәре булуга карамастан, көндәлеген кулга алырга вакыт тапты һәм болай дип язып куйды:

«Ялгызым гына калгач, хыялланырга яратам, образларны, вакыйга һәм эпизодларны музыкада чагылдырырга тырышам».

Музыка язар өчен беренче сюжетны ул үзе уйлап чыгарды һәм шуңа музыка иҗат итмәк булды. Сюжеты бик гади, ләкин гадәти түгел иде. Ул Зәңгәр дингез ярындагы ике гашыйкны — бер-берсен чамасыз сөйгән егет белән кызны күз алдына китергән. Яшьләр гомергә бер-берсенеке булырга вәгъдәләшкәннәр, тик ата-аналары моңа каршы килгән. Гашыйклар Каһирәгә качып китәләр. Дөягә атланып, ком чүле буйлап бик озак баралар (хәрәкәт ритмын ул музыкада күрсәтә). Кәрван көтмәгәндә бинһая көчле булып күтәрелгән ком өермәсе эчендә кала. Котылыр чама юк, алар һәлак булалар. Байтак вакыт үткәч, давыл тына, елмаеп кояш чыга. Талгын җил барганнардан комны куа, шунда кочаклашып үлгән егет белән кызның гәүдәләре күренә...

Тиешле хәзерлексез иҗат уңышсыз тәмамлана. Җәүдәт шунда нык ип аңлады: иҗат итәр өчен төгәлләнгән музыкаль белем кирәк. Икенче нәтиҗә дә аның өчен гаять мөһим иде: гадидән катлаулыга барырга кирәк. Шуларны төшенгәнгә күрә дә, әнем үзенең музыкаль иҗатын җырлар язудан башлады. Вокаль әсәрләр язып, ул озак еллар буена үзенең осталыгын арттырды.

...Казандагы 2 нче мәктәптә, Җәүдәт белән бер класста астрономия профессоры Дюковның улы — Арсентий Дюков укый иде. Җәүдәт һәм аның классташлары еш кына шушы галим сөйләгәннәрне тыңлыйлар иде. Бу хәл аларның астрономия белән кызыксынуларына сәбәп булды. Май аеның икенче яртысында профессор Дюков чыгарылыш класс укучыларын обсерваториягә чакырды. Яшьләр бик теләп бардылар. Майның җылы матур кичендә шәһәрдән читкә чыгу алар хәтеренә сеңеп калды.

Профессор Дюков укучыларны бик ачык каршылаган, бер аудиториягә чакырып, обсерваториянең төзелү тарихын сөйләгән, анда эшләгән галимнәр хакында сүз алып барган. Экскурсиядән соң егетләр һәм кызлар караңгы төшкәнчегә кадәр урманда ял иткәннәр, күңел ачканнар. Айны һәм йолдызларны телескоптан караганнар. Ә аннары арып-талып, ике бинада әзерләп куелган урыннарга кайтып ятканнар. Яткач та тиз генә йокыга китә алмаганнар. Җәүдәтне дә йокы алмаган. Ул бакчага чыккан һәм рояль уйнаган тавыш килгән якка киткән. Профессор өенең террасага чыга торган ишеге ачык калган икән. Музыка әнә шуннан агылган. Җәүдәт, терраса култыксасына таянып, музыка тыңлый башлаган. Көтмәгәндә Арсентий чыгып, аны күреп алган һәм: «Нигә монда торасың, Джон? (Классташлары яратып Җәүдәткә шулай эндәшүчән булганнар.) Әйдә, өйгә керәбез!» дигән. Әнем тартынып-оялып кына өйгә кергән. Рояльдә бер кыз уйный, ә профессор бер читтәге креслода уйланып утыра икән. Ул керүчеләргә игътибар да бирмәгән. Җәүдәтне бөкре кыз уйнаган «Ай сонатасы» әсир иткән. Ул үзенең хыялында бу сонатаны иҗат итүгә этәргән күренешне тудырган.

...Теге ерак замандагы айлы бер төндә, концерттан кайтып барганда, Бетховен, үзенең әсәрен клавесинда бик матур итеп уйнаганнарын ишетеп, бакча ягындагы ачык тәрәзә каршысына килеп туктый. Музыка авазлары тынгач, ул башкаручыны күрергә тели. Үзендә кыюлык табып, йортның ишеген шакый. Клавесинда уйнаучы сукыр кызны күргәч, ул тетрәнеп кала. Өйгә кайтуга, композитор менә инде гасыр ярымнан артык тыңлаучыларны сокландыра торган «Ай сонатасы»н яза.

Профессор йортындагылар үз бүлмәләренә соң гына таралышалар. Бөтен йортларда ут сүнә. Тирә-юнь тып-тын. Җәүдәт классташының бүлмәсендә йокыга китә алмый ята. Гүзәл кичтә күргәннәре һәм ишеткәннәре кат-кат уеннан кичерә. Ачык тәрәзәдән кергән сирень чәчкәләренең исе дә аны үзенчә җилкендерә. Йокысы борчулы була аның бу төндә...

* * *

1928 ел 3 апрель көнне Җәүдәт язучы Гадел Кутуй янына китте. Ул өендә Габдрахман Минский белән ниндидер китап кулъязмасы укып утыра икән. Гадел Кутуй, эшләрен беразга өзеп, Җәүдәтне баласы йоклап яткан кечкенә бүлмәгә алып кергән.

— Мин пьесагызны укып чыктым,— дигән ул аңа.— Беренче-икенче пәрдәләре миңа ошады. Яхшы язылган. Тулаем алганда, сюжеты отышлы. Өченче-дүртенче пәрдәләре комедиядән драмага әйләнгәннәр. Шулай итеп, башы белән ахыры арасында логик бәйләнеш югалган. Пьесаны я драма итәргә, яисә комедия стилен сакларга кирәк. Бу Сезнең беренче әсәрегезме?

— Юк, беренче түгел. Хикәяләр язгаладым, ә пьеса буларак икенчесе,— дип җавап кайтарган Җәүдәт.

— Шулаймыни! Алайса Сез һичшиксез башкарып чыгарсыз. Язу техникагызны камилләштерегез. Күбрәк укыгыз. Бу пьесаны комедия итеп эшләү хәерлерәк булыр дип уйлыйм. Моның өчен Мифтах белән Хәйрулланы Закир ахмакка калдырырга тиеш...

Кайтыр алдыннан Кутуй аңа янә мондый киңәшен бирә: «Сез минем фикеремә риза икәнсез, тоткарлыксыз үзгәртеп эшләгез. Җәен мин бик мәшгуль булачакмын».

Кайту юлында Җәүдәт «Алты бармак» исемле пьесасын ничегрәк үзгәртергә дип уйлый. Гадел Кутуйга баруыннан канәгать булып кала. Киңәшләре кыйммәтле, конкрет. Ихластан сөйләшүче бу кешелекле затка аның ихтирамы тагын да арта төшә...

* * *

Җәүдәтләр мәктәбендә, аңардан бер генә класска түбән укучы бик чибәр кызны Җәүдәт яратып йөри. Җария аның уеннан чыкмый, күңеленнән китми. Мәктәптәге түгәрәк дәресләреннән яки кичәләрдән соң ул Җарияне озаткалап та куя. Озаклап сөйләшеп йөриләр. Ниләр турында гына сөйләшмиләр! Бәхәсләшкән, үпкәләшкән, ачуланышкан чаклары да булмый түгел. Әйтик, бер көнне Җәүдәт аны мәктәптәге кичке дәресләрдән соң озата барды. Тын һәм жылы кич. Яшьләр Җарияләр өе янындагы эскәмиядә гәпләшеп утырдылар.

— Син, Җәүдәт, соңгы араларда бик үзгәрдең, ябыктың да хәтта. Аңлашыла, билгеле. Үзеңә бик күпне аласың, барысына да өлгермәкче буласың. Эреләнеп тә мине дә күрмәмешкә салышасың.

— Син ни сөйлисең, Җария? Һич тә алай түгел. Кирәк икән, раслый алам...

— Ничек итеп?

— Мәсәлән, көндәлегемнең сиңа багышланган битләре белән.

— Алайса күрсәт.

— Бер шарт белән.

— Нинди шарт?

— Башта миңа үз фоторәсемеңне бүләк итәсең.

— Бу — мөмкин түгел.

— Ник икән?

— Ник икәнен үзең беләсең.

— Юк, белмим, фото бүләк итүдә бер дә гаеп эш күрмим.

— Ул чагында сорап торасы да түгел.

— Синең белән сөйләшүе читен.

— Сөйләшмә соң, исем китте ди... Әйтәм ич, эреләнеп киттең, дип.

— Син, Җария, аңларга тиешсең, мин сине яратам. Тик моны кычкырып әйтерлек эш кырганым юк әле. Мин үзем дә белмим, конкрет кына ни белән шөгыльләнә башлармын. Әдәбият беләнме, әллә музыка беләнме? Әллә бәлки техника беләндер? Көчемне теге өлкәдә дә, монысында да сынап карыйм. Яхшы пьеса карадым исә, драматург буласым килә. Күптән түгел Кальманның ике опереттасын карадым һәм музыкаль комедия язу теләге туды. Бездә юк бит әле андый жанр. Тургеневның «Язгы сулар» повестен укыдым да повесть һәм роман язасым килеп китте. Мин музыканы шашып яратам, бигрәк тә татар көйләрен, тик мин...

— Нигә танып калдың?

— Белмим, нигә дип бу хакта сөйли башладым соң әле? Син инде бу бик үзенчәлекле булып кылана, үзенә бәя арттырмакчы дип уйлыйсыңдыр.

— Бер дә алай дип уйламыйм... Ләкин көчен төрле якка тараткан кеше максатка омтылучан булмый бит. Минем абыем әйтә, үзеңә бер максат куярга һәм шуңа омтылырга кирәк, ди. Теләктән тыш, талант та булырга тиеш ич әле. Синең талантың бармы соң?

— Белмим. Анысын киләчәк күрсәтер. Минем гади музыкант кына буласым килми, композитор буласым килә. Язучы икән, Галимҗан Ибраһимов кебек язучы...

— Бик күпкә үреләсең. Һавадагы торнага алданып, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырма. Ачуланма, миңа кererгә вакыт.

Моннан соң алар Җария белән бик озак очрашмадылар...

* * *

1928 елның соңгы көннәренең берсендә Җәүдәтнең мәктәптәше Әхәт хезмәт биржасында белдерү күреп кайткан. Горький өлкәсенең Сергач өязендәге татар мәктәпләренә ике укытучы кирәк. Шуннан Җәүдәтне балалар укытырга китәргә дип кодаларга килгән. Кичен Җәүдәт бу хакта әти белән сөйләште, һәм гаилә башлыгы ризалык бирде. Яңа елның икенче көнендә Әхәт Сабитов Сергачка халәрне белешергә китте. Ике көннән әйләнеп кайтты да шартларның ризалашырлык булуын әйтте. Сергачтан 30 километрдагы Иша дигән авылда икесе бер мәктәптә укытачаклар. Унынчы январьдан да соңга калмыйча килеп җитүне шарт иткәннәр.

Алар 8 январьда Сергачка юл тоттылар. Кичен килеп җитеп, Крестьян йортына куна керделәр. Иртәгәсен УОНОга эшкә билгеләнү кәгазе алырга килделәр. Үз гомерендә хезмәт урынына билгеләнүнең беренче шаһиты булган документта болай диелгән:

«Фәйзуллин Җәүдәт Харисовичка.

Өяз халык мәгарифе бүлеге Сезнең Сосновка волостеның Иша авылы мәктәбенә быелның 9 январеннан укытучы булып билгеләнүегезне хәбәр итә, шуны хәбәр итү белән бергә, УОНО эш урыныгызга күрсәтелгән вакытка барып җитәргә тәкъдим итә.

| | | |
|---|---|---|
| 9 январь, | УОНО мөдире | Ломакин |
| 1929 ел. | Эш башкаручы | Трубкина». |

Әмма укытучылар билгеләнгән урыннарына үз вакытында барып җитә алмыйлар. Кичтән Җәүдәт авырып китә. Килешеп яллаган ялчы иртән килеп житсә дә, сәфәр чыгуны кичектерергә туры килә. Әхәт авылдагы фельдшерны чакырта. Медик Җәүдәтнең ангина белән авыруын, кимендә ике-өч көн ятактан тормаска киңәшлеген әйтә.

Уйбере көнне Җәүдәтнең хәле арулана. Шуннан файдаланып ул көндәлеген яза башлый, дәфтәренә бу төбәк кешеләренең гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешләрен терки. Сергачта, шул җөмләдән Крестьян йортында, күргәннәрен һәм ишеткәннәрен сызгалап куя.

Иртәгесен юлга чыгалар. Суык көн була. Туналар-өшиләр. Авылга килеп житкәндә караңгы төшә. Беренче очратканнары шау-гөр килеп чана шуучы бала-чага була. Таныш булмаган кешеләрне урап алгач, балалар сораша башлыйлар: «Театр куярга килдегезме?» — Укытучылар килгәнне белгәч, кәефләре «бик кырыла». Шулай да мөгаллимнәрне мәктәпкә кадәр озатып куялар. Мәктәп мөдире Петр Дмитриевич Макаров әле шунда була. Ул үзенең яңа хезмәттәшләрен ачык йөз белән каршылый һәм аларны авыл Советы председателе янына алып китә.

Беренче төнне Макаров фатирында кичәргә туры килә. Ул 22 яшьлек буйдак, ишелеп бетә язган һәм бүрәнәләре каралып беткән өйдә яши икән. Идән күптән юылмаган, мич ярылып киткән. Кыш бабай бизәкләре белән шыкырдап каткан тәрәзәләр дә күңелгә ямь өстәми. Җиһаз да бик чамалы: агач карават (ул солдат одеялы белән каплап куелган), калдык-постык ризык кисәкләре аунашкан такта өстәл (шунда ук бер өем укучылар дәфтәрләре), эскәмия һәм барлы-юклы савыт-саба куелган шкаф. Хуҗабикә — карт карчык — мич башында ята. Кунаклар килгәч, ул, җылы урыныннан төшеп, самавыр тирәсендә чуала башлый.

Шыксыз күренеш яңа килгәннәргә ямьсез тәэсир итә. Үзләренең бик авыр шартларда эшләргә тиешлекләрен уйлап куялар (ә чынбарлык тагын да кырысрак булып чыга). Казаннан чыгу хәерлегәме дигән шик кузгала, күнегелгән шартлардан кузгалып, эчкәре бер авылга килү дөрес булдымы дигән уй борчый. Алда ниләр генә көтмидер әле аларны!

Дуслар күзгә-күз карашып алалар һәм икесенең дә уйлары күңелле булмавын сизеналәр. Әмма Макаровка карагач, Җәүдәткә үзенең йомшаклыгы өчен оят булып китә. Менә ул гомерен халыкка хезмәткә багышлаган кеше! Үзеннән башка бер генә рус кешесе дә булмаган татар авылында ике ел эшли инде. Татар телен белмәгән хәлдә, бик азга да канәгать булып, балаларга, авыл халкына бар белгәнен бирә. Соңыннан ачыкланганча, ул әле, укытучылыктан тыш, җәмәгать эшләре дә алып бара икән. Алдагы көннәрдә Макаров яшь укытучылар өчен күп тапкырлар намуслылык өлгесе булды, бөтен эшчәнлеге белән үрнәк күрсәтте.

Ашарга утырдылар. Коллегаларын якыннанрак белергә теләп, Макаров байтак сорау бирде.

Икенче көнне фатир эзли башладылар. Авыл Советы башкарма комитетында кичтән үк берничә хуҗалыкны әйткәннәр иде. Берсе дә кулай булып чыкмады. Гаиләләр зур, өстәвенә, бозау да, сарык бәрәннәре, кәҗә бәтиләре дә өйдә. Аерым бүлмә турында уйлыйсы да юк.

Кәефләре кырылып, янә башкарма комитетка кайттылар. Председатель уйга калды. «Минем чамалап торган бер фатирым бар да, хуҗа хатын ризалашырмы?» — ди. Укытучылар белән бергә, олы урамдагы бу йортка үзе дә барып карарга булды. Биек итеп салынган, калай түбәле бу йорт бүтәннәрдән аерылып тора иде. Килеп кергәч үк, чисталык-тәртип күзгә бәрелде. Стеналарга обой ябыштырылган. Бер бүлмә такта белән аерып бүленгән. Караватта чак кына сыярлык тагын бер бүлмә бар. Ишеккә ситсы пәрдә эленгән. Ап-ак итеп агартылган зур мич артында тагын бер караватт күренде. Җиһаз да гади, ләкин бик чиста. Тәрәзәдән январь кояшы карый. Бүлмәдә җанга рәхәт. Председатель килүенең сәбәбен төшендерде. Хатын-кызларның өлкәне генә сөйләште, яше исә пәрдә артына кереп китте. Хуҗабикәнең шиге бер нәрсәдә иде: хатын-кызлар гына яшәгән өйгә ир-ат кертү җайсыз булмасмы? Председатель монда бер генә дә начарлык юклыгына ышандырырга тырышты. Укытучылар — бик кирәк кешеләр, авыл халкының үзе өчен кирәк. Кызы белән дә киңәшкәч, хуҗабикә укытучыларны фатирга кертергә ризалык бирде. Яшьләр, бик канәгать булып, әйберләрен алып килергә дип киттеләр.

Яши башлагач, хуҗалар белән бик кешелекле мөнәсәбәтләр урнашты. Көнкүреш шартларының әйбәтлеге яшь педагогларның уңышлы эшләүләренә бик ярдәм итте.

Беренче дәресенә Җәүдәт унлүртендә керде.

Укучылары аңа кызыксынулы-сораулы караш төбәделәр. Ул үзенең исемен әйтте. Балалар көлеп җибәрделәр.

— Нигә көләсез, укучылар? Мин мәзәк сүз әйттеммени?

— Исемең кызык синең,— диде арадан берсе.

— Ә синең исемең ничек?

— Ибрай.

— Минем исемем — Җәүдәт, синеке Ибрай, дөресе — Ибраһим икән, моның ни кызыгы бар?..

Шулай башланган беренче көн әллә ни кытыршылыксыз гына узып китте.

Ә авыл нинди рәк иде соң?

Горький өлкәсенең Сосновка волостендагы Иша авылында мишәрләр яши. 345 йортта — 1450 кеше. Халыкның культурасы түбән. Диндарлык белән наданлык көчле. Өч мәхәлләдә икешәр хатынлы өч мулла халыкның башын тәмам аңгыралаткан. Үзләре халык җилкәсендә әйттереп яшиләр. Бөтен авылына берничә генә кеше дөньяда электр, телефон, телеграф барын белә. Газета-журнал дигәннәрне авыл Советы яздыра да укытучы алдыра. Атнадагы көн исемнәрен дә дөрес атый белмәүчеләр күп. Базар көн, баш көн, буш көн, чәршәмбе көн, атна кич, атна көн, атна арасы көн — һәм вәссәлам!

Җәүдәт белән Әхәт, жиң сызганып эшкә керешкәч, авыл тормышына күнектеләр. Укучыларның да белем алырга дәртләре өстәлә барды. Дәрескә йөреш күтәрелә торды һәм бер ай дигәндә тотрыклы төс алды. Ә йөрмәүчеләрне һәм күрәләтә тәртип бозучыларны мәктәптән чыгарырга карар иттеләр. Соңгы чарага житкәнче ата-аналар белән кат-кат сөйләшергә булдылар. Әмма нәкъ кирәк кешеләр мәктәпкә килмиләр иде. Аларның укытучылар белән сөйләшәселәре килми иде, күрәсең.

Дәрескә рәтләп йөрмәүче бер кызның әтисе берничә тапкыр чакырткач киләсе итте. «Нигә кызың мәктәпкә юньләп йөрми?» дигән сорауга ул: «Мәктәпсез дә яшәр. Анасы әле укымаган, ничава, кайнаштыра. Мин үзем дә өч кенә класс укыдым, начар яшәмим» дип кенә җибәрде.

— Бу — ир кеше сүзе түгел, иптәш. Хәзер башка замана. Димәк, Сез кызыгызны укудан тыясыз?— Кабыргасы белән куелган бу сорау аны азрак сискәндерде булса кирәк.

— Үзенең йөрисе килми,— диде ул.— Малайлар белән бер партага утырталар, ди. Бу бит бер дә яхшы түгел. Ник алай эшлисең?

Аның белән байтак сөйләшергә туры килде. Саубуллашып китәр алдыннан әйтте шулай да: «Ярар, кыз укырга йөрер. Килештереп сөйләшмәгән булсам, бигайбә».

Мәктәптә эш күбәйде дә, көйләнә дә барды. Дүрт-биш сәгать дәрес бирү өстенә, эш кәгазьләре тәртипкә китерелде, методик эшләнмәләр зарурлыгы сизелгәч, аларны хәл-хәленчә җайга салу башланды. Макаров үзе дә җигелеп эшләде, яшь укытучылардан да һәр нәрсәне җиренә җиткереп үтәүне таләп итте. Җәмәгать эшләре дә вакытны күп ала килде. Советларга сайлаулар уңае белән мәшәкатьләр бермә-бер артты.

В. И. Ленинның үлүенә биш ел тулу көнендә матәм көне уздырырга карар ителә. Фәйзуллин үз классын хәзерли. Һәр укучы диярлек юлбашчы турында, аның үлемсез эшләре хакында шигырь ятлый (шигырьләрнең кайберләрен Җәүдәт үзе яза).

Укытуның беренче көннәреннән үк җыр дәресләре гамәлгә кертелә. Югыйсә бит әйтүе сәер: бу авылда татар көйләрен бөтенләй диярлек җырлый белмиләр. Берничә рус җырын татар сүзләре белән җырлаган булалар да, шуның белән эш бетә. Укучылар хор белән җырларга хәзерләнәләр. Бу эштә Җәүдәтнең Казаннан алып килгән скрипкасы бик ярап куя.

Язгы каникуллар җитә. Әхәт бер атнага Казанга китә, ә Җәүдәт авылда кала. Вакыт югалтасы килми. Балалар өчен өч пәрдәлек «Янгылышкан» исемле пьеса яза башлый һәм ликбез курсларын дәвам иттерә. Биш кызның ликбезга йөрүдән туктаулары аны борчый. Ә сәбәбе сер түгел, надан егетләр укырга йөргән кызларны хурлап такмаклар әйтәләр, кимсетәләр. Җитмәсә, карчык-корчык: «Дин сабагы түгел бит, җен сабагы укыйсыз!» дип, колак итен кимерә. Җәүдәт: «Укуны берегез дә ташламыйсыз. Белемгә омтылган өчен хурлаучыларның исемлеге төзелде һәм кирәк урынга озатылды»,— дип белдерә. Укырга-язарга өйрәнергә килгән ирләргә исә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә.

Бу темага уздырылган аңгәмәләр нәтиҗәсез калмый, әлбәттә. Теге затсызлар көннәрнең берендә хәреф танырга йөрүче кызларны тагын хурлап такмакларга керешкәннәр. Ә Җәүдәттән укырга-язарга өйрәнүче егетләр тегеләрне тотып ярганнар. Кайберәүләр «йодрык теле»н генә аңлаучан була бит, төшендереп биргәч, төшенгәннәр, кыскасы. Шуның белән шул, син күр дә мин күр, ликбезны хурлаш тәмам була. Карчыклар да телләрен тешлиләр.

Март азагында көннәр матурлана. 27 март көнне кичен эшләп арыган Җәүдәт һава суларга дип урамга чыга. Ике йорт аша гына капка төбендә авыл егетләре җыелган. Арадан берсе скрипка сызып маташа. Җәүдәт тә алар янына килә, тегеләр моны ачык кабул күрәләр. Моны аңлавы кыен түгел, чөнки аларның байтагы ликбезга йөри. Җәүдәт теге егеттән скрипкасын биреп торуны үтенә һәм «Галиябану» көен дөрес итеп уйнап күрсәтә.

Шуннан соң укытучыны урам әйләнергә чакыралар. Җәүдәт ризалаша, тик үзенең дә шарты барын әйтә. «Җырлап барсагыз, әйләнәбез!» ди.

— Без бит кирәгенчә җырлый белмибез,— диешәләр.

— Белгәнегезчә жырлагыз, ялгышсагыз, мин төзәтермен, тик ачуланыштан булмасын.

Шуннан скрипкачы бу авылда бик таралган «Балахна» көен уйнап жибәрә, егетләр дәррәү жыр башлый:

Егет егетлеген итә,
Ат эчерә буранда;
Йөрәгенә чыдый алмый,
Чыгып китә урамга.
Казан юлы киртләч-киртләч,
Киртләч бетә кар киткәч;

Ир олан кайта хезмәт иткәч,
Кыз олан кайтмый бер киткәч.

Кара урманга керер идем,
Куркам умарта кортыннан;
Кыз балакай, бичаракай
Китә туган йортыннан...

Урам әйләнәләр, жырлыйлар, мәзәк хәлләр сөйләшәләр. Ә күктә йолдызлар калыккач, Жәүдәт Жир, Ай, йолдызлар турында сөйли. Тәмам күшеккәч, укытучыны, рәхмәтләр укып, өенә кадәр озатып куялар. Шул кичтән соң авыл егетләре белән яшь укытучылар арасындагы дуслык тагын да ныгып китә.

Мартның соңгы көнендә авылга шомлы хәбәр килә — Петр Макаровны үтергәннәр! Укучылары һәм авылдашлары алдында абруе зур булуга да карамастан (февраль аенда аны авыл Советына депутат итеп тә сайлаганнар иде), көтмәгәндә генә ул Иша авылыннан китеп барды. УОНО приказы нигезендә мөдирлекне Әхәт Сабитовка тапшырды һәм күрше Тульба авылына күчте. Аны 6 февральдә бөтен мәктәп белән озатканнар иде. 2 апрель көнне үтерелгәнлеге төгәл ачыкланды. Ник үтергәннәр, кем үтергән — һичкем белгесез иде. Кайберәүләр генә сөйләштергәләделәр, Иша авылыннан да бит ул кулаклар кат-кат янаганга күрә китте, диделәр.

Жәүдәт коллегасының үлемен бик авыр кичерде һәм берничә көн буена рухы белән якын кешесен югалту тойгысыннан арына алмый йөрде. Мәлҗерәп калмас өчен эшкә тагын да ныграк җигелде. Бу көннәрдә кооперативны яңадан сайлау бара иде. Бу чара бик кискен сыйнфый көрәш шартларында үткәрелде. Жәүдәт бу эшләрдән читтә тормый, сайлау жыелышында зур активлык күрсәтә. Ә жыелыш ике көн (!) дәвам итә. Жыелышта берничә янау да ишетә хәтта.

Кинәт кенә суытып жибәрде, көчле жил чыкты, жәяүле буран купты. Авыл урамнары буп-буш. Шундый чакта мәктәптән кайтып килгәндә ул кемнеңдер сагалап баруын тойган сыман булды. Сагаю, рухи изелү хисе өйдә дә җыелмады. Тәрәзә буенда кемдер йөри һәм менә-менә мылтык атуы ишетелер кебек тоела. Билгесез шартларда һәлак булган иптәшенең хатирәсе бик яңа чак иде шул. Дәресләргә бармый калмады, тик язу эше белән шөгыльләнә алмады. Ликбезда эшен бермә-бер көчәйтте. Хәреф өйрәтү белән генә чикләнергә ярамый иде, төрле темаларга әңгәмәләр үткәрә башлады. Агымдагы политик тормыш беренче чиратта иде, ләкин бер темага сүз башлап та икенче, өченче... унычы темага күчкән кичләр дә еш була торды. Кичләрнең берендә җеннең юклыгын раслап сөйләргә туры килде аңа: «Бу — кешеләр уйлап чыгарган нәрсә яки авыру акыл җимеше», дип төшендерде ул, ләкин тиз генә килешергә теләмәүчеләр дә бар иде. Хәтта «мисаллар» китерә башладылар: фәлән кеше фәлән төштә фәлән вакытта үз күзе белән күргән, янәсе. Ул кеше бик абруйлы кеше, буш сүз сөйләми, аңа ышанмаска мөмкин түгел... Садыйк хәзрәт тә җен бар дип әйтеп тора. Бер төртке теле Тукайны да үзенә терәк итмәк булып маташты, янәсе, шагыйрь «Шүрәле»не чынбарлыктан алып язган...

— Соң син, мөгаллим, җеннең юклыгын нәрсә белән исбатлый аласың? Әнә шүрәле мич артында утырып, без сөйләшкәнне тыңлый...

Һәммәсе дә мич ягына башларын боралар.

— Нәрсә белән исбатлый аламмы? Моның мин наданлык җимеше һәм күп нәрсәне аңлап җитмәү нәтиҗәсе икәнен икенче бер вакытта исбатлармын.

Кайтканда ул ничегрәк итеп тәэсир итү, күңелгә кертү көченең зур фактор икәнлеген аңлату турында уйлап кайта.

Кичке аштан соң ул үзенең гипнозлау көчен сынап карарга була. Әхәттән үзе белән тәҗрибә үткәрергә ризалашуын сорый. Әхәт көлә-көлә рөхсәт бирә, чөнки Жәүдәтнең мондый көчкә ия икәнлегенә ышанмый. Жәүдәт аны үтә җитди булырга өнди, күзләрен йомарга, елмаймаска, бүтән уйлардан арынырга куша, бары тик үзен генә тыңлавын сорый. Ун минутлар чамасы вакыт үткәч, Әхәт йокыга китә һәм гипнозчы кушканнарның һәммәсен үти. Урындык кочаклап йөри, җырлый. Бишкә кадәр санагач, уяна.

Әхәт үзенең кеше ышандыруы көченә шул тикле бирелүенә гаҗәпләнде. Жәүдәт исә үзенең ышандыра алу көченә сөенде, бу тәҗрибәне өлкән укучылары белән дә ясап карарга мөмкин дигән карарга килде һәм төнлә тыныч йоклады.

Ике көннән соң ул егермеләп кеше каршында дүрт кешегә тәэсир итеп карады, аларны төрле хәрәкәтләр ясарга мәҗбүр итте. Берсенә, уң кулың агач булып каткан, бөгелми, дип раслады. Чыннан да, сеанста катнашучылардан ике кеше бөгеп карасалар да кул бөгелмәде. Ничәгәдер тикле санагач, кул гадәти халенә кайтты һәм егет үзе дә уянды. Аның бу осталыгы бөтенесен дә хәйран итте. Авылныкылар Жәүдәткә: «Синдә сихер көче бардыр, я тылсым көчедер!» — диделәр.

Иртәгесен ликбез дәресенә йөрергә тиешлеләрнең һәммәсе дә килгән иде. Класста хәтта исемлеккә теркәлмәгән кешеләр дә бар иде. Дәрес башлангач, егетләрнең кайсыдыр әйтә куйды: «Мөгаллим! Безнең берәребезне йоклатсаң, без җен юклыгына ышаныр идек».

— Һәр нәрсәнең үз вакыты, дәресне өзмибез,— диде Җәүдәт.— Өйгә биргән эшләрне әйбәт башкарып килгән булсагыз, бәлки гипноз сеансын да кабатларбыз.

Дәрестән соң осталыгын янә күрсәтергә туры килде. Шул кадәресен әйтергә кирәк, ул моны бик теләп эшләмәде. Ник дигәндә, нык йончыган һәм үз көченә ышанычы кимегән иде. Шулай да ул теләге булган берәүне чакырып алды һәм сеансны башлады. Пыш-пыш сөйләшүләр, тын гына утыра белмәү аңа бик комачау итә иде. Барчасының тынып калуларын сорады. Кырыкка кадәр санагач, үз ихтыяры белән килеп утырган егет йоклап китте, аннары укытучы кушканнарның һәммәсен үти башлады.

Бу көнне ул, ару-талуына карамастан, дөньяга фәнни караш тәрбияләү юлында кечкенә генә булса да янә бер адым ясарга теләп, авыл егетләре белән озак гәпләште.

Җәүдәтнең дингә ышанмаска өндәүләре, алланы юк дип раславы авыл халкын салкын суга тотып чумыргандай хәлгә куйды. Алар яши торган йортка сөт аертырга килеп йөрүче хатыннар гына түгел, укытучыларны бик олылап торган фатир хуҗалары Гайшә апа белән кызы Хәтимә дә егетләргә эндәшмәс булдылар. Аңлашылса кирәк, мондый хәлдән Җәүдәт боегып калды. Тик укучылары мәктәпкә кабат килә башлагач кына, аз-маз тынычланды. Ә тегеләренә, борын асларны да кибеп җитмәгән наяннарга, хәреф танудан, җөмләләр төзүдән, хисап эшләүдән битәр укытучы абыйларының «күз бууы» кирәк. Гипноз сеансы ясавын сорап ялвардылар. Аларга җавабында Җәүдәт ярым шаярып кына:

— Бөтен классыгыз белән гипнозласам, ризамы соң сез?— дигән иде, балалар бик тиз күнделәр.

— Алайса тып-тын утырыгыз,— диде Җәүдәт абыйлары.— Кулларыгызны парта өстенә куегыз. Селкенмәгез. Миңа текәлеп карагыз да мин әйткәннәрне генә тыңлагыз, фәкать мине генә! Бүтән нәрсә турында уйламагыз! Ишетәсезме?

Берничә минуттан, ике малайдан кала, барысы да йоклыйлар һәм укытучы кушканча шигырь сөйлиләр, күмәк җыр башкаралар, класслары белән «очалар», ягъни кулларын болгап, очкан шикелле хәрәкәтләр ясыйлар иде. Гипнозга бирелми калган ике малай бу тамашаны куркынып күзәтеп тордылар һәм укытучы барысын да йокыларыннан уяткач, тегеләр гипнозланмаган малайлар сөйләгәннәрне гаҗәпләнеп тыңладылар, аннары акрын гына өйләренә таралыштылар. Җәүдәт исә үзендәге гипноз көченә ныграк ышанды.

Апрель уртасы авышкач, укытучылар фатирда торган йорт янындагы җир бүтән төшләргә караганда иртәрәк кипте. Калкулыктарак булгандыр, күрәсең. Бала-чага шунда кузна уйный башлады. Җир тиз кибүне дә Җәүдәттәге «илаһи» көчкә бәйләп карарга тырышучылар табылды. Инде яшь укытучы гипноз көчен күрсәтүенә үзе дә үкенә иде, чөнки аның хакында тузга язмаганнарны сөйли башладылар. Кызлар гына түгел, яшь яшәгән хатыннар да аның күзенә карамаска тырышалар иде.

Мондый мөнәсәбәттән соң укытучы егет «күз буу»дан тыелып торды. Шулай да теше сызлап килүчеләргә булышкалады. Бу хактагы хәбәр дә тирә-юнь авылларга кадәр тиз арада таралып өлгерде. Ат җигеп аның хозурына киләләр һәм газаплардан йолуын гозерлиләр иде. Һәрчак теләгенә ирешә алмаса да, укытучы Җәүдәт Фәйзуллин андыйларны борып җибәрмәде.

Май бәйрәмен мәктәптә оешкан төстә уздырдылар. Әле беркайчан да болай әйбәт узганы юк иде, диештеләр. Укытучылар конференциясендә уку һәм җәмәгать эшләре чараларын үткәрүдә Иша авылы мәктәбен үрнәк итеп телгә алдылар.

Бәйрәм алдыннан Җәүдәт өч пәрдәле «Яңгылыштык» пьесасын язып тәмамлады. Бу әсәрендә ул совет мәктәбенең бурычларын, яшьләрне социалистик тәрбияләүдә комсомолның ролен, нэпманнар каршылыгын күрсәтергә теләгән иде. Пьесасын беренче тыңлаган кешеләр фатир хуҗасы Гайшә апа, аның кызы Хәтимә һәм күрше Сәйфи булдылар. Алар Җәүдәтнең укуын бирелеп, кызыксынып тыңладылар, бәяләрен бик саран гына сүзләр белән «яхшы... кызык» дип кенә белдерделәр, ләкин пьесаның Җәүдәтнеке булуына барыбер ышанмадылар.

Уку елын тәмамлап, авылдан китәр көн якынлашты. Гайшә апа да, бигрәк тә Хәтимә, фатирчыларының китүенә бик күңелсезләнделәр. Хуҗалар белән дә, таныш-белешләр белән дә җылы хушлашып, егетләр Казанга кайтып киттеләр.

* * *

Өйдә Җәүдәтне каршылаучы булмаган. Баксаң-торсаң, Шәүкәттән башка кеше дә юк икән. Әти-әни Идел буйлап түбәнгә киткәннәр иде, минем дә өйдә юк чак. Моңсуланып калган Җәүдәт иртәгәсен үк икмәк юнәтү хәстәренә керешкән (ипи карточкага бирелә иде). Күңеленә хуш килгәне шул гына: Мидхәт абыйсы өйгә телефон куйдырган! Егетнең Казанга кайтып ирешүен ишеткән кешеләр 18-15 номерын җыеп сәламлиләр, тәбриклиләр икән...

Җәен хәзерләнеп, керү имтиханнары тоткач, августның соңгы көннәрендә Җәүдәтнең Совет хокукы институтына (соңыннан юридик институт) кабул ителгәнлеге мәгълүм булды. Егет хәтта беркадәр көтелмәгәнрәк тә халдә калды. Әти исә моны бик кулай күрде, юридик белем алуның кеше алдында киң офыклар ачачагын әйтте. Нур өстенә нур дигәндәй, шул көннәрдә үк минем дә университетның медицина факультетына кабул ителүем мәгълүм булгач, гаиләдәгеләрнең кәефе күтәрелде. Әтинең улларыма югары белем бирим дип тырышып йөрүе гамәлгә ашуының башы иде бу.

Укулар башланды. Җәүдәт 2 сентябрьдә «Хокук һәм дәүләт турында гомуми тәгълимат» дигән кереш лекцияне тыңлады. Берничә көннән ул бу факультеттагы лекцияләрне бик яратуын әйтте.

Җария Казанда иде, ләкин Җәүдәт аны күрим дип ашыкмады. Берничә көннән соң кыз, телефоннан шылтыратып, безнең өйдән ерак түгел генә җирдә булуын әйтте. Җәүдәт аны өйгә чакырды. Җария бездә берничә сәгать булды. Әмма шуннан соң аларның очрашулары яңармады.

Сентябрьнең 28 ендә кичен ул Булатовларда булды (Фуат Булатов — соңыннан Германиядә фашистларга каршы көрәшкән Муса Җәлилнең иптәшләреннән берсе). Аларда Җәүдәт Оренбургтан килгән берничә кеше белән очрашкан. Балачак елларын искә алганнар, музыка уйнаганнар, аннары Җәүдәт авылда үзенең укучыларын һәм өлкәннәрне гипнозлавын сөйләгән.

Мәҗлестәшләре, әлбәттә, моңа бик үк ышанырга теләмәгәннәр. Бигрәк тә Фуат ышанасы итмәгән.

— Теләсәң, хәзер үзеңне гипнозлыйм,— дигән Җәүдәт.

— Карап кара, кулыңнан килсә...

Карап караган Җәүдәт. Фуатны йоклаткан, әкәмәт манипуляцияләр ясаган. Аннары берәм-берәм тагын ике егетне йокыга талдырган.

Бу хәлләрдән берничә көн генә элегрәк, «Мәгариф» журналы редакциясенә кереп, Җәүдәт үзенең «Авыл укытучысы көндәлегеннән» дигән повестеның басылачак әсәрләр исемлегендә икәнен белеп чыккан иде (повесть басылмый калды). Икенче көнне ул нәшриятка үзенең «Янгылышты» пьесасын тапшырды, ләкин аны матбугатка тәкъдим итмәгәннәр, чөнки Фәтхи Бурнаш тискәре бәя биргән иде.

13 октябрьдә Җәүдәт Фәйзуллин Мәдәният йортында Габдрахман Минский белән очрашты. Язучы аның «Алты бармаклы» дигән пьесасын укыган һәм фикер әйткән иде. Җәүдәт аның киңәшләрен тотып, әсәрне төзәтеп эшләде һәм пьеса басылып та чыкты.

* * *

1930 ел азагында Җәүдәт Фәйзуллинны суд эшләре белән Мамадышка җибәрәләр. 1931 елны ул шул төбәктә дусларсыз һәм танышларсыз каршылый. Күп көннәрен район авылларында үткәрә.

26 март көнне, әйтик, пианинода уйнап ял итәрмен, иптәшләрне күреп сөйләшермен дигән уй белән, район үзәгенә кайта. Аңа клубта киңәшмә уздырылуын әйтәләр. Димәк, аның элекке иптәшләре дә анда. Җәүдәт туп-туры клубка юл тота. Аны шатланып каршылыйлар. Сөйләшә торгач, судья К. ны Казанга чакыртып алуларын белә. Яңа судья билгеләнгән икән дә, вазифаларын үтәп җиткерә алмаганлыктан, китәргә җыена, ди. Район Советы башкарма комитеты председателе һәм прокурор Җәүдәтнең судья булып эшләп торуын сорыйлар. Җәүдәт үзенең Актаныш районына командировкага җибәрелгәнлеген аңлата. Шуннан соң Мамадыштан Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына Җәүдәт Харис улы Фәйзуллинны Мамадыш районы җитәкчелеге карамагына командировать итүне сорап телеграмма сугалар.

Райбашкарма председателе Җәүдәткә: «Сез студент кебек киенгәнсез, ә судья күрер күзгә үк күркәм булырга тиеш», ди һәм район сәүдә идарәсенә шылтыратып, аңа костюм таманлауларын сорый. Уена да китермәгән җиреннән Җәүдәт әйбәт кенә костюмлы була һәм шаярып: «Мин, иптәшләр, кая килгәнемне белеп килдем»,— ди...

Менә ул халык судьясы вазифаларын үти башлый. Суд утырышларын урыннарда уздыру өчен еш кына авылларга чыга. Бер-бер артлы төрле мәсьәләләргә кагылган эреле-ваклы эш карарга һәм хөкем карарлары чыгарырга туры килә.

Эш шартлары, бигрәк тә транспорт мәсьәләсе авыр була. Юл өзегендә, апрель уртасында, бер авылдан район үзәгенә кайтканда балагә тарыганлыгын Җәүдәт Фәйзи озак вакытлар буена хәтерендә саклады.

Җәен суы бөтенләй кибеп-корып кала торган, мәгәр ул елларда язлыкта гайрәтләнгән (җирләр туңга сөрелми, кар суы тулысынча иңкүлеккә ага иде) кечкенә бер елганы кичкәндә, җигүле ат бата иза һәм куркудан чыгымчылап, тәртәләрне сындыра. Олаучы да, район судьясы да билдән югары су эчендә калалар. Дөрес, үзләре дә котылалар, атны да коткаралар, тик... арба елгада кала.

Бичарадан ни чара дигәндәй, олаучы атын җитәкләп үз авылына кайтып китә, ә Җәүдәт суд кәгазьләре белән дыңгычлап тутырылган ике портфелен һәм юл кирәкяраклары салынган саквояжын күтәреп, Мамадышка таба тәпиләргә мәҗбүр була. Җәяү атлавы да, йөге авырлыгы да бер хәл, аңа бит озак тукталып хәл алырга да яра-

мый киемнәре манма су. Ә язгы суык бәгырьгә төшүчән. Җелеккә үтә. Туңып үлмәс өчен үҗәтләнеп, өзек-төтек юлдан берничә чакрым титаклый торгач, алда авыл күренә. Бердәнбер чара булып шул авылда төн кичү кала.

Куныл чыккач та, юлын җәяүләп дәвам итә. Әллә җигәр атлары булмый, әллә юллардан барыр әмәл таба алмыйлар. Судьяны район үзәгенә озатыша барырга дип бер егетне генә билгелиләр. Егерме чакрымлап араны мең газап белән узалар. Шундый хәлләрдән иза чиккән Җәүдәт көндәлек дәфтәргә: «Эшләр күп. Юл да юк, чурт та юк. Эшлибез дә эшлибез», дип теркәп куя.

Телеграмма белән Казанга кайтырга чакырылгач та, юлсызлык аркасында, шактый тоткарлана әле ул. Навигация ачылуны көтә. Аннары Вятка, Кама, Идел буйлап республикабыз башкаласына кайтып ирешә. Сагынып, зарыгып кайта.

Казан, нурлы Казан аны шау-гөрле, күп кешеле урамнары белән каршылый. Майның кояшлы көннәрендә тарихи кала аерата матур һәм мәһабәт була. «6» саны язылган трамвайны күреп, Җәүдәт бик сөенә. Димәк, тагын яңа маршрут ачылган дигән сүз!..

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:** Ибраһим ага, Сез күп еллар бу тарихи жанр өлкәсендә эшләп киләсез. Әйтегез әле, тарихи-биографик роман яисә повестьта уйлап чыгару, фәнчә әйтсәк, сәнгатьчә уйланма нинди урын тота? Сорауны икенче төрлерәк куйыйк: язучының хыялы ни дәрәҗәдә ирекле?

**Ибраһим Нуруллин,** филология фәннәре докторы, профессор: Сәнгатьчә уйланмадан башка тарихи-биографик роман юк һәм була да алмый. Чөнки язучы үзенең героен, «терелтеп», укучы күз алдында яшәтергә, замандашлары чолганышында һәм вакыйгалар тезмәсендә сәхнәдәгедәй итеп күрсәтергә тиеш. Ә бит ул, тарихи шәхеснең һәр сүзен, һәр гамәлен теркәп баручы секретаре булмаган кебек, магнитофон тотып, артыннан да йөрмәгән. Димәк, җанлы картина тудыруга хезмәт итә торган детальләрне, күп кенә эпизод, вакыйга һәм кайбер шәхес-персонажларны автор уйлап чыгарырга тиеш була.

Әмма ике шарты бар.

Берсе — сәнгатьчә уйланма төп геройның гадәт-холкы һәм дөньяга карашы белән туры килсен, деталь, эпизод һәм уйланма персонажлар ихтималлык кысасыннан читкә чыкмасын.

Икенчесе — сәнгатьчә уйланма билгеле фактлар һәм фән тарафыннан исбат ителгән хакыйкать белән каршылыкка кермәсен.

Бер генә мисал. Ә. Фәйзинең «Тукай» романында К. Насыйри кечкенә Тукайга карандаш төпчеге бүләк итә. Бу эпизод үзен аклый, ул ихтималлык кысасында. Әгәр әдип үсеп җиткән Тукайны К. Насыйри белән очраштырса, бусы тарихи дөреслекне бозу булыр иде.

Дөрес, Көнбатышта аралары гасырлар һәм континентлар белән бүленгән бөек шәхесләрне очраштырып язылган «тарихи» әсәрләр дә дөньяга чыккалый. Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, үзебездә дә түбәндәгечә фикер йөртүчеләр очраштыргалый башлады: әдәби әсәр фән түгел, язучы тарихи шәхесне үзе теләгәнчә күрсәтергә хаклы.

Сүз реалистик тарихи әсәр турында бара икән, монда иҗади башбаштаклыкка урын юк. Укучыны бер генә тапкыр алда, ул инде синең дөресеңә дә ышанмаячак.

# КОЯШЛЫ ШИГЪРИЯТ

Бабичлар — Урал якларында элек-электән билгеле нәселләрнең берсе. Аларның туган җирләре — Агыйдел буена урнашкан, куе урманнар белән уратып алынган Кыйгазытамак авылы. Чыгышы белән бу нәсел Казан арты татарларына барып тоташа.

Нәсел атасы — Мохтар баба Казаннан күчеп килгән кеше. Анда ул ниндидер бер мануфактура яисә мастерской тотып, бөлепме, сәүдә эшләре беләнме, Агыйдел буйларына килеп чыккан һәм шунда төпләнеп калган.

Мохтар баба хәлле генә кешеләрдән була. Ул үз улларына кечкенәдән төпле белем, һөнәр бирү ягын карый. Аның биш малае да (шәҗәрәдә кызлары хакында берничә мәгълүмат та юк) тирә-якта билгеле кешеләр булып җитешәләр[1].

Шәехзадә Бабич 1895 елның 15(2) гыйнварында Бөре өязе Әсән авылында Мөхәммәтзакир мулла гаиләсендә туган. Йорттагы төп хуҗалык эшләрен кызлары белән хәзрәт үзе алып барганлыктан, Шәехзадә кечкенәдән иркенлектә, кыенлык күрмичә үскән. Аның бөтен шөгыле җыр-бәет чыгару, бакчаларындагы иң биек өянкегә эленгән бишектә такмак сөйләп, җырлап яту, кәмит күрсәтү, «театр» кую. Уку яшенә җиткәч, малай әтисенең җәдит мәдрәсәсендә укый башлый. Шунда ул Бабичларның зур китапханәсен ачып керә, шунда чын шигърият белән таныша, аеруча татар халык шагыйре Г. Тукай иҗатын яратып күңеленә сала.

1908 елда абыйсы Фәтхелкадирга ияртеп, Мөхәммәтзакир мулла Шәехзадәне Кыйгазытамак авылы мәдрәсәсенә мөгаллим-хәлфә итеп җибәрә. Шунда бер ел укытып кайтканнан соң, үсмер егетнең карары үзгәрә — аның күңеле ераграк офыкларга омтыла, киңрәк дөнья таләп итә. 1910 елның җәй айларында Бабич казах далаларында хәлфәлек итеп йөри. Аның көндәлекләреннән шул билгеле: беренче баруында булачак шагыйрь Кустанай өлкәсенең Тургай тирәсендәге Дүсәнбай авылында балалар укыта. Казах далаларында «мүлдәкәлек» итәргә Бабич тагын 1913 елның җәй айларында чыга. Шәехзадә бу сәяхәтеннән яңа бер шигъри дөнья алып кайта. Ул — Абай иҗаты. «Мин Кунанбайның өләңендә фәсахәт, матурлык вә ләззәт табып, аны татарның Тукае, гарәпнең Имрелкайсе дәрәҗәсенә мендердем», — дип яза ул соңрак[2]. Тукай, Абай иҗатлары аша булачак шагыйрьгә рус әдәбиятына да тәрәзә ачыла. Ул Лермонтов әсәрләрен аеруча яратып укый, ятлап йөри.

1911 елда Ш. Бабич, Уфага килеп, төрки-татар дөньясында билгеле «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Ул беренче сыйныфта укыганда ук үзенең шигырьләр җыентыгын әзерли, аңа «Әйтеп узыйм» дигән сүз башы яза. Әмма, билгесез сәбәпләр аркасында, бу китап чыкмый кала.

1912—1913 елларда Бабич халык иҗаты белән кызыксынып китә. Тукайның «Халык әдәбияты»н тырышып өйрәнә. Хәтта 1913 елда Троицкида чыгып килә торган «Акмулла» журналының берничә санында «Мәкальләр фәлсәфәсе» исеме астында мәкаләләр циклы да бастырырга өлгерә. «Галия» шәкерте бу тикшеренүләрен мәкальләрнең «мәгънәләрен, тәрбияләрен, фәлсәфәләрен» ачыклауга багышлый[3]. Шул ук чорда ул мавыгып татар, башкорт халык көйләренең тарихын яза[4].

1913 елларда Бабичның исеме «Шура» (Оренбург) журналында күренә башлый. Ләкин ул монда фольклорчы булып түгел, шагыйрь буларак чыгыш ясый.

Шәехзадә бик тиз арада «Галия»дә иң билгеле шәкертләренең берсенә әверелә. Бабич бу елларда мәдрәсәдәге «Парлакъ» исемле кульъязма әдәби журналның мөхәр-

[1] Бабичлар нәселе кешеләрендә Мохтар баба һәм аның улларыннан башланып киткән тулы шәҗәрә сакланган.
[2] Бабич Ш. Сайланма әсәрләр (Х. Госман сүз башы). — Казан, 1958, 8 бит.
[3] «Акмулла» журналы, 1913, 30 сан, 11 б.
[4] Кара: Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы (VIII бүлек). Казан, 1922.

рире була (үзе киткәч, шагыйрь журналны Г. Нигъмәти кулына тапшыра), «Милли көй, сәхнә вә әдәбият» түгәрәгендә актив катнаша, үзе дә яшерен әдәби түгәрәк оештыра (Х. Туфан беренче иҗат адымнарын шунда ясый), мәдрәсәнең кыллы оркестрында беренче мандолиначы була. Җитмәсә, ул мондагы әдәби-музыкаль кичәләрне оештыручыларның, мәдрәсә идарәсенә җибәрелә торган делегация әгъзаларының иң активына, башлыгына әверелә.

Озакламый Бабичның эшчәнлеге мәдрәсә күләменә генә сыймый башлый. «Дворяннар сарае»нда һәм башка культура учакларында уздырыла торган кичәләрнең 1914 елның көзеннән алып барысында да диярлек Ш. Бабич даими катнашып бара. Ул үзенең шигырьләрен укый, конферансье вазифасын үти, хәтта спектакльләрдә рольләр дә башкара. Мәсәлән, аның 1916 елда Уфага килгән Г. Кариев белән берлектә берничә спектакль куюы билгеле. Соңрак Бабич үз концертларын җырчы Газиз Әлмөхәммәдов белән бергә оештыра башлый. Аларның шундый бер концерт программасы белән Мәскәүгә барырга җыенулары хакында да истәлекләр бар.

Татар, башкорт сәхнә сәнгатен үстерүдә Бабичның роле зур. Ул, төрки-татар дөньясында беренче булып, концерт алып баручылар, артистлар өчен, төрле авторларның әсәрләрен төзеп, «Көлке капчыгы» исемендә җыентык чыгара. Бу китабында Бабич сатираны киңрәк җәмәгатьчелеккә җиткерергә омтылды, аның үтемлерәк чараларын эзләде. «Көлке— диде ул,— кешене рәхәтләндерә, күңелне ача, эч пошуны баса, житди нәрсәләрне тыңларга бөек бер иҗтиһаэ бирә (теләк уята — Г. Г.), ялыккан кешеләрне җиңеләйтеп җибәрә»[1].

«Галия»дә уку чорында (1911—1916) Ш. Бабич XX йөз башында милли культуралар үсешендә азмы-күпме роль уйнаган барлык татар, башкорт һәм өлешчә казах әдипләре, музыкантлары, телчеләре белән дә диярлек аралашып яши.

Бу чорда Уфадагы әдәби хәрәкәт М. Гафури тирәсенә тупланып бара. Бабич та аңа тартыла. Алар шулкадәр дуслашып китәләр ки, «Галия» шәкерте «Шәрык матбагасы»нда М. Гафури урынына берничә тапкыр эшкә дә кала, анда корректор булып эшли.

1914 елның март аенда Уфага С. Рәмиев килгәч, яшь шагыйрь аның белән танышу юлларын эзли башлый. Күп тә үтми, алар арасында дусларча мөнәсәбәт урнаша. Шушындый талантлы әдипләр белән аралашып яшәү яшь шагыйрьнең поэтик осталыгын арттырырга ярдәм итә, дөньяда акны карадан аерырга өйрәтә.

Шулай да «Галия» шәкерте Шәехзадә Бабич тормышына, иҗатына төп юнәлеш биргән кеше — күренекле татар язучысы, галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов. 1915 елда Уфага кайткан әдипне шәкертләр таләбе буенча «Галия» идарәсе татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп чакыра. Г. Ибраһимов әдәбият дөньясында таныла башлаган Бабичны бик тиз күреп ала һәм шагыйрьнең талантын тулырак балкыту өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырыша. «Мин Бабичны байтактан бирле беләм»,— дип яза ул 1922 елда.— Беренче очрашуым Уфада «Галия»дә әдәбият дәресләре укыткан чагымда булды. Ул тәхрир (сочинение — Г. Г.) өчен бирелгән мәүзугъ (тема)ларны да, күрсәткән планны да... файдаланып, шундый кыйммәтле чаткылар чәчрәтә иде ки, әдәби зәвыклылар өчен аның сыйныф тәхрирләреннән ялтыраган истигъдады (сәләтлеге — Г. Г.) белән сихерләмәскә мөмкин түгел иде. Һәм шул вакытта мин аңа үзендәге табигый талантның үсүенә ярдәм бирер дип уйлаган чараларны кылырга тырыштым»[2].

Кызганычка каршы, безгә бу «кыйммәтле чаткылар» килеп җитмәгән. Алар хакында кайбер истәлекләрдән генә белә алабыз. «Шәехзадә Бабич «Чыңгыз хан» исемле бер әсәр язган иде,— дип искә ала З. Бикмурзин.— Бу әсәр Галимҗан Ибраһимов тарафыннан рецензияләнеп, бастырып чыгарырга ярарлык дип табылган иде, ни өчендер, ул басылмый калды»[3].

Шагыйрь Зариф Бәшири «Галия»не яңа тәмамлап чыккан Бабичның Г. Ибраһимов турында болай дип сөйләвен искә ала: «Ул укыта башлагач та, мин үземдә кискен борылыш башланганын сиздем. Аңа чаклы миндә дә матур әдәбиятта, бигрәк тә шигырьдә гарәп-фарсы сүзләрен куллану кирәк дигән бер караш бар иде. Шул уңай белән бервакыт Галимҗан агай миннән сорый: «Син килачәкнең яктыга таба баруында нәрсәгә таянасың?»— ди «Билгеле, мин әйтәм,— халкыма»,— дим. «Шулай булгач,— ди Галимҗан агай әйтә,— синең әдәби телең дә үз халкыңның теле булырга тиеш түгел-

[1] Бабич Ш. Көлке капчыгы. Уфа, 1916, 2 б.
[2] Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы. Казан, 1922, 15 б.
[3] Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Казан, 1966, 81 б.

ме?»— ди. Шуннан соң, халык телен актарып, аның җәүһәрләрен эзләргә керештем»[1].

«Галия» мәдрәсәсен алты ел урынына биш елда уңышлы тәмамлап чыккан Бабич, 1916 елның җәен күренекле телче Вали Хангилдин белән бер фатирда уздыра, балалар укыта (ул хәтта «Галия» мөдире Зыя Камали улына да дәресләр бирә). «Аң» (Казан), «Шура», (Оренбург), «Кармак» (Оренбург), «Сүз» (Мәскәү), «Тормыш» (Уфа) кебек татар газета-журналларында актив языша. Агыйдел елгасында салчылар җитәкчесе булып эшли.

1916 елның көзендә Бабич Троицк шәһәренә укытучы булып китә. Февраль революциясен дә шатланып шунда каршылый. Ул чорда шагыйрь белән якыннан аралашып яшәүче Сәрвәр Әдһәмова болай дип яза: «1917 елда патшаны төшергән көннәрдә аның иксез-чиксез шатланып йөрүләре һәм демонстрация вакытында кулына кызыл байрак тоткан хәлдә җил-җил атлап барулары әле дә күз алдында»[2].

Революция тәэсирендә Бабич ныклап журналистика эшенә тартыла, хәтта Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов дигән журналист белән «Хөр милләт» исеме астында газета да чыгарып йөри. Газетаның беренче санында ук шагыйрьнең «Яшәсен эшчеләр!» шигыре басылып чыга. Шушы ук көннәрдә Бабич С. Кудашның, Җ. Юмаевның шигырьләре һәм үзенең «Тәмсил кисәге», «Хөррият бүләге» дигән әсәрләре кергән җыентык та төзеп чыгара[3].

Г. Ибраһимовның беренчә чакыру хатыннан соң, 1917 елның июнь ахырларында шагыйрь Уфага кайтып төшә һәм остазы кул астында чыга торган «Ирек» газетасында языша башлый.

«Ирек».— үзе бу хакта: «Яшь шагыйрьләремездән Шәехзадә Бабич Троицкидан шәһәремезгә кайтты»,— дип язып чыга[4]. Бабичның бу чор эшчәнлеге хакында Г. Ибраһимов болай дип искә алган иде: «...Уфада (Бабич) социалистлар белән бергә эшли, әдәбият кичәләрендә татар буржуазиясенең җанын җәһәннәмгә җибәрәчәк ачы көлкеләрен укый, безнең «Ирек»тә байларны каһәрләп шигырьләр яза, кайчандыр «таңчы», «уралчы» булган булып, реакция вакытында яңадан буржуазиягә сатылып, эшчекрестьяннан ваз кичкән мөртәт «социалистларны» сүгә... эшчеләрне киң колач белән каршы ала... революция каһарманнарына әфариннәр укый...»[5].

Әмма Бабич Уфада озак тормый. Аны, 150 сум эш хакы вәгъдә итеп, М. Галәү «Кармак» журналына эшкә чакыра. Материаль хәле мактанырлык булмаган шагыйрь бу шартларга риза була. Җитмәсә, «Кармак» белән аның бәйләнеше күп еллар буе дәвам итеп килә.

Август аенда Оренбургка барып урнашкан Бабич җаны-тәне белән эшкә чума. Өстәвенә, ул шәһәрдә концертлар бирә, кичәләр уздыра, әдәби түгәрәкләр оештыра. Шунда аның күптәнге хыялы тормышка аша — шагыйрь Т. Ченәкәй аны күренекле татар шагыйре Дәрдмәнд белән таныштыра. Әмма Бабич бу чорда үзен чолгап алган иҗтимагый вакыйгаларга дөрес бәя биреп бетерә алмый. Социалистик революция алдыннан ук:

Һич тотар хал юк күңелнең тезгенен,
Һич белер хал юк фикернең төзлеген,—

— дип икеләнә башлаган шагыйрь, 1917 ел ахырларында башкорт милләтчеләре хәрәкәтенә барып кушыла. Буржуаз-демократик революция максатларын үз идеаллары иткән Бабичның ярсу, ашкынулы йөрәге «иҗтимагый хакыйкатьне» милли лозунглардан, матур вәгъдәләрдән табарга омтыла. Һәм шулай шомлы, «тезгенсез» вакыйгалар дулкынында бер ел чайкалганнан соң гына шагыйрь күңеленә «төз фикер» килә. Аның чын халык улы булуы шушы критик моментта күренде дә инде: Бабич тора-бара эшнең нәрсәдә икәнен, хакыйкатьнең кем ягында булуын, үзенең һәм үзе кебекләрнең нинди юлакка эләгүен акрынлап төшенә башлады. Нигаять, 1919 елның февраль аенда шагыйрь кызыллар ягына чыкты һәм бу хакта халыкка да игълан итте («Без ник кызылларга кушылдык» әсәре күздә тотыла). Озакламый ул Башкорт республикасы Вакытлы хәрби-революцион комитетының 1919 ел 25 февраль боерыгы белән Башревком карамагындагы башкорт матбугатының хезмәткәре итеп билгеләнә. Әмма, шундый якты юлга чыккач кына, шагыйрьнең тормышы кинәт киселә — ул 1919 елның 28 мартында революция дошманнары тарафыннан җәзалап үтерелә. Бу вакытта аңа 24 яшь кенә иде әле.

Ш. Бабич иҗатында коешка карап бакмаган, йолдызларны күреп хозурланмаган, ай нурлары астында уйланмаган шигырьне күрүе кыен. Шагыйрь хыялының җитез,

---

[1] Баширн З. Замандашларым белән очрашулар. Казан, 1968, 281 б.
[2] Әдһәмова С. Безнең Бабич.—«Совет әдәбияты», 1965, 1 сан, 111 б.
[3] Хөррият бүләге. Троицк, 1917.
[4] «Ирек», 1917, 25 июнь, 24 сан.
[5] Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы. Казан, 1922, 18 б.

омтылышлы булуы әнә шул күк җисеменә бәйле рәвештә язылган шигырьләрдә күренә. Бабич лирик героеның үсеш эволюциясе дә шушы поэтик образларга мөнәсәбәттә аңлатыла. Менә аның 1910—11 еллар арасында язган шигырьләреннән юллар: «Белмәсәң, минем кояшым илдәге мәктәп иде» («Зарлану»), «Шат кояшның шат нурында ялтырый сүнгән Уфа» («Яз тәэсире»), «Дөньяда бик аз булыр чын, зур шагыйрь Габдулладай: ул караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай» («Габдулла әфәнде Тукаев»). Шагыйрь үз Кояшын. Аен нидә күрә соң?— мәгърифәттә, табигать матурлыгында, камил иҗатта. Яшь шагыйрьнең бөтен омтылганы менә шулар. Тора-бара лирик геройның хыял дөньясы киңәя, карашлары катлаулана, күккә, Кояшка төбәлгән күзләр җиргә дә карый, җир халкына да игътибар арта. Ул хәтта үзенең барлык сәләтен, кирәк икән «яшь чагын, алтын чагын» да «халык алдында биргән таза анты өчен» корбан итәргә әзер («Халкым өчен», 1914).

Әйе, Ш. Бабичның лирик герое җирдән калкыбрак, өстәрәк яшәүче герой; шуңа күрә ул ярсу, тынгысыз, хәтта бунтарь герой («Айга мендем», «Теләк», «Дөньяга», «Мин — даһи»). Әмма ул бу ярсуында, омтылышларында халкыннан һич аерылып китми, һәрвакыт аның белән уртаклык эзли һәм аны иҗтимагый хакыйкатькә ирешү юлында табарга омтыла. Ул да «гамь чигә», «тормыш тигезсезлекләрен уйлап яна», чөнки «күзләре алдыннан егълап, ярлы мескеннәр үтә», аның күңелен «ярлыларны кызгану әрнетә» («Бай һәм ярлы», 1914).

Бабич герое, кайгы килсә дә, шатлык хисләре кичергәндә дә һаман шулай ярсу, тынгысыз булып кала. Аның күңелендә хәтта алла белән иблис көрәше чагыла кебек:

Берсе «Дин!» дип, берсе «Мин!» дип тарткалый,
Белмимен,
Әллә алла, әллә иблис алдалый.

Ләкин аның хыялларын күкнең, диннең буш идеаллары да, җир нәфесе дә үзенә йолып ала алмый, аның шәхесе ирекле иҗат әһеле, матурлык, дөреслек эзләүче зат булып калырга тели. Бу омтылышында аның хыяллары чиксез, теләкләре керсез:

Айга мендем, ай нуры белән коендым, уйнадым,
Күп сөендем, сөенеч белән туендым, туймадым.
Туймадым, айдан узып, мендем кояшка ашкынып,
Юк, шулай да булмады ташкын күңелне бастырып...

Шагыйрь алла тәхете каршына менсә дә, туган халкын онытмый, аның эзләнүләре дә шушы халкы өчен икән:

Айга үрләп, нурда уйнап,
Күкрәгемне нурладым.
«Ит гафу, әй, ай!— дидем,—
Мин нурларыңны урладым».

«Һич зарар юк, ал,— диде ай,
Ал да, чәч нур халкыңа;
Мин дә бит төн хакына
Алдым кояшның нурларын.

Дөрес, вакыт-вакыт лирик герой үз Кояшын, үз Нурларын күздән югалта һәм моны бик авыр кичерә. Бу вакытта ул тулысынча ялгызлык кочагында. Шагыйрь дөньяның ике чигенә ташланып карый. Бер караганда ул җир өстендә барган канкойгыч сугышны «күк йөзендә тын гына йөзгән йолдыз, кояш, айга» каршы куя («Сугыш»), күңелен «Күккә оч», күктә тыныч, Монда — сугыш, монда — кылыч» («Әйдә, күңелем») дип тынычландырырга тырыша. Икенче караганда, «Җир хәсрәте» кочагында калып, Кояшына бара алмавына ачына:

Якты эзләп күккә бактым — якты нурлар иңмәде,
Җиргә бактым — җир караңгы, күз чәчәкләр күрмәде.
Шунда миннән көлде йолдыз, көлде ай күктән карап,
Ник газаплыйлар мине? Ансыз да җан күптән кәбап.

Шундый авыр минутларда да герой Кояшы белән очрашудан өметен өзми. Ә анынча, Кояш — киләчәк матур тормыш, азат тормыш хыялы:

Ямь куралмам, гамьле хәлләр китмичә, яшь килмичә,
Күз яшемне киптерерлек якты кояш чыкмыйча.
(«Ямь күрәлмәм», 1916).

Җир белән күк арасында Кояш нурларын сагынып сыктаган Бабич герое үз Кояшын табып сөенә:

Зәңгәр күк — таҗым, чуар җир — тәхтем,
Үзем — азат хан, ак кояш — бәхтем...
Гөлләр елмайган, кырлар нурланган.
Бөтен җир-күгем нурга чорналган.
(«Бәхетем», 1916).

Февраль революциясе шавы ишетелә башлаган 1916 елларда Бабич чын мәгънәсендә зур иҗади үсеш кичерә. Нәкъ шушы елны аның аллага, динга, кануннарга баш күтәреп чыккан Газазил хакында поэма-балладасы дөнья күрә. Бу әсәрендә шагыйрь өр-яңа романтик поэма үрнәге бирде. Берәүләр тарихи легендаларда урта гасырчылыкны идеаллаштырган (Н. Думави, «Шәрык даһие»), икенчеләр дини легенданы шигырьгә салып, тормышта кара көчләр хакимлеге нәтиҗәсендә туган газапларга түземле булу, явызлыкка көч белән каршы тормау, тормыш ләззәтләреннән ваз кичү кебек нәрсәләрне гәүдәләндергән (Г. Сөнгати, «Хозыр»), өченчеләр легенданың үз эчендә уңай һәм тискәре көчләр каршылыгын күрсәтергә омтылган (Г. Шәрифи, «Нәнкәҗан») бер заманда, Бабич дини легенданы пародиягә әйләндереп, аның эчтәлеген үтергеч көлү хөкеменә тотты [1].

Шушы ук елда ул үзенең «Кандала» балладасын һәм «Китабеннас фи хаккыл хавас» [2] дигән эпиграммалар циклын иҗат итте, халыкка көчле сатирик буларак танылып өлгерде. Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк: Г. Тукай сатирасы ачык социаль тәнкыйть, фаш итүне тәшкил итсә, Бабич сатирасы һәрвакыт нечкә юмор, көлке белән өртелеп бирелә һәм анда, романтик әдәбият кануннары белән эш иткәнгә күрә, тәнкыйть фикере бик тирәнгә яшерелгән була.

Менә шушы көлке, юмор Бабич лирик героендагы көр рухны саклап калды, аны ялгызлык, аһ-зар кочагына җибәрмәде. Аның йөрәгендә халык өчен хәсрәтләнү һәм халык өчен шатлану берьюлы яши. Бу очракта ул, Г. Ибраһимов әйткәнчә, «күз яше үтәли көлә...»

Шагыйрь үзенең шатлыгы белән дә, кайгысы белән дә Февраль революциясен кабул итәргә әзер иде. Чыннан да, революция булгач та, ул үз Кояшын табып шатланды:

Исте җил, сүнде бар ялган шәм,
Таралды һәм болыт, һәм томан.
Халыкты чын кояш, киптә яшь...
Капланды «кара көч» йөзтүбән.
(«Хөррият бүләге», 1917).

Ләкин «кара көч» әле тулысынча бетерелмәгән, якты Кояш чыгып өлгермәгән иде. Әмма, нинди генә авыр хәлләрдә калса да, аның лирик герое үз иманына тугры булды. Бу иман: Кояш белән Нур тормышы арасында гармония, матурлык эзләү, аны туган халкына җиткерү. Халык үз шагыйрендә ялгышмады. Бабич «халык алдында биргән таза анты»на тугры калды.

**Галимҗан ГЫЙЛМАНОВ.**

---

[1] Бабич Ш. Сайланма әсәрләр (Х. Госман сүз башы). — Казан, 1958, 14 б.
[2] «Китабеннас фи хаккыл хавас» — «Атаклы кешеләр турында китап».

# ҖЫРЛАП ЯШӘРГӘ!

Татар совет музыка сәнгатендә үз иҗатлары белән тирән эз калдырган җырчылар байтак: Фәттах Латыйпов, Газиз Әлмөхәммәдов, Ситдыйк Айдаров, Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова, Мәрьям Рахманкулова, Фәридә Кудашева, Мөнирә Булатова, Зөләйха Хисматуллина, Усман Әлмиев... Бүгенге көндә дә җыр сәнгатебез яңа исемнәр белән тулылана бара. Димәк, традицияләр бай, җыр сәнгатенең чикләре киңәйгәннән-киңәя.

РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакиров — татар совет җыр сәнгатендә яңа дәвер ачкан, үз мәктәбен тудырган иң атаклы җырчыларның берсе. Яңа җырларның халык арасында таралуы, халык иҗаты үрнәкләренең популярлашып китүе генә түгел, күп кенә яңа җырчыларның сәхнәгә күтәрелүләре дә аның исеме белән бәйле.

Илһам Шакиров җырга-моңга бай Сарман якларында туып-үскән. Аның туган авылы Яңа Бүләк гражданнар сугышыннан соң Бөек Октябрь революциясенең өрнәгә бүләге буларак барлыкка килә. Яңа Бүләккә якын-тирә авыллардан хезмәт сөючән халык күченеп утырган. Биредә иген игәргә, мал-туар асрарга ярaталар. Урман куенына сыенып утырган авылда балта осталарын да күпләп очратырга мөмкин.

Бу авылда яшәүче халыкның тагын бер күркәм сыйфатын искәрмичә мөмкин түгел: алар җыр яраталар, җыр — авыл хезмәтчәннәренең аерылмас юлдашы.

Булачак атаклы җырчының әтисе Гыйльметдин абзый белән әнисе Нуриәсма апа да — гади хезмәт кешеләре булганнар. Гыйльметдин абзый авылның бердәнбер «пролетариаты» — тимерче булып эшләгән. Нуриәсма апа исә урак урган, ындырда ашлык суктырган, балалар тәрбияләгән. Эштән бушаган араларында исә улларына һәм кызларына җырлар өйрәткән.

Илһам гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Әлбәттә, хезмәтне ярату әти-әнисеннән аңа да күчә. Ул инде малай чагыннан ук кырда урак урырга, болында печән чабарга булыша башлый. Кечкенәдән үк әтисез калган малайга нәрсәләр генә эшләргә туры килми! Бөек Ватан сугышы башлангач, тормыш йөген тартып бару карт-корылар, тол хатыннар, бала-чагалар җилкәсенә төшә... Тормыш арбасын кечкенә Илһам да җигелеп тарта. Әтисе урынына калган Имам абыйсының сугышта үлү хәбәре исә гаиләдәге сабыйларга күтәрә алмаслык кайгы булып төшә.

Кул хезмәте тамак туйдырырга ярдәм итсә, җыр-моң кешегә рухи азык бирә. Авылдашларының җыр-бию яратуына Илһам кечкенәдән игътибар итә. Хәтта шундый авыр елларда да халык җырсыз яши алмый. Игенче, терлекче хезмәтләрен бик яратса да, үсеп җиткәч Илһам Шакировның музыка сәнгатенә кереп китүенә нәкъ менә Яңа Бүләк авылы кешеләренең җырга омтылышлары сәбәпче булгандыр да әле. Димәк, яңабүләклеләр татар халкының сөекле җырчысын тәрбияләп үстерүләре белән хаклы горурлана алалар.

Тәләнче-Тамак урта мәктәбендә белем алганда ук Илһам «Әллүки», «Тәфтиләү», «Уел» кебек борынгы озын җырларны башкарырга өйрәнә. Концертларда чыгыш ясый. Үзендә җырлау сәләте барлыгын белсә дә, җырчы булырга хыялланмый, укытучы һөнәрен сайлый ул. Һәм урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетына имтиханнар тапшырып карый. Ләкин язмыш аны шул ук елны Казан музыка училищесына укырга алып килә һәм ул, училищеның беренче курсында башлангыч музыка белемен үзләштергәннән соң, Казан дәүләт консерваториясендә укуын дәвам иттерә.

Музыка училищесына укырга кергән елны ук Илһам Шакиров радиодан чыгышлар ясый башлый һәм тыңлаучыларның яраткан җырчысына әверелә. Бу елларда әле радиодан концертларны, магнитофон лентасына язмаган килеш, турыдан-

туры тапшыралар. Менә шунда ул халкыбызның танылган җырчылары Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһаповлар белән якыннан таныша, алар арасында иҗади дуслык башлана. Мәшһүр җырчылар яшь башкаручыга зур өметләр баглыйлар, аңа киңәшләр бирәләр.

Консерваториядә укыган елларында композитор Мансур Мозаффаров белән иҗади дуслык башлануы Илһам Шакировка зур йогынты ясый. Композитор яшь җырчы өчен махсус җырлар яза: «Менәргә иде Урал тауларына» (Г. Зәйнашева шигыре), «Башка берни дә кирәкми» (С. Хәким)... «Хуш, авылым», «Умырзая», «Кара урман аша», «Күзгә ачы җилләрдә», «Яшь наратлар», «Әниемә хат», «Сибелә чәчәк», «Туган тел» җырларын югары дәрәҗәдә башкаруы Илһам Шакировны студент вакытында ук җырчы буларак танытты. Консерватория укытучылары булышлыгы һәм үзенең дә профессиональ белемгә омтылышы аңа җыр сәнгатенең серләрен тирән үзләштерергә ярдәм итте.





Казан дәүләт консерваториясен Илһам Шакиров 1960 елда Е. Абросимова һәм З. Бәйрашова класслары буенча тәмамлый. Дәүләт имтиханнарын бик яхшы билгеләргә таџшыра. Имтиханнарга тәкъдим ителгән программада шундый күренекле әсәрләр була: Гендельнең «Ксеркс»ыннан ария, Рахманиновның «Сирень» әсәре, Синдингның «Романс»ы, Гуноның «Фаус» операсыннан Валентин каватинасы, Рубинштейнның «Нерон» операсыннан эпиталама, Мансур Мозаффаровның «Башка берни дә кирәкми» романсы, Җәүдәт Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» операсыннан Искәндәр монологы. Әлеге әсәрләрне башкарып чыгу өчен нинди зур профессиональ белем кирәк булуы һәркемгә дә аңлашыла. Илһам Шакиров, әлбәттә, иҗатын классик музыка юнәлешендә дә үстерә алган булыр иде. Әмма халкының борынгы җырларга күбрәк тартылуын искә алып, ул үзенең иҗатын эстрадага багышлый.

Илһам Шакиров — татар халкының борынгы җырларын җыеп һәм музыкаль яктан эшкәртеп, аларны яңадан халык арасында популярлаштыруда зур көч куйган җырчы. Бер яктан караганда бу бик табигый да. Нигезендә социалистик реализм яткан сәнгать әсәрләре безнең илебездә иң беренче чиратта хезмәт ияләренең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү юнәлешендә дөньяга киләләр.

Сәнгатьне халыкка якынайтуның төп чарасы — аны халык авыз иҗаты, халык җырлары белән тыгыз элемтәдә үстерү. Ә менә буржуаз культура вәкилләре,

халыкның иҗтимагый аңын томалау нияте белән, хезмәт ияләрен эксплуатацияләүче аерым катлау мәнфәгатьләрен кайгыртып кына иҗат итәләр. Көнбатыштан һәм океан аръягындагы кайбер илләрдән үтеп кергән шау-шулы музыка моның ачык мисалы булып тора. Илленче еллар ахырында татар совет җыр сәнгатенә килгән яшь җырчы Илһам Шакиров моны ачык аңлый һәм үзенең иҗатын тулысынча халыкка якынайту юнәлешендә армый-талмый эшли башлый. «Иске кара урман», «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зәңгәр шәл», «Салкын чишмә» кебек иҗтимагый яңгырашлы борынгы җырларны ул яңадан халыкка бүләк итте. Әлеге җырлар Илһам Шакиров башкаруында кабатланмас төсмерләргә баеп яңгырадылар. Соңрак ул «Күзге ачы җилләрдә», «Эскадрон» кебек җырларга — Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында туган җырларга мөрәҗәгать итә. Онытылып бара торган җырлар сәхнәләрдә яңадан ишетелә башлады.

Аерым үзешчәннәр тарафыннан иҗат ителеп, шулай ук онытылуга дучар ителгән җырларның халык арасында таралып китүе дә аның исеме белән бәйле. «Кораб» (Дәрдмәнд шигыре), «Син сазыңны уйнадың» (Н. Исәнбәт), «Каръят батыр», «Яңа авыл җыры», «Истә, һаман да истә» кебек җырларны нәкъ менә Илһам Шакиров беренче мәртәбә җыр сөючеләргә ирештерде.

Композиторларыбызның яңа җырларын танытуда да Илһам Шакиров зур өлеш кертә. С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Р. Яхин, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, Р. Еникеев, Ф. Әхмәтов, С. Садыйкова һ. б. композиторларның туган ил, туган як, намуслы хезмәт турындагы әсәрләрен башкарып ул тыңлаучыларда патриотизм хисләре, эшсөючәнлек тәрбияли.

«Җырым сиңа булсын, Октябрь» дип исемләнгән концерт программасы өчен Илһам Шакиров 1970 елда ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Әлеге программага кертелгән «Күңелем Ленин белән сөйләшә» җыры аның тарафыннан бүгенге көнгә кадәр җырлана.

«Өченче көн тоташ кар ява» (С. Садыйкова, М. Кәрим), «Тынычлык солдатлары» (Ф. Яруллин, С. Хәким) кебек җырларны да Илһам Шакиров тамашачыларны тетрәндерерлек итеп башкара. Аның кабатланмас моңлы тавышы сугыш китергән ачы кайгы-хәсрәтләрне дә, совет солдатының җиңелмәс батырлыгын да берьюлы әйтеп бирә. Бөек Җиңүнең 40 еллыгын каршылаганда әлеге җырлар тагын да актуаль яңгырыйлар, җырчыны тыңлаганда миллионнар тавышын ишеткәндәй буласың.

РСФСРның халык артисты Илһам Шакиров «коеп куйган» җырчы гына түгел, ул көндәлек матбугатта публицистик мәкаләләр белән дә еш катнаша, музыка сәнгатендәге яңалыкларга, аерым җырчылар иҗатына үз мөнәсәбәтен даими белдереп бара. Радио буенча оештырган «Халык җырлары — халык күңеленең көзгесе» дип аталган әңгәмә-концертлары җыр сәнгатендә аерым бер фәнни хезмәт буларак каралырга хаклы. Җырчы үз талантының тагын бер ягын ачты. Аның тарафыннан иҗат ителгән «Гөлмәрьям», «Идел буе каеннарына», «Яшьлегемә кире кайтыр идем», «Сәламләү» кебек җырларны халык яратып кабул итте.

Без аны яшь җырчыларның һәм композиторларның остазы, киңәшчесе буларак та беләбез. Күп кенә яшь җырчылар аның хәер-фатихасын алып зур сәнгать юлына аяк бастылар. Мәсәлән, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Сәхәбиев, Мөнир Якупов, Зөһрә Сәхәбиева, Хәмдүнә Тимергалиева, Искәндәр Биктаһировлар халык җырларын һәм композиторларыбыз әсәрләрен башкарыр алдыннан, гадәттә, Илһам Шакиров белән киңәшәләр, тәҗрибә уртаклашалар.

Халыкка рухи азык кирәк. Тамашачыларның әлеге ихтыяҗын истә тотып, Илһам Шакиров илебезнең төрле шәһәрләрендә һәм авылларында еш була. Гастрольләр географиясендә чит илләр дә бар. Тамашачы белән һәрдаим очрашып тору — үзенә күрә халыкның рухи ихтыяҗын өйрәнү дә бит әле ул. Шуның өчен дә халыкның сөекле җырчысы һәр очрашуга ныклап әзерләнә, яңа җырлар сайлый, аларны халыкка үтемле итеп җиткерүнең төрле чараларын эзли. Тамашачы җырга-моңга сусамасын. Җырлап яшәргә кирәк!

* * *

Музыка сәнгате турындагы уй-фикерләре белән даими уртаклашып торучы автор буларак, Илһам Шакиров «Казан утлары» журналы белән дә элемтәдә тора. Тормыш һәм иҗат юлындагы 50 еллык бәйрәме алдыннан без танылган җырчыга журнал укучылары исеменнән берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

— Редакциягә, Илһам Шакировка тапшыру үтенече белән, бер хат килде. «Безнең Ташкент радиосы һәр пәнҗешәмбедә татар артистларының концертын тапшыра. Сезнең моңлы җырларыгызны ишетер өчен концерт көннәрен көтеп алалар.

Без үзебез тумышыбыз белән Башкортстан якларыннан. Бирегә алтмышынчы елларда күчеп килдек. Беренче мәртәбә 1962 елны телевизор аркылы үзегезне күрдек һәм «Әнием» дигән җырыгызны тыңладык. Шуннан бирле безнең сөекле һәм моңлы артистыбыз Сез булып калдыгыз.

Менә бүген 17 нче декабрь, безнең шатлыклы көнебез. Без бүген улыбызга исем таптык. Моннан өч көн элек туган улыбызны кулдан-кулга алып исем таба алмыйча йөргәндә радио аша сез җырладыгыз. Шунда мин: «Илһам кушабыз, безнең улыбыз да Илһамга охшасын, илгә сөекле булсын»,— дидем. Безгә исем табып бирергә Сез булыштыгыз. Мең рәхмәт сезгә, озын гомерле булыгыз!

Шакир Фәсхетдинов,
Ташкент өлкәсе, Ак-курган районы, «Ленинабад» колхозы.»

Сезнең үзегезгә дә бу исемнең кушылуы кызыклы гына булган дип сөйлиләр...

— Әткәй белән әнкәй миңа Инсаф дип исем кушарга уйлаганнар. Янәсе, төпчек малай, безне тәрбияләр, инсафлы булсын, дигәннәр. Әмма миңа исем кушарга килгән Шакир бабай ул чакта инде колакка да катырак булган, ахрысы, Инсафны Илһам дип ишеткән. Хәер, болай да аны Илһам исемен яраткан дип сөйлиләр. Шулай итеп, Илһам булып киткәнмен...

— Тамашачы хатларыннан күренгәнчә, Сезнең иҗатка алар зур бәя бирәләр. Концертларыгызда Сезне алкышлап каршылыйлар, алкышлап озатып калалар. Гомумән, алкышлар җырчыны «бозмыймы?»

— Алкышларга, кул чабуларга минем үземнең мөнәсәбәтем бар. Кайчакта кул чапмасыннар иде дисең. Мәсәлән, сугыш китергән фаҗига турындагы «Өченче көн тоташ кар ява» җырын башкарганнан соң, мин залның тыныч кына утыруын теләр идем. Әмма кайберәүләр, күз яшьләрен сөртә-сөртә, кул чаба башлыйлар. Әлбәттә, тамашачыны аңларга мөмкин: үзенчә рәхмәт әйтәсе килә аның. Тик бу хәл миңа киресенчә тәэсир итә.

Җырчы бервакытта да тынычланып калырга тиеш түгел, минемчә. Аның күңеле битараф булса, ягъни кыйбласын югалтса, ул инде җырчы булудан туктый. Җырчының миссиясе — кеше күңеленә уй салу. Ә җырчы үзе битараф икән, димәк, тамашачы да аңа битараф караячак.

— Нәрсә ул моң? Хәтерлисездер, моннан берничә ел элек моң турында бәхәс чыккан иде. Җыр турындагы әлеге әңгәмәбездә дә моң төшенчәсенә кагылып үтәсе килә. Билгеле булганча, моң сүзен кайбер башка халыкларда очратып булмый. Моң безнең халыкка гына хас нәрсә түгелме икән?

— Чынлап та, моң сүзе кайбер халыкларда очрамый. Әмма моң төшенчәсе юк икән, аларны моңсыз дип әйтү хата булыр иде. Моң ул халыкның үзендә, күңел түрендә ята. Моң аларның тормыш-көнкүрешендә, гореф-гадәтләрендә чагылыш таба. Һәр халык та җырга-моңга бай, рухи хәзинәләрендә моңлы җырлар байтак.

Гомумән, нәрсә ул моң? Бу хакта, әйе, күп бәхәсләштеләр. Ни өчен шундый бәхәс чыкты соң? Без гади генә нәрсәләрне дә кайчакта аңлашылмас дәрәҗәдә катлауландырырга яратабыз, кайбер күренешләрне кеше акылыннан, кеше күңеленнән өстен дип исәплибез. Моң хакында бәхәс туууга да нәкъ шулар сәбәпче булгандыр.

Бу сорауга мин «Азат хатын» журналында дөнья күргән «Артистлар» дигән язмамда да, Татарстан радиосы буенча оештырылган «Халык җырлары — халык күңеленең көзгесе» дигән әңгәмә-концертта да җавап бирергә омтылыш ясап караган идем инде. Кабатлауның зыяны булмас дип уйлыйм.

Гади генә мисаллар китерәм. Бер үк скрипкада бер үк нотаны (көйне) ике кеше башкарды, ди. Берсе бик моңлы итеп уйный, икенчесенең уйнавы исә күңелгә бөтенләй ятышлы түгел. Сәбәп нәрсәдә соң? Сәбәп — тыңлаучының йөрәгенә үтеп керә алуда. Кайбер җырчыларны, башкаручыларны тыңлаганнан соң тамашачы канәгать рәвештә: «Йөрәктәгене әйтте дә бирде»,— дип куя. Димәк, моң ул йөрәктән чыккан нәрсә икән...

Моң җырда гына түгел, ә балки шигърияттә дә, проза әсәрләрендә дә, гомумән, сәнгатьнең башка төрләрендә дә яши. Мәсәлән, балачагымда «Агыйдел» повестен укуым әле дә хәтеремдә. Мирсәй ага Әмирнең бу әсәре миңа шулкадәр тәэсир иткән ки, хәзер дә мин аны иң моңлы әсәрләр рәтенә кертәм. Белмим, әсәрнең тел агышы шулай тылсымладымы, әллә инде андагы вакыйгалар тәэсир иттеме, мин бик моңлы җыр тыңлагандай булдым. Ләкин үсә төшкәч «Агыйдел»гә яңадан әйләнеп кайтмадым. Өлкән язучыбызның рухы рәнҗемәсен, балачагымда алган якты тәэсирләремне югалтырмын дип курыктым.

Моң димәктән, табигатьтә дә моң бар. Нәкый ага Исәнбәт китергән мисалны искә төшереп узу урынлы булыр. Яшьләр, кич белән җыелышып, су буенда учак ягып җибәрделәр, ди. Бу күренеш һәркемне моңаерга, уйланырга мәҗбүр итәр иде. Шул ук яшьләр көпә-көндез су буенда учак ягып карасыннар әле! Монысы инде беркемне дә моңландырмас иде...

— Әйе, хакыйкать күренешләрне шулай үзара чагыштырып карау юнәлешендә ачыла. Әйдәгез, тагын бер чагыштыру китерик: халык җырлары, композиторларыбызның популяр әсәрләре һәм Көнбатышта киң таралган «шау-шу» музыкасы. Һәркайсының үз тыңлаучылары бар. Моны нәрсә белән аңлатыр идегез?

— Башта бер хәл турында сөйлим әле.

Бервакыт Казанга яшьләр арасында дан казанган ансамбль килде. Ансамблнең иҗаты белән кызыксынып, мин дә концерт тыңларга киттем. Сәхнәдә — яшьләр, залда да — яшьләр. Киемнәре дә бер-берсеннән аерылмый диярлек. Менә концертны башлап җибәрделәр. Артистлар пыр тузып бииләр, сызгыралар, акырып җырлыйлар. Сәхнәдә шундый хәл икән, залдагылардан да «яхшылык» көтмә инде. Тәртип саклаучылар залдагыларын берәм-берәм җыеп алдылар. Ә менә сәхнәдәгеләргә сүз әйтүче булмады...

Мин моны кеше көлдерер өчен сөйләмим. Киресенчә, күңелсез хәл бу. Монда борчылыр урын бар.

Күптән түгел Минзәлә районында гастрольләрдә йөреп кайттым. Дөресен әйтим, минем концертларга тамашачы «модалы» җырлар тыңларга киләдер дип уйламыйм. Алар нинди җырлар башкарылачагын алдан ук сизенеп киләләрдер, мөгаен. Минзәлә районы культура йортларындагы тамаша залында бары тик яшьләр генә утыра иде. Әлбәттә, алдан ук искәртеп куярга кирәк таптым: «Бу концертта сез бары тик татар халык җырларын һәм композиторларыбызның популяр әсәрләрен генә ишетерсез. Шау-шулы музыка безнең концертта ишетә алмассыз»,— дидем. Концертлар уңышлы үтте. Мин моңа шатландым. Юк, үзем өчен түгел. Димәк, тамашачы җыр тыңлаганда халык тарихы белән дә таныша диген сүз. Соңгы исәптә мондый җырлар аларга икеләтә файда китерә.

— «Шау-шу» музыкасы турында сүз чыккач, бер сорау туа: халыкның үзендә дә тамашачыга тәкъдим итмәстәй җырлар байтак очрый...

— Әйе шул, хак сүзләр бу. Иҗтимагый тормыштан читләшеп, бәйрәмчә күңел ачып яшәү дәрте уята торган җырлар да шактый. Әмма аларны халыкка җиткерү шарт түгел. Халыкта һәр нәрсә дә халыкчан түгел — моны онытырга ярамый. Җырчының, композиторның максаты нәк менә шунда да инде — халыкчан җырларны җыйнау, аларны профессиональ дәрәҗәгә җиткереп эшкәртү һәм халыкның үзенә бүләк итү. Кайбер җырчылар арасында (бигрәк тә яшьләргә кагыла бу) инде халык күңеленә кереп урнашкан җырларны бозып җырлаучылар да очрый. Мәсәлән:

Безнең урам уртасыннан
Ага суның салкыны.

— дип җырлый бер яшь җырчыбыз. Мин аны төзәтергә мәҗбүр булдым. Сүзләрнең ялгыш булуын аңлаттым. «Урам уртасыннан салкын су агып яткач, анда чокыр казып куйганнармы әллә?»— дип сорадым.

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны.

Гомумән, халык җырларына бик игътибарлы булырга кирәк.

— Кайбер тамашачылар борынгы җырларның, мәсәлән, «Иске кара урман» кебек җырларның сүзләрен алыштырырга кирәк, диләр. Сез бу фикергә кушылыр идегезме?

— Әлбәттә, юк. Әйткәнемчә, һәрбер җырның дөньяга килү тарихы бар. Без бүгенге көн таләбеннән чыгып, аларны үзебезчә эшкәртә башласак, бу халык тарихын бозу булыр иде. Киләчәктә тарихны, сәнгатебез тарихын өйрәнүчеләр дә, халык үзе дә безне гафу итмәс иде.

Хәтерлисездер, СССР Язучылар союзы идарәсенең юбилей пленумында (1984 ел, сентябрь) ясаган чыгышында иптәш К. У. Черненко: «Тарихны яңадан күчереп язарга, аны чистартырга ярамый»,— диде.

Хәлбуки, кайбер яңа табылган җырларның сүзләрен үзгәрткәләргә дә туры килде. Мәсәлән, Волгоград өлкәсеннән язып алынган «Чатырлар» исемле җырга мин шагыйрь Зөлфәткә яңа текст язарга куштым. Далада туган озын, моңлы бу җырның сүзләре, ахрысы, онытылган булган һәм аның эчтәлеге «җанкай-җанаш»ка гына кайтып калган иде. Көйгә социаль эчтәлекле яңа сүзләр язылды. Халык әлеге җырны яратып кабул итте.

— Яшь җырчыларга һәм композиторларга нинди теләкләр әйтер идегез?

— Әүвәл җырчыларга берничә сүз. Яшьләр күбесенчә әзер җырларны башкарырга күнегеп киттеләр. Кемдер тарафыннан эшкәртелгән җырны, әлбәттә, җырлау җиңелрәк. Әмма андый ансат юл сайларга ярамый.

Бу җәһәттән бер мисал китерәсем килә. Сараевода үткәрелгән Олимпия уеннарын кызыксынып күзәтеп бардым. Бигрәк тә чаңгы ярышлары истә калды. Ярышларга анализ ясаучы спорт комментаторы шунда болай диде: «Иң авыры — алдан килүчегә...»

Әйе, иң авыры — алдан юл салып килүчегә. Халык күңеленә үзенчә юл сабучы сәнгать кешеләре моны яхшы аңлыйлардыр. Һәр җырчының халыкка әйтер сүзе булырга тиеш. Моның өчен җырчыга композиторлар һәм шагыйрьләр белән иҗади элемтә урнаштыру зарур. Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев белән бергәләп җырлар иҗат итүебез бүгенгедәй хәтеремдә. Студент чагымда ук бергәләп иҗат иткән җырларыбыз әле дә консерваториядә үзенә күрә бер үрнәк итеп кулланыла.

— Татар халык җырларын эзләп табуда үзешчәннәр дә күп эш башкаралар. Аларга нинди теләкләр белдерер идегез?

— Зеленодольск районының Норлат авылыннан Һава Харисова республика күләмендә уздырыла торган һәр смотр-конкурска үз җырын алып килә иде. Ул аны халыктан отып алганмы, әллә үзе иҗат итә идеме — анысын төгәл генә әйтә алмыйм, әмма ул һәрвакыт яңа җыр белән чыгыш ясый иде.

Хәзер исә үзешчәннәрне тыңлыйм да аптырап куям: барысы да профессиональ җырчылар башкара торган җырлар... Эзләнү җитеп бетми, күрәсең. Хәтта кайберләре танылган артистларны кабатлау юлына басалар. Тавышы гына түгел, килеш-килбәтләре дә, сәхнәдә үз-үзен тотышлары да кемнедер хәтерләтә. Миңа да кайбер танышларымның әйткәне бар: фәлән районда нәкъ синеңчә җырлый торган кеше яши, хәтта кыяфәте дә сиңа охшаган, диләр.

— Димәк, һәр башкаручының үз йөзе, үз тавышы булырга тиеш?..

— Һичшиксез. Дөньяга һәр кеше кабатланмас булып туа. Хәтта җырчы үз-үзен кабатлый башласа да, аның җыр сәнгатендәге әһәмияте кими.

— Әңгәмәбезне тамашачы хатын укудан башлаган идек. Сезгә алар күп киләдер...

— Әйе, хатлар күп килә. Күбесе рәхмәт хатлары. Араларында төрле киңәшләр сорап язганнары да очрый. Кайбер авторлар исә үзләре киңәш бирәләр. Дөрес киңәшләрне һәрвакыт истә тотарга тырышам.

— Тамашачылардан килгән хатларыгызны безгә дә укытмассызмы?

— Кайберләрен бүгенге очрашуга махсус рәвештә алып килгән идем. Рәхим итегез!..

• • •

Сезнең әңгәмә-концертыгыз бездә бик җылы тәэсир калдырды. Аны тыңлаган вакытта: «Илһам җыры белән генә түгел, сөйләве белән дә күңелләргә үтеп керә икән»,— дип уйлыйсың.

Кешеләр авызыннан шундый сүзләрне еш ишетергә туры килә: «Нишләп хәзер мәхәббәт, сөю турында гына җыр чыгаралар икән, нишләп соң әле гражданнар сугышы, стахановчылар турындагыларын, элек клубларда җырлап-уйнап йөргән җырларны оныттылар икән...» Чыннан да андый җырлар тапшыруларда бик сирәк җырлана, яки бөтенләй җырланмый. Күрәсең, ул җырлар безнең яшьлегебезгә туры килгәнгә күңелгә якыннардыр инде. Шулай ук «Иске кара урман», «Сибелә чәчәк», «Гөлҗамал» һәм башка борынгы көйләр дә сирәк яңгырый. Алар буыннан-буынга күчеп килгән, онытылмый торган, хәзер дә яңа чыккан көйләр кебек тыңлана торган (искермәгән) көйләр бит. «Гөлҗамал» җырын гына алыйк. Шул дүрт юллык җырда (кушымтасыннан башка) никадәр мәгънә. Яшь кыз. Серен кем белән дә уртаклаша алмый. Дүрт стена эчендә. Андыйларның алдагы тормышы билгесез. Алар сөяргә дә, сөелергә дә хаклы түгел. Билгесезлек. Аларны кемгә сатарлар? Карткамы, егеткәме, әллә комсыз бер байгамы (ничәнчедер хатынлыкка)? Бу хакта алар ачыктан-ачык кычкырып та сөйләшә алмыйлар, ә колактан колакка сөйлиләр. Билгеле, бу сүзләрнең берсе дә җырда юк. Ләкин билгесез язмышлы җиткән кызның уйлары бик ачык булып аңлашыла. Бу җырны инде беркем дә ялыктыргыч дип әйтмәс, минемчә.

Ә «Иске кара урман» көе турында сез бик аңлаешлы, ачык итеп әйттегез. Андый җырларны яшьләр өчен дә, олылар өчен дә ешрак җырларга кирәк. Яшьләр халкыбызның үткән тормышын күз алдына китерсеннәр, ә өлкәннәр исләренә төшерсеннәр.

Гомумән, мондый әңгәмә-концерт ешрак булсын иде, андый концертлар белән авылларга да килсәгез иде. (Безнең авылларда артистлар да биш-алты елга бер генә күренәләр.)

Әйткәнемчә, табигать Сезгә җырлау өчен генә түгел, сөйләү өчен дә шундый йомшак тавыш биргән, аңлаешлы, гади тел биргән. Әшегездә уңыш, тормышыгызда бәхет телим.

Халисә Сибгатуллина.
Арча районы, Кызылъяр авылы.

Моннан ике ел элек Сез Чайковский шәһәренә зур концерт белән килгән идегез. Без Сезне бик кадерләп каршы алдык, һәм концерт бик уңышлы үткән иде. Инде гафу итегез, үпкәбез бик зур, чөнки безне оныттыгыз, килмисез. Югыйсә без Казаннан ерак яшәмибез. Әгәр безгә атап кына килергә мөмкин булмаса, Ижевск, Сарапул якларына гастрольләргә чыксагыз, безгә инде бөтенләй якын кала.

Чакыруыбызны кире какмасагыз иде. Без бит Сезне түземсезлек белән сагынып көтәбез. Килегез!

Фәнис Заһитов.
Пермь өлкәсе, Чайковский шәһәре.

Без Сезнең радио аша концертыгызны бик яратып тыңладык. Бигрәк тә «Кара урман» ошады. Әлеге җырны тыңлаганда үзеңне урманда кебек хис итәсең, борынгы заманнарда яшәгән әби-бабаларыбызның караңгы тормышлары күз алдына килә. Сезнең матур моңлы тавышыгыз ерактан, бик ерактан чылтырап аккан чишмә суы кебек йөрәкләргә үтеп керәләр.

«Син сазыңны уйнадың» дигән җырны тыңлаганда да үзеңне гөлләр бакчасында кебек сизәсең. Әйтерсең лә ерак түгел генә тыныч су өсте күренеп тора. Син анда берүзең генә калгансың шикелле. Балачакларың, синнән аерылган якын туганнарың, якын дусларың берсе артыннан берсе күз алдына киләләр. Сезне тагын-тагын тыңлыйсы, тыңлыйсы килә.

Сезгә ихтирам белән: Зәйнәп Шәмсетдинова, Разия Рәхимкулова,
Сәлимә Гайнуллина, Ислам Рәхимкулов, Гомәр Рәхимкулов.
Чистай.

Исәнмесез, кадерле дуслар!

Сезгә зур үтенеч бар. Ярты гасыр элек безнең гаилә туган якларыннан (элекке Казан губернасы) бирегә күченеп килгән. Әмма туган як туган як шул, аны мәңге онытып булмый икән. Әле менә бүген Бөтенсоюз радиосыннан халык җырчысы И. Шакировның чыгышын тыңладым. Ихтыярсыз яшьләрем түгелде. Күп мәртәбәләр сатучыларга мөрәҗәгать итеп карадым, әмма татар җырлары язылган пластинкалар беркайда да юк. Ә бит безнең Грозный шәһәрендә татарлар күп яши. Зинһар өчен пластинкалар белән сәүдә итә торган кибетнең адресын җибәрегез әле.

Ә Илһам Шакировка чын күңелдән уңышлар телим. Ул һәрвакыт кешеләр тормышын җырлары белән ямьләндереп яши.

А. Цуриковская.
Чечено-Ингушетия, Гудершес районы, Джалка поселыгы.

...Төрле җырлар һәм төрле җырчылар бар. Кайсыларын бик яратып тыңлыйсың, ә кайсыларын юк. Ә менә Сезнең башкаруда, нинди генә җыр булмасын, барысы да җанга рәхәтлек бирә.

Мин бер мәртәбә Сезнең концертыгызда булу бәхетенә ирештем. Сәхнә артыннан «Бик еракта идек без» дигән җырны җырлап чыгуыгыз һәрвакыт хәтердә торыр!

Сезнең яңа җырларыгызны ишетү минем өчен зур шатлык булыр иде, ләкин аларны табу айга менүдән дә кыенрак. Илһам абый, кинәш итегез әле: мөмкин булса, кая заказ бирергә? Бәлки Казанда, берәр тавыш язу студиясенә магнитофон пленкасын җибәреп яздырырга буладыр? Мин үзем дә татар халык җырларын җырларга бик яратам.

Хатны тәмамлап, сезгә барча җыр сөючеләр исеменнән зур рәхмәт белдерәм, кояштай озын гомер, иҗатыгызда тагын да зур уңышлар телим. Кабатланмас моңлы тавышыгыз һәрвакыт көчле яңгырасын!

Тирән ихтирам белән, Ягъфәр Рысаев.
Томск.

Мин — рус егете. Татар кызына гашыйк булдым. Һәм аны тормыш юлдашы итеп сайладым. Аны яратуым белән сезнең җырларны һәм сезне дә яраттым. Гомерлек юлдашым минем өчен «Янар чәчәк» булып тоела. «Янар чәчәк» җырын башкарыгыз әле. Әлеге җыр аңа уртак бүләгебез булыр.

Туганнарча сәлам белән,
Владимир Волков.
Алма-Ата.

Сезгә бик зур үтенечем бар.

Сезне бик сагындык. Әллә безне онытып та куйдыгыз инде?! Сезне күрмәгәнгә бер ел булды. Җәйләр үтте, көзләр җитте — ә Сез һаман юк та юк. Безнең хәтта производстводагы эшләребез түбән тәгәри башлады. Моңа бары тик Сез генә гаепле... Күпме мөмкин көтәргә?

Без Сезне һәм тавышыгызны бик яратабыз. Хәтта быел күбебез отпускага да китә алмады. Сез килеп төшәрсез дә Мәскәүгә, күрми калырбыз дип куркабыз.

Ихтирам белән,

Роза Абдуллина.

Мәскәү.

Төрле язмышлар аркасында татарлар Советлар Союзының һәм Җир шарының бик күп тарафларына сибелгән. Үзбәкстанда да күп алар.

Элек татар җырларын халыкка ирештерүче җырчы Рәшит Ваһапов иде. Без аны ярата идек, ихтирам итә идек. Хәзер исә җырларны халыкка җиткерүче дип Илһам Шакировны исәплибез. Аның һәр килүе зур бәйрәмне хәтерләтә. Сүзләрем дәлилсез булмасын дип, мисаллар китерәм. 1968 елда ул Ташкентта Ленин комсомолы паркында чыгыш ясады. Бирегә 3000 кеше сыя. Бу концертта хәтта басып торырга да урын юк иде. Илһам Шакиров яңа җырлар алып килгән иде. Җырчы үзе иҗат иткән «Гөлмәрьям», «Сәлам сезгә» исемле әсәрләрне башкарганда җыр көенә бөтен зал кул чабып торды.

Без Илһамсыз татар культурасын бөтен тулылыгы белән күз алдына китерә алмас идек. Аның концертларын тыңлар өчен Казан шәһәренә барып йөрергә һәркемнең дә мөмкинлеге юк! Шуңа күрә безгә ешрак килсен иде ул кунакка!

Аңлыйбыз: Илһам Шакиров безне — үз халкын өзелеп ярата. Без дә аны бирдән-беребез дип атыйбыз.

Әнвәр Максудов,

Ташкент сәнгать сараеның баш рәссамы.

## Илһам кайчан килә?

«Болгар» мосафирханәсенең кырыгынчы бүлмәсендә өч шагыйрь сөйләшеп утыра: Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Зариф Бәшири.

Тукай Бәширине өнәп бетерми, аның тизрәк чыгып китүен тели. Кунак ителгән, сыйланган, сөйләшәсе сүз дә беткән, бары аңа, саубуллашып, рәхмәтен әйтеп, чыгып китәсе генә калган. Ә Зариф Бәшири чыгып китәргә җыенмый, такылдавында дәвам итә, әле бер темага, әле икенче темага күчә.

— Габдулла әфәнде, әйт әле, зинһар, сиңа илһам кайчан килә? — дип сорый ул, ниһаять.

Бөек шагыйрь аңа бераз көлемсерәп карап тора да сорау белән җавап бирә:

— Ә сиңа?

— Миңамы? Миңа төнлә, йокларга яткач, күзне йомгач килә.

— Ә-ә, сере менә нәрсәдә икән! — дип, Г. Тукай җанланып кычкырып җибәрә. — Әйтәм, шигыреңне укыган саен йокы килә. Шуңа икән!

Такылдавык җанның кирәкмәгән сүзләрен эче пошып тыңлап утырган Сәгыйть Рәмиев, моны ишетеп, шаркылдап көлә башлый, ә З. Бәшири, салып куйган галошын да киярга онытып, шундук йөгереп чыгып китә.

## Бабай

Шагыйрь Мәҗит Гафури илле дүрт яшендә вафат булды. Карт түгел иде әле. Иҗатының ташып торган чагы иде. Шуңа карамастан, татар матбугаты инде аны күптән карт шагыйрь дип атап йөртә иде. Кем белә, бәлки, әле картлыгы өчен түгел, ә ул заманда иң өлкән язучыларның берсе булганга олылап, ихтирам итеп шулай атаганнардыр. Ничек кенә булмасын, Мәҗит ага үзен карт яисә бабай дип әйттерергә теләмәгән булса кирәк.

Бер заман шулай, егерменче елның азагында булса кирәк, Мәҗит ага шагыйрь Сәйфи Кудаш белән бергә Уфаның текә ярыннан Агыйделгә сокланып карап тора икән. Көн матур, кояшлы, җылы. Астан, пристань ягыннан кешеләр агылып менә: атлылар, җәяүлеләр... Шунда берсе, шактый авыр капчык күтәргән бер егет, Мәҗит ага янына житкәч, аңардан:

— Бабай, Аксаков урамына ничек барырга икән? — дип сорый.

Мәҗит аганың кинәт йөзе караңгыланып китә. Берничә секунд чамасы ни дип җавап бирмичә тора. Аннары кинәт, кулы белән кире якка күрсәтеп:

— Аксаков урамымы?.. Аста ул, түбәндә, энекәш,— ди. — Төшкәч, сул якта.

Егет, авыр капчыгын күтәреп, түбәнгә, Агыйделгә таба төшеп китә. Сәйфи Кудаш, бик гаҗәпләнеп, М. Гафурига карый.

— Нишләвегез бу, Мәҗит ага? Аксаков урамы анда түгел ич.

— Булмаса соң, нигә ул миңа бабай дип эндәшә,— ди шагыйрь.— Кирәкмәгәнгә картайтмасын кешене!

Күпмедер вакыт уза — секундлармы, минутлармы. Мәҗит ага кинәт Сәйфи Кудашны ашыктыра:

— Бар әле, йөгер әле шул егет артыннан. Аксаков урамының кайда икәнен әйт! Капчыгын да күтәрешеп мен!

Сәйфи Кудаш йөгереп төшеп китә.

# Сәер колак

Тәнкыйтьче Гомәр Галинең уң колагы начаррак ишетә иде.

Бервакыт аңа Татарстан дәүләт нәшриятында эшләп утырганда (әдәбият бүлеге мөдире иде ул) каяндыр, әллә ни ерактан булмаса кирәк, Әбүзәр Түрәй шалтырата. Тавышы калын, көчле, шул ук бүлмәдә эшләп утыручыларга, ягъни безгә дә телефон трубкасы аша яңгырап ишетелә.

— Поэманы укыдыңмы?.. Басарга бирдеңме? — дип кычкыра Түрәй.

Гомәр Гали дә аннан ким кычкырмый:

— Нәрсә?.. Ни дисең?.. Нинди победа?..

— Победа түгел!.. Поэма!.. Типографиягә төштеме әле? — дип яңгырый телефон трубкасы.

— Ишетелми!.. Берни ишетелми!.. Кычкырыбрак әйт!.. Телефон трубкасы шартларга җитәрлек булып зыңлый.

Гомәр, сөйләшүеннән туктап, эшенә тотына, башын бераз кыйшайта төшеп, бик ашыгып нидер яза.

Берничә минуттан телефон янадан шалтырый. Гомәр Гали, трубканы кулына алып, бик каты кычкыра:

— Тыңлыйм!.. Я, нәрсә? — һәм шундук, тонын үзгәртеп, пышылдап кына сөйләшә башлый.

Озак сөйләшә. Бер минут... ике минут... биш минут. Телефон трубкасындагы тавыш безгә ишетелми, ә Гомәргә яхшы ишетелә булса кирәк: бик нәзакатьле, әдәпле сөйләшә, елмая, кай минутларда күзләре чаткыланып китә — хатыны белән сөйләшә, ахры.

Безнең белән бер бүлмәдә эшләп утыручы Фәтхи Бурнаш бераздан, Гомәр сөйләшеп бетергәннән соң, аңа әйтә:

— Нигә шулай ул синең колагың: я ишетә, я бөтенләй берни ишетми? Гаҗәп!

Гомәр Гали, хәйләкәр генә елмаеп, җавап бирә:

— Үзем дә аптыраган инде аңа. Нигә алайдыр. Кирәкне ишетә, ә кирәкмәгәнне юк.

*Кызыклы хәлләрне журналга А. Тәүгилде әзерләде.*

## ОЛЫ ЮБИЛЕЙ ХӨРМӘТЕНӘ

8 декабрьда Казанда, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында, республика иҗат интеллигенциясе активының Татарстан Язучылар союзы оештырылуга 50 ел тулуга багышланган җыелышы булды.

Җыелышны ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Җыелышта КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады. Ул республика Язучылар союзына Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды.

Җыелышта чыгыш ясадылар: Татарстан АССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миннуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре М. М. Годенко, КПСС Үзәк Комитеты членлыгына кандидат, КамАЗның кою заводы ремонтчылар бригадиры Г. С. Баштанюк, СССРның халык художнигы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты Х. А. Якупов, Казан шәһәре, КПССның Бауман райкомы беренче секретаре В. Н. Липужина, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Л. И. Ошанин, СССРның халык артисты, СССР Верховный Советы депутаты Ш. Х. Биктемиров, РСФСРның халык артисты, композитор Р. М. Яхин, Арча районының «Искра» колхозы председателе Ф. Г. Галиев, РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким, СССР литфонды председателе урынбасары В. А. Хохлов, Татарстан АССР Язучылар союзының рус әдәбияты һәм тәрҗемә секциясе председателе Н. Н. Орешина, Мари АССР Язучылар союзы идарәсе председателе Н. Ф. Рыбаков, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Д. К. Шәяхмәтов.

Җыелышта катнашучылар КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш К. У. Черненконың СССР Язучылар союзы идарәсенең юбилей Пленумындагы рече яктылыгында республика партия оешмалары, иҗат коллективлары һәм культура учреждениеләре алдында торган бурычларны тикшерделәр.

Җыелышта катнашучылар КПСС Үзәк Комитетына, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш К. У. Черненкога тәбрикләү хаты җибәрделәр.

Җыелыш эшендә КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар, республиканың партия, совет, профсоюз, комсомол органнары вәкилләре, КПССның шәһәр һәм район комитетлары секретарьлары, халык депутатларының район һәм шәһәр Советлары башкарма комитетлары председательләре урынбасарлары, культура бүлеге мөдирләре катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

26 декабрьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды. Көн тәртибенә шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов иҗатын тикшерү куелган иде. Докладчы Х. Әюпов аның әсәрләренә югары бәя бирде, аларның бүгенге поэзиядә тоткан урынын күрсәтте. Чыгыш ясаучылардан Н. Арсланов, Г. Ахунов, Р. Гатауллин, М. Хуҗин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Б. Гыйззәт, Ф. Зөлкарнәев, М. Әгъләмов шагыйрьнең иҗатына төрле яклап анализ ясадылар, үзләренең уй-теләкләрен белдерделәр.

## УҢАЙ ГЕРОЙ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

27 ноябрьда «Казан утлары» журналы редакциясе һәм Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе инициативасы белән уздырылган зур җыелышта республикабыз әдипләре «Сиксәненче еллар татар әдәбиятында уңай герой» дигән темага сөйләштеләр. Докладлар белән чыккан Мансур Вәлиев (проза), Ф. Зөлкарнәев (поэзия), Б. Гыйззәт (драматургия) бу мәсьәләнең һәр жанрда ничек торышын яктырттылар, игътибарга лаек әсәрләргә һәм геройларга тукталдылар.

Фикер алышуда катнашкан Г. Бәширов, И. Нуруллин, Г. Ахунов, А. Әхмәдуллин, Мәхмүт Хәсәнов, Р. Мостафин, Ф. Галимуллин куелган проблеманы яңа мисаллар белән тулыландырдылар, аның яңа кызыклы катламнарына тукталдылар.

Сөйләшүне «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис һәм Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе председателе Ф. Мусин алып барды.

## ТУКАЙ КЛУБЫНДА — АЭС ТӨЗҮЧЕЛӘР

«Казан утлары» журналы редакциясе, Кама Аланында АЭС төзелә башлаган көннәрдән алып, төзүчеләр белән иҗади хезмәттәшлек договоры һәм әдәби пост төзегән иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, АЭСта күп санлы әдәби очрашулар, шигырь кичәләре булды.

14 декабрьда язучылар белән төзүчеләрнең чираттагы дуслык кичәсенә «КамГЭС энергострой»ның йортлар төзү комбинатының 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәлахов, РСФСРның атказанган төзүчесе, буяучылар бригадиры Алия Вәлиева, күзәнәк-

ле бетон заводы бригадиры Ясир Моратов, йортлар төзү комбинаты инженеры Нариман Габдрахманов, әдәби пост штабы члены язучы Газиз Кашаповлар килде. Алрның чыгышлары тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Язучылардан «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Г. Ахунов, Н. Дәүли, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтжанов, Р. Миңнуллин, Э. Шәрифуллина һәм Р. Хәлиуллиналар кунакларга яңа әсәрләрен укыдылар. Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин төзүчеләргә бүгенге әдәбиятның актуаль мәсьәләләре турында сөйләде. Соныннан язучылар тарафыннан АЭС төзүчеләре өчен 300 дән артык китап бүләк ителде. Дуслык кичәсе Казан телевидениесе буенча да күрсәтелде.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

28 октябрьда Тбилиси шәһәрендә Азия һәм Африка халыклары белән солидарлык буенча V Совет конференциясе булып узды. Конференция тынычлыкны ныгыту һәм империализмга каршы көрәшнең актуаль мәсьәләләрен тикшерде. Азия һәм Африка халыкларының бердәмлек хәрәкәтен үстерүдә совет җәмәгатьчелегенең бурычларын билгеләде.

Конференциядә Татарстаннан делегат булып ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов һәм Казан университеты профессоры К. Ф. Фасеев катнашты. Конференция Азия һәм Африка халыклары белән бердәмлек буенча Совет комитетының яңа составын сайлады. Аның членнары арасында Ә. Б. Баһаветдинов, К. Ф. Фасеев, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының сектор мөдире Н. Г. Юзиев һәм ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин иптәшләр бар.

## МАМАДЫШТА МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

6—9 октябрьда Мамадыш районында Татарстан Композиторлар союзы идарәсенең күчмә пленумы һәм музыка фестивале булып узды.

«Татарстан композиторлары — авыл хезмәтчәннәренә» дигән девизлы бу күчмә пленум һәм музыка фестивален Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин ачты.

Районның яңа культура йортын һәм музыка бәйрәмен ачу тантанасында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, ТАССР Культура министры урынбасары М. Т. Низамиев, КПССның Мамадыш район комитеты секретаре Б. Г. Ильин һ. б. иптәшләр чыгыш ясадылар.

## КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

24 октябрьда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты күренекле татар совет галиме, тәнкыйтьче һәм педагог, филология фәннәре докторы, профессор Латыйф Җәләйнең тууына 90 ел тулуга багышлап Гыйльми совет утырышы үткәрде.

Латыйф Җәләйнең тормышы һәм фәнни эшчәнлеге турында филология фәннәре кандидаты Н. Б. Борһанова доклад ясады. Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы В. Хаков чыгышы да галимнең татар тел белеме өлкәсенә керткән өлешен яктыртуга багышланган иде. Тарих фәннәре докторы, профессор М. Х. Мөхәррәмов, филология фәннәре докторы Г. Халит, Л. Җәләйнең сеңелесе Л. Хәсәнова юбиляр турында истәлекләр сөйләделәр. Шул ук көннәрдә институтның тел секторы тарафыннан әзерләнгән һәм профессор Латыйф Җәләйнең якты истәлегенә багышланган «Татар тел белеме буенча тикшеренүләр» дигән китап дөнья күрде.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

19 ноябрьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты Марсель Сәлимҗановка 50 яшь, аның сәхнә эшчәнлегенә 25 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне ТАССР Культура министры урынбасары М. Т. Низамиев ачты. М. Сәлимҗановның иҗаты турында Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе Р. А. Җиһаншина сөйләде.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады. Ул юбилярны кайнар котлады һәм аңа КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасын тапшырды.

Юбилей кичәсендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнаштылар.

* * *

16 ноябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Бөек Ватан сугышы ветераны шагыйрь Нур Гайсинга 70 яшь тулу уңае белән иҗат кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында каләмдәше Ж. Тәрҗеманов сөйләде.

Соңыннан юбиляр әсәрләреннән төзелгән зур концерт булды.

## МУСА ҖӘЛИЛ ЗЕМЛЯНКАСЫ

Татарстан дәүләт музееи тулыландырган экспонатлар Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилнең сугышчан юлының яңа битләрен ача. Экспонатлар арасында фронтта ул файдаланган язу машинкасы, редакциянең сейфы, керосин лампасы, наушниклы радиоалгыч бар. Аларны бирега В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары китерде.

Билгеле булганча, Бөек Ватан сугышының башыннан алып политрук М. Җәлил Волхов

фронтындагы икенче удар армиянең «Отвага» газетасына языша, редакциядә эшли.

Студентлар Новгород өлкәсенең сазлык эчендә утырган урманында шул чорда редакция урнашкан землянканы табалар. Бирелә Җәлилнең һәм аның иптәшләренең әйберләре сакланган була.

## ТАТАР ПОЭЗИЯСЕ УКРАИН ТЕЛЕНДӘ

Күптән түгел Днепропетровскидагы «Промiнь» нәшриятында татар шагыйрьләренең әсәрләреннән тупланган китап басылып чыкты. «Сип нурыны, Чулпан-йолдыз» дип аталган бу җыентык — татар поэзиясенең кечерәк антологиясе рәвешендә төзелгән. Анда Г. Тукайдан алып бүгенге яшь шагыйрьләргә кадәр буынга урын бирелгән.

Шигырьләрне күренекле украин шагыйрьләре тәрҗемә иткәннәр.

## ӘДӘБИ МИРАС КОМИССИЯЛӘРЕ ОТЧЕТЫ

1 ноябрьда Татарстан Язучылар союзының Өлкәннәр советы утырышында әдипләрнең әдәби мирас мәсьәләсе каралды. Хәсән Туфанның әдәби мирас комиссиясе председателе Ш. Галиев отчеты тыңланды. Әдәбиятыбызның классигы Хәсән Туфанның истәлеген мәңгеләштерү, мирасын өйрәнү һәм матбугатка әзерләү, әсәрләрен татарча һәм тәрҗемә итеп чыгару буенча башкарылган эшләр турында сүз булды. Якын арадагы бурычларның берсе — Хәсән Туфан турында истәлекләр китабын әзерләү. Китапның төзүчесе шагыйрь Х. Әюпов. Хәсән Туфан турындагы истәлекләрне, документларны, аңа багышланган әсәрләрне һәм фотоларны, аның автографларын эченә алачак ул китап. Шагыйрьне якыннан белгән һәркемнең катнашуы көтелә.

## ЯҢА ОРАТОРИЯ

24 ноябрьда Казан консерваториясенең Актлар залында Мәскәү композиторы Екатерина Кожевникованың «Мулланур» дигән ораториясенең премьерасы булды. Оратория Ренат Харис поэмасы буенча иҗат ителгән. Ул ленинчы-революционер Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулуга багышланган.

## РИГАДА ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

7 декабрьда латыш совет язучысы, публицист, әдәбият белгече һәм дәүләт эшлеклесе Андрей Упитның Ригадагы мемориаль музеенда латыш һәм татар әдәбиятлары дуслыгына багышланган кичә булды. Әлеге очрашуда Татарстаннан филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллин, прозаик М. Насыйбуллин һәм шагыйрь З. Мансуров ике тугандаш халык арасындагы культура бәйләнешләре турында сөйләделәр.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

СССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 16 ноябрь Указы белән, совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм СССР Язучылар союзы төзелүнең 50 еллыгы уңаеннан язучы Гариф Ахунов Халыклар Дуслыгы ордены белән, драматург Туфан Миңнуллин «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнделәр.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш дирижеры Владимир Михайлович Васильевка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 18 сентябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен әдәби тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 24 сентябрь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татарстан АССР Дәүләт филармониясенең эстрада җырчысы Зөһрә Сәхабиевага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 24 сентябрь Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңаеннан РСФСРның атказанган художнигы Васил Маликович Маликов КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Озак еллар нәтиҗәле әдәби эшчәнлеге өчен һәм 70 яше тулу уңаеннан язучы Нур Гайсин КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник-график, СССР Художниклар союзы члены Тавил Гыйниятович Хаҗиәхмәтовка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 10 декабрь Указы белән, «Татарстан АССРның халык художнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

*Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары.*

## Нурмөхәммәт Хисамов



Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов 1937 елның 24 мартында Татарстанның Чүпрәле районы Мунчәли авылында туган. Урта мәктәп бетергәч, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, район газетасында хезмәткәр, күп тиражлы газета редакторы булып эшли, КДУның татар әдәбияты кафедрасында аспирантурада укый. 1980 елда ул Мәскәүдә А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында Кол Гали иҗатына багышланган кандидатлык диссертациясе яклый. Бүгенге көндә Н. Хисамов — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, тарих һәм әдәбият институтында өлкән фәнни хезмәткәр. КПСС члены.

1967 елда аның Казанда «Яз миңа чәчәкләр китерә» исемле шигырьләр җыентыгы, 1979 елда Мәскәүдә «Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али» китабы дөнья күрде.

## Наип Лаисов



Наип Хәбибнаҗар улы Лаисов 1935 елның 10 августында Актаныш районының Түбән Яхшый авылында туган. 1954 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1962 елда Алабуга педагогия институтын тәмамлаганнан соң, рус әдәбияты кафедрасында эшкә калдырыла. 1971 елдан филология факультетында декан ярдәмчесе, аннары декан булып эшли. Хәзерге көндә — шул ук институтның укыту эше буенча проректоры. КПСС члены.

1976 елда Н. Лаисовның «Тукай лирикасы» исемле китабы дөнья күрде. Ул — 1979 елда чыккан «Әдәбият теориясе» исемле кулланма авторларыннан берсе.

## Роберт Рәкыйпов



Роберт Җиһанша улы Рәкыйпов (Рәкыйп Чокалый) 1936 елның 10 ноябрендә Чүпрәле районының Яңа Чокалы авылында туган. Иске Чүпрәле урта мәктәбен тәмамлагач, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Чүпрәле районында укытучы һәм мәктәп директоры булып эшли. Хәзер Әлмәт интернат-мәктәбендә физика-математика укыта. 1970 елда Казан университетының механика-математика факультетын тәмамлый. КПСС члены.

1975 елда «Идел» альманахында аның беренче повесте басылып чыкты. 1981 елда Р. Рәкыйповның «Сагыну», ә 1983 елда «Сиңа гына ачам күңелемне» исемле шигырь китаплары дөнья күрде.

# ҖӘЛИЛЧЕЛӘР

«Безнең илебездә халык файдасына булган бер омтылыш та үлми, югалмый, илтифатсыз һәм хөрмәтсез калмый...» Күренекле рус совет шагыйре М. Луконин күп милләтле поэзиянең данлы бер вәкиле М. Җәлилнең үлемсез каһарманлыгы турында әнә шундый тирән мәгънәле сүзләр язып калдырды.

Чыннан да батырлык онытылмый, һәм ул күпләрне иҗатка да рухландыра. Әйтик, сынлы сәнгать осталары Җәлил батырлыгына һәм аның ялкынлы поэзиясенә багышланган уннарча тематик картина, скульптура портретлары, серияләп-серияләп графика әсәрләре иҗат иттеләр. Шулар арасыннан Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» исемле картинасы, Б. Урманченың мәрмәрдән, В. Маликовның чүкелгән тимердән эшләнгән портрет-бюстлары патриот шагыйрь образын калку гәүдәләндерүләре ягыннан аерылып торалар, һәм алар хаклы рәвештә сәнгать сөючеләрнең зур мәхәббәтен казандылар.

Әлеге тематика буенча җитмешенче елларда иҗат ителгән әсәрләрдә образның эчке куәтен бөтен катлаулылыгында ачуга күбрәк игътибар бирү сизелмәнә. Шушы юнәлештәге эзләнүләр барышында рәссамнарыбыз монументаль-декоратив сәнгать белән графика мөмкинлекләреннән шактый оста файдаланалар. Жанрларның органик төстә кушылуы исә гаять үзенчәлекле әсәрләр тууга китерә. Мәсәлән, Искәндәр Рафиковның «Җәлилчеләр» картинасында (1975) мондый эзләнүләр аеруча ачык күренә.

Җәлилчеләр... Богауланган куллары белән бер-берсен кочаклап һәм шул рәвешле тыгыз түгәрәк хасил итеп, алар беравыздан шундый сүзләрне кабатлыйлар шикелле: «Бирмә биленне, бирмә илеңне!..» Теләсә нинди авыр сынауларда да өстен булып калучы туганлык һәм бердәмлек безнең халыкта әнә шулай түгәрәкләнеп басу белән дә белдерелә. Композициянең мондый нигезгә корылуы исә әсәрнең тормышчанлыгын бермә-бер арттыра.

«Җәлилчеләр» картинасы өстендә рәссам шактый еллар эшли һәм, ниһаять, соңгы вариантта табылган композицион башлангычны көчәйтүгә ирешә. Вакыйганың урынын һәм геройларның төс-башын сурәтләүдә натуралистик детальләрдән мөмкин кадәр качып (бары тик Муса йөзе генә портрет төгәллегендә бирелгән), автор үзенең игътибарын Батырлыкны зуррак планда күрсәтүгә күбрәк юнәлдергән. Картина ирекле кул хәрәкәтләре, эскиз алымы белән ясалган. Тоташ һәм шулай ук «сынык» сызыклар белән сурәтләнгән иңбаш чыгынтылары, үзара «бәйләнешеп» беткән куллар, кырыс йөзләр... Башкисәрләр алдына алар менә шундый какшамас монолитка әверелеп басканнар. Әлеге фигураның киеренке пластикасы, соргылт-карасу төсләр гаммасы һәм урыны-урыны белән кандай саркып чыккан кызыллык... Кыскасы, бөтенесе дә җәлилчеләрнең бетмәс-төкәнмәс эчке куәткә, коммунистик рух ныклыгына ия булуларын искәртәләр.

Розалина ШАҺИЕВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов.

**Рөстәм Мансуров** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)